# КАЗАН УТЛАРЫ

3. 1991





**Исмәгыйль бәк Гаспринский**
**(Гаспралы)**
**(1830—1914)**

# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

ТАТАРСТАН
ЯЗУЧЫЛАР
БЕРЛЕГЕ
ЖУРНАЛЫ

1922 ЕЛНЫҢ
МАЙ АЕННАН
БАШЛАП ЧЫГА

1991

3

ТАТАРСТАН
ГАЗЕТА
ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ

КАЗАН

## *Бу санда*

ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Р. ГАТАШ. Гомер-баг капкасын ачсам... *Шигырьләр* . . . 3
К. БУЛАТОВА. Яңа шигырьләр . . . 8
Ф. САДРИЕВ. Адәм әүлиясе. *Юмористик повесть* . . . 11
Ш. МАННАП. Ибрай абзый хикәятләре . . . 69
Р. ВӘЛИЕВА. Дәреслек. *Шигырьләр* . . . 76
Ш. ҖИҺАНГИРОВА. Бер адымга гына. *Шигырьләр* . . . 77
И. ИКСАНОВА. Белми әле дөнья. *Шигырьләр* . . . 78
Ф. МӨСЛИМОВА. Ике фәлсәфә. *Шигырьләр* . . . 80
Л. САДЫЙКОВА. Сөлге чигәм. *Шигырьләр* . . . 81
Ф. БӘШИРОВА. Кошчык. *Шигырьләр* . . . 82
ТАҢЧУЛПАН. Шигырьләр . . . 83
Л. БУЖУРОВА. Зарыгу. *Шигырьләр* . . . 84
Т. ГАНИЕВА. Истанбуллар искә сирәк төшә. *Шигырьләр* . . . 86

ӘДӘБИ МИРАС

С. САБИРОВ. Авыр язмыш *(С. Җәләлнең тууына 100 ел)* . . . 87
С. ҖӘЛӘЛ. Дим буенда . . . 90

ПУБЛИЦИСТИКА

И. НУРУЛЛИН. Әдип эзләреннән — Төркиядә . . . 133

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Ф. ГАЛИМУЛЛИН. Күзгебездә нилә чагыла? . . . 147
А. САДЫЙКОВА. Осталык тамырлары — халыкта . . . 153
Ф. ИБРАҺИМОВА. Ул галим дә иде. *(А. Шамовның тууына 90 ел тулу уңаеннан)* . . . 157

КИТАП КҮЗӘТҮ

М. ӘХМӘТҖАНОВ. Хәбәрдарлык чорында язылган хезмәт . . . 160

МӘДӘНИЯТЕБЕЗ ТАРИХЫНА

Т. КАМАЛ. Татар рухы . . . 163

*Баш мөхәррир*

РАВИЛ ФӘЙЗУЛЛИН

*Редколлегия*

ГАРИФ АХУНОВ
МАРСЕЛЬ ГАЛИЕВ
МИРКАСЫЙМ ГОСМАНОВ
АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ
МАРСЕЛЬ ЗАРИПОВ
ФЛҮС ЛАТЫЙФИ
*(җаваплы сәркәтип)*
МӘДИНӘ МАЛИКОВА
САЛИХ МАННАПОВ
ФӘРВАЗ МИННУЛЛИН
ФЛҮН МУСИН
МАРАТ МӨЛЕКОВ
РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВ
РАШАТ НИЗАМИЕВ
*(баш мөхәррир урынбасары)*
ГӘРӘЙ РӘХИМ
КОЯШ ТИМБИКОВА
*(бүлек мөхәррире)*
МӨДӘРРИС ӘГЪЛӘМОВ
ТӘҮФИКЪ ӘЙДИ
*(бүлек мөхәррире)*
АЗАТ ӘХМӘДУЛЛИН

Безнең адрес: 420066,
Казан, Декабристлар ур., 2

Телефоннар:
баш мөхәррир — 53-07-60,
баш мөхәррир урынбасары —
53-07-09,
җаваплы сәркәтип — 53-07-09.

*бүлекләр:*

чәчмә әсәрләр, шигърият,
очерк — 53-07-61,
тәнкыйть, фән, сәнгать,
хатлар — 53-07-63,
корректорлар — 53-07-65.



Р. САФАРОВ. Төрки халыкларның уртак каһарманы . . . 167
Ф. ӘМИРХАН. Олуг милләтче турында кечкенә бер хатирә . . . 169

СӘНГАТЬ

К. ТИМБИКОВА. Сәхнәләрдә — йолдыз . . . 170

УКУЧЫ СҮЗЕ

Хатлардан юллар . . . 176
Г. САТТАРОВ. Шәһри Болгар. *Шигырьләр* . . . 183

Гарәп әлифбасы нигезендә татарча уку күнекмәләре . . . 185
Котлыйбыз . . . 187
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан . . . 190
Тышлыктагы сурәтләр . . . 192

## В НАШЕМ НОМЕРЕ

«Проза и поэзия»: Повесть Ф. САДРИЕВА «Святой человек»; рассказы Ш. МАННАПОВА; новые стихи Р. ГАТАУЛЛИНА, К. БУЛАТОВОЙ, Р. ВАЛИЕВОЙ, Ш. ЖИГАНГИРОВОЙ, И. ИКСАНОВОЙ, Ф. МУСЛИМОВОЙ, Л. САДЫКОВОЙ, Ф. БАШИРОВОЙ, ТАНЧУЛПАН, Л. БУДЖУРОВОЙ, Т. ГАНЕЕВОЙ.
«Литературное наследие»: к 100-летию со дня рождения С. Джаляла статья С. САБИРОВА «Тяжкая судьба»; повесть С. ДЖАЛЯЛА «На берегах Дёмы».
«Публицистика»: статья И. НУРУЛЛИНА «По следам Г. Исхаки в Турцию».
«Литературная критика»: статья Ф. ГАЛИМУЛЛИНА о проблемах татарской литературы; статья А. САДЫКОВОЙ «Корни мастерства — в народе», статья Ф. ИБРАГИМОВОЙ к 90-летию со дня рождения А. Шамова.
«Книжное обозрение»: М. АХМЕТЗЯНОВ рецензирует книгу А. Каримуллина «Становление и развитие татарской советской книги».
«К истории культуры»: статья Т. КАМАЛА «Татарский дух»; К 140-летию со дня рождения видного просветителя, ученого И. Гаспринского публикуется статья Р. САФАРОВА «Общий герой тюркских народов» и воспоминание Ф. Амирхана.
«Искусство»: очерк К. ТИМБИКОВОЙ о творчестве певицы В. Гизатуллиной.
«Слово читателя»: строки из писем, стихи Г. САТТАРОВА.
Навыки чтения на основе арабской графики.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: памятники татарской архитектуры — мечеть в деревне Ахметьево Заинского района; известный татарский писатель Ахмет Исхак.

*Бүлек мөхәррирләре:* Мансур Вәлиев, Рәдиф Гатауллин.
*Мөхәррирләр:* Нияз Акмалов, Шамил Маннапов, Рәшит Әхмәтҗанов.
*Төзәтүчеләр:* Л. Гатауллина, Г. Моратова, Ф. Сабирова, Г. Сибгатуллина, Г. Хөсетдинова.

Производствога бирелде 11.01.1991 ел. Басарга кул куелды 22.03.1991 ел. Офсет ысулы белән басылды. Кәгазь форматы 70×108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8).
Тираж 41199. Заказ И-12. Бәясе 1 сум 50 тиен.

Татарстан газета һәм журналлар нәшрияты басмаханәсе.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 1991 ел

## Рэдиф Гаташ

# ГОМЕР-БАГ КАПКАСЫН АЧСАМ...

* * *

Бөгеп, без уйнаган таллар... Кара! —
Алар нинди биек!
Сыймый без йөргән урамнар — бүген
Тын, буш оя кебек...

Тәрәзләрең, авыл, яшьләр азга
Моңсуланганмы соң?
Күкне дә, дим, иңнәреңдә картлар
Тотып торамы соң?

Нинди гамь соң, нинди сыйфат киткән
Авыл кешесеннән?
Туган — туганына кырын карый,
Күрше — күршесенә...

Исереклек, әдәпсезлек, буш сүз
Каян әле арткан?
Иман качып бик тиз, ни ул шулай
Үз юлына тарткан?!

Шул хәлләрдән оялыпмы —
Таллар
Күккә карап үскән?!

Яшьлегемдә түгел, бу авылда
Сине бүген күрсәм,
Матурлыкны,
Мәхәббәтнең үзен
Табар идем микән?!

...Ярый очрашканбыз вакытында,
Вакытында, ахры, туганбыз да:
Бәхетлебез икән!

Хәятта ачылып капка,
Багка — матурлыкка баксам,
Хыял күлләренә батсам,
Дәрткә дәрман шул булырмы?

Гөлчәчәккә якын барсам,
Чәнечкесенә кадалсам,
Гомерлек җәрәхәт алсам,
Дәвачы да ул булырмы?

Китә алмыйча шул багтан,
Үз иркемнән әсир калсам,
Күңел җәем багышласам,
Җимешләрем мул булырмы?

Күз сулышын сизеп беркөн,
Мәңгелеккә җыенсам мин,
Баг аңлармы актык сүзем?!
Йә тәмам хафа булырмы?

Гөлчәчәк минсез сулырмы —
Гомер-баг капкасын япсам...

Күңел, һаман эзлисең ни? Һәм каян?
Чик булырмы омтылышка бер заман?

Менә бүген дә синең хыял кошы
Әллә бәйдән ычкындымы — әй очты!

Күккәме — юл? Йә җиргә төшәргәме?!
Юл башыннан — чишмәдән эчәргәме?

Үзгәргәндер ул төбәк вакыт узгач...
...Яз иде безнең яшьлектә, нур-кояш...

Соры тузан күмсә ак чәчәк-серне?!
Яшерсә еллар ярны — бердәнберне?..

...Күкрәде күк, яшенләп койды яңгыр...
Гомер керен юаргадыр? Шул фалдыр...

Бер тапсыз ак җандагы кыз сурәте:
Җыр язарга — матурлыкка өйрәтте...

Аны бүгенге мохиттән эзлимме?
Яшьлек, әйт, сиңа хыянәт түгелме? —

Гел биектә сакладык бит яр-дусны!—
Нәфестән гел өстен калсын җан кошы!

## Сосна Пүчинкәсе авылы зиратында

Әкрен, әй, җил,
тын да тыңла:
Монда — Тукай әнкәсе...

Чишмә җырлый. Гүя, ул да
Шул әнкәнең тәңкәсе,
Йә моңлы чулпы тавышы.

...Кызларның судан кайтышы...
(Тыңла, шагыйрь әнкәсе!)

Һәр татар кызы баш исен
Бөек Ана каберенә.
Шаулый каеннар... Ул инде
Күчкән халык бәгъренә:
Монда бары кабер ташы
Сөйли: «Тукай әнкәсе...»

Ә чишмәләр тынмый җырлый:
— Сасна кызлары, исән бит
Мәмдүдәнең таңкасе,
Чулпылары?
Мирас итте
Якты моңын, ак күңелен
Сезгә — шагыйрь әнкәсе...
Сездә — чулпы, таңкасе.

## 1913 елның җәе. Зәйтүнә — Тукай каберендә

Халкың уяна... Сиңа соң
ул каян иңгән йокы?!
Шагыйрь, тор, кабрең янында
кем әнә корьән укый?!

Исемен мактаган китабы —
чын Кәләмулла кулда;
Күз салмый аңа — яттан ла
ялкынлы сүрә укый!

«Васыят»еңне дәфенеңдә
яңгыратты муллалар,
Ул кушып күк аятьләрен,
кыз хисен — бергә — укый!

...Яд итәр гомере буена:
диварда рәсмең торыр!
Хаҗ юлын багышлар сиңа —
бел, Мәккәләрдә укый!

* * *

...Киләчәк әле күрәчәк:
табыныр чын кәгъбә — син,
Бу шуннан хәбәр — күр: әнкәң
яшедәй саф җан укый!

«Мәхәббәт сакчысы» киткән:
бу мәңгелекнең йорты,
Тузан күк гөнаһы юктыр —
керсез пакь иман! — укый!

Җирдә әллә Гайсәнеме
юган хатыннар өне?!
Татар кызы ул — кабреңә
фәрештәң килгән! — укый!

Инде, Тукай, нәкъ мамык күк
җиңелдер кабрең ташы?! —
Баш очында... әнә ярың —
Зәйтүнәң корьән укый!

*

Чит-ят җирнең үз итмәгәч кояшы,
Йөзем үскән яктан кабат күчендек...
Кан кардәшләр илгә кайта: — Туфрак, аһ!
Бабайлар ник сиңдә калган — төшендек!

*

Шаулы заманның болганчык су-җыры
Күпләрне моң чишмәсеннән аерды...
Колак түгел, җанда сафланып болак,
Ул бәндәләр, дим, ялганнан айнырмы?

*

Яр данлаган Хафизны кызганган бер —
Ярлы санап, аяган Аксак Тимер...
Хафиз җыры ничә җанны баеткан! —
Синең байлык кайда? Сөйлә, җиһангир!

*

Илаһ саз, син тоташ моңнан гыйбарәт,
Нинди көчләр кылларында, тәңрем, әйт?!
...Сезнең шул саз да уятмый — таш җанмы,
Шундый без бүген, әй, Тукай, Дәрдемәнд!

*

Тукай да сәяхәт иткән... җай булган.
Әстерхан, Уфада озак — ай булган...
Пәйтәхетне дә күргән... тик, горур,
Рух тәхтендә чын таҗлы Тукай булган!

*

Ялгыз булганмы Тукай? — Юк, бәхеткә...
Казанда таянган Фатих, Сәгыйтькә...
Гаязга дәшкән, «Кайтчы!» — дип. Сыйган бит
Берьюлы ничә арыслан тәхеткә!

*

Килмәдең син... көткәннеме белмәдең?
Үзең түгел, сәламең дә — килмәде...

Горурлыгың баш бирмиме, башкамы?
Ни булса да, күңел күккә ашмады...

Шулай утка салып мине, кыз бала,
Уйда үртисеңме: — «Ян ла, сызлан ла...

Файда гына сиңа андый сызлану;
Тын күңелне кузгатачак ул яну —

Тойгы җилең белән моң-зар бетәчәк;
Җыр барсын да юып, пакьләп китәчәк...»

Борынгылар зирәклеге ахрысы
Яшь җанында! — төшә миңа яктысы.

Бәяң белепме бу якка килмәдең?
Үкенеч: хәтта ки хатта килмәдең...

*

Бу җиһанда нинди фал ул — Кигәвен?
Хозур күрсәк бакча я кыр гөлләрен,
Акыл һәм хис тудырган дөнья ямен,—
— Мин дә бар! — дип, борнын суза Кигәвен.

Матурлыкның колы без, мәңге гашыйк;
Хисләребез сугара, җаннан ташып,—
Ашлыйбыз еллар буе рух гөлләрен...
Шунда бер тәнкыйтьче мәллә Кигәвен?!

Мәхрүмме ул моң аңлаудан, көнчеме?
Йә көчсезлеген сизеп, еш тешлиме?!
Таһир-Зөһрә багында сакчы ләгыйнь —
Кара батырмы бер — әрсез Кигәвен?!

Җәйге дөнья вәгъдә итә җимешне,
Иҗат көзе булыр камил, килешле.
Тик туйдырды шул ят кавем — фиргавен! —
Һәр бәхетнең сагында ник Кигәвен?!

Гомерләрнең шул матур бакча ямен,
Күңелләрнең кабатланмас гөлләрен
Яклау — сәнгать безгә: җыр тик шул юлда...
Гаҗәп: мин дә шунда, дисең, Кигәвен!

## Клара Булатова

# ЯҢА ШИГЫРЬЛӘР

### Борчулы җәй

Ялгызыма кайгы килсә
Уртаклашам мендәр белән...

Бу бит — илгә, көнгә килгән,
Борчылмыйдыр кемнәр генә:
Гел Тукайдан алынгандай —
«Кыза дөнья, сабыр җитми».
Тик сабырлык җитсә генә
Өмет сүнми, тамыр кипми.

Тамырларны корытырлык
Хата ясап куйдыкмы әллә?
Шуның белән табигатьнең
Сабырлыгын җуйдык мәллә?

### Бәхетлеләр шунда гомер итә

Ерактагы дуслар якынрак,
Ерактагы кояш җылырак...
Шулай дипме чыгып киткән идең,
Кайтып килдең нинди уй уйлап?

Ниләр генә уйлап әйләнсәң дә
Борылганга — ачык бу капка.
Үз башыннан кичкән кире какмас:
Җан тартмаса,монда кан тарта.

Үзең туып-үскән туфрагыңның
Һәр карышы — бакый терелек.
Бәхетлеләр шунда гомер итә
Җаны-тәне белән берегеп.

*

Тигез генә, туры гына түгел,
Кылдан нечкә булган бу тормыш:
Асты — өскә килгән дөнья бүген,
Чакрым саен җиде борылыш.

Дилбегәләр кем кулында бүген,
Кем кулында бүген тезгенең?
Кем токарлый сикерешен көннең,
Үтәр булып заман тизлеген?

Минем аңнан сорау китми һаман,
Ә җавабын бирми бу тормыш....
Юл чуалган, юл маяксыз калган,
Чакрым саен җиде борылыш.

---

Клара **БУЛАТОВА** — *танылган шагыйрә, «Язлар алда», «Җәйләр җитсә», «Марс китабы» һ. б. лирика һәм балалар өчен китаплар авторы. Әлмәттә яши.*

*Чукча шагыйрәсе Антонина Кымытвальга*

Болай гына, очраклылык белән
Бер шигырең кулга эләкте.
Замандашым,
Егерме ел элек
Барыбыз да, күрче, нихәтле
Садә булганбыз бит!..
Кара инде,
Кайтып кара, нәрсә язасың?!
«Чукча халкы ерак йолдызларда
Чәй эчәр»,— дип хыялланасың...
Татарлар да безнең чәй ярата,
Кызганычка каршы, бүгенгә
Ерак йолдызларга менеп түгел,

Чәй эчәлмим хәтта өемдә.
Белмим, Тоны,
анда сезнекеләр
«Чайпауркын» итә ни белән?
Ә мин әле инәйдән хат алдым,
«Кибетләрдә чәй юк», диелгән.
Чәй бетте бит,
белмим кая китте?
Үстермибез
нигә?..
Белмибез.
Ерак йолдызлар дип хыялланып,
Буш калдымы әллә илебез?..

Юк кебек сәбәпләр дә...
Ник әле күңел алгысый
Иртәнгә сәгатьләрдә?

Чыгыплар китәр идем!
Җибәрми сабый чакларым,
Яшьлегем үткән җирем...

Агачлар яфрак ачмаган,
Әле бередә генә.
Бөредәй күңел түрендә
Нидер өлгерә менә.

Уянып язлар килүгә
Тибрәлгән кебек дөнья,

Һаман да сине күрүгә
Йөрәгем тибрәп куя.

Наратта кучкыл яшеллек,
Каенда — яшерене.
Нараттай — хисне ачыйммы,
Каендай — яшеримме?

Җанга сыймас моңнар тудырган
Өнсез-тынсыз кара төннәр серен
Куертарак төште бу буран.

Җил күтәрсә читен пәрдәнең,
Мин уйлаган идем, эчке төсе
Ачылыр дип төнге хәлләрнең...

Ачылмады. Алай булмады.
Буран купты. Тынлык юкка чыкты.
Башы-соңы эзнең югалды...

Ташлар тәгәрәтер көче булган
Елгаларны буу җиңелме соң?
Үз иреген дәгъвалаучы бу җан
Шулар белән тиңдәш түгелме соң?

Ташлар тәгәрәтер көче барда
Агым суга каршы торып кара,
Кайнаганда ярсу хисе җанда,
Шул ярсуга каршы чыгып кара.

Япь-яшь килеш мин яшәүдән туйдым,—
Гаеплесе аның син генә,
Мин дөньяга ышанычым җуйдым —
Гаеплесе аның син генә.

Ут йотудан эчем-тышым янды,—
Гаеплесе аның син генә.
Мәхәббәттән эче нәфрәт калды —
Гаеплесе аның син генә.

Әгәр тормыш сине алдый икән,
Ачуланма, каш та җыерма,
Йөрәгеңне учларыңа кысып
Тор да бер тын упкын кырында,

Кушучыңны күкрәгеңә куеп,
Кире борыл яшәү ягына.
...Бу тормышта андый алданулар
Берни тормый яшәү алдында.

Сылу таллар...
Нишли алар,
Күзге итеп Зәй суларын,
Әле үреп, әле сүтеп
Бөдрә-бөдрә толымнарын?
Сылу таллар —
нишли алар,
Су-көзгедән ни сорыйлар?
Суга багып, тарак салып,
Яз башында ни юрыйлар?

Ярда үскән сылу таллар,
Язмыш белән уйнамагыз,
Бәхет көткән гашыйкларга
Аерылулар юрамагыз.—
Язмыш белән уйнамагыз,
Сылу таллар, сылу таллар...

Үлемнән дә курыкмаска кирәк
Ул барыбер килә кайчан да,
Ул барыбер сине таба эзләп,
Курыксаң да, курыкмасаң да.

Ә гөнаһтан курка белү кирәк,
Кача белү кирәк гөнаһтан..

Кылгач тәүбә итү белән түгел,
Кача белү кирәк — кылмастан.

Фасылларның билгеләре
калган безгә,
Хәтирәгә, тик балачак
дәфтәрендә...
Яз-җәйләрнең чиген хәзер
сизмибез дә
Дөнья куу, көн үткәрү хәстәрендә.

**Фоат Садриев**

# АДӘМ ӘҮЛИЯСЕ

ЮМОРИСТИК ПОВЕСТЬ

1



Чаба торгач, Альфред тәмам хәлдән тайды. Ай инде ындыр артындагы коймаларны сытып, бәрәңге сабакларын изә-изә өйләргә таба тәгәрәде. Аның, астрономия китабында язылганча, таулары да, кратерлары да, тузанлы туфрагы да юк, ул өске өлеше болытларга ук кереп киткән коточкыч зур чуен шар иде. Аның кайчан төшкәнен дә белүче юк, ай акрын гына авыл өстенә тәгәри, үзеннән алда коточкыч шәүләсе шуыша иде. Күзе тонган халык акырыша-акырыша чабулый, мал-туар үрле-кырлы сикерә, кош-корт пырхылдап оча, бәргәләнә. Ир-ат айның астына бүрәнәләр, ташлар, бастырык һәм күсәкләр тыга, кемнәрдер кувалда белән чөй кага, кемнәрдер көрәк белән балчык өя.

Альфредны шунда колхоз председателе Фазылов уңга алып китә. Ул кесәләренә блокнотлар, ручкалар тулган авыр костюмын, күлмәкләрен салып аяк астына бәрә дә майкадан гына килеш зур корсагы белән кызарып-бүртенеп айны этә башлый. Альфред та җан көченә тырыша, тик ай туктамый, һаман алар өстенә тәгәри. Шул чак ул Убырлы Мөштәфширәнең айны терәткән баскычларны, күсәкләрне кул пычкысы белән кисеп йөрүен күрә.

«Терәүләрне ник кисәсең?» — дип аны тиргәмәкче була Альфред, әмма өлгерә алмый, Шүрәленеке төсле озын бармаклары белән Альфредның чалбар кесәсендәге акчалы конвертны эләктерә дә читкә йөгерә Убырлы.

— Тукта, ул бит кешегә бирәсе акча! — дип кычкыра Альфред һәм аның артыннан ташлана. Ләкин шулчак Илгизә бишекле кызыл мотоциклын аның юлына аркылы куя.

— Әйдә комсомол җыелышына, сине көтеп торалар.

— Убырлы акчаны алып качты, башта шуны куып тотыйк, — ди Альфред.

Илгизә газ бирә, ул мотоциклның бишегенә сикерә дә Убырлы

---

Фоат САДРИЕВ *(1941) — әдип, драматург, «Их, сез, егетләр», «Ач тәрәзәң», «Кондырлы кодачасы» һәм бүтән пьесалар, «Шаһзаманов эше» повесте, хикәяләр авторы. Мөслимдә яши.*

артыннан элдерәләр. Бер читтә этисе белән Ибрайның эчеп утырганы күренеп кала. Мотоцикл һич тә Убырлыны куып җитә алмый. Альфред аягүрә басып тибә-тибә:

— Кызурак, кызурак! — дип кычкырганда бишекнең түбе җимерелеп төшә, ул аның ике читенә ябышып, аяклары белән җирдән йөгерә башлый. Менә алар Мөштәфширә карчыкның ямаулы яшел итәге астына керәләр, итәк югары күтәрелеп җилфер-җилфер килеп бара, кортканың ак төскә эре зәңгәр борчак төшкән ыштаны да күренә, тик нишләптер куып җитә, тота гына алмыйлар.

— Бир акчаны! — ди Альфред ярсып.

— Менә сиңа акча! — Убырлы конвертны авызына кабып чәйни башлый. Куыша торгач, алар Чалмыя елгасының иң текә, иң биек кызыл ярына килеп җиттеләр һәм Убырлы аска очты. Альфред та бар көченә йөгереп килде, ярдан аяклары белән этенеп кортка артыннан сикерде һәм... башы белән дыңк итеп өстәл читенә бәрелде. Аның маңгае тумыштан каты, ә агач аннан да катырак булганлыктан, бәрелү көче йокысын шундук ачты, өстәлдәге бер кефир шешәсе тәгәрәп борынына төшкәч, Альфредның күзеннән утлар күренде. Дөньясының асты өскә килгере! Шушы гына җитмәгән иде!

— Уф! — диде ул башын эчтән лом белән чокуларын тоеп. Суккан саен өттереп чатный. Ул авыз, ул тел! Дөньяда булырга мөмкин булган иң тәмсез әйберләрнең бөтенесен җыеп авыз эчендә изгәннәр дә телне шуның белән аңкауга ябыштырганнар диярсең. Аның ак колгадай гәүдәсе, тире астында гел шуышып торучы бугаз төене, озын беләкләре, эре чәчкә төшерелгән трусигыннан ике көрәк сабы шикелле тырпаеп чыккан аяклары манма су, алар җиңелчә генә калтырыйлар иде. Әле генә күргән төштән ул берничек тә айный алмады. Каян килеп керә диген шундый тузга язмаган чүп-чар! Убырлы Мөштәфширә төшкә керсә юньлегә түгел — моны бөтен авыл шулай ди. Тукта, тукта, ул бит акчаны алды. Әгәр чыннан да... Альфред кабаланып мендәр астына кулын тыкты һәм эсселе-суыклы булып китте. Әнисе авылдан биреп җибәргән конверт юк иде. Аның эче «жу-у» итте. Алганнар! Ул тезләнеп мендәрнең икенче ягын әйләндерде, киез асларын актарды. Зур сары портфеле янына килде, аның эчендәге һәр әйберне селкеп чыкты — конверт юк иде. Урын-җирләрен туздырып атты — акча табылмады. Менә ни өчен төшкә кергән икән ул Убырлы тәре! Болай булгач, мәшәкатьләнеп Казанга килүнең мәгънәсе дә калмады. Шулчак аның күзе шифоньер өстендәге физика китабына төште. Болай гына, аптыраганнан гына ачып караса — конверт исән килеш шунда иде! Болай булгач өмет кала диган сүз. Сәгать ничә соң әле? Йә аллам! Имтихан башланырга ярты сәгать вакыт калган! Ул бит иртүк теге кешенең өенә барып, шушы конвертны тапшырырга тиеш иде. Әнисе: ул кеше үзе институтта эшләми, диде, кемнәрнедер күреп, кемнәр ашадыр хәрәкәт итә, ул сине күреп, белеп калырга тиеш, диде. Бәлкем, ул бәндә әле өеннән чыгып китмәгәндер? Очарга, тизрәк барып җитәргә! Юкса, бөтенесе бетә, җимерелә. Аһ, соңармаган булса! Бүлмәдәге егетләр аны нишләп уятмаганнар, игелексезләр?! Кичтән: «Мин эчемдәге биологик сәгать белән төгәл идарә итә беләм, кайчан телим, шул вакытта минутын минутка торам», — дип мактанмаган булса, уятырлар иде, әлбәттә. Ни пычагыма аракы алып кайтты ул? Егетләр барыбер юньләп капмадылар, берүзе лаякыл исерде. Сезне белмим, мин үзем утта янмаячакмын, суда батмаячакмын, барыбер керәчәкмен, дип тә шапырды бугай. Менә баттың да. Физика бит ул! Төп фән! Аны әзерлексез түгел, башыңны өстәлгә бәрә-бәрә укысаң да таманга туры килә әле. Бөтен өмет — конвертта. Очарга, очарга, җир тишегеннән булса да табарга теге кешене!

Ул кабаланып юынгычка барды, кранны боруга, аның тишеге

«пырых!» итеп пошкырып җибәрде. Альфредның болай да бер нечкә тамырда асылынып торган йөрәге өзелеп төшеп киткәндәй булды. Күп пошкыра торгач, краннан сәйлүн чәе төсле су чыкты, бер чыкты, ике чыкты, аннары ашханәләрдәге чәйгә охшап ага башлады. Альфред бармак очлары белән күзенә шул суны тигереп-тигереп алды да өстенә киенде. Конвертны джинсы чалбарының арткы кесәсенә салды. Шулчак сискәндереп ишек шакыдылар.

— Әйе, әйе, — диде Альфред телен көч-хәл белән әйләндереп. Ишектә төз гәүдәле, горур карашлы бер хатын күренде. Ул җирәнгән кыяфәт белән бүлмәне күздән кичерде дә дәһшәтле тавыш белән:

— Биш минуттан җыештырылган булсын! — диде. — Ә кичен аңлатма язарсыз!

Хатынның керт-керт баскан аяк тавышлары гына ишетелеп калды. «Әллә кичтән дә кереп чыккан иде инде бу? — дип уйлады Альфред. — Комендант булды бугай».

Ләкин хәзер аның кайгысы юк иде. Ул физика китабын кулына тотты да урамга йөгереп чыкты. Такси-мазар күренмәде, трамвайга утырып Куйбышев мәйданына кадәр төште, аннары кырыгынчы автобуска күчте. Барасы юл ерак, теге кеше Дербышки поселогында ук яши иде. Альфред физика китабын ачты да укый башлады: «Интерференция нәтиҗәсе яктылыкның элпәгә төшү почмагына, элпәнең калынлыгына һәм дулкын озынлыгына бәйле. Әгәр сынган 2 — дулкыны кайтарылган 1 — дулкыннан бөтен сандагы дулкын озынлыгына соңга калса, яктылыкның көчәюе күзәтелә...» Ни соң бу? Моннан да күңелсез фән бар микән? Әгәр шушы физика дигән нәрсә уйлап чыгарылмаса, җир йөзендә тормыш нинди күңелле булыр иде.

Ул, тирән сулап, китабын ябып куйды. Бүген инде күпме генә укысаң да, үз көчең белән ерып чыга торган түгел. Бөтен өмет теге кешедә. Бүген йә бетәсең, йә каласың. Йә Казан, йә... А-а, ул хакта уйларга да куркыныч! Автобуста кеше күзгә күренеп арта барды. Альфред урынын бер әбигә бирде. Кайсыдыр тукталышта бик күп кеше керде, басып торуы да кыенлашты. Шулчак Альфред түгәрәк йөзле, түгәрәк беләкле, озын чәчле бер егетнең үзенә елышуын тойды. Егетнең кулы иң әлек арка тирәсенә тиеп-тиеп үтте, аннары туптуры теге кесә турына төшеп капшанды, ботка күчте, тагын теге конверт салынган кесәгә менде. Альфредның бөтен тәне куркудан җиңелчә калтырый башлады. Әнисе джинсысының арткы кесәсенә каптырма куйгач, Альфред, кеше көлдермә, дип аны орышкан иде. Менә хәзер әнисенең мең мәртәбә хаклы булганлыгын аңлады ул. Теге егет үзенең кайнар гәүдәсе белән тәмам сыланды.

— Әйдә, төшәбезме? — диде карак ике кулын аның ике боты тирәсендә йөртеп.

Ул борылырга да куркып аңа күзенең чите белән карап алды. Егет, елмаеп, ике мәртәбә каш сикертте. «Беттем!» — дип уйлады Альфред. Аларның ялгыз йөрмәгәнлеген ул яхшы белә. Нишләргә? Кычкырыргамы? Пычак белән чәнчерләр дә төшеп калырлар. Алда троллейбуска утырып маташучы кешеләр күренде. Автобус та нәкъ шунда туктады. Альфред кешеләрне бәреп кинәт ишеккә ыргылды, сикереп тә төште, инде ишекләре ябыла башлаган троллейбуска кереп кысылды. Теге егет автобустан төшә дә алмыйча калды. Альфред җиңел сулап куйды, тез буыннарының дер-дер калтыравын сизде. Кесәсен капшап карады, шпана акчаны ала алмаган иде. Бераз баргач, төшеп такси тотты. Җаны тынычланып, тиешле йортка барып җитте. Менә теге кешенең квартирасы. Аһ, өйдә булсачы! Ул кара төймәгә ике мәртәбә басты, эчтә «теллин, теллин!» дигән матур тавыш ишетелде. Ишек артында эт өргән тавыш яңгырады. Аның әченә җылы керде. Яңа уяналар бугай, шәһәр кешесе озак йоклый

бит ул. Лəкин кабат эт тə өрмəде, ишек тə ачылмады. Икенче мəртəбəсендə Альфред бик озак теллин-теллин иттереп торды, аңа кушылып эт өрде дə өрде. Ниһаять, аның күңелендə өметле шатлык уянып, йозак, шалт-шылт итте һəм янəшəдəге ишек ачылып китте. Тартылган чылбыр артында бик нык җыерылган эчке күлмəкле бер карт хатын басып тора иде.

— Ну чиго двонишь, чиго ыдвонишь?! — хатынның киптерергə элеп куелган мүкне хəтерлəтүче озын чəчлəре арасыннан күренеп торучы сыңар күзе сварка утыдай ялтырап-ялтырап алды. — Аптуринт чту-ли?! Рəҗе ни бидишь, его дума ниту?! Ə?! Вəйт беҗобразие, и выхотнуй пакуя ни дают...

Хатынның тутырылган турсыктай күкрəклəре турындагы чылбыр бушады да ишек шартлап ябылды.

Альфред бу йорттан чыкса да чыкты, чыкмаса да чыкты, автобуска утырса да утырды, утырмаса да утырды. Инде нишлəргə? Имтиханны ничек булса да тапшырырга кирəк. Бəлкем, теге кеше хəстəрен күреп куйгандыр? Ул бит Альфредның исем-фамилиясен белə. Тот капчыгыңны, конверттан башка куйды ди. Ни булса да үзеңə кала хəзер. Үлеп-җитеп, күз яшьлəре коеп, ялынып-ялварып булса да тапшырырга. Иң соңгы кеше булып, укытучылар тəмам арып-алҗып беткəч керергə. Башка юл юк. Бəлкем, берəрсе шпаргалка бирер...

Ул иң элек институтның бер җиренə барып, учлап-учлап су эчте. Су җылы, тəмсез, күңелне болгата иде. Аннары имтихан ала торган аудиториягə күтəрелде. Йə хода! Хəллəр бер дə əйбəт түгел икəн монда... Бөтенесенең чыраена, күзлəренə курку сөреме сарган. Бер өлеше фил сөяге төсле зур ишек каршына өелгəн, икенчелəре коридор буйлап чəчелгəн. Кайберлəре, көзге чебешлəрне хəтерлəтеп, стена буйларына, тəрəзə төплəренə сыенып бөрешкəннəр. Менə саргылт ишек ачылып китте дə аннан кызарып-пешкəн бер кыз чəчрəп чыкты һəм елый-елый читкə йөгерде. Кемдер өметсез тавыш белəн:

— Бу да бирə алмагач! — дип сыгылып төште.

Ишектə йөзе кəфен төсле ап-ак берəү күренде. Бу Альфред белəн бер бүлмəдə урнашкан егет иде. Аны корт күчедəй сырып алдылар, мең төрле сорау яуды:

— Ничек, бирə алдыңмы?

— Нинди сорау туры килде?

— Əйт инде тизрəк!

— Ничəле куйды, ничəле?!

Егет муенына кулы белəн аркылы сызып җибəрде дə:

— Рəттəн суялар! — диде.

Бөтенесе «ах» итте, шау-шу купты.

Коридор чыштыр-чыштыр китап-дəфтəр актарган тавыш белəн тулды, тагын бергə укмаштылар, ах-ух килделəр. Кемнəрдер имтихан алучыларның əшəкелеге, вакчыллыгы, юри төртеп батырырга телəүлəре, җавап бирүченең тəмам җанын суырулары турында кычкырып та, пышылдап та сөйлəделəр. Əлеге фил сөяге төсле ишекнең артында, əйтерсең лə, җиде башлы коточкыч дию пычак кайрап утыра, кергəн бер кешенең муенына шуның белəн сызып җибəрə дə канын суырырга керешə, эчеп бетергəч бу якка ыргыта... Бу мəхшəр Альфредны да үзенə суырып алды, куркудан аның авызы кипте, эче чурлый башлады. Теге ишек артындагы коточкыч җəзадан берəрсе коткарса, Альфред аның табанын яларга əзер иде. Ул түзə алмыйча урамга чыкты. Институттан өч кенə тукталыш ераклыкта урнашкан ашханəдə каты чəй эчү нияте белəн трамвайга утырды. Халык мичкəдəге балыклар кебек бер-берсенə сыланган, энə сыярлык урын да юк. Альфред теге тукталышка җиткəнче үк төшү хəстəренə керешергə уйлап, алга омтылды һəм ток соткандай туктап калды.

Джинсысының конверт белән акча салган теге кесәсеннән кемдер каты итеп эләктергән иде. Аның кычкырып елап җибәрәсе килде. Ни соң инде бу?! Нишләп бөтен бәла гел аңа гына килә?! Әллә теге караклар аны күзәтеп йөреп, чыкканын көтеп торганнармы?! Ул артына борылып карарга да курыкты. Эчендәге чурлау тагын да көчәйде. Тизрәк алга атларга, ычкынырга, кесәгә керергә ирек бирмәскә кирәк иде. Тик ул күпме генә тартылса да, теге кабахәт җан джинсыны җибәрмәде. «Бая качтың, бусында котыла алмассың!» — диюеме әллә?! Альфред нык кына итеп кинәт тартылган иде, бил турына кемдер китереп төртте һәм астан:

— Осторожно, парень![1] — дигән хатын-кыз тавышы ишетелде.

Ул ялт итеп борылып карады. Ап-ак чәчле, түгәрәк кенә чырайлы бер кыз утыргычта утыра, ә Альфред арты белән аны китереп кысkan иде. Ул тураймакчы булып алга омтылды, әмма галанка миче кебек эссе гәүдәләр һәм кесәдән эләктергән күренмәс кул аңа беркая кымшанырга да ирек бирмәделәр. Өченче тукталыш та, дүртенчесе дә калды. Альфред, читкә тартылуның файдасы тимәгәч, кулын аска төшереп сак кына кесә авызына шудырды, әгәр кулын эләктерсәләр яисә башкача зарар салсалар, кычкырырга әзерләнде. Шушы кадәр халык арасында ярдәмгә килүче табылыр дип уйлады ул. Менә аның бармаклары кесә авызына килеп җиттеләр. Ни бу?! Ул җилкәсе аша каерылып карады һәм кесә каптырмасына теге кызның ятьмәсе эләккәнен абайлады. Альфред, аның җебен ычкындырмакчы булып, ятьмәне теге кызга таба этә башлады. Шулчак бармагы нindидер лайлалы, юеш нәрсәгә батып кереп китте. Ул кулын югары күтәрде һәм аңа йомырка сарысы буялганлыгын күрде, нишләргә дә белмәде. «Йомыркагызны читкә алыгыз», диярга теләде, ләкин кыенсынды, чөнки кыз йокымсырап бара иде. Бераздан Альфред джинсы аша боты юешләнүен тойды, кулын төшереп капшагач, мәсьәлә тәмам ачыкланды: йомырка балак буйлап аска юл алган иде. Шул мизгелдә үз гомерендә беренче мәртәбә аның башына тормышның мәгънәсезлеге, күңелсезлеге турында уй килде.

Ниһаять, кыз урыныннан торып чыгарга кузгалды һәм Альфредны ятьмәгә эләктергән хәлдә ишеккә сөйри башлады. Ул, кармакка капкан балык шикелле, аның ихтыярына буйсынып, чигенә-чигенә ишектән чыкты. Трамвай китеп барды, алар басып калдылар. Альфредның курку һәм аптыраш тулы күзләре кызның зәп-зәңгәр күзләре белән очрашты.

— Тизрәк ычкындырыгыз инде! — диде Альфред бармаклары белән йомыркалы җепләрне кармалап.

Ятьмәнең ике-өч урыныннан сап-сары йомырка эче сузылган, кыймшанган саен алар чайкалып очлары белән я Альфредның чалбарына сыландылар, яисә аяк астына өзелеп төштеләр.

— Кеше өстенә утырмаска идең, — диде кыз ачулы тавыш белән һәм, ятьмәне ычкындырмакчы булып, кесә тирәсендә мәшәләнә башлады. Әллә кай арада аларны халык сырып алды, ат кәмите карагандай көлештеләр. Икесе дә, җир ярылса, кереп китәрләр иде, тик монда җир ярыгы түгел, йомран тишеге дә юк иде шул. Кыз башын игән килеш халык арасыннан читкә атлады, Альфред сүзсез генә буйсынып аңа ияреде.

— Кисмичә булмый, — диде кыз үз-үзенә сөйләнгәндәй.

Алар озак бармадылар, биек кенә бер йортның икенче катына күтәрелделәр. Кыз редикюленнән ачкыч алып ишекне ачты, иркен генә квартирага үттеләр. Кыз кухня өстәленнән пычак алып сетканың җебен кисте.

— Менә булды, — диде ул.

---

1. Саграк бул, егет! (Урысча)

Шулвакыт калган йомыркалар ятьмәнең киселгән урыныннан идәнгә чәп-чәп коелып беттеләр.

— Тагын чыгым, — диде Альфред һәм алар шаркылдап көлеп җибәрделәр.

Әле бер-берсенә, әле идәндәге йомыркаларга карап, тыела алмыйча көлделәр. Кызның түгәрәк иңбашлары, тәмам тулышкан күкрәкләре, таза балтырлары баштук Альфредның игътибарын җәлеп иткән булса, хәзер көлгән чакта, шуларга аның иреннәренең дә мәк чәчәгедәй алсулыгы, кечкенә матур колак яфракларында елык-елык килеп торучы затлы алкалар, муенындагы алтын чылбыр, бармакларындагы әллә нинди ташлы йөзекләр дә өстәлгәч, Альфред: «Бу гади кыз түгелдер, берәр министр-мазар баласыдыр», — дип уйларга һәм үзенең шундый зур кеше малае булмаганлыгына үкенергә өлгерде. Бүлмәдәге затлы келәмнәр, төсле телевизор, бәллүр савытлар тезелгән сервант һәм башка бик күп, бик күп нәрсәләр аның әлеге уйларын тагын да ныгытты, ә имтиханга керү ниятен әллә кая — томан эченә үк алып китте.

— Сез бу килеш урамга чыга алмыйсыз ич? — диде кыз аның чалбарына карап.

Чалбарны пычак белән кырып яисә чүпрәк белән сөртеп кенә игә китерерлек түгел иде.

— Салыгыз, хәзер чистартып бирәм, — диде кыз аңа туп-туры карап.

Аның озын керфекләреннән мәрҗәннәр тамды. Ул Альфредны терсәгеннән тотып зал ягына алып керде һәм ефәктән тегелгән озын пижама сузды. Үзе ишекне ябып чыгып китте дә ваннага шыбырдатып су агыза башлады. Озак уйлап торырга вакыт юк иде, Альфред пижаманы киде, алан-йолан карана-карана чалбарны салды, ни булмаска арт кесәсендәге конвертны алып калды. Чалбарны чистартырга биргәч, Альфред үзенең хәлен җентекләбрәк күздән кичерергә тотынды. Һәм, гаҗәп хәл, чалбарлы чактагы фикерләре белән менә хәзер, чалбарсыз утыргандагы фикерләре бөтенләй капма-каршы килеп бәрелештеләр. Моңарчы сизелмичә, бәләкәй генә булып, кыймылдамыйча гына торган фикер үсә, зурая барды да, «имтиханга кереп маташмаска» дигән рәвеш алып, элеккесен бәреп үк екты. Берәр ресторанга керергә дә шәплəп кенә ашап-эчеп чыгарга — иң яхшысы шул. Инде имтихан бирү-бирмәү хәл ителгәч, кыз мәсьәләсе беренче планга басты. Юк, аның болай гына чыгып китәсе килмәде бу квартирадан. Кемнәре бар икән? Ул аяк очларында гына атлап эчке бүлмәгә күз салды. Биредә ике кешелек караваттан, җыелмаган урын-җирдән башка нәрсә юк иде. Әллә ирдә микән? Алай дисәң, бармагында балдагы күренмәде. Бөтенесен дә ачыкларга, танышырга кирәк, ә нәрсәдән башлыйсын һич белеп булмый. Бер караганда, алар инде күптәнге танышлар кебек, үзара бәйләнгән хәлдә күпме матавыкландылар, икенче караганда, бер-берсенең исемнәрен дә белмиләр һәм, иң кыены шунда, хәзер, күпме вакыт узгач, «Сезнең исемегез ничек?» — дип сорау мәгънәсезлек булыр шикелле. Ничегрәк сүз башларга соң? Кинога йә танцыга чакырып булмый, мин сезне кайдадыр күргәнем бар бугай, дияргә дә соңарылды, озатып куярга рөхсәт сорарга да җай юк. Кая китте соң Альфредның тел ачкычы, кызлар янында ул бер дә аптырап калмый иде ләбаса! Әһә, ватык йомыркалар бар ич! Нәкъ үзе!

Кыз аңа чистартылган, үтүк белән бастырып киптерелгән джинсыны сузды.

— Рәхмәт, — диде Альфред, чалбарын киеп кыз янына чыккач. — Мин сезнең каршыда бик зур бурычлы булып калдым...

— Нинди бурыч?

— Ну... йомыркаларыгызны ваттым.

— Пүчтәк! — диде кыз көлеп.

Альфред шул йомыркалар тирәсендә сүз уйнату нияте белән авызын ачарга өлгермәде, залда телефон шылтырады. Ул колагын торгызды. Кызның кем икәнен чамаларга кирәк иде. Ләкин ул берни дә аңлый алмады. Кыз: «Юк, әйе, кичә сөйләшкәнчә», — диде дә трубканы куйды. Альфред кулларын кесәсенә тыкты, кызга баш иде.

— Сезгә бик зур рәхмәт, мин китәм инде.

Кыз, мин сезне бүтән тоткарламыйм, дигән мәгънәдә кулларын як-якка җәйде.

— Гафу итегез, исемегезне дә белмәдем.

— Ә нигә ул сезгә? — диде кыз елмаеп.

Шул мизгелдә Альфредның теле ачылып китте.

— Әгәр исемегезне белсәм, мин сезнең исәнлеккә һәркөн биш мәртәбә дога кылыр идем.

— Күбрәк булмасмы?

— Сезнең кебек кыз өчен күбрәк булмастыр дип уйлыйм.

— Рәхмәт, догагызны исемсез килеш кенә кылырсыз инде.

Альфред бер адым аңа таба атлады, йөзе җитдиләнде.

— Минем сезгә бер тәкъдимем бар, — диде ул. Кыз аңа кызыксынучан караш ташлады. — Әйдәгез ресторанга кереп ашап чыгыйк.

— Әгәр мин «ярар» дисәм?

— Ул чакта җир йөзендә миннән дә бәхетле кеше булмас иде.

— Бу кадәр комплимент әйткән егеткә ничек карышмак кирәк? — диде кыз һәм алар урамга чыктылар.

Юлда барганда бер-берсенең исемнәрен белделәр. Кыз Руфинә исемле булып чыкты. Ресторанда кеше күп түгел иде.

— Заказ бирү сездән, — диде Альфред.

Руфинә менюны елмая-елмая карап чыкканнан соң аңа сузды.

— Эчәргә ни алабыз? — диде Альфред.

— Сез бит инде миңа ышанып тапшырдыгыз. Әллә кесә ягы ниерәкме?

— Юк, юк, акча бездә бер букча!

— Оһо!

Алар төрле ашлар һәм бер шешә шампан шәрабе алдылар. Бокаллар күбекләнеп тулды.

— Сезнең исәнлеккә! — диде Альфред.

— Танышу хөрмәтенә.

Альфред, бүген авызына беренче мәртәбә ризык кабуы булса да, киенсынып кына ашады, барлык кыюлыгын җыеп, үзен иң кызыксындырган сорауларның беренчесен бирде:

— Руфинә, гафу итегез, сез кайда эшлисез?

— Казанда, — Кыз көлеп җибәрде. Аңа Альфред та кушылды.

— Ә сезнең кемнәрегез бар?

— Күп белсәгез, тиз картаерсыз.

— Минем яшьлегемне саклавыгыз өчен рәхмәт инде.

Альфред Руфинәнең үзе белән кызыксынуын, үзе турында сораштыруын теләде. Әмма кыз өчен ул, әйтерсең лә, беркем дә түгел, менә шушы җансыз өстәл белән бер иде. Ул аңа үзен фән үрләрен штурмларга атлыгучы заман герое итеп күрсәтмәкче, әтисен райком секретаре булып эшли, димәкче иде. Министр баласына: «Минем әти колхозда ветфельдшер, төп вазифасы өстенә сыерларны ясалма орлыкландыру эшен дә алып бара», — дип әйтеп кара син! Шуннан соң ресторанда утырырмы ул синең белән? Ә шулай да җай чыкты, Альфред уйлап утырган нәрсәләрен нәкъ шулай ярды да салды. Райком секретаре дигән сүзне ишеткәч, Руфинәнең зәңгәр күзләре әллә нинди җылылык белән тулдылар, ул Альфредка булган игътибарын бермә-бер арттырды. Берәр йөз грамм коньяк та алып эчкәч, Аль-

фред акча түләгәч, алар кайтып киттеләр. Таныш йортның подъездына җитү белән Руфинә бер генә секундка туктады да:

— Сыегыз өчен рәхмәт, хушыгыз, — диде һәм кереп китәргә борылды.

— Руфинә! — Альфред аларның аерылышуы шулай тиз булыр дип уйламаган иде. — Бәлкем кич ресторанга йә киного барырбыз?

— Минем вакытым юк шул...

— Ә иртәгә?

— Иртәгә, иртәгә... — диде Руфинә уйланып. — Шалтыратып карарсыз.

Ул телефон номерын әйтте дә кереп китте.

## 2

Тулай торакта безнең егетне бик тә күңелсез хәлләр көтә иде. Кичә эчелгән аракы һәм сыра шешәләре дә, юылмаган кефир шешәләре дә бер почмакта тезелеп тора. Бүлмәдә кичәге егетләрнең берсе генә, калган икесе — яңалар. Тегеләр, күрәсең, имтиханнарын тапшыра алмыйча кайтып киткәннәр. Яңа егетләрнең берсе аның бик пөхтә итеп җыештырылган караватында укып утыра. Комендантның Альфредны үзенә чакырганын әйттеләр. Ул ләм-мим бер сүз дәшмәде, портфеленә физика китабын салып, ак костюмын киеп алды да чыгып китте. Альфред, арттан килеп тотмасыннар дигәндәй, шактый вакыт бик ашыгып атлады, аннары адымнарын акрынайтты. Нишләргә соң әле? Ул бер сквердагы эскәмиягә барып утырды. Паспортын, акчасын барлады. Каптырманы ычкындырып, теге конвертны алды, бер башын сакланып кына теше белән кисеп чыкты. Конверт эчендәге унбиш йөзлекне санагач, Альфред як-ягына каранып куйды. Үзе белән бу кадәр акча йөртәм дип башына да китермәгән иде ул. Мең ярым! Моны кесәгә тыксаң да, портфельгә салсаң да куркыныч. Ул, күп баш ватканнан соң, акчаны кабат теге бәхетсез кесәгә тыкты. Хәзер беренче эш итеп кунакханәгә урнашырга, аннары берәр кино карарга, кинодан чыккач, ресторанга кереп ашарга кирәк булыр, дип уйлады ул. Иртәгә институтка барып документларны алырга да — әллүр! Юк, бу вариант бармый иде. Имтиханнар беткәнче, конкурс нәтиҗәләре билгеле булганчы Казанда торырга. Аннары күз күрер... Авылга кайтып муеннан эшкә батарга беркайчан да соң түгел. Әллә кайда йөрмәскә, моннан ерак булмаган «Болгар» кунакханәсенә урнашырга карар кылды. «Болгар» үзенең заманча эшләнеше белән тыштан ук аның күңеленә хуш килде. «Дөрес сайлаганмын», — диде ул үз-үзенә һәм кунакханәнең эченә атлады. Бирედә ниндидер спортчылар командасы китәргә җыена иде, ахрысы. Идәннәр сумка, чемодан белән тулган. Алар өстенә дә, утыргычларга да спорт киемнәрендәге егетләр чүмәшкән, бөтенесенең борыны салынган. Бер дә бүтән түгел, җиңелеп китүләре. Юкка борчылмагыз, андый хәлләр була инде ул, дип юатасы, дәртләндерәсе килде аның бу егетләрне.

— Миңа берәр урын, — диде ул администратор тәрәзәсендәге тишеккә паспортын тыгып. — Ләкин бер кешелекне бирегез.

— Сез каян? — диде кызыл иренле хатын тагын да кызылрак иренле хатын белән сөйләшүеннән туктап.

— Дулкынбаштан.

Хатынның чырае бозылды. Паспортны ул чатлатып кире ыргытты.

— Һушны алды! Күрмисеңме әллә?! — диде ул Альфредның борын төбеннән уңдарак торучы язуга күрсәтеп. Анда чабата кадәр хәрефләр белән, «урыннар юк», диелгән иде. Альфредның бу хатынга

котырып ачуы килде. Җикерүен кара әле. Әйтерсең, дөньяның кендеге аның кулында гына. Беләбез без ул язуны. Ярар, кертергә теләмәсәң, ялынган юк. Казанда кунакханә синдә генә түгел. Ул эре-эре адымнар белән «Таң» кунакханәсенә юл тотты. Биредә чемодантөенчекләр дә, халык та «Болгар»дагыдан күбрәк булып чыкты. Инде тәҗрибә туплаган кеше буларак, Альфред иң элек администратор пыяласына күз атты, биредә дә, «урыннар юк», дигән язу тора иде. Язу тора бирә, ә кемнәрдер һаман паспортларын сузалар, рөхсәт кәгазе алып тутыралар, акча түлиләр һәм киерелеп кереп китәләр. Әнә берәүнең паспорт эчендәге акчасын өстәл тартмасына шудырып кына төшерде администратор. Башың эшләмәсә, менә бу мескеннәр хәлендә тора бирәчәксең икән. Альфред паспорты эченә бер унлык салды да администраторга сузды.

— Одно место[1], — диде ул хатынның елмаеп җибәрүен көтеп.

Ләкин хатын сикереп торды, паспортны акчасы-ние белән пыяла өстеннән ишек катына ук очырып җибәрде.

— Ах, юньсез! — аның ярсулы тавышы бөтен Казанга яңгырады. — Әле ришвәт төртеп маташасыңмыни?! Милиция!

Альфред артына да борылып карамыйча ярты сәгать чапты, чигәсе сулкылдады, йөрәге какты, тыны бетте, өстеннән шыбырдап тир акты. Кәефе тәмам кырылды аның. «Татарстан» кунакханәсе администраторы аның соравына җавап та бирмәде, кемнәрнедер елмаеп, хәтта басып кабул итә торды, Мисыр күгәрченедәй сөйләшә торды, көлеп озата торды.

Инде кичке сигез дә тулып китте. «Совет» кунакханәсенә гомумән үтеп кергесез, «урыннар юк» дигән язу каршында өелеп торган халыкның санына да чыкмалы түгел иде. Альфред чынлап торып пошаманга төште. Кемдер аңа: «Яшьләр үзәге»нә барып карагыз», дип тәкъдим итте. Дүртенче троллейбустан төшкәч, Альфред бер татар әбиеннән «Яшьләр үзәге»нең кайда икәнен сорады.

«Яшьләр үзәге»ндә дә Альфредны ипи-тоз белән каршы алмадылар. Администратор урынында утыручы яшь кенә чибәр хатын:

— Урыннар юк, семинарга килүчеләрне урнаштырабыз, берәрсе китсә генә инде, — диде.

Юк, әле һаман өметен өзеп бетермәде Альфред. Ничек инде Казан тикле Казанда урын булмасын ди?! Ул «Волга», «Дуслык», «Казан» кунакханәләрен гиздe, кабат «Татарстан»га кереп чыкты да «Яшьләр үзәге»нә юл тотты. «Берәрсе чыкса», диде бит. Ләкин беркем дә чыкмаган икән шул. Ул үзенең коточкыч аруын һәм ачыгуын сизде. Аякларның ут булып януына чыдарлык түгел. Хәзер нинди дә булса кунакханәгә кереп, рәхәтләнеп аякларны сузып утырырга, ныклап ашарга, эчәргә кирәк иде. «Яшьләр үзәге» ресторанына шунда торучылар гына кертелә икән. Альфред «Волга»га китте. Бая анда чеңгел-чеңгел музыка тавышы яңгырап калган, ишек төбендә кешекара да күренмәгән иде бугай. Хәзер ишеге дә бикләнгән, керергә өтәләнеп йөрүче халык төркеме дә барлыкка килгән шул. Ах, бая кереп чыккан булса соң? Пыяла ишекнең бигендә торучы хатын үзе генә белгән билгеләре буенча кемнәрнедер кертә, кемнәрнедер чыгара, эчтә кемнәрдер кызарып-бүртеп ашап-эчеп утыралар, рәхәтләнеп музыка, җыр тыңлыйлар, бииләр, ә баскыч төбендәге ач халык өере шуларны тилмереп карап тора, ишек ачылган саен һәркем кереп китмәкче булып этенә, сарык көтүе сыман акыра, бакыра, сүгенә, бәддога укый. Биредә тәмам өметен өзгәч, Альфред елардай булып «Казан» ресторанына чапты, тик анда аны тагын да зуррак халык төркеме каршылады. Башка рестораннарда да хәл шундый ук булып чыкты. Ахырда ул үзләре көндез матур итеп ашап чыккан «Татар-

[1] Бер урын (урысча).

стан» ресторанына барды. Йә аллам, шул ук мәхшәр! Ичмасам пыяла аша күренеп тормасын иде! Әнә бит тәмле-тәмле ризыклар, өстәлләрдә әфлисун тутырылган савытлар, аракы, шәрап, сыра салынган бокалларны теләр-теләмәс кенә иреннәренә тигереп утыручы тук бәндәләр. Барысы да җитеш, бөтенесе бар — тик Альфредка гына түгел. Әйтерсең лә, пыяланың теге ягында җәннәт, ә бу ягында җәһәннәм. Җитмәсә ишек ачылган саен тәмле исләр бөркелеп борынга тула. Альфредның күз аллары әлҗе-мөлҗе килде, аның беркайчан да бу дәрәҗәдә ачыкканы юк иде әле. Әгәр берәрсе бер телем ипи белән сыңар котлет ыргытса, ул «әһ» тә итмичә теге унбиш йөзлекнең берсен чыгарып бирер чиккә җитте. Ул, этешә-төртешә торгач, ишеккә шактый якынайды. Менә әчтәге әзмәвер берәүне чыгарып җибәрергә ишекне ачты. Шул чак Альфред янындагы тузган чәчле берәү тегенең колагына: «Мин... янына», — дип бер хатын-кыз исеме әйтте дә кереп юк булды. Ишек кабат ачылгач, Альфред та әзмәвергә нәкъ шул сүзләрне кабатлады. «Уз», — диде теге. Альфред бәйдән ычкындырылган эт кебек эчкә ыргылды. Бу көннәрне дә күрергә насыйп икән! Теге тузган чәч берүзе бер буш өстәлгә барып та утырды, шөпшәдәй бер нечкә бил бии-бии атлап моның каршына килеп тә җитте. Альфред та аның каршына барып утырмакчы булган иде, нечкә бил аны читкә куды. Ул ресторанны аркылыга-буйга ике мәртәбә йөреп чыкты, ләкин беркайда да утырырга рөхсәт итмәделәр. Гүя, кемдер: «Бу егет керсә-нитсә, якын җибәрә күрмәгез», — дип барысын да кисәтеп куйган. Ишек янында ул утырып карамаган бер урын калган икән. Дүрт урындыкның кара-каршы икесендә кемнәрдер утыра булса кирәк, алар әлегә юк, әмма алларындагы ризыклары, мөлдерәмә тулы рюмка-бокаллары, шампанский, коньяк, шәрап, сыра шешәләре тора. Альфред ике буш урынның берсенә утырды да ут булып янучы аякларын сузып җибәрде, иреннәрен ялап, тәкеререген йотты. Сәгать унбер тула икән ич! Официантлар поднос, шешә, счет тотып туктаусыз йөгерәләр, тик аның янына гына туктамыйлар. Менә музыка тынып калды, биючеләр урыннарына ябырылдылар. Альфред утырган өстәл янына унҗиде яшьләрдәге кызны култыклап карт кына бер адәм килде. Аның киез итек кадәр борыны да, җыерчыклы чырае да, шактый зур мәйдан биләүче шома пеләше дә, йонлы беләкләре дә кояшта кап-кара булып янган, ә кыз базда үргән бәрәңге сабагы төсле ак һәм нечкә иде. Аннары килеп, бу адәмнең күз-күз тишекле зәңгәр свитер кигәнлеген, ул тишекләрдән мохер җепселләре төсле ап-ак йоннар чыгып торуын, борын астында уртача буяу пумаласы кадәр мыегы барлыгын да өстәргә кирәк. Дөреслеккә хилафлык китермәү йөзеннән, тагын шуны әйтмичә ярамый: аның уң як битенә кайчандыр бер миң чыккан, ул миң төсе һәм зурлыгы белән эре виктория җиләген хәтерләтсә, япа-ялгыз тырпаеп торуы белән күзгә бакчада берүзе калган кәбестәгә охшаш иде. Алар кара-каршы утыруга, теге адәм Альфредның урындыгына күрсәтеп:

— Гафу ит, кадерлем, бу урын — безнеке, — диде.

Ач кешенең ачуы яман. Альфред күзләрен очкынландырып:

— Сез утырган ич инде, монысында — мин, — диде.

Шунда кызның үпкә катыш ялварулы иркә тавышы ишетелде.

— Ярар инде, Зорик, утырсын бу егет тә. Кызганасыңмыни? — Кыз үрелеп аның йонлы беләген сыпыргаларга, иркәләргә кереште, ә сөрмәле күзләре белән йотылып Альфредка карады.

Зорик пианино клавишлары төсле ак һәм кара тешләрен күрсәтеп хәйләкәр елмайды.

— Ю-ук, кадерлем, монда син дә мин генә утырачакбыз.

Ул кискен генә кулын күтәрде дә бармагын шартлатты. Шул минутта ишек янындагы теге әзмәвер Альфредны култыгыннан әләктереп урыныннан торгызды һәм чыгарып та җибәрде. Аннан котыл-

ганга гомуми шатлыкны белдергәндәй, оркестр дәртле музыка уйнап калды. Альфредның бөтен дөньяга ишетелерлек итеп улап җибәрәсе килде. Хәзер инде ачыгу бетте, ачу гына калды. Ул җир йөзендә үзе белгән һәм белмәгән барлык җан ияләрен дә каргады, чөнки Альфредның бер үзен шушындый хурлыкларга, түбәнсетүләргә, газап утларына ташлап, алар барысы да менә хәзер рәхәттә йөзәләр, беринди гамьсез, тук килеш, йомшак ястык-мендәрләр өстендә изрәп йоклап яталар...

Урамда да ямь калмаган иде. Җимерелгән, зарарланган кәрәзләрне хәтерләтеп, йортларда тигезле-тигезсез саргылт утлар яна. Сискәндереп, шалтыр-шолтыр трамвай үтеп китә. Борынга мичтә кыздырылган кирпечне хәтерләтүче ис бәрә. Ачудан ул теләсә кемне өзгәләп атарга әзер иде. Ах, шушында Ирдәүкә Илгизә килеп чыкса! Күрмәгәнен күрсәтер иде аңа Альфред. Төптән уйлап карасаң, аның шушылай тилмереп йөрүләренә Илгизә сәбәпче түгелмени? «Класс белән колхозда калыйк», — дип иң элек шул чәтнәби безәнләп йөрде. Аннары башкалар тотынды. Комсомол дип, тегеләй дип, болай дип ризалаттылар. Ярый әле кайсыдыр акыллы башы табылды: институтта укырга теләге булганнарга китәргә ярый, диделәр. Әгәр шул колхоз өскә басарга тормаса, Альфред монда укырга керергә килеп тә йөрми иде. Алдагы язга барыбер армиягә китәсе.

Инде кая барып бәрелергә? Юк, кемнәрне генә каргаса да, иң юләре үзе икән ул. Әнисе Казандагы туганнарының адресын бирде бит. Алмаган булды, имеш, ник кирәк алар, тулай торакта йә кунакханәдә урын бетмәгән, янәсе. Кырдың менә! Кинәт аның башына бер уй килде. Әгәр Руфиналәргә барып карасаң? Ашатып чыгарсалар, вокзалда да йоклар иде әле. Иң элек шалтыратып белешергә кирәк. Ул автоматтан номер җыйды. Руфинә телефон төбендә көтеп утырган диярсең, шундук трубкада дулкынланган тавыш ишетелде:

— Жора, синме бу?! — ул еш-еш сулыш алды. — Ни булды?

Альфред тын алырга куркып торды да трубканы элде. Димәк, ул өйдә. Кем соң ул Жора? Егетеме? Ник шайтаным булмый, хәзер Руфиналәр квартирасының бусагасына барып егылудан башка юл юк.

Ярты сәгать узуга, ул менә сүнәм, менә сүнәм дип лепелдәп торган өмет утын күкрәгенә кысып тоткан хәлдә, таныш ишек каршына килеп басты. Хәзер ул утка, шушы ишекне ачып, йә су, йә бензин сибәчәкләр. Ул чәчләрен, якаларын төзәтеп, тирән сулыш алды да звонок төймәсенә басты. Әчтә сандугач сайравына охшаш тавыш ишетелде һәм, — әллә тагын Руфинә шунда басып көтеп торган, — ишекне шартлатып ачып җибәрде. Аның өстендә затлы кофта, итәге билдән әз генә төшкән юбка иде. Руфинәнең зәңгәр күзләре түп-түгәрәк булды.

— Альфред?! — диде ул тере юлбарыс белән очрашкандай гаҗәпләнеп. — Бу вакытта нишләп йөрисең?

— Тулай торакта урынны бүтән кешегә биргәннәр. Кунакханәләргә баш тыккысыз...

— Әйдә, кер...

Руфинә ишекне япты да телефонга китте.

— Әтигә шалтыратам, хәзер урнаштырыр.

Ул номер җыя башлады да трубкасын кире куйды.

— Ах, да, соң икән шул...

Руфинәнең йөзендә канәгатьсезлек билгеләре чагылды, шул ук вакытта ул Альфредны куып чыгарырга да батырчылык итмәде.

Альфредның башыннан: «Әллә ул ялгызы гына яшиме икән?» — дигән уй чагылып узды. Руфинә аны зал ягына алып чыкты һәм Альфред тынсыз-өнсез калды. Өстәл сый-нигъмәттән, төрле-төрле эчемлекләрдән сыгылып тора иде. Аның күңеленнән: «Оҗмах шушы икән», — дигән уй йөгереп үтте.

— Әниләр киләсе иде, килмәделәр,— диде Руфинә утырырга ишарәләп.

Өстәлнең ике кеше өчен генә әзерләнгәнен күрсә дә, Альфред андый вак-төяккә игътибар бирмәде. Руфинә икесенең дә рюмкасына коньяк салды, сүзсез генә чәкештерделәр дә эчеп җибәрделәр. Әмма Альфред чак кына чәчәмәде: теләнә дә, җенәнә дә ут капты, сулышы куырылып ни эчкә кермәс, ни тышка чыкмас булды. Руфинә сузган шифалы суны эчкәч кенә ул шаулатып тын алды. Бу коньяк та түгел, спирт та түгел, теге усал әйбер иде. Альфред кимендә бер атна ризык күрмәгән кеше шикелле ике-өч калҗа итне, кызыл балык телемен чәйнәмичә диярлек йотып җибәрде, кых-кых килде, аңа карап Руфинә елмаеп куйды.

— Вообще-то синең килүең әйбәт булды әле,— диде Руфинә һәм аңа якын ук килеп рюмкасын чәкештерде. Бусын эчкәч, Альфред күзләрен өстәл өстендәге ризыкларга юнәлдерергә күпме генә тырышса да, алар, авыш тактадан тәгәрәгән йомыркалар төсле, юбканың кыска итәгенә юнәлделәр. Ул үзенең исергәнлеген сизде. Аңа шундый рәхәт, дөнья түгәрәк, берни дә кирәкми иде. Ул теге ятьмәне ясаган фабрика коллективына, йомыркаларны салган тавыкларга, ул йомыркаларны саткан сатучыларга рәхмәт укыды.

Руфинә музыка җибәрде, аның гүзәл моңы колакны гына түгел, бөтен тәнне, җанны иркәләде. Утырып тору мөмкин түгел иде. Альфред аны биергә чакырды, Руфинә карышмады. Альфред кулларын кызның биленә, ә Руфинә ике җилкәсенә салды һәм астан өскә таба биек агач башындагы җимешкә караган шикелле карады. Альфредка Руфинә фәрештә булып күренде. Түп-түгәрәк алсу йөз, шундагы төпсез ике зәңгәр күз, и йөрәгем, түз! Ул серле күзләрдә әллә нинди шәүләләр уйный, бер караганда алар: «Миңа кил»,— дип ялваралар, икенче караганда: «Син кем?»— дип төпченәләр шикелле. Ул битләрнең шомалыгы, дымлы, мәк чәчәге төсле ул иреннәрнең серле елмаюы... Ул мең төрле хуш исләр килеп торучы күперенке ак чәчләрнең иңбашларына төшеп торулары, ул көмеш алкаларның булат кылыч очы кебек ялык-йолык килүләре!.. Менә теге сихри иреннәр хәрәкәткә килеп, аларның эченнән сандугач тавышы ишетелде:

— Әйдә мин сине Альфа дип атыйм. Ә син мине Руфчик диярсең.

— Соң ярар,— диде Альфред, яңа таныклык алгандай куанып.

— Ә нишләп син русча акцент белән сөйләшәсең?

— Авыл мәктәбендә укыгач, шулайрак инде,— диде Альфред үзен акларга теләп.

— Но син әтиеңне райком секретаре дидең. Авылда райком бармыни?

— Ә ни ул...

Альфред үзенең килеп капканын аңлады. Әгәр алдашканыңны сизсә? Фәрештәләр андый нәрсәне кичермиләр, урамга чыгып очуың да бар.

— Ни бит... минем әти машина белән йөреп эшли.

— Кара син аны!

Руфинәнең йөзенә шикләнү билгесе чыкты. Аны бетерергә кирәк иде.

— Безнең әти көне-төне эшли, шәһәрдә яшәүчеләрне азык-төлек белән тәэмин итү өчен яна,— дип алып китте ул.

Әтисенең тырышлыгы аркасында аларда арышлар ярсып үсә, чөгендерләр котырып уңа, сыерлар дәртләнеп чиләк-чиләк сөт бирә, сарыклар йон таулары өя, болын-әрәмәләрдә йөреп булмый — җиләк-җимеш өстенә китереп басасың, елга-күлләрдә беләк буе кызыл һәм кара балыклар чопырдап кайнап тора, өйләрдә чежелдәп газ

яна, урманар линейка белән сызгандай төз, юллар асфальтланган...

Аның сөйләгәннәрен тыңлап бетерергә Руфинәнең, әлбәттә, түземлеге җитмәде, ул кулын җайлап кына күтәрде дә Альфредның борынына бик каты итеп чиертте һәм көлеп җибәрде. Борыны авыртса да, Альфред аңа кушылып көлде. Чиертүнең беренчесе артыннан икенчесе дә көттермәде.

— Ә нишләп синең борының очлы?— диде кыз.

— Чибәр кызларның исен еректан ук сизү өчен,— диде егет. Җавап Руфинәгә ошады.

— Кара син шаянны!— диде ул көлә-көлә.— Әгәр томау төшсә?

— Ул чакта кызлар яратудан мәхрүм кала.

— Ә син кызларга ярату бирә алам дисеңме?

— Моңа син үзең дә ышаначаксың, Руфчик!

Ул кинәт аны үзенә кысты, битләрен, иреннәрен үбә башлады. Руфинә карышмады, бертуктаусыз: «Ах, шаян, ах озорник!»— дип, кытыгы килгән кеше кебек көлде дә көлде. Альфредның битләрен аның аккош мамыгыдай чәчләре кытыклады, ул үз йөрәгенең дөпдөп тибүен ишетте. Әйтерсең лә, иртән башны әчтән кусәк белән дөпегән затлар хәзер күкрәк читлеге эчендә субай кагалар иде. Менә Альфред кызны бер кулы белән тез асларыннан ук эләктереп, икенчесе белән биленнән тотып күкрәгенә алды, ул исә сабый бала кебек аның муеннарына сарылды... Шушы рәвешле музыка көенә бии башлагач, Альфред Руфинәнең коточкыч авыр икәнен сизде, аны идәнгә бастырмакчы булды, әмма кыз аның муенын ятьмә каптырманы эләктергән ише генә эләктермәгән, ә бәлки арматура тимере кебек чытырдатып кыскан иде. Идәнгә бастырырлык җай булмагач, Альфред аны йокы бүлмәсенә алып чыгып китте һәм алар йомшак урынга аудылар. Альфред ниләр эшләгәнен дә, ниләр әйткәнен дә сизмәде. Руфинә йокылы-уяулы мәче баласы мыр-мыр килеп ими эзләгәндәй, борынын аның күкрәгенә төртеп:

— Ну, Альфа, кирәкми, ну, Альфа, кирәкми...— дип пышылдады, Альфредның кабаланучы кулларын читкә алырга теләгәндәй хәрәкәтләр ясады, әмма ул хәрәкәтләр «Торып китә күрмәсен тагы» дигәндәй, бик йомшак, юл куючан хәрәкәтләр иде...

Алар җир йөзендә икәүдән-икәү генә калдылар. Очсыз-кырыйсыз дәрьялар да, кыйтгалар да юк, авыл да юк, шәһәр дә юк, колхоз да юк, имтихан да юк, әти белән әни дә юк,— һәммәсе каядыр еракка киткән, юк булган, алар икесе генә калган иде.

И язмыш! Нинди усал да, игелекле дә икәнсең син! Әле кайчан гына әт тибенгәсендә тилмереп йөргән, үзе арыган, үзе ач, үзе беркемгә дә кирәкмәгән адәм баласы хәзер йомшак түшәк өстендә, кайнар кочакта ята, ул корсагында бет үтерерлек дәрәҗәдә тук, шулкадәр кирәкле, үз-үзеннән канәгать һәм бәхетле. Бәндәләр белән ник син шулай уйныйсың икән, язмыш? Ник син адәм балаларына шул кадәр миһербансыз да, шул кадәр игелекле дә? Берниндн кануннарга да буйсынмыйча бөтенесен үзеңчә бутарга, болгатырга сәләтле нинди бөек зат син? Әллә соң син күрсәткән җәбер-җәфалар да кеше файдасынамы? Әгәр бичара хәленә төшмәсә, Альфред менә бу ләззәтләрне бәяли алыр идеме икән? Юктыр. Ул язмышка рәхмәтле уйлар белән эреп китте.

### 3

Альфред уянганда төш туры җитеп килә иде инде. Руфинә әле һаман изрәп йоклый. Аның тузган чәчләрен, кызылы җуелган шешенке иреннәрен күргәч, мес-мес итен тын алуын ишеткәч, Альфредта җирәнүгә охшаган нииндидер бер сәер тойгы кузгалып куйды,

тизрәк киенеп чыгып качасы килде. Ул аны күрмәс өчен сырты белән борылды. Чыгып качарга ярамый иде шул. Киресенчә, Руфинә нәкъ менә аңа кулай кеше, ничек булса да, аның җылы канаты астына керергә, шушында төпләнергә кирәк. Альфред аның ялгыз яшәвен, шушы квартирасы, гаражы, «Жигули» машинасы барлыгын, бер институтның икенче курсында укуын, әтисенең зур гына түрә икәнлеген, әнисенең фән өлкәсендә эшләвен, тәрбия проблемалары буенча диссертация якларга җыенуын белеп өлгергән иде инде. Аны колхоздан тартып алса, Руфинә генә алачак. Үлеп яратам, синнән башка яши алмыйм, ашавым ашау, эчүем эчү, йокым йокы түгел дияргә, ничек тә шушы ояны яуларга кирәк. Бер төпләнгәч, җае чыгар. Язга армиягә китәсе. Әле аннан кайтканчы кем бар да кем юк. Ләкин Руфинә дә юләр түгел, сөлек кебек шәһәр егетләре барында русча да юньләп сөйләшә белмәгән авыл каргасын нишләп якын китерсен ди. Дөрес, Альфредның чибәрлеге бар, кызларның үзенә тыныч карый алмауларын ул яхшы белә. Тик Руфинәнең боларга гына исе китәрме соң? Шәһәр кызларына иң элек акча кирәк, аннары гына калганы. Акчаң җитешле булса, чибәрлегең дә, яшьлегең дә бер читтә торсын. Альфред моның шулай икәнен кичә ресторанда үз күзләре белән күрде. Әйе, әйе, эшне акча тирәсендә әйләндерергә кирәк. Кичә Руфинәнең һәр керфеге, һәр чәч бөртеге өчен җанын бирергә әзер булган Альфредның бүген аңа сыртын куеп ятканда башына әнә шундый уйлар килде.

Аның карыны өзелеп ачкан, башы да чатнап тора, зал ягындагы ризыкларның тәмле исләре дә бу якка ук керә иде. Альфред акрын гына торды, аяк очларына гына басып залга чыкты, арадагы ишекне ябып куйды. Ашык-пошык юынып алды да өстәл янына утырды. Күзеңнән ут чыгара торган теге әйберне эчеп җибәргәч, ашыкмыйча тәмләп кенә ашады. Аннары өстәлне җыештырып алды, савыт-сабаларны юып куйгач, кухня өстәленең астын ачса, бурсыган, күгәргән искә тончыга язды. Анда юылмаган савыт-саба эскертләп өелгән иде. Альфред су кайнарлап аларның барысын да юды, урыннарына тезеп куйды. Ул кухня өстәлен сөртеп маташканда Руфинә дә торып чыкты.

— Хәерле иртә!— диде ул үптерү өчен иренен сузып.

Альфред аның иреннәренә иреннәрен тигереп алды да:

— Хәзер хәерле көн инде!— диде.

— Ах, озорник!— Руфинә тагын аның борынына чиертеп алды. Аннары җыештырылган, юылган әйберләрне күздән кичергәч, канәгатьләнү хисен белдерде: — Синең белән яшәргә була.

Альфред ике кулын күкрәгенә куеп баш иде.

— Синең белән дә яшәргә була.

Руфинә ваннада юынган-төзәтенгән арада ул чәй өлгертте, үзе булдыра алганча өстәл әзерләде. Кухняда мәшәләнү колхоз эше түгел, түзәргә, ничек тә сынатмаска кирәк иде. Нәфсесе бик кымырҗып торса да, теге әйберне, хәтта Руфинә кыстаса да, капмаска булды. Әнисе әйтмешли, аракы кешенең дәрәҗәсеннән алып һәммә нәрсәсен түбән төшерә, бер авызыңа хуҗа булмасаң, синең турыдагы фикернең үзгәрүе дә бар.

Алар тәмләп чәй эчеп утырганда, ишекнең сандугачы өч мәртәбә сайрап җибәрде. Альфред Руфинәгә сораулы караш ташлады.

— Борчылма, әни булырга тиеш.

Руфинә шулай дип ишекне ачты. Анда чал чәчле, күзлекле, кулына георгин чәчәкләре тоткан хатын күренде.

— Исәнме, кызым!

Ул бусаганы атлау белән Руфинәне кочып алды, аркасыннан сөйде, чәчәкләрне бирде һәм кулъяулык белән күз яшьләрен сөртте. Шуннан соң гына Альфред белән исәнләште.

Руфинә Альфредны, Казанга авылдан килеп заводта эшли, читтән торып укырга керергә җыена, дип таныштырды, инде дуслашуыбызга айдан артты, диде. Бергәләп чәй эчү вакытында Ләлә ханым аңа сорау арты сорау яудырды. Аның сораулары, кыргый җәнлекне бер-бер артлы яралаган аучы пулялары кебек, Альфредны тәмам хәлдән тайдырдылар, үзенең генә көче җитмәгәндә, ярдәмгә Руфинә килде. Шунысы әйбәт булды, Ләлә ханым Альфредның үзен дә, аның әшче сыйныф арасында чыныксын, дип малаен Казанга җибәргән райком секретаре этисен дә яратып өлгерде. Бу — Альфред белән Руфинә ирешкән хәлиткеч казаныш иде.

Ләлә ханым киткәч, Альфред өстәлгә күкрәк кесәсеннән алып, башта бер йөзлек, аннары икенчесен, өченчесен куйды.

— Син нишлисең?!— диде Руфинә аптырап.

— Сыена күрә түләве.

Руфинә бармак янады, әмма акчаларга кагылмады. Кичкә таба, киногa барып кайткач кына, йөзлекләр сервант өстенә күчтеләр. Икенче көнне өйлә турында йокыдан торгач кына Руфинә аларны үзе генә белгән ышанычлы урынга алып куйды. Егетнең финанс ресурсларының күпме булуы белән ул кызыксынмады, тик шунысы ошады: өч көн «Жигули»да җилдергәндә, ресторанда күңел ачканда Альфредта әле теге йөзлекләрнең күплеге сизелде. Альфредның исә эчен акрын гына бер корт кимерде: «Акча беткәч, ни булыр? Руфинә аны урамга куып чыгармасмы?» Савыт-сабаны күпме генә тырышып юсаң да, аннан акча төшмәячәк. Димәк, уңга-сулга сибүне акрынлап киметергә туры киләчәк.

Дүртенче көнне алар тагын парлашып «Жигули»га утырып чыгып киттеләр. Бүген, күпкә булмаса да, тәүге мәртәбә бер-берсеннән аерылалар иде. Физиканы «биш»легә бирдем, дип авылга шалтыраткан булса да, Альфред кабул итү комиссиясеннән документларын алырга карар кылды. Руфинә машинасын институтның баскыч төбенә үк китереп туктатты, Альфредка ит белән колбаса өчен бер уч талон биргәч, ирененнән үптерде һәм чожлап китеп барды.

Күп тә үтмәде, аның машинасы тавыш-тынсыз гына бер мәһабәт бина янына килеп туктады. Руфинә таш баскычлардан керткерт күтәрелеп сулга борылды һәм «Кабул итү бүлмәсе» дигән язулы ишекне ачты. Андагы күн урындыкларда йөзләренә олы җитдилек һәм борчу иңгән кешеләр көтеп утыралар. Секретарь ханым, Руфинәне күргәч, пружина аткандай сикереп торды. Ул:

— Анда кеше бар...— дип сүзен очларга өлгерә алмады, Руфинә ишекне дөпелдәтеп ачып кереп тә китте.

Әтисе, гадәттәгечә, биш-алты телефонлы, селекторлы, кәгазьләр белән тулы өстәл артында утыра иде. Руфинәгә аның сирәк чәчләре тагын да күбрәк коелган, түгәрәк гәүдәсе дә сизелерлек юанаеп киткән кебек тоелды. Әтисенең каршында бер ир үрә катып тора, аның бит очлары алланган, маңгаена тир бәреп чыккан.

— Мин бу хакта безнең арада кабат сүз булмас дип ышанам!

Әтисе учы белән өстәлгә шапылдатып сукты. Теге кеше башын иеп аска карады һәм авыз эченнән хәлсез генә:

— Ышаныгыз, Заһит Рәхмәтуллович,— диде.

— Сезгә китәргә мөмкин.

— Рәхмәт, Заһит Рәхмәтуллович.

Теге кеше юк булды.

— Нихәл, кызым,— диде әтисе аягүрә басып.

Руфинә аның каршына ук килеп утырды.

— Шапырынырлык әйбер юк,— диде Руфинә.

Аларның үзара русча сөйләшкәнлеген укучы, әлбәттә, беләдер дип уйлыйм.

— Дусларың да арткан икән...

— Нинди дуслар?

Руфинә гаҗәпсенеп аңа карады.

— Әниең әйтте. Альфред исемле егет турында...

— Ә, аны әйтәсең икән! Әйе, симпатичный гына малай.

— Бик яхшы, якын кешесез яшәү кыен,— диде Заһит Рәхмәтуллович, каядыр бер ноктага төбәлеп.— Тик... тәртип булсын.

— Әти, син кафедра мөдире белән килешермен диган идең. Бер-ике имтиханны булса да тапшырырга. Ә ул минем белән сөйләшергә дә теләмәде...

Ул күз яшен сөртеп алды да бүлмә буйлап арлы-бирле атларга кереште. Әтисе, тынычландырырга теләп, аның артыннан ияреп йөрде.

— Үз-үзеңне бетермә инде, барысын да җайларбыз, барысы да җайланыр...

Заһит Рәхмәтуллович кызын тынычландыру өчен сүз запасы гына җитмәвен аңлап, ике егерме бишлек рәвешендә акча запасы да өстәгәч, Руфинә чыгып китте, акча белән бергә ул әтисенең тынычлыгын да алып китте. Заһит Рәхмәтуллович өч төрле йөрәк даруын берьюлы эчте дә арткы бүлмәгә кереп ятты. Бу дөньяның гаделсезлегенә хәйран калырлык иде. Әгәр бала студент итеп алынган икән, әгәр ул нормаль икән, ни өчен ул имтиханын тапшыра алмый? Әгәр бу шулай икән, укыту-тәрбия процессы дөрес оештырылмый, институт доцентлары, профессорлары тиешле белем бирә белмиләр, акча алу өчен генә йөриләр дигән сүз. Ә аларның шулай йөрүе яшьләрнең язмышларын җимерә, җәмгыятьнең кризисына, регресска китерә. Бүгенге якты көндә ник елый аның кызы? Ата кеше тоныкланып баручы күзләрен сөртте. Әгәр яшь буын турында Заһит Рәхмәтуллович кебек акыл белән алдан күреп кайгыртучы җитәкчеләр булмаса, ул күз яшьләре ил өстенә диңгез кебек җәелер иде. Кафедра мөдире кабакбаш Чәчәншиннар фаҗига тудырып яталар. Аның Руфинә белән юри, үч итеп сөйләшмәгәнен белә Заһит Рәхмәтуллович. Былтыр бер җирдә бер хатын өчен маңгайга-маңгай бәрелештеләр алар. Әлбәттә, салган баштан. Анда да теге хатын гаепле булды: Заһит Рәхмәтулловичны йә Чәчәншинны үзе сайлыйсы урында, аларның чукышканын читтән елмаеп күзәтте. Ярар, анысы булган, ник соң ул Заһит Рәхмәтулловичның үчен кызыннан ала? Руфинә болай да кыл өстендә тора. Кыз кешегә хәзерге заманда сарылырга гына торалар һәм бер дә яхшы ният белән түгел.

... Заһит Рәхмәтуллович шулкадәр аның малай булуын теләгән иде. Юк, шул! Бик күп нәрсәләргә көче җитсә дә, кызны малайга әверелдерү куәсеннән мәхрүм иде Заһит Рәхмәтуллович. Өстәвенә кызлары да үтә көйсез булды. Йокласын, үссен, чирләмәсен, дип аяк очларына гына басып йөрделәр, күзен ачуга икесе ике ягына барып бастылар. Кыз көн буе йоклады, арып-талчыгып эштән кайткан әтисе белән әнисен төне буе әпипәгә дә, былбылымга да, баламишкинга да биетте. Кыз, берәр нәрсә ошамаса,— ә аңа ошаган нәрсә сирәк иде,— дык итеп артына утырды да тәгәри-тәгәри акырып еларга кереште. Заһит Рәхмәтуллович ул күрсәткәннәрнең ачуын Ләлә ханымнан алды, алып бетермәгән өлеше үзенең кул астында эшләүчеләргә төште. Сүз дә юк, дык итеп утырып елау юлы белән түгел. Ул вакчылланды, сабырсызланды, һәр эштән кимчелек тапты, бәйләнде, эзәрлекләде, сүкте, янады...

Руфинәгә яследә дә, бакчада да аерым карау булды. Тәрбиячеләр аның тирәсендә йөгереп кенә йөрделәр. Ул теләсә — йоклады, теләсә — торды, теләсә — башкаларга әйбер атты. Апалары дәшмәгәч, моңа балалар түзде, шулай тиеш, дип карадылар.

Җәй көне аны ике-өч айга әбисе янына авылга кайтара торган булдылар. Әбисе оныгын бик яратты, көне буе йоклатты, кыз уянгач та бик озак урын өстендә иркәләнде, яткан килеш уйнады, телевизор карады, ашады һәм эчте. Руфинә тазарып, матурланып китте, юкка-барга чәүчәләкләнүләре, көйсезләнүләре кими барды, басынкы кызга әверелде.

Ләкин бу аның көенә торганда гына шулай, әгәр әз генә аңа ошамаган нәрсә булса, кыз дөрләп кабына, әйберләрен атып бәрә иде. Врачлар «невроз» диделәр, табигатьтә йөртергә, физкультура-спорт белән чыныктырырга кирәк диделәр. Әмма Руфинә боларны теләмәде. Бердәнбер дәва булып аның көенә тору калды. Көенә торганда Руфинәдән дә яхшы кеше юк иде. Рәхмәт укытучыларга, Заһит Рәхмәтулловичны аңладылар, нәкъ шулай эшләделәр.

Урта мәктәпне бетергәч, Руфинә институтка керде. Әмма беренче елны тарта алмады, холыксызлана башлады. Аңа академик ял бирделәр. Икенче елны ул бик авырлык белән булса да беренче курсны бетерде. Җәйге каникул чорында ул бер якут егетен ияртеп кайтты да: «Без өйләнешәбез»,— диде. Бу сүзне ишеткәч, Заһит Рәхмәтуллович бер якка, Ләлә ханым икенче якка гөрселдәп аудылар. Ләкин авып котылмак юк иде, кыз чигенергә теләмәде. якут университетның соңгы курсына керә икән. Руфинәне алар үзләре генә яратырга теләсәләр дә, бу эгоистик хисне җиңеп, аны башкалардан да яраттыру мөмкинлеге тудырдылар. Тик бер нәрсә генә аңлаешсыз иде: үзенең җилкәсеннән дә тәбәнәк булган кысык күзле якут аңа ни бирә ала, киләчәктә ничек, кайда яшәрләр — бу мәсьәләләр һәммәсе дә ачык калды. Ул хакта сүз кузгатсаң, Руфинә аяк тибеп кенә кычкырды. Бала бит, нишлисең? Ашыгыч чаралар күреп, квартира мәсьәләсен хәл итә алды Заһит Рәхмәтуллович. Кыз кешене сораучы барында биреп калу хәерле булса да, туйны бәла-каза кебегрәк кабул иттеләр. Бер дә якутлар белән туганлашасылары килмәгән иде аларның. Шуңа күрә кода белән кодагыйга, Якутиядән үк килсәләр дә, бик коелып төшмәделәр, кунакханәгә генә урнаштырдылар. Заһит Рәхмәтуллович белән Ләлә ханым эчләрендә дөрләгән канәгатьсезлек утын туйда ничек кенә яшерергә тырышсалар да, булдыра алмадылар, аларның йөзләре яктырмады. Менә бүләкләр бирер чак җитте. Заһит Рәхмәтуллович белән Ләлә ханым яшьләрне котлап яңа квартира ачкычы тапшырдылар. Шуннан соң кияүнең әтисе торып: «Без яшьләргә «Жигули» машинасы бүләк итәбез»,— дигәч, бөтенесе өнсез калды. Ышанырга да, ышанмаска да белмәделәр, бу шаярту гынадыр дип кул чабарга курыктылар. Туйны алып баручы машина бүләк итү турындагы документны укыгач кына алкышлар яңгырады. Заһит Рәхмәтуллович белән Ләлә ханым кодасы белән кодагые янына ничек йөгереп барганнарын, аларның битләрен, авызларын гына түгел, кысык күзләрен дә ничек үбә башлаганнарын сизми дә калдылар. Һай, әйбәт тә кешеләр булып чыкты соң кода белән кодагый!

Менә шулай матур гына яшәп киткәннәр иде балалар. Кияү бик тынгысыз булып чыкты, ашарга да пешерде, чәтертән кебек керен дә уды, идәнен дә юды. Руфинә укуын дәвам итте. Балаларның матур тормыш коруына куанудан Заһит Рәхмәтуллович белән Ләлә ханым үзләре дә түгәрәкләнеп, матурланып киттеләр. Әмма аларга борчылусыз озак яшәргә насыйп булмаган икән. Яңа ел алдыннан квартирасын да, Руфинәне дә, «Жигули»ен дә калдырып, якут кияү чыкты да качты. Руфинә берни дә сөйләмәде, ул идиот хакында сөйләшәсем дә килми, диде. Кодалар белән телефон аша элемтәгә кергәч, шул мәгълүм булды: боларның кызы тегеләрнең малаен ат итеп җиккән, сыер урынына сауган, эт итеп суккан, ишәк урынына да күрмәгән икән. Санга сукмаса да, малай-

ларының күзенә аш чүмече белән суккан. Хәзер ул Казанга килү түгел, каз сүзен ишетсә дә, калтырый башлый, укырга да башка университетка күчә икән. Кычкырышмадылар, судлашмадылар, «Жигули»ның биш меңен аларга салдылар да шуның белән вәссәлам. Руфинә шул квартирада яшәп калды. Әнисе белән барып, мәшкәләнеп, күгәреп беткән кефир шешәләрен, савыт-сабасын, лакашып каткан, кыргаяклаган кием-салымын күз яшьләрен кушакуша юып кайткаладылар. Бала бит, нишлисең? Әгәр барлык кешеләр дә балаларын шулай кайгыртса, тормыш бөтенләй башкача булыр иде. Руфинәсенә ул аталык хисләрен кызганмады, кем баласы дигәндә, ким-хур булырлык итмәде. Җәмгыять бакчасына яшь үсенте утырткансың икән, син инде иренмә, аңа барлык шартын тудыр. Әгәр аны үз ихтыярына ташлыйсың икән, син ата түгел. Аллага шөкер, бу мәсьәләдә Заһит Рәхмәтулловичның халык алдында йөзе ак. Нindидер кыенлыклар, кытыршылыклар, уңышсызлыклар бар икән, аларын һич тә баланың холкына яисә Заһит Рәхмәтулловичның игътибарсызлыгына аударып кына котылып булмый. Сәбәпне аерым кешедән түгел, тирәннән, җәмгыятьнең гаделсезлегеннән эзләргә кирәк. Ә Заһит Рәхмәтуллович кызы өчен җаваплылыкны бер генә минутка да үз өстеннән төшерә алмый. Ләлә ханым Альфред турында кайтып әйткәч тә, алар үзара сөйләшүләрен киң җәелдереп җибәрделәр һәм дипломатларча осталык белән төп буынны тотып алдылар. Бу буын — авыл иде. Руфинә авылны сагынам, авылга кайтасым килә, дип аларның бәгырь итен аз ашамады. Ләкин әбисе инде бу дөньядан киткән, тегеннән хаты-хәбәре дә юк, каз-үрдәкләр дә, җиләк һәм балан каклары да салмый, шулай булгач, авылга юл киселгән. Аулак сөйләшүләрендә кызның әнә шул авылга омтылуы төп җирлек рәвешендә алынды, беренче дәвердә үзара аңлашу шартларында егет белән танышлыкны дәвам итәргә, авылга кыз белән егетнең рәсми дуслык сәфәрен оештырырга, ә инде икенче нәүбәттә өйләнешү мәсьәләсен кузгатырга, дигән нәтиҗәгә киленде. Сүз дә юк, ниятләр җентекләп уйланган, үлчәнгән һәм алды-арты исәпләнгән булса да, кызыксынучы якларның өметләре шактый гына аерылуын әйтмичә ярамый.

Югарыда билгеләп үтелгәнчә, төп буын чыннан да дөрес тотып алынган: Руфинәнең әбисе янында уздырган бәхетле көннәрне, шул көннәр белән бергә авылны сагынуы хак иде. Ул Казанны, аның шау-шулы урамнарын, чакрымга сузылган чиратларын күрә алмый, трамвай-троллейбустагы этеш-төртешләрен, хлорлы җылы суларын сөйми, аны гел сагалап-тикшереп торучы, акыл сатучы әтисе белән әнисен яратмый иде. Альфред йөзендә ул гөнаһсыз, тәҗрибәсез авылны таныды, әнә шул җене котырган нәрсәләрдән вакытлыча булса да күз күрмәслек еракка алып китүче затны күрде. Шуның өстенә Альфред, кайсы якка теләсәң, шул якка бөгәрлек яшь, чибәр, теле бар, Руфинә кечкенәдән үк хыялында йөрткәнчә озын ботлы, бер сүз белән әйткәндә, нинди генә компаниягә алып барсаң да, ким-хур булырлык түгел.

Альфред исә башкачарак исәп белән янды. Институт дигән әйбер аның өчен түтүт. Башыңда җил уйнаган килеш кая тыгыласың? Имтиханнар беткәч, авылга кайтырга, укырга кердем диярга һәм август азагында Казанга ычкынырга. Һәм биредә аның бердәнбер таянычы — Руфинә. Байлыгы җитешле, ә иң мөһиме — квартирасы бар. Кешенең бит хәле мөшкел. Кошлар гына ул, кая барса, шунда оя кора. Адәм баласына кеше кулына карап торудан бүтән чара юк, бигрәк тә шәһәр җирендә. Руфинәгә өйләнү турында сүз дә булырга мөмкин түгел. Альфред үзеннән кимендә ун яшькә кечерәк, иң чибәр, иң акыллы, аның өчен үлеп торучы кызны табача-

гына әз генә дә шикләнми. Фил гәүдәле Руфинәгә боларның берсен дә сиздерергә ярамый, сиздермәү өчен аңа бертуктаусыз: «Синең өчен үләм, сине яратам, нечкә билем, акыллым»,— дип кенә торырга, янында һәр теләген үтәп бәтерелергә кирәк иде. Башыңа төшкәч, анысына гына түзәсең, күбрәгенә дә түзәргә туры килә. Мәсьәләнең бит икенче ягы да бар: Альфред уйлавынча, Руфинә аңа егылып гашыйк, бу якты дөньяда Альфредтан башка яшәүне күз алдына да китерә алмый иде. Аның бу тойгысын сүндермичә дөрләтеп торсаң, күп нәрсәләргә ирешеп булачак.

Заһит Рәхмәтуллович белән Ләлә ханым яшерен сөйләшүләренең төп нәтиҗәсен Руфинәгә башта бик сакланып кына, читләтеп, ишарәләр белән генә җиткерделәр, ниятләренең нигездә кызларыныкы белән туры килүен белгәч, аңа ачыктан-ачык сәяси басым ясарга керештеләр. Бу вакытта Альфредның Казанда яшәвенә инде өч атна тулып килә, ягъни имтихан һәм конкурс нәтиҗәләре әйтелер чак, димәк, аның авылга кайтып китәр көннәре якынлаша иде. Шушы шартларда Руфинә дә уртак ниятне тормышка ашыру өчен актив хәрәкәткә килде. Бер бик матур кичне йокы бүлмәсендә шаярышып ятканда ул Альфредның борынына шалт итеп чиертте дә (сүз уңаеннан әйтим, бу аның иң яратып башкара торган даими шөгыленә әйләнде) мондый сорау бирде:

— Альфа, ә син миңа авылыңны кайчан күрсәтәсең?

Егет өчен бу иң дәһшәтле сорау иде. Ул Руфинәне алып кайтырга, беркемгә дә күрсәтергә теләмәде, бу хакта уйларга да курыкты. Шуңа күрә шаярту белән котылмакчы булды:

— Аның нәрсәсен күрәсең инде, авыл белән шәһәр арасындагы төп аермалар күптән бетте бит.

— Ах, син озорник!— диде Руфинә чиртүен кабатлап.— Ә минем авыл урамнарындагы асфальттан йөрисем килә.

— И җаным, нинди асфальт ди ул, минем салгач әзрәк шыттыра торган гадәтемне беләсең бит.

— Ах, озорник!

Альфред аңа җайлап кына урамнарда яз-көз резина итекләр белән дә йөрерлек түгеллеген, әрәмәләрне сыер-сарыклар ашап бетереп килүен, елганың кибеп баруын, чөгендерләрне чүп, бәрәңгеләрне колорадо коңгызы басуын сөйләп күрсәтте. Ләкин Руфинә боларны ишеткәч дәртләнеп кенә китте.

— Бик шәп!— диде ул кулларын чәбәкләп.— Әле мин элекке авылны күрә алмыйм икән дип кайгырган идем.

Шулай итеп, чигенер юл калмады. Ул, әтием дә мал печүче генә булып эшли, димәкче иде дә тыелып калды, бу факт аның абруен кисәчәк. Анысына соңрак та өлгереп була.

Альфред өчен хурлыклы солых төзүдән башка юл калмады. Руфинәнең машинасы белән кайтырга, икебез дә бер институтка укырга кердек, диярга, кояшта кызынып, коенып ял итәргә дә бергәләп китеп барырга, дигән карарга килделәр. Билгеле, өйләнгән кеше төсле чит-ят хатын-кыз ияртеп кайтып төшкәнгә әтисе котырыр, әнисе шатланыр, авыл халкы тегеләй дә, болай да сөйләр, классташлары төпченер, әмма ничек кенә булмасын, аның укырга кергәнлегенә барысы да ышанырлар, димәк, тавыш-гаугасыз гына Казанга китү хәл ителер. Руфинәнең көенә генә торганда аңардан башкача берничек тә ала алмаган нәрсәләрне алып булачагын Альфред яхшы аңлаган иде инде.

Менә күчтәнәчкә базардан лимон, анар, өрек, йөзем җимешләре кебек әйберләр алынды, машинаның багажнигы колбаса, һиндстан чәе, затлы эчемлекләр, тәм-том белән тулды. Ләлә ханымның һәм Заһит Рәхмәтулловичның катгый таләбе буенча Альфредның әтисе белән әнисенә бүләкләр дә алынды. Руфинә:

— Мин бит килен булып төшмим, кунакка гына барам,— дип караса да, аның авызын шундук томаладылар.

Руфинә дә артык карышмады, ник дисәң, акча җәлләп торасы юк, һәммәсе дә Альфред хисабына алынды. Ул исә саранланып тормады, Казан урамында акча тоткан килеш кунып чыгарга урын, ашарга ризык таба алмыйча газап чигеп йөрү аңа акыл керткән, Руфинәнең алтыннан да кыйммәтрәк зат икәнлегенә инандырган иде.

Менә барысы да әзер. Иртәгесен сәгать унда ук кузгалырга булдылар. Моның өчен тугызда ук торырга кирәк иде. Ләкин ун минут бәхәсләшкәннән соң, Руфинә, сәгатьнең шылтыравын унынчы яртыга куябыз, иркенләп өлгерәбез, диде. Ул әйткәнчә куйдылар да йокларга яттылар.

4

Сәгать бик озак шалтырады. Икесе дә, уянсалар да, күзләрен ачмадылар, кыймшанмадылар. «Иртә торырга кирәк, иртә торырга кирәк»,— дип кыткылдаган өчен Руфинә Альфредны эчтән генә сүкте. Ник кирәк иде инде бу кабалану? Аларның поездга йә самолетка ашыгасы бармы әллә? Әтисе белән әнисе Руфинәгә тәкрарлап әйттеләр: берүк авылга кайткач йоклап ята күрмә, анда кешене күпме вакыт йоклавы белән бәялиләр, диделәр. Авылда иртә торасы булгач, монда чакта йокыны туйдырырга кирәк ләбаса!

Руфинә бераз йоклап алды. Карале, гел кирәксезгә ник кирәк булган бу кабалану? Иртән ни, кичтән ни, иртәгә ни барыбер түгелмени? Әйтерсең, арттан куалар, әйтерсең, аларның кайтуын әзерләнеп көтеп торалар. Юк, рәхәтләнеп йокларга кирәк һәм ул изрәп тә китте.

Альфред Руфинәнең башлап торуын көтте. Чөнки кем алдан тора, шул кеше чәй куярга, ашарга әзерләргә тиеш, ә тормаучы ул вакытта рәхәтләнеп йоклый ала һәм ул бәхетле кеше, һичшиксез, Альфред булырга тиеш иде. Болай да аңа эш муеннан, димәк, ял кирәк. Ул күпме генә ятса да йоклый алмады, ә Руфинә мес-мес сулап йокыны иште генә. Бу гаделсезлек Альфредның ачуын китерде. Әгәр үзе дә йоклый алса, ул, әлбәттә, башын да күтәрмәячәк иде, ә болай Руфинә рәхәтләнеп, ул уяу хәлдә интегеп яткач, түзмәде, торып аңа да эндәште. Руфинә күзен ачмады, авызын ачмады, кымшанмады, каяндыр борын астыннан:

— Нигә иртә уятасың? Сәгать ничә?— дип мыгырданды.

— Унбер тула инде...

— Сәгать шылтырамадымыни?

— Шылтырамаган шул,— диде Альфред.

— Шылтырый да алмагач, ник чыгаралардыр шуны,— Руфинә икенче ягына борылып ятты.— Чәй куйдыңмы?

— Юк әле...

— Әзер булгач эндәшерсең.

Чәй кайнап, өстәлгә тегесен-бусын тезгәч, Альфред Руфинәгә эндәште.

— Торам,— диде ул ишетелер-ишетелмәс тавыш белән.

Чирек сәгатьтән соң Альфред тагын уятты.

— Торам,— диде Руфинә шактый нык тавыш белән.

Өченче мәртәбәсендә Руфинә одеалын Альфредка таба селтәп үк җибәрде һәм:

— Күрмисеңмени, торам бит инде!— дип кычкырды.

Альфред каршы әйтмәде, каршы әйтүнең бөтенләй көтелмәгән

нәтиҗәләргә китерү ихтималы барлыгын ул бик яхшы сизде. Руфинәнең үз көенә торып, үз көенә юынып, үз көенә киенүен сабыр гына көтте.

Ашарга утыргач, Руфинә нишләптер кәефем юк дип, бер шампан шәрабе ачтырды, аны эчеп бетерделәр. Альфред, Руфинәнең рульдә барасын уйлап бераз шөлләсә дә, берни әйтмәде. Чөнки, беренчедән, кичтән күбрәккә киткән, үзенең дә башы шаулап тора, икенчедән, болай акрын кыймылдаучан Руфинә машинада бик кызу йөри, ә салмаса, әллә ачудан, әллә үз-үзенә артык ышанудан, коточкыч куа иде. Аның машинасына утырганда Альфред һәрвакыт кәфенен муенына урый, бөтен гәүдәсе пружина кебек киерелә, тешләрен чытырдатып кыса, аякларын машина төбен тишеп чыгардай итеп тери. Руфинәнең «Жигули»е башкаларныкы кебек туры гына бармый, еландай хәрәкәтләнә, берсенең алдына, икенчесенең артына төшә, тау кадәр машиналарның көпчәгенә бер-ике сантиметр терәлә язып үтә.

— Әллә син куркасыңмы?— дип сорады ул бервакыт.

Егет башың белән ничек инде «куркам» дип торасың. Альфред:

— Юк,— диде.

— Курыкма, минем реакция отличная.

Ул әйтүен әйтә дә, барыбер шикләндерә шул.

Ниһаять, кузгалдылар. Урамнардан ярыйсы гына узган Руфинә, Казанны чыгу белән спидометрны йөз егермегә җиткерде. һәм шул килеш газны киметмәде диярлек. Каршы килүче, яисә алар узып киткән машиналар чышт-чашт итеп юк булдылар. Бер сәгатьтән артык кайткач, Альфред әзрәк йокымсырап алырга ниятләде. Күпме шулай баргандыр, машина уңга-сулга боргалануга уянып китте. Руфинә күзләрен угалый иде. Альфред аңа аптыраулы караш ташлады:

— Ни булды?

— Йокымсырап кителгән,— диде Руфинә иснәп.— Алай озак түгел, барсак бер-ике километр барганбыздыр...

Альфредның коты очты, шуның белән бергә йокысы да очты. Йә аллам, димәк, алар үлемнән калганнар! Шуннан соң ул Руфинәне юл буе сөйләштереп кайтты. Әтисенең райком секретаре түгеллеге дә әйтелде. Әмма ул барыбер йокымсырап-йокымсырап китте. Ахырда туктап, бер елгада коенып алдылар, термостан каты чәй эчтеләр. Шуннан соң гына Руфинәнең күзе ачылды.

Кояш офыкка якынлашканда, алар Дулкынбаш җирләренә килеп җиттеләр. И авыл, син һаман тырышып-тырмашып яшәп ятасың. Синдә рәхәтләнеп карарлык, гаҗәпләнерлек әйберләр әлек тә житәрлек иде, хәзер дә күп. Әнә синең арыш-бодаеңа, борчагыңа караганда солычасы бермә-бер күбрәк булган иген басуларың! Менә синең әллә күктән, әллә җирдән агу сиптерү сәбәпле, яртылаш саргаеп кипкән каенлыгың! Әнә буеннан-буена куәтле насослар белән көне-төне суын суырта торгач саегып беткән, бер генә төнбоегы да калмаган, өстеннән кара нефть өреләре һәм җәйләүләрдән төшкән сыер тизәкләре агучы үлмәс Чалмыя елгасы! Менә әлек озын-озын печән эскертләре тезелеп торган болында һәр үләнне тамырына кадәр кыркып, хәрби дивизия кебек тигез рәт булып йөрүче сарык көтүләрең! Әнә сөт планын үтәтү өчен әрәмә арасына, аның соңгы карлыган, шомырт, балан куакларының ботак-яфракларын ашаучы һәм сындыручы сыерларың! Менә куәтле машина-тракторлар ермачлап бетергән, эскәк белән өзеп алырга сыңар үләне булмаган кәкре-бөкре урамнарың! Әнә тигәнәк, алабута баскан хуҗасыз өй урыннары, кызыл миләш тәлгәшләредәй колорадо коңгызы каплаган бәрәңге бакчаларың! Кояш, шушыларның барысыннан да качып баргандай, кып-кызыл булып офыкка якынлашты...

Урамда машинаның төбе тиюдән куркып, Альфред аны ындыр ягындагы тар тыкрыктан гына алып керергә булды. Тигез, бәпкә

үләнле ындыр юлыннан чажлап килеп тыкрыкка борылуга, олы фаҗига була язды. Тыкрыкның нәкъ уртасында алдын кыйблага, артын машинага каратып Убырлы Мөштәфширә чүгәләгән иде. Руфинә кисәк тормозга басты, машина әллә нинди тавышлар чыгарып, аңа әз генә терәлмичә туктап калды. Убырлы яртылаш борылып әрекмән яфрагы өзеп маташкан җиреннән сикереп торды да җыеп токкан итәген һаман төшермичә кисәү агачы төсле кәкре аяклары белән тыкрыкның аргы башына йөгерде. Руфинә белән Альфред артка борылып күләргә тотындылар.

— Кем ул?— диде Руфинә күлүеннән тыела алмыйча.

— Аның исеме Убырлы булыр.

Бу карчыкның ничә яшьтә икәнлеген дә белүче юк, ул ялгыз гомер итә, имештер, киптереп сукыр тычкан, пешереп кара елан ашый, дип сөйлиләр. Мөштәфширә карчыкның кинәт кыстала, кысталса, бер минут та түзә алмый торган гадәте бар һәм шуның аркасында аның үзе күргәннәрен дә сөйләп кенә бетерерлек түгел иде. Бер елны дөм караңгы кичтә Куян Рәхмәйләре турыннан узып барганда кинәт шулар ишек алдына кереп чүгәләгән бу. Әмма Рәхмәйнең бозау кадәр бурзаеның оясы каршына туры килгән. Бурзай, ни микән бу диптер инде, иң элек боз кебек салкын борыны белән моның шәрә тәненә тиеп алган, аннары кот очарлык итеп бер генә мәртәбә «Һау!» дигән. Убырлы, итәген җыеп тоткан килеш, туптан аткан ядрә кебек, боларның өенә барып кергән, үзе һаман бәвел кыла, ди. Куяннар тугыз җан тезелешеп өстәл янында ашап утыралар икән. Куркудан бөтенесе кайсы кая качалар. Рәхмәй үзе, каушавыннан нишләргә белмичә, кашыгындагы токмачын мыегы белән борын арасына төртә, ди. Ике яшьлек кызы да кача алмаган, ул кыз шуннан соң тотлыга торган булып калды.

Узган кыш Мөштәфширә карчык, өем салкын, дип, Васбиҗамал карчыкка кунарга барган. Төнлә кысталып уянган да аралыктагы иске чиләкнең капкачын ачып шуңа утырган. Гөнаһ шомлыгына каршы ул көнне Васбиҗамал, Убырлының сөякләре җылынсын әле, дип миченә бик каты яккан, шаулап торган имән күмерен теге чиләккә салып куйган булган. Убырлы утыруга кайнар пар тегене ракета урынына күтәреп җибәрә язган. Күтәрүе әллә ни булмас иде, әссе пар тегенең барлы-юклы итен ботыннан аркасына кадәр көйдергән дә төшергән. Мөштәфширә карчык күрткә чыгып аунаса да, соң булган — аны ашыгыч ярдәм машинасы белән больницага алып китеп, ул шунда кыш чыкты. Атрай Ибрае аны больницада күрдем, бер малай тапкан, тач Ахшам Талибы (сиксән алты яшьлек ялгыз карт), суеп каплаган төсле, сакалы гына юк, дип сөйләп йөрде.

Күлешкән арада болар һәммәсе дә Альфредның күңеленнән узды. Мөштәфширә карчык та юкка чыккан иде. Ашыкмыйча гына тыкрыктан төшеп урамга борылдылар, капканы ачып ишек алдына кергәч кенә өйдән әнисе йөгереп чыкты. Капылт сөендерәбез, дип, алар кайтачакларын хәбәр итмәгәннәр иде. Әнисе бердәнберенең машина белән кайтып керүенә ышанырга да, ышанмаска да белмәде. Ул Руфинә белән баш иеп кенә түгел, кул кысышып күреште. Альфредның укырга керүе, Руфинә белән бер төркемдә укыячагы турында ишеткәч, Кәүкәбелҗәннәт аларны берәм-берәм кочып чыкты, ә кызны йомшак, итләч аркасыннан шапылдатып сөйде. Үзе бертуктаусыз гел ягымлы сүзләр сөйләде, имтиханнар бик авыр булмадымы, диде, нигә алдан хәбәр итмәдегез, диде, әзерләнеп көткән булыр идек, диде, әле өйгә кереп китте, әле йөгереп тышка чыкты, хәзер аш салам, диде. Альфред белән Руфинә аны ул ниятеннән кочкә туктаттылар, берни дә кирәкми, һәммәсе дә бар дип, күчтәнәчләр белән өстәлне тутырып ташладылар. Бу кадәр сый-нигъмәтне күргәч, Кәүкәбелҗәннәт

«ах» итте, аларны тагын бер мәртәбә сөеп, иркәләп чыкты, дәртләнеп өстәл әзерләргә тотынды.

Ире Газдалдан башлап (аның бүген кәеф-сафа коруы аркасында өйгә кайтып җитмәвен укучылар гафу итсеннәр) авылдагы һәрбер кеше аны Җәннәт дип кенә атаса да, без, таныклыгына язылганча, тулы исем белән атау гадел булыр, дип уйладык. Ни өчен ата-ана куйган исемне өтеккә әйләндерергә? Икенчедән, Кәүкәбелҗәннәт ханым үзе гәүдәгә зур да, таза да түгел. Болай да кечкенә нәрсәне киметү ничектер гаделсезлеккә охшый кебек. Шуның өстенә, бәләкәй чакта аны чем-кара чәчле, карлыгандай күзле, тәненең чутырдай булуы сәбәпле, күмер чүлмәге, дегет лагуны, дип кенә йөрткәнлекләрен дә әйтсәк, укучы безнең хаклы икәнлегебезгә үзе дә ышаныр. Дөньяның ир-ат токымына кермәгән икенче яртысы вәкилләренә тулаем диярлек хас булганча, Кәүкәбелҗәннәт ханымның бөтен көче телендә иде. Ул тел кирәк чакта ягымлы һәм йомшак, кирәк чакта шаян, кирәк чакта ачулы һәм өттереп тә ала белә! Ә кайчан ни рәвешле сөйләү мәсьәләсе аның яшәү принципларына бәйле иде. Әйтик, инде егерме елга якын балалар бакчасы мөдире булып эшләүче Кәүкәбелҗәннәт ханым кешене башкалар алдында тәнкыйтьләп түгел, ә бәлки югары күтәреп тәрбияләүне алга сөрде. Еракка бармыйча, ире Газдалны гына алыйк. Газдалның салырга ярактанын, турысын әйткәндә, эчмичә тора алмаганлыгын авыл халкы белүгә карамастан, Кәүкәбелҗәннәт ханымның беркемгә дә аны, шыр исереп кайткан, дип яманлаганы булмады, киресенчә, бүген дуңгызларга укол кадаганнар, бик нык талчыккан; койма койган иде, биленә төшкән, шуңа күрә көч-хәл белән генә атлый, дип сөйләде. Газдал эштән кайтышлый Чалмыя ярына таеп егылып, өс-башы кызыл балчыкка буялса да: «Балыкка барган иде, бәләк буе корбаннар алып кайткан»,— дип абруен күтәрә. Газдалның пычранып кайтканын күрүчеләр дә икеләнергә яисә фикерләрен үзгәртергә мәҗбүрләр иде. Кайда да булса берәр нәрсә, әйтик, мич чыгару хакында сүз чыкса, Кәүкәбелҗәннәт ханым: «Безнең Газдал аны менә дигән итеп чыгара да куя»,— дип ирен мактый. Газдалның ел саен мунчасына мич чыгаруы, ул мичнең ел саен ишелеп төшүе мәгълүм булса да, исереклеге, булдыксызлыгы өчен Кәүкәбелҗәннәт өйдә аның җиде кат тиресен салдырса да, халык алдында беркайчан да яманламады. Өйдә аяк астына салып тапта, муенын рашпил игәве белән ышкы, кәҗә маен чыгар, ә инде кеше алдында күккә чөй, табын, зурла — шул чакта аны да кеше итәрсең, үзең дә яхшы хатын булырсың. Шушыннан да изгерәк, акыллырак тәрбия принцибы була аламы? Юк, әлбәттә.

Кәүкәбелҗәннәт ханымның малаен яманлар чаклары, кычкырып елардай көннәре бик күп булса да, аның турында да теш арасыннан ялгышып ник бер яман сүз чыгарсын! Альфреды хакында әледән-әле:

— И акыллы, и булган, и башлы, белмәгән нәрсәсе юк, эшләмәгән эше юк,— дип, авыл хатыннарын таң калдырды.— Инде дә тәртипле, инде дә тынгысыз, кем бәхетләренә үсәдер,— дип мактады.

Альфред, әлбәттә, әнисе сүзләре белән үзе арасында җир белән күк аермасы булуын белсә дә, ул сөйләгәннәргә мөмкин кадәр охшарга тырышты. Малае бәрәңге утыртышамы, утын ярамы, кар көриме — боларның һәрберсе ун булып бәбәйләде, бөтен авылга таралды. Альфред соңгы елын укыганда Кәүкәбелҗәннәт ханым үзенең педагогик бурычларын түбәндәге сүзләр ярдәмендә тормышка ашырды:

— Булса да булыр икән адәм әулиясе,— диде ул.— Кушкан юк, әйткән юк, мәҗбүр иткән юк, китабына ябышкан, укый да укый, белемне су урынына эчә, алтын йә көмеш медальгә тартмагае...

Әнисенең юраулары укытучылар һәм классташлары колагына да килеп ирешә, алар әлеге сүзләр белән төрттерә, чеметкәли башлагач, Альфред тырышмас җиреннән тырышырга мәҗбүр булды, ме-

дальлек чамасы юклыгы мәгълүм иде, шулай да ике генә «өч» ле билгесе төшкән аттестат ала алды.

Ихтимал килен белән кайнана көрешкән арада бирелгән кыскача мәгълүмат укучыны хәзергә канәгатьләндерер дип уйлыйм. Иң куанычлысы шунда, тәүге очрашуда ук алар бер-берсен бик тә ошатыштылар. Кәүкәбелҗәннәт ханымның күрешкәндә:

— Исәнмессез!— диюе үк Руфинәнең йөрәгенә сары май булып ятты. Чөнки «с» авазын аның кебек матур әйтүче бөтен Рәчәйдә юктыр, булса да сирәктер. Ул «с», бераз сакаурак яңгырауга карамастан, сандугач авызыннан чыккандай, әллә нинди йөрәктән ала торган бер моң белән сызгырып ишетелә иде. Хикмәт «с» авазында гына булса! Кәүкәбелҗәннәт ханым Руфинәне әле үпте, әле аркасыннан сөйде, «Әлфрит улым, Руфинәгә сөлге алып бир, Әлфрит улым, Руфинәгә алма өзеп алып кер, Әлфрит улым, Руфинәгә таянып торырга мендәр салып бир»,— дип, йөгерә-атлый аның тирәсендә бөтерелде, җәймә булып җәелде, ефәк булып чорналды. Ошатмаган кешесенә кем шулай кылансын? Дөресен генә әйткәндә, кызның чиртсәң каны чыгарга торган алсу битләре, таза бәдәннәрен күрү белән Кәүкәбелҗәннәт ханымның күңелендә шатлык тойгылары кабынды. Алай-болай ерак киләчәктә киленгә әйләнеп куйса (тфү, тфү! әйтмәгәнем булсын!), монын килеш-килбәте дә (тфү, тфү! күз тимәсен!) аллага шөкер, эшкә дисәң дә, курка торган түгел. Кыскасы, ул гомер буе хыялланганны язмыш, үзе эзләп табып, машина руле артында ишек алдына китереп кертте. Кәүкәбелҗәннәткә, күпме генә ашаса да, балачактан ук ит кунмады. Ул ризыклар кая китәдер — бер ходай үзе генә белә. Ботгәүдәләрен уйнатып урамнан, кибет тирәләреннән бер генә мәртәбә урап кайту өчен ул ярты гомерен бирергә әзер иде. Әмма кыз чагыннан алып бүгенге көнгәчә ходай аңардан бу бәхетне кызганды. Врачлар: «Калкан сыман бизең дөрес эшләми»,— диделәр. Бик күпләрне бик күп сырхаулардан арындырган Убырлы Мөштәфширә аңа: «Эчеңдә унлы пилтә юанлыгы бик озын ак суалчан бардыр, шул дошман барлык ашаганыңны, бөтен каныңны имеп ятадыр»,—диде. Ике көн берәр стакан эчәргә кушып ниндидер яшькелт үлән суы бирде. Шуны эчкәч костырыр, теге суалчаның исереп авызыңнан чыгар, диде. Кәүкәбелҗәннәт үзен гомер буе газаплаган теге хәсистән шул кадәр дә нык котыласы килде ки, ире Газдалга ошаса, суалчанның бер стакан белән генә канәгатьләнмәячәген уйлап, ул төнәтмәнең берьюлы ике стаканын да эчеп җибәрде. Бераздан башы әйләнеп күңеле болганырга тотынды. Ул шатланып абзарга чыкты, суалчанны сугып үтерергә көрәкне җайлап тотты, укшый торгач, эче актарылып берни дә калмады, тик суалчан чыкмады, ул зәңгәрләнеп тирес өстенә ауды. Врачлар аны көч-хәл белән генә коткарып калдылар, «Ни эчкән идең?» дип җанын ашадылар. Кая ди әйтү! Терелеп кайткач, Мөштәфширә карчык аны тешсез авызын чәпе-чәпе китереп сүкте, дивана, диде, аның бер стаканы дару, ике стаканы бергә агу, диде, эчеңдә суалчан булмаган икән, майлырак ризыклар аша, диде. Кәүкәбелҗәннәт май ашап май эчте, барыбер котаймады. Шуннан соң ул тазару мәсьәләсендә врачлардан да, Мөштәфширә карчыктан да бөтенләйгә кул селтәде...

Руфинә көзге каршында төзәтенә башлауга, Кәүкәбелҗәннәт:

— Әйдә, улым, кыяр-помидор, ашка салырга суган-укроп алып керик,— дип, Альфредны җиңеннән әләктереп бакчага сөйрәде.

Анда чыгу белән пышылдап:

— Китер теге конвертны,— диде һәм кулын сузды.

— Мин бит аны тоттым, әни.

— Ничек тоттың?!— Кәүкәбелҗәннәт ханымның күз аллары караңгыланып китте һәм ул пешеп яткан помидор сабагы өстенә ларт утырды.— Син бит акчаны теге кешегә бирмәгәнсең!

Альфред бу сорауга җавапны Казанда ук әзерләп куйган иде.

— Руфинәнең әнисе кабул итү комиссиясендәге бер укытучы белән таныштырды. Акчаны шуңа бирдем, шул барлык имтиханнарны да җайлады,— диде ул.

Бердәнберенең күзен дә йоммыйча әйткән бу сүзләренә ана кеше ничек ышанмасын ди? Әлбәттә, ышанды һәм аягына да торып басты.

— Ярар, мең ярым каян килеп кая китмәгән, укырга керүен кергәч, анысы хәер генә,— диде ул, яшел суган кыяклары, укроплар өзәөзә.

Шул арада туктаусыз Руфинә хакында сорашты, аның япа-ялгызы ике бүлмәле квартирада яшәвен белгәч, әллә шатлануыннан, әллә гаҗәпләнүдән, йөрәгенә урын таба алмыйча, бакчаның дүрт почмагын бер итеп урап чыкты. Квартирасында төсле телевизордан, затлы келәмнәрдән башлап һәрнәрсә барлыгын, машинаның да гел үзенеке булуын, эти-әниләренең дә бик зур кешеләр икәнен ишеткәч, Кәүкәбелҗәннәтнең зиһене бөтенләй чуалды, кыяр өзәсе урынга кишер суырып чыгарды, помидор дип әле йодрык кадәр генә үскән өч баш кәбестәне төбе-тамыры белән йолкыды. Моның өчен аны һич тә гаепләргә ярамый, ник дисәң, ана кешенең башын Альфредның якты килачәге белән бәйле матур хыяллар томалап алган иде. Ул, ашына бәрәңге салгач, суган-укропларын турап куйгач, әле һаман күзге каршында утыручы Руфинәне ничәнчедер мәртәбәсенә аркасыннан сөйгәч, йөгерә-атлый күршесе Гайшәгә кереп китте.

— И, Гайшәкәем, Әлфритем Казаннан бер кыз белән кайткан, ул чибәрлеге, ул буе-сыны, бөтереп борынына тыкмалы инде,— дип Руфинә хакында үзенең бай фантазиясе белән бизәкләнгән мәдхиясен башлады. Гайшәнең тәмам өнен алгач, көянтә-чиләк белән чишмә суы алып кайтып килүче Фәһимә каршына йөгерде:

— И, малакаем, Әлфритем борынына бөтереп тыкмалы кыз алып кайткан, адәм әүлиясе инде...

Автор башкасын тыңламады, хатын-кыз сүзенә катышуы өчен хакка да, нахакка да гомер буе сүз ишеткәнлектән, бу очракта читкә китүне һәм казанында быкыр-быкыр итле шулпа кайнап торган йортка кайтуны хәерлерәк күрде.

## 5

Бу вакытта Руфинә машинаның ишеген ачып әчкә бөгелгән һәм чуар ата каз, борынын сузып, аңа таба якынлаша иде. Менә ата каз килеп җитте, бер генә секундка, нишләргә микән дигәндәй, тукталды да кызның симез балтырын тешләп алды. Руфинә чак кына машинаны башына киеп чыгып йөгермәде, әче итеп кычкырды. Альфред шул тирәдә иде, ата казны типкәләп читкә куды; күз яшьләре чәчрәп чыккан Руфинәне өйгә алып керде, каз томшыгы кызарткан урынны бальзам буяп марля белән чорнадылар. Руфинә бик озак тынычлана алмады, алар шуннан соң ата каз белән бер-берсенә дошманнарча караша торган булып калдылар. Моңа кадәр беркемгә тимәгән, урамда иң юаш ата казның болай кылануы һич тә аңларлык түгел иде: әллә ул Руфинәгә үзенең җенси хисләрен белдерергә омтылды, әллә аны яратмавын сиздерергә теләде. Ата казның эчендәгесен шайтан белсен аны.

Бераздан көтү кайта башлады. Ишек алдының яртысына кереп җиткән сарыклар, Руфинәне күргәч, берсен-берсе таптый-таптый дәррәү түбән очка кадәр артларына да карамыйча чаптылар. Мыш-мыш сулап тыныч кына кайтып кергән сыер, Руфинә турына җиткәч, кинәт колакларын шомрайтты, күзләрен акайтты, борын тишекләрен киңәйтте дә мөгезен сөзәргә җайлап аның өстенә килә башлады.

Альфред сыерның һөҗүмен кире кайтарды. Ләкин гомер-бакыена беркемне сөзеп карамаган бу мәхлукның болай кылануын ничек аңлатырга? Әллә француз хушбуеның исен яратмыймы мал-туар? Ни дә булса бар, әле бит төнлә Руфинәнең сыйрагын мәче тырныйсы, икенче көнне иртән беләгеп корт чагасы, төшлектә ботын этәч чукыйсы, урамга чыккан саен һау-һаулап этләр сырып аласы бар иде.

Әнә урам коймасы өстеннән Газдалның вак-вак тишекле ак капрон эшләпәсе күренде. Ул капкага таба якынлашкан җиреннән туктап калды. Газдал үзенең ахири дусты Әпсәләм белән голдыр-голдыр килде. Бер ярты ак, бер шешә кызыл, әллә ничә төрле әче бал эчү сәбәпле телләре көрмәлгәнлектән, аларның сүзләрен юньле-башлы аңларлык түгел иде. Әпсәләмнең күк күзләре тавык күкәе кадәр булганнар. Аның күз кабаклары эчкән саен киерелә баралар һәм, ниндидер бер чиге җиткәч, чүп төшсә дә, йомылмый торганга әйләнәләр иде. Ә Газдалның күзләрен беркайчан да юньләп күрә алмыйсың: алар вак бәлешнең әз генә купкан бөрелмәсеннән майлы шулпасы елтырагандай чалынып кына китәләр.

— Син мине ачуланмыйсыңмы?— диде Әпсәләм, күзен гел йоммыйча астан өскә таба Газдалга текәп.

— Юк ла инде, нишләп ачуланыйм,— диде тегесе, кырыкмаса кырык тапкыр бер үк сүзләрне кабатлап.

— Ә син ачуланасың төсле,— Әпсәләм аның саубуллашырга дип тоткан кулларын тагын да ныграк кысты һәм дустына күзләре белән генә түгел, шактый зур булып ачылган караңгы авызы белән дә төбәлде. Ничек кенә төбәлсә дә, ул «ачуланмыйм»нан башка җавап ала алмады, тагын чирек сәгать буе шул рәвешле тирән эчтәлекле, җитди сөйләшүдән соң гына дуслар көч-хәл белән бер-берсеннән аерылыштылар.

Газдал, ишек алдындагы ак машинаны күргәч, аптырап калды. Аларның мондый машина белән килердәй туганнары да, бүтән якын кешеләре дә юк. Ә шулай да кемдер килгән, димәк, аңа тагын «мәммәм» (аракыны ул шулай дип атый) эләгәчәк. Ул тәмләп төкереген йотып куйды, шулчак авызының уң ягындагы очлы азау теше тышка чыгып калды. Газдалның азау теше туганда ук булгандыр. Аның аскы ирендә шомарып, бирчәеп беткән үз эзе бар. Тешнең очы кырык градуслы салкында да, җәйге чилләдә дә, йоклаганда да, мунчада юынганда да тышка чыгып йөри. Шул сәбәпле ул мал печкәнне дә, Мәскәү метросын да, поезд-пароходларны да, хәтта айнытКычларны да — һәрбарчасын күрде. Күпне күрү ягыннан андый бәхетле теш, белмим, кемдә генә бар икән. Газдал яшь чакта бик ярпач булганлыктан, иптәшләре белән гел сугышып торды, сугышкан саен азау тешкә йодрык эләкте. Барлык биологик, физиологик кануннар буенча ул әллә кайчан төшәргә тиеш иде. Ходай тәгалә аны үзенең сейфында гына саклана торган иң ныклы материал белән беркеткәнлектән, азау барлык фәнни кануннарны кире кагып, үз кануны буенча яши бирде. Дөрес, еллар узу белән ул сөт сыман, балавыз сыман өлгерештәге кукуруз төсенә керде, өйләнешеп торуларының ничәнчедер елында Кәүкәбелҗәннәтнең бәрәңге тукмагы төшкәч, селкенә башлады. Шуннан соң әлеге теш, хуҗасы бик нык гырылдап йоклаганлыктан, кайнаган аш өстендәге турта шикелле төннәр буе дерелдәп гомер кичерде. Әгәр ул кыңгыраулы булса, авыл өстендә тәүлек буе челтерчелтер итеп матур тавыш яңгырап торыр иде. Авыл халкының бәхетсезлегенә күрәдер, теш кыңгыраусыз иде. Аннары кешенең һәрбер әгъзасыннан файда көтү дөрес тә булмастыр. Атрай Ибрае Газдалның азау теше ат бәйләргә уңайлы дип йөри йөрүен, тик аның сүзен авылда беркем дә җитдигә санамый. Туктагыз әле, без кечкенә әйбер белән артык мавыкмыйк, әнә бит Газдал өйалды ишегеннән чыгып килүче Руфинәне күреп алды. Атлылар атыннан төшеп, җәяүлеләр

ятып карарлык нинди зат бу?! Аның болай да гектарлы авызы бер почмагыннан икенче почмагына кер бавы сузарлык булып җәелеп китте. Әүлиядер бу! Ходай моңа һәммәсен дә житкелекле итеп биргән иде. Аның Мәскәү колбасасы кебек тыгыз тәненең зәңгәр күлмәген ерта язып торуы Газдалга тагын бер рюмка салып биргәндәй тәэсир итте. Чөнки ул, өйләнешкәч, Кәүкәбелҗәннәт түгәрәкләнеп китәр, дип өметләнсә дә, өмете акланмады. Аннары хатыны беренче баладан соң тазарыр дигән яшерен ышаныч белән яшәде, әмма ул да тормышка ашмады. Шуңа күрә Руфинә аңарда әллә нинди кайнар кичерешләр уятты. Аның энҗедәй тезелеп торган тешләрен күргәч, Газдалның азау теше хәтәр селкенергә тотынды. Кызның әле генә мичтән алып ак мендәр өстенә салган пар күмәчтәй күкрәкләренең яртылаш ачык булуы, борынына француз хушбуеның исе ярып керү Газдалның болай да әллә ни калмаган һушын бөтенләй алды, күптән йомшаган буыннары мультфильм сурәтендәге төсле кыеш-мыеш килде. Ул егылып та киткән булыр иде, әмма аны бер серле көч тотты. Юк, укучым, бер күрүдә гашыйк булу дип уйлый күрмә. Хикмәт шунда, Газдал үзен искиткеч мәдәниятле итеп күрсәтергә ярата. Моның өчен бер шарт — аның янында мәдәниятле кешеләрнең булуы гына кирәк. Кешедә омтылыш булырга тиеш. Шул серле көч әйдәмәсә, Руфинә каршына әнә шулай басып кила алыр идеме ул?

— Хә... хә-хәерле ки-кич!

Газдал күрешергә дип кулларын сузды. Ләкин кыз аның кулларын күрмәде, чөнки кызыл чыраеннан күзен ала алмады һәм:

— Исәнмесез,— диде дә, каршысына авызын киереп баскан крокодилдан качкандай, машинасына таба атлады. Газдал карашын аңардан аера алмады. Шулчак күршеләреннән кайтып кергән Кәүкәбелҗәннәт аның кабыргасына дык итеп төртте:

— Тагын лыкынгансың, исерек хәнҗә!— Ул аның азау тешенең дерелдәвеннән эчендә ниләр кайнавын бик яхшы аңлады.— Күзеңне майландырып торганчы юын, өс-башыңны алыштыр!

Кәүкәбелҗәннәт аның кабыргасына тагын берне төртте дә ашыга-ашыга өйгә кереп китте. Әмма Газдал хәзер, кабырга арасына динамит куеп шартлатсаң да, берни сизәрлек түгел иде. Машинадан иелеп нидер алучы бу гали зат белән чагыштырганда хатынының әйткән сүзләре дә, тирә-юньдәге барлык нәрсәләр дә төссез, әһәмиятсез, үткенче әйберләр, менә бу күз алдындагысы гына чын, мәгънәле, мәңгелек һәм аның өчен җаныңны бирсәң дә жәл түгел иде. Каяндыр Альфред килеп чыкты, исәнләште, Руфинә исемле бу кыз турында, аның машинасы белән кайтулары хакында сөйләде, тагын ниләрдер әйтте, аннары кызга дәште:

— Руфинә, таныш бул, бу — минем этием.

Кыз тураеп Газдалга борылды, ә ул эшләпәсен салды да башын иде. Аның коймакны шома ягы белән өскә каратып каплаган төсле түгәрәк пеләшен кичке шәфәкъ кып-кызыл итеп күрсәтте. Әллә шуңа, әллә Газдалның күкрәгендә кайнаган хисләрне тоеп, Руфинә тыйнак кына елмайды. Шулчак Кәүкәбелҗәннәт килеп чыкты.

— Әйдәгез, балалар, ашарга керегез,— диде ул ягымлы тавыш белән һәм ирен беләгеннән умырып өйгә сөйрәде.

Руфинә каршында аның күзләрен алартып, башлар иеп торуы Кәүкәбелҗәннәтне чыгырыннан чыгарды. Өйдә чит кеше булмаса, тәрбия йөзеннән ул аның ләшперәйгән чалбар төбенә берне тибеп алырга да күп сорамас иде, әлбәттә. Хәзер исә пышылдап кына игәүләргә калды:

— Оятсыз, олтырак чырай, исерек дуңгыз! Карале күзләрен?! Малаеңнан оялыр идең! Хәзер үк алыштыр өс-башыңны!

Бу сүзләр Газдалның колагыннан чәчрәп читкә генә очтылар, шулай да ул киемнәрен алыштырырга йокы бүлмәсенә кереп китте.

Мәдәниятле теге әүлия янында ферма исе сеңгән күлмәк-ыштаннан утыру дөрес булмас иде.

Ул арада Кәүкәбелҗәннәт мысыр күгәрчене гөрләгәндәй ягымлы тавыш белән яшьләрне өстәл янына дәште. Руфинәнең бер ягына Альфред, икенче ягына Кәүкәбелҗәннәт утырды. Кырынып, өр-яңа күлмәк-чалбарларын киеп чыккач, Газдал да танымаслык булып үзгәргән иде. Ул рюмкаларга аракы бүлде.

— Әйдәгез, балалар, сезне уңышлы укуыгыз, бәхетле булуыгыз өчен,— диде Кәүкәбелҗәннәт.

Бәллүр рюмкалар чең-чең итте.

— Бәхетле булгач, укуы да шуның эченә керә инде аның,— диде Газдал, хатынының сүзен төзәтеп.

Мондый хәл елга бер-ике мәртәбә яисә бер-ике елга берәр тапкыр гына була һәм ул Газдал өчен һич тә яхшылык белән бетми, яхшылык белән бетмәсә дә, Газдалның ниндидер җене уянып, тыелгысыз рәвештә шуңа этәрә, төнге күбәләк янган утка кергәндәй, ул дәртләнгәннән дәртләнәп, Кәүкәбелҗәннәтне үчекли иде.

— Укыган кешеләр дә бәхетсез була.— Кәүкәбелҗәннәт иренә юнәлтелгән кисәтүле карашына, Руфинә сизмәсен өчен, елмаю суты кушты. Аның сүзен яшьләр дә хупладылар.

— Кайтуың белән, Руфинә кызым...— диде дә Кәүкәбелҗәннәт, көлеп җибәрде.— Ялгыш кызым дидем, кабат хаталансам, ачуланмассыз бит?

Руфинә оялган кыяфәттә аска карады.

— Ачуланмам...

Берничә генә секундка уңайсыз тынлык урнашты.

— Помидорларын да авыз итегез әле, Руфинә,— диде Кәүкәбелҗәннәт әлеге тынлыкны бозу өчен.— Альфред белән әтисе үстергән помидорлар бу.

Ата белән улның карашлары мизгел эчендә очрашты да бер-берсеннән читкә тайпылды. Түтәлләрне казышканда Альфред азмы-күпме ярдәм итсә дә, помидорларын да, башкасын да Кәүкәбелҗәннәт берүзе утырткан, тәрбияләгән, үстергән иде. Моңа ул бары тик эш сәгатьләрен дөрес файдалануы һәм аек фикерләве аркасында гына ирешә алды. Аның карамагындагы ясле-бакчада адәм балалары чәчәктәй үсеп килгәндә үз бакчасын кысыр, чәчәксез калдырырга хакы юк иде Кәүкәбелҗәннәтнең. Ләкин ул, тыйнаклык саклап һәм тәрбия максатларын күздә тотып, бу хакта әйтмәде, бакчадагы барлык җиләк- җимешләрнең яшелчәләрнең уңуын, тәмлелеген ире белән малаена аударды. Помидорын кабамы, кыярын авыз итәме, Руфинә кызыл иреннәрен матур итеп бөреп соклануын белдерде:

— Шундый тәмле!

— Ә ник икәнен әйтимме?— диде Газдал азау тешен кулындагы чәнечкесе белән бер тактта селкетеп.

— Химия кермәгәнгә,— диде Кәүкәбелҗәннәт, иренең авызын яптырып, азау тешен яшертү нияте белән.

— Юк!— диде Газдал тантаналы төстә Руфинәгә туп-туры карап.— Минем кул тәмле, шуңа ул.

— Анысы хак, кулы үтә дә тәмле картның.

Бу сүзләрне ул хәзер генә түгел, җай килгән саен кабатларга ярата иде.

— Ә сез беләсезме, яхшы күңелле кешенең генә кулы тәмле була.— Газдал күзен Руфинәгә төбәгән хәлдә аңа гына мөрәҗәгать итте, әйтерсең, хатыны белән малае юк иде. Мәдәниятле кеше хөрмәтенә гадәттәгечә әз генә шыттырып та куйды:— Бу фән тарафыннан расланган. Тучны әйтәм мин сезгә.

— Хатыны яхшы ирнең генә кулы тәмле була.— Кәүкәбелҗәннәт тә елмаеп кызга карады.

Руфинә, гүя, залда утыручы могтәбәр тамашачы, ә алар икесе сәхнәдә аның өчен тырышучы артистлар иде.

— Хатын ир кулының түбән белгәннән соң гына яхшыра ул...

Газдалның чик-чаманы онытып баруына әченнән кайнап утырган Кәүкәбелҗәннәт бик матур елмаеп:

— Әйдәле, карткаем, аш кертик,— дип аны алгы якка алып чыгып китте дә, ишекне ябып, касыгына дыкылдатып төртте һәм пышылдап:

— Минем кул тәмлеме?!— диде.

Ире сынсыз катып торган арада ягымлы елмая-елмая ашларны ташырга кереште. Ә кулның тәмле булу-булмау мәсьәләсе шактый четерекле, аларның өйләнешүенең өченче төненнән үк килә иде. Шул төнне чалкан израп йоклап яткан Газдал күкрәк өстенә куелган уң кулын әллә бастырылып кинәт җәеп җибәрде. Кул, акчарлак канатыдай җәелеп, Кәүкәбелҗәннәтнең нәкъ күзенә килеп төште. Ул авыртудан чәчрәп торып утырды, ире сукканны аңлагач, ачуына буылып, идәннән иренең кырык бишенче размерлы туфлясын эләктерде һәм үкчәле ягы белән тегенең гырылдык авызы читендә дерелдәп торган азау тешенә тондырды. Теш дерелдәүдән, авыз гырылдаудан шундук туктады, Газдал корт чаккандай аягына басты, хатынын бугазыннан эләктерде:

— Ник миңа суктың?!

— Юк, син миңа суктың!

— Мин йоклап ята идем.

— Юк, мин йоклап ята идем. Син башлап суктың!

— Мин сукмадым, син суктың.

— Юк, башлап сугучы — син.

— Син ул башлап сугучы!

Кәүкәбелҗәннәт ягыннан чыбык очы-тал башы Убырлы Мөштәфширә шушы хәлне ишеткәч, әйткән:

— Кушылуларының беренче атнасында ук болай булгач, гомерләре ызгыш-талаш белән үтәчәк,— дигән.

Убырлының юравы әллә рас килде, әллә рас килмәде, моны кистереп кенә әйтүе кыен иде. Әлеге каһәрле төндә кемнең башлап сугуы хакындагы бәхәс, әледән-әле атучы вулкан шикелле, алар арасында гомер буе туктамады. Кулының тәмлелегенә килгәндә, чыннан да, Газдалны авылда сугымга чакыручылар шактый. Үзе айнык та булмый, ә шулай да ул чалган малның ите тәмле диләр.

Газдалның кулы мал суярга җиңел булса да, төшкән чакта шактый каты иде. Теге төннән соң Кәүкәбелҗәннәтнең күзе атна буе күгәреп йөрде. Карынындагы Альфредына дүртенче ай киткәч, алар тагын бик каты тузыныштылар. Моңа Газдалның дусты Әпсәләм белән исереп кайтуы сәбәп булды. Кәүкәбелҗәннәт башта аларның икесен дә сүкте, чагарга йөргән төкләтура шикелле, күзләренә керде. Әпсәләм кесәсеннән бер ярты чыгарып өстәлгә куйгач, яртыны идәнгә алып бәрде, Әпсәләмне өйдән куып чыгарды. Шунда ул ир кулының тәмен нык лап торып татыды һәм, аерылам, дип әниләренә кайтып китте. Әмма әти-әнисе аны кочак җәеп каршы алмадылар, киресенчә, «син үзең әшәке», дип сүктеләр. Көннәр үтте, Газдал аны килеп алырга уйламады да, чөнки ул, бәйдән ычкынып уҗымга кергән мал кебек, рәхәтләнеп эчте. Кәүкәбелҗәннәт ничек чыгып китсә, шулай кайтып керде. Тик ул акыллыланган иде инде. Тормышта һәммә нәрсә кабатлана тора, Газдал аны тагын канга батырып кыйнады. Бусында ул туп-туры милициягә барды. Җинаять эше кузгаттылар. Ике ай буе Газдал милиция, прокурор юлын таптады. Кимендә өч ел каты режимда төрмә, диделәр. Аның иң курыккан нәрсәсе төрмә иде. Ул көн саен кайнар күз яшьләрен агызып хатынына ялынды, гафу итүен, эшне яптыруын үтенде.

— Яңадан кыйнау түгел, чиертсәң дә, төрмәдә черисеңне оныт-ма!— диде Кәүкәбелҗәннәт.

Һәм моның шулай булачагы бәхәссез, чөнки Кәүкәбелҗәннәтнең туганнан туган энесе прокурор иде. Шуннан соң Газдал майлаган каешка әверелде. Аңа бер генә юл — хатынына тулысынча капитуляция ясау гына калды. Әчүен ул мәңге ташлый алмасын белә, армиядә көне-төне командиры белән бергә спирт эчеп, тәмам бозылып кайткан иде. Әгәр хатынына сукса, ул аны утыртачак. Бервакыт, Альфред тугач, ул эчеп кайтып өйдәге савыт-сабаны кырды. Унбиш тәүлек утырып кайтты, әмма Кәүкәбелҗәннәт аны өйгә кертмәде. Өй Газдалныкы булса да, хәзер аңа Кәүкәбелҗәннәт хуҗа иде. Исерек ирнең кемгә хаҗәте бар? Күпмедер вакыт урам эте кебек йөргәч, Газдал өтәләнеп, тәмам селәнҗеп, тагын Кәүкәбелҗәннәтнең аягына кайтып егылды. Шуннан соң акылга тәмам утырды. Дөрес, кайчакта элекке ирлек каны уйнап ала. Әйтик, ныграк салып велосипедына атлана алмаса яисә аның белән барганда егылса, Газдал велосипедын җиргә күтәреп бәрә, өстенә менеп таптый, бөтен ачуын чыгара. Тик моннан кемгә зыян? Үзенә генә. Икенче көнне велосипедны беркем дә төзәтеп бирми, үзенә кала. Атналар буе эчеп, алышынып чиккә җиткәндә, ул өйдәге ястыкны алып чыгып, чыбыркы белән яра. Чыбыркысын эш урынында яшереп саклый. Ни хикмәттер, Кәүкәбелҗәннәт аны моның өчен сукми, ул ястыкка тотыну белән чыгып китә. Ике-өч елга иренең шулай үзен күрсәтеп алуын гафу итә, күрәсең. Гаиләдә бит аның сүзе алдан йөри, Газдал үтәүче генә. Шуңа күрә, ата кеше булаrак, ул Альфредка да бернинди дә йогынты ясый алмады. Малай бәләкәйдән ук, нишләптер, аның сүзенә колак салмады, кушканын эшләмәде, этисе бер сүз әйтсә, ул ун сүз белән каршы җавап бирде. Альфредка әнисе сүзе генә күпмедер тәэсир итте. Шуңа күрә Газдал аңа сул кулын селтәде, бөтен уен, бөтен дәртен эчүгә салды. Аның өчен куаныч та, юаныч та, өмет-ышаныч та шул, бу бик рәхәт, бернинди борчусыз, бары тик бер генә кайгы, бер генә мәшәкать белән сугарылган бер күзәнәкле башмакчык кебек гади тормыш иде. Моның кичәгесе дә, бүгенгесе дә, иртәгәсе дә аңлаешлы һәм билгеле иде. Бүген Руфинәне күргәч кенә Газдал ничектер уянып китте, күңелендә әллә нинди аңлаешсыз тойгылар кымшанды. Ул бу күркәм затка ничек кенә булса да ошарга тырышты. Вакыт-вакыт кеше күп җирдә — йә җыелышта, йә мәҗлестә аның шушыңа охшаш халәт кичергәне бар һәм ул чакта Газдал Кәүкәбелҗәннәткә төртмә сүз әйтә, гел кирегә сукалый, аның сүзен юкка чыгарырга тырыша. Сыерның Руфинәне сөзәргә килүен телгә алгач, Кәүкәбелҗәннәт:

— Ул сине, кызым, Альфредтан көнләгән, Альфред бит аңа печән әзерли, өйдә дә карап-тәрбияләп кенә тора,— диде.

Газдал исә аның авызын томалады да куйды:

— Пүчтәк! Нинди матур чәчәк микән, дип ашарга килгән ул!

Бу сүз Руфинәнең дә, Альфредның да күңеленә хуш килде, алар рәхәтләнеп көлделәр. Газдал тагын да дәртләнебрәк китте. Табын ярлары уртасындагы сүз елгасы самолетларның егылуы, поездларның бәрелүе, газларның шартлавы, җирләрнең тетрәве кебек утрауларга кагылып узды, японнарның алга китүен, Американың байлыгын, бездә әйберләрнең кыйммәтләнүен һәм сыйфатсыз булуын, аптекаларда кирәкле даруларның юклыгын урап чыкты, җәйләрнең килешенә, игеннәрнең уңуына, авылда халыкның азаюына, Казанда яшьләрнең тәртипсезләнүенә килеп бүәлде.

— Альфред кебек, мәктәптә дә тырышып укысалар, өйдә дә баш күтәрмичә эшләсәләр, ул яшьләрнең сугышып йөрергә вакытлары калмас иде,— диде Кәүкәбелҗәннәт бу мәсьәләгә үзенең катгый мөнәсәбәтен белдереп.

— Ата сүзен тыңламаучылардан һәммәсен дә көтәргә була,— ди-

де Газдал һәм Альфредка туп-туры карады.

Кәүкәбелҗәннәт аңа каршы дөньяларның тынычлыгы Альфред кебек кыю, батыр егетләр кулында булуын әйткәч, инде ире бернинди каршы дәлил таба алмас дип уйлаган иде, әмма өмете акланмады.

— Юк, дөньяның тынычлыгы минем кулда!— диде ул, күкрәгенә бик итагатьле төстә кулын куеп.

Кәүкәбелҗәннәт бу юлы ачуын яшерә алмады.

— Ничек синең кулда?!

Аның тавышы нечкәреп чыкты, чыраен усал җыерчыклар каплады. Газдал уйчан кыяфәткә керде, күз карашы бер ноктага төбәлде.

— Өченче көн мин төш күрдем,— дип сөйләп китте ул.— Сыерлардан кан алабыз икән дим. Шул Атрай Ибраеның сөзгәк сыеры касыкка мөгезен китереп тыкты.

— Ай!— дип куйды Руфинә куркудан.

— «Ашыгыч ярдәм» белән больницага алып киттеләр, биш сәгать буе операция ясап бавырны тектеләр. Палатага чыгарып салдылар, төнлә бөтен авырулар үлеп йоклый, ә мин сызланып ятам. Ут яна операция урыны. Шулчак акрын гына палата ишеге ачылды да, чалма ураган, чапан кигән бер кеше килеп керде. Башы түшәмгә тия язып тора. «Мин Мөхәммәт пәйгамбәр булам, Газдалетдин,— ди.— Син үзеңне сакла, сиң барлык гавәм халкы өчен кирәкле кеше»,— ди. «Нишләп?» дим, көч-хәл белән телемне әйләндереп. «Аллаһе тәгаләнең әмере шундый,— ди.— Әгәр син үлсәң, икенче көнне үк сары халык Рәчәйгә сугыш башлаячак һәм дөнья бетәчәк»,— ди. Ул бераз тынып торды. «Менә шулай, мин исән чакта сугышфәлән булмаячак. Ну мин үлсәм — бетте, дөньяның асты өскә киләчәк».

Әллә ничек ышандырырлык итеп сөйләде Газдал, шуңа күрә Кәүкәбелҗәннәт «юк нәрсә» дигән мәгънәдә кул селтәсә дә, яшьләр елмаешып кына куйдылар.

— Алайса дөньяның иминлеге күбрәк миңа бәйле булып чыга икән!— диде Кәүкәбелҗәннәт.— Синең күпме яшәвең минем ничек тәрбияләвемә бәйле ләбаса!

— Дөрес, дөрес!— диештеләр бу сүзгә.

Шунда Руфинә рюмкаларны үзе тутырды да:

— Әйдәгез Газдал абый исәнлеге өчен тамчысын да калдырмыйча эчик әле!— диде, рюмкасын Газдал белән чеңләтеп чәкештереп.

Кәүкәбелҗәннәт белән Альфредны да көтмичә икәүләп эчеп җибәрделәр. Кәүкәбелҗәннәттә шул чакта Казан кызына карата әллә нинди бер бик үк яхшы булмаган тойгы уянып куйды, ләкин ул аны шундук үткәреп җибәрде һәм онытты. Ул коштабак тутырып ит китерде. Ит эре итеп туралган, бер-бер калҗасы ясле-бакча балаларының ашындагыдан ун-унбиш мәртәбә зуррак иде. Моны шулай Кәүкәбелҗәннәт кенә чагыштырып карый алды, әлбәттә. Газдал иткә кулы белән үрелмәкче булган иде, хатыны аның аягына басып өлгерде. Ул чәнечкегә үзенең йодрыгыннан әз генә кайтыш калҗа эләктерде дә умырып тешләде, әмма ярлы урыны туры килгәнлектән ит өзелергә уйлап та карамады. Газдал максатына чәнечкесен авызыннан читкә этү юлы белән ирешмәкче булды, алай эшләгәч, итнең тешләр белән чәнечке арасындагы өлеше корыч аркан кебек тартылды, азау теше, кәҗә тоягы күрсәткәндәй янтаеп, кырыйга чыкты. Руфинә каршында хәзер итнең тешләгән өлешен кире чыгарып, пычак белән турасаң да мәзәк, ә һаман читкә этсәң, итнең чәнечкедән ычкынып, борынга бәрү ихтималы да бар. Боларның һәр икесе дә мәдәни кеше гамәленә сыя торган нәрсәләр түгел иде. Үткәндәге бай тәҗрибәсенә таянып, Газдал итне шул бөтен килеш кенә чәнечкесе белән авызына этеп кертте дә чәйнәмәкче булды.

Ләкин моның өчен өске тешләрнең аскы тешләргә тиюе шарт, ә ит аңкау белән тел арасында авызны яптырып бетермичә тыгылып калды. Газдал аны әле бер, әле икенче ягына күчереп чәйнәгәндәй итте. Гөнаһ шомлыгына, плитәдә кайнар шулпада торган ит, кыздырылган тимер кисәге кебек, кайсы гына якка шудырсаң да, авызны пешерә иде. Бераз яньчеп йомшаткач, аны өзгәли алмасын аңлагач, Газдал итне йотып җибәрмәкче булды. Тик калҗа зур иде, ул тамактан шома гына үтәргә теләмәде. Газдалның авыз-борыны алга сузылды, кашлары күтәрелеп маңгаен җыерды, күзләре түшәмгә төбәлде, бугаз төене калҗаның тамактан үтүен белдереп акрын гына селкенеп куйды, әмма... Каһәр суккыры калҗа ашказанына төшмәде, тынны буып тыгылып калды. Хикмәт шунда — итнең ярысы соңгы урт тешнең астан ашалган бер киртенә ычкынмаслык булып эләккән һәм йоткылыкта туктап калган иде. Газдал йоту хәрәкәтләре ясады, бармагын авызына тыгып итне чыгармакчы булды, тик эләктерә алмады, иреннәре күкшелләнде һәм ул әкрен генә хатынына ава башлады.

Руфинә куркудан кычкырып җибәрде һәм сикереп торды.

— Тизрәк бул!— дип кычкырды Кәүкәбелҗәннәт Альфредка.

Газдалның бер мәртәбә мондый хәлгә тарыганы булганлыктан, алар эшнең нидә икәнен бик тиз аңладылар. Альфред кашык тыгып әтисенең авызын ачтырды, әнисе бармаклары белән капшап табып, теге ярыны өзде. Газдал ух итеп тын алды, еш-еш сулый башлады, ә бераздан күзен ачты. Шундый әкияти кичнең бозылуы, мәдәниятле Казан кызы каршында аның хурлыкка калуы бик тә аяныч иде. Шуңа күрә ул юри күзләрен йомды, Альфред белән Кәүкәбелҗәннәт аны йокы бүлмәсенә кертеп салдылар.

Газдал йокламаса да, тормады, Кәүкәбелҗәннәт урын җәяргә кергәч кенә кузгалды.

— Хәлең ничек?— дип сорады Кәүкәбелҗәннәт.

— Әйбәт,— дип мыгырдады ул.

Яшьләр машина янында, ә Кәүкәбелҗәннәт очына-очына урын җәеп йөри.

— Аларга урынны олы якка салам,— диде ул пышылдап.

— Ничек олы якка?

— Соң Альфредка диванга, Руфинәгә караватка.

— Малай аның янына барып ятсын дисеңмени?— Газдалның күзләре ачулы елтырады.

— Нишләп ятсын?— диде Кәүкәбелҗәннәт берни булмагандай.

— Тузга язмаганны... Верандада чебен дә юк, тыныч та. Кунак кызын шунда яткырырга кирәк.

Иренең бу сүзләре Кәүкәбелҗәннәтнең яшьләрне тизрәк кушу нияте белән ярсыган йөрәген бераз суындырып җибәрде. Чыннан да, дөрес әйтә ире. Гел берни булмаса да, авылда аларның бер бүлмәдә йоклавын әллә ничә мәртәбә күпертеп сөйләячәкләре билгеле бит. Ул ире әйткәнчә эшләде.

Төнлә Газдал туктаусыз әйләнде дә әйләнде, һава җитми дип печәнлеккә чыгып китте. Шул чак Кәүкәбелҗәннәтнең эченә шик төште. Гомере буе мәет кебек йоклаган ире нишләп болай кылана соң әле? Табын янында да гел беркайчан булмаганча җорланып сөйләште, Кәүкәбелҗәннәтне гел чәнчеп-чәнчеп алды. Кабык авызына ни туры килде шуны стаканлап түнтәргән Газдал аракыны да бик чамалап кына эчте. Гомергә тонган чабак балыгыныкы төсле күзләре дә яктырып киттеләр, гел Руфинәгә карап сөйләде, аңа карап көлде. Юк, бу хакта уйлау оят иде! Акылы булган хатын малаеның кызыннан ирен көнли димени?! Бу — түбәнлек иде. Кәүкәбелҗәннәт ул

хакта уйламаска тырышты. Мал тизәге арасында Әпсәләм белән әчеп йөргән кешедән нинди әхлак көтәсең? Алдан ук билгеле максат белән верандага яткырган ул Руфинәне. Шуңа күрә печәнлеккә чыгып китте дә. Хәзер сиздермичә генә кермәде дә микән?! Ул, аяк очларына гына басып чыгып, ишек ярыгыннан тын алмыйча веранда эчен карады. Руфинә үзе генә йоклап ята иде. Инде тынычландым дип кереп яткач, аның елыйсы килде, шушы кадәр түбәнлеккә төшкәне өчен ул үз-үзеннән оялды, әлеге уйларын каһәрләп читкә куды. Инде йоклап кына китәм дигәндә, ишек ачылган тавышка уянды. Альфред тышка чыгып кергән икән. Руфинәнең дә чыгу ихтималы бар лабаса! Шундый уйлар уйлап, ул төне буе сыңар керфек тә какмады. Инде тәмам башы тубалга әйләнгәч, ахмаклыгы, тинтәклеге, әшәке фикерле булганлыгы өчен үзен туйганчы сүкте, сүкте дә таң атканда йоклап китте. Йокысы каты булды, көн саен таң тишегеннән күзен ертып тора торган Газдал да бүген кымшанып карамаган. Кәүкәбелҗәннәтне күршесе Гайшә кереп уятканда көтү авылны чыгып киткән иде инде: юньсез уйның азагы һәрчак юньсез була шул!

Кәүкәбелҗәннәт ахмаклыгы өчен эченнән генә көне буе үзен тиргәп йөрде. Руфинәнең күзенә карарга оялды. Югыйсә, аның кайтуына куанырга кирәк аңа. Ник дисәң, ул иртәгә Чаллыга дүрт көнлек семинарга китә, өйдә йорт эшләренә хатын-кыз кала, булачак килен (тфү, тфү, әйткәнем түгел, кеше ишетмәсен) беренче сынауны ничек узуын да күрсәтәчәк. Моннан да уңайлырак очракны, юри уйласаң да, таба алмассың. Кичтән ул Руфинәне сыер саварга алып чыкты. Алланың рәхмәте, сыер аны хәзер ят итмәде, тыныч күшәп торды, ә Руфинә, озаграк булса да, сөтне савып бетерде. Башка мал-туар Газдал өстендә иде. Кәүкәбелҗәннәт он, йомырка, май, ит ише нәрсәләрнең кайда икәнен күрсәтте, өйрәтте. Руфинә: «Ие, ярар, аңладым»,— дип кенә торды.

Шулай итеп, Чаллыга ул тыныч күңел белән китте. Семинарга үзенең тәүге мәхәббәте Фәритнең дә киләсен белү аның күңелен аерата җилкендерде. Фәрит ерак түгел бер районда халык мәгарифе бүлеге мөдире булып эшли, ә семинарга чакырылучыларга җибәрелгән программада аның да чыгыш ясаячагы күрсәтелгән иде. Икесенең дә яшьлек хатирәләре кабат дөрләп китсен өчен, Фәрит бүләк иткән яшел күлмәген дә алды. Шуны кигән беренче кичне ул Фәрит янында кунарга калды һәм гөнаһсыз кыз чагы белән мәңгегә аерылышты... Малаена Әлфәрит дип исем куюы да юкка түгел аның.

Кәүкәбелҗәннәт ике сәгать алдан барып урнашты, яшел күлмәкне яхшылап үтүкләде, парикмахерскаяда чәчләрен төзәттерде, иң затлы хушбуйларын сипте, алтын муенсасын киде. Аның йөрәге егерме яшьлек чагындагы кебек сикерде, ул авыз эченнән туктаусыз үзләре җырлаган яшьлек җырларын көйләде. Фәрит белән очрашулар әллә нигә бер генә тәти, шуңа күрә алар бик кадерле, ләззәтле һәм онытылмас булып хәтергә уелалар иде.

Семинар башланды, әмма Фәрит күренмәде. Эше күп булгандыр, соңаргандыр дип тынычландырырга тырышты ул үзен. Ләкин чыгыш ясарга чират аңа җиткәч, семинарны алып баручы Фәритнең килмәгәнен әйтте. Шуннан соң Кәүкәбелҗәннәтнең колагына мөнбәрдән сөйләгән сыңар сүз дә кермәде. Аның күңеле рәнҗеш, ачу һәм каргыш белән тулды. Кичкә ул кунакханәгә хәлсезләнеп кайтып егылды, хәтта яшел күлмәген дә салмады. Төнне йокысыз уздырды, нишләптер уйлары авылга, үзләренең өенә йөгерде. Иң элек аны автобуска утыртып җибәргәндә Газдалның әллә нинди серле итеп карап калуы күз алдына килде. «Әллә Фәрит белән очрашасыны сизенәме соң бу?»— дип уйлаган иде Кәүкәбелҗәннәт шул мизгелдә. Хәзер ялгышканын аңлады: Газдал аңа: син тизрәк кит, монда

калгач күз күрер әле, дип калган икән ләбаса! Аның карашы нәкъ шуны аңлата иде. Кайсы кайда ятты икән? Әгәр кичәге кебек Газдал печәнлектә, Руфинә верандада, Әлфәрит өйдә ятса? Юк, алай һич тә ярамый! Әлфәритнең өстеннән трактор белән йөрсәң дә уянмаганын Кәүкәбелҗәннәт үзе дә, Газдал да белә. Аның маңгаена көчле кичерешләр тәэсирендә тир бәреп чыкты. Газдал кече якта, Руфинә түрдә, Альфред йокы бүлмәсендә ятса... Юк, болай да булмый. Кәүкәбелҗәннәт, елга аша кәбестә, кәҗә һәм бүрене ничек исән килеш чыгарырга белмичә баш ваткан теге кеше кебек, күңелендә әллә нинди вариантлар уйлап карады, тик бай хыялы ярдәмендә ничекләр кыландырса да, Газдал Руфинәгә тимәслек юлны таба алмады. Төне буена ул әллә ничә электрон-хисаплау машинасы башкарырлык гигант эшне ялгыз башы белән актарып атты.

Менә хәзер Руфинә верандада ятадыр. Таң атуга Газдал аны сыер саварга уятырга керәчәк. Ишек шакымас, янына керер, ә тегесе таралып йоклап ятар. Газдалның азау теше селкенә башлар, дәшмәс, кулы белән Руфинәнең тулы иңбашларына кагылыр, күкрәген сыпырыр. Аның кулы камсарга гына тора... Кәүкәбелҗәннәт уфылдап сикереп торды, ачуыннан йодрыгы белән мендәрен төйде, тагын ятты. Казан кызының да җаны бар, җаны барның тыны бар, дигәндәй, безгә, хатын-кызга, күп кирәкмени. Сыерны да Газдал белән бергә саварга кушты шул дивана булгач. Сыер савып кына калсалар ярый ла. Ул күз яшенә буылып мендәр читен чәйнәде. Әгәр алар янында булса, бу уйлары өчен ул үзен эт итеп сүгәр иде. Ләкин бит Кәүкәбелҗәннәт еракта! Күз күрмәс, кул җитмәс арада! Ул ераграк булган саен аларның якынаю ихтималы арта бара һәм өйдә моңа комачау ясардай беркем дә юк иде. Өч көн буе ни юньләп ашамыйча-эчмичә, ни йокламыйча бәргәләнгәннән соң, ул, бөерем авырта, дигән сылтау белән кайтып китте.

Урам капкасын атлап керүгә Кәүкәбелҗәннәтнең сумкасы төшеп итте, ул тораташ катты да калды; өр-яңа костюм-чалбар кигән Газдал ишек алды уртасында Руфинә белән үбешеп тора иде! Ире, капкага арты белән булганлыктан, аның керүен күрмәде. Кәүкәбелҗәннәт коймага сөяп куйган күсәкне алды да алар өстенә китте, бөтен авылга ишетелерлек итеп кычкырырга теләде, әмма тамак төбеннән хырылдаудан башка нәрсә ишетелмәде. Кабахәтләр, җир җирәнгечләре! Инде күсәкне күтәреп башларына орыйм дигәндә, авызын ачып туктап калды: Газдал кулъяулык почмагы белән Руфинәнең күзеннән чүп кенә алып маташа икән!

— Исәнмесез,— диде ул елмаерга тырышып, тик елмая алмады, тешен генә күрсәтте.

— Бәрәкәт, нишләп иртә кайттың? —«Хәлең ничек, исән-сау йөрдеңме, карчык?»— диясе урынга Газдалның сүзе шул булды.

— Әллә чүп кердеме?— диде ул, иренең соравына җавап бирмичә.

— Мин таба алмадым, син телең белән карап кара әле,— диде Газдал читкә китеп.

Кәүкәбелҗәннәт җайлап кына күсәкне җиргә ташлаган иде инде, Руфинәнең күзенә үрелде. Кызарып, яшьләнеп торучы бу күзгә ул тел очы тыгу түгел, лач итеп төкерер иде дә бит, ярамый! Менә бу вак тир бөртекләре бәреп чыккан курнос борынын да шырт итеп тешләп алыр иде. Күз кабагын әйләндереп, кулъяулык чите белән чүпне алгач, мөмкин кадәр ягымлы булырга тырышып, ул югында ничек торуларын сорашты, сыер интектермәдеме, диде. Сыерны Газдал үзе сауган булып чыкты. Бу башка сыярлык түгел иде. Күпме бергә яшәп, сыер имчәге тотып карамаган ире өч көн сыер сауган! Әллә соң Кәүкәбелҗәннәт саташамы?! Чүп алганда да, сөйләшкәндә дә ул Руфинәдән француз хушбуе исенә кушылып, тагын нindидер бик та-

ныш ис килүен дә сиздө. Нинди ис соң бу? Ул кызга якынрак килде һәм ап-ачык тойды: бу Газдал исе, аның үзенә генә хас әчкелтем-төчкелтем бер ис иде! Кәүкәбелҗәннәтнең күз аллары караңгыланып, башы әйләнеп китте. Аны-моны сиздермәс өчен өйгә ашыкты. «Әйдә әле»,— дип Газдалны да ияртте. Йокы булмәсендә өс-башын алышканда:

— Әлфәрит кайда? — дип сорады.

— Аны иртүк район үзәгенә ипигә җибәргән идем.

— Ә үзең?

— Әлфәрит: «Классташымны да күрәсем бар»,— диде.

— Нишләп машина белән бармадылар?

— Руфинәне уятмыйк,— дидек.

— Ә син нишләп эштә түгел?

— Бүген бармадым әле,— диде Газдал.— Син булмагач, эш тә күп.

Эчмәгән дә бу. Тахта башындагы егерме литрлы ачы бал да кимемәгән. Ул берничә мәртәбә иренә юри терәлә язып үтеп китте һәм аның аркасына салкын тир бәреп чыкты: Газдалның авызыннан француз хушбуе исе килә, ә ул хушбуй Руфинәдә генә бар иде!

Ул ашыгып верандага чыкты, изелеп беткән, җыелмаган урынны борынын тигереп-тигереп иснәде һәм йөрәге шартлый язды — урыннан Руфинә белән Газдал исе кара-катыш борынын ярып керде! Мәсьәлә ачык, икеле-микеле уйларлык урын юк иде, чөнки Кәүкәбелҗәннәтнең борыны ис сизү ягыннан авылда бер генә борын иде, аның берничек тә ялгышуы мөмкин түгел иде! Ул, гөнаһлы булмыйм дип, әле Газдал, әле Руфинә яныннан кабат-кабат үтте, Газдалдан Руфинә исе, Руфинәдән Газдал исе бөркелепләр дә килә иде. Шуның өстенә Альфред исереп, чәчләрен туздырып кайтып керде. Кәүкәбелҗәннәт аны Руфинә каршында: «Килгән кунакны ташлап йөрисең»,— дип сүкте, ә асылда мәмкә булганлыгы, ачык авызлыгы, берни дә сизмәве өчен әрләде.

Ул аш салып ишек алдына чыкса, тегеләр өчесе тагын җыелышып торалар. Әнә Руфинә Газдалның костюмыннан нәрсәдер алды да читкә өреп җибәрде, рәхәтләнеп көлешергә тотындылар. Йә бер аллам, син бу дөньяны Кәүкәбелҗәннәтне газаплар өчен генә яраттыңмыни соң?! Азау тешле ямьсез ирнең исереклеге өстенә инде аның күз алдында зина кылуын да күрсәтеп җәберлисеңмени?! Карале син аларның бөгелеп-сыгылып торуларын, теге карт пиусның кыланмышын! Кәүкәбелҗәннәтне бар дип тә белмиләр, күрмиләр! Әйтерсең лә, ул бу гаилә кешесе түгел, бер артык кашык, әйтерсең лә, ул кайтып кереп, аларның ашына таракан булып төште!

— Әйдәгез бакчага, коңгыз чүплибез! — дип кычкырды ул ачуына буылып.

— Нинди куңгыз? — дип сорады Руфинә, кып-кызыл иреннәрен ялап. Күрәсең, ул аны ашый торган берәр җимеш дип уйлады.

— Бик әйбәт әйбер ул, кызым, бакчага чыккач күрерсең,— диде Кәүкәбелҗәннәт, аны күзе белән ашардай булып.

Әмма аларны колорадо коңгызы чүпләргә бакчага алып керү ул көткәннең киресен бирде. Руфинә бәрәңге сабагы өстенә үтә нык бөгелә торган булып чыкты, ул башын аска игәч, болай да тар һәм кыска күлмәге билдән түбән өлештә гел калмады. Җитмәсә әллә черки тешләгәнгә, әллә бәрәңге сабагы тиеп киткәнгә Руфинә, «менә монда карагыз», дигән төсле юан ботларына чалт итеп китерде дә сукты, китерде дә сукты. Газдал аңардан күзләрен ала алмады, сукыр кеше кебек бәрәңге сабагы арасында кармаланып корт чүпләгән булып маташты, беркем берни сизми, дип уйлады. Кәүкәбелҗәннәт гел аларның арасында йөрде, кызны күрсәтмәскә тырышты, ләкин бу — чыпчыкның бройлер тавыгын үз шәүләсе белән капларга маташуы

кебек мәгънәсез бер шөгыль иде. Ахырда ул Газдалны: «Өр-яңа костюм-чалбарыңны бетерәсең, бар, алыштырып чык»,— дип өйгә куалады. Ире бакча капкасы янына да җитәргә өлгермәде, Руфинә: «Уф, чыдый алмыйм!» — дип турайды да бәрәңге сабаклары арасыннан арт саннарын уйната-уйната кереп китте. Ә Альфред берни сизми, коңгыз җыя. «Аңгыра зирәк! Тый теге картлач белән кызыңны, берни дә күрмисеңмени?!» — дип кычкырасы килде Кәукәбелҗәннәтнең. Ләкин бөтенесе ап-ачык, күзгә күренеп торуга карамастан, тотып «менә бит» дип күрсәтер нәрсә булмагач, алай дип кычкырыр җиреңнән кычкыра алмыйсың шул.

— Әйдә, син дә кер! — диде ул ачу белән һәм бәрәңге сабакларын таптый-сындыра өйгә таба атлады.

Өйдә анда бәрелеп, монда сугылып җанын куяр урын тапмагач, күршесе Гайшәгә кереп китте. Әмма ник кергәненә үкенде. Әйтерсең, Гайшә аның ни уйлаганын белгән һәм керүен көтеп кенә торган иде.

— Теге Казан кызын әйтәм, күршекәем, киленең булып куймагае,— диде ул биргән исәнлекне дә ала тормыйча.

— Нигә алай дисең? — Кәукәбелҗәннәт аңа туп-туры карады.

— Газдал белән бик килешteләр бит,— дип алып китте Гайшә.— Ничә карасаң да бергә, авызлары авызда, киңәшмичә берни дә эшләмиләр. Газдал әйбер какса, теге кыз кадак биреп тора, берсе битен юса, икенчесе сөлге суза. Су сибеп тә аерышлы түгел! Ә минем Кәшби киленне сөймәгән булды, шәһәргә чыгып киттеләр...

Гайшә күз яшьләрен сөртеп туктап калды, әмма шуннан бүтән бер сүз дә кирәк түгел иде инде. Кәукәбелҗәннәтнең йөрәгенә ут капты. Әле моңа кадәр аның күңел түрендә, «мин ялгышамдыр, миңа шулай тоела гына торгандыр», дигән уй яшеренеп ята иде. Гайшәнең сөйләгәннәре аның һич тә ялгышмаганлыгын кире какмаслык итеп раслады. Күршесенең сүзләрен ул тыштан: «Әйе, әйе, шулай була күрсен инде»,— дип җөпләп торса да, эчендә корбанына ташланырга әзерләнүче арыслан уяна башлады. Шушы минуттан ул Руфинәне күрә алмас булды.

Үзләренә чыккач, йокы бүлмәсендә башын тотып уйга чумды. Бу кыз бер зур түрәнең сөяркәседер, дип фикер йөртте. Алар үзләренең йөрешләренә квартирасын да бирәләр, машинасын да алышалар, башкасын да эшлиләр, ди бит. Яшь кенә килеш шулкадәр дәүләт гадел юл белән ничек килсен аңа? Юньле кеше бу кадәр тазармый да. Әнә бит аракыны эчә, селкенеп тә карамый. Димәк, өйрәнгән, һәммәсенә дә өйрәнгән. Соң нишләргә? Теге арысланны тышка чыгарып, аны Казанына куып кайтарыргамыни? Юк, моны эшләргә һич тә ярамый, бу кыз Әлфәрит өчен кирәк, вакытлыча булса да кирәк иде. Соң нишләргә? Аларның Газдал белән мачамайланып йөрүенә күз йомаргамы? Юк, нәрсә-нәрсә, бусы булмас инде! Кәукәбелҗәннәт үзеннән көлдермәс! Һәм ул бердәнбер дөрес юлны тапты: Газдалны үзенеке итәргә, иркәләп сөяргә, елмаерга-көләргә, көйләргә-чөйләргә, әвәләргә-шәвәләргә, Казан өстерәлчегенә борылып карарлыгын калдырмаска. Аңарда гәүдә булса — Кәукәбелҗәннәттә хәйлә бар, аңарда төс булса — Кәукәбелҗәннәттә көч бар, сөяркәдә кочак булса — ир хатынында пычак бар.

Ул яшел күлмәген, затлы алсу свитерын киде, төзәтенде, бизәнде, сөртенде, сибенде. Аккош кебек кенә атлап чыгып:

— Карт, өстәлгә помидор алып кер әле! — диде дә аккош кебек кенә атлап кереп китте.

Газдал хатынындагы бу үзгәрешне ничек бәяләргә дә белмәде, ни булмаска иң кызыл, иң пешкән помидорларны гына өзеп алып керде. Кәукәбелҗәннәт, иренең орлыкка калдырган иң эре, җитлеккән помидорларны алып кергәнлеген күрсә дә, тавышланмады. Менә өстәл янына утырыштылар. Кәукәбелҗәннәт үзенең көндәшенә ул

күрмәгәндә сугардай итеп карады. Ничек моңа кадәр аның кыланмышларына игътибар итмәде икән ул? Карале, ашыйм дип утыруын! Иренenә сыланган бер гәрәнкә помаданы саклау өчен ул авызын яртылаш ачып бик нык алга суза, кашыкны зур саклык белән шуңа турылап китерә. Аның очы иреннәргә, тешләргә тимичә, эчкә — тамакка таба кереп китә, әйтерсең лә, анда аш түгел, ә утлы күмер. Мина зарарсызландырганда сапер гына шулай сак эш итәдер. Кәүкәбелҗәннәт юри теге якка чыгып киткән булды, әз генә торды. Нәкъ Руфинәнең урындыгы турында бер селкенә торган сайгак бар иде, кабат кергәндә шуның башына шарт итеп басты. Урындык селкенеп куйды, Руфинәнең авызына инде килеп җитә язган кашыгындагы кайнар шулпа итәгенә түгелде. Ул чәбәләнеп сикереп торды. Кәүкәбелҗәннәт эченнән чиксез куанса, тантана итсә дә, тыштан борчылган булды, теге якта шактый керле, майлы чүпрәк бар иде, шуны алып кереп, чүпрәк корыганчы көндәшенең итәген ышкыды. Зәңгәр күлмәкнең ул туры корымлы кастрюль утырткан төскә керде. Аның берниен дә калдырмыйча алып бетерә, дигән булып, өстенә бер уч тоз сипте. Үзе эченнән рәхәтләнеп көлде, кикригең шиңдеме, диде. Аннары ул ит чыгарды. Газдал иттән курка иде, ул «ит ашыйсы килми» дип, фарфор чәйнек кадәр тәмам мәмрәгән бер помидорны алды. Моны пычак белән киссәң, бөтен эче агып бетәчәк иде. Шуңа күрә авызын бегемотныкыдай ачып аны яртылаш капты һәм куәтле казналары белән китереп кысты. Помидорга иң элек теге каһәр төшкән азау теш килеп кадалды, эчтәге масса куәтле кысуга түзә алмыйча, ватык клапанны ачкан шикелле, азауны читкә этәрде дә кызыл томат юан чәптерек ясап Кәүкәбелҗәннәтнең нәкъ күкрәк турына сиптерде. Газдалның күзе Руфинәдә иде, ул берни сизмәде, абайламады, помидорны согы чыгып беткәнче кысты... Яшел күлмәк белән бергә азау теш үзе дә помидор сүленә гарык булган һәм кишер очын хәтерләтеп салмак кына селкенеп тора иде.

— Ой, не могу!

Руфинә буылып көләргә тотынды, тыела алмагач, ишек алдына чыгып көлде. Кәүкәбелҗәннәт бер үзенең түшенә, бер Газдалның азау тешенә карап чарасыз калды. Әгәр теге күсәк кул астында булса, ике дә уйламыйча шуның белән азауга томырыр иде ул.

— Юри эшләдең син моны, юри эшләдең! — диде Кәүкәбелҗәннәт ажгырып һәм елый-елый свитеры белән күлмәген салып бәрде.

Кич Әлфәрит белән Руфинә беренче мәртәбә мәдәният йортына чыктылар һәм, бәхетләре бар икән, дискотека оештырылган көнгә туры килделәр. Күптән дискотекада булмаган Руфинә очына-очына биеде, мәдәният йортының инде әллә кайчан алыштырыласы сайгаклары ул сикергәндә сына язып сыгылдылар.

Ирдәүкә Илгизә танцы вакытында Әлфәритнең колагына пышылдап, аны үртәп алырга да өлгерде:

— Син тапкан бу кызга камыт-вәлүкләр табып, ат сабаны белән бәрәңге бакчасы гына сөрдерергә.

Авыл егетләре исә:

— Ай-яй, карале, Казанда әллә нинди казылма байлыклар бар икән,— дип тел шартлаттылар, ә Әлфәритнең үзенә:

— Ну, малай, эләктергәнсең кошны! — диделәр.

Каникулга кайткан студентлар да, килгән кунаклар да күп иде. Дискотека төн уртасына кадәр барды. Руфинәнең бик тә күңеле булды, алар таң йолдызлары калыкканчы Чалмыя буйларын урадылар, гашыйклар гына таба торган аулак урыннарга кереп кочаклаштылар, үбештеләр, инде ничә көннәр буе сусаган ләззәтләрне татыдылар. Йолдызлар аларга күз кысты, өй түбәсеннән ай каш сикертте, агачлар куе ябалдаш шәлләре белән каплады, йомшак үләннәр шуышында, безнең янда тукталыгыз, дип аякларыннан сыпырды. Мак-

танчык авыл этәчләре күрше тавыклары каршында җилле күренү өчен тамакларын ертып: «Кайтырга вакыт! Кайтырга вакы-ыт!» — дип кычкырмаса, алар бәлкем таң атканны да сизми калган булырлар иде. Руфинәнең помидор сиптергән чакта ук күтәрелгән күңеле тәмам түбәсенә җитте.

— Ах, нинди матур, нинди һава, ничек рәхәт! — диде ул күзләрен очкынландырып.

Ә эченнән: «Ничек тә Альфред әнисенең мәхәббәтен яуларга кирәк!» — дип уйлады. Иң элек кичтәнге көлүне юарга кирәк, шуннан соң гына мәхәббәт яулау хакында уйларга мөмкин иде. Авылга кайтып, әле бер мәртәбә дә иртән торып күрсәтмәде ич ул. Югыйсә әтиәнисе кат-кат әйтте: авылда кешене йокыдан кайчан торуы белән сыныйлар, синең бу яктан мактанырлыгың юк, иртәрәк ятып иртәрәк торырга тырыш, шул барысын да хәл итәчәк, диделәр. Бүген ул сыер саварга торачак, ул булачак бианасының мәхәббәтен, һичшиксез, яулаячак!

Аларның гаҗәпләнүенә каршы, Кәүкәбелҗәннәт әле һаман йокламаган иде. Ул барлык эшләрен бетерде, яшел күлмәге белән ал свитерын юып элде, утны сүндереп ятып карады, йөрәге чәнчеште, күзенә йокы кермәде. Кичтән урманчы Шәрип кереп, бер печәнле алан калган иде, шуны чабып алыгыз, диде. Шуңа күрә ул яшьләр кайтып керү белән:

— Улым, иртәгә иртүк әтиең белән урманга печән чабарга китәсез,— диде.

— Мин дә барам, мин дә барам,— дип кулларын чәбәкләде Руфинә.

Кәүкәбелҗәннәт аңа яратмыйча карап куйды, аның Газдалга тагылырга теләвенә ачуы килде.

—Сиңа өйдә дә эш күп булыр,— диде ул кырыс кына.

Руфинә аның иңбашына кагылды:

— Апа,— диде ул хискә бирелеп,— мин сезгә булышырмын, мин иртүк торырмын, сыерны да савармын!

— Бик рәхмәт,— диде Кәүкәбелҗәннәт күңеле йомшап.

Утларны сүндереп, ишекләрне бикләп йокларга яттылар.

Ә авыл барыбер тик ятмый. Иртән сәгать бишенчедә сыер савучылар җәйләүгә барырга автобусларга утыргач, Ирдәүкә Илгизә җырлап җибәрде. Аның күпмедер йокысын корбан итү бәрабәренә чыгарган такмаклары болай башлана иде:

Машинадан куркып кача
Авыл күгәрченнәре.
Бройлер тавыгы төсле
Казан хөрәсәннәре...

Ирдәүкәнең теленә эләккән кеше исән калмый, алар авылның хәтеренә алтын хәрефләр белән язылачак, моның башы бар, бакасы, һичшиксез, булачак иде.

## 7

Иртән Кәүкәбелҗәннәт верандага кереп Руфинәгә берничә мәртәбә эндәште:

— Сыер саварга вакыт!

Соңгы керүендә хәтта селкеткәләп тә карады — Казан кызы уянмады. «Уятырсың пычагым, шәһәр ялкавына дүрттән торып сыер саву каян килсен ул. Сез башкага гына бик оста»,— дип каргана-каргана сыер сауды, малларны көтүгә куды.

Әлфәритне торгызуы да җиңел булмады, билгеле. Газдал белән

аларны ашатып-эчертеп урманга озаткач, ул черем итеп кенә алыйм дип яткан иде, сәгатьтән артык йоклаган булып чыкты. Кәүкәбелҗәннәт ашыга, кабалана башлады, йорт мәшәкатьләре муеннан, ә аңа эшкә дә китәргә кирәк иде. Верандага юри дөп-дөп басып керепчыгып йөрсә дә, Руфинә борынын месләтеп йоклавында булды. Ул казларны юри бик каты кычкыртып: «Көшегез, мур кыргырлары!» — дип куып чыгарды, бер гаепсез тавыкларны тиргәде, шалтыратып савытларны төшереп җибәрде. Шулкадәр тавышлануга да уянмагач, веранда ишегенә килеп, төбендә әллә кайчан сөт кәеп касмакланган кастрюльне кытыр-кытыр кырды, аның тавышы үзенең тешләренә тиде. Бакчадан веранданың нәкъ ул йоклый торган башына килеп известь каткан калай бакны чүкеч белән хәле беткәнче төйде, оркестрдагы кебек әледән-әле аның калай капкачына да суккалап алды. Болар да тәэсир итмәгәч, үлмәгәндер бит дип кереп карады — кыз исән, куәтле күкрәкләре акрын гына селкенә, моның өстенә атом бомбасы ташласаң да, уяначак түгел иде. Шуннан соң ул соңгы чарага кереште: ишекне ачып верандага чебен тутырды, аларны болдырдан сөлге белән куа-куа кертте. Август чебене усал, кием аша да үтәреп ала, хәзер котәргә генә калды. Авыл чебеннәре, шәһәр колбасасына ябырылгандай, Руфинәне сырып алдылар. Бераздан аның астындагы тахта кызганыч тавыш белән сигнал бирде. Кәүкәбелҗәннәт моны ишетеп елмаеп куйды. Чебеннәрнең һөҗүменә түзә алмыйча, Руфинә әле бер якка, әле икенче якка әйләнде, башыннан ук томаланмакчы булды, әмма алар әллә нинди тишекләрдән үтеп кереп тешлиләр иде. Ул кымшанган саен тахта коточкыч шыгырдады, «ник мине бу кадәр газаплыйсыз, сезгә нинди начарлык эшләдем», дигәндәй, кызганыч итеп ыңгырашты. Ярый әле Руфинә төнлә кайсы ягы белән ятса, шул ягыннан борылмыйча йоклый, әгәр ул төнлә селкенгәләсе булса, тахта тавышына өйдәгеләрнең генә түгел, бөтен авылның йокысы качасы икән.

— Руфинә-әү, кызым, тор инду-ү! — дип юри сузып эндәште Кәүкәбелҗәннәт.

Руфинә җавап бирмәде, аның әле телен әйләндерерлек хәле юк иде. «Торырга, ничек булса да торырга! Мин бит сыер саварга сүз бирдем. Торырга, торырга!» Аның башында шушы уй бөргәләнде. «Авылда кешене кайчан торуы белән сыныйлар! Менә хәзер сыналыр чагың җитте. Тагын бер генә минут ятам да сикереп торам»,— диде каяндыр эчтән икенче бер ягымлы уй. «Тагын ярты гына минут, ярты гына минут»... Түшәктә ятуның ләззәтле һәр минуты өчен ул әнә шул рәвешле титаник көрәш алып барды. «Хәзер, унбиш кенә секунд... Ах, ничек тиз уза вакыт! Аны келәшчә кебек берәр нәрсә белән эләктереп алып, үзең теләгән кадәр җибәрмичә тотып торырга иде. Торасың килмәгән чакта мәҗбүри торудан да әшәкерәк җәбер юктыр адәм баласы өчен. Ник бу авыл кешесе шулай иртә тора?! Гомумән, кешенең үзе теләгән чакта ятып, теләгән чакта торырга гына да хокукы булмагач, нигә кирәк бу тормыш?! Кайсы диванасы уйлап тапкан бу газапны?! Әнә бит инде ничәнче мәртәбәсенә тамак кыра-кыра, дөп-дөп басып үтте. Әйе, торырга кирәк!» Ул ике кулына таянып авырлык белән генә күтәрелде, инде торып утырдым дигәндә, кабат ауды. Юк, үтерсәң дә булмый, башы эшләсә дә, аның әле бөтен гәүдәсе изри, һәр күзәнәге, әнисе күкрәгеннән җылы сөт имгән шикелле, кинәнә һәм бу ләззәтне бүлү иң зур җинаять, имине авызыннан вакытсыз алып баланы татлы ризыгыннан мәхрүм иткән, акыртып елаткан төсле үк әшәкелек иде. Ниһаять, күңеленнән шулай рәнҗеп һәм елап ул торып утырды, ләкин күзләре ачылмады, ул йоклаган килеш әле бер, әле икенче якка авып китә язып утырды.

Менә ул нәрсәләргәдер ябыша-ябыша веранда ишегенә таба атлады, тик кенә басып торган урындыкны өч литрлы варенье банкасы

өстенә аударды. Кәукәбелҗәннәт онытып калдырган тавык җименә басты, өстәлдәге китапларны шул җим өстенә сыпырып төшерде, каплап куелган табакка абынып мәтәлде дигәндә, кер бавына эләгеп кенә калды, тик бау шартлап өзелгән иде инде. Руфинәнең бөтен гәүдәсе йоклавын дәвам итте, борыны мес-мес сулады, күзләре ачылмады. Аның шулай барлык нәрсәне изеп-җимереп үзенә таба якынлашуын дошман танкын күзәткән сугышчы кебек читтән коты очып күзәткән Кәукәбелҗәннәтне Руфинә капшап-кармалап узса да, кулларының тере әйбергә тигәнен сизмәде. Ул кармалана-кармалана баскычтан төшеп, исән-имин генә юынгычка барып җиткәч, Кәукәбелҗәннәт җиңел сулап куйды һәм веранданы рәткә китерергә тотынды. Аннары Чәй чишмәсеннән бер көянтә су алып кайтты — Руфинә әле һаман юына иде. Тавыкларга җим болгатып чыгарганда да юынуы тәгәлләнмәде. Кәукәбелҗәннәт, бакчаның түренә үк барып, әллә ничә төптән яшь бәрәңге алды, юып әрчеде, турады — булачак килен кермәде. Камыр басып токмач кисә башлаганда, аның верандага кереп китүе ишетелде. «Әллә тагын йокларга ниятлиме, ходаем»,— дип Кәукәбелҗәннәт ишек читеннән генә эчкә күз салды һәм авызын ачып хәйран калды. Руфинә чемоданындагы исәпсез-хисапсыз киемсалымнарын берәм-берәм киеп карый, ошатмыйча кабат сала, аннары икенчесенә, өченчесенә үрелә иде. Кәукәбелҗәннәтнең үз гомеренә бу кадәр чуар чәчәк һәм борчак төшкән, буйлы һәм шакмаклы итәкләр, җиңсәләр, күкрәкчәләр, бәбитәкләр, төрле-төрле бөрмәләр, складлар, киң һәм тар, аеллы һәм аелсыз путалар, ызмалар һәм аркалыклар күргәне юк иде. Ул киемнәрне кигәндә-салганда кармак һәм сәдәф төсле каптырмалар черт-черт итте, керешле тарттырмалар чирттергән тавыш чыгарды, кара-каршы китереп тәрәгән вак пычкы теше төсле елтыравыклы нәрсәләр тезелдәп эләкте һәм олы ерык ясап аерылды. Руфинәнең төзәтенеп-ясанып бетергәнен көтсәң, төшкә кадәр эшкә бармаска туры киләчәген аңлап, ул киенде, ике сәгатьтән ашка бәрәңге салырга кушып, Газдал белән Әлфәритнең төшлеккә кайтачакларын әйтеп, бакчага китте.

Руфинә исә ярты сәгать кием сәйлаганнан соң, бизәнергә керешкәнгә кадәр, тышка чыгып керергә булды. Ул сыер саварга тора алмаганын аңлаган иде инде. Шулай да Альфред әнисенең аш пешерергә кушуына бик сөенде. Һәрвакыт аңа ташланырга гына торучы чуар әтәчнең күренмәве дә кәефен күтәреп куйды. Ул борын эченнән «Арлекино»ны көйли-көйли абзарга кереп чыкканда, усал кыткылдап, канатлары белән бәреп, аның өстенә әтәч сикерде. Руфинә чинап өйгә таба йөгерде, әтәч бер тотам да калмыйча тузаннар туздырып, аның артыннан томырылды, өйалды ишеге төбендә генә аерылып калды. Руфинәнең йөрәге әтәч куып тоткан тавыкныкыннан да болайрак сикерде, ул шактый вакыт тынычлана алмады. Тынычлангач, иркенләп чәй эчте, Альфредлар кайтмыйча ишек алдына чыкмаска булды. Ах, чыккан булса, һич югы күз генә салган булса соң! Җәй буе абзарда бикләнеп яткан коба бозау капканың ачык калуына куанып бетә алмады. Ал аякларын сузып, гамьсез генә күшәп яткан җиреннән ул сикереп торды, ашыга-ашыга ишек алдына атлады, туктап, нәрсәнедер ошатмагандай, борынын җыерды да язгы яшел үләнне хәтерләтүче күлмәккә барып ябышты. Әйбер чәйнәү — бу мәхлукның иң яраткан эше иде. Күлмәкнең сул як җиңен ипләп-ипләп чәйни торгач, ул култык төбенә үк килеп җитте. Әгәр уңын да чәйнәсә, әле аны кыска җиңле итеп төзәтеп булачак иде. Ләкин бозау үзенең караңгылыгы, томаналыгы аркасында бу хакта уйлый алмады, итәккә күчте. Күлмәкнең сул як күкрәк турында сәйләнләп каймалган бик матур зур чәчәк бар иде. Ул чәчәк ничә еллар Кәукәбелҗәннәтнең кайнар күкрәге өстендә тирбәлде, Фәритнең дәртле күз карашларын сеңдерде. Аңгыра булса да, бозауга ходай, күрәсең, нидер сиздерә

иде: ул, чәйни башлаган итәген ташлап, селәгәйләрен агыза-агыза әлеге чәчәккә күчте, рәхәтлектән койрыкларын болгады. Әлбәттә, аңлашылса кирәк, Кәүкәбелҗәннәтне халык мәгарифенең алдынгы вәкиле белән бәйләүче иң кадерле яшьлек ядкарен чәйним дип чәйнәмәде бозау. Әгәр ул аны аңласа, мондый әхлаксыз гамәлне кылмас иде. Чират свитерга да җитте. Аның ал буявының үзенчәлекле бер тәмен бозау бик нык ошатты. Әйбер чәйнәүдән туйгач, коймa буена өелгән утынга барып ышкына башлады, аны ишеп төшерде, көл салынган иске чиләккә тыгылып «пуф-пуф» килде, борынын кинәт өскә күтәрүгә, чиләкнең тоткасы башына эләкте, аны чайкап йөри торгач, үзен дә, ишек алдын да көлгә батырды. Машинаны читтән-читтән иснәштерде, аңа якын килергә курыкты. Аннары, ябылып бетмичә калган капкадан чыгып, урам буйлап атлады.

* * *

Балалар бакчасына барып җитүгә үк, Кәүкәбелҗәннәтнең кәефен боздылар. Бала китергән берничә хатын көлешә-көлешә нидер сөйләшкәндә шым туктадылар, аның белән исәнләшкән булдылар, ул узып киткәч, кеткелдәргә, хихылдарга керештеләр. Димәк, аның гайбәтен саталар иде. Руфинә кайтканнан бирле тәрбиячеләрнең дә бик серле карап йөрүләрен сизә ул. Мәхәббәтле Газдал белән Руфинә арасында яшерен элемтә барлыгын беләләр, Кәүкәбелҗәннәт юкта аларны туйганчы чәйниләр иде. Башын мондый уйлар чуалткач, аңа тәрбиячеләр — гыйфрит, балалар җен булып күренде. Ул кухняга сугылды, бүлмәләрне әйләнеп чыкты, кибеттән, медпункт белән мәктәптән урап кайтты, әмма күңеле урынына утырмады, ниндидер билгесез корт эчтән кимерде дә кимерде. И дөнья, исерек Газдал хурлыкка төшерер дип кемнәр уйлаган! Менә хәзер дә Газдал матае белән өйгә кайткандыр кебек тоелды аңа. Унбер дә тулып килә икән, ул тиз генә өеннән урарга ниятләде. Урамга чыгып җитә алмады, тәрбияче Сания тәрәзәне ачып:

— Кәүкәбелҗәннәт апа, сине телефонга чакыралар! — диде.

Ул кире борылды.

— Әйе, тыңлыйм,— диде ул трубканы алып.

— Кәүкәбелҗәннәт апа... бозавың...

Трубка колак ярысын ертырлык дәрәҗәдә «шалт» итте дә шытыр-шытыр килеп тора башлады. Кәүкәбелҗәннәт:

— Әлү, әлү, син кем?! — дип кычкыра-кычкыра трубкага өрде.

Ләкин өрү генә түгел, аның башындагы вак тишекләрен биш энә белән чөшкенләсәң дә, берни аңларлык түгел иде. Ул да булмады, трубкада әллә радиодан, әллә телевизордан тапшырылучы соңгы хәбәрләр яңгырый башлады. Кәүкәбелҗәннәт аны ачу белән урынына куйды. Шуны гына көткәндәй телефон тагын шылтырады. Бу юлы кемдер су төбеннән, бик тирәннән эндәшә иде кебек. Ахырда Кәүкәбелҗәннәт аны таныды: ул мәдәният йорты мөдире Роза иде.

— Монда синең бозавың ята, кеше-кара күргәнче килеп ал.

Кәүкәбелҗәннәт аны тыңлап бетермәде, трубкасын атып ук бәрде. Каһәр генә төшсен икән! Аның борчылуы юкка буламы соң? Атрай Ибрае мәдәният йортының урындыкларын төзәтә иде, Газдал урманнан кайткан да шуның белән эчеп егылган, дип уйлады ул. Кәүкәбелҗәннәтнең ничә көннәр буе җыелган ачуы, рәнҗеше, хурлануы бөтен гәүдәсен ток тоткан шикелле калтырата башлады.

— Хайван, оятсыз, олтырак чырай! — дип кычкырды, бүлмәсендә ялгызы булуга карамастан.— Ну күрсәтәм мин сиңа!

«Гомер буе газап чиктем, җитте!» — диде, күз яшьләрен йота-йота мәдәният йортына атлаганда. Кинәт кырт борылып авыл советына

таба юнәлде. Ул аның белән бер көн дә торачак түгел! Әлфәритне урманда калдырып, теге кызыл ирене артыннан кайткандыр әле, оятсыз! Теге чакта куып чыгаргач, гафу итәсе булмаган ул исерекбашны. Эчкән кеше гомер буе эчә, йөргән кеше гомер буе йөри. Бу да төзәлә торган түгел. Аны кеше итү өчен улниләр генә кыланып карамады! Өйләнешкән елларында теләсә кайда аунап ятмасын, кеше күрмәсен дип, кич ферма буйларын, урамнарны әйләнде. Тәмам аптырагач-йөдәгәч, аңа биш-алты яшеннән Әлфәритне ияртә торган булды. Билгеле, сабый аны әшәкелектән тыя алмый, шулай да кайткач әнисенә һәммәсен түкми-чәчми сөйли иде. Ә ул, игелексез җан, дөресен сөйләгәнгә Әлфәритне күрә алмады. Ул хәтта баласын гарип калдырудан да тайчанмады. Җиде яшьтә улы ялгыш уң беләген сындырды. Кулының сынып ялганган булуына карамастан, Газдал аңа эш кушты да эш кушты. Әгәр Кәүкәбелҗәннәт улын сакламаса, ул кушканның һәрберсен эшләтсә, ни булыр иде? Бала эшләр, кулына авырлык килүен дә, гарип калуын да белмәс. Ул чакта Әлфәрит рәсем ясау белән мавыга иде. «Минем малай теләсә нәрсәне ясый ала, коеп кына куя»,— дип, күкрәк кагып йөргән Газдал, үзенә беренче кырынлык килүгә, малаен дошман күрә башлады. Ул болай булды. Әлфәрит дүртенче класста укыганда, альбомына өй рәсеме ясаган. Шулкадәр дөрес ясаган, мич башындагы егерме литрлы әче бал мичкәсен дә бөкесе-ние белән төшереп куйган. Башта мәктәп, аннары бөтен авыл шаулады. Штраф та салдылар, мичкәне дә алдылар. Ә Газдал тоткан да улын кыйнаган. Болай да эштән ярсып кайткан Кәүкәбелҗәннәт баланың елап утыруын, Газдалның исереп ятуын күргәч, тотынды тегенең үзен дөмбәсләргә.

— Син дә сук, улым, сук бу исерек дуңгызга! — диде ул, ачуыннан нишләргә белмичә.

Әлфәрит сукмады, карап кына торды.

— Аңламаслык бала түгел ул, юри ясаган ул аны,— дип, улын гаепләде Газдал.

Их, шул чакта ук куып чыгарган булса! Аның кыйнавына каршы бер хәрәкәт тә ясамагач, күңеле йомшады шул. Ә ул, астыртын, тыштан баш игән булып йөрсә дә, һаман Әлфәриткә эш өйдә дә эш өйдә.

— Син аны рәсем ясавыннан биздерү өчен эш кушасың! — ди Кәүкәбелҗәннәт тәмам түземе беткән чакларда.

— Рәсемен дә ясасын, башкасын да эшләсен. Эшләп бирәү дә үлми, акыл гына җыя.

— Син үзең күбрәк эшлә, акыл тупларсың. Юкса, булганы да чыгып китеп бара.

— Үземнеке үземә җитә, синнән акыл сораганым юк әле.

Мондый сөйләшүләр алар арасында еш кабатланып тора, әмма сүз булудан узмый, Газдал ул әйткәннәрне колагына да элми. Җитәр, Кәүкәбелҗәннәт аның белән күп черетте гомерен. Әнә ялгыз яшәп карасын!

Авыл советы секретаре Нәбирә аның борчулы йөзен күрү белән ниндидер гадәттән тыш хәл булганлыгын аңлады.

Кәүкәбелҗәннәт хәлсезләнеп урындыкка утырды.

— Безнең әйберләрне описька алыгыз!

— Ни булды, Кәүкәбелҗәннәт?! — Нәбирә аны иңбашыннан кочып алды.

— Бер кабар җирем дә калмады, аерылам! — диде Кәүкәбелҗәннәт күз яшьләрен сөртеп.

— Ни сөйлисең, картаеп беткәч!

— Ялгышып бер айнык көне юк бит аның,— диде Кәүкәбелҗәннәт кулларын селкеп.— Печән чабарга җибәргән идем, кайтып теге шадра тәре белән эчкән!

Нәбирә күпме генә үгетләсә дә, Кәүкәбелҗәннәт аны тыңларга да

теләмәде, дулап чыгып китте. Газдалның бертуган энесенең йөк машинасы капка төбендә тора, Җәүдәт үзе койма буендагы имәннәрен каезлый иде.

— Абыеңны алып кайтып ташла,— диде Кәүкәбелҗәннәт аның белән исәнләшеп тә тормастан.

Җәүдәт тураеп басты, маңгаеннан тирен сыпырып алды.

— Тагын чәкәләштегезмени?

— Әнә клуб янында исереп ята, миңа кирәге юк, үзегезгә булсын!

Җәүдәт ачу белән балтасын агачка чапты, черт итеп төкерде.

— Ни сөйлисең, җиңгәчәй, әле генә печән чабып ята иде бит.

— Ята ди шул, клуб янында ята ди.

Җәүдәт сүгенеп куйды.

— Әйдә, утыр әле,— диде ул.

Машина үкереп килде дә мәдәният йортының баскычына менә язып туктады.

— Кайда ул? — Җәүдәт кабина ишеген ачкан килеш муенын сузып тирә-юньне күзәтте. Машина тавышына Роза йөгереп чыкты.

— Кайда теге алкаш? — диде Кәүкәбелҗәннәт ачуына буылып. Ул бу минутта Газдалның башын сугып ярырга әзер иде.

— Нинди алкаш? — Розаның зур зәңгәр күзләре гаҗәпләнүдән челт-челт йомылдылар.

— Нинди алкаш булсын — Газдал!

— Минем аны күргәнем юк.

Кәүкәбелҗәннәт аңа очып кунар чиккә җитте.

— Нәрсә? Аны да Ибрай белән эшләтергә уйладыңмыни?! Әйтмәскә, яшереп калдырырга күндерделәрмени?!

Розаның зәңгәр күзләре челт-челт йомылудан туктап, коточкыч зурайдылар, иреннәре нидер әйтмәкче булып түгәрәкләнде, әмма ярга чыгарып атылган балыкның авызы селкенсә дә тавышы чыкмаган кебек, аның иреннәреннән дә бер кәлимә сүз дә ишетелмәде.

Кәүкәбелҗәннәт аны җилтерәтә үк башлады.

— Ә-ә, дөресен әйткәч, каушап төштеңме? Шулай гына үтәр дип уйлаган идеңме?! — дип бармак янады.— Кайда яшердең ул исерек чучканы?!

Ниһаять, гомер буе сәхнәдән шигырь сөйләп йөргән Розага сүз куәсе кабат кайтты.

— Ни сөйлисең син, апа җаным?! — диде ул ялварып.— Газдал абый нишләп монда булсын?!

— Әле генә шалтыраттың лабаса, монда ята дип! Карале, алдашып торуын!

— Мин бит сезнең бозауны әйттем. Теге якта күләгәдә ята әнә.

Бу сүзләрне ишеткәч, Кәүкәбелҗәннәт бер Розага, бер Җәүдәтнең кара янган чыраена карады, хәзер аның сүз куәсе югала башлады:

— Соң... ни... мин бит... бозау дигәч, ята дигәч...

Ул, тыны кысылган кеше сыман, туктап калды.

Читтәрәк басып торган Җәүдәт аңа якын ук килде. Ул — авылның иң холыксыз ирләренең берсе, ни туры килсә шуның белән алып бәрә иде. Кәүкәбелҗәннәт күзләрен чытырдатып йомды, бетүем шушы икән, хәерлегә булсын, иремнең энесенең кулыннан үтәм икән, дип, фани дөнья белән хушлашты. Роза, шаһит булып йөрүдән куркып, мәдәният йортына йөгереп кереп китте дә пәрдә читеннән күз генә сыярлык тишек ясап, бушлай тамаша карарга әзерләнде. Җәүдәт тезләрен биетеп, иреннәрен кыеш-мыеш китереп (сугар алдыннан ул шулай итә) аңа карап торды да:

— Сине бәреп үтерсәң дә аз, җиңгәчәй,— диде һәм катлы-катлы сүгенеп машинасына атлады.

Сукмагач-нитмәгәч, Кәүкәбелҗәннәтнең башыннан: «Әллә таптатып үтермәкчеме?» — дигән уй узды һәм ул культура йортының аргы ягына йөгерде.

Танавыннан алып колагына кадәр көлгә баткан бозау рәхәтләнеп күләгәдә ята, авыз читеннән ал җеп тә асылынып тора иде. Бозау, аны күргәч, кикереп куйды һәм күңелле генә итеп күшәргә керешге.

— Тор, мур кыргыры!

Кәүкәбелҗәннәт китереп типкәч, малкай ашыкмыйча гына торып киерелде, гәүдәсен дерелдәтеп җилпеп алды.

— Түчә, түчә өйгә!

Кәүкәбелҗәннәт бозауны урам буйлап алып кайтып китте. Ничек абзардан чыккан соң бу? Аның башыннан әллә нинди уйлар узды. Газдал кайтып, Руфинә белән печәнлеккә кергәндә капканы ябарга оныткандыр да чыккандыр. Бер дә бүтән булмас. Авызыннан асылынып торучы әнә теге алсу җеп хакында уйларга да куркыныч иде. Әгәр бозау әлгән керләрне күреп... Юк, моның булуы мөмкин түгел, ни генә булса да булсын, ул уйлаган нәрсә генә булмасын! Менә алар кайтып җиттеләр. Күңелгә килгән алга килмиме соң?! Йә мәүләм, аны яшьлек хатирәсеннән мәхрүм итеп, синниләр оттың?! Ул тынсыз-өнсез басып торганда, бозау тагын яшел күлмәккә барып тотынды. Юк, ул күлмәккә түгел, аның йөрәгенә ябышты! Инфаркт булачак аңа. Алла аны быел яздан бирле бертуктамый интектерә. Язгы пычракта Кәүкәбелҗәннәтнең поликлиника ишеге төбендә салып калдырган йөз сиксән сумлык өр-яңа итеген урладылар. Хикмәт бәядәмени! Аны кыш очрашкач, Фәрит бүләк иткән иде. Түзә алмыйча, район газетасына ун битлек мәкалә язды. Ул болай башлана иде: «И кабахәт җан! Муеның аска килсен! Хәләл кешенең күкрәк көче белән казганып тапкан итеген оятсыз рәвештә урлап, тишек кәлүш калдырган өчен аяк-кулларың корышып, көне-төне акырып ят, аяк-кулларың берәм-берәм череп аксыннар, гангренага әйләнеп, сине каберга алып китсеннәр. Гүрендә ләхетең өстеңә лапырдап ишелеп төшсен, итекләрнең рәхәтен күрмә, нәселең төбе-тамыры белән корысын һәм башкалар, һәм башкалар»,— дип язды. Редактор мәкаләне басмады, күзлек пыяласы ватылып күзенә кергере!

Кара инде, бу чырайсыз хәшәрәте аның иң соңгы һәм бердәнбер кадерле истәлеген харап иткән. Моңа нинди йөрәк чыдасын ди?! Ул кичәге күсәкне эзләде, күсәк юк иде. Кәүкәбелҗәннәтнең кулына балта эләкте.

— Мин бит сине, оятсыз, авызыңа бармак тыга-тыга сөт эчереп үстердем,— дип елады Кәүкәбелҗәннәт.— Шуны гына булса да аңларга тиеш идең бит син, тонган күз, уйнаштан туган җанвар гыйбрәте.

Ул балтаны җан көче белән селтәп, адәм гыйбрәтенең нәкъ маңгаена җибәрде. Балта тимәде генә, тисә бозауның башын яра иде, ул югарырак очып, бакчага — карлыган төбенә төште. Бозау исә моңа игътибар да итмәде, гүя, аның баш очыннан балта түгел, ә гадәти чебен очып китте. Көн дә авызына тәмле бармакларын тыгып сөт эчерә торган апасы тимер көрәк белән сыртына ике мәртәбә кундыргач кына ул, нииндидер начарлык кылганын сизеп, абзарга сызды.

Кәүкәбелҗәннәт, яшел күлмәген күкрәгенә кысып, борчак-борчак яшь койды. Сеңлесе Себердән кайтасы иде, ул кайтса, болай да булмый иде, кайта алмады шул. Алар кадәр бәхетсез! Сеңлесе бер чатанга кияүгә чыккан иде, шул чатан тәренең чатан аягы тагын сынган да кайта алмадылар. Безнең нәселгә генә калгандыр инде исерек йә гарип ир белән, чәйни торган бозау белән интегергә, дип елады Кәүкәбелҗәннәт. Белмим, әгәр мотоцикл белән Газдаллар кайтып кермәсә, ул күпме елаган булыр иде. Хатынының зар-моңнарын тыңлап бетергәч, Газдал:

— Бозауны кем чыгарган соң? — диде.
— Кем булсын, шул хөрәсән инде!
Әлфәрит түземсезләнеп баскан урынында таптанып куйды.
— Күрдеңмени?
Кәүкәбелҗәннәт иренең ни әйтергә теләгәнен бик яхшы аңлады:
— Күрәсе юк, өйдә ул гына калды. Әйдә, яклый башла, бозау койма башыннан сикереп чыккан диген! Хәзер иманын укытам мин аның!
Кәүкәбелҗәннәт барысын да гафу итә алыр иде, әмма күлмәкне кичерә алмады. Ул ажгырып өйгә ыргылды, аңа Газдал белән Әлфәрит иярде. Ишекне ачып җибәрүгә өйдән янган ит, көйгән бәрәңге исләре ияртеп төтен бөркелде...
Нәкъ шул чакта урамнан алан-йолан каранып, Убырлы Мөштәфширә үтеп бара иде. Газдалларның өй ишегеннән төтен бөркелгәне күргәч, ул янгын чыккан дип уйлады һәм нишләргә белмичә борчылды. Берничә секундтан бу борчылу гөнаһсыз шатлык хисе белән аралашты. Ул — беренче булып кешеләргә яңа хәбәр салу, аларны шаккаттыру, әрле-бирле чаптыру шатлыгы иде.
— Пужар! Пужар! Пужар!
Шулай кычкыра-кычкыра Убырлы югары очка таба йөгерде. Ә өйдәгеләрнең миен бер уй яндырып үтте: «Руфинә төтенгә тончыгып үлгән!» Плитә өстендәге аш кайнап-көеп беткән иде. Өчесе дә кабаланып түр якның ишеген ачтылар. Анда әле төтен аз гына кергән, Руфинә кулларын баш астына салып, юан ботларын бака шикелле җәеп, лаҗраеп диванда йоклап ята иде. Кәүкәбелҗәннәт керган кызулык белән аның янбашына китереп сукты һәм:
— Тор, хөрәсән! — дип кычкырды.
Руфинә, өстенә кайнар аш койгандай, сикереп торды, ыскырт ачы төтенгә, төтен арасындагы таныш кешеләргә төш күргәндәй гаҗәпләнеп карап торды.
— Безнең өйдә эзең булмасын, җир җирәнгече! — диде Кәүкәбелҗәннәт, аның комод өстендәге бик күп санлы бизәнү-ясану әсбапларын өстенә ыргытып.
Әлеге әйберләр Руфинәнең яшьлек истәлеге генә түгел, көн саен мәхәббәт яңарту өчен кирәк кораллары булганлыктан, аның йөрәге тукталгандай булды, күңеленә зәһәр ачу тулды. Җитмәсә, аңа үз гомерендә беркемнең дә сукканы юк иде. Кызның чәчләре үрә торды, әле йокыдан ачылып бетмәгән күзләре шакмакланды, ул кулларын як-якка аерып әз генә чүгәләде дә авызын югары күтәреп кычкырып җибәрде:
— А-а-а-а!!!
Болай дәһшәтле итеп Африка чүлләрендә ач юлбарыс кына үкерә аладыр. Кәүкәбелҗәннәт, Газдал һәм Әлфәрит төтен генә булдылар, ишек алдында ничек чәчелешкәннәрен дә сизмәделәр. Биш минут үттеме-юкмы, өйдән Руфинә дә чыкты, кулына редикюлен, бүтән вак-төякләрен тоткан килеш, башын югары чөеп машинасына таба китте. Әлфәрит әле һаман аның кычкыруыннан айный алмый, кызның янына барырга шикләнә, ул йә бугазын чәйнәп өзәр, йә җиргә салып изәр кебек иде.
Ул арада «Янгын! Янгын!» дигән тавышлар көчәйде, капкадан сулы чиләкләр, багорлар, пумалалар белән коралланган халык төркеме күренде. Төркем уртасында барысыннан да бер башка озын булып Убырлы Мөштәфширә күренә иде. Багор тоткан Әпсәләм башкалардан аерылып алга таба берничә адым атлады да:
— Бәй, ни... сезне янасыз дигәннәр иде бит,— диде.
Газдал шушы кадәр халыкны кузгатып китергәч, аларның һәм дусты Әпсәләмнең өметләрен акламаган өчен үзендә нииндидер кыенсыну тойгысы уянуын сизде.

— Барыгыз, бар, килүегез өчен рәхмәт, берни дә янмый,— диде ул гаепле кыяфәт белән.

Халык төркеме Убырлы сүзенә карап ничек тиз җыелган булса, аны каргый-каргый шулай ук юкка да чыкты.

Ул арада Кәүкәбелҗәннәт Руфинәнең верандадагы чемоданын, аннары аның кием-салымнарын алып чыгып баскычка бәрде.

— Әни, син нишлисең? Тынычлан зинһар! — дип Әлфәрит ул ыргыткан әйберләрне җыйнарга тотынды.

— Белдем мин аның кем икәнен! Юри чыгарган ул бозауны! — Кәүкәбелҗәннәт баскычтан йөгереп төшеп Руфинәгә таба йодрыгын селкеде.— Карап торма миңа күзеңне мытырайтып, хәзер үк Казаныңа ычкын!

Әлфәрит машина янына килеп бөтерелде, үзе һаман:

— Руфчик, Руфинә, карале, Руфчик...— диде.

Менә әйберләр җыйналып бетте, Руфинә рульгә кереп утырды.

— Әйдә, тизрәк киттек синең бу дию пәриең яныннан! —диде.

Әлфәрит әнисе янына йөгерде.

— Әни, китә бит, китә, гафу үтен, җибәрмик аны!

— Гафу үтенермен мин, көтеп тор! — диде Кәүкәбелҗәннәт тагын да ныграк ярсып.— Олтырагыма да тормаслык шәһәр ялкавыннан гафу гына үтенәсем калган!

Әлфәрит тагын машинага йөгерде.

— Әйдә, утыр кереп!

— Руфчик, ни бит...— ул сүз таба алмады.— Әни кызып китте, без бит бүген кич синең белән Чалмыяның аръягына чыгарга сүз куешкан идек.

Әйе, турысын гына әйткәндә, Руфинәнең үзенең дә китү исәбе башына да кереп карамады. Бүген көймәдә йөрергә кием сайлап маташмаса, бәлкем ашны карарга да онытмаган булыр иде. Авылда ул тыныч, шау-шусыз көннәр кичерде. Чалмыяның аръягында уздырасы бүгенге кичтән мәхрүм калу бигрәк тә кызганыч иде.

Баядан бирле читтән мыек астыннан гына көлеп торган Газдал капканы ачты да машина янына килеп ярып салды:

— Дүрт ягың кыйбла!

— Син нәрсә, эти?! — диде Әлфәрит аны читкә этмәкче булып.

Ләкин Газдал аның үзен читкә тибәрде, бик тә кыланып эшләпәсен баш өстенә күтәрде, уң кулын капкага таба сузып һәм азау тешен дерелдәтеп:

— Үтенәм, мадам! — диде.

Руфинәнең йөзе ямьсез булып җыерылды, ул ике генә сүз ташлады:

— Общество идиотов![1]

Машина коточкыч тизлек белән чигенеп урамга чыкты, артыннан йөгереп килүче Әлфәритне тузанга күмеп китеп барды.

Иренең шулай кылануына Кәүкәбелҗәннәт шаккатты. Ул бит аны шушы минуткача Руфинәне җибәрмәс өчен теше-тырнагы белән тырыша дип уйлаган иде.

— Булдырдың, карт, шәп иттең,— диде Кәүкәбелҗәннәт.

— Ә ник сиңа каршы әйтә ул? — диде Газдал кулларын йодрыклап.— Андый кешегә түзеп тораммы соң мин...

Хатынын эчтән дә, тыштан да нык өйрәнгәнлектән, Газдал шушы сүзләрнең аның булган гөнаһларын да, булачакларын да берничә тапкыр ярлыкарга җитәчәген яхшы аңлый иде.

Альфред ни әтисенә, ни әнисенә бер сүз дәшмәде, күбенеп печәнлеккә кереп ятты. Кәүкәбелҗәннәт ашарга әзерләгән арада Газдал чалгы чүкергә кереште. Аның кәефе күтәренке, бөтен кыяфәтенә ка-

[1] Диваналар җәмгыяте (урысча).

нәгатьлек билгесе чыккан иде. Бүген кич мал өе түбәсендәге теге өч литрлы әче балны алып, Әпсәләм янына барырга кирәк. Ул чалгысына төкерде дә, Атрай Ибраеның сүзен искә төшереп, көлеп куйды. Атрай әйтә, чалгыңны әйбәтләп чүким дисәң, Әпсәләмнең төкерегеннән тамызу шарт, ди. Иң әлгәре, ди, Әпсәләмне бер атна көне-төне эчерергә кирәк, ди. Бүтән кеше ярамый, чөнки бүтән кеше эчкәч ашый, ә Әпсәләм тәгам ризык җыймый, ди. Бер атна эчкәннән соң Әпсәләмнең авызындагы төкерегә яшькелт төскә керә, нишләтсәң дә өзелми, аскы ирен белән өске ирен арасында сузылып тора. Шуны чүкеч очына төкертеп чүкесәң, чалгың кыяк була, нәкъ бер атна теләсә нинди куралы печәнне янавыч та тигермичә чабасың, ди. Әпсәләмне ун көн эчерсәң, чалгыңның үтүе ун көнгә, унбиш көн эчерсең, унбиш көнгә җитә, ди Атрай Ибрае. Атрай сөйләр, аның әтисе мәрхүмне дә туктаусыз сөйләгәне өчен, Сталин тегермәне, дип йөртәләр иде шул.

Кәүкәбелҗәннәт хәлсез тавыш белән ашарга дәште. Альфред әнисен дә, әтисе чакырганны да тыңламады, берни сөйләшмәде, ашарга утырмады. Әтисе урманга, әнисе эшкә киткәч тә тормады, уйланып ята бирде. Кайсы яктан гына килеп караса да, әнисе гаепле иде. Әгәр ул джинсы чалбарның кесәсенә каптырма такмаган булса, Руфинәнең ятьмәсе ул каптырмага эләкми иде, ятьмәсе эләкмәгәч, ул имтиханга кереп өлгерә иде, әгәр керсә, имтиханын тапшыра алмаган сурәттә дә Руфинә белән танышмый иде, Руфинә белән танышмагач, аны авылга алып кайтмый иде, аны авылга алып кайтмагач, капканы ачык калдыручы булмый, капканы ачык калдырмагач, бозау чыга алмый, бозау чыкмагач, яшел күлмәк белән свитерны чәйнәүче булмый, аш та янып бетми иде. Руфинә китте, аңа кайда да оҗмах. Ә менә Альфред ни эшләр? Әйдә утыр, дигән чакта ник утырып кына китмәде икән ул? Хәзер барып кереп кара син аның квартирасына! Кертү түгел, сәламеңне дә алмаячак. Казанда борын төртер бүтән җире юк аның. Димәк, укырга дип чыгып китү бетте. Казан урынына колхоз кала... Әгәр алар башын бутамасалар, ул үзе конкурс-мазар булмаган берәр техникум ише җиргә тавыш-тынсыз гына барып керәсе иде. Әнисе институтка, әтисе колхозга кыстады. Альфред әнисен тыңлады, чөнки барыбер аныңча буласын ул яхшы белә. Аларның гомер буе ике якка каеруларыннан Альфред моңа кадәр отты гына. Әтисе «Берүк әниеңә әйтмә»,— дип акча бирсә, әнисе: «Кайларда йөрде, кемнәргә керде, күпме эчте?» — дип тагын аңа ялынды. Ул мондый хәлдән отыш алырга, дөреслекне яшерергә, һәр сүзен теш арасында кысып тотарга өйрәнде, әлеге сүзне нинди дә булса яхшылык бәрабәренә генә йә әнисенә, йә әтисенә сатты. Аларның кушканын үтәү дә нәкъ шундый алыш-биреш аша башкарылды.

Андый чаклар инде әллә кайчан үткән, аласылар алынып беткән, алар хәзер аның ачуын гына китерәләр, үзе теләгәнчә яшәргә комачаулыйлар иде.

Кеше үз тормышын үзе корганда гына бәхетле. Ә кайда монда иреклe тормыш? Мәңге булмаячак ул. Ничек кенә уйласаң да, аңа бер генә юл бар: укырга кердем, дигән булып, башны ераккарак алып качу. Шунсыз колхоздан да, әтисе белән әнисеннән дә котылмак юк...

Газдал печәнне чабып бетереп соң гына кайтты. Әштер-өштер капкалагач, Әпсәләмнән ферма хәлләрен белешеп кайтам әле, диде дә, теге банканы эләктереп, дусты янына очты. Әпсәләм Чалмыяга кабык батырырга киткән иде. Шактый кабарынкы сумка тоткан Газдалның ярдан төшеп килүен күргәч, ул шатлыгыннан чак кына Чалмыяга чуммады. Яр астындагы вак ташлык төбенә утырдылар. Икешәр кружка бал эчкәч, Әпсәләм:

— Бүген нинди янгын чыга язды соң сездә? — дип сорады. Газдал гыжылдап көлеп җибәрде һәм кунак кызының күрсәткәннәрен озак итеп, тәмләп сөйләп бирде.

— Кәүкәбел тегеңә бер-ике сүз әйткән иде, кызыбыз гудок сыман акырып җибәрмәсенме? Убырлыныкы кебек, боелыгыбыз ычкына язды. Ха-ха-ха!

— Соң шуннан ни булды?

— Мин: «Үтенәм, мадам!» — дип юл күрсәткәч, машинасына утырды да ычкынды.

— Гел шулай дидеңме?

— Ничек кенә әйттем әле!

Газдал эшләпәсен салып, башын җиргә кадәр иде, кулын Чалмыяга таба сузды. Әпсәләм эчә торган әче балын пошкырып көләргә тотынды:

— Ха-ха-ха! «Мадам» дидеңме?!

— «Прошу, мадам!» дидем.

Аларның көлүеннән елганың бу тирәсендәге балыклар еракка ук качтылар.

— Сиңа бер серем бар,— диде Газдал пышылдап һәм кызыл битен дустының кимендә өч көн кырылмаган куе төкле чыраена тери язды.— Хатын теге кызны кайтып кергән көнне үк миннән көнләде бит.

— Сәйләмә юкны! — диде Әпсәләм аны читкә этеп җибәреп.

— Валлаһи! Ул кыз үзе болай шәп нәрсә. Шикәр инде. Ул буферлары, малай...— Газдал азау тешен «ыфф» дип эчкә суырып куйды.— Мин юри җай килгән саен тегеңә елышкан булам, гел аңа гына карап торам, аның белән генә сөйләшәм. Үзем астан гына күзәтәм — котыра хатын, күзеннән ут чәчә. Ха-ха-ха!

— Ут чәчәме?

— Чәчә. Икебезне дә чәйнәп атар иде.

— Хи-хи-хи!

Көлүеннән туктап, Әпсәләм тагын сорау бирде:

— Хатын-кыз болай да әле ул... Ник үртәдең соң аны?

— Берни дә аңламыйсың син! — Газдал: «Беткән кеше икәнсең», дигән мәгънәдә кулын селтәп куйды.— Теге кызның нинди кош икәнен күрү белән чамаладым мин. Әлфәрит белән бер ояга сыя торган кош булмагач, ник кирәк ул безгә?!

— Хәйләкәр дә инде үзең, чукынчык! — дип Әпсәләм аның иңбашына шапылдатып сугып алды.— Кәүкәбелҗәннәт күзеннән ут чәчә дисең инде.

— Чәчә!

— Алайса «Пужар! Пужар!» дип Убырлы дөрес кычкырган бит! Шуның чәчкән утын күргәндер ул. Ха-ха-ха!

Аңа, гыжылдап һәм хихылдап, Газдал кушылды.

— Көнләшкән чакта Кәүкәбелнең күзләрен күрсәң, менә бу кружка кадәр була, малай!

— Ай, бер генә карап торырга!..

Дуслар тагын көлешәләр, тагын салалар.

— Гел «мадам» дидеңме?

— «Үтенәм, мадам!» дидем.

— Ай, тыңлаплар торырга!

Аларны төн уртасына кадәр тәгәрәтә-тәгәрәтә көлдергән өч литрлы банка, эчендә берни калмагач, үзе дә яр буенда япа-ялгызы тәгәрәп калды.

## 8

Икенче көнне иртүк Альфред: «Дустым янына барам»,— дип, район үзәгенә китте. Төшлектә Кәүкәбелҗәннәт белән Газдал чәй эчеп утырганда Ирдәүкә Илгизә килеп керде. Керү белән:

— Исәнмесез, саумысез, әйбәт кенә яшәп ятасызмы? — дип хәләхвәл сораштыра башлады, ферма хәлләрен сөйләде.

И ходаем, дип уйлады Кәүкәбелҗәннәт аңа карап. Бигрәк черки инде. Җитмәсә джинсы чалбар кигән, чәчен кистергән булган. Ярый инде, гел елмаеп, гел сөйләшеп торучы олы авызы бар. Бу беләкләр белән ничек сыер сава торгандыр. Әлфәритнең өйдә юклыгын белгәч, Илгизә:

— Бүген кич чыксын әле, яме? — диде.

Карале син аны, борыч белән бер үзе, күзеңә чәчрәп кереп тора. Казан кызының китүен генә көтеп, Әлфәритне кармагына эләктерергә ниятләп килмәдеме икән бу? Юк инде, авыл кызларына якын да җибәрмәячәк аны Кәүкәбелҗәннәт. Шәһәргә төпләнсен. Белмәссең, картайган көнеңдә алар янына юл тотуың да бар.

— Илгизә, апаем, укуыгызны бетергәннән бирле күренмәгән идең, әллә бер-бер хәл бармы?

— Юк, юк,— дип көлде Илгизә.— Сыерларга чөгендер ташышырга чакырабыз без аны. Баш тартмас бит?

— Баш тартмас дип...— Кәүкәбелҗәннәт аңа бәреп кенә: «Мин аны колхоз эшенә чыгармаячакмын!» дип әйтә алмады.— Баш тартуын тартмас иде дә, аның укырга китәр чагы да җитә бит инде.

Илгизә шаркылдап көлеп җибәрде:

— Нинди укуга ул, Кәүкәбелҗәннәт апа?

— Нинди дип... институтка.

— Институтта уку өчен башта аңа керергә кирәк бит.

Кәүкәбелҗәннәтнең йөрәге,ниндидер ямьсез хәбәр ишетәсен сизенеп, ачытып куйды.

— Әллә ул кермәгәнме? Бик беләсең килсә, кереп кайтты ул, үскәнем.

— Кермәгән шул, Кәүкәбелҗәннәт апа,— диде Илгизә җитдиләнеп.— Кичә генә Ләйсән Казаннан кайтты. Кагылган ул анда. Керүчеләр исемлегендә Әлфәрит юк, ди.

— Ялгыш машинистка төшереп калдыргандыр,— диде Кәүкәбелҗәннәт, батып барганда саламга ябышып.

— Ә сез кайгырмагыз,— диде Илгизә.— Бергәләп колхозны тәкә күтәрербез.

Кәүкәбелҗәннәт Илгизәнең ничек чыгып киткәнен дә сизми калды. Әлеге хәбәр аның башына күсәк белән органдай итте.

— Хәере белән булсын, кул астына да керергә кеше кирәк,— диде Газдал, хатынын тынычландырырга теләгәндәй.

Кәүкәбелҗәннәт ике кулы белән ике кәҗә тоягы ясап, иренең борын төбендә селкеде:

— Менә сиңа кул астына керүче! Колхозда эшләтер өчен үстермәдем мин аны!

Газдал каршы дәшмәде. Аның белән уртак тормыш көтү дәверендә Газдал ия булган иң көчле корал — дәшмәү, башны юләргә салу иде. Әйе, әйе, ул бу коралны шулкадәр яхшы үзләштерде ки, аның өстенлекләреннән шулкадәр күп файдаланды ки, хәзер башкача яшәргә кушсалар, моны ул үзе өчен олы фаҗига дип кабул итәр иде. Синнән хатын да, колхоз җитәкчеләре дә, авыл халкы да беркайчан да ниндидер зур, югары нәрсәләр көтми һәм таләп итми. Рәхәтләнеп үзең теләгәнчә йөри бир, эч, аша, эшеңдә күренгәләсәң, аунап ятмасаң, ватмасаң-җимермәсәң — син иң әйбәт кеше. Дөрес, кайчакта үзеңә көлеберәк карауларын сизәсең, әмма син тормышны алардан ким аңламыйсың, киресенчә, күпләрнең шул тормышны үзгәртәм дип җан-фәрман чабуларын, үз-үзләрен бетерүләрен, вакытсыз гүргә керүләрен мыек астыннан елмаеп күзәтәсең, димәк, алардан өстен торасың, җаен чыгарып ул юләрләрне кәкре каенга терәтәсең.

Газдал әнә шуңа күрә дәшмәде. Ул өйдән чыкты да туп-туры

колхоз идарәсенә юл тотты. Анда баруының сере бар иде. Әлеге серне Газдал хәтта кичә Чалмыя буенда дусты Әпсәләмгә дә әйтмәде. Аңлы рәвештә әйтмәде. Бүген берсен әйтсә, башка вакытта икенчесен, өченчесен ычкындырса, Әпсәләм аның яшәү хәйләсен белеп алачак иде. Ә инде бер серне ике кеше белү — ул бөтен авыл белү дигән сүз.

Газдалның идарәгә баруы малае белән бәйле иде. Әгәр Альфред институтка кергән булса, ул идарәгә ике аягының берсен дә атлаячак түгел иде. Илгизә әйткән хәбәрне ул борчылып түгел, киресенчә, эченнән куанып кабул итте һәм бер минут та тормыйча председатель янына ашыкты. Инде теге сергә килгәндә, аның теләге Альфредны авылда калдыру иде. Кәүкәбелҗәннәтне көнләштерүе дә Казан кызын хатыны кулы белән кудыртып җибәрү, аны малаеннан аеру өчен эшләде. Дөрес, башлап Кәүкәбелҗәннәт көнләшмәсә, моны эшләү аның ике ятып бер төшенә дә кермәс иде.

Альфредны бала чакта ул үлеп яратты. Шуннан файдаланып, Кәүкәбелҗәннәт Газдалга бала чүпрәкләренә кадәр юдырды. Аның өчен дип яңа өй салдырды. Ләкин үсә башлагач, Альфред әтисен бар дип тә белмәде, әнисен генә тыңлады. Шулкадәр тырышуга лаек булганмы соң бу малай? Әнисе әйткәнчә, адәм әүлиясеме ул? Газдал аның өчен һаман бил бөгәргә тиеш, хәзер аны укытып чыгарырга, өйләндерергә, шәһәрдә төпләндерергә, аңа итен-балын ташып торырга тиеш. Ә Альфред кайчан кайтарыр соң бу бурычны? Кайтару өчен моны аңларга кирәк, ә малайның башына андый исәпнең кереп тә караганы юк һәм мәңге кермәячәк тә. Бусын Газдал күреп тора. Хәзер ул әнисе ярдәмендә авылдан чыгып качачак, аннары теге бурычка кул аркасы белән дога кылырга гына кала. Менә хәзер эләктереп алып, кара тире чыкканчы эшләтергә кирәк аны.

Әлбәттә, Газдал председательгә ул нәрсәләрне әйтмәде, колхозда эшче куллар җитмәвеннән, үзенең һәм хатынының сәламәтлегеннән зарланды, малай укырга керә алмаганын яшереп, аны авылдан чыгып киткәнче эшкә кушарга кирәк, диде. Мондый үтенеч белән керүемне беркемгә дә әйтмәсәгез иде, юкса мине әнисе үтерәчәк, аның холкын беләсез, диде. Председатель Газдалны күзләре яшьләнер дәрәҗәдә кызганып калды.

Район үзәгеннән Альфред кич сыер көтүе белән бергә кайтып керде. Аерма шунда гына иде: сыерлар үлән ашап туйганнар һәм сөт алып кайтканнар, ә ул аракы эчеп туйган һәм уң күзенә «фонарь» асып кайткан.

Аның чайкала-чайкала капкадан килеп керүен күргәч, әнисе каз куарга алган чыбыгы белән сыртына сыдырды.

— Карале җир битне, ә?! Рәсем ясап әзер акчаны алырга ирендең, эчеп исереп йөрергә оят түгелме сиңа?!

— Ә кем өйрәтте мине? Йә әйт әле?

Альфред кызарган күзләре белән әнисенә туп-туры карады.

— Тфү, оятсыз! — дип төкерде дә Кәүкәбелҗәннәт, читкә борылды.

Ах, ул тылсымлы сүзләрнең көче! Үзенә очып кунучы әнисен инде ничәмә-ничә мәртәбә чигенергә мәҗбүр итте ул сүзләр.

Әлфәрит алтынчы класста укыган чакта алар әнисе белән Казанга бардылар, кунакханәдә аерым бүлмәгә урнаштылар. Кич бер абый килде. Өстәл тулы сый-нигъмәт иде. Телевизордан гел күзен алмыйча утырган Әлфәритне чакырып, әнисе ярты стакан чамасы бик баллы һәм куе бер әйбер эчерде. Әз генә утыруга Әлфәрит күзе йомыла башлавын сизде. Аңа шундый рәхәт иде, тез буыннары гәүдәсен тота алмаслык булып йомшардылар. Әнисе аны култыклап алып барып урынга салды. Шуннан соң малай теге тәмле әйберне гел эзли торган булды, олылар күрмәгәндә шешә төбендәге калган

әчемлек тамчыларын авызына тамызды, әкренләп-әкренләп исерү тойгысын татырга өйрәнде. Шулай итеп, эчү мәсьәләсендә әнисе аңа сүз әйтә алмый, әтисенең үзе исерек булганлыктан, хакы юк иде. Әнисенең авызы шуның белән туктады дип, Альфред тынычланырга да өлгермәде, бөтенләй көтелмәгән яктан һөҗүм башланды:

— Син бит укырга кермәгәнсең. Ник безне алдадың?! — дип җилтерәтте аны әнисе.

Әтисе читтән генә карап торды. Әлфәрит айнып киткәндәй булды. Бу — уен түгел, әгәр ул укырга кермәгән икән, теге мең ярымны кайтарып бирергә тиеш иде. Ә ул акчаның инде соңгы йөзлекләре генә калып бара. Очкылык тоткан арада ул көч-хәл белән:

— Кем сөйли ул гайбәтне? — диде.

— Ләйсән исемлекне күреп кайткан.

Әлфәриткә фонарьлы күзе яктырып киткәндәй булды. Ах шул Ләйсәнне! Каян барып кергән ул анда әрсез алабай?! Инде нишләргә? Ни диярга? Аракы зиһенне чуалткан, башка бер генә юньле фикер дә килми.

— Исемлек ни бит ул... Анда мин бүтән фамилия белән язылган.

— Андый нәрсә була алмый! — диде Кәүкәбелҗәннәт чәрелдәп.— Ничек бүтән фамилия язылсын?!

— Теге ярдәм иткән кеше шулай кирәк, диде.

— Ничек ярдәм иткән кеше шулай кирәк, диде.

— Ничек кирәк?!

— Кирәк булгач, кирәк булгандыр.

— Син миңа «дыр» сөйләмә!

— Дыр булгач, дыр инде! — диде Альфред йөзенә үпкәләгән кыяфәт чыгарып.— Ә керүем хак.

Кәүкәбелҗәннәт белән Газдал бер-берсенә карашып куйдыларр.

— Ну, малай актыгы, чамала! — диде Кәүкәбелҗәннәт аның маңгаен йодрыгы белән төя-төя.— Әгәр алдашсаң, башыңдагы чәчеңне бәрәмләп йолкып бетерермен!

Чәч акча түгел, аны бәрәмләп йолкып бетерергә бик күп эш кирәген белгәнгә күрә, Әлфәрит кипшенгән иреннәрен кыеш-мыеш китереп елмайды да печәнлеккә кереп ауды.

Иртән аны колхоз председателенә чакырдылар. Бүлмәдә классташ кызлары Илгизә, Ләйсән, Рушания да бар иде. Институтыңа укырга киткәнче генә (бусы — дипломатик алым) сыерларга басудан чөгендер ташырга булыш, дип ялынгач, Әлфәрит ризалашты. Бергә булгач, Ләйсәннең теге исемлек турында сүз куертуын да туктатырмын, дип уйлады ул.

Ләкин авылда Альфредның укырга керә алмаганлыгы турында хәбәр, язгы су җәелгән кебек, таралып бара иде инде. Аңа каршы әнисе аяусыз көрәш ачты.

— Әлфәрит кермиме соң, кергән! — дип тәкрарлады ул.— Кермәс, алып кадәр башлы! Бишлегә генә биреп керде, аллага шөкер! Профессорлар шаккаттылар, ди, кайда укыдың, атаң-анаң кем, дип сорыйлар, ди. Ие, валлаһи менә. Керде, кермиме соң! Галимҗан кызының әллә нинди исемлек карап кайтуына Әлфәрит гаепле түгел инде. Әллә ни бит аның башы! Кермәскә теге...

* * *

Альфред өчен көтелмәгән яңа тормыш башланды. Беренче көнне алар автомашинага төяп ике юл чөгендер кайтардылар. Көн шундый матур иде. Кояш көне буе көлеп торды, ак болытлар зәңгәр күктән кыр казлары шикелле аларны сәламләп әкрен генә каядыр еракка. Казан ягына ук актылар, юлда очраган электр баганалары аларга, пионерлар

кебек, салют биреп калдылар. Азык чөгендеренең самавыр кадәрлеләре бар иде. Ике кулыңа берничә чөгендер йолкып аласың да, кара-каршы бәреп балчыгын коясың, шуннан соң машина тартмасына ыргытасың. Кызлар туктаусыз шаярышалар, Альфредны: «фонарьлы Казан кияве»,— дип үртиләр. Ул аларны чөгендер арасыннан куып китә, эләктерсә, билләреннән кыса, кулларын каерган була, кочаклап күтәрә, кызларның кайнар тәннәренә кагылудан, чырык-чырык көлүләреннән йөрәге сикерә.

Көтүлеккә кайткач, сыерлар сырып ала, машина акрын гына бара, ә алар дүртәүләп өем өстенә баскан хәлдә чөгендерне җиргә ыргыталар.

Кич танцыдан соң Илгизә чытлыкланып Альфред янына килде дә:

— Әйдә, озатып куям,— диде.

— Юк, мин сине озатам.

Алар урамга чыктылар. Күк дигән иксез-чиксез диңгездә ай дигән түп-түгәрәк көмеш таба йөзә, аның тирәсендә йолдыз дигән исәпсез-хисапсыз күп энҗеләр җем-җем итә. Илгизә аны култыклап алды. Альфред алар урамына таба борылмакчы иде дә, Илгизә аны шып туктатты.

— Сине мин озатып куям.

— Әллә хәзер мода шундый?

— Мин мода куучы түгел.

Вак-төяк сөйләшеп алар бик тиз кайтып җиттеләр. Альфред аны тагын озатырга теләде, әмма Илгизә «юк» кына диде. Шунда Альфред аны кочып алмакчы булды, Илгизә кисәтүле төстә бармак янап:

— Ашыкма, ашка пешәрсең! — диде. Һәм йөгереп китеп барды.

Альфред бик озак йоклый алмады. Илгизә аны ярата бугай. Ул аның яратуын телиме соң? Әллә инде. Нигә авылда калудан курка соң әле ул? Квартира да, тулай торак та әзлисе юк. Эшнең нәрсәсе бар? Балчыклырак инде. Авырлыгы бар барын, куллар сызлап тора. Кызлар эшләгәнне, Альфред эшләмәсме? Алар бит әле шуның өстенә иртәнге дүрттән торып сыер да савалар. Альфред тырышып эшләячәк, үзенең кем икәнен күрсәтәчәк. Сөт артыр, ферма алга китәр, аларны мактап газеталарга язарлар. Көз көне төзү бригадасына күчербез, диде председатель. Ике катлы матур-матур коттеджлар салырлар, берсен үзенә бирерләр. Өйләнеп җибәрер. Кемгә өйләнер икән? Юк, һәрхәлдә Ирдәүкәгә түгел. Артык иләс-миләс. Ләйсән әрсез, Рушания «өч»легә генә укыды. Юк, ул кызның иң асылын район үзәгеннән яисә шәһәрдән алып кайтачак. Аларның гаиләсенә сокланмаган кеше калмас. Бу вакытта Альфред читтән торып институт тәмамлар, аны колхозга йә баш инженер, йә баш агроном итеп куярлар. Үзенең махсус җиңел машинасы. Теләгән җиреңә оч кына. Әгәр арендаторлыкны сынап карасаң? Хәзер бит җир алып, аена икешәр мең сум эшләүчеләр бар. Ә даны? Телевизордан чыгышлар ясыйсы була инде. Тукта, ә нигә җирне хәзер үк алмаска? Классташ егетләр күп бит. Кайсы комбайнчы ярдәмчесе, кайсы тракторда, кайсы фермада эшли. Шуларны тупларга да. Алар белән иртәгә сөйләшергә кирәк, дигән ныклы карарга килгәннән соң гына йоклап китә алды Альфред.

Икенче көнне ул йомшак кына куллар битенә кагылудан күзләрен ачты. Кем дисә — Илгизә!

— Тор, йокы чүлмәге, без инде сыер савып кайттык!

— Сәгать ничә? — диде Альфред карлыккан тавыш белән.

— Тугыз тула. Без сине трактор белән көтеп торабыз,— диде дә Илгизә йөгереп чыгып китте.

Эшкә киткәндә әнисе уяткан иде шул. Кабат йоклап кителгән икән. Альфред сикереп торды. Фу, шайтан алгыры, ни соң бу? Гәүдәне җыеп алышлы түгел. Куллар бөтенләй тагып куелган

төсле. Салкын бәргән, күрәсең. Ә нишләп караңгы? Күкне болыт каплаган икән. Ул юынгычтан ике уч су алып битенә сипте, авызын чайкап төкерде, бер-ике кабым ипи белән өстәлдәге сөтне эчте дә, аягына туфлясын, иңбашына курткасын эләктереп, урамга йөгерде. Трактор дигәне Һашим абзыйның әллә кайчан гамәлдән чыгарылган, тәрәзәләре инде коелган, кабинасы кыйшайган «Беларусь» икән. Аның колхозга кайчан кайтканын да, төсен дә хәтерләүче юк, чөнки ул хәзер бер төстә дә түгел, андый төс, гомумән, юк инде. Кызлар өелешеп трактор арбасына басканнар. Альфред алар янына менде. Арбаның арты бөтенләй юк, ә ян-яклары бүре ашаганнан калган җәнлек кабыргалары төсле чәйнәлеп, өзгәләнеп, сынып беткәннәр, уртадан тарттырылган юан тимерчыбык ике якка ачылып китәргә ирек бирми. Арбаның төбе пычрак булганлыктан, утырырлык түгел иде, алар аягүрә бер-берсенә тотынган хәлдә бардылар.

Басуга килеп җитүгә, пыскаклап яңгыр яварга тотынды, тора-бара ул шыбырдатып ук коя башлады. Чөгендерләрне китереп бәрүгә, сулы балчык чәчелеп битләргә кадәр сылана. Ун-унбиш минут эшләүгә, алар муеннан балчыкка баттылар. Туфлялар, балчык ябышып, фил аягы кадәр булды. Аларны сөйрәп йөрү үзе бер газап иде.

— Бу яңгыр астында күпме эшләмәкче буласыз сез? — диде Альфред шат күренергә тырышып.

Кызлар чытлыкланып көлеп җибәрделәр.

— Бүген икене генә түгел, өч юл алып кайтырга кирәк әле,— диде Илгизә.

— Яңгыр бит...

— Яңгырда сөт кими дә инде ул. Ә кимемәсен өчен чөгендер кирәк.

Альфред яңадан аларга күтәрелеп тә карамады, тешен кысып түзде, эшләде. Ә кызлар әллә юри аны үртәп җырлыйлар да җырлыйлар, шырык-шырык көләләр. Авызларына чөгендер төшкере! Аларга төшми шул. Ә менә үзе аткан чөгендере өч мәртәбә кире тәгәрәп аның башын тишә язды. Соңгысы самавыр кадәр бар иде, күзеннән утлар күренде, ә түбә чәркәсе күбеп чыкты. Тагын бер-ике чөгендер башына туры килсә, ун ел укып алган белемнәреннән берни дә калмаячагын аңлады ул.

Төяп бетергәч, шул яңгырда йөк өстенә утырып кайттылар. Бушатуы төяүгә караганда мең мәртәбә кыенрак булып чыкты. Юеш, сазланган чөгендерләрне эләктереп булмый, эләксә, кулдан шуа. Йөк өстендә кайтканда дер-дер килә башлаган Альфред чөгендер бушатканда тиргә батты. Хәерчегә җил каршы дигәндәй, дыңгылдыкта аягы таеп, ул трактор артыннан чиру кебек ябырылып килүче сыерлар арасына да егылып төште. Маллар аңа тиюен тимәде, әмма кызлар тәгәри-тәгәри көлделәр. Кичен аның табаны купкан туфлясын, җиргә салып тәгәрәткән кебек пычранган киемнәрен, кабарып, суелып беткән уч төпләрен күргәч, Кәүкәбелҗәннәт кычкырып еларга тотынды. Ә Газдал өчен бәйрәм иде. Ул гыжлап көлеп җибәрүдән башта тыелыптыелып торды да, түзә алмагач, сарайга чыгып туйганчы көлде. Колхоз тормышының әнә шулай әче булуын, тәмле ризык ашаганчы, затлы киемнәр кигәнче бик күп тырышырга, интегергә кирәк икәнлеген белергә тиеш иде ул малай актыгы!

Башка чакта сәгать буе өстәл янында утыра торган Альфред каптыр-коптыр ашады да верандага чыгып ауды. Әнисе салкын тимәсен өчен аның өстенә ике кат одеал, өч кат юрган япты, ә үзе эченнән: «Мәңге эшләтәсем юк, шушы арада районга абыйның малае янына барам, прокурор башы белән бер юньле эш табып бирмәсә, йөзенә төкерермен»,— дип уйлады.

Альфред шул ятудан иртәнгә кадәр йоклады. Аны тагын Илгизә

кереп уятты. Бүген әнисе кирза итек, җылы күлмәк-ыштаннар, кожан әзерләп куйган иде. Салкын яңгыр кичә үзәгенә үткәнлектән, аларны ул сөенә-сөенә киде. Ләкин томанланып торган көн кинәт кенә ачылып китте, ялтырап кояш чыкты, дөньяны бөркүлек биләп алды. Альфред кожанын салып трактор кабинасына куйса да, теге җылы киемнәргә түзәр чама юк иде. Аның маңгаеннан аккан борчак-борчак тир күзен әчеттерде, бөтен җире шыбыр су булды, муеннары, култык аслары, ярып тоз сипкәндәй, әчетте, пышлыкты, чиләнеп чыкты. Кирза итекләрнең эченә чөгендер яфракларыннан чәчрәгән су, балчык тулды. Шушындый киемнәр куйганы өчен ул, үз гомеренә ахмаклыгы, диваналыгы бетмәде, дип, әнисен сүкте. Аның үлеп тамагы кипте, су эчәсе килү шулкадәр көчле иде ки, Альфредның хәтта вакыт-вакыт күз аллары караңгыланып алды. Әллә нинди тәмсез, ачкылт һәм тозлы лайладан башка авызында берни калмады, теле кибеп аңкавына ябышты. Ә трактор арбасы, аның шушындый хәлдә икәнен сизмәгән кебек, туларга һич тә ашыкмады.

Ул бу көнне дә кич культура йортына чыга алмады, ничек кайтып ауган булса, шул килеш йоклап китте. Илгизә: «Концерт килгән, кызлар шуңа чакырдылар»,— дип кергән иде, Кәүкәбелҗәннәт аңа юри: «Ул район үзәгенә китте»,— диде.

Аны тагын Илгизә кереп уятты. Көн бүген бик матур иде. Кичәге аяныч хәлгә төшмәс өчен, Альфред кыска җиңле күлмәк, чүпрәк сандалилар гына киде. Беренче йөкне әйбәт кенә төяп кайтардылар. Ләкин икенчесенә баруга, бүрек кадәр болыт килеп чыкты да, шатыр-дөбер давыллап, бозлы яңгыр яуды. Кызлар һәркайсы ябынырга полиэтилен алган булганнар, ул исә йөгереп трактор арбасы астына йөгерде. Кергәндә бәреп маңгаен җимерде. Яңгыр барыбер арба астына да үтте, ул шәбәргән тавыкка әйләнде. Өченче йөкне алып кайтып бушатканда, Альфред классташ кызларыннан да, чөгендердән дә, яңгырдан һәм балчыктан да туйган иде. Ул бер сандалиен югалтып кайтып керде. Дөресрәге, икенчесен дә болгап калдырды, чөнки ул чөгендер тыгып куярлык булып авызын ачкан иде.

Юк, болай яшәп булмый. Шушындый шартларда арендага җир сорау мөмкинме соң?! Ни өчен чөгендер алуны, төяүне механикалаштыру турында беркем дә кайгыртмый?! Моның бит бер арбасын төягән өчен дә орден бирерлек. Председатель, сыра мичкәсеннән юан корсагы белән иелеп, самавырдай чөгендерне үзе йолкып, үзе арбага ыргытып карасын иде әнә. Йә булмаса, Казаннанмы, Мәскәүдәнме килгән берәр зуррак түрә. Күпме түзәрләр иде икән? Институтка имтихан бирергә барсаң, син төягән чөгендерне ашаган сыерның сөтен эчкән профессор сиңа ук «икеле» куеп утырачак. Шушы да булдымы гаделлек?! Юк, моны болай калдырырга ярамый. Альфред, өс-башын алыштыргач, ашагач, председательгә китте. Аның күкрәгендә ургылып ачы нәфрәт уты кайнады. Ник син абзый гәүдә селкетеп йөрисең, диячәк ул аңа. Ник безне шушылай газаплыйсың, диячәк. Фән-техника революциясе заманында кешеләрне коллар кебек эшләтү — җинаять ул, диячәк. Әгәр эшләргә теләмәсәң, урыныңны бушат, башкалар эшләр, диячәк. Ишетмәгәнен ишеттерәчәк әле ул аңа, кешеләр алдында әйтәчәк.

Менә ул идарәгә килеп җитте, икенче катка күтәрелде, председатель ишегенең тоткасына үрелгәндә туктап калды. Йә ярар, әйттең, ди. Шуннан ни булачак? Председатель гафу үтенеп, аңа рәхмәт укыячакмы, чөгендер басуына чыгып йөгерәчәкме, комбайн алып барачакмы? Тагын да авыррак эшкә куяр — шул булыр. Ул акрын гына идарәдән чыкты да кайтып китте. Болай итеп берни дә кыра алмыйсың. Колхозда берни дә үзгәрмәячәк. Димәк, беркөн корган уй-планнар да һавада асылынып калачак. Чөнки аларны тормышка ашыру өчен шартлар юк. Бу шартларны булдыру өчен Казанга китеп белем алырга,

аннары кайтып хуҗалыкны күтәрергә кирәк. Исән-имин чакта бу эшне сузарга ярамый иде. Альфред иртәгә үк Казанга китәргә булды. Әнисенә:

— Теге исемлектәге фамилияне үземнекенә күчертер вакыт җитте, мин институтка киттем,— диде.

Беренче самолетка өлгерү өчен, ул кичтән үк район үзәгенә ычкынды.

Иртән алар турына арбасына кызлар баскан теге «Беларусь» килеп туктады. Ишектә йозак күреп, кызлар аптыраштылар. Илгизә балалар бакчасына кереп, Кәүкәбелҗәннәттән:

— Альфред кайда? — дип сорады.

— Институтыннан чакыру килде, шунда китеп барды,— диде Кәүкәбелҗәннәт.

Илгизә җилкәсен сикертеп куйды. Бу хәбәрне ишеткәч, Ләйсән белән Рушания берьюлы көлеп җибәрделәр:

— Әйттекме без сиңа, Альфредны колхозда эшләтә алмыйсың, дип. Оттырдың, оттырдың, апай, синнән икешәр шоколод тиеш! — дип аны үчекләделәр.

Альфредның китү хәбәре дә тиз таралды. «Укырга да кермәгән килеш пропискага алырлармы икән соң?» — диючеләргә Кәүкәбелҗәннәт бик оста җавап бирде:

— Кермиме соң, кергән, үзебезнең җибәрәсе килмирәк тора әле,— диде.— Газиз балаңнан аерылу кемгә рәхәт? Әтисе дә, сагынырбыз, ди. Әллә берәр елын, авыр булса да, читтән торып кына укытасы микән, дип тә уйлыйбыз. Үзенең дә китәсе килми бугай. Шуңа күрә ректор белән киңәш-табыш итеп карарга китте. Э-э. Читтән торып укырга рөхсәт бирсәләр, кайтыр, бирмәсәләр, нишләрсең, торып укыр инде.

Яңа такмаклар чыгарудан тыш, Илгизә башка берни дә кыра алмады.

## 9

Руфинәнең квартирасы каршындагы тукталышта төшкәч тә, Альфред бераз басып торды. Аның янына керүдән нидер тыя иде аны. Ни? Курку булса кирәк. Руфинә куып чыгарса? Кая барыр ул? Шулчак аның күзе ак күлмәк, ак чалбар кигән бер кызга төште. Кызның сары чәчләре матур булып җилкәләренә җиткән. Йөзе нинди икән? Йөзе күренми, чөнки ул Альфред басып торган җирдән инде узып киткән, беркая борылмыйча ашыга-ашыга каядыр атлый иде. Ләкин мондый фигураны, мондый билләрне, тар чалбар аша сизелеп торган мондый матур аякларны аның беркайчан да күргәне юк иде. Бу инде тау кадәр Руфинә дә түгел, черки кебек Илгизә дә түгел, бу нәкъ аның хыялында йөргән кыз иде. Альфред үз-үзен тыя алмыйча аның артыннан ашыкты. Танышырга, ничек кенә булса да танышырга. Әгәр шушыны эшләмәсә, ул үзен мәңге гафу итмәячәк. Таш яуса да, ул аңардан калмаячак! Альфредка ниндидер бер әчке тавыш аның яхшы кыз икәнлеге, аны кире какмаячагы хакында аваз салды. Ул адымнарын кызулатты, кыз да аны көтеп тормады. Ярты сәгатьләп баргач, кыз трамвай тукталышына килеп басты. Альфредның йөрәге күкрәген җимерердәй булып дөп-дөп типте. Ул бөтенләй икенче якка караган булып, кызның янәшәсенә басты да, йөзен күрергә теләп, акрын гына башын аңа таба борды. Йә аллам! Ник син шушы кадәр дә мәрхәмәтсез соң?! Аның кыз дип әллә никадәр җирләр узып килгәне сап-сары мыеклы бер егет иде! Тфү! Альфред борылып китеп барды, әмма кайсы төштә икәнен абайлый алмады: ул адашкан иде. Нәфисәнең буйлатып йөргән өчен шул кирәк сиңа, дип үз-үзен тиргәде. Руфинәнең квартирасына барып җиткәндә тәмам хәлдән тайган иде. Менә ул таныш баскычлардан күтәрелде, кулъяу-

лыгы белән тирләрен сөртте, «уф» дип бер тирән сулады да таныш төймәгә басты. Бернинди тавыш-тын ишетелмәде. «Өйдә юктыр», дигән уй Альфредның болай да төшкән кәефен тагын да кырды. Әгәр уяна алмыйча гына ятса? Ул төймәгә берничә мәртәбә басты. Ике-өч минут вакыт узгач, Руфинәнең:

— Кем анда? — дигән тавышы ишетелде.

Альфредның эченә җылы йөгерде.

— Мин бу, Альфред.— диде ул шатланып.

Ишек ачылып китте. Руфинә элэктерелеп тә бетмәгән кыска халаттан басып тора иде.

— Исәнме, Руфчик!

Альфред аны үпмәкче булды, әмма Руфинә зал ишегенә таба чигенде. Аның йөзендә әз генә дә шатлык билгеләре күренмәде.

— Йә, нәрсә?

— Безгә аңлашырга кирәк иде...

Руфинә мыскыллы елмайды, тик бер сүз дә дәшмәде. Аның бөтен кыяфәте, күз карашы Альфредның тизрәк чыгып китүен тели иде. Мондый мөнәсәбәтнең булачагын алдан ук исәпкә алган Альфред:

— Мин синнән башка яши алмыйм! — диде.

— Ә мин яши алам!

Кыз, шушының белән сүз бетте, дигәнне аңлатып кухняга атлады.

— Руфинә! — диде Альфред ялварулы тавыш белән.— Әйдә өйләнешик!

Кыз кинәт аңа таба борылды да елмаеп җибәрде:

— Шулаймыни?

Альфред тагын нидер әйтергә авызын гына ачкан иде, зал ишегеннән кар кешесенекедәй бөдрә йон баскан ярым шәрә адәм килеп чыкты.

— Кадерлем, нинди кошчык ул анда? — диде ул, иңбашындагы йоннарын шатыр-шотыр кашып.

Альфред аның киез итек кадәр борынын да, уң як бит уртасындагы ялгыз тырпаеп торучы миңен дә таныды. Бу — теге чакта аны ресторанннан куып чыгарган Зорик иде. Альфредның тыны кысылды, Руфинәнең яңагына чабып җибәрәсе килде, ләкин кулын күтәрерлек хәле калмаган иде.

— Хыянәтче! — дип кычкырды ул күз яшьләре белән.— Акчага сатылган кәнтәй!

Ул ишекне дә япмыйча коридорга ташланды, баскычның ике-өч басмасын берьюлы гына атлап, аска атылды. Хәзер бу дөньяда аңардан да бәхетсез, аңардан да ныграк мәсхәрәләнгән беркем дә юк иде. Бетте, барысы да бетте! Кабахәт дөнья! Кабахәт тормыш! Хыянәтче хатын-кызлар! Бу тормышта ни бар соң аның өчен?! Казанда аны аяк астына салып таптадылар. Авылда муеннан саз, яңгыр астында кол шикелле бил бөгү. Биредә хыянәт! Бөтенесе аңа каршы, бөтенесе аны алдый. Юк, мондый яшәү кирәкми аңа. Үләргә, үләргә! Үкерә-үкерә еласыннар. Илгизәләр еласын. Юк, аларга кадәр Руфинә еласын, үкенсен, чәчен йолкый-йолкый үкерсен. Аны зурлап күмәрләр, бөтен авыл җыелыр. Ул кызыл табут эчендә чәчәкләргә күмелеп матур булып ятар. Укытучылар, классташлары килер, чәчкә салырлар. Комсомол оешмасы секретаре буларак, Илгизә чыгыш ясар. Без аның белән сыерларга чөгендер ташыган идек, ул шундый тырыш, хезмәтен яратып башкара иде, дияр, аның аркасында сыерларның сөтләре күзгә күренеп арткан иде, дияр, без аның белән айга карап серләшеп тә йөргән идек, дияр. Мәктәп директоры да, колхоз председателе дә сөйләр, бөтен халык лышык-лышык елар, аның ак, чибәр йөзенә, күперенке иреннәренә карап, кызлар: «Их, бер генә үбәргә иде»,— дип күз яше түгәрләр, уфтанырлар. Үләргә, бер минут та тормаска! Әнә

торба төягән бер машина ажгырып килә. Шуның астына ташланырга! Фу, бу бигрәк әшәке, кара сөрем бөркеп килә, әнә юньлерәге. Ул аны уздырып җибәрде дә юл читенә үк килеп басты. Машиналар тызбыз үтәләр дә үтәләр иде, Альфред уңайлысын һич тапмады. Әнә бер матур гына, җыйнак кына машина килә. Алай бик кызу да килми. Шуның алдына ятарга кирәк. Ул чемоданын кайда куярга белмәде. Тротуарда гына калдырмаганына үкенде. Ярар, үзе белән бергә машина астына керсен. Шулчак арттан килеп, аны кемдер култыклап алды. Борылып караса — өлкән яшьтәге таза гына милиционер.

— Егет, бу турыдан юлны аркылы чыгарга ярамый,— диде ул.— Беренче юлга штраф салмыйм, матри, яңадан эләкмә!

Альфред китеп барды. Бу кадәр халык кайнап торган урында сиңа үләргә ирек бирәләрме соң! Юк, әлбәттә. Ул үзенең дөрес юл сайламаганын аңлады. Машина имгәтеп кенә калса? Аннары сызланып, операция ясатып больницада ятарсың.

Шулчак аның башына даһи бер уй килде. Университет биредән ерак түгел бит. Аның физика-математика факультеты егерме дүрт катлы бугай. Шуның иң өске катыннан ташланырга. Үлеме аны укырга алмаган профессорларга протест булып яңгырасын. Шундый язу да калдырыр ул. Альфред университетка йөгерде. Физика-математика факультеты бинасына башын чалкан җибәреп карап торды. Моннан сикерсәң дә, үкенечле түгел. Җиңел генә котыласың. Ул әлеге бинага керде, як-ягына каранып лифтны эзләде. Шулчак бер юан гына хатын килеп:

— Сез кемне эзлисез? — диде.

— Мин... эзләмим...

— Сез студентмы соң?

— Юк,— диде Альфред.

— Монда чит кешеләр кертелми, чыгып китегез.

Чыгып китте Альфред. Университетыңны эчеңә бәйлә, түтекәем, әллә бүтән җир тапмас дип беләсеңме, дип уйлады ул. Гомумән, моннан сикерү дөрес булмаган икән. Аяк астына җәелгән шушы бетон плитәләргә егерме фәләненче каттан төшкәч, синнән ни кала инде? Менә хәзер нишләргә икәнен белде ул. Ленин районына чыга торган күпердән суга сикерергә. Бауман урамына төште, «Татар ашлары» яныннан узып, дүртенче троллейбус тукталышына барды һәм өзелеп ашыйсы килүен тойды. Тукта, ник ул ач килеш үләргә тиеш? Рәхәтләнеп соңгы мәртәбә ашап-эчәргә хакы бар лабаса аның! Альфред икенче ягын да уйлады: буш корсак белән сикерсәң, суның сине батырмый торуы да ихтимал, каз куыгы кебек өстә йөзәрсең. Ә корсагың тулы булса, кургаш кебек төпкә генә китәсең, берниндн ыкыр-шыкырсыз. Ул, ресторанга кереп, бик күп төрле аш-суга заказ бирде. Аракы сорарга әле иртә иде. Руфинә өйрәткәнчә, бер егерме бишлекне күрсәтеп:

— Коньяк булмасмы? — дип пышылдады.

Официант хатын «ярар» дип баш какты. Акча кызганып торыр чак түгел, үлгәч барыбер кала. Официант коньякны чынаякка гына салып китерде. Янәшә өстәлдәгеләргә сиздермәс өчен Альфред аны голтлатып эчеп куйды. Дөнья әз генә яктырып китте. Әллә кайчан шушында кергән булса соң! Юк, ул күп утырмый, аның вакыты санаулы, карары кабул ителгән, хәзер язмыштан узмыш юк. Кинәт ул үзенең тагын ялгыш юл сайлаганын аңлап алды. Ә ни өчен күпердән сикерергә! Сине кайчан эзләп табарлар? Күбенеп, ямьсезләнеп беткән булырсың. Хыянәтче Руфинә, теге йонлы кукысы белән вәрәкәмәч килеп, аның үлгәнен белми дә калыр. Юк, бөтенләй ялгыш юл иде бу. Иң яхшысы — эчеп үлү. Аның ишеге төбенә ятып үләргә. Үзенең нинди олы фаҗига эшләгәнен аңласын, гомере буе Альфредның үлеме вөҗданын газаплап торсын аның. Чиләнеп бетсен шуның белән, күп

уйланып, кан-яшь түгүдән йөзенә сары коелсын, чиргә сабышсын.
Альфред ике шешә коньяк алып, Руфинәнең квартирасына юл тотты. Бер ташландык урынга кереп беразын эчкәннән соң, юлын дәвам итте. Таныш баскычтан авырлык белән күтәрелде дә аның ишегенә сөялеп утырды. Тукта, ә ни өчен ул шушында ишек төбендә үләргә тиеш? Аның, шулкадәр чөгендерләр тояп йөреп, кеше кебек урын өстендә ятып үләргә дә хакы юкмыни? Ул ике кулына таянып, аякларын аерып шактый торганнан соң гәүдәсен турайтты һәм йодрыгы белән теге төймәгә берничә мәртәбә басты. Әгәр Зорик булса? Булса, чыгып китәр. Ни өчен Зорик аны куып чыгара ала, ә Альфред моны эшли алмый? Ничек кенә куып чыгара ала! Ул аның чыгып китүен таләп итәр, үтенер. Үләсе кешенең соңгы үтенече канәгатьләндерелергә тиеш. Менә ишек ачылып китте. Халатын иңбашына гына салган Руфинә басып тора иде.
— Әйдә, керәсеңме? — диде ул елмаеп.
— Керәм.— диде Альфред һәм эчкә узды.— Ул мондамы?
— Китте, хатыны белән иде бит ул. Ә син сорашып та тормадың...
«Алдама!» — дип уйлады Альфред. Ярар, аның кайгысымыни хәзер. Ул чайкала-чайкала барып чемоданын ачты һәм коньякларны алып килеп өстәлгә утыртты. Өстәл тулы туралган колбаса, ит иде. Ләкин алар берсе дә Альфредны кызыксындырмадылар. Ул үрелеп ике бокал алды, икесен дә тутырып коньяк салды.
— Утыр! — диде Руфинәгә.
Руфинә елмаеп аның каршына килеп утырды.
— Мин бүген сиңа үч итеп үләм! — диде Альфред үз-үзен жәлләп һәм бокалын эчеп җибәрде.
— Нинди үлү, нинди үлү? — диде Руфинә йомшак җылы куллары белән аның битеннән сөеп.
Аннары ул аның янына килеп кочаклап аягына бастырды.
— Әйдә, ятып ял ит, арыгансың.
— Мин ял итмим, мин үләм! — диде Альфред кычкырып.
— Ярар, ярар, үләрсең.
Альфред мәсхәрәле елмаеп куйды. Руфинә аның сүзләренең ихлас күңелдән әйтелүенә һәм үләчәгенә һаман ышанмый иде.
— Син ник миңа ышанмыйсың?! — диде ул ачу белән.— Мин бит чынлап үләм. Аңлыйсыңмы: үләм!
— Ышанам бит, ышанам...
Руфинә аны култыклап йокы бүлмәсенә алып кереп чалкан салды.
— Ә син елаячаксың, гомер буе... О-о-о! Ничек озак елаячаксың.
Альфред башының туктаусыз аска төшүен, аягының өскә күтәрелүен тойды. Ул инде әллә кайчан әйләнеп, мәтәлчек атып китәргә тиеш иде, әмма нишләптер бертуктаусыз авышты да авышты. Менә ул Руфинәнең ястыктай йомшак киң күкрәгенең тиюен сизде, аның елмаючы иреннәре өстән аңа якынайдылар. «Үбәргә тели».— дип уйлады Альфред һәм башын як-якка чайкады, үзе бертуктаусыз:
— Әле бит мин үлмәдем, үлгәч үбәрсең, үлгәч! — дип кычкырды.
Ләкин Руфинәнең кайнар иреннәре аның иреннәрен эләктереп алдылар. Ах, ничек рәхәт! Нинди тәмле аның иреннәре! Эчеп үлү рәхәт дип әйтәләр иде, чыннан да, шулай икән, дип уйлады Альфред. Әнә ул каядыр еракка очты, димәк, үлде. Берние дә юк икән үлемнең. Ул үз башының нечкәреп, иреннәре белән бергә суырылып, Руфинәнең авызына керә баруын тойды. Баш артыннан ике җилкәсе дә тараеп һәм сузылып авыз эченә керде, ул Руфинәнең тигез, вак тешләре аркылы бүлмәдәге яктылыкны күрде. Ниһаять, акрын гына шуып бөтен гәүдәсе, билләре, аяклары да кереп бетте, теге яктылык ерагайды да бөтенләй сүнде. Альфред шундый йомшак, җылы, ләззәтле, юеш караңгылыктан эчкәре кереп югалды.

## Шамил Маннап

# ИБРАЙ АБЗЫЙ ХИКӘЯТЛӘРЕ

Туган як, балачак хатирәләре һәр адәм баласының күңелендә аның үз гомеренә җитәрлек тәэсирләр калдыра торгандыр. Мондый хатирәләр язучы кеше өчен аеруча кыйммәтле хәзинә.

Минем иҗатым да «кендеге» белән туган җирем — Әлки якларына тоташкан. Хезмәт сөючән, җор күңелле авылдашларым турында соңгы елларда кыска-кыска хикәяләр яздым. Авылымда күргән, ишеткән, үзем кичергәннәрне кайчандыр ут күршебез булган урман карачы абзый образы аша бирергә тырыштым.

Татар Мулла авылына бер кайтуымда Ибрай абзыйның хәләл җефете Миңзифа апа үз итеп әйтте:

— Ибрай абзаңның данын еракларга җибәрергә телисең ахры син, күрше?

— Хикәяләрдә үз исемен алганга картың үпкәләмиме соң? — дип сорадым мин үз чиратымда.

— Юк, нани, үпкәләми,— диде Миңзифа апа көлеп,— үпкәләргә ни, ул бит юньләп укый да белми. Без аңа үзе турында мактап язганнарыңны гына укып бирәбез...

Ибрай абзый үзе исә минем белән күрешкәндә аны-моны әйтми, бары тик мыек астыннан елмаеп кына куя торган иде.

Ибрай абзый турындагы хикәятләрнең кайберләре көндәлек матбугатта басылгалады. Тик, ни үкенеч, инде аларны тыңлар өчен Бөек Ватан сугышы һәм хезмәт ветераны, минем җор күңелле күршем үзе генә дөньяда юк...

***АВТОР.***

## Ачык йөрәк һәм ябык ишекләр



Аяклары җиргә казып утыртылган өстәлдә домино сугабыз. Көннәр язга авышканлыктан, кул туңарлык түгел. Ибрай абзый, гадәтенчә, транзисторының «колагын борып» куйды. Казаннан кичке концерт башланды. Таныш җыр яңгырады:

> Килегез сез миңа, кешеләр,
> Йөрәгем һәркемгә шар ачык...

Шулвакыт, һич көтмәгәндә, тәмәкедән саргайган эре тешләрен ыржайтып, Ибрай абзый хихылдарга тотынды. Без моңа аптырап карадык.

— Ни булды, Ибрай абзый, әллә шайтан кытыклый инде үзеңне?

Ул, шаркылдап көлүдән атылып чыккан күз яшьләрен шарф очы белән сөртәп ташлады да:

— Бу җырның сүзләрен язган Рамай Рәхмәтидә кунакта булуым искә төште,— диде.

Ибрай абзыйның җырга-көйгә, шигырьгә бик мөкиббән кеше икәнен дә, кәҗәсен менә шушы транзисторны алу өчен күптән түгел Казанга барып,

---

Шамил МАННАП *(1938) — шагыйрь һәм прозаик. «Әти урманы», «Апрель авазы», «Җиргә сыенам» һәм башка китаплар авторы. Казанда яши.*

сатып кайтуын да беләбез. Әмма шагыйрь хәтле шагыйрьдә кунакта булуын әлегәчә ишеткәнебез юк иде.

— Ну борчакның эресен сибәсең дә инде, абзыкаем!

Ул колакчын бүреген арткарак шудырып куйды:

— Билләһи газим, алдамыйм, нанилар. Менә сезнең белән сөйләшкән кебек янәшә утырдык.

— Соң аның нинди көлкесе бар?

— Вәт анысы башка мәсьәлә. Тәки төбенә кадәр төшәсез бит. Шушы җыр капчыгы (ул транзисторга чиертеп алды) өчен калага барганымны беләсез инде. Паром соңарганлыктан, Казанга кичкырын гына барып төштем. Итне базар складына урнаштырдым да, инде үземә кая барып сыенырга, дип уйладым. Кышкы кич, шактый суык. Кунакханә дигәннәренә бардым — урын юк, диделәр. Шәһәрнең бер-бер йортына безнең авыл халкы кереп сыярлык та бит, белмәгән килешкә кайсы ишекне кагасың. Шулай баш ватып торганда шалт — искә төшмәсенме: бәй, Рамай Рәхмәти яшәргә тиешле бит монда. Радиодан көн саен диярлек «Килегез дә килегез!» дигән җырын җырлыйлар. Исеме генә түгел, үзе дә рәхмәтле адәмдер ул, мәйтәм, югыйсә шулай өзелеп-өзелеп чакырмас иде. Киттем радиокомитетне эзләп. Анда Рамайның адрисен бик тиз табып бирделәр, рәхмәт төшкерләре.

Колхоз базарыннан әллә ни ерак та тормый икән. Ишекне көрәк сакаллы ир-ат ачты. Буйга зур түгел үзе. Кылыч борыны өстендә күзлек эзе кызарып тора. Китапларыннан Рамайның сурәтен күргән бар, ул сакалсыз булырга тиеш иде.

— Миңа Рамай Рәхмәти кирәк иде.

— Бик хуп, агайне, ул сезнең алда,— ди бу.

— Һм-м. Рәсемдәге Рамай сакалсыз иде шикелле.

Ул пеләшләнә башлаган башына ишарәләде:

— Чәч урынына, төк санын киметәсе килми.

— Ансы шулай,— мәттем,— сакал үстерү — иген игү түгел, үсә бирсен. Тик сез күзлекле идегез бит.

— Ә мин сезне күзлексез дә күрәм агайне. Ни йомыш?

— Йомыш дип, әйтерлек йомыш юк та. Тик менә...

— Ярый, әйдә керегез әле, аяк өсте сөйләшү әйбәт түгел.

Фатиры ару гына икән. Диванда, җәмәгатедер инде, бер хатын сузылып яткан килеш телевизор карый. Ул әллә сәламемне ишетмәде, әллә ишетеп тә илтифат итмәде — күзен экраннан алмады.

Рамай мине икенче яктагы кечерәк бүлмәгә алып керде. Монда китап та китап, минсиңайтим — идәннән түшәмгә кадәр. Вәт, мәйтәм, яфрак калынлыгы китап язу өчен күпме укырга кирәк икән. Ә бер почмакта кармак таяклары кебек нәрсәләр.

— Балыкка да баргалыйсыз, ахры,— мәттем.

Рамай, уңайсызлангандай, сакалын сыпыргалап алды.

— Сирәк-мирәк. Еш ычкынып булмый, агайне,— диде. Һәм, нәрсәләрдән ычкынып булмавына ишарә ясагандай, башта карашын күзлеге аунап яткан язу өстәленә, аннары хатыны яткан теге бүлмәгә юнәлтеп алды.

— Без танышмадык та бит әле,— дидем мин.— Ибраһим булабыз. Авылда Ибрай гына диләр.

Рамай көлеп куйды:

— Язучылар теле белән әйткәндә, псевдонимыгыз була инде ул алайса. Язмыйсыздыр бит?

— Ю-у-ук. Шту сез. Кеше язганны укуны гына мәслихәт күрәм. Мин базарга ит апкилдем. Транзистор аласы бар ие. Ә кунакханәдә урын юк икән, кадалгыры.

— Шулаймыни? — диде Рәхмәти, хәлемне аңлагандай.— Гостиница ягыннан шәһәрдә читенрәк шул. Берәр туган-тумачагыз юкмыни соң?

— Хикмәт тә шунда шул.

— Ә нигә нәкъ менә миңа керәсе иттегез? Гостиницага минем ни катышым? — диде Рәхмәти, күземә туры карамаска тырышып.

— Соң, аптыраган үрдәк арты белән суга чума дигәндәй, сезнең теге, «Килегез миңа» дигән җырыгыз искә төште дә...

Рәхмәти өстәлдә яткан күзлеген алып, кылыч борынына атландырды, ни сөйли бу адәм, дигән сыман, миңа текәлде. Аннары, ык көләсе килсә дә, тавышын тыеп кына хихылдады. Хәтта сакал төпләре алсуланудан кара сакалы җирән төскә кергәндәй булды.

— Хи-хи-хих. Вәт кәмит. Соң ул бит — җыр, агайне. Җырның ертыгы юк.
Мин дә бирешергә теләмәдем:
— Чын ихластан түгел икән, ничу чакырырга!
Алгы бүлмәдән теге хатын тавышы ишетелде:
— Нәрсә кешнисез анда? Башны авырттырып. Бетмәде бу җилкуарлары да. Авылдан килделәрме — күзләрен акайтып монда чабалар. Постоялый дворга әйләндерделәр чистый!
Рамай, бер карыш кечерәеп калгандай булып, урындыгына сеңде.
— Кхым. Ярый, агайне, мин сиңа (ул «сез»дән «син»гә күчте) булышырга тырышырмын. Киттек.
Урамга чыккач өстәде:
— Ерак та түгел, минем бер дус яши. Бәлки, ишеткәнең дә бардыр — Зыя Ихласины?
— Теге, «Йолдызларың белән кил син миңа»,— дип язучымы?
Рәхмәтинең күзлек пыялалары елтырап китте:
— Оhо, агайне, син безнең братны гомумән дә шәп беләсең икән бит! Болай булгач, чәйли-чәйли сөйләшеп утырырга була синең белән.
Тик Зыя Ихласи дигәне кайсыдыр районга командировкага киткән булып чыкты.
— Кайгырма,— диде Рәхмәти,— безнең Гадел Идеалов та шушы тирәдә генә... Ул үзе, болай корырак булса да, деловой егет.
— Гәзиттәме, журналдамы — кайдадыр укыганым бар шикелле ул шагыйрьне.
— Шагыйрь түгел, драматург. Элегрәк шигырь яза иде. Соңыннан драмага күчте. Драма язганнарга сәмәнне күбрәк түлиләр.
— Безнеңчә әйткәндә, театр куючы икән.
Идеалов дигәннәре безне кочак җәеп каршы алды. Яшь. Җегәрле күренә.
— Оhо-hо! Әйдүк. Түрдән узыгыз, егетләр,— диде ул.— Какраз хатын да өйдә юк чак. Утырыйк әле бер иркенләп.
Хәл-әхвәл белешкәннән соң тагын да ачыла төште:
— hо-hо, миллионлы шәһәрдә кунып чыгарга урын юк диң, ә? Шәп конфликт бит бу!
Идеалов учын-учка шапылдатып алды:
— Ну, нинди чәй пешерим, hинд чәенме, сәйлүннеме?
— Безгә сәйлүне дә ярый,— диде Рәхмәти, ачылып елмайды.
— Мәтрүшкә дә салыйммы?
— Иллә дә тәмләтә инде ул чәйне!
— Бөтнек тә өстәргәме, егетләр?
Гадел шулай сөйләнә-сөйләнә кухняда әвәрә килде. Нәрсәнедер шалтыратып төшереп җибәрде, нәрсәнедер дөбердәтеп аударды. Аннары янә безнең яныбызга чыкты.
— Газ юк икән, егетләр. Бигайбә инде,— диде. Аннары:— Ну, хәзер нишлибез, егетләр? — дип сорады.
— Инде китсәк тә буладыр, шәт,— дидем мин кузгалып.
Гадел каршы килмәде.
— Ярый алайса, бигайбә, егетләр. Хатын өйдә булмады. Пилмән дә ашаган булыр идек. Минем хатын бик шәп әмәлли пилмәнне...
Төнге урамга чыккач, беркавым сүзсез тордык.
— Хәзер нишлибез инде, егетләр? — дип куйды Рәхмәти, әллә шаярып, әллә чынлап...

Ибрай абзый, сүзеннән туктап, кесәсеннән «Астра» кабы чыгарды. Тартучыларга өләшкәннән соң, үзе дә сигарет алып капты. Кабызып, авызыннан төтен алкалары чыгара башлады.
— Шуннан нишләдегез соң? — дип сорады арадан берәү.
— Шуннан утырган да шуган, чалбары тишек булган, тишегеннән кар тулган.
Ибрай абзый шулай, бәясен арттыргандай әз генә көттереп алганнан соң, сүзен дәвам итте:
— Ул төнне кунакханәләргә дә кабат сугылып карадык, әмма ләкин берсендә дә аякны сузып ял итү насыйп булмады. Шуннан Рамай Рәхмәти гаҗиз булып әйтте:
— Ярый, Ибраhим абый,— диде,— үземә генә кайтырбыз инде булмаса. Хәзер, ялгыз кайтсам да, барыбер миңа хатыннан мәрхәмәт булмаячак,— диде.

Безгә ишекне озак ачмый тордылар. Аннары хатынының тавышы ишетелде:

— Кем бар анда?

— Без әле бу, Муза,— диде Рәхмәти.— Ач әле.

— Ач булсаң, ашап кайталар аны!

Шуннан, нанилар, ишек сызык кына ачылды, аннан кызыл тырнаклы йомры гына кул сузылды да Рәхмәтинең якасыннан эләктереп алды. И Рәхмәтине син күр дә, мин күр. Күз ачып йомган арада әлеге кул артыннан суырылып, өйгә керде дә китте. Ишек шапылдап ябылды. Мин подъездда япаялгыз калдым.

Нишлим, бераз таптангалап тордым да вокзалга юнәлдем. Анда, үзегез беләсез, һәрвакыт кеше була. Шунда, скәмьядә чүмәшеп, төнне уздырдым. Икенче көнне, эшне бетереп, шушы транзисторны элдем дә авылга сыпырттым.

— «Килегез, кешеләр, сезгә йөрәгем шар ачык»,— диде арадан берәү.

Ибрай абзый сигаретын чытырдатып тагын бер суырды да төпчеген җешпек карга ташлады!

— Нишлисең бит, нанилар, ачык йөрәктә төн кунып булмый шул, ишекләр бикле булга-а-ач,— дип сузды ул.

## Кәкре каенлы Полковник абзый



Узган сугышта безнең авылдан шактый кеше катнашса да, алар арасыннан зур командирлар чыкмаган, әй. Әле соңгы елларда гына кайбер егетләр, хәрби училищеларга китеп, офицер дәрәҗәсе ала башлады. Элек патша да белмәгән йөз йортлы кечкенә генә авылдан Бөек Ватан сугышы өчен хәрби җитәкчеләр табылмавы әллә ни гаҗәп тә түгелдер.

Шулай да бер «Полковник» абзый бар безнең авылда. Урман карауччы Ибрай абзыйны олысы да, кечесе дә әнә шулай атый.

— Полковник абзый зелпе тамыры тапшырганнарга печән чабарга рөхсәт итә икән.

— Яшь үсентеләр утыртырга барасы. Полковник безне үзе идарәдән сораган.

Хәтта үзен очратканда да аңа шулай дәшәләр:

— Полковник абзый, исәнлек-саулыкмы?

Ул, аркасындагы ике көпшәле мылтыкны рәтләштергәләп куя да, сынын туры тотарга тырышып:

— Так-тучны, тимер кебек! — дип җавап бирә.

Печтик кенә «тамак чылатып» алган — кәефле вакытларында үзенең ничек итеп полковник булуы турында сөйләргә дә ярата ул.

Сөйләвенә караганда, Ибрай абзый сугыш башында самолетта кочегар булган, имеш. Һөҗүм вакытында бомбалары беткәч, фрицларга зур-зур антрацит кисәкләре тондырырга да күп алмаган. Әй, качалар икән тегеләр, әй, йөгерәләр! Утлы табага басканнар, диярсең.

— Самолетка күмер ягалармыни? — дип, берәрсе шик-шөбһә белдерсә, җавапны тәмәке янчыгы белән бергә тартып чыгара ул:

— Бензиның бетсә, күмер түгел, салам да ягарсың, нанилар.

Ибрай абзый, сөйләгәндә, терсәктән киселгән сул кулы белән каз канатыдай итеп кагынып-кагынып куя. Бу аның сөйләвенә янә дә җорлык өсти сыман. Олыраклар: «Әй, килештереп тә алдый бу»,— дигәндәй, мыек астыннан гына елмаеп утыралар, ә без — малайлар — күзләребезне дүрт итеп, колакларыбызны биш итеп тыңлыйбыз.

— Шуннан, нанилар,— дип дәвам итә урман карауччы,— сәләтемне белеп алган башлыклар мине җәяүле гаскәргә күчерде.— Тик, мимечне куып барган-

да, гөнаһ шомлыгына каршы, безнең полк командиры сырхаулады. Эченә кату төште. Кату да төшәрлек, фрицны һич куып җитеп булмый, яман да каты сыпырта, каһәр. Шуннан эчен тоткан полковник әйтә миңа: «Иптәш Ибрай,— ди,— минем портупея, планшетны тотып тор бераз»,— ди. Үзегез беләсез, командир фәрманы — солдат өчен закон.

Ул арада фрицлар да туктап, күзлекләрен ялтырата-ялтырата безнең якка карап тора башладылар. Борылып һөҗүм итәргә ахры исәпләре мәлгуньнәрнең.

Шуннан мин полковникның портупеясын киеп алдым да, полкны ияртеп, алга ыргылдым. «Ур-ра!» — кычкырабыз, гранаталар томырабыз. Лимонкалар, минсиңайтим, Австрия казлары шикелле оча.

Дошман, хәлдән таеп, каршыдагы урманга кереп качты. Ә урманда минем судагы балык кебек икәнне үзегез беләсез. «Эһ» дигәнче куып чыгардык дошманны. Башта, ялтын-йолтын каранып, күзлекле янарал килеп чыкты.

— Һенде һох! — дип кычкырдым моңа. Безнеңчә: «Кулларыңны күтәр, собакы!» — дигән сүз була бу.

Колга буе кулларын һавада бутап, ялына башлады теге:

— Киндер-миндер, арбайт-марбайт! — ди. Ягъни мәсәлән, егетләр, һәлак итмәгез. Мин дә «уфалла» арбасы тартып үскән малай, мин дә эшче-крәстиән яклы, дигәне.

— Әһә,— минәйтәм,— хәзер син дә безнең яклымыни?! Алайса ни пычагыма эшче-крәстиән дәүләтенә каршы корал күтәрдең?

— Гитләр капут! — ди бу. Гитлер кушты, янәсе.

— Шәһәр, авылларны җимерергә, бер гөнаһсыз бала-чагаларны, хатынкызларны, карт-корыны үтерергә, урманнарны яндырырга да шул тилергән эт куштымы? — дип, әй, сал-лып җибәрмәкче идем тегеңә, бәхете — безне куып җиткән командир җиңемнән тотып калды.

— Коралсыз дошманны кыйнау егетлек түгел, иптәш Ибрай,— ди.

Башта шулай ачуланса да, соңыннан стройны тезеп, фашистларны үзеннән башка йөз чакрым куганым өчен миңа рәхмәт әйтте тагы. «Әле, бәлкем, орденга да тәкъдим итәрмен үзеңне»,— дип өстәде.

Шунда арадан беребез сорап куя:

— Бирделәрме соң орденны, Полковник абзый?

— Сугыш беткәч, бирәр атна көт, орденың килеп җитсен,— дигәннәр иде дә, җан түзмәде. «Урмандагы кәкре каенымны, Шүрәлемне сагындым»,— дип кайтырга чыктым. Кайчан да булса килеп җитәр әле ул бүләк. Шүрәлемне сагындым шул, нанилар, Шүрәлемне...

Ул арада без Ибрай абзыйны яңадан йолыккалый башлыйбыз:

— Ә Шүрәлеңне безгә кайчан күрсәтәсең?

Ул зәңгәр очкынлы күзләрен кыса төшеп елмая:

— Хет бүген үк, әйдәгез соң. Тик үзегез белән китмән, көрәкләр алырга онытмагыз. Шүрәле ул эшсез кул кушырып торганны бер дә өнәми.

Без, шаулаша-сөйләшә кыркапкадан чыгып, авылга ук авып торган урманга юнәләбез. Ибрай абзый безне туп-туры яшь имәнлеккә алып бара.

— Узган юлы Шүрәлене шунда күрдем. Былтыр кыскан бармагын чүпрәк белән бәйләп утыра иде,— ди ул.— Хәзергә менә шушы яшь имән төпләрен йомшарта торыгыз. «Урман сарыгы» күренгәч тә, мин сезгә әйтермен.

Урман караучының төрле мәзәкләрен тыңлап, эшли-эшли кояш баеганын да сизми калабыз...

Кайтыр юлга чыгар алдыннан Шүрәле янә исебезгә төшә.

— Әй, Полковник абзый, кайда соң синең Шүрәлең?

Ибрай абзый, чын-чынлап гаҗәпләнгәндәй, тирә-ягына карана.

— Күрмәдегезмени соң, нанилар? Сез эшләгәндә ул ә-әнә теге кәкре каен артыннан ялтын-йолтын каранып китте бит. Минем сезне эштән генә бүлдерәсем килмәде. Ярый инде, башка вакытта...

Бу вакыйгадан соң:

— Безне дә кәкре каенга терәткәч, фрицларны терәткән дә терәткән инде Полковник абзый! — дип көлештек.

# Мунча пəрилəре



Уку ялыктырып, уен туйдыргач, без малайларның билгеле инде — берəр яңа кызык эзли башлыйбыз. Ə кызыкны аны əллə кайдан аласы түгел. Əнə ул, əбилəр чуагының җылымса көнендə башына зур колакчын бүрек, аягына киез итек киеп, капка төбендəге эскəмиягə чыгып утырган.

— Нихəл, Ибрай абзый?

Ул, уң кулын каш өстенə куеп, безгə күтəрелеп карый. Шаярып җавап бирə:

— Сезне күргəч бетте хəл, нанилар, сезне күргəч бетте хəл.

Башлап сəлам бирүче, гомумəн, өлкəннəр белəн гəплəшергə яратучан белдекле Миңнəхəт аптырап калмый:

— «Саумы?» — дисəң, «Əллə син духтырмы?» — дисең, сиңа, Ибрай абзый, сүз табып та бетерə алмассың. Əйдə булмаса, үзең күргəн-белгəннəрне сөйлəп җибəр əле. Сөйлəргə артык күп хəл дə кирəкми.

— Һе, алай икəн. Күргəн-белгəннəр сезнең елтырык борын төбеннəн бик ерак китми шул инде хəзер. Аякта рматиз бит...

— Йə инде, Ибрай абзый, ялындырма,— дип без дə ябырылабыз.

Ул кожан кесəсеннəн чигүле янчыгын ала, ашыкмый гына «кəҗə аягы» төрергə тотына.

— Нəмəстə сүлим икəн соң сезгə, нанилар? Хəзер бит сез туганда ук нивирситет бетереп туган ахырзаман кувшиннары.

— Э-э, əнə теге Болан сазлыгындагы Шүрəлелəр туе турында сөйлə! — ди Миңнəхəт.

Авызын һəрвакыт карга баласы кебек ачып йөри торган һөҗүмчəн холыклы Сəпəр аңа каршы төшə:

— Таптың сүз! Шүрəлелəр түгел, урман талаучы исерек браконьерлар турында бит ул. Шуны да аңламадыңмыни?

Миңнəхəт, Сəпəрнең сүзен колагына элмəгəн булып кыланса да, фикерен үзгəртə:

— Алайса Латыйф абзый мунчасында күргəн мунча пəрие турында.

Ибрай абзый, безнең бəхəслəшкəнне кəефе килеп,тəмəке төтененнəн саргайган мыек чылгыйлары астыннан елмаеп тыңлап тора да, тəмəкесен кабызып җибəрə.

— И-и, нанилар, Латыйф кордаш мунчасындагы пəри пүчтəк икəн ул. Мунча хуҗасының үз карчыгына охшаган ул мəхлүкнең миңа зəррə-бөртек тə зарары тимəде. Ə менə кала мунчасындагыларын күрсəгез икəн сез! Əле дə, исемə төшкəн саен, салкын тиргə батам.

Ибрай абзый, аз гына көттереп-тынып торганнан соң, дəвам итə:

— Шул, калага баргачтын булды бу хəл. Аякларымны берсəк парлап кайтыйм дип, мунчага ниятлəдем. Теге, Сазгурттагы иске мунчага. Кызым каршы да төшеп караган иде. Ваннада гына рəхəтлəнеп чупырдап ят, ди. Тыңламадым шул. Без, авыл кешесе, каен миннеге белəн парланып керергə күнеккəн бит. Ну, кызны тыңламаганга соңынтын үзем дə үкендем-үкенүен, тик терсəк кенə ерак инде.

Баштук чират сиратына барып төртелдем. Анда ике рəкягать намаз укырлык вакыт узды. Аннары мунчага кердем,— ут сүнеп китте. Мунчачы карчыкның сукрануына караганда, электрик-слесарь исереп кайтып киткəн. Капланып эчə торган вакыты башланган икəн, мөртəтнең.

Капшана-капшана бер урын табып, килеп утырдым. Мəгəр уңмадым. Ике тарафымнан да юынтык сулар сибəргə тотындылар, абзыкаем.

— Нишлисез! — мəтəм. Мин үзем дə юына алам лабаса!

Тик кычкыру-ялваруларым һичнинди файда-нəтиҗə бирмəде. Тондыралар гына, рəхмəт төшкерлəре. Ул да булмады, баш өстеннəн выж да выж миннеклəр оча башлады.

Мин шик-хафага төштем. Бабай мəрхүмнең сүлəгəннəре кылт итеп искə төште. Элек, мəдрəсəлəрдə төнлə бəйдəн ычкынган шайтаннарның мендəр, киезката, себерке ише нəрсəлəр атышып уйнаулары турында сүли иде ул. Мəтəм,

мөгаен шул мәлгуньнәр! Адәми зат булсалар, яхшылап әткәнне аңламаслар идеме?

Белгән догаларымны укый-укый бу шаукымлы урыннан тынычрак почмакка күчәсе иттем. Әмма дә ләкин, почмакка җитәрәк, торбадан чыккандай гөрелдек тавыш туктатты мине:

— Стой! Хту идет?

— Бывши гвардин, стрелок первого класса Ибрай Хамраев! — дип чатнатып җавап бирдем.

— Ә-ә, минем кебек картлач икәнсең, утыр әйдә,— ди теге тавыш.

Бу очракта минем бәхет басты, әлеге абзагыз шайтан түгел, адәми зат булып чыкты. Зарымны тыңлагач, көлеп кенә куйды. Шул, бер-беребезнең аркасын юыштык. Дөрес, мин сабынлауга кайнар су килми башлады. Ярый әле, теге запаслы кеше икән. Җыеп калган бер таз суы бар иде, шуны икебезгә җиткездек.

Тик шайтаннарның миңа хассынуы моның белән генә бетмәгән икән әле. Чыга башлагач, ни күрим: киемнәремнән җилләр искән. Ертык подштаннигым гына калган. Анысы да калмаган булыр иде, бер йонлач күкрәкле шайтан үз астына салып утырган да тәмәке пыскыта. Мин әйберләремне эзләп чабулый башлагач, акаеп бер карады да, салкын парнойга кереп китте.

— Кая минем әйберләрем? — дип сорыйм мунчачыдан.

— Мин каян белим. Бу караңгыда үземне урлап китсәләр дә берниш ләп тә булмый,— ди бу.

— Син җен карчыгы кемгә хаҗәт,— минәйтәм.

Ә теге, минем белән юынган карт, көлә генә:

— Ярый әле, кордаш, карчыгыңны алып килмәгәнсең, юкса аңардан да колак кагасы икәнсең,— ди.

Үзе миңа артык-портык киемнәрен бирде, рәхмәт төшкере. Шуларга төренеп, кызым фатирына чак кайтып егылдым...

— Их, шәһәр мунчасы, көн дә шулай булсачы! дип җырламадыңмы соң, Ибрай абзый?

— Һә, җырларсың, бар. Шайтаннар шаукымыннан әле дә айнып җитеп булмый, абзыкаем. Рматизым да куәтләнде. Әбиләр чуагы җиткәч тә киез итек өстерәп йөр инде менә хәзер...— дип түгәрәкләде сүзен Ибрай абзый.

*1978—1981.*

## Шигърият

# Резеда Вәлиева

## Дөреслек

Ничек кенә аны измәделәр:
Зинданнарга аны яптылар,
Этапларда аны озаттылар,
Алтыннарга аны саттылар.
Яшерделәр кара җир астына,
Агыздылар салып суларга.
Бугазына басып тилмерттеләр,
Һава бирми аңа суларга.
Күпме җәбер...
Күпме газап, золым...
Ничек яшәгән ул сүнмичә?
Болыт ярып чыккан
Кояш кебек
Ул нур чәчә бүген,
Ул — исән!

*

Кулларыңа каләм алсаң, җырың булсын
Салкын җанны Мәҗнүн итеп сөйдерерлек.
Ядрә булсын, ялкын булсын һәрбер сүзең —
Дошманыңның таштай җанын көйдерерлек.

Назлы йөрәк тылсымлы наз алсын аннан,
Сагышларын бассын сагыш күргән күңел.
Ләйсән яңгыр булсын туңган бәгырьләргә...—
Шунсыз бит ул берәүгә дә кирәк түгел.

*

Әле җырлыйм, әле елыйм, әле көләм,
Тормыш дигән олы юлдан шулай киләм.
Ялгыз түгел ләкин кайгы-шатлыкларда,
Ни күрсәм дә барсы бергә халкым белән.

# Шәмсия Җиһангирова

## Бер адымга гына

Мин йөргәндә уйлап — очратырга
Җир йөзенең әллә кай ягында,
Син булгансың икән
Миннән бары
Бер адымда гына,
Бер адымда гына...

Уртаклашыр кеше табалмыйча,
Кайгылардан ут йоткан чагында,
Син булгансың икән
Миннән бары
Бер адымда гына,
Бер адымда гына...

Гомер юлын синсез кичә алмам! —
Бул янымда, гел җанымда гына.
Җирдән киткән чакта,
Син соңга кал
Бер адымга гына,
Бер адымга гына...

❁

Аһ дисәм дә, уһ дисәм дә
Җиңел түгел, авыр хәлем —
Гомеремнең бер ялгызы
Юл чатында калган мәле.

Җиңел түгел тутыруы
Гомер буе бушатканны...
Сөю эстәп ярсуларым
Хәзер микән, шул чактанмы?

Җилгә каршы, сөрән салып,
Килә ярсып кычкырасым:
— Мин барасы юлга чык! — дип, —
Нигә карап тик торасың?!

Күрмисеңме: күзләремдә
Соңгы сөю уты дөрли...
Шул утларда көйри-көйри,
Ничек яшим сине күрми?!

Килә әле, килә минем
Соңгы кабат сөеләсем!
Ә аннары... Сүнәрменме?
Дөрләрменме?! Син беләсең...

❁

Мин ярattым сине
Җаным-тәнем белән.
Янып-көеп. Дөрләп. Ут кабып.
Ләкин синең саран күңелеңдә
Кабынмады җавап учагы.

Син сындырдың — тик син! —
Ике канатымны.—
Мин егылдым. Хәлсез. Әлсерәп.
Суга гына белгән ике кулың
Йөрәгемә үрелә... Җан сорап...

❁

Син минем иң гүзәл чагымны күрмәдең —
Яшендәй янганын күзләрнең...
Син минем иң моңлы чагымны күрмәдең —
Еладым... еладым — түзмәдем.

Син минем иң назлы чагымны күрмәдең —
Аһ орып, ятларга сыендым.
Син минем иң иләс чагымны күрмәдең —
Нур булып күкләргә уелдым.

Син минем иң изге чагымны күрмәдең —
Фал ачып төшемне юраттым...
Хәзер мин гап-гади җир заты —
Югалттың син мине, югалттың...

## Мөслимдә — сабантуйда

Томырылып килә чабышкылар,
Тоякта — ут, күзләрендә — ярсу.
Мин дә кайныйм кеше диңгезендә,
Кычкырышам: «Әйдә, әйдә, Мансур!»

Кайсы җайдак исемедер — белмим,
Тик барыбер дәшәм өзелеп-өзелеп,
Җайдаккамы, әллә хыялгамы:
— Әйдә, Мансур! Әйдә, әйдә! — диеп.

Аптырашып тора ят агайлар
Алар белән бергә кычкырганга.
Күпме генә өзелеп сөрән салма,
Мин чакырган кеше юк шул анда.

— Әйдә, Мансур...— диеп, мин бит Аңа
Хыялымда гына дәшә алам...
Сабантуйда кычкырсаң да килешә —
Барыбер ишеттерми гөжле мәйдан.

# Илсөяр Иксанова

## Белми әле дөнья

Киткәнеңне белми әле дөнья.
Яңгыр-карлар яуды, җан янды...
Пыран-заран килеп, эчке дөнья
Тышкы дөнья белән ялганды.

Тышкы дөнья сиңа якын иде,
Әрнүләрем йоттым эчемә.
Мин әлегә түзәм...
Тышкы дөнья
Үзгәрмәде шуның өчен дә.

Киткәнеңне белми әле дөнья.
Миңа авыр, миңа...
Син киткәч.
Дөнья гына тетрәнмәсә иде,
Синең китүеңне ишеткәч...

## Көндәшемә

Кара көндәш түгел,
Ак көндәшем,—
Син җирдәшем минем,
ил-көндәшем.
Синең белән танышканнан бирле
Күктән төштем...
Инде җирдә яшим.

Син көндәшем икән — сөюдәшем.
Йөрәктәшем минем, күңелдәшем.
«Аңла Аны, бәхетле ит», — диеп
Сиңа дәшми тагын кемгә дәшим?!
Икебез дә берүк моңны күргән,
Икебез дә: бу ул — җаным, дигән.

Кайсыбызның ярты җаныдыр ул,
Анысын кемнәр белгән...
Син өлгергән.

Бәхетеңнән синең мин көнләшмим,
Җанда сөю булсын, и көндәшем!
Мәхәббәтнең аның кодрәте киң —
Сөю җылытканга мин дә яшим.

Мәхәббәт ул җирнең бар төсендә,
Мең сыйфатлы, түгел ул бер генә —
Алма кебек кызлар туган синнән...
Миннән туды бары шигырь генә.

## Фаҗига

Төнге күлгә илтеп утлар салдым,
Утлар салдым төпсез упкынга...
Сулар яна,
Төнге сулар яна —
Икебез дә калдык тоткында...

Сулар яна,
Сызылып төннәр яна,
Тик барыбер инде таң атмас...

Җаннар яна,
Соңгы хисләр яна —
Башка беркем бездәй яратмас!

Упкыннарга төшеп утлар сүнәр,
Әй, болганыр сулар, болганыр.
Сулар янды...
Утлар суга калды...
Мәхәббәтнең соңы булгандыр...

*

Бу җәй үтәр, үтәр...
Шатлыкларның
Көзе җитәр — җанны телгәләп.
Мин әлегә ут тирәли очам,
Мин — әлегә ап-ак күбәләк.

Көзгә керсәм, канатларым көяр,
Бу җәйнең мин күрәм ахырын

Күбәләкнең гомерен озайтырлык,
Табылмаган әле, юк ырым.

Бер ырым тап,
Салма мине утка!
Азаккача янам, кабынсам.
Үзеңнең дә җаның пешәр, әрнер —
Утлы канат белән кагылсам...

## Мин

Бу яңгырлар көзге яңгыр төсле,
Җәй җылысы юк бу болытларда.
Яңгыр көтеп арыгач,
Боз яуганда
Җанын ачкан чәчәк булып кара!..

*Казан.*

# Фәйрүзә Мөслимова

## Ике фәлсәфә

Яшь кешенең фәлсәфәсе гаҗәп:
Бәхет эзләр офыклардан ары...
Сүзсез генә яшен коеп торыр
Бакча артындагы тупыллары.

Агачларга күзе төшәме соң?
Алда шатлык — тупыллардан олы!
Офыкларга китеп күмелгәч тә
Ишетелеп торыр дәртле җыры...

Карт кешенең фәлсәфәсе башка:
Туган якка юлы, туган якка.—
Моңаешып калган тупыллары
Ничә еллар буе шунда тарта.

Туган яктан күңел бизәме соң?
Җырлары да моңлы — сагынганга:
Мөлдерәшеп күз яшьләре тама,
Тупылларга хисләр кагылганда...

## Күбәләк

Бу дөньяның хозурлыгы
Акылыннан яздыра.
Аллы-гөлле чәчәкләре
Күзләрен чагылдыра...

Иксез-чиксез зәңгәрлеккә
Күтәрелергә теләп,
Чәчәк сыман канатларын
Җилпеп карый күбәләк.

Ни үкенеч: дөнья ямен
Тәрәзә чикләп тора.
Ватып кара, дигән сыман,
Аны үчекләп тора.

Килер әле кем дә булса —
Бер ачылыр тәрәзә.
Ул арада кояш байый,
Төнге күктә ай йөзә.

Алларында тәрәзә лә
Очам дигән мәлендә...
...Кайчагында үзебез дә
Шул күбәләк хәлендә.

## Җиде җил чатында

Җиде юл чатында...
Җиде җил чатында
Җил искән тарафтан
Ут-уклар атыла.

Җәяләр киереп
Җиде ук атканда
Җиде ят бер уйда:
— Һәлакәт — башкага!

Җил исә төрлечә —
Мәшрикътән, мәгъриптән...
Ут-уклар кемнәрне
Аударыр кинәттән?

Йөгерәм, өлгерәм
Җиде юл чатына!
Җиде ук сызгыра
Алдымда, артымда...

Минем җан кош булып
Күкләргә ашканда
Җиде як исән-сау!
...Һәлакәт — башкага...

## Янмый учак

Янмый учак, янмый учак,
Төтен генә бөркелә —
Әчесеннән күзләремне
Ачалмыйча интегәм.

Пыскый учак, пыскый учак.
Төтен исе чәчемдә.
Җил иссә дә ялкынланмый,
Көле генә чәчелә.

Тәтен әчеседәй, кисеп,
Тамагыма бәялә
Синең исем... Калдың ничек
Үткән утлы көннәрдә?

Учакларың исән микән?
Бардыр сиңа тиңнәр дә...

Синле көннәр сагыш булып
Баса минем иңнәргә.
Шатлык — парлы, сагыш — сыңар.
Учак янмый интегә.
Өмет тулы күңелемә
Тәтен генә бөркелә.

## Лена Садыйкова

### Сөлге чигәм

Хыялларым шушындадыр,
Кулымда җеп — бер калып.
Чигү чигәргә утырдым,
Айдан көмеш нур алып.
Чигүемә кучә бирде
Офыктагы кызыллык.
Инде изге теләкләрем —
Сөлгеләрем озынлык.

Өлге булды зәңгәр күкнең
Җете зәңгәрлеге дә.
Йөрәк сурәтен ясадым:
Ярату бу — чигүдә.
Ук та ясыйм микән әллә?
Ясыймчы — белсен күңел:
Мәхәббәттә тыныч кына
Яшәве мөмкин түгел!

### Хыял

Бу хәятның киң кырларын
Хушлык, дуслык сугарса,
Ил өстендә искән җилләр
Безгә гимн уйнаса,
Гарип-гораба, фәкыйрьгә
Шәфкать кояшы чыкса,
Явызлар шул юлдан язып
Яхшылыкка юлыкса,
Инсафлылар саф күңелдән
Кылса җиргә игелек,

Һәр җан иясе яшәсә
Игелектә иң элек,
Һәр кешегә гадәттән тыш
Хөррият килсә әгәр,
Тирән акыл, хисси йөрәк
Игезәктәй йөрсәләр...
Нинди булыр иде дөнья!
Тик, укучым, күзалла:
Көрәшсез юк җирдә тормыш,
Көрәшсез юк... хыял да.

### Ни булды минем йөрәккә?

Ни булды минем йөрәккә?
Табалмый җирдә урын:
Көне-төне яна ласа...
Янудан — шушы җырым...
Янам яз алкынлыгыннан,
Ал гөл ялкынлыгыннан...
Куырылам кырыс карашның
Кырау салкынлыгыннан
Янам мин гомер буена,
Уйларым — биеклектә:

Җирдә яшәсәм дә, йөрәк
Менәргә тели күккә:
Хыяллар тарта йөрәкне,
Тарта ымсындырып гел.
Бәлми: күк — яшен-күкрәүле,
Балкый — санаулы мизгел...
Их, йөрәк! Язмыш хөрлеген
Күккә менеп эзләмә.
Барлык чик-чылбырны Җирдә
Үзең уз, ват, өзгәлә!

*Ульяновск шәһәре.*

# Фирдәвес Бәширова

## Кошчык

Бу кошчыкка да бит хак-табигать
Биеклектә очу биргәндер.
Тик көмешен өләшкәндә, тормыш:
«Менә сиңа читлек!» дигәндер.

Бар дөньясы — нечкә чыбыклардан
Оста куллар үргән тар читлек.
Гүзәл кошчык... Нинди сыны... Тавышы!..
Моңлы җырын тыңлап аһ иттек.

Тормыш нечкәлеген белгән хуҗа
Аңа азрак ачкан ишеген.
Ләкин кошчык ташлап чыкмый икән
Аң сеңдергән шушы «бишег»ен.

Тик шулай да башын тыгып кына
Карап куя шикле тишектән...
Сукмас микән ирек яшен кебек,
Чыга калса ачык ишектән?!

*

Бер хәсрәтсез, бер болытсыз,
Урам киңлек елмаюы,—
Җиңел басып юләр килә,
Кайда икән тоткан юлы?

Йортлар аңа — бер ачусыз,
Кош-корт куя канат кагып.
Адәм заты кереп китә
Шарт-шорт итеп капка ябып.—

Нидән кача аңлы кеше?
Тоя мәллә бераз гаеп?
Акылсызлар көчле, бәлки,—
Куркытамы бераз — гарип?

Койма аша, тәрәз ачып
Әй күршеләр гәпләшәләр.
Акылсызны кирәк җиргә
Илттерергә сөйләшәләр.

Һәм мескеннең, көтмәгәндә,
Язмышкае хәл ителә...
Гел елмаеп, урам буйлап,
Бер гаепсез исәр килә.

## Офык

Кулны сузсаң өтәр төсле
Калкып килгән кояш-ялкын.
Минем туган авылымда
Офык шундый-шундый якын.

Атылып ла, ашыгып ла
Чыккан чакта авылымнан,
Ут йомгагы офык буйлап
Тәгәрәде әй артымнан.

«Кая киттең,— диде,— ташлап
Агыйделне, бу тауларны?
Сине сөеп, нурга төреп,
Зур үстергән бу таңнарны?

Үләннәрдән чык тәгәри,
Сулык-сулык һәрбер чишмә,
Кошлар төшкән зур шөбһәгә.
Ташлап китмә, читкә китмә...»

Киттем. Ачтым авылымның
Челтәрләнгән офыкларын
Һәм очраттым күкселләрен,
Яктыларын, тонықларын.

Табалмадым җанга сеңгән —
Кул җитәрдәй якыннарын...
Һаман тоям артта калган
Туп-кояшның ялкыннарын.

## Тетрәү

Ап-аяз көн. Тыныч сыман иде.
Тетрәп куйды бүген бар дөнья.
Мәңгелектәй иде бөтен нәрсә,
Кайдан килде, төште бәддога?

Табигатьнең әллә кузгалдымы
Йокымсырап яткан көчләре!
Әйтерсең лә көтмәгәндә генә
Дер селкенде җирнең күчәре.

Җимерелде таулар, таш диварлар,
Борылдылар сулар кирегә.
Аяп тормый һичбер җан иясен,
Дәһшәт белән күкләр илерә.

Мәхшәр купты җирдә, көтмәгәндә
Дөнья гүя кинәт исерде...
Бәддогамы төште күңелемә? —
Җаным бүген тетрәү кичерде.

*Казан.*

# Таңчулпан

❋

Мин бала имездем... Төшемдә.
Үчтеки-үчтеки уйнаттым.
Шул чакта, бүлдереп төшемне,
Бер «юньсез» сәбәпсез уятты...
Күз йомам,
Чакырам:
Кая син, сабыем — төштәге?
Күкрәктә сызлану,
Ирендә тозлы яшь —
Төш тәме.

❋

Казан урамында танып алам
Безнең яктан искән җилләрне.
Яңгыр шавы аша ишетелә
Туган якның йомшак сөйләме.

❋

Дәшмим сиңа.
Юк, ачудан түгел.
Гаҗизлектән, артык сөйгәннән.
Күңелемнең кылындагы һәр моң
Синең исем булып төйнәлгән.

❀

Син арып йокыга талгансың.
Кулларың сөялле.
Сизмисең. Үбәмен тын гына,
Сөйкемле сөягем...

❀

Мин ходайдан
Түземлелек сорыйм —
Бармас өчен
Синең алларыңа.
Кайтмас өчен кабат —
Сөю биреп, алдап
Мине тинтерәткән
Язларыма.

Мин ходайдан
Түземлелек сорыйм —
Сөю утым
Кабат кабызмаска.
...Син — бер түмгәк булган
Минем юлда.
Теләгем шул —
Кабат абынмаска!

## Лилия Бужурова,

кырым-татар шагыйрәсе

### Зарыгу

— Әйтче, доктор, аңлат миңа, зинһар,
Яшермичә генә җавап бир:
Йөрәк сызлый, чигәләрем кыса,
Нинди авыру миндә — каян чир?

— Каушамагыз... Куркыр сәбәп күрмим.
Талчыккансыз бугай, аргансыз.
Сез, мөгаен, соңгы вакытларда
Борчуларга бераз таргансыз.
Тыныч йокы һәм ял... Беләсез бит,
Дөньялары хәзер, һай, тыгыз.
Нервадан бу... Берәр ял йортына,
Йә көньякка барып кайтыгыз...
— Ах, сез хаклы, доктор! Хаклык үзе
Саркып тора сезнең сүзләрдән.
Ардым, доктор, ардым — күптән инде
Йокы качты минем күзләрдән.
Ардым, доктор... Ардым йөрәгемне
Мең йозакка бикләп яшәүдән,—
Үз телемдә балкып сөйләшмәүдән,
Үз телемдә сөеп дәшмәүдән.
Ардым, доктор... Ата-бабам чәче
Ят илләрдә килеш чаларды.
Ниләр кылыйм, туган җирләрендә
Җирләсеннәр өчен аларны?
Гайбәтләрдән, шикле карашлардан,
Ялалардан, үчтән, янаудан

Ардым, доктор... Илнең ертык җирен
Яңа ялган белән ямаудан.
Сукырлыктан дошман булганнарның
Куралмаудан куркам алласын.
Үз алламнан сорыйм: оныклары,
Берүк, безнең хәлгә калмасын...
Сез бик хаклы, доктор... Коньяк кирәк!
Шул як яши минем тәнемдә.
Ардым, доктор, ардым, без бит монда
Оҗмахтагы шайтан хәлендә.
Коньяк кирәк, доктор, коньяк кирәк!
Илем тарта — Кырым һавасы!
Бу — чир түгел... Җирсү, зарыгу бу,
Һәм юк аның бүтән дәвасы...

## Юк, мин шагыйрь түгел...

Юк, мин шагыйрь түгел, бар язганым —
Сыкрануы йөрәк кылымның,
Сызлануы халкым язмышының,
Зар елавы газиз Кырымның.

Туган туфрак — ана карыны кебек,
Ятим сагышында мин яшим...
Кара диңгез кибеп беткәндә дә
Кипмәс кебек, халкым, күз яшең.

Юк, мин шагыйрь түгел... Әмма сүзнең
Җанда йөртәм кискен, турысын:
Яралгыны ана карыныннан
Каерганның кулы корысын!

## Әйт син, әткәм...

— Кара күзләр миңа каян иңгән, әткәм?
— Кара диңгез тамчысыннан, балакаем.
— Ә ник синең күзләреңдә яшь тамчысы?
— Кара кайгы ачысыннан, балакаем.

— Кайда минем туган илем, туган йортым?
— Кара диңгез ярларында калды, бәбкәм.
— Әйт син, әткәм: нигә соң без чит җирләрдә?
— Туган илне ятлар тартып алды, бәбкәм...

Нияз АКМАЛ тәрҗемәләре.

## Тамара Ганиева,

башкорт шагыйрәсе

Истанбуллар искә сирәк төшә,
Тарта мәгәр Казан тарафлары:
Ул якларда, якын кардәш санап,
Сагыналар микән башкортларны?

Уйлана да күңел өметләнә...
Кай дуамал кора безгә мәкер?
Кан аралаш тәгам бүлеш тә син,
Ташлап китсен шуннан аек хәтер.

Тәрҗемәсез лөгать, охшаш гадәт,
Уртак шатлык белән уртак зарлар.
Араларда бары чакырым юллар,
Нух чорында яуган корым-карлар...

Аерылып та, кавышып та булмый,
Кодрәтлеме гөнаһ шомлыклары?!
Гыйбрәтле бер драма-трагедия
Башкорт белән татар язмышлары!..

*Уфа.*

## Качаклар

Әй, сабыйлар, эчем өзелә лә,—
Миша, Армен, Артур, Нәргизә! —
Бармы сезгә бирәр сыеныр урын
Совет иле дигән зур җирдә?!

Йорт-курасы яна качакларның,
Җәһәннәмнәр кебек тәкъдирләр.
Ничә ятим, ничә тол калганны
Кай төбәккә юллар илтерләр?!

Бүлешегез, диеп алма сондым,
Дүртегезгә җитте бер алмам.
Дүрт телдәге сезнең рәхмәтләрдән
Яшьләнә бит минем күз алмам...

Җиңелрәк мәллә хаким булу,
Таркалганда рухи бөтенлек?..
Йөрәк бирсен сезгә өлкәннәрне —
Гаепләне гафу итерлек...

*Мәскәү — Малеевка.*

## ӘДӘБИ МИРАС

# АВЫР ЯЗМЫШ




Шәхес культы хөкем сөргән елларда репрессиягә дучар булган күренекле язучыларыбызның аклануы, аларның озак еллар буена тыелып торган гүзәл әсәрләренең гамәлгә керүе әдәбиятыбызны күпкә баетты, кыйммәтле мәдәни хәзинәбезне киң халык массаларына җиткерергә мөмкинлек ачты.

Татар әдипләре арасыннан бу аяусыз әзәрлекләүгә башлап эләгүчеләрнең берсе «Дим буенда» повесте, күп санлы лирик һәм юмористик хикәяләр, публицистик мәкаләләр авторы Садри Җәләл булды. Ул Казан педагогия институты каршындагы рабфакта татар теле һәм әдәбияты укытучысы булып эшләгәндә 1931 елны кулга алына, 1932 елның 11 маенда ирektән мәхрүм ителеп, Ак диңгез-Балтик каналы төзелешенә сөргенгә җибәрелә.

Бу — гаять авыр, йончыткыч каторга хезмәте була. Адәм түзә алмаслык суык баракларда ачлы-туклы яшәүче меңләгән тоткыннарга, җәен-кышын булсын, сазлыкларда көрәк белән җир казырга туры килә. Бик күпләре ачлыктан һәм төрле авырулардан кырыла, гомерлек инвалидка әверелә. Әнә шундый шартларда сәламәтлеге тәмам какшаган, күзләре начар күрә башлаган кырык дүрт яшьлек Садри Җәләл 1935 елны Казанга гаиләсе янына кайтып төшә.

Тормышның авыр чагы, һәркайда мохтаҗлык. Гаилә тәрбиясендә бераз көч-хәл алгач, ул сукырлар остаханәсенә эшкә урнаша, аннары больницага массажчы булып керә.

Әмма Садри Җәләлгә ирektә озак яшәргә ирек бирмиләр. Илдә репрессияләр дулкыны кабат көчәя башлау белән, 1937 елда ул, тагын кулга алынып, Казандагы Пләтән төрмәсенә ябыла. Сәламәтлеге начарлану сәбәпле, тиздән аны төрмә больницасына салалар. Биредә ул нәкъ шул чакны Ялтадан кайтарылып, шушы төрмәгә ябылган әдип Галимҗан Ибраһимов белән очраша.

Бу, әлбәттә, аларның беренче очрашуы булмый. «Аң» журналында эшләгән вакытта ук әле Г. Ибраһимов Учительская школа шәкерте С. Җәләлне әдәбият мәйданында күренә башлау белән (1913—1914 еллар) игътибарга ала, аның «Дим буенда» повестен басарга кабул итә. Ул аны моннан соң да күздән югалтмый, вульгар социологлар һәм «күсәкле» тәнкыйтьчеләрнең урынсыз гаепләвеннән яклап чыга.

Шуңа күрә байтак еллардан соң төрмә больницасындагы бу көтелмәгән очрашу аларның икесе өчен дә дулкынландыргыч вакыйга була. С. Җәләлнең хатыны — якшәмбе көннәрне төрмә больницасына авыру иренең хәлен белергә йөрүче Хөснури ханым Булатова әйтүенә караганда, алар анда бер-ике мәртәбә икәүдән-икәү генә сөйләшә алганнар, илдә хөкем сөргән террордан туган уй-фикерләре, авыр кичерешләре белән уртаклашканнар. С. Җәләл ярдәмчел остазының бума ютәлдән интегүен, көннән-көн сүнә баруын күреп тора, аның газаплы вафатын авыр кичерә.

Хәер, бу вакытта инде С. Җәләл үзе дә каты авыру була, хастасы көчәйгәннән-көчәя бара. 1939 елны саулыгы инде бөтенләй какшаган, күзләре сукырайган хәлдә аны төрмә машинасында фатирына, хатыны белән кызы янына кайтарып куялар. Ул 1943 елның 29 июлендә вафат була.

Садри Җәләлнең (Вәлидов Садрислам Хәйретдин улының) тормыш юлын күздән кичергәндә, барыннан да элек, аның «Инде мин аңа рәнҗемим» исемле хикәясе хәтер-

---

Рәсемдә: *Садри Җәләл кызы Айсылу белән (1927 ел).*

гә килә. Әдипнең биографиясе дә шул хикәя герое Әсгать язмышына охшаган булуын күрәсең. Садрисламның этисе — элекке Тәтеш өязе, Апас авылы мулласы Хәйретдин хәзрәт — улын башта үзе укыта, киләчәктә аны мулла итәргә өметләнә. Шәригать кануннарын кечкенәдән белеп үссен дип, ул мәхәллә кешеләре чакырган ифтар (уразада авыз ачу) мәҗлесләренә үзе белән бергә малаен да алып бара торган була.

Улы бераз үсә төшкәч, Хәйретдин мулла аны Казанның иң иске карашлы Мөбарәкҗан хәзрәт мәдрәсәсенә укырга кертә.

Әмма һәр нәрсәнең асылын аңларга омтылучан, төпченүчән Садрислам бу мәдрәсәгә кереп уңмавын: монда дөньяви белем бирү юклыгын, бөтен укуның постулатларга сукырларча ышанудан гыйбарәт икәнлеген бик тиз күреп ала һәм, шул хакта зарланып, Ставропольдә яшәүче туганнан туган агасы Җамал Вәлидигә хат яза. Һәм шуның ярдәме белән тиздән ул алдынгы уку йортларыннан саналган Буби мәдрәсәсенә күчеп укый. Мәдрәсәне тәмамлап туган авылына кайткач та, үзлегеннән белемен күтәрүен, рус телен өйрәнүен дәвам иттерә. Г. Тукай, Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимов әсәрләрен, рус һәм дөнья классикларын күп укый.

Үзсүзле кадимче Хәйретдин мулла исә катгый рәвештә моңа каршы чыга, улының китап һәм дәреслекләрен җыеп алып, утлы учакка ташлый. Ике арада каты ызгыш күтәрелә. Ахыр чиктә Садрислам, югарыда телгә алынган хикәя герое кебек, кышкы салкын төндә туган авылыннан чыгып китәргә мәҗбүр була.

Идел буе, Кырым шәһәрләрендә төрле сезонлы эшләрдә нужа чигеп йөргәннән соң, ул 1911 елның көзендә Казанга кайтып, татар мәдрәсәләрендә рус теле укытучылары әзерли торган мәктәпкә укырга керә.

Башта бу мәктәп патша самодержавиесенең мөселман халыкларын урыслаштыру политикасын гамәлгә ашыручы укытучылар әзерләү максаты белән ачылган булса да, чынлыкта миссионерлар көткәнгә капма-каршы нәтиҗә бирә: анда укучылар арасыннан Х. Ямашев, Г. Коләхмәтов, Г. Сәйфетдинов, И. Кудашев-Ашкадарский кебек күренекле революционерлар, әдәбият, сәнгать эшлеклеләре үсеп чыга. С. Җәләл үзе бу мәктәп турында: «...Казан учительская школасы шикелле караңгылыкның оясы булган бер мәктәптә укыган чорда... бу мәктәптә чын мәгънәсе белән жандарм режимы хөкем сөрә иде»,— дип искә ала.

Тик шуңа да карамастан, иҗтимагый һәм милли азатлык идеяләре биредә елданел көчәя бара, алдынгы укучылар надзирательләрдән яшеренеп, прогрессив әдипләрнең әсәрләрен укыйлар, үзләре дә шигырь, хикәяләр язалар, музыка, театр сәнгатенә багышланган мәкаләләр белән газета-журналларда катнашалар.

С. Җәләлнең шунда язган тәүге әдәби әсәрләре дә яшь буынны гуманистик рухта тәрбияләү идеаллары белән сугарылган. Бу җәһәттән аның 1914 елны «Ак юл» журналында басылган «Иреккә» хикәясе аеруча характерлы. Әсәрнең герое — читекчедә өйрәнчек асрау малай Заһит — урамда куәл ачып йөрүләрдән мәхрүм, бүтән балаларның уйнаганын тәрәзәдән күреп, үзен тоткын кебек бәхетсез хис итә, җәберсенә. Шәһәргә чыккан бер көнне ул урамда кош сатучы карт белән очраша. Аның зур читлегендә чыр-чу килгән кошлар арасында бер читтә бөрешеп кенә торган нәүмиз песнәкне күреп, аны үзе кебек чарасыз, ярдәмгә мохтаҗ итеп тоя һәм шундук барлы-юклы ун тиенено мескен кошчыкны сатып алып, тоткынлыктан коткара, аны ирекка чыгарудан үзенә юаныч таба.

Шул ук 1914 елны «Аң» журналында С. Җәләлнең «Дим буенда» повесте басыла, тиздән әсәр «Гасыр» нәшриятында аерым китап булып та дөнья күрә.

Повесть Казан ханлыгы тар-мар ителгәннән соң башкорт җирләренә күчеп киткән, дворянлык өстенлекләрен югалтмас өчен рус патшасына хезмәт итүче татар морзалары тормышыннан алып язылган. Заманында күп төрле бәхәс, каршылыклы фикерләр кузгаткан бу әсәрне укыганда, табигый ки, автор аны нинди материалга таянып язган дигән сорау туулы мөмкин. Әдипнең хатыны Хөснури ханым сүзләренә караганда, С. Җәләл Учительская школада укыганда бер сабакташы — инде бөлгенлеккә төшкән «чабаталы морза» улы белән якын таныш булган, берничә тапкыр җәйге каникулын аларның Дим елгасы буендагы утарында үткәргән.

Югарыда әйтелгәннәрдән күрәбез: повестьта авторга шактый ерак, чагыштырмача аз таныш мохит тасвирлана. Шунлыктан булса кирәк, геройларны хәрәкәттә, бәрелешләрдә күрсәтүдән бигрәк, әсәр, башлыча, «кешеләрнең эчке кичерешләрен, рухи дөньяларын ачуга нигезләп язылган...» (М. Әмир. «Хатирәләр урманы», 162 б.)

Һәрхәлдә, ничек кенә булмасын, кыска гына вакыт эчендә повесть киң популярлашып китә, геройларының аянычлы язмышы, уй-хисләренең тәэсирлелеге белән күпләрне җәлеп итә. Әсәр М. Илдар тарафыннан сәхнәләштереп, 1925—26 елгы сезонда Татар дәүләт театрында уйнала; бу әсәр мотивлары буенча опера да языла (композитор Х. Вәлиуллин музыкасы, драматург Х. Вахит либреттосы).

«Дим буенда» повесте — С. Җәләлнең бердәнбер зур күләмле әсәре, дип әйтергә мөмкин. Моннан соң ул революция һәм Совет властеның беренче елларындагы тиз үзгәрүчән тормышта, иҗтимагый хәрәкәттә актив катнашырга мөмкинлек бирә торган оператив, сугышчан жанр — кыска әсәрләргә күчә һәм күләме зур булмаган хикәяләр, лирик нәсерләр, нечкә юмористик һәм сатирик новеллалар авторы буларак киң таныла.

Әдипнең бу төр әсәрләреннән Г. Тукайга багышлап язылган «Аның сөекле углы» дигән бик тә үзенчәлекле лирик нәсеренә тукталасы килә. Биредә «Аның» алмашлыгы күп гасырлар җәберләнгән туган халык мәгънәсендә алынган булса, ә шагыйрь шуның күтәп алган сөекле улы, авыр язмышын кайгыртучы, моң-зарларын, изге хыялларын җырлаучы итеп сурәтләнә, эмоциональ тәэсирлелеге белән укучы күңелендә тирән уйлар уята.

Яшь Совет властеның язмышы кыл өстендә торган, Колчак гаскәрләренә каршы каты сугышлар Татарстан җирендә барган авыр көннәрдә С. Җәләл азатлык даулаучы кызыл сугышчыларны изге көрәшкә рухландыргыч хикәяләр, очерклар яза. «Кызыл Армия» газетасының 1919 елгы 16—18 июль саннарында басылган «Кадерле кунаклар» хикәясендә күптән түгел генә аклар отряды бөлдереп киткән авылга фронтка баручы бер рота кызыл сугышчылар килеп керә. Авыл халкы аларны үз күреп, талаучылардан яклаучы итеп каршылый. Төркем-төркем бүленеп төн кунарга туктаган йортларда хуҗалар аларны хәзинәләрендә булган аш-сулары белән сыйлыйлар. Бу вакыйга үзенә бер бәйрәмгә әверелә. Исерек акгвардиячеләрдән нәүрәпләргә яшеренергә мәҗбүр булган кыз-кыркын, ак армиягә алынудан урманда качып яткан яшүсмер егетләр кичен урамда кызылармеецлар белән бергәләшеп күңел ачалар.

Садри Җәләлнең күпчелек хикәяләренә тормыш вакыйгаларын юмор, сатира элементлары белән сугарып сурәтләү, кинаяле көлеп, тыштан ялтыравык тискәре күренешләрнең черек асылын, зур эш майтарган булып шапырынып йөрүче коры куыкларның эчке мәгънәсезлеген фаш итү хас. Илдә Октябрь революциясе җиңгән көннәрне, мәсәлән, бер мәзәк вакыйга була: бер төркем җете кызыл әһелләр халыкны шәһәр мәйданына җыеп, «Тәтеш социалистик республикасы» игълан итәләр. С. Җәләл «Министрда кунакта» исемле хикәясендә шул «респубика» министрының урман, басу, сукмак-юллары, коры елга, ерганак күпер-басмалары белән идарә иткән булып йөргәндә түзга язмаган, мәгънәсез фәрман, күрсәтмәләр биреп, авыл халкы алдында хурлыкка калуын күрсәтә. Кайчандыр С. Җәләл күреп алган андый типлар хәзер дә исән-сау яшиләр: илне бөлгенлеккә төшерүче булдыксыз түрәләр, номенклатуралы бюрократлар — әнә шундый «министрлар»ның уллары, оныклары бит...

Авторның «Даррәхәт мөселманнары», «Атып калганчы, ятып кал», «Ахыры заман хикәясе», «Барысы да советски» хикәяләре дә безнең көннәрдә бик актуаль яңгырыйлар, искелек белән яңалык көрәшен дөрес аңларга, тыштан ялтыравык коры куыкларның мәгънәсез асылын күрә белергә ярдәм итә.

Үз әсәрләрен язу белән беррәттән, С. Җәләл рус һәм дөнья классикларын да тәрҗемә итә. М. Горькийның «Мальва», «Макар Чудра» хикәяләрен, Д. Фурмановның «Кызыл десант» повестен, М. Сибиряк, Мультатули әсәрләрен татар халкы аның тәрҗемәсендә укый. Ф. Шиллерның дөньякүләм атаклы «Вильгельм Телль» драмасы татар телендә беренче мәртәбә С. Җәләл тәрҗемәсендә китап булып басылды (1920), Татар дәүләт драма театрында куелды (1926).

Билгеле ки, татар зыялыларының бер өлешенә революция барышында туган катлаулы процессларда, сыйнфый бәрелешләрдә дөрес юл сайлау, әлбәттә, җиңел булмый. С. Җәләл бу чирдән тиз арада катгый рәвештә арынып, үзенең иҗаты һәм көндәлек практик эше белән туган халкына хезмәт итә. Казаннан акгвардиячеләр һәм фетнәче чехлар куылганнан соң, ул губерна мәгариф бүлегендә мәктәпкәчә тәрбия инструкторы булып эшли, Арча кантонында укытучылар әзерләү курсларында җитәкчелек итә, Татрабфакта һәм Сәнгать техникумында татар теле һәм әдәбияты укыта. Төрле елларны «Безнең юл» (хәзерге «Казан утлары»), «Чаян» журналларында җаваплы секретарь булып эшли, эшче-крестьян арасыннан килгән яшь әдәби көчләрне иҗади үстерүгә күп көч куя.

Шул ук вакытта ул вакытлы матбугат битләрендә җәмәгатьчелекне дулкынландырган мөһим проблемаларга, яңа китапларга, спектакльләргә багышланган рецензияләр, публицистик мәкаләләр белән катнаша. Әдәби әсәрләре кебек үк, аның публицистикасы, тәнкыйть мәкаләләре,— һәм авторның тулаем үз язмышы да,— деспотизм елларында халкыбыз кичергән коточкыч бәла-казаларны күрә белергә өйрәтә, андый фаҗига киләчәктә бүтән кабатланмасын өчен барыбызга да гыйбрәтле кисәтү булып яңгырый.

**Сафа САБИРОВ**

Садри Җәләл

# ДИМ БУЕНДА

## Автордан

«Дим буенда» дигән хикәяне икенче тапкыр бастырганда кайбер сүзләр әйтеп китәргә кирәк кебек тоела.

Беренчедән, бу хикәя минем тарафымнан мәктәп эскәмиясендә вакытында ук язылган бер нәрсә; мәктәпнең дә, Казан Учительски школасы шикелле, каралыкның бер оясы булган бер мәктәптә.

Мин укыган чорларда, ягъни 1911—1915 нче елларны, бу мәктәптә чын мәгънәсе белән жандарм режимы хөкем сөрә иде. Бу мәктәптә чагында без һичбер сәяси тәрбия алмау белән бергә, бу якны бүтән юллар белән дә тутыра алмый идек. Чөнки гәзит-журналлар уку, бигрәк тә татар әдәбияты белән шөгыльләнү безгә бөтенләй мөмкин түгел иде. Бу юлдагы кысынкылыкны ачып күрсәтү өчен, Хәсән Гата казыйның «Татар тарихы» дигән китабын укыган өчен генә дә бер укучының мәктәптән куылу вакыйгасын күрсәтү җитсә кирәк.

Бишенче елларны школьникның татар революция хәрәкәтендә шактый гына зур роль уйнаганлыгын игътибарга алып булса кирәк, мәктәп идарәсе безнең заманда школьникларны җәмәгать эшләренә катнаштырмас өчен кулыннан килгән бөтен чараларны күрә, хәтта аларга татар көтепханәсе белән татар театрына йөрергә дә рөхсәт итми иде.

Менә шуның кебек бик күп сәбәпләр аркасында, әлбәттә, безнең сәяси аңыбыз әйтеп тә бетергесез түбән иде. Дүрт ел буенча Илувайскийның «Русия тарихын» чәйнәгән, тәүлекнең иң зур өлешен ябык кына түгел, чын мәгънәсе белән бикле, йозаклы пансионда, жандармнар урынында торырлык надзирательләрнең көне-төне өзлексез тикшерүләре астында арестантлар урынында яшәгән школьниклар болай самообразование белән дә үзләренең сәяси белемнәрен тәгаллли алмыйлар иде. Бу эш белән шөгыльләнү бөтенләй мөмкин түгел иде.

Менә бу алдыгыздагы хикәя шундый бер мәктәптә, шундый бер мохит эчендә тәрбияләнеп ята торган бер укучы тарафыннан кача-поса язылган бер нәрсә. Хәзерге көндә бик тә табигый буларак, мин бу хикәямдә пролетариат идеологиясенә чит булган һәм әдәби яктан да шактый ук төчесентименталь тоелган урыннары байтак булуын сизенсәм дә, бу юлы басылуында хикәямдәге бернәрсәне дә үзгәртмәдем.

Икенчедән, бу хикәя «Аң»да һәм аерым китап булып басылганда, мин аның корректурасын үзем карый алмадым. Нәширләр исә, нәрсәгә таянгандыр, аны «роман» дип бастырганнар. Мин үзем аны «хикәя» дип кенә язган идем һәм хәзер дә шулай «хикәя» дип бастырам.

**С. ҖӘЛӘЛ**

*Казан, 3 нче март, 1929.*

---

Садри ҖӘЛӘЛ *(1891—1943) — әдип, журналист, тәрҗемәче, җәмәгать эшлеклесе, тугыз проза китабы авторы. «Дим буенда» повесте язучының йөз еллыгы уңаеннан (хәзерге әлифбада — беренче мәртәбә) басыла.*

## I



Әнә күрәсезме, кояшның җылы нурлары астында ялтырый-ялтырый Дим ага.

Әнә аның кырыенда чиксез киң болынлык, аннан ерак та түгел, таллык.

Әнә еракта тау кашлары беленер-беленмәс кенә булып сузыла; зәңгәрсу һава аша аның өстендәге кара урман төтенләнеп күренә. Якты суның өстендә вәкарь белән генә аккошлар йөзеп йөри; болынлыкта төрле кошлар сайрый; ара-тирә акчарлакларның ачы тавыш белән кычкырганнары ишетелеп китә; күк йөзендә карчыга дигән усал кошның җентекләп җирдән үзенә җим карап барганы күренә.

Монда һәр нәрсәдән иркенлек, бәхет аңкый. Бу киң болыннарга карау белән күңелгә: «Мондый матурлык, мондый байлык эчендә адәмнең бәхетсез булуы мөмкин түгелдер», дигән уй килә.

Әнә тагын еракта, Дим буена утырган ике мәчетле зур гына авыл. Якынрак барып карасаң, аның бер читендә урман шикелле куе бер бакчалык күренә. Бакча бик күптән утыртылган булса кирәк: андагы агачлар инде тәмам картайганнар. Бакчага карау белән аңар инде күптәннән бирле адәм кулы орынмаганын белергә була. Аның койрыгы Дим буена барып терәлә. Икенче башындагы агачлар арасыннан аслы-өсле зур гына агач өйнең ташландык хәрабәсе күренә. Аның манзарасы гаять күңелсез: тәрәзәләр такта белән томаланган, түбәсендәге калайлар, буяулары күптән уңып, яңгырдан күгәренеп, самавыр морҗасы төсле, челтәр-челтәр булып беткәннәр. Баскычлар янтайган, морҗаларга чәүкәләр, тәрәзә башларына да күгәрченнәр оялаганнар.

Ишек алдына, йөрүче булмаганга, ямь-яшел чирәм үскән; бөтен җир буш, бөтен нәрсә тын гына нәрсәдер көтә...

Төннәрдә монда бигрәк тә тын була, тик ара-тирә шомлы кош мәче башлы ябалакның ачы тавышы белән кычкыргалаганы гына ишетелә.

Әбиләр кышкы озын төннәрдә, орчыкларын эрле-эрле, яннарына түгәрәкләнеп утырган балаларга ул хәрабә турында әллә нинди куркынычлы әкиятләр сөйлиләр. Картлар исә аның яныннан узганда тирән уйга чумган бакчага бер карап алалар да мәгънәле генә итеп: «Бичара мирзаның балаларына бу нигездә рәхәт күрергә язмаган икән инде,— диләр. Тагы шуның артыннан ук: — «Мал да бар иде, дәүләт тә. Булмаса булмый икән инде»,— диләр.

Гомумән алар бу нигезгә бер тәгъзыйм[1] белән карыйлар һәм яшьләрдә дә шул тойгыны уяндырырга телиләр булырга кирәк: урыны чыкканда, ул нигезнең әүвәлге хуҗаларының тормышлары, аларның иткән яхшылыклары, башларыннан үткән вакыйгалары турында бик озын иттереп сөйләргә яраталар; шундый бер гаиләнең болай эзсезнисез юк булуына алар күп вакыт аптырыйлар. Аның сәбәпләрен төрлечә тикшерә башлыйлар һәм актыгыннан тагы мәгънәле генә итеп: «Булмаса булмый икән инде ул»,— диләр.

## II

Картларның сүзе буенча, элек, унтугызынчы гасырның ахырларында, бу хәрабә Исхак мирза гаиләсенең кайнап торган оясы булган.

Мирза үзе дәүләтле, фәкыйрьләр өчен һимматле,[2] бөтенесе белән тәмле телле, йомшак сүзле, икмәк-тозга юмарт, гыйлем һәм дәрәҗә иясе бер кеше булган. Аның ике улы һәм бердәнбер кызы булган. Улының олысы Рөстәм, кечесе Касыйм, кызы Кәримә исемле булганнар.

---

[1] Тәгъзыйм — олылау.
[2] Һимматле — ярдәмчел.

Мирзаның бикәсе Зөләйха абыстай уртача гына тәрбия күргән гади генә бер хатын була. Ул балаларын бик тә ярата, алар өчен җанын да кызганмый һәм барысын да иң әүвәл үзе тәрбияләп үстерә.

Шул килеш боларның тормышлары тыныч кына уза. Шул елларда гына Исхак мирзаның үзе белән бергә укыган дусты Шаһингәрәй мирза үлә. Аның бердәнбер кызы Фәридә дә һичбер тәрбиячесез-нисез ятим кала. Анасы инде аның күптән, ул бала чагында ук үлгән була. Исхак мирза, мәрхүм Шаһингәрәй мирза белән үзе арасында булган дуслыкны искә алып: «Үзебезнең Кәримә белән бергә үсәр, аңар иптәш булыр, Зөләйха абыстасыннан тормышка өйрәнер, шунда безнең балалар белән бергә укыр да», дип сигез яшьлек Фәридәне үз өенә тәрбиягә ала.

Менә шул вакыттан алып кара кашлы, кара күзле, әзһәр[1] йөзле, аз сүзле, мөлаем табигатьле Фәридә Исхак мирза гаиләсендә яши, аның балалары белән бергә Уфадан китерелгән урыс кызы мөгаллимәдән укый, Зөләйха абыстайдан төрле догалар, намаз тиреләрен өйрәнә. Җәйге аяз көннәрдә бакчада алар белән бергә уйный башлый. Үзе шикелле йомшак табигатьле Кәримә аңар бигрәк тә ошап китә. Ул аның белән чын күңелдән дуслаша. Чәчрәп чыккан матур, чиксез җитез, үткен Касыймны ул никтер бигүк яратып җиткерми. Киң маңгайлы, саргылт чәчле, соры күзле Рөстәм исә үзенең тынычлыгы һәм һәрвакыт җитдилеге белән аңарда әллә нинди бер олылау хисе уяндыра: ул аны абзасы иттереп таный.

Ул вакытларда Рөстәм унике, Касыйм тугыз, Кәримә җиде яшьләр тирәсендә була.

Шул килеш берничә еллар узып китә — мирзаның балалары уйныйлар, укыйлар һәм көннән-көн үсә баралар. Мөгаллимә Лиза ханым рояльдә уйнарга яхшы гына оста була. Ул Кәримә белән Фәридәгә музыкадан да дәрес бирә башлый. Кәримә музыкадан бик ул кадәр ләззәт ала аламаса да, Фәридә бөтен көче белән аңарга бирелә. Кышкы озын төннәрдә күнегүләрне тәкрар[2] итеп утыру да аңарда бетмәс-төкәнмәс нечкә хисләр уяндыра. Исхак мирзаның гаиләсе аңар никадәр йомшак караса да, ул үзенең монда чит кеше икәнен белә, җанында яңа гына тишелеп килә торган музыкага мәхәббәт аңар һәм ана мәхәббәте урынына тора. Ул бетмәс-төкәнмәс музыка бүлекләреннән үлгән анасының бишек янында көйләгән моңлы тавышын ишеткән төсле була. Шулай итә-итә ул көннән-көн җаны-тәне белән музыкага бирелә бара; рояль аңа дөньяда иң якын кешесе булып күренә. Шундый вакытлар була: ул уйный-уйный да ирексез үксеп-үксеп еларга тотына. Шул арада ишек ачылып залга әкрен генә Кәримә килеп керә. Ул Фәридәнең елаганын күреп, уйлап-нитеп тормый, аны бик каты кочаклап үзе дә еларга тотына. Бу вакыт Фәридә аңар бик кызганыч, чиксез кызганыч тоела; ул аны юатыр өчен каршында газиз булган бөтен нәрсәсен бирерлек була.

## III

Дим җәй көннәрендә кояшның нурлары астында көлә-көлә яшел үләннәр, төрле чәчәкләр белән томаланган болыннарны ерып, кичләрен ай яктысында җем-җем итеп ялтырап ага да ага.

Кыш көннәре ул тип-тигез булып ката. Җәй көннәре аның өстендә Исхак мирзаның балалары көймәдә йөриләр, күңел ачалар. Кызарынып кояш батканда тал арасыннан гына балык тоталар. Ә көз көннәрендә яңа гына каткан боз өстендә берсен-берсе куа-куа тимераякта йөриләр. Су алырга һәм кер чайкарга килгән яшь киленнәр дә аларга кызыгып, кинәнеп карап торалар.

---

[1] Әзһәр — ак, матур.

[2] Тәкрар итү — кабатлау.

Еллар берсе артыннан берсе тигез генә уза — Рөстәм инде унбиш, Касыйм да уникегә чыга. Исхак мирза инде аларны нинди дә булса бирәр хөкүмәт мәктәбенә биреп укытырга һәм шул килеш алардан ватанга файдалы кешеләр җитештерергә уйлый. Озак уйлашкан, дусиш белән киңәшкәннән соң, ул Рөстәмне: «Бу эфисәрлекне бигүк яратып җиткермәс, азрак йомшаграк», дип Казан гимназиясенә, Касыймны, үткен һәм җитез булганга: «Бусыннан бар да булыр, ходай кушса», дип Оренбург кадетски корпусына бирергә була. Көз җитүгә ул, Рөстәм белән Касыймны алып, иң әүвәл Казанга бара. Анда Рөстәмне кабул имтиханыннан соң гимназиянең бишенче сыйныфына ләйли шәкерт[1] итеп кабул итәләр. Карт мирза аерылганда аңар үзенең калтырана төшкән тавышы белән:

— Ярый, улым, сау бул. Тырышып укы, бабаларыңның кем булганын онытма. Алар шикелле илгә файдалы кеше булырга тырыш, аларның мактаулы исемнәренә кара китерерлек булма. Минем синдә өметем зур,— ди.

Шуннан соң ул Касыйм белән Оренбурга китә.

Башта Рөстәмгә гимназиядә чит кешеләр арасында бик уңайсыз була. Ул кич белән, башка иптәшләре йоклаганда, күз алдына матур Дим буен, андагы үзләренең өйләрен, Зөләйха абыстайны китерә. Аның бер генә минутка булса да өйдә буласы, аналары белән бергә җыелышып иртәнге чәйне эчәсе, тәрәзәдән Дим өстендә күтәрелгән болыт шикелле томанга карыйсы килә. Ләкин инде аларның берсе дә мөмкин түгел, алар инде ерак...

Көннәр узган саен ул мәктәпкә ияләшә, дәресләрне яратып укый башлый, һәм озак та үтми, гимназиянең юаш әхлаклы, истигъдатлы[2] шәкертләреннән исәпләнә; ул һаман да өйдәгеләрне ара-тирә сагынып ала, ләкин бу турыда иптәшләренә сөйләргә яратмый. Хәер, аның иптәшләре арасында бигүк якын дусты булмый да. Ул үз галәмендә, үзенең кадерле уйлары белән ялгыз гына яши һәм бөтен нәрсәсен эчендә генә сакларга телә. Иптәшләре дә аны ни өчендер ара-тирә: «Даладан килгән Чыңгыз баласы», дип атыйлар. Рөстәм исә аның өчен аларга ачуланып-нитеп тормый.

## IV

Рөстәмнәр укырга киткәннән соң Исхак мирзаның өе, нәрсә дә булса югалткан шикелле, тын, күңелсез кала. Зөләйха абыстай улларын икесен дә өзелеп сагына, кичләрдә намаздан соң озын иттереп аллә нинди догалар укый, алладан сөекле балаларына тәүфикъ, бәхет, хәерле гомерләр, зур дәрәҗәләр тели, кергән хәерчеләргә дә:

— Менә бусы Рөстәм пае, менә бусы Касыйм пае,— ди-ди күп-күп иттереп тәмле ашамлыклар бирә. Рөстәмнәрдән берничә атналап хат килми торган чакларда ул бигрәк тә тынычсызлана, көненә әллә ничә мәртәбә картына:

— Әллә булмаса, үзең барып кайтасыңмы? Дөньяның эшен белер хәл юк, әллә ниләр булып куяр...— ди.

Исхак мирза исә аңар борын эченнән генә нәрсәдер җавап бирә дә, юан бармаклары белән тәрәзәгә барабан каккандагы шикелле итеп бәрергә тотына, улларыннан хат килмәве аны ул чаклы борчымый. Зөләйха абыстай да аңар карап эченнән мәгънәле генә итеп «Ирләргә ни аларга», ди.

Кәримә белән Фәридә дә киткәннәрне сагыналар. Фәридә алар киткән көнне, атасы үлгән чагындагы шикелле, уңайсызлык, күңелендә

---

[1] Ләйли шәкерт — кичке сыйныфта укучы шәкерт.

[2] Истигъдатлы — сәләтле, булдыклы.

эллә нинди бер авырлык хис итә. «Индедән соң янибызда аз сүзле, акыллы күзле, һәрвакыт йомшак мөгамәләле Рөстәм абый булмый бит», дигән уй аңар никтер авыр тоела. Шуның артыннан ук аның күз алдына Рөстәмнең яхшы яклары, аның һәрвакыт Фәридәне туганы шикелле күрүе, Касыймнан аны җәберләттермәүләре, бер-бер тәмле нәрсәсе булса, аны авызыннан өзеп, үзе белән Кәримәгә бүлеп бирүләре, аның кайчагында бакчада ямьсезрәк тавыш белән борын эченнән генә эллә нинди бер моңлы көйне шыңшый-шыңшый уйланып йөргәннәре килә. Ул тирән генә сулый да: «Инде Рөстәм абый юк, ул эллә кая еракта», ди. Көннәр узган саен ерактагы Рөстәм аңа якын, кардәш, туган абзасы төсле тоела. Ул күп вакыт төшендә эллә нинди бер чит урманның зур агачлары арасыннан атлап бара торган Рөстәмне күрә. Ул никтер ябыккан була. Ул башын түбән иеп үзе бара, үзе борын эченнән генә теге ямьсезрәк тавышы белән моңлы гына итеп шыңшый... Шул арада каяндыр Фәридәнең анасы килеп чыга да бер Фәридәгә, бер Рөстәмгә карый. Аның йөзе карт агачлар күләгәсеннән бик ачык беленми. Бервакыттан эллә нинди мәче башлы ябалак тавышына охшаган бер тавыш ишетелеп киткән төсле була, Фәридә дә куркып уянып китә. Аның йөрәге өзелеп-өзелеп сызлана, тамак төбенә нәрсәдер килеп тыгыла. Аның күңелендә эллә нинди тойгылар, айлы кичәдә күктәге кара-кучкыллы болытлар сыман, әкрен генә дулкынланып йөриләр. Шул арада аның янындагы Мәүли әби дә уяна:

— Фәридә бәбкәм, синме соң бу? Йокла, бәбкәм, йокла! — ди.

Фәридә исә җавап урынына аны кысып-кысып кочакларга, җыерчыклар белән томаланган битеннән суырып-суырып үбәргә башлый:

— Мәүли әби, төшемдә әнине күрдем, әнине, үлгән әнине,— ди.

Мәүли әби исә, барын күптән аңлаган шикелле итеп, башын гына ия. Шуның артыннан ук Фәридә:

— Мәүли әбием, җаным, барыбер йоклап булмый, бер әкият сөйләп җибәрче! — ди.

Мәүли әби башта кыстаткан була (аның һәрвакыттагы гадәте ул), аннары гына иске заманнар турындагы озын-озын әкиятләрен тәмле иттереп сөйләргә керешә. Калмый анда эллә нинди шаһзадәләр, калмый анда тулган ай тик матур йөзле хан кызлары. Шаһзадә белән хан кызы берсен-берсе күреп, үләр чиккә җитеп, гашыйк булышалар. Ләкин алар бер-берсенә бик озак кавыша алмыйлар: эллә нинди кара көчләр аларның кавышуына манигъ[1] булалар. Шуңар күрә алар икесе дә сак белән сок шикелле бер-береннән аерым яшиләр, кичләрен бер-берсен сагынып кан яшьләрен агызалар. Менә шулай төрле мәшакатьләр күргән, газапланганнан соң ахырында болар кавышалар...

Фәридә әбинең һәрбер сүзен йотардай булып тыңлый, хан кызы белән шаһзадә өчен ачына, аларны чиксез кызгана һәм соңыннан аларның кавышканнарын ишеткәч, чын күңелдән шатлана. Кәримә исә бу вакытта тәмле иттереп йоклый. Түгәрәкләнеп килә торган ай көлемсерәп тәрәзә аша бүлмәгә карый, идәнгә буй-буй зәңгәрсу яктыларын чәчә, ишек алдында сузып-сузып кына этәчләр кычкырганы ишетелә. Фәридә дә әкиятнең татлы хыяллары белән тәмле йокыга китә.

Иртә белән чәйгә кадәр ул Кәримә белән, Зөләйха абыстайның кушуы буенча, иртә намаз укып ала, чәйдән соң Лиза ханымнан дәрес өйрәнә. Инде ул урысчаны тәмам аңлый һәм дәресләреннән бушангач, мадам Лизадан әдәби китаплар алып укый. Бигрәк тә Пушкинның әсәрләре ошый аңа. Ул аның һәрбер нәрсәсен эллә ничәшәр кат укып чыга. Төшләрендә ул «Бакчасарай фонтаны»нда тасвир ителгән Гәрәй ханның хәрәме, анда тоткын булып ята торган кара кашлы, матур күзле кызлар, аларның җырлары, Кавказияле Зарима исемле кыз-

[1] Манигъ — каршылык, тоткарлау, комачау.

ның Гәрәй ханны өзелеп яратулары, ханның аны ташлап, поляк патшасының кызы Мариягә гашыйк булулары, Зариманең бер айлы кичәдә көнләшеп Марияне үтерүләре белән саташып чыга. Ул рояльдә уйнарга көннән-көн остара. Аның кайгылы йөзе дә көннән-көн матурлана, кара күзләре дә аның көннән-көн мәгънәле, көннән-көн кайгылы карыйлар. Авыл халкы үзара:

— Мирзаның Кәримәсе дә матур, ләкин Фәридә аннан да бигрәк матур, аннан да бигрәк сөйкемле,— диләр.



## V

Инде яз якынлаша. Кояш көннән-көн югары күтәрелә, көннән-көн нурларын арттыра. Бөтен җир йөзен томалаган кар, актыкны көннәрен сизгән шикелле, әллә нинди бер күңелсез төскә керә. Кыш, актык көчен җыеп, куәтле яз белән тартышып карый: кайсыбер кичләрдә тышта җил өрә, сибәләп яфрак-яфрак кар ява, ләкин инде булмый. Кыш үзе дә көчле язга каршы тора алмаячагын аңлый, шуңар күрә ул кискен ачы тавыш белән елый, кыш урталарындагы шәүкәтен исенә төшереп, актык көннәренең якынлашканын сизенеп елый. Озак та үтми, аның кул астында булган карлар, үзләренең башчыларын ташлап, дошман ягына авышкан гаскәрләр шикелле, кояшның якты нурлары астында көлә-көлә, әллә нинди музыка тавышына охшаган серле тавышлар чыгарып, чылтыр-чылтыр алга чабалар, бер-берсенә кушылып, зур елгаларны тутыралар, болыннарга җәеләләр. Алар инде бар да язга бирелгәннәр, алар инде язның матурлыгын бетерә алмыйлар, кыш көне вакытны залим кыш кулы астында әрәм үткәргәннәренә инде алар үзләре дә аптырыйлар.

Су буендагы урманнар, «шулай кирәк, шулай», дигән төсле итеп, аларга түбәнчелек белән башларын селкиләр. Инде җир йөзе яшел үләннәр, агачлар шул ук төстәге яфраклар, болыннар да ал, сары, зәңгәр чәчәкләр белән бизәнә. Инде Дим дә дулкынлап-дулкынлап агуыннан туктый: юаш кына, тын гына ага, дөньяга агач күләгәләре аркылы мөлаеманә көлә; әнә инде кошлар да кайтканнар: бар да үзләренең матур тавышлары белән язны, табигатьне өзелеп-өзелеп мактыйлар, бөтен мәхлукатьне[1] тормышка, шатлыкка өндиләр. Кояш югартын боларның бөтенесенә: «Әлләлә, нишләтте абзаң!» дигән төсле итеп, мактанып, көлеп карый.

Инде Рөстәм дә укудан кайта. Өйдә тагы шатлык, сөенеч башлана. Кәримәләр дә укудан туктыйлар. Рөстәм ярыйсы гына үскән була. Инде ул малайлар белән уйныйсы урында, күп вакыт бакчаның бер читенә барып китап укый һәм кайчагында укыган нәрсәләрен Кәримәләргә дә сөйли. Карт мирза ара-тирә чәй яннарында аңардан укыган нәрсәләрен, гимназиядәге тормышны, андагы мөгаллимнәрне, ашаучыларне сораштыра. Рөстәм аңарга барын да сөйли, карт исә:

— Шулай диген, ә? — дигән шикелле беркатлы сүзләр әйткәләп кенә аны тыңлап утыра. Мондый вакытларда Зөләйха абыстай бер улына, бер картына карый, картының йөзеннән Рөстәмнән риза булып-булмаганлыгын аңларга тырыша.

Май ахырларында Исхак мирза Оренбургка барып Касыймны да алып кайта. Касыйм кайткач, йорт эче бигрәк тә җанланып китә, ул бөтенесе белән шаяра — кадетски корпуста өйрәнгән уеннары, әңгәмәләрен сеңелләренә күрсәтә, сөйли, аларны көлдерә.

Ул җәй шулай шатлык эчендә тыныч кына уза. Көз җитүгә, Рөстәм белән Касыйм тагы укырга китәләр һәм алдагы җәйне тагы авылда үткәрәләр. Өченче җәйдә авылга Касыйм гына кайта.

[1] Мәхлукать — тереклек дөньясы, җан ияләре.

Рөстәм исә, актыккы сыйныфка күчкәнгә: «җәен дә укыштыргаламын», дип, Казандагы бер ерак кардәшләрендә кала. Фәридә инде ярыйсы гына үсә. Җәен Рөстәмнең өйдә булмавы аңар никтер бик авыр тоела; ул аны сагына, төшләрендә аның кара урманда ямьсезрәк тавыш белән борын эченнән генә шыңшып йөргәнен еш-еш кына күрә. Тагы кыш җитә.

Рөстәм бу елны бик нык тырыша, төрле хыялларга күп бирелми. Яз көннәрне имтиханнар тәмам биреп бетергәч, ул авылына кайта. Бу вакыт инде ул унсигез яшенә җиткән, иреннәренә йомшак кына кара төк чыга башлаган, тавышы да калыная төшкән бер яшь егет була. Карт мирза белән Зөләйха абыстай гимназия бетереп кайткан улларын күрүгә бик сөенәләр.

— Кара инде, безнең Рөстәм нинди үскән, нинди зур егет булган! — диләр.

Зөләйха абыстай улының зур булуына сөенсә дә, — аның кеше белән сөйләшергә яратмыйча, ялгыз гына уйланып йөрүен, артык сабырлы булуын бигүк ошатып бетерми. Карчыклар белән сөйләшкәндә: «Бигрәк тә артык сабыр, артык юаш шул инде... Әй, аның сабырлыгын азрак Касыймга биреп, Касыймның җитезлеген дә азрак моңар бирергә!» — ди.

Рөстәмнең кайтуына Фәридә бөтенесеннән артык сөенә. Ул чәй яннарында аның ябык йөзенә, соры күзләренә, акыллы киң маңгаена, бакчада йөргәндә аның вәкарь[1] белән атлап баруларына карап туя алмый. Көннән-көн аның күңеленә Рөстәм икенче кеше, үлгән атасы белән анасыннан да якын кеше, бер егет булып урынлаша бара. Инде ул рояльдә уйнаганда Бетховенның моңлы көйләре белән үзенең Рөстәм турындагы уйлары арасында әллә нинди якынлык сизә. Шуңар күрә дә ул айлы кичәләрдә, тәрәзәне ачып, рояль уйнауда үзенә бертөрле хозур,[2] үзенә бертөрле сәмави[3] шатлык тоя башлый. Ул әле үзендә яңа гына уяна башлаган бу яңа тойгыларны ни дип атарга да белми, йокысыз үткәргән кичләрдә: «Миңа ни булды икән!» дип аптырый, уйлана; тик өченче этәч кычкырган, сызылып таң аткан чакларда гына йокыга китә.

Төнендә ул тагы «Бакчасарай фонтан»ында тасвир ителгән Заримәне күрә: алар аның белән зур бакчада булалар, бер рәткә тезелгән озын сәрви агачлары арасыннан посып-посып кына йолдызлар карыйлар; каядыр чылтырап фонтан ага, тирә-як тын, гүя, бөтен табигать тирән йокыга талган. Заримә исә аны бик каты кочаклый; Фәридәгә аның кызу сулышы бәрелә, дөп-дөп итеп йөрәге типкәне ачык ишетелә. Ул Фәридәгә шыпырт кына:

— Курыкма, җаным Фәридә,— ди,— син инде гашыйк булдың,— ди.

Ул да булмый, бөтенесе күздән юк була. Фәридә дә: «Гашыйк булдым, гашыйк», ди-ди уянып китә. Аның йөрәге дөп-дөп тибә, тәмле генә сызлана, ачынып та киткән төсле була. Ул көләргә дә, еларга да белми. Бик кыен да, бик рәхәт тә төсле була.

— И ходаем, рәхмәтеңнән ташлама! — ди.

Инде ишек алдында тәмам таң аткан була. Каядыр агачлар арасында чут-чут иттереп сандугач сайрап куя. Беравыктан аңар шул ук тавыш белән икенчесе дә җавап бирә. Фәридәнең күңеленә Мәүли әбинең мондый вакытта әйтә торган:

— Алар да, җаннарым, бер-берсенә дәшәләр, алар да шул бергә яшәргә яраталар,— дигән сүзләре килә.

Шул арада аның күзләрен тойдырмый гына йокы баса башлый.

---

[1] Вәкарь белән — горурлык белән.
[2] Хозур — рәхәтлек, күңеллелек.
[3] Сәмави — хыялый, романтик.

Әйе, ул Рөстәмгә чын күңеленнән гашыйк була, аның сурәте көне-төне зиһененнән чыкмый. Ләкин ул аңар яратканын әйтү түгел, инде чәй яннарында: «Күңелемдәген белмәсә ярар иде», дип, йөзенә карарга да курка. Ә аулакта калгач, тагы аның турындагы татлы хыялларына чума. Рөстәм исә әле һаман да Фәридәгә туганына караган шикелле карый, аны кардәше кебек якын күрә, абзалык мәхәббәте белән сөя, аның озын керфекләре арасына яшеренгән күзләрендәге әллә нинди тирән кайгыларны укып, аны чын күңеленнән кызгана. Ул Фәридәнең рояльдә уйнаганын тыңлап туя алмый: аның уйнаган көйләреннән аңар әллә нинди бер елау, кара көчтән өзелеп-өзелеп зарлану, зарыгулар, кемгәдер ялынулар ишетелгән төсле була. Боларны ишетүгә Рөстәмнең күңелендә әллә нинди томанлы тойгылар хәрәкәт итә башлый, шулай да ул аларга бик ул кадәр әһәмият бирми: үзенең китапларын укый да укый, шуның белән томанлы тойгыларын сүндерергә азаплана.

Инде көз якынлаша. Фәридәдәге мәхәббәт тойгысы үскәннән үсә. Ул Фәридәне сөендерә дә, газаплый да. Кайчагында ул үзеннән үзе ояла, төннәрдә уянып елый, ләкин күз яшьләре күкрәктәге утны сүндерә алмыйлар. Ул серен беркемгә дә ачмый. Рөстәмнән ояла. Бүлмәдә аның белән ялгыз калганда ул әллә нинди китаплар хакында сүз ача. Мондый вакытларда аның йөрәге дөп-дөп тибә, оялуыннан битләре кызара. Шуңар күрә ул тизрәк Рөстәм янынннан качарга ашыга.

Берсендә шулай Рөстәм кич белән бакчада ялгыз гына йөргәндә кинәт аңар таныш рояль тавышы ишетелә. Ул әз генә туктап тора да ирексез шул сәмави тавышлар ишетелгән якка таба бара һәм, нигезгә басып, ачык тәрәзәдән өйгә карый. Күрә: анда рояль алдында ак күлмәктән Фәридә утыра. Рөстәм аның аркасыннан кара елан төсле сузылып төшкән озын чәч толымнарына, әз генә күпереп тора торган мәгъсум[1] күкрәгенә, кайгылы әсмар[2] йөзе белән бер ноктага караган кара күзләренә — кыскасы аның бөтен гөнаһсыз гәүдәсенә аптырап карап тора. Фәридә исә нәзек бармаклары белән һаман уйный. Рояльнең моңлы тавышлары берсен-берсе куа-куа кичке һавада юк булалар, алар артыннан икенчеләре туалар... Моны күрүгә Рөстәмнең йөрәге әллә нишләп китә. Ул тыңлап тора-тора да, әкрен генә:

— Фәридә! — ди.

Фәридә исә тиз генә әйләнеп карый да:

— Ай, Рөстәм абый! — дип кычкырып җибәрә. Ул сөенергә дә, сөенмәскә дә белми, Рөстәм үзендә әллә нинди бер уңайсызлык тоя, шуны бетерер өчен:

— Әмма, Фәридә, матур да уйныйсың икән,— ди, үзе никтер кызарына.

Фәридә аңар ни дип тә җавап бирми, тик башын гына аска ия. Рөстәм исә:

— Йә, ярый, уйна син.— ди дә китеп бара.

Фәридә тәрәзәдән аның теге ямьсезрәк тавыш белән борын эченнән генә моңлы көен шыңшый-шыңшый бакчадагы агачлар арасына кереп киткәнен карап кала. Аның никтер бик каты:

— Рөстәм абый, мин сине яратам, чын күңелемнән яратам! — дип кычкырасы килә. Ул Рөстәмнең: «Әмма, Фәридә, матур да уйныйсың икән!» — дигән сүзләрен исенә төшерә дә: «Рөстәм абый минем уйнавымны ярата», дип чиксез сөенә, аның яшь күңелен чиксез шатлык тутыра. Аңар инде бу дөньяда күңелсез булу мөмкин түгелдер төсле тоела. Бу вакыт аңар күктәге йолдызлар бөтенесе көлеп карыйлар, тик урман өстендәге тирән уйга калган айның саргылт төстәге тонык һәм моңсу нурлары аңар тирән кайгы белән карагандай була.

---

[1] Мәгъсум — гүзәл, саф, гөнаһсыз.
[2] Әсмар — кара-кучкыл.

## VI

Бер айдан соң Рөстәм, дарелфөнүннең[1] тыйббия[2] шәгъбәсенә[3] керергә дип, Мәскәүгә китә. Аерылган чагында, аталары белән исәнләшкәннән соң, ул озатырга чыккан Фәридәгә:

— Ярый, туган Фәридә, син дә сау бул! — ди.

Бу вакыт ул Фәридәгә чиксез якын, чиксез кадерле, бөтен дөньядан, хәтта тормышыннан да кадерлерәк кебек тоела. Ул аның артыннан дөньяның аръягына чаклы ияреп барырлык була. Рөстәмнең киткән чагында:

— Ярый, туган Фәридә, син дә сау бул!..— дигән сүзләре берничә көн аның колагы төбендә яңгырап торалар. Бер агнадан соң, кайгы, хәсрәтеннәнме, әллә булмаса икенче бер сәбәптәнме, ул бик нык авырый, төннәрдә саташа, кызыша, еш-еш үлгән әнисен исенә төшерә; шул арада: «Рөстәм абый...» дип нәрсәләрдер сөйли башлый, әченнән: «И ходаем, үзең ташлама», ди. Зөләйха абыстай белән Кәримә көнетөне аның яныннан китмиләр һәм аңар карап аптырыйлар. Фәридә исә тик берничә атнадан соң гына терелә. Бу вакыт ул ябыккан һәм хәлдән тайган була.

## VII

Рөстәм Мәскәүгә барып, дарелфөнүннең тыйббия шәгъбәсенә керә. Ул елларда Мәскәү университетының иң алга киткән чаклары була. Шәкертләр арасында яңа агым, яңа фикерләр башлана. Рөстәм керүе белән тырышып дәресләрен укырга тотына, бигрәк тә урыс әдәбиятында булган татарлар хакындагы тарихи китапларны ул яратып укый, аларның чит милләт кешеләре тарафыннан язылган якты исемнәрен күреп шатлана. Ул Фәридәне башта сагына, ләкин тора-бара аны оныта башлый. Тик ара-тирә, дәрестән бушаган араларда гына аның турында уйлап ала. Гомумән, ул үзен теләсә ничек йөретә ала торган төпле бер егет була. Вакыты буш булганда, ул үзенчә яхшы дип белгән студентлар янына барып утыра, сүзгә катышмый гына, аларның үзара моназара[4] кылышканнарын тыңлый; ара-тирә аларның җиңел генә әчке мәҗлесләренә дә катышкалый. Башта иптәшләре аңа ул кадәр игътибар итмиләр. Ләкин түбәндәге кечкенә генә бер вакыйгадан соң аңар бөтенесенең игътибары арта. Аңар бар да, эшлекле һәм мәгълуматлы шәкерт вә иптәш, дип карый башлыйлар. Эш менә ничек була.

Берсендә шулай берничә студент тарихи каһарманнар турында гәп корып утыралар. Искәндәр, Кәбир, Наполеон, Бөек Петр, Чыңгыз хан шикелле тарихи каһарманнар бар да телгә алына, эшләгән эшләре мөхакәмә[5] ителә, алар арасында Рөстәм дә була. Шул арада яшьләрдән берсе бик кызып китеп:

— Теләсәгез генә нәрсә әйтегез, ләкин мин Чыңгызны каһарман дип таный алмыйм; ул ерткыч, вәхши, кан эчүче азиат, варвар булган! — ди.

Шул арада сүзгә катышмый бер читтә генә утыра торган Рөстәм урыныннан тора да, азрак калтырана төшкән тавыш белән:

— Юк, иптәш, сез ялгышасыз, Чыңгыз ул, сез әйткәнчә, кан эчүче вәхши булмаган: ул Наполеоннар, Искәндәрләр шикелле үк,

---

[1] Дарелфөнүн — университет.
[2] Тыйббия — медицина.
[3] Шәгъбәсенә — бүлегенә.
[4] Моназара — сүз көрәштерү, бәхәсләшү.
[5] Мөхакәмә ителә — тикшерелә, бәяләнә.

хәтта алардан да оста бер полководец булган; ул күчмә хәлендә яши торган һәм һичбер тәртип-фәлән күрмәгән бер халыктан бөтен дөньяга нәмунә[1] булырлык тәртипле һәм монтазам[2] бер гаскәр тәшкил иткән,— ди.

Шуннан соң төпле тарихи дәлилләр белән аның эшләгән эшләренең яхшы якларын исбат итәргә тотына. Бу вакыт аның йөзе кызара, күзләре нурлана, иптәшләре исә аңар аптырап карап торалар. Ул һаман сүзендә дәвам итә:

— Нинди генә тарихи каһарманнарны алма, ул бөтен дөнья халкының файдасыннан бигрәк, үз кул астындагы кешеләрнең файдасын күзәткән һәм шушы юлда башкаларга зарар итүдән дә тартынмаган. Чыңгызның эшләгән эшләрен дә, хакыйкатькә хөрмәт өчен булса да, шулай карарга мөмкин түгелмени? Юк, әфәнделәр, теләсәгез генә ни әйтегез, мин Чыңгызны үз заманасының зур кешесе дим. Әйе, ул үзенең халкы өчен яхшылык теләүче зур бер полководец булган. Мин дә үземнең тамырларымда шул тарихи каһарман Чыңгызның каны уйнау белән бөтенегез алдында мактанам! — ди.

Яшьләрнең бер усалрагы ярым житди тавыш белән:

— Браво, Чыңгыз, афәрин! Әйдә үзен күтәрәбез! — ди. Шуннан соң озак та үтми мәҗлестәгеләр таралалар.

## VIII

Җәй җитү белән ул тагы ике айга гына авылына кайта. Фәридә белән Кәримә икесе дә буйга җиткән, матурланган булалар. Мирза индедән соң аларны укудан туктатырга исәпли, шуңар күрә мадам Лиза, яз җитүгә, үзенең Уфасына кайтып китә. Ул җәйне Касыйм никтер авылга кайтмый, Оренбурда кала.

Фәридә Рөстәмнең кайтуына чиксез сөенә. Көннәр бик кәефле уза башлый. Кичләрен мирза өендә Фәридәнең рояльдә моңлы гына көйләр уйнаганы, Кәримәнең яшь, саф һәм матур тавыш белән рухлы башкорт көйләрен җырлаганы ишетелә. Кайчагында кичләрен Рөстәм, Фәридә белән Кәримәне көймәгә утыртып, Дим өстендә йөртә; аларга Мәскәүдәге тормышны, андагы яңа фикерләрне бик озын, бик тәмле иттереп сөйли, үзенчә фәлсәфә сата. Кайчагында кызып китеп:

— Инде укыган бөтен ирләребезгә, бөтен укыган хатыннарыбызга халык арасына чыгып хезмәт итәргә, аларны аз булса да агартырга тотынырга вакыт,— ди.

Шуннан соң үзенең курс бетергәч, шушы Дим буендагы авылларның берсенә доктор булачагын, киләчәктә ничек итеп тора башлаячагын бик якты буяулар белән тасвир итәргә тотына. Мондый вакытларда аның күзләре зурая, йөзе ачыла. Фәридә белән Кәримә дә аны тәгъзыйм белән тыңлап торалар. Инде Фәридә өчен аның авызыннан чыккан һәрбер сүздән мәхәббәт, гөнаһсыз саф мәхәббәт аңкый. Ул аларның барын да үзенчә юрый, эченнән генә: «Әйе, шушы Дим буенда бергә яшәрбез: син фәкыйрь авыруларга ярдәм итәрсең, мин дә аларның балаларын укытырмын», ди.

Мирза белән Зөләйха абыстай инде яхшы гына картайган булалар. Алар балаларының тигезлегенә, аларның кичәләрдә бергәләшеп йөрүләрен карап туя алмыйлар.

Көннәр берсе артыннан берсе тын гына узып тора. Рөстәм буш вакытларында китап укый. Кайчагында алар Фәридә белән икәү генә бакчада йөриләр. Алар инде бер-берсеннән ул чаклы оялмыйлар, лә-

[1] Нәмунә — үрнәк.
[2] Монтазам — рәтле, тәртипкә салынган.

кин шулай да үзләренең тойгылары турында бер-беренә ләм-мим дә әйтмиләр.

Шул җәйне Рөстәм янына күрше мирзаның егерме ике яшьлек Ибраһим исемле офицер улы килеп-китеп йөри башлый. Рөстәм никтер аның белән бик ул кадәр дуслашып җитә алмый. Шулай да Ибраһим килеп-китеп йөргәндә, кичләрен Кәриманең тавышын мактавында дәвам итә. Озак та үтми, алар Кәримә белән бер-берсен яратышалар. Мирза белән Зөләйха абыстай инде аулакта гына Кәримане Ибраһимга бирү турында планнар да кора башлыйлар. Көз җитүгә Рөстәм тагы укырга китә.

## IX

Икенче җәйдә Рөстәм Кәриманең туена ике атнага гына кайтып китә. Әйе, Кәримане Ибраһимга бирәләр. Гаять тантаналы туй ясала. Тирә-яктан кунаклар, мирзалар, карт муллалар чакырыла — кыскасы, туй гаять дәрәҗәдә хозур уза.

Рөстәмгә бу җәйне Фәридә никтер күңелсезләнеп йөргән төсле тоела. Ул күп вакыт бер үзе генә күңелсезләнеп бакчада йөри, уйлана, нәрсәдән дә булса курыккан шикелле, як-ягына карана. Инде аның рояльдә уйнаганы да бик сирәк ишетелә. Үзе ара-тирә йөткергәли дә. Боларны күргәч, Рөстәмдәге аны кызгану хисе тагы да арта. Аның Фәридәне татлы сүзләр белән башыннан сыйпыйсы килә.

Берсендә шулай Фәридә кич белән әңгер-меңгер чагында бакчаның ары башында берүзе уйланып утыра. Ул тиздән Кәриманең Ибраһим янына, Рөстәмнең дә Мәскәвенә китүен, шушындый зур йорт эчендә үзенең томанлы, караңгы уйлары белән япа-ялгыз калачагын уйлый, күңелсезләнә, үзенә-үзе бөтенесе тарафыннан ташланган бер мескен төсле тоела, аның күңеле, киләчәктә үзе өчен нинди дә булса бер начар эш булачагын сизенеп сызлана. Каядыр авыл кызларының киндер тукмаклаганнары, егетләрнең су буенда сыздырып гармун уйнаганнары ишетелә. Авылның ары башында берсе бугазы ертылганчы: «Җамалетдин-н-н... кайт-т-т-т!» дип бик каты кычкырганы тын һавада яңгырый.

Фәридә һаман уйлана, шул арада Рөстәм үзенең ямьсезрәк тавышы белән борын эченнән генә шыңшып агачлар арасыннан килеп чыга һәм Фәридәне күреп туктый:

— Исәнме, Фәридә, монда ни эшләп утырасың? Әллә авырыйсыңмы, төсең бик киткән,— ди.

Фәридә аңар күтәрелеп карый:

— Юк, авырмыйм, болай гына,— ди, шуның артыннан ук ул тагы бер Рөстәмгә карап ала; ул аның күз карашлары белән тавышында үзенә чиксез бер якынлык тоя һәм ирексез әкрен генә:

— Эч поша, Рөстәм абый, чиксез эч поша. Мин нәрсәдәндер, анысын үзем дә белмим, куркам, миңа киләчәгем куркынычлы тоела, никтер елыйсы килә, ләкин инде мин, электәге шикелле, туйганчы елый да алмыйм, сез киткәч инде миңа тагы да уңайсыз була, иптәшкә Кәримә дә булмый. Бөтен өйдә япа-ялгызым калам,— ди.

Аның инде, әүвәл вакытлардагы шикелле, Рөстәм белән сөйләшкәндә йөрәге типми, ул инде Рөстәмгә туп-туры карый. Рөстәм аның кулыннан тота һәм әкрен генә:

— Алла кушса, бар да үтәр. Болар бар да нервлар бозылганнан гына, бар да үтәр,— ди.

Шуннан соң инде ул мәсьәлә күптән хәл ителгән шикелле бик гади генә итеп:

— Инде, туган Фәридә, син дә бала түгел, мин дә, шуңа күрә от-

кровенно[1] әйтергә кирәк. Җитәр инде, әле дә байтак бернәрсә дә әйтми, яшеренеп йөрдек... Әйе, без бер-беребезне яратабыз, мин аны, син әйтмәсәң дә, беләм, синең гүзәл күзләреңнән беләм, аны яшереп торудан мәгънә юк,— ди.

— Син инде ничек тә бер-ике ел түз, аннары, алла боерса...— дип сүзен әйтеп бетерми, Фәридәнең кечкенә генә кулыннан чут иттереп үбеп ала. Фәридә исә бу вакыт һичбер авырлык хис итми.

## X

Кәримә белән Ибраһим өчен кызыклы, Фәридә өчен күңелсез, Рөстәм өчен дә бертөрле генә булган тагы бер ел узып китә. Бу кыш Рөстәм гаять дәрәҗәдә тырышып укый, шул чаклы ки, яз көне имтиханнардан соң докторлар аңар: «Исәнлегеңә зарар килүе ихтимал, нервларың бик какшаган», дип кымызга барырга киңәш итәләр. Шуңар күрә Рөстәм язын авылга бармыйча, Оренбург губернасына кымыз эчәргә китә. Касыйм исә авылга кайта. Ул инде матурланган, тазарган, унҗиде яшәр егет була. Матур гына иттереп эчә, очраган матур ханымнарга тәмле генә сүзләр кыстырырга, алар артыннан ухаживать итәргә өйрәнгән генә түгел, остарган була. Кызлар да аны кырын какмыйлар, яраталар: «Булдыклы, мәлле егет ул!» диләр. Ул картада да уйный һәм атасының байтак кына акчасын оттырырга да өлгергән була.

Авылга кайтуына аның күзе Фәридәне күреп кызыша, ул эченнән генә ничек тә булса «бу кошны» кулдан ычкындырмаска карар биреп куя. Ул һаман ара-тирә урыны килгәндә Фәридәгә комплиментлар да әйткәләп ала. Фәридәнең, билгеле, моңар гаять ачуы килә: ул Касыймга бер пычрак малайга караган шикелле карый. Аның үзенә игътибар итмәгәнен күргәч, Касыймның уйнап кына башлаган дәрте тагы үсә, ул ничек тә булса Фәридәне үзенә каратырга уйлый, ләкин шул арада гына аңар Оренбурга китергә туры килә.

Көз көне Рөстәм ярыйсы гына тазарып, Мәскәүгә кайтып, тагы укырга башлый. Гыйнвар башларында ул өеннән Кәримәнең баладан үлүе турында хат ала. Рөстәм аның үлүенә бик ул кадәр кайгырып тормый: өйдәгеләргә тәэсирле генә бер мәктүп[2] яза да, тагы укуында дәвам итә. Касыйм исә бу елны бөтенләй юк-бар нәрсәгә бирелә. Карт мирза аңар әллә ничә мәртәбә ачуланып хат та язып карый. Касыйм да шуннан соң вакытлы рәвештә азрак инсафланган төсле була.

## XI

Май урталарында авылга иң әүвәл офицер киеменә киенгән Касыйм кайта. Анасы аның кайтуына бик нык сөенә. Инде Зөләйха абыстай кызының хәсрәтеннән ярыйсы гына картайган була. Касыйм кайтуына тагы бик тырышып Фәридә артыннан йөрергә башлый. Үзенең бетмәс-төкәнмәс комплиментлары белән аны бөтенләй аптыратып бетерә. Бу эшкә Фәридә азаплана, ни эшләргә белми, хәтта Зөләйха абыстайга әйтергә дә уйлый, ләкин никтер курка, үзе: «Тизрәк Рөстәм абый кайтса ярар иде», дип аның кайтуын түземсезлек белән көтә. Өйдәге асраулар белән кучерлар, бергә җыелганда, төрлечә Фәридәнең гайбәтен ашый башлыйлар. Кучер сүз арасында хаинән[3] көлеп:

[1] Откровенно — ачыктан-ачык.

[2] Мәктүп — хат.

[3] Хаинән — мәкерле, эчкерле.

— Касыймың ни эшләтә, булдырамыни? — дип тә куя.

Касыйм көннән-көн Фәридә артыннан ныклап йөри бара, аңар ялына, бик усал дәлилләр белән үзенең яратканын аңлатырга азаплана.

Рөстәм исә әле һаман кайтмый. Аның эше бик күп: ул актыккы елның актык имтиханнарын бирә. Инде май ахырлары да якынлаша. Бер заман ул имтиханнарны биреп бетергәч, үзенең иптәшләре, дүрт ел гомерен уздырган университеты, шунда яшәгән фатиры, аның сахибәсе[1] карчык белән саубуллаша да туган иленә кайтырга чыга.

Өй сахибәсе карчык:

— Дүрт ел бездә тордың, һичбер начарлыгыңны күрсәтмәдең. Син миңа балам шикелле якын идең, сау бул инде, безне начарлык белән искә алма,— дип елап кала.

Рөстәм юл буе өйдә ничек тора башлаячагын, Фәридә белән ничек очрашачагын уйлап бара.

Аның кайтуына пристаньгә ат килеп торган була. Юлда барганда түгәрәк кенә сакаллы, өреп тутырган шикелле тулы йөзле, тәбәнәк кенә буйлы Хисами кучер Рөстәмнең:

— Соң, Хисами абзый, өйдә тагы ниләр бар? Карт нишли, бетеренмәдеме әле? — дигән сөаленә башта бик мәгънәле генә итеп:

— Көн дә кунак, көн дә туй — көн дә сагыш, көн дә уй, дигәнди инде,— дип аңлашылмаслык кына итеп җавап бирә, аннары тагы бара-бара ачыла төшеп: — Бетерә инде, ул да бетерә: картая. Бакчы Касыймны да. «Бик акчаны әрәм итә, юк-бар нәрсә артыннан йөри», дип сөйлиләр. Бар да бит ул ата-әнкәгә уңайсыз. Ата күңеле бит тарая,— ди, үзе чырт иттереп бер төкерә, яндагы атка: — Әй, милай, уйнама! — дип кабырга буйлап берне сыдыра, атлар да иренеп кенә тагын юырта башлыйлар. Ә Хисами һаман да Рөстәмгә ярты борылып сүзендә дәвам итә: — Касыйм инде күптән кайтты. Ул инде зур үскән, тазарган, матурланган, күрсәң, бөтенләй исең китәр; малай чая, әйтергә түгел, барын да булдыра, көлдерә дә белә, елата да... Теге сездә тора торган Фәридә бар бит әле? Әнә шуның бөтенләй башын әйләндереп бетерде инде, этиләр күрер, дию дә юк, нитү юк, һаман аның артыннан йөри дә йөри. Беркөн шулай бакчада көтү кайтыр алдыннан агачлар арасыннан, күрмәгәнгә салышып кына карап торам. Алдан сүз куешканнар булырга кирәк: Фәридәсе бакчаның ары башыннан шулай әкрен генә бара, як-ягына карана, ярый. Мин һаман, белмәгәнгә салышып, торам да торам. Шул арада Касыйм да агачлар арасыннан ут шикелле килеп чыкты.

— Ә, җаным Фәридә, синме? — ди.

— Мин,— ди, тегесе әйтә.

— Сине күрүемә мин бик шатмын, җаным Фәридә,— ди.

Ничу, малай усал, булдыра. Ярый. Мин һаман торам. Малаең тегене култыгына алырга әйтә, ә Фәридәң юри чытланып:

— Җитәр, Касыйм,— ди,— минем белән уйнама,— ди,— нигә син мине болай мыскыл итәсең — ди,— мин дә кеше ич! — ди. (Алар һәрвакыт шулай чытлыкланган булалар, ул инде кызларның гадәте). Ярый, мин, ни булыр икән, дип сулу да алмый тыңлап торам. Касыймың чая: тотты да тегенең алдына тезләнде:

— Җаным, бәгърем,— ди,— мин,— ди,— минә җир йотсын, чәчрәп китим,— ди,— синең белән уйнарга теләмим,— ди,— мин, җаным, сине бик яратам,— ди.— Тагы шунда әллә ниләр, әллә ниләр, ди. Малай ничу егет, әйтергә дә түгел. Аннары нәрсә булгандыр, анысын белмим: мине ат җигәргә бай дәшеп алды.

Бу сүзләр төрле якты уйлар белән өенә кайтып бара торган Рөстәмгә ут шикелле нык тәэсир итә, аның йөрәгендә нәрсәдер өзелеп

[1] Сахибәсе— хуҗасы, иясе.

киткән төсле була. Ул кинәттән бик кадерле нәрсәсен югалткан кеше шикелле, бик аптырап, як-ягына карана; башы тәртипле эшләми башлый, уйлар тарала, күңелгә әллә нинди кызыксыз уйлар килә, ул эченнән генә: «Әйе, инде ул аның белән йөри, алар бакчада бергә күрешәләр, бер-берсенә мәхәббәтләрен сөйлиләр»,— ди.

Шуның артыннан ук нәрсәгәдер Мәскәүдәге иртә белән дәрескә барганда очрый торган карт хәерчене аерымачык итеп исенә төшерә, аның: «Барин, а барин, подайте бедному старику копейку!» — дигән тавышын ишеткән төсле була. Тагы шуның артыннан ук күңеленә: «Инде ул башканы сөя», дигән ачы уй килә. Шуның артыннан ук тагы әллә нинди вак-төяк мәгънәсез нәрсәләр исенә төшә. Ул бөтенләй аптырый: «Миңа ни булды икән?», ди. Атлар һаман бер көйгә баралар да баралар: кыңгырау һаман бертөрле җырын җырлый: кай чагында ул әллә нинди сүзләр сөйләгән, кат-кат: «Бик шәп булган, бик шәп булган», дигән төсле була.

Рөстәм һаман үзенең тозсыз уйларын уйлый. Хисами ара-тирә әллә нинди мәгънәсез гыйбарәләр белән атларны сүгә, кайчагында аларга яхшы гына нәсихәтләр дә укып ала; үзе борын эченнән генә нәрсәдер җырлый, чит җирләрдә торуның кыенлыгыннан зарлана, туган иленә кайтасы килгәнне сөйли:

— Кайтыр идем — илем ерак, кайтмасам — яна йөрәк,— ди, тагы шуның артыннан ук кемгәдер ачуланган сыман: — Карлар түгел, боз яуса да, илгә кайтуым кирәк! — ди.

Рөстәм һаман уйлый, инде аның башы авырта башлый, йокысы килә. Хисами: «Үтте ич рәхәт җәйләр,» дип тына да бераз уйлап торгач, тагы моңлы гына итеп: «Үтте ич рәхәт җәйләр», ди.

Кыңгырау һаман яңгырый, колакны тондырып бетерә. Рөстәм инде йокымсырый башлый. Ул да булмый — ул үзен университет аудиториясендә күрә. Карт профессор кафедрадан нәрсәдер тактка салып сөйли, кулларын бутый, ара-тирә стаканнан су эчә. Ул да булмый, кафедрада профессор урынында дегеткә буялып беткән алъяпкыч бәйләгән, кулына ат чыбыркысы тоткан Хисами пәйда була. Ул стаканнан бик озак итеп су эчә дә кафедраның читенә чырт иттереп тешләре арасыннан бер төкерә, аннары теге карт профессор шикелле, ишарәт бармагын югары күтәреп: «Үтте ич рәхәт җәйләр»,— ди. Шул арада коридордан кыңгырау шалтыраган тавыш ишетелә...

Рөстәм дә аның тавышына уяна: профессор да юк, иптәшләр дә. Ул үзен юлда күреп аптырый. Үзендә әллә нинди бер уңайсызлык, авырлык хис итә. Аның күңеле никтер ачына, эченнән генә: «Нигә соң әле бу болай икән?» ди. Шуның артыннан ук: «Ул башканы сөя, башкасы белән йөри», дигән уй кылт итеп исенә төшә.

Атлар тауга түбән, урман эчләп бар хәлгә чабалар. Инде караңгылана башлаган була. Әнә инде урман да бетә, әнә инде хәрәкәтсез-нисез караңгылыкта катып калган агачлар күңелсез генә баш иеп артта калалар. Җир йөзен тәмам караңгылык томалый. Күктә берсе артыннан берсе ялт-йолт итеп йолдызлар күренә башлый. Кояш баешындагы болытлар куркынычлы кан төсенә буялалар. Алар берсе өстенә берсе гаять тә матур тезелгәннәр.

Кояш чыгышы ягы караңгы, дөм-караңгы. Әллә ник ул якка карыйсы килми: анда тормыш бөтенләй юктыр төсле тоела. Ә кояш баешы алай түгел. Дөрес, андагы болытларның күренеше куркынычлы, фаҗигале, ләкин шулай да аларга карау үзенә бер төрле рухны күтәрә: аннан тормыш аңкый, канлы булса да, анда тормыш манзарасы күренә.

Атлар өстеннән пар чыга. Алда бер рәткә тезелгән әллә нинди чүмәләләр күренә, этләр өргән ишетелә. Рөстәмгә кинәт һава суыкланып киткән төсле була. Озак та үтми, атлар авылга барып керәләр. Бер-ике эт бик иренеп кенә өрә-өрә юлчыларны каршы ала. Хисами,

дөньяга бары шул этләр белән генә булышыр өчен җибәрелгән шикелле, тырышып, ихлас белән аларны котыртырга башлый. Озак та үтми, атлар Исхак мирзаның йортына барып туктыйлар. Бу вакыт инде Рөстәм, җансыз кеше шикелле, бернәрсә дә уйламый. Менә инде иске капка да, борын эченнән генә әллә нәрсәләр мыгырдый-мыгырдый, әкрен генә ачыла, тарантас та ишек алдына барып туктый. Өй тәрәзәсеннән елт итеп ут күренә, кешеләр әрле-бирле йөри башлыйлар. Шул арада аннан-моннан гына киенгән Касыйм килеп чыга:

— Кайттыңмы? Менә рәхмәт! Без инде сине көтә-көтә зарыгып беттек,— ди.

Рөстәм иренеп кенә тарантастан төшә һәм каршы чыккан анасын күреп:

— Исәнме, әнкәй, исән йөрисеңме? — ди.

Зөләйха абыстай шатлыгыннан ни әйтергә дә белми; аның улы белән күрешкәндә иреннәре калтырый, ул нәрсәдер әйтергә азаплана, ләкин булдыра алмыйча елап җибәрә:

— Сеңлең Кәримә генә... юк тик,— ди.

Аннары ул Рөстәмгә бер карап ала да, ни өчендер аңар рәхмәт әйтергә тотына, шуның артыннан ук:

— Карчыкларның шул инде аларның,— ди.

Өйгә барып керәләр. Карт мирза улын утырган җирдән каршы ала: Рөстәмнең аның картайганлыгын күреп исе китә, чынлап та, мирза бик нык ябыккан, картайган була. Ул Рөстәмне күргәч, ачык тавыш белән:

— Ә кайттыңмы, дуктыр, менә һәйбәт, шулай кирәк ул, күптән шулай кирәк! — ди.— Алай да малаебыз үзгәргән, ябыктырганнар! Әйдә, ярар, монда анаң тәрбиясендә тазарырсың әле,— ди.

Шул арада ишектән әкрен генә Фәридә дә килеп керә. Ул Рөстәм белән әзрәк кызара төшеп күрешә:

— Исән кайттыңмы, Рөстәм абый? — ди.

Рөстәм аны күрүгә башта ирексез шатлана. Ләкин шуның артыннан ук: «Ул башканы сөя, ул әнә шул матур егетне сөя», дигән уй аның башына килә. Ул эченнән генә: «Юк инде, мин малай түгел, алдатмам»,— ди. Фәридә белән дә бик гади генә исәнләшә.

Фәридә аның күз карашын күреп, никтер куркып китә, аңар Рөстәм үзенә ачуланып караган төсле була. Шуның артыннан ук ул: «Юлда арыгандыр, мескен», дип күңелен юата. Бичара, әле ул усал кара көч алдагы көннәр өчен үзенә ниләр хәзерләгәнен бер дә белми.

Озак та үтми, өстәлгә самавыр да килеп утыра. Касыйм үзенең әллә нинди көлкеләре белән чәй янындагыларны көлдерергә азапланса да, мәҗлес бик күңелсез уза. Карт мирза бер туктамый исни һәм бер чынаяк чәй эчә дә:

— Миңа инде, карт кешегә, йокларга да вакыт, яшьләр, сез утырыгыз,— дип өстәлдән торып китә. Зөләйха абыстай, нинди дә булса бер яңа нәрсә кәшеф[1] итәргә азапланган төсле, берсүзсез-нисез улына карый. Фәридә дә чәй ясаганда ара-тирә посып кына Рөстәмгә карап ала, аның йөзендә үзе өчен гаять мөһим бер әйбер табарга тырыша, ләкин бер нәрсә дә булдыра алмый, аның дусының йөзе инде эч пошу, бөтенесенә тараюдан башка, бер нәрсә дә аңлатмый. Рөстәм, бер чит гаиләдә утырган шикелле, үзенә әллә нинди бер авырлык хис итә. Ул кулларын кая куярга белми аптырый. Аның никтер бертуктамый сөйләнеп утырган Касыймга, үзеннән күзен алмый торган анасына, буларын чыгарып кәефләнеп утыра торган самавырга — кыскасы, каршындагы бөтен нәрсәгә чиксез ачуы килә, гүя, бөтенесе аның дошманнары, гүя, алар Рөстәмнең иң кадерле нәрсәсен тартып алганнар. Аның бөтенесенә аяк тибеп:

[1] Кәшеф итү — ни дә булса эшләргә, уйлап табарга омтылу.

— Житәр! — дип бик каты кычкырасы килә.

Шуның артыннан ук ул бик гади нәрсәләр турында уйлый башлый. Ул Касыймның сүзләреннән бернәрсә дә аңламый. Ахырында ул:

— Мин бик арыдым, туганнар, миңа йокларга китәргә рөхсәт итегез,— дип урыныннан тора.

Төнне ул бик уңайсыз уздыра, әллә нинди начар төшләр күрә. Бер юлда барган Хисаминың сузып кына: «Үтте ич рәхәт җәйләре-е-е,» дип җырлаганын ишеткән, бер университетта иптәшләре арасында утырган төсле була. Тагы шуның артыннан ук: «Үтте ич рәхәт җәйләре-е-е», дигән тавыш ишетелә.

Фәридә дә ул төнне бик озак йоклый алмый ята. Аның башына берсе артыннан берсе әллә нинди уйлар килә; ул үз-үзенә уйланып кына: «Рөстәм абый нигә алай күңелсез икән? — ди, шуның артыннан ук,— арыгангадыр, ходай кушса», дип күңелен юатырга әйтә, ләкин ул уйның дөрес түгеллеген инде ул үзе дә сизенә.



## XII

Рөстәм кайтканнан соң берничә көн күңелсез генә үтеп китә. Рөстәм һаман уйлана, күп вакыт: «Кәефем юк,» дип аналары белән ашап-эчми; ул алар янында Касыйм белән Фәридә булгангамы, авырлык хис итә. Бу көннәрдә аның чиксез эче поша, ул бернәрсә турысында да төптән уйлый алмый. Хисамидан теге сүзләрне ишеткәннән соң, аңар дөньяда торуның бөтенләй мәгънәсе калмаган төсле тоела. Ул әле ялгыз гына бакчада йөри, әле су буена төшеп утыра. Инде ул бер нәрсәнең дә кызыгын тапмый. Касыйм белән бер бүлмәдә ятмас өчен, ул бакчаның аргы башындагы беседкага күчә һәм шунда тора башлый. Кайчагында ул үз-үзенә: «Ахрысы, болай ярамый, боларның бөтенесен ташлап эшкә башларга вакыт,» дип кулына китап алып җитди генә укый башлый. Ләкин бернәрсә дә аңлый алмый: аның башында икенче уйлар йөри. Кайчагында ул эченнән генә Фәридәгә ачулана: «Нигә инде мине алдарга?», ди. Шуның артыннан ук үзенең аңар ачуланырга һичбер хакы юклыгын игътираф[1] итәргә мәҗбүр була. Өйдәгеләр аңар карап бөтенләй ни әйтергә дә белмиләр. Зөләйха абыстай аулакта гына мирзага:

— Мин аңар ана ич, нигә инде минем белән сөйләшмәскә? — ди, елый. Мирза исә бер дә исе китмичә генә:

— Үтәр, ходай кушса, бар да үтәр,— ди.

Фәридә никтер аның күзенә күренергә, янына барырга, аның белән ялгыз калырга курка. Ул көне-төне.

— Рөстәм абый нигә болай үзгәрде икән? — дип баш вата, ләкин бер төпле нәрсә дә уйлап чыгара алмый. Касыйм исә эченнән генә абзасын:

— Җүләр, простой кеше! — дип куя, ул аңар бик ул кадәр игътибар итми: үз эше үзенә җиткән, ул ничек тә булса Фәридәне кулдан ычкындырмаска, ничек тә булса аны үзенә каратырга уйлый. Фәриданең игътибарсызлыгы аның хайваният хисен котырта гына. Ул һаман урыны чыкканда Фәридәгә бәйләнә, аны бөтенләй аптыратып бетерә.

Рөстәм кайтканнан соң биш көн узып китә. Рөстәм, һаман беркая чыкмый-нитми, тик үзенең беседкасында яши. Инде ул бик озак уйланганнан соң, Фәридә белән элеккечә сүзгә керешеп, аның рәхәтенә манигъ булмаска карар бирә.

[1] Игътираф итү — хаксызлыгын, гаебен тану.

Беркөнне Касыйм иртүк ат җиктереп, күрше авылдагы яшь земский начальникка китә. Ул аннан икенде алдыннан гына кайта һәм, гадәте буенча, азрак кәефләнгән була. Бу арада аның да эче поша. Ул үз-үзенә: «Хезмәткә китәргә дә инде вакыт җитә, ә мин, ачык авыз, һаман шул Фәридә белән эшне рәтли алмыйм. Бүген ничек тә булса аның белән эшне бетерергә иде инде», ди.

Оренбургта вакытта хатын-кызның бөтенесен үзенә каратып та, мондый авылда ята торган килмешәк бер кызның болай һаваленуына аның чиксез ачуы килә. Ул үзе залның бер почмагыннан бер почмагына йөри, үзе эченнән генә: «Әллә инде мин аңар бөтенләй гашыйк булдыммы?» — ди, тагын да ачуы килә. Шул арада ул тәрәзәдән бакча эчләп бара торган Фәридәне күрә дә:

— Ни булса да булыр, бүген эшне бетерәм! Алай, малайлар шикелле, куркырга ярамый,— дип тиз генә өйдән чыга. Бу вакыт инде аның күзе вәхши хайванныкы төсле ялтырый. Ул өйдән чыгуына ауга бара торган мәче шикелле посып кына бакчаның аргы башына, икенче сукмак белән китә. Ул Фәридәгә бакчаның ары башында очрарга уйлый. Фәридә исә бернәрсә дә белми, күңелсез генә һаман бакча эчләп алга бара. Ул инде төннәрен йокламыйча бик күп уйлаган, бик күп азаплангannan соң, Рөстәмне күреп сөйләшергә, аның белән бөтенесен аңлашырга уйлый, һәм хәзер дә: «Аны ничек тә аулакта очрата алмаммы?» — дип бакчага бара. Ул үзе бара, үзе нәрсәдәндер курка: «Ни дип сүз башлармын икән?» — ди. Күңеленә: «Булдыра алмасам, бер нәрсә дә әйтә алмасам,» дигән уй килә. Шулай да ул: «Ни булса да булыр, барыйм әле», ди.

Инде ул бакчаның аргы башына якынлаша. Дим буенда казлар кыйкылдашканы, малайлар кычкырышканы, суга килгән хатыннарның сөйләшкәннәре ишетелә. Шул арада Фәридәгә агачлар арасыннан бер нәрсә чытырдап киткән төсле була. Фәридә эченнән генә: «Рөстәм абый йөри булыр... Очраса ни дип сүз башлыйм инде? — ди.— Әй ходаем, үзең ярдәм бир!» ди. Ул арада булмый, куаклар арасындагы кеч-кенә сукмактан, шпораларын шалтыратып ялт итеп Касыйм килеп чыга һәм Фәридәне көтмәгәндә очраткан төсле итеп:

— Ә, мамзель Фәридә, сезмени! — ди, килеп Фәридә белән исәнләшә, бик каты аның кулын кыса. Ялтыраган күзләре белән аңар йотардай булып карый: «Мөмкин булса, мине дә үзегез белән алыгызчы!» ди. Һәм җавап көтеп тормый, Фәридә белән бара башлый. Рөхсәт сорап-нитеп тормый, аны кысып кына култыгына ала. Фәридә бөтенләй аптырап кала, ни дип җавап бирергә белми. Касыйм исә:

— Фәридә, сез минем белән уйныйсыз, мине шаяртасыз, мин инде сезнең аркада төннәр дә йоклый алмыйм, көне-төне мучиться итәм[1]. Ә сез һаман, монахиня төсле, мине яныгыздан куасыз. Менә инде миңа хезмәткә китәргә дә вакыт җитә, ә мин сездән әле һаман да бер юньле күз карашы да күргәнем юк,— ди.

Алар инде бакчаның аргы башына, иң аулак җиренә якынлашалар. Фәридә: «Инде ничек кенә моның кулыннан ычкыныйм икән?» ди. Шуның артыннан ук:

— Касыйм абый, мине җибәрегезче, минем эшем бар иде! — ди.

Касыйм исә аны култыгына тагын да ныграк кысып:

— Әйе, мин сезне сөям, дөньядагы бөтен нәрсәдән артык сөям һәм сез мине үзегездән никадәр кире каксагыз да, мин шул кадәр азапланууларым өчен бер награда[2] алмыйча китәргә риза түгелмен. Әйе, мин риза түгелмен. Сез мине малай дип уйлыйсыз булыр, ләкин мин сезгә үземнең малай түгел икәнлегемне күрсәтә алырмын,— ди.

Инде аның тәннәре калтырана башлый. Фәридә:

[1] Мучиться итәм — газапланам.

[2] Награда — бүләк.

— Касыйм абый, зинһар, җибәрегез мине, җибәрегез дим ич инде! — дип тартына башлый.

Шул арада Касыйм көчле куллары белән аны нечкә гәүдәсеннән кысып кочаклап ала да битеннән үбә башлый. Фәридә кычкырырга тели, ләкин булдыра алмый — инде аның башы әйләнергә, күз аллары караңгыланырга тотына. Ул инде бер нәрсә дә белми, Касыймның ялтыраган күзләренә карый да карый. Касыйм һаман вәхши хайван төсле аны уа, битләреннән үбә, әллә нинди исемнәр белән атый.

Фәридә бераз онытылып тора. Шул арада аның колагына Рөстәмнең борын эченнән генә теге мәгълүм көен шыңшыганы ишетелеп киткән төсле була. Ул тиз генә күзен ача һәм үзеннән биш адым чамасы ераклыктагы аптырап катып калган Рөстәмне күреп ни эшләргә дә белми.

— Уй! — дип бик каты кычкырып җибәрә.

Башта ул Касыймнан ычкынуына Рөстәм абзасына атылырга, аңар Касыймның үзен тәхкыйрь[1] итүен, бөтенесен сөйләп бирергә уйлый, ләкин никтер курка һәм кулы белән битен уалап өйгә йөгерә. Касыйм бер йөгереп киткән Фәридәгә, бер үлек төсле ап-ак булган абзасына карый да:

— Әллә нәрсә булды шунда! — дип чырт иттереп бер төкерә һәм, һич нәрсә дә булмаган шикелле, сызгыргалап икенче якка китә. Рөстәмнең энесенә дә, Фәридәгә дә, үзенә дә — кыскасы, бөтенесенә чиксез ачуы килә. Бу манзараны күргәннән соң, ул Фәридәнең Касыймны яратуына аз гына да шөбһә итми. Аның башы бөтенләй бушап калган төсле була, тамак төбе кибә, ул тиз генә беседкасына бара да бер нәрсә турысында да уйлый алмыйча, караватына йөз түбән ята. Аның ничек тә булса бу авырлыктан онытылып торасы, аларны күрмәс өчен беразга гына булса да күзен йомып торасы килә. Торып суык су эчеп карый — булмый, күңелендәге авырлык һаман да басылмый. Инде тышта тәмам караңгылана. Рөстәм бүлмәсендә ут ягып-нитеп тормый, һаман бер урында ята бирә. Аңар вакыт зерә дә акрын узган төсле тоела. Ул аталары янына кичке чәйне эчәргә дә бармый.

## XIII

Икенче көнне ул соң гына уяна. Күңелдәге теге авырлык һаман да бетмәгән була. Ул инде беседкасында ялгыз калырга курка, аның кем белән булса да утырышасы, сөйләшәсе килә. Ул беседкасында гына аннан-моннан гына чәй эчә дә, Хисамига ат җигәргә куша, эченнән генә:

— Шул карт доктор янына барып утырыймчы, беразрак күңел ачылмасмы? — ди. Озак та үтми, Хисами:

— Әйдә, киттекме, атлар җигелде,— ди.

Рөстәм дә юл кожаны белән искерә төшкән студент тужуркасын киеп тарантаска чыгып утыра.

Зөләйха абыстай тәрәзәдән ачык йөз белән:

— Бүген кайтасың булыр бит? — ди.

Рөстәм аңар:

— Кайтырмын,— ди.

Юлда барганда Дим буендагы киң болыннарны, ерактагы урманнарны күрү, кошлар сайраганын ишетү белән аның күңеле азрак тынычланган төсле була, ләкин бу озакка бармый — аның йөрәген тагы әллә ни тырный башлый. Ул Хисамига үтенгән-ялынган сыман иттереп:

— Әйдә әле, туган, атларны бар хәлгә бер чаптыр әле! — ди.

[1]Тәхкыйрь итү — мыскыллау, хурлау.

Хисами да үзенең кайгысыз тавышы белән:

— Була ул, була торган йола ул! — дип дилбегәләрне ипләп кенә тота, бүреген басыбрак кия дә атларга да:

— Әй, малкошлар, әйдәгез әле, бер селкенеп карыйк! — дип һәрберсенә икешәр мәртәбә суга, атлар да бар хәлләре белән чаба башлыйлар. Тарантас та сикереп-сикереп китә.

Рөстәмгә офыктагы таулар, болыннар, еракта ы беленер-беленмәс кенә торган авыллар, алар янындагы озын канатлы җил тегермәннәре кирегә таба йөгергән шикелле булалар. Ул:

— Менә шулай кирәк, менә шулай! — ди.

Өйлә алларында алар матур гына су буена утырган кечерәк кенә бер урыс авылына җитеп, больница янындагы җыйнак кына бер өйгә туктыйлар. Аларга каршы озын гына буйлы, пеләш башлы, ябык кына йөзле, агара башлаган сакаллы илле биш яшьләр чамасындагы доктор Соколов үзе чыга. Рөстәмне күрү белән аның авызы ерыла, ул чын күңелennән:

— Ә, коллега Рөстәм Исхакович икән! — ди, аның белән гаять дустанә күрешә, искә төшереп килүенә чын күңелennән рәхмәт укый.

— Күптән кайттыгызмы, нигә миңа килмәдегез? Үзегез дә беләсез ич, мин сезне, яшьләрне хөрмәт итәм. Соң ничек, имтиханнар шәп чыктымы? — дип бер юлы әллә ничә сөаль бирөп ала.

Өйгә кереп утыруга, ул асравына самавыр куярга һәм нәүрәптән коньяк алып чыгарга куша; үзе исә Рөстәмнең бик ихлас белән университет хәлләрен, андагы укуларны, Мәскәүдәге үзенең танышларын сорашырга башлый, Рөстәм дә аңарга иренеп кенә җавап биреп утыра.

Доктор Соколов үзе гаять дәрәҗәдә яхшы белемле, урыны килгәндә, кешегә ярдәм итәргә, төпле генә киңәшләр бирергә ярата торган бер карт була. Атасы фәкыйрь генә бер поп булса да, ул семинария бетергәч, үзенең истигъдаты, түземлеге һәм чиксез үзенә ышануы аркасында Мәскәү университетына кереп укый; вакытында яшьләрнең иң эшлеклесе исәпләнә. Үзе сөйләргә яратмаса да, аның башыннан бик күп авырлыклар үткән, ул байтак кына ачлыклар татыган була. Ахырында ул үзенең түземлеге аркасында дарелфөнүнне бетереп, эшлекле генә бер доктор була, тормышы яхшы гына рәтләнә. Баштан үткән авырлыклар анда яхшы гына эз калдыралар. Ул кешенең кайгысын аңлый белә, авыл халкының тормышы начар икәнен ул күрә һәм, хәленнән килгән кадәр, аларга ярдәм итәргә тырыша. Һичбер вакыт кеше өчен иренми, үзенең шул кара халыктан чыкканын бер вакытта да онытмый. Якташлары да аны тәкъдир итә беләләр: урысы, татары — бөтенесе: «Василий Василич!» дип аның өчен үлеп китәләр. Ул үзе өйләнми һәм, гомумән, гаилә тормышына, хатын-кызга кырын карый. Әгәр бер-бер мәҗлестә ирләр арасында хатын-кыз, саф мәхәббәт турысында сүз чыкса, ул бер стакан аракы эчә дә әкрен генә чит бүлмәләрнең берсенә барып утыра һәм ул көнне аның авызыннан бер нәрсә дә ишетеп булмый: аның чырае киткән була, күзләре әллә нинди кайгылы һәм өметсез карыйлар. Ул һаман ара-тирә барып-барып эчкәли, ахырында ярыйсы гына исергән килеш, беркем белән дә күрешми-нитми өенә кайтып китә. Мәҗлестәгеләр аны кызганалар. Алар арасында докторның яшь чагында әллә нинди бер бәхетсез мәхәббәткә бирелеп тә сөйгәне тарафыннан алданганына даир[1] бер риваять йөри. Аның бу мәхәббәте турындагы имеш-мимеш хәбәрләрнең дөрес булып-булмаганын беркем дә белми, чөнки доктор аның турысында сөйләргә яратмый. Ул инде яхшы гына картайган була, шулай да ул әле һаман да армый-талмый эшли. Буш вакытларында китап укый. Әгәр дә тирәякта бер-бер мәгълүматлы яшь кеше кайтканны белсә, ничек тә аның

[1] Даир — бәйле, шул хакта.

белән таныша, аннан хәзерге заман яшьләрен, алар арасында йөргән идеалларны сораша. Ул ара-тирә матур гына иттереп эчәргә ярата һәм урыны чыкканда: «Бер бутылка коньяк белән киңәш итеп, чәй эчү мәгънәсез кеше белән юкны бушка төяп утырудан бик күп артык», дигән була.

Менә инде Рөстәм: «Күңел ачылмасмы?» дип, шушы картка килә, ләкин аның күңеле һаман да тынычланмый, ул докторның сөальләренә иренеп кенә җавап биргәләп утыра. Менә инде алар әкрен генә чәй эчәргә утыралар. Доктор:

— Сез, иншалла, чәйне коньяк белән эчүгә каршы тормыйсыз булыр бит, эч пошкан чагында ул бик яхшы тәэсир итә,— ди.

Бу вакыт Рөстәмнең күңеленә: «Тукта әле, болай итеп карарга кирәк», дигән уй килеп төшә, ул әкрен генә:

— Мөмкин булса, миңа бөтенләй тутырып бер стакан салып бирегез әле,— ди.

Доктор аңар гаҗәпсенеп карый:

— Коньякны алай күп истигъмаль[1] итәргә ярамый бит! — ди.

Рөстәм:

— Мин анысын үзем дә беләм, ләкин бер юлга миңа ул кануннан чыккач та ярый, салыгыз әле,— ди.

Доктор:

— Бу елдагы яшьләрне аңлап бетерә алмассың, алар дөньяга бөтенләй икенче күз белән карыйлар,— дип Рөстәмгә берне салып бирә. Рөстәм дә берьюлы аны эчеп җибәрә. Аның тәннәре калтыранып китә, теге эчтәге уңайсызлык та басылган төсле була. Гомумән, эчеп өйрәнмәгәнгә күрә, ул бер стаканнан ук исерә башлый. Ул тагы аз-аз гына эчә. Аның инде эчендәге бар авырлыгын шул мөлаем йөзле картка сөйләп бирәсе, аннан киңәш сорыйсы килә.

— Сез, Рөстәм, бу ел бик үзгәргәнсез, сез дөньяга өметсез караган төсле күренәсез, яшь кешегә алай булырга ярамый бит ул,— ди карт.

— Әйе, әйе, Василий Васильевич, мине дөнья үзгәртте. Дөресен генә әйткәндә, дөнья мине бик нык алдады, минем бөтен якты өметләремне бушка чыгарды. Мин хәзер эчемдә чиксез бушлык хис итәм. Миңа хәзер бөтен кеше үземне алдалар, минем кадерле тойгыларымны, каршымда газиз булган бөтен нәрсәмне аягы астына салып таптар төсле,— дип җавап бирә. Шуның артыннан ук киная белән генә үзенең бер кызга кечкенәдән үк гашыйк булганын һәм хәзерге көндә аның тарафыннан алданганын сөйли: — Менә инде шуннан соң миңа бөтен дөньяның кызыгы китте. Мин үземне Сахраи кәбирдә[2] адашкан кеше төсле ялгыз хис итәм,— ди.

Ул тагы тутырып кына берне эчә. Доктор да аңар иштиракъ[3] итә. Инде ул да кыза төшә. Ул әллә нинди бер сынык, өметсез тавыш белән:

— Хәзер инде мин сезне аңладым,— ди.— Әйе, мин сезне аңладым. Яшермичә миңа әйтүегезгә рәхмәт; ихтимал, бирәчәк киңәшемнән файда да итеп куярсыз. Бар иде вакытлар: мин дә, сезнең шикелле, якты хыяллар белән ләззәтләнеп йөри, киләчәгемнән әллә ниләр өмет итә һәм өмет иткәннәремнең бөтенесенең булачагына ышана идем. Ул чагында минем хатын-кызга да иманым чиксез зур иде. Мин аларның ирләргә һәм бөтен җәмгыяте бәшәриягә[4] тәэсирләре зурлыгына; гали[5] хисле бер кызның кулында нинди генә каты күңелле ирнең дә рәткә килүенә, хатыннарның авызыннан чыккан һәрбер хакыйкатьнең тормышта үзенә зур урын табуына чын күңелемнән ышана идем. Әйе, мин хатын-кызны тәгъзыйм итә, аларга табына идем һәм минем аларга

[1] Истигъмаль итү — файдалану, куллану.
[2] Сахраи кәбир — зур чүл (Төньяк Африкадагы Сахара).
[3] Иштиракъ — кушылу, иярү, булышу.
[4] Җәмгыяте бәшәрия — кешелек җәмгыяте.
[5] Гали — олы.

карашымда һичбер пычрак хисләр юк иде. Кайчакларда мин күз алдыма бер мәгъсүм кыз белән очрашуыбызны, аның белән бер-беребезне яратышып, бергә тора башлавыбызны, аның мине көннән-көн ислах[1] итүләрен, аның белән бергә халыкка хезмәт итүләребезне фараз итә идем. Озак та үтми мин андыйга очрадым да. Ул тәмам мин дигәнчә иде, ләкин берсе генә мин уйлаганча барып чыкмады, ул да: кызым бер матур гына көнне мине ташлап, бер бай артистка ияреп заграницага китте. Мин дә, үги ана тарафыннан урманда адаштырылган бала шикелле, үземнең татлы хыялларым белән япа-ялгызым калдым. Билгеле, миңа башта бик авыр булды. Мин әле анда, әле монда сугылдым, үзем өчен инде дөньяда кызык калмаган төсле тоелды...

Доктор туктап ярты стакан коньяк эчә дә тагын сүзендә дәвам итә:

— Әле бездә хатын-кыз дөньяга үзенең ни өчен җибәрелгәнен, үзендә нинди зур көчләр яшеренеп ятканын үзе дә белми,— ди.— Әдәбиятыбыз да, аларда гали, мөкаддәс хезмәткә мәхәббәт уяндырасы, аларны шул юлга өндәү урынында, аларның башын әллә нинди юкбар нәрсәләр белән тутыра. Ирләребез һаман да аларга үзләренең хайваниятләрен үтәргә генә ярый торган мәхлуклар дип карыйлар һәм аларны шул юлда тәрбия итәләр. Табигый, мондый мохит эчендә үскән кызларыбызга безнең шикелле кара эшчеләр ошамый; алар безне тупас, рухсыз, диләр. Шуңа күрә безгә, уңайсыз булса да, ялгыз яшәргә, өстебезгә йөкләнелгән бөтен авырлыкны үзебезгә генә күтәрергә туры килә. Ихтимал, килер бер көн, хатыннарыбыз үзләренең вазифаларын, җәмгыяте бәшәрия каршындагы мәсъүлиятләрен[2] аңларлар...

Доктор бераз туктап тора да, тагы сүзендә дәвам итә:

— Менә, туган, нәрсә: сүзне озайтуда мәгънә юк. Хәлең авыр икәнен үзем дә күрәм. Ләкин аңар бөтенләй бирелергә, корган планнарны бер кызның алдавына карап болай җимереп ташларга ярамый. Минемчә, менә сез ни эшләгез: тотыгыз да моннан китегез, ныклап эшкәябышыгыз. Әле сез яшь кеше, иң әүвәл мәгълүматны, практиканы арттырырга тырышырга кирәк, безнең докторларга ансыз булмый. Әгәр дә дәртегез бар икән, заграницага барып азрак укыгыз. Минемчә, моннан да артык юл юк. Югыйсә сез монда бөтенләй ялкаулыкка бирелерсез. Әтеге кызыгызны бөтенләй истән чыгарырга, авыр булса да, онытырга тырышыгыз. Аннан файда чыкмас.

Ярыйсы гына исергән Рөстәм аны аптырап тыңлап тора, докторның сүзләрен аңлаган да, аңламаган да төсле була. Ул:

— Әйе, китәргә, бөтенесен ташлап китәргә кирәк,— ди.

Инде самавыр күптән сүнгән, икенче шешә коньяк та яртылашкан була. Рөстәм тагы эченнән генә: «Әйе, китәргә кирәк, китәргә,» ди.

Шуның артыннан ук аның күңеленә: «Өйгә кайтырга да инде вакыт», дигән уй килә. Ул әкрен генә урыныннан тора да:

— Ярар, Василий Васильевич, яхшы киңәшегезгә рәхмәт, мин китим, мәшәкатьләгәнем өчен ачуланмагыз,— ди.

Алар кулларын кысышып бик озак торалар. Доктор Рөстәмне китмәскә кыстый, ахырында бик үтенгәч кенә җибәрә һәм күздән югалганчы озатып кала. Аңар Рөстәм никтер бик якын тоела, аңар карап ул үзенең яшь чакларын, ул вакыттагы тойгыларын, яшьлектәге йөрәгенең сызлануларын һәм алдануларын искә төшерә. Аңар никтер бик авыр булып китә. Аның шул Рөстәм шикелле янасы, сызланасы килә. Ул эченнән генә: «Бар да инде үтте, мин ялгыз,» ди.

Күктәге аксыл болытлар, еракта урман белән кырлар — бөтенесе Рөстәмгә бертуктамый әйләнгән төсле тоела. Ул күзен бер нәрсәгә текәп карарга тели, ләкин булдыра алмый: бөтен нәрсә әйләнә дә әйләнә. Инде эчтә дә ул чаклы авыр түгел. Кайчагында аңар Хисаминың

---

[1] Ислах итү — агарту, үзгәртү.

[2] Мәсъүлият — җаваплылык.

атлар куалаганы: «Үтте ич рәхәт җәйләре-е-е», дип сузып җырлаганы ишетелгән шикелле була. Ул кучерның каешланып беткән аркасына мәгънәсез генә бераз карап тора да, эченнән генә: «Әйе, үтте инде, бар да үтте,» ди; тагы онытыла. Атлар һаман алга чабалар: аларны Хисами һаман кыздыра. Ул Рөстәмгә әйләнеп нәрсә турысындадыр бик озак сөйли, ләкин Рөстәм аның сүзләреннән берничә дә аңламый.

Эңгер-меңгер чагында алар өйгә кайтып җиталәр. Ишек алдына барып керүгә иң әүвәл Зөләйха абыстай каршы чыга:

— Нихәл, бәбкәм Рөстәм, исән йөреп кайттыңмы? Ни эшләп ул кадәр озак тордың? Без инде бүген кайтмассыңдыр дигән идек,— ди.

Рөстәм әкрен генә тарантастан төшә. Анасына, билгеле, берни дип тә җавап бирми. Шул арада өйдән Касыйм да килеп чыга һәм, тәҗрибәле, дөнья күргән кеше булганга, күрүенә эшнең нидән гыйбарәт икәнен аңлап ала. Ул тиз генә абзасын җитәкли:

— Һәй, андый эшләр була ул. Әйдә әле, без матур гына итеп йоклап алыйк,— ди.

Зөләйха абыстай әле һаман эшне аңлап җиткерә алмый. Ул аптырап:

— Ни булды соң, бәбкәм, сиңа болай? — ди, үзе Рөстәмгә якынрак бара. Шул арада аның борынына эчемлек исе килеп бәрелә. Ул да, кинәттән башына суккан кеше шикелле, бер урында катып кала. Чиксез аптыраган тавыш белән:

— Әй, бәбкәм, бәбкәм! — ди дә туктый.

Рөстәм, аның тавышын ишетүгә, айнып киткән төсле була, ул аналык шәфкате белән әйтелгән шул сүзләрдән әллә нинди тирән мәгънәләр аңгара. Бу вакыт анасы аңар зерә дә кызганыч тоела, ул нинди дә булса бер сүз әйтергә тели, ләкин булдыра алмый, тик:

— Әни, миңа ачуланма! — ди.

Аннан ары аның башы тагы әйләнә башлый. Зөләйха абыстай:

— Ярый-ярый, бар инде үз урыныңа. Атасына әйтә күрмәгез инде,— ди, үзе әкрен генә өйгә кереп китә.

Касыйм абзасын беседкасына илтеп яткыра. Рөстәм дә тиз генә тирән йокыга китә.

Зөләйха абыстай өйгә керүенә еларга тотына. Ул әлегә чаклы Рөстәмне тәүфикълы, юаш улы дип йөри һәм хәзер аның да Касыйм төсле икәнен белгәч, аңар чиксез авыр була. Шул арада аның янына Фәридә килеп керә. Ул тәрәзәдән Рөстәмнең кайтканын күрү белән аның исерек икәнен һәм ни өчен эчкәнен белә:

— Әй, ходай кәрим[1], рәхим[2], мин нишлим? Инде тагы ниләр генә күрәсем бар икән! — ди дә еларга ябыша.

Теге Рөстәм белән бакчада очрашканнан бирле инде ул һичбер рәхәтләнеп йоклый алмый: көне-төне Рөстәмгә ничек итеп үзенең гөнаһсыз икәнлеген исбат итәргә уйлап йөри ләкин бернәрсә дә булдыра алмый, башына мең төрле уйлар килеп китә, ләкин алар берсе дә эшкә ярамыйлар. Кайчагында ул Рөстәмгә бөтенесен сөйләргә дип карар биреп куя, ләкин үзе, аңар бөтенесен сөйләп бирү түгел, аның белән очрашырга да курка. Хәзер ул Рөстәмнең ни өчен эчеп кайтканын белә, шуңар күрә аның өчен Зөләйха абыстайдан да бигрәк кайгыра.

Залда караңгы була. Фәридә әкрен генә Зөләйха абыстай янына бара, аңар үзенең елаганын белдермәскә тырышып әкрен генә:

— Дәү әни! (Ул һәрвакыт Зөләйха абыстайны дәү әни дип атый.) Еламагыз, дәү әни! — ди.— Мин бик яхшы беләм, Рөстәм абый эчми, ул безнең барыбыздан да яхшы, барыбыздан да саф кеше. Бу юлы аңар эчми мөмкин булмагандыр, аның күңелендә нинди дә булса хәсрәте булгандыр. Әйе, аңар авыр булгандыр, ул да аптыраганнан гына эчкән-

[1]Кәрим — бөек, газиз.
[2]Рәхим — шәфкать.

дер. Мин аны бик яхшы беләм, иртәгә ул үзе дә бу эшенә үкенер, газапланыр һәм, алла боерса, үзегез дә күрерсез, ул сездән килеп гафу сорар. Анакаем җаным, кил, зинһар өчен аңар ачуланмагыз! — ди, Зөләйха абыстайны кочаклый, һәм аның ачуланмавына бик нык ышанган төсле итеп: — Ачуланмыйсыз бит, анакай? — ди.

Зөләйха абыстайга Фәридәнең сүзләре яхшы гына тәэсир итә. Аның күңеле азрак тынычланган төсле була. Рөстәм инде аңар тагы юаш, акыллы, тәүфикъле, сөекле Рөстәм булып күренә. Ул Фәридәнең башыннан сыйпап:

— Шулай шул, бәбкәм, бик дөрес, яшь чагында әллә ниләр дә була ул,— ди.

Алар инде икесе дә тынычланалар. Фәридәнең үз сүзләре үзенә дә тәэсир итә: аңар инде иртәгә Рөстәм абзасына барып бөтенесен сөйләп бирү бик ансат булыр төсле тоела. Ул инде эшләрнең тагы рәтләнәчәгенә, Рөстәмнең үзенә тагын ачык йөз белән карый башлаячагына чынлап ук ышана һәм шулай татлы хыялларга чумган килеш таң алдыннан гына татлы йокыга китә.

Шулай, яшь йөрәк киләчәк өчен төрле якты уйлар кора, аларга чын күңеленнән ышанып юана һәм алдагы якты көннәрне түземсезләнеп көтә — тәкъдир, төрек шагыйрьләренчә әйткәндә, явыз фәләк[1] аңар бөтенләй киресен хәзерли.

## XIV

Рөстәм иртәгесен соң гына уяна. Башта ул үзенең кая икәнен белми, тик аптырап түбәгә карый, баш авырта, кыйнап ташлаган кешенеке шикелле, бөтен җирендә әллә нинди бер авырлык, авызында бер тозсызлык тоя, йөрәкне нәрсәдер тырный. Башының авыртуыннан ук кичә генә ниләр булганы күләгәләр шикелле әкрен генә берсе артыннан берсе аның күңеленә килә. Аның никтер үзенә чиксез ачуы кабара. Ул эченнән генә: «Докторга бару анысы яхшы эш, тик нәрсәгә инде, итекче төсле, эчеп кайтырга!», ди, үзеннән-үзе җирәнеп идәнгә тач иттереп бер төкерә. Беседкада салкын, дымлы була, тышта сибәләп вак кына яңгыр ява. Рөстәм өстәлдән тәмәкесен алып кабыза да, тагын барып ята. Өстенә ябынып җылынырга тели, ләкин булдыра алмый. Әллә нинди кызыксыз уйлар, мәгънәсез сөальләр йөри, котыртырга теләгән шикелле берсе артыннан берсе күңелгә киләләр. Ул тиз генә урыныннан торып киенгән, битләрен юганнан соң, тәмәкесен кабызып, тиз-тиз генә идән буйлап йөрергә тотына. Эченнән генә:

«Әйе, докторның сүзе дөрес, ничек тә моннан ычкынырга, чынлап эшкә ябышырга кирәк, югыйсә, алла сакласын, монда акылдан язарсың. Бөтенесен ташларга да, бүген-иртәгә кая булса да китәргә кирәк», ди. Инде тәмам китәргә карар биреп куя.

Озак та үтми, аңар чәй китерәләр. Ул иренеп кенә эчә. Шул арада аның янына Касыйм килеп китә: «Баш авыртмыймы? Әллә үзеңә азрак китеримме?» — ди.

Рөстәмнең аңар ачуы килә. Ул энесенә ни дип тә җавап бирми. Көннән-көн буе аны ике нәрсә борчый: берсе ничек тә булса анасын күреп тынычландыру, аңар үзенең бозык кеше түгеллеген аңлату, икенчесе — моннан киткәч, кая барырга һәм нәрсәгә ябышырга, тормышның бушлыгын нәрсә белән тутырырга икәнен билгеләү.

Инде аңар бернәрсәдә дә кызык юктыр төсле тоела. Шулай да ул бик озак уйлагач, иң әүвәл Мәскәүгә барырга карар бирә: «Анда баргач күз күрер әле», ди.

Кич алдыннан аның янына Зөләйха абыстай килә. Ул инде эченнән

[1]Фәләк — язмыш, тәкъдир.

генә күптән узган кичәге эш өчен, улын гафу иткән була, тик индедән соң аның яман эш артыннан йөрмәвен үтенергә тели һәм беседкага килеп керүенә йомшак кына тавыш белән Рөстәмнән исәнлек-саулык сораша. Аның тавышын ишетү Рөстәмгә бик каты тәэсир итә; аның Зөләйха абыстайны кочаклап аңар үзенең алдануларын, бөтен якты өметләренең бушка чыгуын сөйләп бөтенесеннән зарланасы, елыйсы килә. Эченнән генә бер тавыш аңар: «Синең якын кешең бары шул гына бит инде», дигән төсле була. Бу вакыт ул үз-үзенә дә чиксез кызганыч тоела. Ул инде анасыннан гафу үтенеп торырга хаҗәт тә күрми. Бераз тора да:

— Анакай, мин иртәгә беразга Мәскәүгә китәм, азрак эшләр бар иде. Әлбәттә, сез мине җибәрерсез. Мин анда озак тормам,— ди.

Зөләйха абыстай:

— Мәскәүдән яңа гына кайттың ич әле. Азрак безнең янда тору кирәк иде,— ди.— Хәер, инде без сине тота алмыйбыз. Китәсең килә икән кит,— ди.

Тагын ул шуның артыннан ук нәрсәдер әйтергә тели дә, булдыра алмый, аның еларга теләгән шикелле иреннәре калтырана башлый:

— Җаным, бәгърем Рөстәм, кил, алла разый булсын, юк-бар артыннан йөреп минем йөрәгемне өзмә. Минем инде Касыйм белән мәрхүмә Кәримә өчен елый-елый да күзләрем калмады,— ди. Рөстәм аны төрле сүзләр белән юата, яхшы булырга вәгъдә бирә. Бу вакыт ул моннан киткәч, үзенең чынлап торып эшкә башлавына үзе дә ышана.

Зөләйха абыстай киткәч, ул үзендә бер җиңеллек хис итә: «Аллага шөкер, анакай ачуланмаган икән әле», ди.

Инде җир йөзен тәмам караңгылык томалый. Кич алдыннан азрак басылып торган яңгыр тагы иренеп кенә ява башлый, салкын җил өрә.

Мирзаның өендә инде ут күренми: бар да йоклыйлар, тик Фәридә генә йоклый алмый. Аның инде башы әйләнгән, уйлары таралган. Аның йөрәген: иртәгә Рөстәм китә, дигән уй тырный. Шуның артыннан ук аның күңеленә: «Мин инде аның каршында алдакчы, очраган бер ир белән йөри торган начар кыз», дигән уй килә. Бу уй аңар бик авыр тәэсир итә. Ул уйлый-уйлый да: ни булса да булыр, хәзер барып, үзенә бөтенесен сөйләп бирим, бөтенесен аңар аңгартыйм!» ди. Һәм шул ният белән ул әкрен генә торып ишек алдына чыга. Бакчада кот очарлык караңгы була. Вак кына яңгыр сибәләп ява, җил өрә, тәрәзә капкачларын шалтырата, бакчадагы агачларны селкетә. Күңелгә әллә нинди куркынычлы уйлар килә. Бөтен тормыш шушындый караңгы, суык төннән гыйбарәттер, аны яктырткан бер йолдыз да юктыр төсле тоела.

Фәридә курка-курка гына бакча эчләп беседкага якынлаша. Үзе калтырана, йөрәге еш-еш тибә. Менә инде ул беседкага да килеп җитә, ләкин туры анда барып керергә курка, иң әүвәл тәрәзәдән барып карый. Күрә: кечерәк кенә бер лампы белән яктыртылган беседканың эче туздырылган. Идәннең бер читендә төйнәлгән бер зур гына биштәр тора, аның янында ачылган зур гына бер кәрзинке күренә. Әле анда, әле монда кәгазьләр, гәзитләр аунап ята. Өстәл өстендәге китаплар бар да туздырылганнар. Рөстәм исә үзе искерә төшкән студент пальтосын иң башына салып тәмәкесен тарта-тарта идән буйлап әрле-бирле йөренә, кашларын җыерып нәрсә турындадыр уйлый, үзе борын эченнән генә теге иләмсезрәк тавышы белән нәрсәдер шыңшый, аның озын чәчләре тузган, чыраe киткән. Фәридә аңар бик озак аптырап карап тора. Җил һаман өрә, бакчадагы агачлар шаулый. Рөстәмнең борын эченнән генә шыңшыганы ишетелә. Фәридә эченнән генә хәзер кереп аңар бөтенесен әйтергә тиешлеген белә, ләкин никтер ишек ачып аның янына керергә базмый. Ул ишек янына барып әллә ничә мәртәбә ача башлый, ләкин нindидер куәт аны туктата. Ул үзен-үзе: «Куркак, булмаган нәрсә!» дип ачулана. Тагын гайрәтләнеп китеп ишек тоткасын тота, ләкин булдыра алмый. Рөстәм һаман каты-каты атлап идән буйлап йөри.

Фәридә бик озак үзе белән тартышып, ахырында суыктан калтыранган рухы төшкән хәлдә, караңгы уйлары янына өйгә кайтып китә, Рөстәм белән аңлаша алмый.

## XV

Карт мирза икенче көнне үз бүлмәсендә Рөстәм белән исәнләшкәндә аңар ике йөз тәңкә акчаны тоттыра да түбәгә карап:

— Гаспадин[1] дуктыр (ул «дуктыр» дигән сүзне никтер бик каты әйтә), син үзең дә беләсең, без бала җанлы, сез теләгәнне, начармы-яхшымы икәнен тикшереп тормый, эшли бирәбез. Сезгә акча дисәң — акча хәзер, ат дисәң — ат хәзер, берсеннән дә тоткар юк. Әйе, без сезнең өчен бер нәрсә дә кызганмыйбыз. Сезгә дә шуның кадерен белергә, без тапкан малны юк-бар нәрсә артыннан йөреп, әрәм итмәскә тиеш,— ди, шуның артыннан ук кемгә дә булса ачуланган сымак итеп чыраен сытып: — Әнә, Касыймың, күрәсең бит, ни эшләр тудырып йөри! Аларны күрү безгә ансат дип беләсеңмени? Менә үзегез бала үстереп карагыз әле, шунда ничек икәнен белерсез,— ди.

Рөстәмгә аның «гаспадин дуктыр» дип башлаган сүзе, тагы шунда балалары өчен үзенә бернәрсә кызганмаганнарын искә төшерүләре әллә ниндирәк тәэсир итә, ул аны кызганырга да, кызганмаска да белми. Ул:

— Мин бит, атакай, әлегә кадәр сезгә үземне начар яктан күрсәткәнем юк, индедән соң да күрсәтмәм дип уйлыйм,— дип җавап бирә.

Карт моны ишетүгә азрак йомшый төшеп:

— Анысын мин үзем дә бик яхшы беләм. Рәхмәт, әлегә кадәр начарлыгыңны күрсәткәнең юк. Тик индедән соң ул-бу булмасын иде дим,— ди.

Рөстәм эченнән генә: «Инде карт ул-будан нәрсә уйлый икән тагы?» дип куя.

Аны озатырга бөтен өй җәмәгате чыга. Бөтенесе белән исәнләшкәннән соң, Рөстәмнең күзе читтә генә: «Күрешим микән, күрешмим микән», дигән төсле боегып торган Фәридәгә төшә. Бу вакыт ул аны никтер кызганып җибәрә һәм ирексез ачык тавыш белән: «Фәридә, син дә сау бул!» ди. Фәридә моны ишетүгә сискәнеп китә, ашыгып кына Рөстәм абзасына кулын бирә һәм каушавыннан бер нәрсә әйтә алмый, тик аңар бер тутырып кына карый. Шул арада атлар кузгалып китә. Фәридәнең күз аллары караңгылана башлый, тамак төбенә нәрсәдер килеп тыгыла. Аның бик каты: «Рөстәм абый, мине дә үзең белән алып кит!» дип кычкырасы, аның артыннан йөгереп барасы килә. Ул тиз генә хәл җыя да үз бүлмәсенә, үзенең кара бәхете өчен кайнар күз яшьләрен агызырга йөгерә.

Көн аяз, җылы, һава да тын була. Тик ара-тирә тургайлар сайраганы гына ишетелә. Хисами кучер кырга чыккач, атларын бер көйгә сала да үзе, гадәте буенча, гадәттәге көйләрен сузарга, рәхәт җәйләрнең үтүеннән зарланырга, Хәйриҗамалның француз яулыгын тәгъриф[2] итәргә тотына; аның уймак шикелле авызыннан алдап, суырып үбә алмаганына үкенә.

Юлчылар зур-зур гына урманнары, сират күпереннән дә куркынычлы күперләрне узалар. Рөстәм әле атасының киткәндә әйткән сүзләрен уйлый, аларның мәгънәсен аңларга азаплана; әле Фәридәнең аерылгандагы үзенә карашын искә төшерә; әле Хисаминың каешланып беткән аркасына текәлеп карый. Аннан ары тагы бу соңгы

[1] Гаспадин — әфәнде.
[2] Тәгъриф — сөйләү.

елларда үзенең башыннан үткән вакыйгалар турысында уйларга тотына.

Атлар һаман чабалар да чабалар. Юл буендагы картаеп беткән каеннар, беленер-беленмәс кенә итеп башларын селки-селки, Рөстәмнең артыннан карап калалар. Аңар инде күптәннән бирле үзе шулай юлда барган, күптәннән бирле Хисаминың шулай: «Үтте ич рәхәт җәйләре-е-е», дип җырлаганын ишеткән, күптән бөтенесе тарафыннан ташланган, рәхәт, тыныч көннәр аңа бер дә булмаган төсле тоела. Ул Мәскәүгә баргач ни эшлисен, анда баргач күпме торасын — берсен дә белми. Башка вакытта бер-бер җиргә барганда аның тизрәк барып җитәсе килә иде, хәзер инде аңар атлар әкрен барсалар ни, тиз барсалар ни — бар да бер.

Мәскәүгә килүенә, ул әч пошудан нишләргә белмичә, аз-аз гына сәфаһәткә[1] бирелә башлый. Васька исемле бер иптәш студенты аңар бу юлда нык кына булыша һәм бик кызып киткән араларда күңелсезләнеп утыра торган Рөстәмгә:

— Их, туган! Пошынмыйча яшә, үлсәң — зыян юк! — дип куя.

Һәр көн иртә белән уянуга Рөстәм үзендә бер авырлык, рухында бер төшенкелек хис итә. Кайчагында Фәридәнең фәрештә шикелле саф вакытлары, аның белән бакчада уздырган төннәре, ахырында аның алдаулары берсе артыннан берсе аның күз алдына киләләр. Йөрәк ачынып сызлана. Рөстәм дә, тормышның кызыксызлыгын күрмәс өчен, тагы тиз генә шул Васьканы алып чегәннәр янына ашыга. Ул сәфаһәткә көннән-көн чума һәм шул килеш тормышның күңелсез, кызыксыз якларын күрмәскә тырыша. Инде ул атасыннан әллә ничә мәртәбә телеграмма белән күп-күп кенә акча да соратып ала. Карт әчендән генә ни кадәр пошынса да, берсүзсез-нисез аңар акчаны җибәреп тора, тик чәй яннарында карчыгына карап тирән генә бер сулый да:

— Үзебез боздык, үзебез,— ди.

Шул килеш берничә айлар үтеп китә. Бу арада Рөстәм тәмам ябыга, кешелектән чыга. Ахырында ул, бу килеш барганда, һичбер рәтле эш чыкмаячагын үзе дә аңлап, ничек тә булса үзен тагын кулга алырга, бу тормышны ташларга, яңадан сызганып эшкә керешергә карар бирә. Үз-үзенә: «Безнең ишеләргә тормышыннан әлләни өмет итәргә ярамый. Эшләргә, эшләргә дә үләргә. Фәридә алдаган өчен дә, башкасы өчен дә үзеңне әрәм итә башласаң, аннан ары ни калыр!»— ди.

Озак та үтми, ул Мәскәүдә үзенең тәрбиялелеге белән шөһрәт казанган бер карт докторның кулы астында хезмәт итә башлый. Һәм шул килеш үзенең мәгълүматын киңәйтергә тырыша. Көннәр узган саен аның ярасы төзәлә: инде ул Фәридә турында күп уйламый, һаман тырышып эшләвендә дәвам итә.

Бер еллар чамасы вакыт узып китә. Рөстәм инде тәмам эзгә баса. Шул арада аны Киевка доктор итеп җибәрәләр. Ул яңа урынга баруга, җитди генә эшкә керешә. Гомумән, ул анда кешегә күп катышмый, үзе генә яшәргә ярата.

Кайчагында кышкы озын төннәрдә, яшь вакытларны уйлый торгач, хиссиятләр бик артык кузгалып китсә, ул, үзенең тәгъбиренчә, азрак күңел тынычландыру өчен, коньяк белән гәпләшеп утыра да белә. Инде ул тормыштан артык бернәрсә дә өмет итми. Озак та үтми, ул шәһәрнең яхшы гына тәҗрибәле докторларыннан исәпләнә, аны затлы гына гаиләләргә дә дәшә башлыйлар.

Күзге караңгы һәм яңгырлы төннәрнең берсендә ул шулай квартирасында ялгыз гына уйланып утыра. Ул төнне аның нигәдер йокысы килми, нәрсәгәдер эче поша. Бу соңгы вакытларда аны ялгызлык

[1] Сәфаһәт — кәеф-сафа.

азаплый. Күп вакыт ул үз-үзенә: «Еллар берсе артыннан берсе үтә, кызыксыз гомер һаман кими», ди. Янында бер якын кешенең булмавы аны көннән-көн борчый. Ул иренеп кенә чәй белән коньягын эчә, үзе һаман уйлана: «Әллә булмаса, шул Сарага өйләнергәме? Һичшиксез ул мине ярата, мин дә аның янында тынычлык хисе итәм. Ихтимал, аның белән тормыш аз булса да кызыграк үтәр иде», ди. Инде төн урталары якынлаша, тышта җилләп һаман яңгыр ява. Рөстәм утырган җиреннән тормый, һаман уйлана да уйлана. Үзенең картлык көннәрен, ул вакыттагы ялгызлыгын күз алдына китерә. Аңар киләчәктә һичбер якынсыз-нисез бик кыен булыр төсле тоела. Ахырында ул Сарага иртәгесен әшне сөйләп бирергә карар бирә: «Ни булса да булыр, гаилә тормышын да бер сынап карарга кирәк», ди.

Бу карардан соң аның күңеле азрак тынычланган төсле була. Шул арада никтер кинәттән аның күз алдына Фәридә килә, аның йөрәге тагы сызылып китә. Бу вакыт аның ничек тә булса, шул иске дусын бер күрәсе килә, шуның артыннан ук: «Ул бит инде бүтән белән йөри», дигән уй исенә төшә. Фәридә турында артык уйламас өчен тутырып берне эчә дә урынына ята.

Сара дигәне инде анысы егерме ике яшьләр чамасында матур гына бер яһүдә кыз була. Алар анасы белән икәү генә үз йортларында торалар. Көнкүрешләре аларның ярыйсы гына була. Рөстәм ул кыз белән менә ничек таныша:

Бер көнне аны төн урталарында бик ашыгыч кына авыру янына алып китәләр. Авыртуның өендә аны төсләре киткән, елый-елый күзләре шешенеп беткән бер матур гына кыз каршы ала:

— Доктор әфәнде, зинһар өчен әнине коткара күрегез!— ди.

Рөстәм аның кырык яшьләр чамасындагы авыру анасын бик дикъкатьләп караганнан соң:

— Зарарлы нәрсә юк, лихорадка гына, без аны хәзер терелдерербез,— дип кызны тынычландыра.

Карчыкның авыруы куркынычлы булганга, Рөстәм кичен аның янында кала һәм сөйләшә торгач, теге кызның Сара исемле икәнен, моннан өч ел элек гимназия бетергәнлеген, хәзер анасы белән икәү генә яшәгәнлекләрен белә. Шул көннән соң ул бер атна буенча һәр көн кич белән Сараларга килә, авыруның хәле докторның тырышуы аркасында көннән-көн яхшыра бара. Сара Рөстәмгә үзенең рәхмәтләрен укып бетерә алмый: «Мин сезнең инсаниятлегегезне[1] гомеремдә дә онытмам, ходай кушса!» ди.

Бер атнадан соң авыру терелә, Сара үзе дә, анасы да Рөстәмгә бик күп рәхмәтләр укыйлар һәм, аның ялгыз кеше икәнен белгәч, вакыты булганда үзләре янына килгәләп утыруын үтенәләр. Рөстәм шушы атна эчендә үзе дә сизмичә, Сарага ияләшеп китә һәм аратирә кичләрен аларга барып утыргалый. Анда бармаган кичләрдә ул үзендә әллә нинди бер эч пошу хис итә. Һәрвакыт шат күңелле Сара аны якты йөз белән каршы ала, тәмле кайнатмалар белән чәй эчерә, матур күзләре белән аңар карый һәм озатканда тагы килүен, аннан башка үзенә күңелсез икәнен сөйли.

Менә Рөстәм шул Сара белән тора башлый: Сара берсүзсез-нисез аның тәкъдимен кабул итә. Алар, икесе дә укыган кеше булганга, гражданский никах белән торырга карар бирәләр.

Рөстәм үзенең өйләнүе турында өйгә бернәрсә дә язмый. Сара башта Рөстәм янында үзен тәмам бәхетле саный. Рөстәм дә үзен бәхетле исәпләргә тырыша, ләкин һәрвакыт аның эчен нәрсәдер тырный, күп вакыт ул ирексез үз-үзенә: «Мин көткәнчә барып чыкмады бу»,— ди.

[1] Инсаниятлек — кешелеклелек, кайгыртучанлык.

Ул, Сара белән ялгыз калганда шатланып-сөйләшеп утырасы урында, аның төсен, кыйланышларын Фәриданеке белән чагыштырып карый. Гомумән, бу соңгы көннәрдә ул Фәридәне еш-еш исенә төшерә. Ул һәр көн сәгать берләрдә, икеләрдә больницадан арып кайта. Сара инде аны күптән көтеп тора һәм ишектән барып керүенә, көләч йөз, ачык тавыш белән:

— Кайттыңмы, Рөстәмчик, милый[1]!— дип ирен каршы ала. Рөстәм исә аңар иркәләп җавап бирәсе урында, бөтенләй икенче нәрсә турында уйлый: «Әгәр дә Фәридә булса, милый» диясе урынга әкрен генә: «Әйдә, Рөстәм җаным!» дияр иде бит ди; шуның артыннан ук: «Бигрәк тә малай икәнмен инде,— дип үз-үзенә ачулана,— Фәридә күптән бүтән белән йөри ич инде!» ди. Сара исә аңар аптырап карап тора. Аш янында Сара гына сөйли, Рөстәм гел күңелсез утыра.

— Син нигә бүген шулкадәр төксе?— дигән сөаленә каршы:

— Беләсезме, бик арыдым мин, авырулар бик-бик күп килде,— ди.

Башта Рөстәм: «Ихтимал, бара-бара мин аңар иялэшермен», дип үзен юатырга азапланса да, көннәр узган саен, ул Сарага салкыная бара, никтер ул аны бөтенләй чит күрә. Бара-бара Сара да күңелсезләнә башлый.

Көннәр берсе артыннан берсе иренеп кенә, күңелсез генә уза. Рөстәм белән Сара арасындагы әллә нинди караңгы пәрдә һаман да бетми. Алар күңелсез яшиләр, ләкин бер-берсенә серне бирмәскә тырышалар.

Бер ел үтеп китә. Октябрь урталарында Рөстәмгә хат килә. Хатны бу юлы Фәридә яза:

«Сентябрь ахырларында атакай кинәттән үлде,— ди,— хәзер без дәү әни белән өйдә икәү генә калдык, инде ни эшләргә дә белмибез, дәү әни көне-төне елаудан туктамый: «Ичмасам балаларым да янымда юк», ди. Бу соңгы айларда Касыймнан һичбер хат-фәлән булмавы аны бигрәк тә борчый. Әгәр дә вакытыгыз булса, үзегез кайтып китсәгез дә яхшы булыр иде, чөнки әгәр дә Гали абый килсә, аның белән гыйнвар ахырларында үземнең Кырымга китүем дә ихтимал: докторлар анда барырга кушалар, сәламәтлегең бик начар диләр», ди.

Рөстәм бу хатны укуга бөтенләй аптырап китә. Көн буе нишләргә дә, ни уйларга да белми аптырап йөри. Сара ул көнне аналарына киткән була.

Кич белән Рөстәм, тәмәкесен авызына капкан килеш, арлы-бирле йөренә, тышта җил өргәнне азрак тыңлап тора да тагы теге иләмсезрәк тавышы белән борын эченнән генә шыңшый башлый; коньяк катыштырган чәен барып эчә дә, өстәл өстендә аунап ята торган хатны тагы бер кат укып чыга. Үлгән атасы да, хәсрәтеннән көне-төне елый торган анасы белән авыруыннан Кырымга китәргә мәҗбүр Фәридә дә, үзе белән Сара да — бөтенесе инде аңар кызганыч кебек тоела. Ул йөри торган җиреннән туктап: «Инде нишләргә?— ди,— бөтенесен ташлап китсәң, уңайсыз, китмәсәң дә...»

Шуның артыннан ук аның күз алдына Фәридә килеп утыра; күңеленнән аның хатындагы: «Инде нишләргә дә белмибез», дигән сүзләре килә, үзе дә мәгънәсез генә итеп: «Инде нишләргә дә белмибез», ди.

Тышта җил һаман өрә, салкын яңгыр ява. Рөстәм тагы бер: «Инде нишләргә дә белмибез», ди. Ябыккан, саргайган Фәридә дә аның алдына килеп тагы бер: «Инде ни эшләргә дә белмибез», дигән төсле була.

[1] Милый — сөйкемле.

## XVI

Рөстәмнең кинәт кенә авылдан китүе, еш-еш кына күпләп акча соратып алдырулары, язган хатында ни белән шөгыльләнгәне, өйгә ни вакыт кайтачагы турында бернәрсә дә язмаулары Исхак мирза гаиләсенә бик нык тәэсир итә. Тагы шуның өстенә Варшавага офицерлык хезмәтенә киткән Касыймнан да рәтле хәбәр килмәве картны бигрәк тә борчый. Ул улларына акча җибәргәндә һәрвакыт: «Менә, карчык, без азапланып еллар буенча җыйган малны улларың ничек җиңел бетерәләр!» ди.

Зөләйха абыстай ни эшләргә дә белми. Рөстәмнең дә болай булып китүе аны бөтенләй аптырашта калдыра. Почтадан хат китерделәрме, ул коелып төшкән төсле була, калтырана башлый: «Инде тагын ниләр генә яздылар икән?! Атасы ачуланмаса ярар иде!»— ди.

Фәриданең инде күләгәсе генә кала. Ул көне-төне Рөстәм турында уйлана, аны күреп сөйләшмәгәнлеге өчен үз-үзенә ачулана, юаш кына, акыллы гына Рөстәмнең болай юк-бар нәрсәгә бирелеп китүен бөтен өй эчендә ялгыз ул гына аңгара: «Инде ул нишләргә белмәгәнлектән аңар ябышкандыр»,— ди.

Кайчагында аның Рөстәм янына Мәскәүгә барып: «Әйдә, Рөстәм абый, кайтыйк, ташла боларның барын да. Мин сине яратам ич», дип әйтәсе килә. Кичләрдә аның күзен йокы алмый. Инде аның рояльдә уйнаган көйләреннән өметсезлек, кара бәхеттән зарлану, ачынып елаулар аңкый. Ул көннән-көн ябыга; көннән-көн саргая бара. Зөләйха абыстай аның башта болай үзгәрүенә аптырый, тик чәй янында Рөстәм турында сүз чыкканда, яисә аннан хат-фәлән килгәндә аның төсе үзгәрүеннән азрак эшнең чын сәбәбен аңгара төшә, ләкин ул турыда Фәриданең үзенә «ләм-мим» дә әйтми. Фәридә балавыз шәм төсле ябыга, ара-тирә йөткергәли дә башлый. Шундый вакытлар җитә ки, аның бөтенләй артык түзәрлеге калмаган төсле була: башы әйләнә, күз аллары караңгылана, йөрәк еш-еш тибә, бик каты кычкырасы, кемнәргәдер ачуланасы, ничек тә булса шул йөрәкне тырнап тора торган авырлыктан котыласы килә... Ахырында ул хәлсезләнеп, урынына барып ята. Мондый вакытларда кинәт кенә аның күңеленә Мәүли әбидән ишеткән: «Хак ни язса, безгә шул булыр, бәлки, шатлык көннәр дә булыр», дигән шигырь килә. Күңел ни өчендер тынычланган төсле була. Ул: «Әйе, бәлки, шатлык көннәре дә туыр. Бу азапланууларның ничек тә бер соңы булыр. Ихтимал, минем өчен дә якты көннәр килер», ди һәм ул якты көннәрнең, кайчан да булса бер киләчәгенә ныклап ышана вә шуның белән күңел юата.

Бер ел, ике ел узып китә — ә якты көннәр һаман күренми. Мирза инде тәмам картая. Рөстәмнең Киевтә урынлашып, тагы юаш кына тора башлавы аны тәмам тынычландырса да, Касыймнан юньле хәбәр килмәве, аның ел саен егермешәр урынга авышуы, жалованьесыннан тыш та өйдән күпләп акча алуы аны һаман борчый. Ул аратирә чәй яннарында тирән генә сулый да беркемгә дә карамый: «Әй, бу бала дигәнең бәла!» ди.

Фәридә инде бу вакыт эчендә саргая, ямьсезләнә, бик еш-еш йөткергәли. Тик аның матур күзләре генә һаман әүвәлгечә йомшак кына нурланып тир-яктагы нәрсәләргә кайгылы карыйлар.

Көннәрнең берсендә Исхак мирза Мәскәүдән Гали мирза дигән бер кешедән хат ала. Хатны язучы Гали мирза Фәриданең атасы мәрхүм Шаһингәрәй мирзаның якын кардәше булып чыга. Ул хатында үзенең, әлегә кадәр эшләре начар булганга, әле анда, әле монда гомер үткәрергә мәҗбүр булганын, шуңар күрә кардәшләре белән беразга гына булса да галәкасын[1] өзеп торырга туры килгәнен, хәзер инде

---

[1] Галәка — бәйләнеш, элемтә.

Мәскәүдә тәмам җирләшкәнен яза: «Мәрхүм кардәшем Шаһингәрәй мирзаның кызы Фәридәнең сездә торганын ишеткәч, үземнең дөньяда икәнлегемне сезгә белдерүне бурычым дип белдем,— ди.— Бу көнгә кадәр кардәшемне йортыгызда тәрбия итүегез өчен затыгызга чын күңелемнән рәхмәтләр укыйм һәм моннан соң Фәридәгә гаит[1] булган бәгъзе бер мәсьәләләрдә миңа да мөрәҗәгать итсәгез, аның өчен төрлечә ярдәмдә булуны үзем өчен мөкаддә[2] вазифадан санар идем», ди һәм моннан соң Фәридәнең ара-тирә булса да үзенә хат язып торуын үтенә. Табигый, аңар җавап бирәләр.

Тагы бер ел узып китә. Фәридәнең исәнлеге һаман начарланганнан начарлана бара. Җәй урталарында карт мирза аны Уфага алып барып, мәшһүр докторларга күрсәтә. Докторлар аның авыруын җитди табалар: «Авыруның тиз көннән чахоткага әйләнүе ихтимал, шуңар күрә тизрәк Кырымга алып китәргә кирәк»,— диләр.

Өйгә кайтуга моның турысында әлеге Гали мирзага хәбәр итәләр. Озак та үтми, аннан җавап килә: ул гыйнвар ахырларында Фәридәне Кырымга алып китәргә вәгъдә итә: «Минем үземә дә докторлар бөтенләй анда яшәргә кушканнар иде, бигрәк тә уңай булыр», ди.

Көннәр узган саен Фәридәнең алда шатлык көннәренең булуына иманы азая бара. Өйдәгеләрнең бөтенесе нәрсәгәдер һәрвакыт күңелсез йөриләр. Тагы шуның өстенә шул көзне сентябрь ахырларында мирза да кинәттән генә үлеп китә. Бу вакыйгадан соң өйдәгеләр генә түгел, хәтта мирзаның йорты, бакчалары да кайгылы, өметсез төскә керәләр. Инде өй эчендә шаркылдап көлешүләр ишетелми. Зөләйха абыстай да, Фәридә дә, кичке күләгәләр шикелле, әкрен генә йөриләр, үзара пышылдап кына сөйләшәләр. Кайсыбер кичләрдә Фәридә бик аптырагач, утырып рояльдә уйный. Ләкин инде музыканың тавышларыннан элекке шикелле шатлык, өмет, тормыш аңкымый, аның моңлы тавышларын ишеткәндә әллә нинди кара киемнәр киенгән кешеләрнең куркышып әкрен генә караңгылыкта йөргәннәрен күргән шикелле буласың.

Соңгы көннәрдә Фәридәне: «Рөстәм абый кайтырмы-юкмы? Миңа инде ничек карый башлар?»— дигән уй борчый. Ул түземсезлек белән теге дәү атасының үлүе турысында язган мәктүбенә җавап көтә.

Менә бер заман, гыйнвар ахырларында көтелгән хат килеп җитә. Рөстәм атасының үлүенә үзенең кайгырганлыгын, никадәр авыр булса да, Зөләйха абыстайга сабыр итәргә тиешлеген язганнан соң: «Үзем, мәгаттәәссеф[3], урындагы кеше булганлыгымнан, язсыз кайта алмыйм, яз җитүгә, бөтенләйгә сезнең янда торырга кайтырмын, ходай кушса, аңар чаклы ничек тә түзегез инде»,— ди.

Бу хатны укыгач, Фәридәнең эче жу итеп китте. «Гали абый килер дә мине Кырымга алып китәр, тагы Рөстәм абыйны күрә алмам», дигән уй аны бигрәк тә борчый, аның күңеленә: «Рөстәм абыйны күрсәм, йөткерүем дә бетәр, ябыкканым да, тагы әүвәлге шикелле шат тора башлармын», дигән уй килә.

Февраль урталары якынлаша. Инде кояш дөньяга көлеп карый башлый. Һәркем тышка чыгу белән яз якынлашканын сизә, аның рухында әллә нинди әйтеп бетерә алмаслык шатлык уяна. Көннәрнең берсендә, өйлә алларыннан, Фәридә тәрәзәдән бакчадагы саесканнарның очып йөргәннәрен, кояшның нурланып яктыртуын карап тора, үзе нәрсә турындадыр уйлана. Шул арада капка алдына бер пар атлы килеп туктый. «Әллә булмаса Рөстәм абый кайттымы?»— дип Фәридә шатланып китә.

Атлар ишек алдына кергәч, чанадан өстенә калын толып, башына

---

[1] Гаит булган — бәйләнешле, кагылышлы булган.
[2] Мөкаддә — изге бурыч, намус эше.
[3] Мәгаттәәссеф — үкенечкә каршы.

озын кара бүрек кигән сарырак кына сакаллы, симез дә түгел, арык та түгел йөзле, уртача гына буйлы бер кеше чыга. Фәридә тиз генә эченнән: «Гали мирза шулдыр инде»,— дип уйлап ала, һәм Зөләйха абыстайга барып: «Дәү әнкәй, нииндидер бер кеше килде»,— ди.

Зөләйха абыстай каушап китә. Кунакны өйгә алып керәләр. Ул исәнлек-саулык сорашканнан соң, үзенең Гали мирза икәнен һәм Фәридәне үзе белән Кырымга алып китәргә килгәнен сөйли. Моны ишетүгә, Зөләйха абыстай елап җибәрә.

— Соң инде мин Фәридәдән башка нишләрмен? Балаларымның берсе мәшрикъта[1], берсе мәгърибтә[2]. Тагы шуның өстенә минем кызым шикелле якын күргән Фәридәмне дә алып китсәгез, миңа үләргә генә кала инде,— ди.

Гали мирза:

— Карагыз әле монда, Зөләйха абыстай, мин бит аны гомерлеккә алып китмим ич. Аның авыру икәнен үзегез дә беләсез. Менә Кырымда азрак хәл алсын да тагы сезгә кайтыр, үз кулым белән сезгә китереп тапшырырмын,— ди.

Зөләйха исә һаман елый, аның елаганын күреп, Фәридә дә түзә алмыйча елап җибәрә.

Сөйләшкән-киңәшкәннән соң, иртәгесен өйлә алларыннан юлга чыгарга карар бирәләр. Ул көн Фәридә бик тә күңелсез йөри. Бакчаны берничә кат әйләнеп чыга. Андагы ялангач калган һәрбер агач, ап-ак кар белән томаланган һәрбер сукмак, һәрбер чокыр бу вакыт аңар чиксез якын тоела. Иртәгесен мирза өенә Фәридәнең авылдагы таныш кызлары озатырга җыела башлыйлар, алар барысы да Фәридәнең ни өчен кайгырганын белмәсәләр дә, аны кызганалар.

Менә инде Хисами ишек алдында атларны җигә дә башлый. Әнә инде чанага Фәридәнең нәрсәләрен ташыйлар. Зөләйха абыстай елый-елый аңар юл киемнәре кидерә. Калтыраган куллары белән аңар яулыкка төргән бер нәрсә тоттыра:

— Мә, бәпкәм, кирәгеңә тотарсың,— ди.

Бу вакыт аңар дөньяда Фәридәдән дә якын кешесе юктыр төсле тоела.

— Бәпкәм, анда баргач мине онытасы булма: гөнаһ булыр онытсаң, хат яз,— ди.

Менә бар да утырып бик озак иттереп дога кылалар. Менә Фәридә, калын толыпка төренгән килеш, ишек алдына чыга. Кемнәрдер аны Гали мирза янына чанага утырталар, аның колагына кемнәрнеңдер елаганы ишетелә, кемнәрдер, тиз генә килеп, аны бик каты кочаклап, битеннән бик озак суырып үбә, шуның артыннан ук аның йөзенә нииндидер кайнар тамчылар тама. Тагы аны бик каты суырып үбәләр. Кемнеңдер:

— Әйдә инде, Хисами, кузгалырга да ярый,— дигән тавышы ишетелә.

Капка нәрсәдер мыгырдап ачыла, «син хәзерме?» дигән төсле иң әүвәл кыңгырауның берсе нәзек кенә тавыш белән яңгырап китә, икенчесе аңар «булды!» дигән төсле итеп калын гына тавыш белән яңгырап куя. Бервакытка тирә-як тып-тын булып тора. Гали мирза калын тавыш белән: «Ярый инде, сау булыгыз!»— ди. Атлар кузгалалар, кыңгыраулар берсен-берсе бүлә-бүлә нәрсәдер тиз-тиз генә сөйли башлыйлар. Кемдер арттан килеп тагы Фәридәне бик каты кочаклап ала, бик озак иттереп суырып үбә. Фәридә дә аз-аз гына акылын башына җыя. Тиз генә ул үзенең ничә еллар шунда уйнаган, шунда шатланган-көенгән, киләчәк өчен әллә нинди якты планнар корган, ничә еллар рәттән шунда саф мәхәббәт ялкыны белән газапланган җиреннән китәчәген уйлап ала. Тиз генә түбәсе ап-ак кар белән то-

---

[1] Мәшрикъта — көнчыгышта.
[2] Мәгърибтә — көнбатышта.

маланган өйгә җыелган бик күп хатыннарга, тирән уйга чумган бакчага бер карый, аның йөрәге сызылып киткән төсле була. Ул күңеленнән:

— Бөтенегез мәңгегә сау булыгыз!— ди.

Әнә инде искергән, картайган мәчет тә артта кала. Әнә инде Дим өстеннән чыгалар. Әнә ап-пак кар белән томаланган дала; аның кырыйлары үзалдына тотенләнеп торалар. Кар бөртекләре кояш каршында «җем-җем» итеп ялтырыйлар. Кыңгырау үзенең бертөрле моңлы аерылу көен һаман җырлый да җырлый. Атлар бертигез йөгерәләр, Хисами атларны ара-тирә кыздыра. Олы юлның кырыенда утыртылган, картаеп беткән каен агачлары берсе артыннан берсе артта кала баралар. Алар аяз көннәрдә кош шикелле оча торган тройкага утырган, үзенең сөйгәненә кавышыр өчен ашыга торган бәхетле егетне, гомернең калган кызыксыз көннәрен Сахалинның суык җилләре, караңгы төннәрендәге яңгырлары, караңгы, пычрак казармаларында уздырырга хөкем ителгән, туган иленнән, бала-чагасы, якын кардәшләреннән, каршында газиз булган бөтен нәрсәсеннән аерылган арестантны да, әңгер-меңгер чагында казенный урманнан утын урлап кайтып килә торган угрыны да, хәлдән тайган җитмеш яшәр фәкыйрь картны да — кыскасы, бөтен юлчыны, урысы, татары, ары[1] — бөтенесен шулай салкын кан белән башларын селкиселки күздән югалганчы озатып калалар.

Теге егет сөйгәне янына ашыга: әллә кем малае Хәйретдин, сөйгән кызны тәхкыйрь[2] иткән өчен, Шыр Вәлинең таз малаен үтергән икән дә, аны шуның өчен туган иленнән аерып Сахалинга озаталар икән; әллә нинди бер мирза кызы Фәридә шунда яшь гомерен уздырган, шунда беренче мәртәбә сәмави бер тойгы, мәхәббәттән ләззәтләнеп, йөрәге тибрәнгән иленнән аерылып китә икән; аңар чиксез кыен икән — аларга бар да бер; алар әкрен генә үз тормышлары белән тора бирәләр, юлчыларны да: «Юкка азапланып йөрисез, беркөн булыр — сез газапланмассыз да, сөенмәссез дә!» дигән төсле озатып калалар.

Фәридә артына борылып караганда инде офыктагы авылның тик мәчет манаралары гына күренә. Хисами ара-тирә җырлый, Рөстәм белән баргандагы шикелле сузып кына: «Үтте ич рәхәт җәйләре», ди.

Беренче станцадан ул кире кайтып китә. Фәридә белән күрешкәндә ул никтер кинәт кенә йомшап китә. Ул ни әйтергә дә, ни эшләргә дә белми. Бу вакыт аңар Фәридә чиксез якын тоела, аңар нинди булса бер йомшак сүз әйтәсе, бер нәрсәгә дә карамыйча, барып аны кочаклыйсы: «Сау бул, бәпкәм!»— диясе килә. Ул аңар кесәсеннән унбиш тиен акчасын да алып бирергә уйлый, ләкин азрак уйлагач, никтер ул ниятен үзе дә килештереп бетерми. Аның иреннәре калтырана, күзеннән ирексез ике-өч бөртек кайнар яшьләре агып төшә. Ул күзендәге яшьләрне күрсәтмәскә тырышып:

— Сау бул инде, исән-сау барып җитегез!— ди.

Кырга чыккач ул, ни өчен икәнен үзе дә белмичә, туйганчы елый. Аның күңеленә асраулардан Фәридә турында ишеткән: «Ул Рөстәмгә гашыйк булган имеш, Рөстәм ни өчендер аны ташлап киткән, имеш, Фәридә дә шуның хәсрәтеннән авыруга сабышкан имеш»,— дигән сүзләр килә. Аннары ул тагы җырлый башлый, сузып-сузып кына: «Ай-вай Зәйнәбе шул, Зәйнәбе-е-е... Үтте ич рәхәт җәйләре-е-е», ди.

Инде җир йөзен караңгылык томалый. Юл буендагы каеннар башларына ап-пак нәрсә бөркәнгән әллә нинди озын кешеләр булып күренәләр. Почта атлары һаман йөгерәләр дә йөгерәләр. Кучер атларны әллә нинди аңлашылмаслык ят гыйбарәләр белән сүгә. Сикәлтә-

---

[1] Ар — удмурт.
[2] Тәхкыйрь — хурлау, мыскыллау.

ләрдә ул утырган җиреннән сикереп төшә дә байтак яннан йөгереп бара. Ара-тирә еракташы авылның тычкан уты шикелле утлары ялт итеп күренеп китәләр. Тирән йокыга талган чыршы урманнары, кар белән күмелгән авыллар — бөтенесе артта кала баралар. Нииндидер бер куәт Фәридәне каядыр караңгылыкка кош шикелле очырып алып бара.

Ул котырган шикелле йөгерә торган атлар Фәридәне кая алып баралар? Алда аны нәрсә көтә? Кара бәхет аңар тагын нинди көннәр хәзерли?

Фәридә шундый кызыксыз уйларын уйлый. Ул бөтенләй арый. Күзне сиздерми генә йокы баса башлый. Аның колагына татар көйләренә охшаган әллә нинди бер кайгылы көй ишетелә, ләкин сүзләрен аңгарып булмый: кыңгырау һаман үзенең бетмәс-төкәнмәс көен көйли: «Киттек, киттек, киттек, киттек», ди. Шул арада чана нәрсәгәдер бик каты бәрелә — Фәридә уянып китә: үзенең юлда барганын, кучерның әллә нинди бер озын көен көйләгәнен белә. Болытлар арасыннан ай юлчыга никтер күңелсез генә карый. Әллә кайдан ерактан әтәчләр кычкырганы ишетелә. Борынга махорканың исе бәрелә. Атлар һаман чабалар да чабалар.

## XVII

Өйдән чыкканның тугызынчы көнендә иртә белән Фәридә уянуына вагон тәрәзәсеннән алда кояш чыгышының төтенләнеп күккә күтәрелгәнен, мәһабәт тауларны, алар өстендә әйләнеп йөри торган кара-кучкыллы болытларны, алар арасыннан кемнән дә булса оялган чытлык кыз шикелле елмаеп карый торган җәнүп[1] кояшын, тирә-яктагы әллә нинди зур-зур тармакларга бүленгән тоз күлләрен күрә. Тәрәзәне ачуга, борынга үзенә бер төрле саф ис бәрелә. Йөрәк нәрсәдәндер шатланып тиз-тиз генә тибә башлый. Поезд, куркынычлы кара-кучкыллы төтеннәрен чәчеп, һаман алга, әнә теге болытларга тиеп тора торган таулар янына йөгерә. Юл кырыендагы акшарлаган ап-пак өйләр, алар янындагы, су буена курай уйнарга җыелган зифа буйлы кызлар шикелле, бергә түгәрәкләнгән озын тупыл агачлары күренеп-күренеп китәләр.

Поезд нииндидер бер кечерәк кенә станцага туктый. Вагон янында башларына әллә нинди бүрек кигән кара сакаллы, кәкрәеп килгән зур борынлы, киң чалбарлы кешеләр йөриләр, вагондагыларга ука белән чиккән, нәзек кенә үкчәле башмаклар, төрле-төрле җимешләр һәм «чүбәрәкләр»[2] тәкъдим итәләр.

Фәридә вокзал ишеге өстендәге язудан «Бакчасарай» дигән сүзне укый. Пушкинның «Бакчасарай фонтаны», анда тасвир ителгән Заримә кылт итеп аның исенә төшә. Поезд кузгалып киткәч тә, ул бик озак ерактагы ике тау арасындагы шәһәрнең берсе өстенә берсе утырган ап-пак өйләренә, күккә сузылган ап-пак озын манаралар белән ямь-яшел бакчаларына карап бара. «Әнә инде Заримә шул озын агачлар арасында гыйшык уты белән янган, шунда газапланган», ди.

Әнә инде офыкта зәңгәрсу диңгез күренә. Әнә еракта беленер-беленмәс кенә җилкән көймәсе селкенә. Бер пароход кара төтеннәрен чыгарып каядыр бара. Әнә инде Севастополь. Әнә диңгез буенда корабларның хәтсез, хисапсыз мачталары күккә күтәрелә.

Алар Севастопольдә бер атна чамасы торганнан соң Ялтага, аннан Алупкага китәләр һәм шунда тора башлыйлар.

---

[1] Җәнүп — көньяк.

[2] Чүбәрәк — итле сумса.

Кырымның матур һавасы, төрле зиннәтле бакчалары, күккә тиеп тора торган кыялары, очы-кырые күренми торган диңгез, иртәдән алып кичкә кадәр диңгез буенда эшсез йөри торган сәяхәтчеләр белән авырулары, парклардагы музыкалар — берсе дә Фәриданең күңелен ача алмыйлар: ул үзенең Дим буен, андагы урманнарын, үзенең бакчадагы сөекле урыннарын, ничә еллар шунда яшәгән бүлмәсе белән яшьлек дусты роялен, һәрвакыт ялгыз гына борын эченнән иләмсезрәк тавыш белән җырлап йөри торган Рөстәмне сагына. Кайчагында ул дачаларының тәрәзәләрен ачып, узган-барганнарга, ерактагы диңгезгә, андагы балыкчы көймәләренә, ерактагы пароходның төтененә карый. Шул арада урам буйлап кара мыеклы татар проводнигы белән матур гына, симез генә бер урыс хатыны көлешә-көлешә атка атланып узып китәләр. Боларны күргәч Фәриданең, атланып, кая да булса бик каты йөгерәсе, саф һаваны тутырып иснисе килә, ләкин шул арада гына ул ачы гына итеп йөткерергә тотына.

## XVIII

Май аенда Рөстәм Сара белән бөтенләй шунда торырга дип авылга кайта.

— Мирзаның улы Рөстәм марҗа алып кайткан икән,— дигән хәбәр яшен шикелле тиз арада тирә-якка таралып өлгерә. Бар да Рөстәмнең бу эшен тикшерергә, артында аның гайбәтен сатарга башлыйлар.

Зөләйха абыстай да аның бу эшен яратмый. Ул Рөстәмне кайтып керүенә:

— Бусы кем була соң?— дигән сүзләр белән каршы ала.

Рөстәм никтер аның гади генә сөаленә азрак аптырый төшеп җавап бирә:

— Бумы?— ди.

Зөләйха абыстай эшнең хакыйкатен аңлагач, никтер аптырап китә:

— Әй, улым-улым, марҗа алмасаң, атаң-анаң нигезенә марҗа кертмәсәң, кыз тапмам дип уйладыңмы?— ди.

Шул көннән соң аның Рөстәмнән бөтенләй ихласы кайта. Ул аның белән чынлап сөйләшми, урыны чыкканда, аңар марҗа алганлыгы өчен сукрана:

— Мәрхүм атаң белән без бу малларны бер марҗадан туган бала өчен җыймаган идек тә инде... Ни эшлисең, язмыш шулайдыр инде,— ди.

Мирзаның якынрак дуслары да, урын килгәндә, Рөстәмне бу эштән кайтырга, Сараны аерып җибәрергә димлиләр:

— Шулай нәсел бозу буламыни?!— диләр.

Тирә-якта тәкъвалыгы[1] һәм гыйльме белән шөһрәт тоткан бер карт мулла да килеп Рөстәмне үгетләп китә:

— Вакытында атаң мәрхүм безнең якын дустыбыз иде. Мәрхүмнең бик күп кадер-хөрмәтен күрдек. Шундый бер кешенең баласы марҗа белән тора икән дигән хәбәрне ишеткәч, исем-акылым китте дә барды, тукта әле, үзем барып кайтыйм, дип килдем,— ди.— Әле син ата-ана догасы да, имамнар догасы да кирәкми дип уйлыйсыңдыр. Кирәк булыр әле, җаный Рөстәм, кирәк булыр. Бакчы, бу эшең өчен анаңны да рәнҗи диләр, һич булмаса, аның хәтерен саклау кирәк иде,— ди.

Рөстәм никадәр аларга игътибар итмәскә тырышса да, үзен әллә нинди бер җинаять эшләгән кеше шикелле хис итә. Аңар урамнан узганда бар да үзенә бармак белән төртеп күрсәтәләрдер төсле тоела.

[1] Тәкъвалык — диндар, дин кушканча гына эшләүче.

Кайчагында ул иркле-ирексез: «Ялгышлык иттем бугай», дип куя, ләкин Сарага бернәрсә дә белдермәскә, ничек тә булса, аның күңелен ачарга тырыша. Үзе эшләре белән шәһәргә әйбергә киткәндә аңар иптәш булсын өчен бер урыс хәдимәсе[1] ала. Авылга кайтканнан соң, ул үзе дә сизмичә, Фәридә турында еш-еш кына уйлый, залның читендәге рояль дә, бакчадагы агачлар да — кыскасы, өйдәге бөтен нәрсә аңар Фәридәне искә төшерәләр. Аның бакчаның аргы башына аулак кына җиргә утырып өйдә Фәридәнең рояль уйнаганын тыңлап торасы килә. Аның көне-төне эче поша, ул күп вакыт ни булса да югалткан кеше шикелле йөри һәм бик аптырагач, Хисамига ат җиктереп, теге карт докторы янына барып утыра. Доктор да аны коньяк белән сыйлый, дөньяга бөтенләй үк бирешмәскә киңәш итә.

Сара да авылга кайткач бик үзгәрә: Рөстәмнең, аннан ни дә булса яшерергә йөргән шикелле, гел аның җаена гына торуы һәм еш-еш кына эчкәләве, Зөләйха абыстайның Рөстәмгә дә, үзенә дә кырын каравы аңар начар тәэсир итә. Ялгызлык, сөйләшергә беркемнең дә булмавы аңар бигрәк тә авыр тоела. Ул урыс гаиләсе эчендә төрле кешегә катнашып йөрүгә өйрәнгән, андагы гадәтләргә тәмам күнгән, ул гадәтләр инде аның канына сеңеп беткән. Мондагы халыкның тормышы да, гадәте дә аңар бөтенесе ят. Шуңар күрә ул үзенең әүвәлге тормышын, андагы танышларын сагына, аның бу кайгылы йорт белән күңелсез караңгы бакчаларны ташлап әллә кая еракка, Днепр буйларына качасы килә. Ул, уйлаган саен, үзенең Рөстәм белән тора башлавының ялгышлыгына ышана бара.

Җәй урталарында авылда, Рөстәмнең тырышуы аркасында, земство больница эшләтә башлый. Инде Рөстәм хәзер үзендә бераз җиңеллек хис итә; һәркөн диярлек больница эшләгәнне карарга Сараны үзе белән бергә алып бара.

— Менә, ходай кушса, тиздән без дә эшкә башларбыз, син больницада миңа булышкаларсың. Тагы фельшерицалар килерләр, безгә дә иптәш артыр, күңелле булыр, ходай кушса,— ди.

Зөләйха абыстай көз җитүгә мирзаның хәсрәтеннәнме, балачага сагышыннанмы, әллә булмаса, картлык авыруыннанмы, үлеп китә. Ул үләр алдыннан Рөстәмне, янына чакырып, аңар ачуланмаганын сөйли.

— Миннән сиңа хәер-дога, рәхәт гомер ит,— ди, шуның артыннан ук тирән генә сулап ала да: — Рөстәм бәпкәм, зинһар өчен мине гүремдә тыныч яткыр: шул Сара белән торма,— ди. Тагы ул нәрсәдер әйтергә тели, ләкин «Ф...ә...р...» дигән сүзеннән башкасын аңгарып булмый. Шул көнне ул кич алдыннан җан тәслим итә.

Тагы бер ел узып китә. Рөстәм инде ярыйсы гына үзгәрә, картая төшә, яңаклары эчкә бата, йөзләре саргая. Һәрвакыт нәрсәдер аның йөрәген тырный, көне-төне больницада эшләү, еш-еш кына эчкәләүләр дә аның эч пошуын бетерә алмыйлар. Ара-тирә ул теге карт докторына да барып утыра. Никтер ул инде бөтенләй картайган Соколовны якын күрә, аның янында үзенә бертөрле җиңеллек хис итә һәм, никадәр үзенең хиссиятләре турында башкаларга сөйләргә яратмаса да, аннан күп серен яшерми.

Бервакыт шулай ул, бик эч пошкач, докторга барып бик озак утыра да, кич белән генә аннан кайтырга чыга. Вакыт кыш урталары була. Рөстәм юлда азрак йокымсырый. Хисами һаман да үзенең бетмәс-текәнмәс җырларын җырлый. Инде тәмам караңгылана. Болар һаман баралар да баралар. Бер заман күз ачкысыз буран күтәрелә. Тирә-якта бернәрсә дә күренми, җил өрә, атлар бармый башлыйлар. Хисами Рөстәмгә:

---

[1] Хәдимә — хезмәтче хатын-кыз.

— Адаштык бугай. Буран узганчы туктап тормыйкмы? Юкка атларны өшәндермик дим,— ди.

Туктыйлар. Буран һаман куәтләнгәннән куәтләнә бара. Башка әллә нинди кызыксыз уйлар килеп китә. Хисами, атлар янына барып, әрле-бирле йөренгәли, аларның эшлеяләрен төзәтә дә чана янына килеп, махоркасын тарта башлый. Аннан ары үз-үзенә сөйләнгән шикелле:

— Моннан ике-өч еллар чамасы элек Фәридәне озатып кайткан-да шулай бер адашкан идем, япа-ялгызым кырда кундым,— ди. Шуның артыннан ук Фәридә турында сөйли башлый: — Менә кыз дисәң дә кыз иде ичмасам! Матурлыкмы дисәң, акыллылыкмы ди-сәң — бөтенесе килгән иде инде... Бичараның шул чаклы моннан китәсе килмәде — бер дә әйтергә дә түгел инде... Ыстансада минем белән күрешкәндә үзе: «Сау бул, Хисами абзый», ди, үзенең күзеннән мөлдерәп яшьләре ага. Мескен, югалганчы мине озатып калды. Шулай чыктым кырга, үзем барам, үзем һаман аның турында уйлыйм да уйлыйм. Ә бит беләсең нәрсә, юкка гына бит аны, «Касыйм белән йөри», дип чыгарганнар. Ул, Касыйм никадәр ялынса да, һич тә аның белән йөрмәгән. Дөрес булса, ул сине сөйгән һәм, син киттең бит әле, әнә шуннан соң ул кайгысыннан авыру булган. Кем белә соң инде тагы? Яшь чагында бар да була торган эш, ди. Тагы азрак уйлап то-ра да: — Белер хәл юк, бар да була торган эш, ди.

Рөстәм аның сүзләрен ихлас белән тыңлап тора һәм, ул сөйләп бетергәч, үзе дә сизмичә, Фәридә турында уйлый башлый. Яшьлек хатирәләре берсе артыннан берсе аның күз алдына килеп китәләр. Менә ул яшь кенә егет, кич белән бакчаның ары башыннан Фәридә-нең залда рояль уйнаганын тыңлап тора, төрле якты уйларга чума. Менә ул Фәридә белән бакча әчләп бара. Аның тирән, мәгънәле карый торган күзләренә үләрдәй булып төбәлә; менә ул якты уйлар белән университет бетереп авылга, Фәридәсе янына кайтып килә, Хисамидан Фәридәнең Касыйм белән йөргәнен ишетә; бакчада Ка-сыймның Фәридәне кысып кочаклаганын үз күзе белән күрә. Менә инде ул яратмаган, каны, рухы, холкы үзенә ят булган Сара белән өченче ел тора, әнә тегендә кайгысыннан саргайган Фәридә постоялый двор тәрәзәсеннән елый-елый Хисами кучерне күздән югалганчы оза-тып кала. Әле һаман да ул каядыр Кырымда, кадерле яшь чакларын сагынып, күзләреннән яшьләр агыза, менә монда Рөстәм арган, дөнья-дан туйган, якты көннәрдән өметен өзгән килеш кыр уртасында тора, алга барырга юл юк, тирә-як аның бәхетеннән дә караңгы: җил өрә, буран уйный, әнә Хисами карт җырлый. Ул да яшь чакларын сагына:

— Үксеп-үксеп елый күрдисә,
Әллә алыйм микән юк исә,—

ди. Аннары тагы үзенең: «Үтте ич рәхәт җәйләре-е-е»н сузып тора. Рөстәм дә күңелсез генә: «Әйе, үтте рәхәт җәйләре, бар да үтте», ди. Аның инде никтер гомергә шулай юлда, караңгылыкта туктап тора-сы, җилнең сызгырганын, Хисаминың җырлаганын бертуктамый ишетәсе килә.

Таң атыр алдыннан буран азрак басыла төшә, юлчылар да кузга-лып китәләр. Рөстәм юлның юл буе үзе калтырана, үзе бертуктамый Фәридә турында уйлый:

— Ничек соң ул чагында мин бер нәрсә дә сизенмәдем?!— ди. Инде ул Фәридәнең гөнаһсыз икәнлеген аз гына да шөбһә итми.

Өйгә кайтуына, ул үзендә бер авырлык хис итә һәм кичкә таба азрак кызыша башлый. Кич була. Ул яткан җиреннән һаман Фәридә турында уйлый да уйлый. Залдан Сараның әкрен генә рояльдә уйна-ганын, ара-тирә асрау белән сөйләшкәне ишетелеп китә. Бераздан күз аллары караңгылана, тирә-яктагы нәрсәләр беравыкка югалып

торалар. Ул да булмый, Рөстәм үзен аз гына яктыртылган зал уртасында күрә. Ул нинди дә булса начарлык эшләгән кеше шикелле, үзендә әллә нинди бер авырлык хис итә. Як-якка карый — ни күзе белән күрсен: каршыда гына үлек шикелле ап-пак чырайлы анасы, аның янында гына ак киемгә төренгән Кәримә, алардан ерак та түгел атасы тора. Ул никтер калын толыпларга төренгән, шарфка чорналган. Алар бар да селкенми-нитми текәлеп Рөстәмгә карап торалар. Рөстәм аларга тагы бер кат дикъкатьләп күз йөртеп чыга һәм, җентекләп карый торгач, ишек янында Фәридәне күрә: ул чиксез ябыккан, күзләре эчкә баткан, чәчләре тузгыган. Ул да кайгылы гына итеп Рөстәмгә карый, аннан нәрсәдер сораган төсле була. Рөстәм аңар аптырап карап тора. Менә бервакыт анасы акрын гына аңар якынлаша: аның ап-пак иреннәре әллә нинди, машина белән селкеткән шикелле, кыймылдый башлыйлар. Сүзләр, әллә нинди, ерактан килгән шикелле ишетеләләр. Ул: «Без сине тудырдык, тәрбияләп үстердек, синең өчен бернәрсә дә кызганмадык: тукта, кеше булсын, тукта, кеше булсын, дидек, ә син тоттың да безнең йортыбызда бер марҗа белән тора, атаң-анаңның намаз укыган җирләрен тәһарәтсез бер марҗадан таптата башладың. Мин сине тудырган, үз сөтем белән тәрбияләп үстергән анаң, синең болай үземнең саф канымны, саф нәселемне бозарга тырышуыңа каберемдә азапланам: мин сине тудырган сәгатьләремә дә, сиңа да көне-төне ләгънәтләр укыйм. Синең бу эшең өчен бер мин генә азапланмыйм, әнә алар бар да азапланалар, бар да сиңа ләгънәтләр укыйлар. Әнә Фәридәне күрәсеңме: ул сине ярата, күптәннән бирле ярата, үлерлек булып ярата. Әнә инде аның матур күзләре синең хәсрәтеңнән сүнгәннәр, яңаклары аның эчкә баткан; еракта ай яктысында әкрен генә диңгез шаулаганда, агачлар арасында сандугачлар сайраганда, ерактагы мәчетләрнең манараларында кычкырып азан әйткәндә, ул озын сәрви агачлары арасында синең өчен күзеннән кан яшьләрен агыза, ул сине чакыра, ул сине көтә», ди.

Мирза да читтән генә: «Дөрес сөйлисең, бик дөрес», дигән шикелле итеп, ул сөйләгәндә һаман башын селки; Фәридә исә һаман урыныннан кыймылдамый-нитми, өзелеп Рөстәмгә карый да карый. Аннары әкрен генә Кәримә сөйләргә башлый: «Рөстәм абыем, җаным, бәгърем, син бит безнең бөтенебезне яратасың, менә безнең бөтенебез хөрмәтенә шул Сараны ташлап, Фәридә апа янына бар, аның күңелен юат, ул бит сине ярата. Бөтенесен ташла да кит. Аның бит инде күп көненнән аз көне калган», ди.

Ул да түгел, алар бар да күздән юк булалар. Ишектән өстенә сары тун кигән, пута белән билләрен буган Хисами килеп керә, тиз генә ишекне яба да:

— Киттекме?— ди.

Шул арада Рөстәм: «Киттек, киттек. Әйдә хәзер үк киттек, бөтенесен үк ташлап киттек!» ди.

Һәм шуның артыннан ук уянып китә. Тирә-як тын. Ул бөтенләй тиргә баткан. Ул бик озак күргән төше турында уйлап ята.

Менә шул көннән соң аңар дөньяның кызыгы бөтенләй китә. Ул иртәдән алып кичкә хәтле гел Фәридә турында гына уйлый. Кичләрен йоклый алмый, йокласа, төшләрендә Фәридә белән саташып чыга. Гүя, әллә кайдан ерактан Фәридәнең кайгылы күзләре аңар моңаеп кына карыйлар, Рөстәмнән нәрсәдер үтенгән төсле булалар. Ул әллә нинди томанлы тойгылар белән уяна һәм әллә каян, ерактан, Фәридәнең ачы тавыш белән елаганын, өзелеп-өзелеп үзен чакырганын ишеткән төсле була. Нindидер бер куәт аны тегендә, Фәридә янына өстери, аны эзләп табарга куша. Ул Фәридәгә ни әйтергә теләгәнен, аның белән нишләячәген үзе дә белми, ләкин ничек тә аны күрәсе килә. Инде ул больницада да яхшылап эшли алмый; өйгә

кайтса, Сара янында әллә нинди бер уңайсызлык, авырлык хис итә һәм шул авырлыктан котылыр өчен, ул ике коннең берендә диярлек, ераклыгына да карамый, карт доктор янына барып утыра һәм еш-еш кына эчкәләргә башлый. Көне-төне уйлану, кичләрдә яхшылап йоклый алмау, еш-еш кына эчкәләүләр аны чиксез ябыктыра, нервларын бетерә, кайчагында ул юк кына нәрсәләр өчен дә Сарага ачулана, мондый вакытларда аның Сарага бик каты кычкырасы, ни өчендер аның йөзенә бик каты сугасы килә, башлар әйләнә, күз аллары караңгылана, бөтен тәне калтырана башлый. Ул тиз генә ачуын басар өчен суык су эчә дә, Хисамига ат җиктереп, карт доктор янына китә. Юлда саф һавада нервлары азрак тынычланалар. Ул үз-үзенә ачулана башлый: «Мескен көчсез хатынга барып нигә этәчләнергә инде!» ди.

Өнендә Сараны, төшендә Фәридәне күреп, көне-төне аның вөҗданы газаплана. Бара-бара ул шундый бер дәрәҗәгә җитә ки, акылдан язмасам, ачу вакытында әллә нинди бер җинаять эшләп ташламасам ярар иде, дип курка башлый. Сара инде үзе дә аннан тәмам туя. Киевкә анасы янына беразга булса да кунакка барырга тели. Рөстәм кайчагында аннан бөтенләй аерылырга уйлый. Ләкин соңыннан: «Ул тагы нинди вөҗдансызлык!» дип үз-үзенә ачулана һәм аның турында уйламаска тырыша. Ләкин бу соңгы көннәрдә ул фикер еш-еш кына аның күңеленә килә. Ахырында ул башыннан үткән бөтен эшне, Фәридә белән араларында булган маҗараларын, Сарага өйләнүләре, хәзер аңар үзенең карашларын; менә хәзер көне-төне Фәридә күңеленнән чыкмаганлыкларын — берсен дә калдырмый карт докторга сөйләп бирә: «Инде мин ни эшлим? Зинһар, миңа бер киңәш бирегез, мине бу газаптан коткарыгыз!» — ди.

Доктор ак сакалын аралаштыра-аралаштыра бик озак уйлый, трубкасын бик озак иттереп суырып тора да:

— Әйе, нервларыгыз чиксез какшаган, сезгә хәзер мөмкин кадәр тыныч яшәргә, тынычлыгыгызны боза торган һәммә нәрсәне читкә ташларга, әнә ул Сарагыздан да бер дә сырланмый-нитми генә аерылырга кирәк. Барыбер сез аңар рәхәт тормыш бирә алмассыз, ул — сезгә. Ихтимал, сез аны аерып җибәрүне инсаниятсезлек була, ярамый дигән булырсыз, мин бит бу елдагы яшьләрне бик яхшы беләм. Алар шундый гали нәрсәләр артыннан йөрергә бик оста булалар. Дөрес, ул яхшы нәрсә дә, ләкин бу урында түгел. Чөнки, бердән, үзегез дә ачыктан-ачык әйтергә тиешлесез ки, инде аны бәхетле итәлмәссез; икенчедән, аның белән торып, сез һаман газапланырсыз, көннән-көн нервларыгыз какшар, менә шулай итеп, ахырында халык үзенең бер иң файдалы кешесен югалтыр. Әйе, анысы шулай. Аннары сезгә һич юктан бер-ике ай ял итми ярамый. Җәнүп якларыннан бер әйләнеп килсәгез, шунда беразга Сараны да Киевтә калдырсагыз, бигрәк тә яхшы булыр,— ди.

Рөстәм бераз уйлап торгач:

— Анысы шулаен шулай, ләкин мин нигә дә Сараны үзем илтеп анда ташлап китә алмыйм, аңар минем көчем җитми,— ди.

Бик озак сөйләшкәннән соң, карт доктор яз җитүгә Сараны үзе Киевкә «аналарына кунакка» дигән булып илтергә, юлда бөтенесен аңар бик һәйбәт кенә иттереп аңгартып бирергә, Рөстәмнән аерылуның тиешлеген бик төпле дәлилләр белән исбат итәргә карар бирәләр. Доктор кайтканнан соң, Рөстәм бер-ике айга Кырымга ял итәргә барырга була.

Яз җитүгә, доктор Соколов Сараны алып Киевкә китә. Сара анасы янына кунакка барасы булгач, бик сөенсә дә, үзе белән Рөстәмнең бармаганын белгәч, азрак уңайсызлана. Ләкин аңар Рөстәмнең бара алмаячагын, аның эше күплеген сөйлиләр. Рөстәм докторның кайтканын түземсезлек белән көтә, аның мөмкин кадәр тиз Кырымга

барып Фәридәне табасы, ничек кенә булса да, аны күрәсе килә. Доктор кайтуга, ул ике айга отпуск ала да Кырымга китә.

Ялан дөньяның җәннәте булгач Кырымның матур манзаралары, күккә тиеп торган таулары, тау буйларындагы йөзем бакчалары, нечкә билле сылу кызлар шикелле, озын буйлы сәрви агачлары, очсыз-кырыйсыз диңгезе — берсе дә Рөстәмнең назар[1]-дикъкатен җәлеп итә алмыйлар: ул Алушта, Ялта, Алупка шикелле диңгез буендагы бөтен шәһәрләрне йөреп чыга, дачадагы кешеләрдән, докторлардан Фәридәне сораша, ләкин һичбер аны белгән кешегә очрамый. Ул бөтен нәрсәдән өметен өзеп, өйгә кайтырга җыена башлый. Шул арада ул Алупкада үзе төшкән гостиницада кырымлы бер татар бае белән таныша. Сүздән сүз чыга. Рөстәм дә үзенең монда ни өчен килгәнен аңар сөйләп бирә. Бай:

— Ул Гали исемле абзасы белән идеме?— ди.

Рөстәм:

— Әйе, шулай,— ди.

— Алай булса, мин аларны беләм. Алар безнең авылда ике еллап тордылар. Симиез дигән авылны, бәлки, ишетмәкче үзегез дә беләсез булыр, ул моннан ерак түгел, өч-дүрт чакрым гына. Менә алар, расход та азрак булыр һәм тынычрак та булыр дип, Алупкадан шунда бер кассапның[2] диңгез буендагы дачасында тордылар иде. Алар моннан өч айлар чамасы элек ватаннарына кайтып киттеләр. Дөрес, минем үземнең алар белән танышлыгым юк иде, ләкин шулай да беләм, инде алар китте,— ди.

Моны ишеткәч, Рөстәм нишләргә дә белми.

— Тагы аларны куып Мәскәүгә барыргамы? Ә соң алар анда булмасалар?

Бик озак уйлаганнан соң, ул Мәскәүгә барырга була һәм, шул нияте белән, диңгез кырыйлап почтовый атлар белән Севастопольгә юнәлә. Аннан Мәскәүгә билет алып поездга утыра. Инде ул юлда бернәрсә турында да уйлый алмый. Кич белән поезд Бакчасарайга беразга гына туктый. Рөстәмнең никтер монда төшәсе килә. Ул монда нишләячәген үзе дә белми һәм аның турында уйламый да, ләкин әллә нинди бер яшерен куәт аны нәрсәләрен җыеп вагоннан төшәргә, вокзалдан чыгып, ерактан җем-җем итеп утлары күренә торган шәһәргә барырга фаэтон яллаурга мәҗбүр итә. Ул фаэтончы татарны һаман куалый, тизрәк барырга куша, үзенең йөрәге никтер дөп-дөп тибә, ул нәрсәдер көтә. Аңар әнә шул ялтырап утлары күренә торган шәһәр эчендә үзе өчен бик кирәкле бер нәрсә бардыр төсле тоела.

Менә бер заман фаэтон, зур шәһәр капкасын кергәннән соң, тар гына урамнардан бара башлый. Урамнарда караңгылыкны ерып җәяүлеләр йөриләр. Әллә нинди кәрйә тавыш белән кемнәрдер кычкыралар. Менә инде фаэтон зур гына бер йорт алдына барып туктый. Рөстәм аның «Мәркәзи кунакханә» икәнен белгәч, фаэтончыга акча бирә дә, каршы чыккан яшь кенә татар хадименә нәрсәләрен алып керергә куша. Аңар кечерәк кенә бер бүлмә бирәләр. Юынгач-ниткәч, әлеге яшь егет аңар кечкенә генә финҗан[3] белән каһвә[4] китерә һәм, башка нәрсә кирәкмәгәнен белгәч, юлчыга тыныч йокы теләп, чыгып китә.

Инде Рөстәмнең күңеле, нинди дә булса бер зур максатына ирешкән кешенеке төсле, тынычлана. Ул караватына барып яту белән, өстеннән бик зур бурычын төшергән кеше төсле, тыныч кына йокыга китә.

---

[1] Назар — игътибар, илтифат.
[2] Кассап — мал суючы.
[3] Финҗан — кофе чәйнеге, касә.
[4] Каһвә — кофе.

## XIX

Докторлар Гали мирзага: «Сезгә сеңлең белән икегезгә дә хәзер бик чынлап ял итәргә һәм һич юктан Кырымда, диңгез һавасында, бер-ике ел яшәргә кирәк», диләр. Шуңар күрә мирза Мәскәүгә барып, хатынын да Кырымга алып килә. Алупкада бераз торганнан соң, алар, тынычрак булыр дип, Симеиздән очсызлы гына бер дача алып, анда күчәләр. Гали мирзаның исәнлеге ярыйсы гына төзәлсә дә, Фәриданең арткан җире күренми, ул һаман көннән-көн кибә. Ул актык минутларына кадәр Рөстәмнең кайчан да булса бер килүенә бик нык ышана, шулкадәр азаплану, шулчаклы януларның бер мөкафәтен[1] күрмичә үлү аңар мөмкин түгелдер төсле тоела.

Ике елга якын вакыт узып китә. Гали мирзаның исәнлеге тәмам яхшыра. Шуңар күрә ул хатынына:

— Гел Кырымда торып булмас, инде кайтырга кирәк, безнең Фәриданең барыбер тереләчәге юк, докторлар: «Аңарда чахотканың иң куәтлесе башланган»,— диләр ди.

Озак та үтми, алар кайтырга чыгалар.

Пароходта суык тидергәннән булса кирәк, кайтырга чыкканның икенче көнендә Фәридә поездда бик ныклап авырый башлый. Шуңар күрә Гали мирза Бакчасарайда туктарга мәҗбүр була. Фәриданы кунакханәгә бөтенләй хәлсез килеш алып киләләр. Мирза, хатынын авыру янында калдырып, үзе яхшырак доктор алып килер өчен Акмәчеткә китә. Кич алдыннан Фәридә саташа башлый. Аппак чәчле, җыерчыклы битле Мәүли әбине күргән, аның йомшак кына тавыш белән: «Елама, бәбкәм, шатлык көннәр дә булыр», диган тавышын ишеткән төсле була. Әкрен генә: «Әйе, бәлки, шатлык көннәр дә булыр,— ди, шуның артыннан ук: — Нигә соң, Касыйм абый, сез мине болай мыскыл итәсез, җибәрегез мине, җибәрегез дим ич!» ди. Янындагылар аны, «саташа», диләр. Кинәт кенә аның күзләре ачыла. Ул тирә-яктагыларга акыллы гына бер карап ала да, тирән генә итеп сулый. Ул күзләре белән кемнедер эзли, ләкин таба алмый. Бу вакыт аның йөзе чиксез газаплануын аңгарта. Ул күзләрен азрак йома төшеп һәм кабердән ишетелгән шикелле акрын, ләкин шулай да матур сынык тавыш белән саташып җырлый. Тирә-яктагылар аның тәһлил[2] урынында өзелеп әйткән бу җырларының мәгънәсен аңармасалар да, икенче бер сәбәптән, калтыранып китәләр. Шул актыгы тәһлилен әйтүгә Фәридә әкрен генә тына. Инде аның мәгъсүм[3] рухы бу газап урыны булган җирне ташлап, мәңгелек бәхет, мәңгелек сәгадәт[4] урыны күккә, үзе шикелле мәгъсүм фәрештәләр янына оча.

## XX

Икенче көнне Рөстәмгә кунакханә хадиме, кичәге яшь егет, лимон белән бер стакан чәй һәм ашарга китерә, юлчыдан кайдагы икәнен сораша. Сөйләшә торгач, Рөстәм аннан-моннан ике-өч айлар чамасы элек шушы кунакханәдә Фәриданең үлгәнен белә. Хәзер инде ул бу соңгы айларда көне-төне гел Фәридә турында уйлавының, ахырында бөтенесен ташлап Кырымга килүенең, кичәгенәк үзен ниндидер бер куәт монда, Бакчасарайда, туктарга мәҗбүр итүенең бөтенесенең сәбәбен аңгара. Аның инде елыйсы да килми, күңеле аның әллә нинди тын гына томанлы хисләр белән тулып кала, алар әкрен генә Рөстәмне һаман басалар да басалар.

---

[1] Мөкафәт — игелек, бүләк.
[2] Тәһлил — мәет күмгәндә укыла торган дини дога: (Бер алладан башка алла юк).
[3] Мәгъсүм — гөнаһсыз, керсез, саф.
[4] Сәгадәт — бәхет.

Рөстәм уйланып бик озак булмәсендә утыра, ахырында ул көндезге сәгать өчләрдә аннан-моннан аш ашый да, теге яшь егетне алып, Фәридәнең каберенә китә. Менә алар шәһәрнең керәле-чыгалы тар гына урамнарыннан баралар. Авызларына тәмәке капкан Кырым татарлары, тик күзләрен генә калдырып башларыннан аякларына кадәр ап-пак нәрсәгә төренгән хатыннар очрый.

Менә инде алар, шәһәрдән чыгып, тау өстендәге мазарстанга[1] җитәләр. Бераз баргач, алар бер яңа кабер алдына туктыйлар. Ул Фәридәнеке була. Рөстәм туктый, аңар бик озак карап тора. Тирә-як тын, һава ачык була. Еракта тау астындагы шәһәрнең күккә күтәрелгән манаралары белән тупыл һәм сәрви агачлары, шәһәрнең Мәккә, Мәдинә рәсемнәрендәге шикелле йортлары күренә. Җәнүп тарафыннан болытлар төн ягына таба агылалар. Күк йөзендә әкрен генә ниндидер бер бик зур кош очып йөри.

Рөстәм тирә-яктагы каберләргә карый да:

— Менә болар бар да вакытында яшәгәннәр, шатланганнар, көенгәннәр, бер-берсен дошман күргәннәр, яратышканнар, ә хәзер бар да тын гына йоклыйлар. Алар белән бергә кара кашлы, кайгылы күзле Фәридә дә йоклый,— ди.

Шуның артыннан ук аның күз алдына Фәридәнең бөтен гомере — аның азапланулары, бөтен гомеренә һичбер рәхәт, һичбер шатлык күрмәүләре килә. Аңар шул кадәр азапланып янып-янып та аларның һич бер мөкафәтен күрмичә үлеп китү зур хаксызлыктыр төсле тоела. «Шулай ук без бары үләр өчен генә яратылган микәнни инде?!»— ди. Шушындый уйлар белән ул кунакханәгә кайта.

Инде кич якынлаша, шәһәр өстендәге көндез күтәрелгән тузан әкрен генә басыла. Озак та үтми, төрле мәчет манараларында ахшам азаны укыла.

Рөстәм иске ханнардан калган, хәзерге көндә, «Хан сарае бакчасы», дип йөртелә торган бакчага китә. Анда татардан, урыстан йөрүче халык байтак була. Рөстәм аулак кына бер эскәмиягә барып утыра. Тирә-якны тәмам караңгылык томалый. Кырымның саф һавасы борынга барып керә. Бакча агач яфраклары исе белән тула. Бара-бара йөрүчеләр сирәкләнә. Һава гаять дәрәҗәдә тын. Тик якындагы бер бакчада скрипкә уйнаганы гына ишетелә. Анда туй. Уйнаучы — Кырым татарлары арасында сирәк-сирәк кенә очрый торган оста скрипкәче картлардан берсе булырга кирәк. Ул Хисамича әйткәндә, өздереп бирә — Кырым татарларының озын һәм моңлы гына бер көен уйный. Көй ачы чыга. Ул адәм балаларының бүгенгә чаклы никадәр азаплансалар да, тел белән аңгарта алмаган тойгыларын кемгәдер сөйли, ачы, йөрәкне кистерерлек иттереп сөйли, аның тавышы тамырлардан йөгерә, югарыга күтәреләсе килә. Уйнаучының йөрәге дәртенә чыгып җитә алмыйча, скрипкәнең өстенә чыгып, телләре арасында тиберченгән кебек була.

Синең йөрәк күтәрелгәннән күтәрелә. Ул түзми — скрипкә белән — бергә елый, сызлана башлый. Тамак төбенә нәрсәләр килеп тыгыла. Нарасый балалар кебек бер үксеп-үксеп елыйсы килә. Менә инде скрипкә бер матур кызның бала тирбәткәндә борын эченнәнрәк чыгарган тавышына охшаган бер тавыш чыгара да туктый. Һава бер-авык «ыңңң» дигән бер тавыш белән яңгырап тора.

Инде бакчада Рөстәмнән башка кеше калмый, бар да китеп бетәләр. Агарып бара торган ай күңелсез генә тау артына батып ята. Аның актык нурлары зур тау башындагы каберләрнең озынча ташларын әз-мәз яктырталар. Ул ташлар ай яктысында кәфенгә төренгән үлекләр төсле булып күренәләр. Солдатлар төсле бер рәткә тезелгән озын тупыл агачлары арасыннан озын мәчет манаралары сузылып тора.

[1] Мазарстан — зират, каберлек.

һава гаять дәрәҗәдә тын. Менә берзаман хан сарае мәчетенең мәзине фәукылгадә[1] матур тавыш белән иртәнге азан әйтергә башлый. Аның тавышы дулкынланып-дулкынланып тау буенча бик озакка китеп югала. Мәзин, үзенең тавышы кая китеп югалганын тыңлап торган төсле, бераз туктап тора да, тавышының ингыйкясы[2] беткәч, тагын сузып җибәрә. Аның тавышы музыкадан да ягымлы, сөйкемле тоела, ул бөтен тамыр буенча йөгерә. Ул кемнәрнедер йокыдан уятырга тели, чакыра, ләкин һаман да кыймылдаган, уянган кеше күренми. Менә мәзиннең актыккы тавышы Чөфет кальганең[3] диварларына бәрелеп кире кайта башлый. Мәзин төшеп китә.

Тирә-якта тагы тынлык хөкем сөрә.

Бу музыка, бу матурлык Рөстәмгә шул кадәр нык тәэсир итә ки, ул ни кадәр азаплануы өчен беренче мәртәбә елап җибәрә. Күздән аккан кайнар яшьләр белән эчтәге авырлыклар да азрак тышка чыккан, күңел азрак тынычланган төсле була. Ул хәзер дөньяда бөтен авырлыкларда үзенә ярдәм итә, булыша торган югары бер көчнең барлыгын, адәм балаларының бөтен эшләре, елаулары, шатланулары шул көчкә бәйләнгәнен томанлы гына сизенә. Аның менә шул мәчеткә кереп намаз укыйсы, бөтен якыннары, дөньядагы бөтен кеше өчен саф кальб[4] белән дога итәсе, бөтен эшенең бәхетле, мәсгуд булуын алладан сорыйсы килә... Шуның артыннан ук ул үзенең больницасын, андагы авыруларын, «Үтте ич рәхәт җәйләре-е-е», дип җырлый торган Хисами белән карт докторын сагына, аның тизрәк алар янына кайтасы килә.

Шул көнне ул кичке поезд белән өенә китә.

Инде ул авылда тын гына тора башлый. Больницада бик тырышып эшли. Йомыш белән килгән халыкка кулыннан килгән кадәр ярдәм итә. Шифаханәдә ул кайчагында килгән чирлеләргә акыра, ләкин шулай да авырулар аны яраталар.

— Карахтиры начарын начар, әмма үз эшен яхшы белә һәм «син пычрак игенче!» дип җирәнеп тормый, ярдәм итә,— диләр.

Аның дөньяда иң якын ике кешесе була. Берсе Хисами, берсе теге карт доктор. Ләкин озак та үтми, алар икесе дә картлыктан үләләр. Рөстәм дә үзенең кылый күзле, озын бөдрә чәчле Актырнак исемле эте белән ялгыз кала. Инде ул ярыйсы гына картая.

Кайчагында ул кичләрен бүлмәсендә китап укып утыра, Актырнак та, колакларын салындырып, акыллы күзләре белән аңар карый. Менә бер заман Рөстәм укудан туктап, тәмәкесен тартырга, агара башлаган сакалын чәйнәргә башлый. Үткәндә булган эшләр берсе артыннан берсе аның күңеленә киләләр. Ул теге иләмсезрәк тавышы белән борын эченнән генә шыңшыйсы урында, Хисамидан өйрәнгән җырларын көйли, моңая, үзенең хәзерге ялгызлыгын уйлый. Озак кына иттереп: «Үтте ич рәхәт җәйләре-е-е-е», ди. Актырнак акыллы күзләре белән аңар карап тора-тора да, хуҗасының эчендәге бөтен авырлыгын аңлаган, аның бөтен хәсрәтен бүлешкән шикелле, үзе дә уларга, елаган төсле итеп тавышлар чыгарырга башлый. Рөстәм аның башыннан сыйпый, үбә. Актырнак та улавыннан туктый, тик кисәк, кисәк кенә шыңшып куя.

Рөстәмнең күңеленә Фәриданең Киевкә язган хатындагы: «Инде нишләргә дә белмибез», дигән сүзләре төшә. Ул Актырнакка карый да:

— Әйе, инде нишләргә дә белмибез...— ди.

---

[1] Фәукылгадә — гадәттән тыш, чиктән тыш.
[2] Ингыйкяс — кайтаваз.
[3] Кальга — крепость.
[4] Кальб — күңел.

* * *

Еллар уза. Рөстәм инде үлгән була. Касыймның кая икәнен белгән кеше булмый. Тик халык арасында: «Сибириядә йөри имеш, урыс булган имеш»,— дигән хәбәрләр генә ишетелә.

Мирза җирләрен ниндидер бер ерак варисы килеп юк кына бәһасына авыл халкына сатып китә.

Дим әкрен генә ага да ага, еллар һаман берсе артыннан берсе уза баралар. Гайса мирзаның бакчасы да, өйләре дә инде көннән-көн искерәләр, көннән-көн кайгылы төскә керә баралар. Анда бөтен җир буш, бөтен нәрсә тын гына нидер көтә. Төннәрен монда бигрәк тә тын була. Тик ара-тирә шомлы кош мәче башлы ябалакның ачы тавышы белән кычкыргалаганы гына ишетелә.

Әбиләр кичке озын төннәрдә орчыкларын эрли-эрли яннарына түгәрәкләшеп утырган балаларга ул хәрабә турында әллә нинди куркынычлы әкиятләр сөйлиләр. Картлар исә аның яныннан узганда тирән уйга чумган бакча белән ишелеп бара торган өйгә бер карап алалар да мәгънәле генә итеп:

— Бичара мирзаның балаларына бу нигездә рәхәт күрергә ходай язмаган икән инде!— диләр, тагын шуның артыннан ук:

— Мал да бар иде, дәүләт тә. Булмаса булмый икән инде!— диләр.

Гомумән, алар бу нигезгә әллә нинди бер тәгъзыйм белән карыйлар һәм яшьләрдә дә шул тойгыны уяндырырга телиләр булырга кирәк. Урыны чыкканда, аның әүвәлге хуҗаларының тормышлары, башларыннан үткән вакыйгалары, аларның иткән яхшылыклары турында бик озак иттереп сөйләргә яраталар; шундый зур бер гаиләнең болай эзсез-нисез юк булуына алар күп вакыт аптырыйлар, аның сәбәпләрен төрлечә башлыйлар, һәм актыгыннан мәгънәле генә итеп:

— Булмаса булмый икән инде ул,— диләр.

# ПУБЛИЦИСТИКА

## Ибраһим Нуруллин

# ӘДИП ЭЗЛӘРЕННӘН — ТӨРКИЯДӘ

Тәкъдирдә язылган чынга ашмый калмый дигәндәй, миңа да тарихыбызда, мәдәниятебезнең барышында зур гына роль уйнаган Төркия җиренә аяк басу һәм айдан артык һавасын сулап яшәү насыйп булды. Әмма кайберәүләрнең, сәяхәтче булып барып, Америка яисә Һиндстанны ачканнары кебек, мин «Төркияне ачтым» дип әйтә алмыйм. Чөнки андагы һәр ун көннең сигез-тугызы кульязма һәм китап-журналлар уку, күчерәсен күчерү яисә эчтәлеген кыскартып язу мәшәкатьләре белән узды.

Мәсьәлә аңлашылсын өчен чигенеш ясамый булмый.

Журнал укучыларының исендәдер: бүген кабаттан татар милләтенең мактанычы булып санала башлаган Гаяз Исхакыйны һәм аның мирасын халыкка кайтару кебек, ул вакытта әле тормышка ашмастай күренгән эшне кузгатып җибәрүчеләрнең берсе һәм төпкә җигелеп тартучы кеше шушы юлларны язучы фәкыйрегез иде. «Вопросы литературы» журналында беренче публикация, «Казан утлары»нда аның тәрҗемәсе, «Вечерняя Казань» һәм «Социалистик Татарстан» газеталарында тулы бит, искечә уйлый торган берничә профессор белән матбугат битләрендә шактый озакка тартылган бәхәс...

Бу вакытларда Г. Исхакыйның Анкара шәһәрендә яшәп ятучы кызы профессор Сәгадәт ханым Чагатай, андагы татар җәмәгатьчелеге бөек әдипне кайтару өчен барган көрәшне зур кызыксыну һәм өмет белән күзәтәләр иде. «Исхакыйның соңгы унбиш елы узган Төркиягә барып, аның турында материал җыяр идем, ярдәм итмәссезме?» — дигән үтенечемне, билгеле инде, алар бик теләп тормышка ашырырга керештеләр. Менә берзаман чиновниклар кул куйган, мөһерләр басылган чакыру кәгазе килеп төште. Чыгып китү вакытын сентябрь урталары дип билгеләдек, чөнки аңарчы Сәгадәт ханым һәм миңа кирәкле бүтән кешеләр ялдан кайтып җитмиләр икән. Әмма миңа Гаяз Исхакыйның бердәнбер баласы, бердәнбер варисы Сәгадәт ханымны күрергә насыйп булмады: 1989 елның 24 июнендә үлеп киткәнлеге хакында кайгылы хәбәр килде. Мине чакыруны оештыручылар шулай да әйтелгән вакытта баруны хупладылар.

Алда әйтелгәнчә, бердәнбер максатым — материал туплау, әдип хакында мөмкин кадәр күбрәк белеп кайту булганга һәм татарлар белән генә дип әйтерлек аралашканга күрә, хөрмәтле укучылар миннән Төркия турында, аның экономик һәм сәяси хәле, мәдәнияте, гореф-гадәтләре һ. б. турында күп мәгълүмат алырга өмет итмәсеннәр. «Төркияне ачтым» дип әйтә алмыйм, дигән сүзләрнең мәгънәсе әнә шуңа кайтып кала. Күз бар, колак бар, дигәндәй, соңгыларыннан да кайбер нәрсәләр ияреп кайтты, билгеле. Шулар белән уртаклашсам, укучы өчен бөтенләй үк файдасыз булмас дип беләм.

* * *

Ни рәвешле таможнядан узуым, ничек самолетка кереп утыруым, һавага күтәрелеп, ике сәгатьләп вакыт үткәннән соң, җәйрәп, зәңгәрләнеп яткан

Кара диңгез өстеннән очып узуым, Босфорның ике ягына бүленеп утырган Истанбулның мәһабәт сарайларын, йөзләгән манараларын дулкынланып күзәтүем, Төркия өстеннән Анкарага таба очканда өй түбәләренең тоташтан кызыл булуына гаҗәпләнүем һәм моңардан нindидер мәгънә чыгарырга азапланууларымны язып тормыйм. Мине чакырып китерүне башкаручы, вакытымның файдалы узуы өчен иң күп булышучы бер шәхес турында киңрәк мәгълүмат бирүне исә кирәк табам.

Сүз инженер-гидролог Мәхмүт әфәнде Таһир турында бара. Харбинда туган, инженер дипломы алган Мәхмүт әфәнде, пенсия яшендә булса да, ведомство җитәкчеләренең үтенүе буенча, эшләвен дәвам иттерә. Тырышып, җиренә җиткереп эшли. Ял хисабына, йокы хисабына, яратып, илһамланып башкара торган икенче эше — бәлки әле беренчеседер — тарих. Татар милләте, татар мәдәнияте тарихы. Искиткеч хәтергә ия. Белмәгәне аз булыр. Каләме дә бар. Яза, язганнарын төрле урында дөньяга чыгара тора. Ерак Көнчыгыштагы татар эмиграциясе тормышы аны аеруча кызыксындыра. Бусы, әлбәттә, гаҗәп түгел. Гаҗәбрәге шул: безнең илдәге татар мәдәнияте тарихын да ул, артыграк булмаса, әйтик, миннән ким белми кебек.

Атаклы кешеләр тарафыннан язылып, кайчандыр рус телендә басылып, әмма соңрак тыелган китапларның соңгы елларда Лондонда фотокүчермәләре чыгарыла башлады. Кемнәрдер аларга инглиз телендә кереш яза, кемнәрдер бай гына библиография белән тәэмин итә. Шундыйлардан И. Гаспринскийның «Русское мусульманство», Г. Исхакыйның «Идел-Урал», Җ. Вәлидинең «Очерк истории образованности и литературы татар» исемле китаплары минем кулга да керде. Бу сериянең инициаторы, кереш мәкаләләрен һәм библиографияләрен язучы яисә оештыручы кеше дә нәкъ шушы Мәхмүт әфәнде булып чыкты! Җ. Вәлиди турындагы китапны ул тулысынча үзе әзерләгән. Бу басманы миңа бүләк итеп китергәч, мин аңардан автографын сорадым. Риза гына булмый бит. Минем эшмени ул, янәсе, Бенигсен эшләде аны. Бик озак кыстагач, түбәндәге сүзләрне язып куйды: «Хөрмәтле Ибраһим Нуруллинга Төркиядәге хатирәләребезнең бер билгесе итеп тәкъдим итәм. Мәхмүт Таһир».

Төркиядәге татар мәдәнияте учагын ягулык өсти-өсти, сүндерми асраучыларның иң күренеклесе шушы Мәхмүт әфәнде дисәм, шаять, хата булмастыр.

Нindидер ашыгыч эше килеп чыгу сәбәпле, Мәхмүт Таһир мине каршылый алмады. Аэропортка ул төрки халыклар мәдәниятен өйрәнә торган Институтта гыйльми хезмәткәр һәм китапханә башлыгы Сәидә ханым Арсланбәкне җибәргән иде. Мөһаҗирәттә, ягъни эмиграциядә күренекле урын тоткан педагог һәм шагыйрь мәрхүм Мансур Арсланбәк кызы ул. Ике энесе бар: берсе — Мәсүд, Төркия парламентында инглиз теленнән тәрҗемәче булып эшли, икенчесе — Сами, инженер, Көнбатыш Германиянең Штутгард шәһәрендә яши. Әниләре Мөшфика ханым пешергән токмачларның тәме әле дә авызда кебек. Төркиядәге миссиямнең, үзем уйлаганча, уңышлы чыгуы белән мин, икенчедән, әнә шул Арсланбәкләргә бурычлымын.

Сәидә ханым белән күрештек, таныштык. Аннары — такси. Тигез асфальт юл. Эреле-ваклы авыллар. Өй түбәләре, әлеге дә баягы — кызыл чирәп. Мәчет манаралары сузаеп-сузаеп кала.

Кайнап торган зур, шаулы һәм чуар шәһәргә килеп керәбез. Бу — Анкара. Автомобиль нindидер бер мәйдандагы күпкатлы бина янына килеп туктый. Мәхмүт әфәнденең эш урыны икән бу. Бераздан ул үзе дә килеп чыкты. Күрештек. Урта буйлы. Чандыр ук булмаса да, шактый төз гәүдәле ир. Артык исе китмәгәндәй, төчеләнмичә генә күреште. Әйтерсең, кыска вакытта аерылышып торганбыз да хәзер күрешәбез.

Тагын таксига утырып киттек. Кибетләр. Рекламаларга күмелгән урамнардан бара торгач, бер тыныч кына, тар гына урамга барып кердек һәм җиңел кулдан салынгандай күренә торган өч катлы кечерәк өй янына килеп туктадык.

Озын гына коридордан бер зур бүлмәгә керәбез. Буш, шыксыз. Бер аш, бер язу өстәле, хан заманыннан калган сервант, суыткыч та вәссәләм. Бу бүлмәгә кергәләп кенә чыгалар булса кирәк.

Соңыннан билгеле булганча, Сәгадәт ханым Чагатай 1988 елда Идел-Урал төбәгендә һәм Урта Азиядә яшәүче төрки халыкларының тарихын һәм мәдәниятен өйрәнүгә ярдәм йөзеннән «Аяз-Таһир Төркестан — Идел-Урал вәкыфы» исемле бер учреждение булдырган һәм 1984 елда вафат ире про-

фессор Таһир Чагатай белән үзе тапкан малның зур өлешен шуңа биргән. Мин килеп кергән әлеге өч катлы, алты фатирлы өй Сәгадәт ханымның вакыф (бүләк) итеп биргән өе икән.

Тагын шунысы да мәгълүм булды: Сәгадәт ханым мине үзенең хәзерге өенә кабул итәргә ниятләп, иренең эш бүлмәсен ремонтлаткан булган. Ләкин үзе үлгәч, варислары калмаганлыктан, өенә мәхкәмә мөһер суккан. Мена ни өчен мине вакыф советы әгъзасы, уйгур Шәкүр Туран исемле бер ялгызак чиновник кына тора торган шушы каралмаган өч бүлмәле фатирга куярга мәҗбүр булганнар.

Мәхмүт әфәнде, минем күңелемдә туа башлаган ниндидер шыксыз тойгыны юкка чыгарырдай сүз әйтеп куймасынмы:

— Сез хәзер Гаяз аганың креслосында, үз кулы белән ясаган өстәле янында утырасыз...

Язмыш юк дип әйтеп кара син! Г. Исхакыйның мирасын барлау-өйрәнү эшен башлаучы адәм Советлар иленнән беренче кеше булып аның креслосына барып утыра, бер ай буе аның өстәлендә эшли! Бер ай буе шушы хакыйкать мине җылытып, миңа көч-куәт биреп торды.

Шулай да, яшерер хәлем юк, баштагы бер атнам рәхәт үтте дип әйтә алмыйм. Беренчедән, Мәскәүдән салкын тидереп килгән идем, төчкерәм дә йөткерәм. Икенчедән, чит җир, ят халык. Телләребез якын булса да, сүз житешмәгәнгә һәм колак күнекмәгәнгә, аңлашу кыен. Хәтта Шәкүр әфәнде белән сөйләшкәндә дә вакыт-вакыт кул ишарәсенә эш кала. Анкарада яшәүче милләттәшләр мине ташламасалар да, көн саен димим, көн аралаш килеп торсалар да, шушы беренче көннәрдә мин үземне еш кына бик үк тансык түгел итеп хис кыла идем.

Эч пошулы халәтемнең өченче сәбәбе дә бар иде.

Авырганлыктан һәм башым житди эшкә сәләтсез булганлыктан, вакыт бушка узмасын дип, иртән якта Г. Исхакыйның ун ел буе үзе чыгарган «Яңа милли юл» исемле журналында дөнья күргән «Гәзитчелек эшендә 25 ел» исемле озын истәлеген күчерергә, ә кичке якта мөһаҗирәттә язылган һәм шунда басылган әсәрләрен укырга керештем.

«Көз» исемле кыска романы психологик нечкәлек һәм Гаязга хас осталык белән язылган булуыннан кала, безнең позициядән торып карагавда да, идеологик җәһәттән зарарсыз. Анда купец кызының, лаеклы кешене сөеп һәм мәхәббәте өчен көрәшеп, бәхеткә ирешкәне, ә мирза кызының, морзачылык гореф-гадәте һәм характер йомшаклыгы аркасында, эчкече офицерга тап булып, фаҗига кочагына барып кергәне тасвир ителә. «Ойгә таба» исемле повесте исә минем күңелне күтәрерлек булып чыкмады. Россия гаскәрендә хезмәт итүче татар полковнигы, бер төркем мөселман офицерлары белән берләктә, солдатлар арасында аңлату һәм оештыру эшләре алып барып, җае чыккач, дивизиясе белән Төркия гаскәре ягына чыга. Моның белән ул, күрәмсең, өеннән, ватанынинан ерагаймый, киресенчә, якыная. «Дулкын эчендә» диган драмасы да рухландыра алмады: Октябрь көннәрендә большевиклар өйләргә бәреп керәләр, талыйлар, үтерәләр.

Истәлегенә килсәк, анда әдипнең тормыш юлы шактый тулы яктыртылганга, кызыксынып күчерә башладым. Әмма беренче яртысы объективлыкны саклабрак язылган булса да, 1905-07 еллардагы «Таң йолдызы» газетасын чыгарган Гаяз анда юк инде, хәтта 1912-16 еллардагы «Ил»че Гаязны да күреп булмый. Истәлекнең икенче яртысында, бигрәк тә «Яңа милли юл»ның бүтән саннарына кергән мәкаләләрендә инде ул сыйнфыйлык принцибын читкә атып, социалистик идеалдан ваз кичкән, «тар милләтчелек» позициясенә баскан һәм әлеккеге идея дошманнары И. Акчура, С. Максуди белән дуслык мөнәсәбәтендә яши башлаган Исхакый булып калка.

Марксизм-ленинизм тәгълиматының дөреслегенә иман китергән, Октябрь революциясен кешелек тарихында бөек борылыш дип таныган һәм Ленинның даһилыгына сокланып яшәгән мин фәкыйрьнең җаннан газиз нәрсәсен болар аяк астына салып таптагандай тоела иде. «Юкка керештем ахрысы бу эшкә, ничек дәвам итәрмен» кебек уйлар кила башлады. Анкарадагы беренче атнамны төшенке күңел белән үткәрүемнең тагын бер житди сәбәбе әнә шул.

Болары күбрәк — күңел, йөрәк эше, билгеле. Әле бит акыл диган нәрсә бар. Ул әйтә: Исхакыйны тарихи шартларга куеп кара син! Ул бит, барлык эсерләр һәм меньшевиклар кебек үк, Россия, бигрәк тә аның милли төбәкләре, социалистик революция өчен өлгереп җитмәгән, Октябрь — боль-

шевиклар авантюрасы, диган караштa тора иде. В. И. Лениннын үлеп китүе, аның мәкер һәм ялган алдында аптырап кала торган көрәштәшләрен этеп-төртеп, Иосиф Джугашвилиның властька килүе, Ленин эшен ленинча дәвам иттерергә теләгән кыю кешеләрне төрлечә юкка чыгара-чыгара, тоталитар-деспотик режим урнаштыруы аның шул карашын, билгеле, ныгыта гына барган. Сталинны ул Ленин эшен дәвам иттерүче итеп күрә, сталинизмны ленинизмнан чыгара башлаган. Тагын болай дип уйлый идем: политик карашларының эмиграциядә нинди рәвеш алуына карамастан, Г. Исхакый безгә барыннан да элек, тормыш чынлыгын тирәнтен ачып бирә торган әдип буларак, XX йөз башы татар әдәбиятының баш фигурасы, тәнкыйди реализм юнәлешен нигезләүче буларак кадерле.

Әнә шул килеш, йөрәк белән акыл бәхәсен тыңлый-тыңлый, мин «Яңа милли юл» журналын хронологик тәртиптә рәттән укыйм да укыйм, материалларының эчтәлеген үз сүзләрем белән теркәп барам, аерым урыннарын күчереп алам, бик тә әһәмиятле мәкаләләрне ксерокопиясен алдыру өчен билгелим. Әдипнең мөһаҗирәттә язылып басылган яисә басылмый калган кайбер бүтән әсәрләрен уку, архивта сакланган хатлары һәм башка төр документлар белән танышу да арага керә. Гаяз Исхакый күңелемә кабаттан якыная, сурәте ягымлылана, аңа багышланган хезмәтем дә кирәкле һәм мәгънәле тоела бара.

* * *

Иң күп вакытым дүрт стена эчендә укып һәм язып узса да, тыштагы зур дөнья да читтә калдырмады, билгеле. Ашыйсы-эчәсе дә, кирәк-яракларны эзләп кибетләргә кергәлисе дә бар бит. Бүтән төр мәшәкатьләр дә чыккалап тора.

Мин социалистик ил саналган җирдән Төркиягә — европалаша башлавына күп заманнар узган илгә килгән кеше бит инде. Соң моны ничек хис итәм? Ике ил арасында нинди аерма, нинди контраст күрәм? Баштарак әллә ни аерма да, контраст та күрмәдем. Ике аяклы, ике куллы шундый ук кешеләр. Иртән ашыга-ашыга эшкә баралар. Балалары шулай ук, букчаларын аркаларына тагып, мәктәпкә юл тоталар. Карт-корылары да бездәге кебек. Сумка тотып кибеткә йөри.

Аермага килсәк, иң элек күзгә ташланганы шул: адым саен — төрледән-төрле кибет. Азык-төлектән җаның ни тели, шул бар. Җиләк-җимеш һәм яшелчә матур, җыйнак әрҗәләрдә тышка тезеп куелган. Төрле төсләр белән елкылдап, күзне иркәлиләр. Әйберләр белән дә шул ук хәл. Көннәрдән бер көнне хатыным, кызларым һәм оныкларыма бүләк сайлауда ярдәм итәр өчен Сәидә ханым белән Мәсүд әфәнде мине Ататөрек бульварындагы сәүдә үзәгенә алып киттеләр. Андагы кибетләрнең зурлыгына, мәһабәтлегенә, эчләрендәге малның күплегенә, төрлелегенә һәм затлылыгына хәйран калдым.

Айдан артык яшәп, чират күрмәдем, дип әйтер идем, телефон-автомат янында басып торгаларга туры килде. Анысы да дүрт кабинаның икесе яисә өчесе эшләмәгән чакта. Министрлык карамагындагы объект шул бу...

Күз ияләшеп, колак зирәкләнә төшкәч, мин, әлбәттә, буржуаз илдә яши башлавымны хис итә башладым. Хәер, килгәннең икенче көнендә үк иртән моның беренче билгеләре ишетелде. Сузып-сузып кычкырган тавыш колагыма кереп, балконга чыгып карасам, башына куйган зур түгәрәк поднос белән нindидер ашамлык сатып йөрүче адәмне күрдем. Аннары кул арбасы белән суган, бәрәңге кебек нәрсәләр сатучы килеп чыкты. Мотороллер яисә йөк машиналарыннан яшелчә, он, ярма кебек әйберләр тәкъдим итеп аваз салучыларны да ишеткәләдем. Чиста су сатып йөри торган махсус автомобильләр дә бар икән.

Начармыни бу, дияр укучы, бездә дә шулай сатып йөрсәләр, халык рәхмәт кенә укыр иде. Әйе, начар түгел. Минем игътибарны җәлеп иткән бүтән нәрсәләрнең дә күбесе һич тә яманларлык түгел, хәтта безгә күчерерлек. Подъездларның һәр катында, мәсәлән, лампочканы 15-20 секунд кына яндырып тота торган автомат куелган. Фатирыбыз эчендә андый автомат булмаганлыктан, минем арттан лампочкаларны Шәкүр әфәнде сүндереп йөри иде. Мин эшли торган әлеге бүлмәдәге люстраны да биш төрле вариантта яндырырга өйрәтте. Яисә кешенең хезмәткә мөнәсәбәтен алыйк. Эленке-салынкы

йөрү, эш вакытында ләчтит сату яисә тәмәке тартып утыру юк инде монда. Җитмешкә якынлашып килә торган Мәхмүт әфәндегә бер көнне болай дидем: «Ник бер үзегез чабасыз? Берәр яшь кеше юкмыни миңа ярдәм итәргә?» Мәхмүт әфәнде сорау белән җавап бирде: «Сезнең моңарчы буржуаз илдә булганыгыз бармы?» Минем тискәре җавабыма каршы: «Шул-шул, сезелә,— диде ул.— Тырышып эшләмәсәң, монда өстеңә менәләр».

Буржуаз җәмгыятькә хас, аның аслыннан чыга һәм күчергеч булырга ярамый торган байтак күренешләр дә күзгә чалынды.

Профессор Әхмәт әфәнде Тимер (аның турында әле сүз булыр) бер көнне мине ресторанга алып китте. Соңыннан сорап белдем: бу, иң югары разрядлы ресторан булмаса да, икенче дәрәҗәгә туры килә икән. Ашадык-эчтек, Әхмәт әфәнде официант белән исәп-хисапны өзде. Икенче бер буш зал янынан узганда, профессор әйтте: «Кофе эчеп чыкмыйбызмы?» Миңа кызык, беләсе килә, уңай җавап бирдем. Уймактан зуррак ике чынаяк белән кофе китерделәр. Эчтек, түбәре аста калды. Әхмәт әфәнде каядыр телефоннан сөйләшергә китте. Туктале, мин әйтәм, кесәдә лира бар, байларча итенеп, исәпләшеп куйыйм. Официант егетне чакырып китердем дә төрекчәләтебрәк: «Кач парә?»— дидем. 5750 лира димәсенме бу! Күзем маңгаема менде. Урамдагы һәркем керә торган кафеда бу акчага төшкене туйганчы ашап була. Социаль контрастларның бер чагылышы дими ни дисең моны? Яисә менә тагын берсе. Урамнарда машина күп. Хәрәкәттәгеләре дә, яртылаш тротуарга кереп төн куна торганнары да. Соңгылары уңае белән Шәкүр әфәндедән сорадым: гаражлары юкмыни? Байларныкы бар, диде. Контрастның өченче бер чагылышы үз аягы белән килде. Кыңгырау шалтырагач, ишекне ачкан идем, тәбәнәк буйлы, кара сакаллы бер карт басып тора. Шәкүрне чакырдым. Ул нидер сөйләште дә ишекне ябып куйды. Минем сорауга бер сүз белән генә җавап бирде: теләнче. Шуңа охшаш хәлне Истанбулда да күрергә туры килде. Үзебез төшкән кунакханә күршесендәге бинаның эчкәрәк кереп тора торган подъездында төн үткәргән бер карт иртән уянып, торып килә иде.

Коммерция — коммерция инде. Тулаем алганда, ул закон кысасыннан читкә чыкмый. Әмма хәрәмләшү юк түгел икән. Бигрәк тә әҗнәбиләрне, ягъни читтән килгәннәрне алдыйлар. Совет илчелегенә барып күренү бурычымны үтәүдә дә Мәхмүт әфәндене борчымаска теләп, такси белән үзем генә бару фикеремне Шәкүргә әйткәч, ул киңәш бирмәде. Чөнки, диде, әйләндереп-әйләндереп йөртәчәк тә күп акча алачак. Магнитофонга кассеталар алуны да, шуны ук сәбәп итеп, Мәхмүт әфәндегә тапшырырга киңәш итте. Гомумән, монда сатулаша белмәгән кеше кибеттә тиешлесеннән күбрәк калдырып чыга икән.

Сизеп торам, укучым ирония белән елмая: соң бит социаль контраст дигәннәрегез бездә дә бар. Өйсезләр дә, саилчеләр дә, алдаулар да. Соң ни турыда сөйли бу? Бездә дә социализмның юклыгы турында гына түгелме? Күп еллар буе күзәтү, уку, уйлануларымның нәтиҗәсе булып ныгыган иманым шул: егерменче елларның уртасыннан башлап без, Ленин васыятьләрен үтибез, дип шапырына-шапырына, социализмның кайбер билгеләрен эченә алып та, бу гадел түзелеш белән берниди уртаклыгы булмаган ниндидер яңа типтагы крепостнойлык строе барлыкка китердек.

Укучының кызыксынуы мөмкин: күпне күргән, күп газап кичергән һәм кабат демократия юлына баскан илебезгә төрекләрнең мөнәсәбәте ничек? Кистереп әйтә алмыйм. Чөнки дүрт стена эчендә утырып күп нәрсә күреп, ишетеп, белеп булмый. Кызыксыну барлыгын һәм шактый куәтле булганын беләм. Мөнәсәбәт тә бер төсле генә түгелдер дип уйлыйм: чөнки җәмгыять төрле социаль катлау һәм сыйныфлардан тора. Түбән катлау, хезмәт ияләре безгә симпатия белән карыйлар төсле күренде. Бер аш өләшүче минем кайдан килгәнлегемне һәм милләтемне сорады. Мин, Казан татары, дим, аңламый, шималь төрке дим, бусы да барып җитми. Советлар берлеге, Русия дигән идем, ниһаять, чамалап алып: «Горбачев!»— дип кычкырып җибәрде. Официантым кабат әйләнеп килгәч, сорау бирдем: «Горбачев яхшымы?» «Яхшы!»— диде бу имән бармагын тырпайтып. Соңыннан әйттеләр: кибет яисә ашханә кебек урыннарда русларга, гомумән, «Горбачев» дип эндәшәләр икән: керең, Горбачев, боерың, Горбачев!..

* * *

Төркия җиренә килү максатымның икенче өлеше — Г. Исхакыйны күргән-белгән кешеләрне эзләп табу, сөйләтү, язып алу һәм акка күчереп кул куйдыру — һаман сузыла килә. Бу турыда борчылуымны белдергәч, «Бередә алай гына җиңел түгел ул,— диде Мәхмүт әфәнде.— Алдан сөйләшергә, аңлатырга кирәк».

Хәер, миңа кирәкле кешеләрнең кайберләре үзләре килеп чыктылар. Анкарага аяк басуымның икенче көнендә үк профессор Әхмәт Тимер килде. Ул Бөгелмә ягында мулла гаиләсендә туып үскән. Урта мәктәптән соң, Ленинградка барып имтихан биргән. Ләкин, мулла малае дип, алмаганнар яисә алып та куып чыгарганнар. Шуннан әтисе әйткән: «Монда сиңа уку насыйп булмас инде, улым, Төркиягә китү ягын чамала!» 1929 елда ул бер иптәше белән Батумга барып, контрабандистлар ярдәмендә, Төркия ягына чыккан. 1936 елда, шунда алган белемен киңәйтергә теләп, Берлин университетына барып кергән. Студент чагында ук, шарыкны өйрәнү семинарында, үзе дә дәресләр биргән. Белгечлеге — тюркология һәм монголоистика. Фән докторы дәрәҗәсе алып кайту максаты булганга, сугыш башлангач та ул, Германиядә торып калган.

Гыйльми дәрәҗә алгач, Әхмәт әфәнде Төркиягә кайтып киткән. Башында Иосыф Акчура торган мәдәни идеологик хәрәкәт нигезендә барлыкка килгән «Төрек культурыны араштырма (өйрәнү) институты»ның ул — беренче директоры. Хәзер аслый үйә, ягъни действительный член, сыйфатында гыйльми эшен дәвам итә. Г. Исхакыйны Германиядә дә, Төркиядә дә күп мәртәбә күргән. Вәгъдәсендә торып, әдип турында истәлек язып бирде.

Галим белән еш очраштык, байтак әңгәмәләштек. Бу урында аның бер фикерен генә әйтәсем килә: Исмәгыйль Гаспринский башлап җибәргән, Й. Акчура үстереп алып киткән, бездә куркыныч эпитетлар кушып, пантюркизм дип аталучы күренешне, аныңча, бу исем белән атау дөрес түгел. Чөнки ул, ягъни төрекчелек, төрки халыкларны сәяси яктан түгел, бәлки мәдәни яктан берләштерүне генә алга сөргән.

Сүз арасында тагын шул аңлашылды: Әхмәт әфәнде туган илен сагынып яши икән. Гади сагыну түгел бу, җирсү, ностальгия дәрәҗәсенә җиткән сагыну.

Тагын берничә көннән соң, мин эшләп утырганда, кыңгырау чыңлатып, бер карт килеп керде дә үзен «Әсфәндияр» дип таныштырды. Өстәл янына утыру белән ярым төрекчә, ярым себер татарыча ничек итеп әсирлектә булуын, ничек легионга эләгүен тәфсилләп сөйли башлады. Аз гына да тынып тормыйча, сүз артыннан сүзне сиптерепме сиптерә! Көч-хәл белән генә сүзне биографиясенең баштагы өлешенә таба бордым. Тобол тирәсендә туган, 7 классны бетергәч, Свердловск техникумында укыган. Әдәбият түгәрәгенә йөргән, шигырьләр язган, Хатип Госман һәм Абдулла Әхмәтләр белән аралашкан. Оренбург пединститутын тәмамлагач, тел-әдәбият укытучысы булган. Аннары сугыш, әсирлек. Легионга тартканнар, «Идел-Урал» газетасында корректор булып эшли башлаган. Сугыш бетеп, күпмедер вакыт үткәч, Төркиягә күчеп килгән, өйләнгән, балалар үстергән. Хәзер пенсиядә.

Гаяз Исхакыйны ул беренче мәртәбә 1948 елда, Төркиягә килгәч кенә күргән.

Әсфәндияр агай Ижгайның икенче килүендә ишектән үк сөйли-сөйли керүе, мин чәйнекне карарга чыкканда да, сөйләвеннән аз гына да бүленмичә, тагылган кебек ияреп чыгуы, ияреп керүе, кунакка алып китүе, шактый бай китапханәсе белән таныштыруы, үз хисабына чыгарган ике шигырь җыентыгын күрсәтүе һәм өйдәгеләрнең, мине аяпмыйдыр, тыебрак торулары турында артык җәелмим. Ни әйтсәң дә, тугызынчы дистәсен ваклый башлаган, илле елга якын читтә яшәгән агайның сүзе бик күп җыелган, тыгызланып тулган.

Минем исемлеккә кергәннәрнең берсе — Зөһрә ханым Киришне Сәидә Арсланбәк алып килде. Кечерәк кенә, түгәрәк кенә, матур гына бер карчык. Фамилиясенең ник шундый булуы белән кызыксынгач, яңгыравыклы яшь тавыш белән: «Гаяз әфәнде кисте аның коерыгын!» — дип куйды.

Пенза ягында туган, Манчжуриянең Хайлар шәһәрендә үскән, гимназиядә укып мөгаллимә булып киткән, мәктәптә мөдирә вазифасын да башкарган. Гаиләсе ишәя төшкәч, ул җәмәгать эшләрендә катнашу белән чик-

ләнә башлаган. Г. Исхакый белән Зөһрә ханым 1934 елда, әдип Хайларга килгәч, танышкан. Фамилия коерыгын кисү мәсьәләсенә кайтсак, сүз татарларны милли рухта тәрбияләүгә гаять зур әһәмият биргән Г. Исхакыйның русларга охшатмас өчен фамилияләрне кыскартырга киңәш биргәне турында бара.

Зөһрә ханым сөйләгәннәрне шулай ук Ерак Көнчыгыштан, тегәлрәге, Харбиннан күчеп килгән теш врачы Маһирә ханым Байчура да тулыландырды (хәзер пенсиядә).

Ул, гимназиядә укып йөргән чагында, Г. Исхакыйны күргән, танышкан, чыгышларын тыңлаган. «Без, яшьләр, ул вакытта рус мәктәпләрендә укып, руслаша башлаган идек,— диде ул.— Татарлыгыбыздан хәта ояла идек. Рус тәэсире шул чаклы көчле иде ки, исемнәребезне дә русчалатып бетергән идек: Маруся, Галя... Гаяз әфәнденең мондый сүзе истә калган: «Сезнең милләтегез — бөек милләт. Сез татарлыгыгыздан оялмагыз! Кая барсагыз да, кая керсәгез дә, башыгызны югары тотып керегез! Милләтебезне саклап калу өчен сезгә укырга, гыйлем алырга, зиһенегезне баетырга кирәк»...

Миссиямә бәйле рәвештә аеруча зур өмет баглаган шәхес белән очрашуга әзерлек аеруча озакка сузылды. Мин профессор Адилә ханым Айданы күздә тотам. Сырхаулыгы да бар, халәте рухиясе дә тиз һәм еш алмашынып тора, аңлашылмаучылыклар да килеп чыкты.

Мәнә без Мәхмүт әфәнде белән таксида Адилә ханым яши торган өй янына килеп туктыйбыз. Төгәл уналты сәгатькә чакырылган идек. Хәзер дүрт туларга унбиш минут. Йөзенә каушаулы җитдилек чыккан Мәхмүт әфәнде, шул тирәдәге бер эскәмиягә күрсәтеп: «Утырып торыйк шунда бераз»,— диде.

Дәүләт думасы депутаты, 1918 елда игълан ителгән беренче татар җөмһүриятенең хөкүмәт башлыгы, Төркиядә фәнгә бирелеп, хокук профессоры булган һәм җитди хезмәтләр язган Садрый Максуди кызы ул — Адилә ханым.

Россиядә туган, Берлинда һәм Парижда укый башлаган, Төркиядә урта мәктәпне тәмамлап, юридик институтка кергән. Диплом алып чыккач, Чит ил эшләре министрлыгында эшләгән. Хатын-кызны илчелекләрдә эшләүдән тыюга протест йөзеннән бу өлкәне ташлап, әдәбият факультетын укып бетерә. Кияүгә чыгып Истанбулга күчкәч, башта ассистент, аннары ун ел буе доцент була. Биш ел гына эшләгән бер доцентны, аңардан уздырып, профессор итүләренә тагын протест белдереп, Чит ил эшләре министрлыгына кайта. Бу вакыт инде хатын-кыз дипломатларга карата чикләү бетерелгән була. Төрле илчелекләрдә советник булып эшләгәннән соң, 1968 елда Адилә ханым Айданы Италиягә илче итеп билгелиләр. Бөек илче үлгәч, ул бер ел буе аның вазифасын башкара. 1976 елдан башлап Адилә ханым — сенатор. Хәзер пенсиядә.

Әнә шундый гаиләдә туып, шундый тормыш юлы узган ханымның беркадәр капризлы һәм шактый һавалы булуы табигый хәлдер, күрәсең. Мәхмүт әфәнде белән «уналты ноль-ноль»не көтеп, унбиш минутлап эскәмиядә утыруыбызның сере аңлашылса кирәк. Бүтән кайберәүләр дә Адилә ханым Айда янына генерал-губернатор катына кергән коллежский регистратор кебек керәләр икән.

Безне халат кына кигән Адилә ханым үзе каршылады һәм, тиз-тиз генә исәнләшеп, эчкә кереп китте. Без аякларны салып һәм аз-маз төзәтенеп бүлмәсенә кергәндә, ул, мендәренә аркасын куйган килеш, ятагына ярым утырып, ярым ятып тора иде.

Башта тегесен-монысын сөйләшеп алдык. Аннары мин Төркиягә килеп чыгуымның максатын аңлаттым. Сораулар бирә-бирә, Адилә ханымнан үзе турында сөйләттем. Аннан соң С. Максудига бәйләп, сүзне Г. Исхакыйга таба юнәлттем. Әдип турында сөйләгәннәрен монда кертеп тормыйм, чөнки мин аның үз кулы белән язып биргән хатирәсен «Социалистик Татарстан» газетасында доньяга чыгарган идем (1990, 22 февраль).

Адилә ханымда ару билгеләре күренгәч, без, рөхсәт сорап, кузгалдык һәм, әлеге хатирә хакындагы вәгъдәсе белән бергә, бүләк итеп биргән китапларын — безнең эрага кадәр яшәгән этрусклар турында берничә хезмәтен (Адилә ханым аларның төркиләр булганын исбат итә) һәм әдәби тәнкыйть мәкаләләре җыентыгын (бер ара ул бу өлкәдә дә актив эшләгән) алып өйдән чыгып киттек.

Чыгышы белән Кытайның Хайлар шәһәреннән булып, бүген Мюнхенда, язмыш кушуы буенча Төркия аша Европага килеп чыгып, Германиядә төпләнеп калган, Г. Исхакый белән якыннан аралашкан, аның секретаре вазифасын башкарган, бездәге тәртипләрне тәнкыйтьләгән мәкалә һәм китаплары өчен берничә «ортодокс» галим тарафыннан берсеннән-берсе куркыныч эпитетлар белән «бүләкләнгән» журналист Али Акыш яшәп ята. Анкарада аның бертуган абыйсы Азизулла, сеңелләре Фәридә һәм Сәидә бар икән.

Алдан сөйләшү буенча шушы Сәидә ханым мине үзләренә кунакка алып китте. Апасы белән генә торалар икән. Минем хөрмәткә оештырылган мәҗлес булып чыкты бу. Җәмәгате белән Азизулла әфәндедән кала, туганнан туган энеләре Габдрахман һәм Әбрар да хатыннары белән килгәннәр иде. Габдрахман әфәнде Нью-Йоркта яши икән, Әбрар әфәнде — Истанбулда.

Ай-ваема карамый, өстәл башына утырттылар. Сый-хөрмәт гаять мул иде, хәтта «тегесе» дә булды.

Сораулар бирә башладылар. Бигрәк тә «американ» активлык күрсәтте. Аеруча кызыксынганнары — динне кысмыйлармы, яңа мәчетләр салынамы, Казанда күпме татар бар, мәктәптә татарча укыталармы, Чернобыльдән татарларга зыян килмәдеме, Әфганстанда татар егетләре күп үлдеме һ. б. һ. б.

Тагын шунысына игътибар иттем: рус милләтенә карата берсендә дә дошманлык сизелми. Әбрар әфәнде хәтта Ерак Көнчыгыштагы русларны мактап, дус яшәүләрен сөйләп алды. Кытай халкына карата да җылы хистойгы калган. Әшчән, кешелекле, ярдәмчелләр икән. Хатын-кызлар ягыннан «тынычлык булсын иде инде, сугыш чыкмасын иде» дигән сүзләр ишетелде. Ирләрдән берсе өстәп куйды: «Перестройка барып чыксын өчен, тынычлык кирәк». Минем күңел өчен әйтелдеме бу сүзләр, белмим.

Минем белән сөйләшү өчен Али Акыш телефонга заказ биргән икән. Сөйләшүебез ярты сәгать кенә булмагандыр. Беренче мәсьәлә, икенче мәсьәлә, ди-ди, җидегә җиткерде. Төп тема, әлеге дә баягы, милләтне кайгырту.

Шунысын искәртеп узу да артык булмас: мәҗлестә катнашучыларның берсе дә ата-бабаларының туган җиренә аяк баса алганнары юк икән. Али әфәнде Акыш кына былтыр җәй беренче мәртәбә Казанны күрү бәхетенә ирешә.

7 октябрьдә, шимбә көнне «Казан төрекләре культур вә ярдәмләшмә дәрнәке» исемле җәмгыятьнең сезон ачылуга багышланган мәҗлесенә алып киттеләр.

Зур гына зал. Стеналар буйлап куелган өстәлләргә табын тезелгән. Каршыда Казан вокзалының яңа бинасы стенасындагы калфаклы татар кызы рәсеменең күчермәсе. Без барып кергәндә, халыкның бер өлеше өстәлләр тирәсендә утырып, бер өлеше баскан килеш сөйләшеп тора иде. Ирләрнең шактые һәм хатын-кызлардан берничәсе: «Хуш килдегез!» — дип күреште. Әхмәт Тимер, Сәидә, Мәсүд һәм мин утырган безнең өстәл янына килеп, танышып, сөйләшеп китүчеләр күп булды.

Мәҗлесне дәрнәкнең башканы, ягъни рәисе, Гаяз әфәнде Акчура ачты. Озын төз буйлы кара мыеклы бу чибәр егет кәсебе буенча табиб икән. Җәмгыятьнең бер еллык эшенә хисап биргән рәвешле төрекчә кереш сөйләгәч, ул миңа сүз бирде. Гаяз Исхакыйның кемлеге, тормыш һәм иҗат юлын өйрәнүнең торышы һәм алда торган бурычлар турында ун минутлык сүз әйттем. Игътибар белән тыңладылар.

Мәҗлеснең икенче өлешендә, лотерея өчен саннар сугылган кәгазьләр сатканнан соң, җыр-уеннар башланды. Кулга-кул тотышып та әйләнделәр, кара-каршы җырлау да булды. Егет белән кыз булып такмак әйтешүләр җыелганнарга аеруча ошады. Бу кадәресендә татар көйләре яңгырады. Моннан соң тоташ төрек көйләре яңгырый башлады. Соңыннан бүләк биреләчәк бию-танцы ярышлары да төрек көендә алып барылды.

Ахырга таба лотерея уйналды. Гаяз әфәнденең өч яшьлек улы барабаннан билетларны да тыгылып ала, откан кешеләргә бүләкне дә илтеп тапшыра. Шундый килештерә! Миңа да, беркадәр хәрәмләп булса кирәк, матур гына поднос тоттырдылар.

Бу мәҗлес миндә сөенечле дә, көенечле дә уй-тойгылар калдырды. Шундый җәмгыятьнең яшәве җыр-көйләребезне гореф-гадәтләребезне һәм телебезне саклауга күпмедер өлеш кертә, әлбәттә. Олы буынның гына татарча сөйләшә белүе, урта һәм яшь буынның төрекләшә баруы исә көендерә.

Төркиягә татарлар, нигездә, дүрт дулкын булып килгән. Беренчесе — XIX гасырның ахырында җан исәбен алу заманында күчеп киткән татар-

лар. Алар күбрәк авылларда яши һәм милли гореф-гадәтләрен һәм телләрен чагыштырмача ныграк саклый икән. Икенчесе — Октябрь революциясе һәм Советлар власте белән килешә алмыйча китеп мөһаҗир булучылар. Өченчесе — Бөек Ватан сугышыннан соң килеп урнашкан татар әсирләре. Ниһаять, дүртенчесе — Мао Цзедун диктатурасы шартларында яшәргә рәт калмагач, Ерак Көнчыгыштан күчеп килгән татарлар. Боларның берсен дә, билгеле, кочак җәеп каршы алмаганнар. Мең газап белән аякка басарга, юктан бар итәргә мәҗбүр булган алар.

Төркиядә ничәләп татар яшәгәнен беркем дә белми. Бу турыда статистика да дәшми. Төрекләр үзләре татарларны милләттәшләре итеп караган кебек, төрек булып язылуга каршы булмаган татарлар да аз түгел. Гомумән, монда татар дип атау һәм аталудан качу сизелә. Татар җәмгыятенең исеменә генә игътибар итик: анда «Казан төрекләре» дип әйтелә. Олы буын китеп бетеп күпмедер вакыт узгач, Госманлы җирендә татар сүзе ишетелми, татар җыры яңгырамый башлау ихтималы бер дә куаныч китерми.

Хуҗаларның «программасында» Истанбул каралмаган булып чыкты. «Төркиягә килеп, Истанбулны күрми кайтсам, мине Казанга да кертмәсләр»,— дигәч, Мәсүдне миңа юлдаш итеп, шушы тарихи каладан йөртеп кайтарырга булдылар.

Җомга көнне төштән соң (Мәсүднең дүшәмбегә эшкә кайтып җитәсе бар) ике катлы дип әйтерлек зур, мәһабәт автобуска утырып киттек. Самолеттагы кебек креслолар. Ашап-эчәр өчен чыгарыла торган өстәлчекләре дә бар. Бервакыт астагы буфеттан татлы су меңгезделәр. Әлеге өстәлчекләрне чыгарып, стаканнарны шуның өстенә куйдык. Тамчысы да түгелми! Автобус бара бит, хәрәкәттә. Тизлеге дә 70-80 км.дан ким түгел. Анкара белән Истанбул арасына салынган киң магистраль юлның сыйфатын шуннан чамаларга мөмкин.

Истанбулга без төнлә килеп төштек һәм «Кәнт» исемле уртакул кунакханәнең ике урынлы булса да, суыткыч һәм телевизорсыз кечкенә генә бер бүлмәсенә урнаштык. Паспорт карау, анкета тутырту кебек нәрсәләрнең берсе дә юк. Әмма бәясе «тешли» торган иде — 50 мең лира. Анкарада бер килограмм итнең 8000 лира торганлыгыннан чыгып, моның кыйммәтме, түгелме икәнен чамаларга мөмкин.

Иртән торып шәһәр эченә кереп киттек. Акылым хәйран. Истанбул янында Анкара провинциаль шәһәр булды да калды. Ул зиннәтле сарайлар һәм мәһабәт мәчетләр, ул әрсәң, очып китәрдәй тоелган челтәр күперләр һәм Византия диварларының калдыклары, ул машина һәм җәяүлеләрнең күплеге!

Беренче эшебез Гаяз Исхакыйның каберен зиярәт кылу булды. Бераз гына адашып алсак та, «Әдернәкапы шәһитлеге» дип атала торган зиратны барып таптык. Гади генә капкасыннан кергәч тә сулда — манаралы кечкентәй генә мәчет һәм контора бинасы. Төрле якка асфальт юллар китә. Машина белән керергә тулы рөхсәт икән.





Мәсүд белән берлектә конторадан чыккан зират мөдире, юлуңаенда булганга, башта Иосыф Акчура кабере янына алып китте. Сөембикә манарасы рәвешендә эшләнгән таш. Кабер каралмаган. И. Акчураның кемлеген аңлатып биргәч, мөдир вәгъдә итте: карарбыз, чәчәкләр утыртырбыз.

Ниһаять, Истанбулга килүемнең бер (бәлки әле беренчедер) максаты үтәлде: мин — Исхакый кабере янында. Гади генә, җыйнак кына кабер. Өстендә күч-күч булып кызыл чәчәкләр үсеп утыра. Яхшы каралган (Сәгадәт ханым алдан түләп куйган икән). Гадәти генә таш. Анда латин хәрефләре белән «Тәңре рәхмәт әйләя. Әдип вә мөхәррир М. Аяз Исхакый Иделле. Идел-Урал төрекләрининин кортылыш хәрәкәте рәһбәре. Казан 1878 Анкара 1954» дип язылган. Татарчасы болай: «Алла рәхмәт әйләсен. Әдип һәм публицист М-Гаяз Исхакый. Идел-Урал төрекләренең азатлык хәрәкәте башлыгы». Нәкъ шушы зиратка һәм И. Акчурадан ерак булмаган урынга Г. Исхакый үз васыяте буенча күмелгән икән.

Кире кайтканда кабат Акчура кабере яныннан уздык. Ике эшче, чүп үләннәрен йолкып атып, кабер өстен чистартырга керешкәннәр дә иде.

Зират конторында Мәсүд әфәнде телефоннан без күрергә тиешле кешеләрнең бүген кабул итә алмаячагын ачыклагач, бу көнне Истанбулның берничә атаклы урынын карауга багышларга булдык.

Менә без Солтан Әхмәт мәйданында. Византиянең ипподромыннан калган ике монумент бар икән монда. Шуларны карадык. Моннан ерак та түгел алты манаралы Солтан Әхмәт мәчете. Бөтен Төркиядә иң зур мәчет. Солтан Әхмәт архитекторга әйткән, имеш: «Алтын манаралы мәчет сал миңа». Теге, ялгыш аңлап, алты манаралы итеп салган, ди. Эченә кердек. Дәүлеге, биеклеге, матурлыгы турында әйтеп бетерерлек түгел. Фигуралы зур-зур тәрәзәләрнең кырык төстәге пыялалары гына да ни тора!

Аннары атаклы Айя-Суфия мәчетенә киттек. Моңарчы гидлык вазифасын теләп башкарган Мәсүдемнең монда «эссесе» сүрелде. Бераз соңрак: «Яратмыйм моны, чиркәү бит бу»,— дип куйгач, сәбәбе аңлашылды. Чыннан да Византиядән калган бина бу. Манараларын гына төрекләр үстергән.

Эчкә кердек. Гаять биек, киң түгәрәк зал. Ремонт бара. Бер як стенасында гөмбәзгә кадәр дип әйтерлек «леса» өеп мендерелгән. Төркем-төркем туристлар. Төрле телләрдә сөйләшәләр. Немец теле күбрәк ишетелә.

Айя-Суфиядән чыккач, Мәсүд, Топ-капене карамый ярамый дип, мине төрек солтаннарының күп гасырлык резиденциясенә алып китте. Босфорның биек ярында гаять зур мәйданны биләп алган икән ул. Төрле зурлыкта, төрле форма-фасондагы бина-корылмалар — мәчет, сарай, аш-су өйләре, җарияләр яши торган хәрәм һ. б.

Солтаннарга бүләк итеп китерелгән алтын әйберләр залына барып кердек. Бөтен дөньяның алтыны шушында килеп тулган икән диярсең. Гигант шәмдәлгә охшаган утыз килограммлы бер озын савыт та бар хәтта. Мәсүд әфәнде монда җанланып китте. Беләгемнән эләктереп алып, экспонатларның берсеннән икенчесенә өстери-өстери сөйли, аңлата башлады.

Сугыш кораллары, солтан һәм солтан хатыннарының кием-салымы, көмеш, зөбәрҗәт белән бизәлгән әйберләр, кухня-ашханәләрендәге савыт-сабалар турында язып тормыйм. Тик шуны гына әйтәм: барысында да күз явыңны алырлык, акылыңны хәйран итәрлек матур манзара.

Музейда йөрүне бүлеп, ресторанга төштек. «Төштек» дим, чөнки ул биек тау-калкулыкның Босфорга төшә торган ярына урнашкан. Бөтен бугаз аның Мәрмәрә диңгезенә барып кушыла торган ягына чаклы уч төбендәгедәй күренә. Яшелле-зәңгәрле булып, вак дулкыннар белән аз гына шадраланып тора. Эреле-ваклы теплоход һәм катерлар, бугаз өстен чуарлап, тыз-быз йөреп торалар.

Официантлар йөгереп килеп җитмәгән беренче очрак булды бу. Нишлисең, Топ-капе биләмәсендә бердәнбер ресторан. Ә туристлар күп. Бәяләр котны очырырлык булса кирәк. Бу Мәсүд әфәнденең ашамый калдырмаслык итеп оста заказ бирүеннән дә, сыраның 250 граммлы шешәсен кулайрак күрүеннән дә сизелде.

Рестораннан менгәч, кайбер залларның һәм хәрәмнең ябык булуы сәбәпле, күп нәрсә карый алмадык. Топ-капега багышланган бу өлешне Мәсүд әфәнденең төрек патриоты булганын күрсәтә торган бер эпизод белән тәмамлыйсым килә.

Француз мәдәниятенең Төркиягә йогынтысы турында сүз чыккач, «гид»ым, бу йогынтыны арттырыбрак сөйлиләр, зурайтыбрак язалар, дигән кебегрәк фикер әйтте һәм төрекләрнең бик борынгы заманнарда мәдәни яктан

французлардан өстен булганнарын күрсәтә торган бер риваять сөйләде. Имештер, мәгълүм бер заманда французларда мунча да, туалет та булмаган. Болгаткыч ис эчендә яшәгәннәр. Әнә шул исне бетерер, һәрхәлдә, киметер өчен алар берсеннән-берсе татлы хуш исләр чыгара торган майлар уйлап табарга мәҗбүр булганнар. Менә ни өчен Франциядә парфюмерия алга киткән икән.

Шактый ерак булса да, кунакханәгә җәяү кайтырга теләк белдердем. Кабат Солтан Әхмәт мәйданын узып, «үзебезнең» урамга кердек. Як-яктагы өйләрне карап барам. Әнә электән калган биналар. Искереп, каралып бетсәләр дә, архитектур башкарылышлары белән эстетик ләззәт бирәләр. Әнә яңарак салынган «коробка»лар. Юкадыр, җиңелдер, куәтлерәк җил чыкса, авардыр кебек. Почмаклары үткен булып, төртеп тора. Янгыннан соң караеп калган кечкенә, әмма гаҗәеп матур өйгә игътибар иттем. Соравыма җавап рәвешендә Мәсүд: «Хуҗалары яндырган булса кирәк»,— диде. Монда өйнең үзенә караганда, ул биләгән җир кыйммәтрәк икән. Хуҗа кеше искесен җимереп яңа өй салырга тели, әмма шәһәр администрациясе рөхсәт бирми. Закон. Шуннан, хәйләгә керешеп, төртеп яндыра...

Икенче көнне, әйткәнемчә, визитларга багышладык.

Менә без — Зәйнәп ханым Халидиләрдә. Пөхтә генә, матур гына, ачык кына бер карчык. Квартиралары артык зур булмаса кирәк, әмма бай җиһазлы. Иске стильдәге матур урындык-кәнәфиләр. Әдип исемле яңарак өйләнгән улы һәм йөкле килене (татар кызы) бар икән.

Зәйнәп ханым «Яңа милли юл» журналында исеме еш күренә торган гаҗәеп фидакарь мөгаллим һәм мулла (бусы мәхәллә халкының гозере буенча) Хатип Халидинең хатыны булып чыкты. Г. Исхакыйны Х. Халиди Россиядә үк күргәләгән, ә Хайларда танышлыклары яңарган. Истанбулда исә әдип Халидиләр гаиләсендә еш кунак булган.

Зәйнәп ханымның мәчетләрдә һәм Топ-капеда булуыбыз уңае белән әйткән бер сүзе, азрак гаҗәпләндерү белән берга, күңелгә хуш килде. «Алар (солтаннар — И. Н.),— диде ул,— халык турында уйламаганнар, халыкны ач тотып, алтын җыйганнар, җарияләр асраганнар. Исемнәрен калдыру өчен җамиләр (мәчетләр — И. Н.), сарайлар салганнар. Хәзер шул сарай, шул җамиләр дәүләткә керем бирә!».

Г. Исхакыйга якын кешеләрнең тагын берсе — аның белән күп аралашкан һәм әдипнең тууына 100 ел тулуга багышланган зур җыентыкны төзүчеләрнең берсе булган Хәсән Агайга баглаган өметем акланмады. Юк, күрдек без аны, әмма нинди хәлдә... Тулысынча үз акылында булган һәм хәтере яхшы сакланган Хәсән аганы хатыны психиатрик больницага салган.

Килүемнең максатын аңлаткач, Хәсән ага хәлем дә юк, башым да эшләми, диде. Әмма бераздан, язылa төшеп, кайбер нәрсәләр әйтте. Анныры болай дип куйды: «Гаяз Исхакыйны күп күрдем, материаллар да бар. Терелсәм, язармын». Шундук күңелгә уй килде: кая инде ул язу...

Моннан соңгы визит та зур файда бирмәде.

Садрый Максудиның кече кызы Наилә ханым Турхан, 75 яшен тутырган булса да, шактый сакланган, фигурасын да бик үк югалтмаган. Хәтере дә яхшы, күзәтчәнлеге дә сизелә. Хәер, бу гаҗәп тә түгел: язу-сызу белән шөгыльләнгән ул, француз телендә чыккан романы да бар.

Файда ала алмавымның сәбәбе ике нәрсәгә кайтып кала. Беренчесе — Наилә ханымның татар телен бөтенләй онытканы булуы. Ул саф төрекчә сөйли, мин, билгеле, аңлап бетермим, Мәсүдкә ялварып карыйм. Әмма аның белән минем арага да ара-тирә тылмач кирәк була. Икенчесе — вакытның азлыгы. Безгә бүген Истанбул-Анкара автобусына өлгереп, юлга чыгарга кирәк. Вакыт тыгызлыктан хәтта төшкене дә ашый алмаган идек. Күңелдә ишеттереп әйтелмәгән бер өмет бар иде: бәлки, Наилә ханымда капкалап булыр. Әмма, хуҗабикә безнең ач икәнне белмәгән кебек, без дә моны сиздерергә җөрьәт итмәдек. Дөрес, Наилә ханым чәй кайнатып китерде, чәй янына тәлинкә белән печенье дә куйды. Сые өчен Наилә ханымга рәхмәт әйтеп бу өйдән чыгып киттек.

Шунысы да мәгълүм булсын: Хәсән әфәнде дә, Наилә ханым да хәзер юк инде. Беренчесенең вафаты көтелсә дә, Наилә ханым уңае белән андый уй башка да килерлек түгел иде. Авыр туфраклары җиңел булсын...

Гаяз Исхакый чит илдә ничек яшәгән? Бу сорауга бүген әле тулы һәм җентекле җавап бирергә мөмкинлек юк. Тикшерәсе дә тикшерәсе, өйрәнә-

се дә өйрәнәсе әле. Әдипнең гомере тәгәлләнгән җирдә булып кайту шулай да күп кенә ачыклык кертте.

Моңарчы без (дөресрәге, мин) Г. Исхакыйның туып та яшәп кала алмаган Идел-Урал хөкүмәтенең вәкиле сыйфатында Версаль конференциясенә чыгып киткәнен, аннары, чит илдә калып, 1929 елга кадәр Берлинда яшәгәнен, моннан соңгы ун елы Варшавада узганын һәм, бер яктан — Гитлер, икенче яктан Совет гаскәрләре Польшага бәреп кергәч, Төркиягә барып төпләнгәнен белә идек. Безгә шулай ук татар эмиграциясенең төп лидеры булганлыгы, Ерак Көнчыгышта аның тырышлыгы белән татарча газета чыгарылганлыгы, Берлинда «Милли юл» исемле журнал оештырып, җир шарының татарлар яшәгән күп тарафларына таратуы билгеле иде. Гаязны һәм татар эмиграциясен тоташ кара төскә буяп ипи ашаган кайберәүләрнең кыздырып торуына карамастан, Г. Исхакыйның немец фашистлары белән хезмәттәшлек итмәгәнлеге дә ачыклана башлаган иде. Әмма шул ук төркем баскан яңа бер кара мөһер — Исхакый берничә разведканың агенты булган, дигән версия әле күпләрне ышандыра, күпләрне аптырашта калдыра иде.

Соң нәрсә ачыкланды, нинди яңалык өстәлде? Бу сорауга җавап бирүне Исхакыйның агентлыгы мәсьәләсеннән башлыйк.

1920-30 елларда Польшада «Прометей клубы» исеме астында бер оешма яшәп килгән. Аның вазифасы — үз халыкларының азатлыгы хакына Сталин режимына каршы көрәшүне максат итеп куйган милли-патриотик оешмаларны бергә туплау, аларның эшен координацияләү булган. Украина, Төркестан, Әзербайҗан, Кырым, Грузия, Белоруссия оешмалары белән беррәттән, башлыгы Гаяз Исхакый булган «Идел-Урал» төрек-татарларның бәйсезлеге комитеты» да бу клубта әгъза булып торган. Маршал Пилсудскийның игътибар үзәгендә булган бу клубның чыгымнарын Польша хөкүмәте күтәргән.

1933 елның җәй ахырларында Г. Исхакый, юлга әнә шул фондтан тиешле акчаны алып, пароход белән Ерак Көнчыгышка чыгып китә. Максаты — Япония, Корея, Манчжурия һәм Кытайда таркау яшәүче татарларны «Идел-Урал» байрагы астына җыю, үзләре яшәгән тирәлеккә кереп эремәүләренә, телләрен, гореф-гадәтләрен, мәдәниятләрен югалтмауларына, кыскасы, үзләрен милләтнең бер кисәге итеп саклап калуларына ирешү.

Әдипне каралтучылар версиясе буенча исә, Г. Исхакый Ерак Көнчыгышка «Шольц» дигән кличка астында, мәгълүм органнардан 90 фунт стерлинг алып, Польша һәм Англия разведкаларының заданиесен үтәү өчен чыгып киткән. Японияга килеп җиткәч, ул, янәсе, барыннан да элек, Япон генераль штабының югары дәрәҗәдәге хәрби хезмәткәрләренә визит ясаган, советка каршы нинди мәсьәләләр буенча фикер алышкан һ. б. Исхакыйның разведчиклык эшчәнлеген раслый торган конкрет материал таба алмаганга булса кирәк, алар әлеге «Шольц» дигән исемгә чытырдап ябышалар: ул юкка гына шундый кличка йөртмәгән, янәсе.

«Харбинское время» исемле рус эмигрантлары газетасының 1933 елгы 22 сентябрь санында басылган «Г. Исхакый язмышы өчен хәвефләнү» исемле хәбәр аларның бу дәлилен дә аударып ташлый.

Мәкаләдән аңлашылганча, Г. Исхакыйның Европадан кайчан, нинди пароход белән, ни рәвешле чыгып китү хәбәре күптән килеп җиткән. Шанхайда ул пароходны каршыларга барсалар, Гаяз юк. Булганмы ул анда, әллә кайдадыр төшеп калганмы — моңа экипаж да, белмибез, дип җавап биргән. «Г. Исхакыйның бүтән кеше исеме белән юлга чыгу ихтималы булганлыктан,— диелә хәбәрдә,— пароход администрациясенең мондый җавабы табигый. Инкогнито бара торган 3-класс пассажиры йөзләгән башка пассажирлар арасында эреп югалырга мөмкин».

Г. Исхакыйның коммунистлар властена каршы актив көрәшүче булганын истә тотып, мондый курку белдерәләр: «Коминтернның берәр агенты күренекле эшлеклене юлда юк итмәгән микән». «Шольц» — кличка түгел, бәлки псевдоним икән ләбаса. Яшеренергә исә сәбәп бар. Чит илдәге күп кенә кешенең Сталин агентлары тарафыннан үтерелгәнлеге шул турыда сөйли. 1934 елда «Идел-Урал бәйсезлек комитеты» секретаре Гариф Кәрими (Ф. Кәриминең энесе) үлгәч, ул НКВД агентлары тарафыннан үтерелгән, дигән версиянең йөри башлавы да очраклы булмаса кирәк.

«Яңа милли юл» журналы һәм Анкара белән Истанбулда мин җыйган истәлекләрдән чыгып хөкем итсәк, Г. Исхакыйны Японияда менә нинди вакыйгалар көтеп торган.

Токиодагы татар колониясенең лидеры Габделхәй мулла Корбангалиев,

мондагы татарларны бүтән җирлектә берләштерүнең аны башлык булу шәрәфеннән мәхрүм итәсен белгәнлектән, үз тирәсенә яраннарын туплап һәм рус эмигрантларыннан кайберләрен ярдәмгә чакырып, Г. Исхакыйның оештыру эшләренә аяк чала башлый. «Япон мөхбире» исемле журналында ул Гаязны һәм аның идеясен хурлый торган материаллар урнаштыра, скандаллар ясап, Исхакый тарафдарларының җыелышларын өзәргә маташа (Поротиков фамилияле бер ак офицер хәтта әдипкә суккан), полиция департаментына донос артыннан донос җибәреп тора. Япон полициясенең, әлбәттә, колагы торган, «тынычлык бозучы»ны ул берничә мәртәбә чакырып сорау алган һәм, ахыр чиктә, Япониядән чыгып китүен таләп иткән. Исхакыйга бу илдә калу һәм эшен дәвам иттерү өчен үзенең Варшавадагы танышы, Япониянең Польшадагы элекке атташесы Яначитага мөрәҗәгать итүдән башка чара калмый. Бу кешенең, күрәсең, сүзе үткән, хәрби властьлардан күрсәтмә килгән: тимәгез, эшләсен.

Ерак Көнчыгышның ак эмигрантлар матбугатында Гаяз Исхакыйга һөҗүм кампания төсен алган булса кирәк. Менә япон газеталарының берсендә полициянең Исхакыйны Советлар белән яшерен бәйләнештә булуда һәм коммунистик хәрәкәткә катнашуда гаепләве турында хәбәр басылып чыга. Корбангалиев газетасы, аңлатма белән берлектә, ул хәбәрне татарчага тәрҗемә итеп чыгара. Янсә менә М. Колосова дигән ниндидер шагыйрә Шанхайда чыга торган «Новый путь» газетасында «бердәм, бүленмәс Русь» дигән шовинистик позициядән торып, «Идел-Урал бәйсезлек комитетына» һәм Г. Исхакыйга ташланган икән. Кытай һәм рус телләрендә Харбинда чыга торган «Гун-бао» газетасының ике санында да шундыйрак материал басылган. Бусына әдип үзе җавап бирергә карар иткән. Әмма аның язмасы дөнья күрмәгән булса кирәк. Машинкада басылып, әдипнең имзасы куелган биш битлек тексты гына архивта сакланып калган.

Г. Исхакый уңае белән полиция һәм бүтән рәсми учреждениеләр арасында язышу бер елга сузылган. Бу документлар соңрак, билгеле, архивка барып керә. Бер өлеше 1945 елгы җиңүдән соң безнең илгә кайткан. Әдипне өнәмәүчеләр нәкъ менә шул материалларны гаять үзенчәлекле итеп, ягъни акны — кара, караны ак итеп күрсәтү рәвешендә файдаланалар.

Әдипнең Бөек Ватан сугышы чорындагы тормышы нигездә ачыкланган булса да, шикләнүчеләр һәм, ачы тәҗрибәдән чыгып, исхакыйчылар, аны күтәрү өчен, фашистлар белән эш итүен яшерергә маташмыйлар микән, дип уйлаучылар булганга, бу мәсьәләгә дә тукталып китми ярамый.

Әсфәндияр ага Иҗгайның газета корректоры сыйфатында легионның үз эчендә булуына карамастан, Исхакыйны бер генә мәртәбә дә күрмәгәнлеге, аның Германиядә булганлыгы хакында бер генә сүз дә ишетмәгәнлеге әйтелгән иде инде. Профессор Әхмәт Тимер биргән белешмә аеруча кыйммәтле.

Берлин университетында укыган чагында аны немецлар профессор Фон Менде җитәкчелегендә Идел-Урал әсирләрен өйрәнү эшенә тартканнар. Фронтта эшләре хөртиләнә башлагач, әсирләрдән легионнар оештыру фикеренә килеп, алар лидер эзли башлыйлар һәм Әхмәт Тимернең фикерен сорыйлар. Ул ике кандидатура тәкъдим иткән: милләте белән казакъ булган Мостафа Чукай һәм Гаяз Исхакый. «Ни сәбәптәндер,— диде Әхмәт әфәнде,— Гаязны түгел, Мостафа Чукайны чакырдылар». Сәбәбен без Али Акышның Г. Исхакыйның йөз еллыгы уңае белән чыгарылган җыентыктагы мәкаләсеннән беләбез.

1942 елның июнь аенда Исхакый Али Акышны өенә чакырган. Бу барып кергәндә, Германиянең Төркиядәге илчелегеннән ике түрә утыра икән. Алар легионнар оештыру эшен тәкъдим итәргә килгәннәр. Г. Исхакый, тыңлап бетергәч, өч шарт куйган: 1) Идел-Урал дәүләте өчен юридик гарантия; 2) корылачак легионнарның командирлар составы бәйсез булырга тиешлек; 3) Идел-Урал дәүләте өчен бәйсез югары мәхкәмә (суд). Немецлар бу өч шартны кабул итмәгәнлектән, килешү булмый калган. Шулай итеп, Бөек Ватан сугышы елларында Гаяз Исхакыйның Германиядә бөтенләй булмаганына шикләнмәскә мөмкин.

Төркиядә Г. Исхакый баштарак иҗтимагый-сәяси эшчәнлектән ваз кичмәсә дә, күбрәк язу эшләре белән шөгыльләнгән. Аның берничә хикәя, «Татар кызы» исемле роман, Олугмөхәммәт турында тарихи пьеса һәм үзенең тәфсилле хәлен язганлыгы билгеле. «Шималь төрек әдәбиятына бер назар» исемле монографиясе һәм Казан ханлыгы турында Худяков китабының тәрҗемәсе дә шушы елларга карый.

Соң яшәү шартлары ничек булган?

Казан матбугатында Гаяз Исхакый турында беренче публикация булган мәкаләмдә («Веч. Казань», 1988, 17 окт.) мин уйламый-нитми «ялгызлыкта һәм фәкыйрьлектә үлгән» дип ычкындырган идем. Моның соңгысы дөрескә чыкса да, баштагысы чынлыкка туры килми. Г. Исхакый Төркиянең югары дәүләт идарәчеләренә билгеле булган кебек, әдәби һәм гыйльми җәмәгатьчелек күзендә дә абруй казанган. Илнең бөек кешеләренә генә бирелә торган, заманына күрә ярыйсы гына саналган 250 лиралык пенсия-пособиянең аңа да билгеләнүе очраклы хәл түгел. Татарларның яше, карты күзендә ул аллага ук булмаса да, пәйгамбәргә тиң. Шуңа күрә аның яныннан кеше өзелмәгән.

Фәкыйрьлегенә килгәндә, моның шаһиты — барыннан да элек торак шартлары. Торак урынын берничә кат алыштырса да, һәркайсы кеше өе, кеше квартирасындагы бер бүлмә булган. Соңгы бүлмәсен Маһирә ханым Байчура менә ничек тасвирлый: «Торагы подвальный катта иде. Баскычтан аска төшеп ишек шакыдык. Кергәч, мин аптырап куркып калдым. Караңгы, шыксыз, җиһазы юк дип әйтерлек». Үзе ясаган язу өстәле, сатып алган аш өстәле, мин утырып эшләгән кәнәфие, бер-ике кат кием һәм кайбер вактөяктән башка бернинди мирас калдырмавы да шул фикерне расласа кирәк.

Бу хәлнең бердәнбер үк булмаса да, төп сәбәбе Г. Исхакыйның, чит илдә яшәүче замандашлары сүзенчә, «идеалист» булуы, ягъни идея хакына яшәп, байлыкка аз гына да исе китмәве. Максат итеп куйса, бәлки ул «череп» баемас, әмма үзенә иркен, мул тормыш тәэмин итә алыр иде. Революциягә кадәр, мәсәлән, Гаяз — иң популяр һәм иң зур гонорар алучы өчнең (икесе — Тукай һәм Ф. Әмирхан) берсе була. Әсәрләреңне тупла да чыгар, тупла да чыгар. Менә сиңа акча. Ә аның, «Кәләпүшче кыз» исемле хикәясеннән башка, барлык әсәрләре бер басма белән калганнар. Бөтен ислам дөньясына танылган шәхес буларак, мөһаҗирәттә дә теләсә кырык төрле чыганак таба алыр иде. Инде булмаса, Ерак Көнчыгыш, Төркия һәм Финляндиядә яшәүче татар байлары да аңа тиешле яшәү һәм эшләү шартлары тудыра алырлар иде. ГФРның корпорацияләре белән хезмәттәшлек итеп илленче елларда Төркияне автомобильле илләр рәтенә бастыруда төп рольне уйнаган Әхмәтвәли Мәңгәрне алыйк. Ата-анасы Арча районының Олы Мәңгәр авылыннан чыккан, үзе Петропавел шәһәрендә туып, Ерак Көнчыгышта эшкә ябышкан, баеп киткән, Төркиядә илнең иң зур капиталияләре сафына баскан шушы зат «Милли байрак» (Мукден) газетасы һәм «Казан» (Анкара) журналының, шулай ук күп кенә татар авторларының китап чыгымнарын күтәргән, мин мәҗлестә булган әлеге өйне «Дәрнәк»кә бүләк иткән. Милләтнең горурлыгы булган зур әдип һәм җәмәгать эшлеклесенең барлык ихтыяҗларын берүзе канәгатьләндерә алмас идемени ул? Әмма Гаяз Исхакый — бер кемнән дә, бигрәк тә байлардан садака ала торган кеше түгел. Али Акышның минем кулдагы истәлегендә мондый юллар бар: «Гаяз ага татарларның миллионеры Әхмәтвәли Мәңгәр белән дә дусларча мөнәсәбәттә түгел иде. Гаяз аганың социаль гаделлекче булуы Мәңгәрнең буржуалыгы белән килешә алмый иде».

Гомеренең соңгы ике аен Г. Исхакый Анкарада кызы Сәгадәт ханым Чагатай янында үткәргән. Күрергә, хәл белергә килүчеләр күп булган. Замандашларының язу һәм әйтүләренә караганда, әҗәлнең якынлыгын белсә дә, күңелен төшермәгән, дөнья хәлләре, бигрәк тә илдәге һәм мөһаҗирәттәге төрек-татар тормышы белән кызыксынып торган. Хәтта юмор тойгысын да югалтмаган.

1954 нче елның 22 июле кайгы алып килә: 12 сәгать 10 минутта Гаяз Исхакыйның йөрәге тибүдән туктый. Үзенең васыяте буенча аны, Истанбулга алып китеп, югарыда тасвир ителгән зиратка күмәләр. Анкарада да, Истанбулда да җеназаны озатучылар күп булган.

Менә шул. Зиһенгә, күңелгә кереп калганнарның барысы да әйтелеп бетмәсә дә, шушы урында нокта куям. Инде милләттәш дуслар ярдәмендә әйберләрне җыештырасы, чемодан-сумкаларга дыңгычлап тутырасы, иртән такси белән аэропортка барасы, озатырга килгән Мәхмүт Таһир, Әхмәт Тимер әфәнделәргә һәм Сәидә ханымга рәхмәт әйтеп, саубуллашып, самолетка таба атларга гына калды.

**Фоат Галимуллин**

# КӨЗГЕБЕЗДӘ НИЛӘР ЧАГЫЛА?

Сиксәненче еллар ахыры иде. Чирмешән районында йөргәндә, Кара Чишмә дигән авылның бер агае миңа бик четерекле сорау бирде:

— Мин үзем китап укырга бик һәвәс кеше. Төрлесен укып барам. Укый торгач, бер шик туа башлады. Кайчакта язучылар арасында да тормышка ераклашучылары бар кебек тоела миңа. Күңелендәген әйтми, сүзләрнең түрәләр йөрәгенә сары май булып ятардайларын уйлап чыгара. Ә уйлап чыгарган нәрсә, тыңларга матур булса да, хакыйкать түгел инде...

Мондый сүзләр мине беразга аптырашта калдырды. Биредә тота-каба гына җавап бирү әңгәмәдәшне ышандырмаячак, мәсьәлә шактый катлаулы. Димәк, җавап та дәлилле булырга тиеш.

Язучының инандыру көче. Сүзенең үтемлелеге, сәнгатьчә төгәллеге һәм камиллеге... Болар — кулына каләм алган һәр кешенең бөек омтылышы, өмете һәм ирешергә тиешле хыялы. Әлеге югарылыкка менүнең беренче баскычы — дөреслеккә хилафлык кылмау. Мин дә әлеге агайга җавапны менә болайрак бирдем:

— Татар әдәбияты, агай-эне, шактый киң һәм озын, шул ук вакытта тигезле-тигезсез басу ул. Киңлеге-тарлыгы, уңдырышлылыгы-уңдырышсызлыгы даими күрсәткеч түгел, әмма ул басуның озынлыгы кире кагылгысыз хакыйкать. Әле XIII гасыр башында ул Кол Гали кебек бөек сүз остасы булган әдәбиятлар безнең ил халыкларында бармак белән генә санарлык. Менә шуннан бирле татар халкының сәләтле уллары-кызлары кулларыннан каләмен төшерми. Каурый каләм, камыш каләм, корыч каләм... Сыйфаты, җисеме үзгәрсә дә, каләм халкыбызның күңел хәзинәсен, аһ-зарларын, борчу-кайгыларын, нигездә, дөрес чагылдыра килгән. Без моның шулай икәнен бик күп мисалларда күрсәтә алган булыр идек. Котб, Х. Кятиб, С. Сараи, М. Болгари, Мөхәммәдъяр, Утыз Имәни, Г. Кандалый, З. Бигиев, Акмулла һәм башкалар иҗаты шуңа мисал түгелмени? Егерменче йөз башының туры Тукае үзе генә дә ни тора! Бу мәсьәләдә ул аерым бер олы биеклекне тәшкил итә. Дәрдеменд, С. Рәмиев, Г. Ибраһимов, М. Гафурилар иҗатын гадел түгел дип кем әйтә алыр икән? Менә шундый ныклы нигездә торган әдәбият совет чорына аяк басты. Җиде дистәдән артык ул хезмәт ияләре хәл-әхваленең көзгесе булырга тиеш иде. Күпчелек язучыларыбыз шуңа омтылды да.

Көзге, дидек... Бу җансыз көнкүреш әйберенең бер уңай ягы бар — ул, нәрсәне генә булмасын, дөрес итеп, чынбарлыктагыча күрсәтә. Аңа беркем дә: моннысын болай күрсәт, тегесен тегеләй күрсәт, дип боерык бирә алмый. Авызың кыек икән, көзге аны турылап тормый инде, ничек бар — шулай, хәзинәдә барынча... Ә менә әдәбиятка килгәндә, бөтенләй киресе. Җанлы тормышның реаль күренешләреннән чыгып фәлсәфә итү урынына, еш кына аңа акны — кара, караны — ак дип сурәтләргә кушып торалар. Революциягә кадәр дә патша хакимияте ялчылары әдәбият һәм сәнгать әсәрләренең эчтәлегенә битараф булдылар, дип әйтмәс идем. Г. Тукай, Г. Коләхметов, Г. Ибраһимов, М. Гафуриларның цензура тарафыннан кысылулары кемгә генә мәгълүм түгел?! Ә совет хакимияте елларында исә тегеләй язарга, болай язарга дигән карарлар ел саен диярлек чыгып кына тордылар. Шулар арасыннан 1944 елның 9 августында кабул ителгән «Татарстан партия оешмасында масса-политик һәм идеология эшенең торышы һәм аны яхшырту чаралары турында»гы карарны аеруча басым ясап әйтергә кирәк.

Бу карар, билгеле булганча, татар язучыларының каләмен рәсми идеологиягә буйсындыру өчен, үтемле инструмент хезмәтен үтәде. Ул игълан ителү белән үк, андагы күрсәтмәләрне тагын да төгәлрәк итү максаты белән, күп кенә чыгышлар, мәкаләләр басыла. Мисал өчен, «Пропагандист» журналының 1944 ел, 15—16 санындагы «Идея-политик эшне тагын да югарырак күтәрергә» дигән баш мәкаләгә күз салыйк. Анда партиянең Татарстан өлкә комитетына нинди генә гаепләр ташланмый! Өлкә комитеты совет язылыларын идея-политик яктан тәрбияләү эшен оештырмаган; язучылар һәм сәнгать эшлеклеләренең эше белән канәгатьләнмәслек җитәкчелек иткән; сәнгать оешмалары репертуарларына җитәрлек контроль ясамаган булып чыга. «Шуның нәтиҗәсендә,— диелә әлеге баш мәкаләдә,— республикада татар халкының тарихын яктырту буенча һәм шулай ук татар әдәбиятында, сәнгатендә идеологик характердагы җитди ялгышлар урын алган. Татарстанның кайбер әдәбиятчылары һәм тарихчылары Алтын Урданы үз заманының алдынгы дәүләте итеп күрсәтергә маташканнар. Кайбер татар язучылары тарафыннан хәзерге темага язылган пьесаларда һәм операларда СССР халыкларының дуслык идеясе чагылмый».

Моннан күренгәнчә, совет җәмгыятендә бөтен нәрсәгә кулы һәм карашы җитәргә тиешле партиянең республика комитеты «Идегәйнең тарихи роле мәсьәләсен тикшерә белмәгән, аерым татар тарихчыларының һәм язучыларының әсәрләрендәге ялгышларны ачып салмаган, идеологик тормыш белән җитәкчелек эшен кулыннан ычкындырган, Татарстан Тел, әдәбият һәм тарих институтының эшенә контроль ясамаган, шуның нәтиҗәсе буларак, идеологик характерда җитди ялгышлар туган». Һәм шуннан соң инде бик күп бурычлар санап үтелә. Шулардан берсе аеруча күзгә ташлана — каләм көчләрен «Татарстанның социалистик нигездә яңадан корылу тарихын яктыртуга» юнәлдерергә. Ул вакыттагы идеология чиновниклары татар халкының язмышы совет власте елларында гадел хәл ителгәнлегенә шулкадәр нык инанган ки, башкача булырга мөмкин дигән уй аларның башына да килми. Әгәр безнең әдәбият идеология басымы астында кыек көзгегә әверелмәгән булса, татар халкының илдә икенче, хәтта өченче сорт халык булып әверелүе, хокуклары бик чикләнгән булуы, акрынлап милләт буларак бетүгә дучар ителгәнлеге әсәрләрдә чагылмый калмас иде. Ә без исә бөтенесе дә хәл ителгән, ал да гөл булып яшәгән халык булып уйнадык, нининдер абстракт милләтсез совет халкын тәшкил итәбез дип шапырындык. Ә күңелебезне мәче тырнады. Автономияле республика дип кәнфит кәгазенә төрелгән ялганга укучыларны ышандырырга тырыштылды. Укучы юләр түгел, ул да йөри, уйлый, күрә, чагыштыра. Союздаш республикаларның бөтенләй башкача, без хыялллана да алмаганча яшәгәнлекләрен белеп тора. Шул сәбәпле, китап сүзенә ышанычы кими башлый. Бу исә әдәбият өчен бик куркыныч әйбер. Укучының ышанычын җуюдан да зур бәхетсезлек юк әдәбият өчен.

«Пропагандист» журналы өйрәткәнчә, Татарстанның социалистик нигездә яңадан корылу тарихын дөресенчә язсаң, укучының, үз күңелендә йөрткән хакыйкатьне укып, исе китәр иде. Тик моңа юл куелмады. Чөнки язучының баш өстендә Жданов кебек идеологларның авыр күсәге торды. Ул күсәккә мондый сүзләр дә язылган иде: «Без таләп итәбез: язучы иптәшләр совет строе аңардан башка яши алмый торган нәрсәне, ягъни политиканы кулланып эш итсеннәр». (1946 елда «Звезда» һәм «Ленинград» журналлары турында партия активы белән язучылар җыелышында сөйләгән докладыннан.)

1963 елның 9 декабрендә партия өлкә комитеты вәкиленең язучылар белән очрашуы вакытында, мәсәлән, әдәби әсәрләргә бары тик идея ягыннан бәя бирүнең классик үрнәген ишетергә туры килә. Партия өлкә комитеты вәкиле әдәби иҗат кебек гаять нечкә әйбер турында болай фикер йөртә: «Идея ягыннан йомшак әсәрләр дә булды. Мәсәлән, үзе талантлы һәм сәләтле язучы булса да, А. Гыйләҗевнең «Өч аршин җир», оста каләм иясе Ә. Еникинең «Рәшә» повестьларында идея ачыклыгы җитеп бетми... Җәмәгатьчелектән читләшеп, күбрәк вакытларын үз бүлмәләрендә үткәргәнлектән, бу авторларның әлеге әсәрләре тиешле югарылыкка күтәрелә алмаган. Ә бит язучы халык белән аралашырга, аның тормышын туктаусыз өйрәнергә тиеш. Шул вакытта гына ул югары идеяле һәм художество эшләнеше ягыннан камилләшкән әсәр иҗат итә ала» (Совет әдәбияты, 1964, № 1, 157 бит).

Әгәр сүз сәнгатьчә эшләнеш ягыннан шактый камил әсәрләр турында бармаса, бу чыгышка игътибар итмәскә дә мөмкин булыр иде. Нихәл итәсең, ул вакытта партия хезмәткәрләре үзләрен бөтен өлкәдә дә мәгълүматлы, фикер йөртерлек дәрәҗәдә дип санадылар шул.

Ә. Еники димәктән, әле исән вакытта ук классик дип кабул ителгән бу язучыбызның иҗат үзенчәлеге, ягъни кеше күңелен тирәннән ачып бирү осталыгы аерым очракларда аның кимчелеге итеп тәкъдим ителде. Х. Хәйри, мәсәлән, илленче еллар ахырында менә ниләр язган иде: «Рухи кимчелекле, үз хисләрендә буталып, аптырашта калган, гел үзе генә әчтән газапланучы типлар Ә. Еники әсәрләрендә очраклы

күренеш түгел. Алар аның элекке әсәрләрендә дә бар. 1956 елда язылган «Кем җырлады?» хикәясендә яралы солдат образы да шундыйларга керә. Үлем алдыннан саташучы солдатның уй-тойгылары тасвирланган өлешен укыганда ниндидер аллә кайчан язылган хикәяләр стиле, кеше үзенең намусын тик хыялында, саташканда гына таба алуы мөмкин, дигән идеалистик хикәяләр искә төшә» (Совет әдәбияты, 1958, № 8, 106 бит). Түгел, Х. Хәйри хаклы түгел! Хикәяне тагын бер тапкыр укып карагыз, хаксызлыкны шундук аңларсыз, дип кычкырасы килә бу юлларны укыгач. Хәзерге көндә дәреслекләргә кергән, кеше халәтенең газаплы мизгелләрен үзәгеңә үткәрерлек итеп бирүче, шул ук вакытта укучыда нәфис хисләр тәрбияләүче бу хикәяне яклыйсы, аралыйсы килә! Х. Хәйри бер нәрсәдә хаклы: ул да булса — тоталитаризм вакытында «кеше үзенең намусын тик хыялда, саташканда гына таба ала иде». Моның шулай икәнлегенә дистәләрчә мисаллар китереп була.

Мондый каршылыклы уйлар тагын башка әсәрләр турындагы фикерләрне укыганда да барлыкка килә. Менә Г. Иделленең «Онытылмас еллар» (И. Гази) әсәренә карата язылган мәкаләсеннән бер өзек: «Гражданнар сугышы, чит ил интервенциясе һ. б. Шундый шартларда, ленинчыл милли политиканың тантанасы буларак, Татарстан республикасы төзелә. Аны дөрес юл белән алып бару һәм ныгыту өчен, Дәүләтъяров, Курманаев кебек милләтчеләргә каршы көрәшергә кирәк була» (Совет әдәбияты, 1964, № 2, 137 бит). Укучы хәтерлидер, Дәүләтьяровлар милли кадрлар үстерү, моның өчен аларга яхшырак шартлар тудыру турында кайгырталар. Моны гаеп итеп түгел, бәлки хуплап бәяләргә кирәк булган ич. Үз милләте кешеләре язмышы өчен кайгырткан Дәүләтъяровлар, ай-һай, кирәк булган безгә! И. Гази, сизгер сүз рәссамы буларак, моны дөрес аңлаган һәм әлеге образларның эш-гамәлләрен әсәр тукымасына кертүне кирәк дип санаган. Мәгълүм ул чорда, ягъни милләт мәнфәгатьләрен кайгыртуда бары тик корткычлык кына күрелгән ул елларда, әлбәттә, Дәүләтъяровлар нинди дә булса уңышка ирешә алмыйлар иде. Әмма, шулай да, алар булды. И. Гази аларны сурәтләми кала алмады. Бу аның тормыш хакыйкатенә тугрылыгы иде. Дөрес, теге «кыйшык көзге» аның да кулын тоткарлады, әйтергә теләгәнен ачыктан-ачык җиткерү мөмкинлеге бирмәде.

Югарыда искә алынган «Пропагандист» журналының баш мәкаләсендә: «Татар халкының атаклы эшлеклеләрен, галимнәрен һәм революционерларын, Ватан сугышы геройлары булган улларын популярлаштырырга»,— диелә. Чынбарлыкта болай эшләргә мөмкинлек бирелдеме соң? Мисалларны ерак тарихтан түгел, шул еллар тирәсеннән генә эзлик. Татарстан күләмендә генә түгел, халыкара мәйданда политик эшлекле булган Мирсәет Солтангалиев шәхесе һәм эшчәнлеге турында матбугатта сүз әйтеп кара! (Кырыгынчы еллар турында әйтеп тә тормастан, 1980 елда да М. Абдуллин, С. Батыев тарафыннан М. Солтангалиев турында егерменче-утызынчы еллардагы әкият кабат искә төшерелде. «Солтангалиевның концепцияләре башыннан алып ахырынача панисламизм һәм пантюркизм белән сугарылган иде. Моны яшерү өчен Солтангалиев үзенең милләтчелек фикерләрен марксизм фразеологиясе белән пәрдәләргә маташты». (Абдуллин М., Батыев С. Татарстан АССР: чынбарлык һәм буржуаз уйдырмалар. — К.: 1980, 132 бит.)

Татар әдәбияты классигы Гаяз Исхакыйның исемен шулай ук телгә алу да тыелды. Фашистлар тоткынлыгында баһадирларча кыюлык күрсәткән Муса Җәлил һәм аның көрәштәшләре исеме сталинчыларның каһәренә юлыкты. Тарихка кара чор булып кереп калган утызынчы еллар каһарманнары К. Тинчурин, Ш. Усманов, Г. Ибраһимов, Х. Туфан һәм тагын йөзләрчә фидакарьләр билгесезлеккә, онытылуга дучар ителгәннәр иде. Язучы халкы «Пропагандист» журналының икейөзлелеген шул вакытта ук аңлады, әлбәттә. Әмма чын геройлар, чын каһарманнар турында язу тыелган бер вакытта каләм әһеленең илһамы тоткарлана, авызы томалана. Бу хәл бездә тарихи, тарихи-революцион теманың үсешен киртәләүче әйбер булды. Бүгенге Н. Фәттах, М. Хәбибуллиннар ул елларда ерак элгәрләребез турында яза алмаган булырлар иде. Ник дигәндә, халкыбыз үткән олы юлның болгар һәм аннан соңгы чорлары да ул чакта шик-шөбһә пәрдәләре белән өртелеп тәкъдим ителә иде.

Билгеле бер чорны идеологик яктан тәэмин итүче күрсәтмәләр белән эш итү әнә шулай әдәбиятның кыек көзге булуына китерде. Бу шул көннәрне генә түгел, тарихны сурәтләүгә дә бердәй кагылды. Мәгълүм булганча, тарихны үзгәртеп булмый, аны булганынча язарга гына мөмкин.

Г. Ибраһимов «Адәмнәр» дигән әсәрендә 1921 елгы ачлык вакытында кешеләрнең соң чиккә җитеп ерткычлану күренешләрен тасвирлый. Язучы әлеге очракта шул вакыйгаларны ничек күргән һәм ишеткән булса, шулай тасвирларга тырышкан. Без исә, инде әдип күптән дөньядан киткән булса да, аның язганнарын «төзәтергә», алай түгел, болай ул, дип әйтергә тырышабыз. Утызынчы-илленче елларда Сталин төзегән халыклар төрмәсен «Нинди иркен минем туган илем, нинди рәхәт синдә сулавы» дип мактаган әдәбиятыбыз шулай ук кыек көзге иде.

Дөрес, 1917 елның октябрендә булган революциядән соң халкыбызның мәдәни тормышында сизелерлек уңай үзгәрешләр булды. Казан, Мәскәү, Әстерхан, Оренбург, Пермь, Екатеринбург, Сембер, Самара, Донбасс, Түбән Новгород һәм башка төбәкләрдә татарча газета-журналлар чыга башлады, театр коллективлары барлыкка килде, үзешчәнлек бик киң җәелде. Шулай да иҗади көчләрнең иң зур күпчелеге Казанда тупланды. Тора-бара автономияле Татарстанның үзәге итеп нәкъ менә шушы шәһәрнең сайлануы очраклы түгел иде. Борын-борыннан Болгар дәүләте үзәкләренең берсе булган Казанның татар халкы мәркәзе итеп игълан ителүе табигый булды.

Ләкин Россиядә сан ягыннан икенче урында торган татар халкының бары тик В. И. Ленин үзе үк икрар иткәнчә, өлкә буларак исәпләнгән автономия бирелеп кенә тынычландырылуы милли сәясәтнең башыннан ук дөрес хәл ителү түгел иде. «Хәзерге замандагы чын демократик дәүләтне азмы-күпме әһәмиятле хуҗалык һәм көнкүреш үзенчәлекләре булган, халкы аерым милли составлы һ. б. ш. булган һәрбер ө л к ә г ә (курсив минеке — Ф. Г.) шундый автономия бирүдән башка күз алдына китерергә мөмкин түгел» (Ленин В. И. Әсәрләр, 20 т., 32—33 битләр). Бу сүзләр В. И. Ленинның барлык милләтләр үзбилгеләнү хокукына ия дигән үз фикеренә үк каршы килә! Үзбилгеләнү хокукына ия булу ул урысның да, татарның да һәм тагын барлык башка милләтләрнең дә бер үк дәрәҗәдә иректә эш итүе дигән сүз. Әмма союздаш республикада яшәүче украин белән өлешенә автономияле округ кына тигән корякның хокуклары арасында җир белән күк аермасы барлыгын бүген күңеле дөм сукыр кеше генә күрмәс.

Югыйсә, В. И. Ленин бик ачык итеп болай дип тә язган иде бит: «Пролетариат «үз» милләте тарафыннан изелә торган колонияләрнең һәм милләтләрнең политик аерылып чыгу ирекен таләп итәргә тиеш. Шулай булмаганда, пролетариатның интернационализмы буш сүз генә булып кала» (Ленин В. И. Әсәрләр, 22 т., 152 бит). Күрәбез ки, пролетариат алдына куелган бу бурыч та үтәлмәде. Россия тирәсендәге һәм аның эчендәге күп кенә милли төбәкләр үзәкнең ярты хокукка гына ия булган автономияләре булып калдылар. Алай гына да түгел, рәсми хакимият бу халыкларның милли аңы үсешенә ясалма киртәләр коруга юнәлдерелгән гамәлләрне уйлап чыгарып кына торды. Бу бигрәк тә татар халкына карата шулай эшләнде. Югарыда санап үтелгән төбәкләрдәге татар матбугатының әкренләп бетерелүе, сәнгать оешмаларының ябылуы, халыкның бары тик русча гына укытыла башлавы — болар барысы да мәдәни үсеш тарихы ерак гасырларга барып тоташа торган татар милләтен урыслаштыру сәясәте иде.

Урыс язучылары белән бу мәүзугка сөйләшкәндә, еш кына алар болай диярга яраталар: совет хакимияте урысларның да милли аңын үзгәртергә аз тырышмады, мәсәлән, күпме чиркәүләр җимерелде... Бу сүзләрдә, әлбәттә, хаклык бар. Әмма шунысы да ачык: урысларның иң әһәмиятле әйберләре үзгәрмичә калды — теле һәм язуы. Алар «Слово о полку Игореве»дан алып бүгенге язучыларының әсәрләрен дә бер үк хәрефләр белән укыйлар. Телсез халык — беткән халык. Мәгълүм булганча, тел ул — аң да, дин дә, халык авыз иҗаты да, күңел дөньясы да. Тел һәм язу булса, милләт югалмый, бетми. Ә менә татар халкыннан шушы ике иң кыйммәтле әйберне тартып алырга тырыштылар. Автономиядән читтә яшәүче барлык татарлар урысча укырга мәҗбүр ителде. Татарстанның үзендәге күп кенә мәктәпләр рус телендә укытылуга күчерелде. Мәсәлән, Чирмешән районында Иске Үтәмеш дигән татар авылы бар. Әлеге авылда яшәүчеләр бу төбәктәге иң милли үзаңлы кешеләр икән. Ник дигәндә, алар авылда мәчетне саклап калганнар. Чирмешән районындагы бердәнбер булган бу мәчет эшләвен туктатмаган, аны карап-тәрбияләп, буяп-төзәтеп торганнар. Җомга, гает көннәрендә бирегә күңелендә иман булган байтак кеше җыела. Манара тәрәзәсеннән төшкән электр уты яктысы кичләрен авылга бик тансык, кадерле ямь биреп тора.

Әмма шушы авылда, мәчеттән ерак та булмаган мәктәптә, татар балалары урысча укырга мәҗбүр. Әти, әни, Ватан, ил сүзләрен алар «папа, мама», «Родина», «страна» дип әйтергә тиеш. Ләкин, урыс сүзләрен әйткәндә татар өчен әлеге иң якын төшенчәләрнең кыйммәте тоныклана, күпкә кими.

— Ни өчен мәктәптән татар телен куып чыгардыгыз? — дип сорыйбыз шагыйрь Газинур Моратов белән икәү директор ханымнан. Бу сорауга бирелгән җавап искиткеч мәгънәсез яңгырады. Күрше Куйбышев өлкәсеннән бу мәктәпкә берничә чуваш баласы йөреп укый икән. Аларны урысча укытасы булгач, татар авылының йөзләгән балалары да бер чыбыктан сөрелергә, чит халык телендә белем алырга тиеш булган. Йә әйтегез, бу чуваш балаларын үз авылларында укыту мәгъкульрәк түгелме икән? Моны оештыру Куйбышев өлкәсе җитәкчеләре кайгысы бит. Күз алдына китерегез: безнең Кукмара районындагы Арпаяз авылы Киров өлкәсенең Ершовка авылына ике генә чакрым. Әйтик, шушы татар авылыннан дүрт-

биш бөртек баланы әлеге Ершовка мәктәбенә алып барып бирдек, ди. Шуннан соң урыс авылы мәктәбе үз укучыларын татар телендә укытуга күчерер идеме? Бу акылга сыймаслык, мөмкин булмаган хәл. Ә татар авылында шулай эшләү гадәти хәл санала. Мондый хәлләрне дистәләп, йөзләп очратырга мөмкин. Инде язу алыштыруга килсәк, совет хакимияте чорында, гомер-гомердән килгән гарәп графикасыннан мәхрүм итеп, ике дистә ел вакыт эчендә башта латин, аннан урыс хәрефләренә күчүне бары тик татар халкының фаҗигасе дип кенә санап була. Әмма М. Мәһдиев «татар Ждановы» дип атаган С. Батыев һәм аның каләмдәше М. Абдуллин «Татар язуын рус графикасына күчерү «көчләп» түгел, бәлки хезмәт ияләренең үз теләкләре буенча эшләнде»,— дип раслыйлар. Хакыйкатьне бу кадәр инкарь итәргә мөмкинме соң? Алар кебек «Бу чара татар халкының интересларына тулысынча җавап бирде»,— дип әйтү өчен, үз халкыңны сөймәү, рәсми идеологиягә мөкиббән киткән булу, ягъни, дөреслеккә хилафлык итеп, куццанны әйтүче булу кирәк. Әлеге авторларның китабы «Татарстан АССР: чынбарлык һәм буржуаз уйдырмалар» дип атала. Ләкин авторлар үзләре дә уйдырма мәсьәләсендә кимен куймаганнар, караны ак дип күрсәтү өчен, турыдан-туры фактларны инкарь итү юлына басканнар. Фәндә, әдәби иҗатта бервакытта да дөреслеккә, халкыңа, үз намусыңа хилафлык кылуга бармаска кирәк. Тарих андыйларны иртәмесоңмы хөкем итә. Тарих хөкеменнән котылу урыны юк. Кеше үз гомерендә ана телендә язуның бер генә рәвешен өйрәнергә тиеш. Аның әле чит язуларны, телләрне өйрәнәсе бар. Гомер болай да бик кыска.

Халкыбыз кичергән бу хәлләрне хәтерләү бүгенгебез, киләчәгебез өчен кирәк. Халык хәтере — иң ышанычлы хәтер. Ул шуның ярдәмендә башкача «хәтерләүчеләрнең» язмаларын үз бизмәненә салып карый һәм, кирәксез әйбер буларак, чүп савытына ташлый. Әйе, яңалиф кабул ителгәч, гарәп хәрефләре белән язылган китапларны җыеп яндырганны, кириллица белән язарга мәҗбүр ителгәч, латин белән чыгып өлгергән китапларның тау-тау өеп юк ителгәнлеген үз күзе белән күргәннәрнең хәтере — бик ышанычлы чыганак.

1944 елның 18 маенда кырым татарлары туган җирләреннән куылган булса, шул ук елның августында татар халкының әдәби җәүһәре «Идегәй» дастаны кулланыштан алып ташлана, милләтебез тарихына карата яла сүзләре әйтелә. Кем белә, «Татар халкы үзенең сугыш эшендә чыдам һәм батыр йөрәкле солдатлары белән армиябез каршында хөрмәт казанды»— дип торучы Р. Малиновский кебек маршаллар булмаса, безнең язмыш та бөтенләй икенче төрле булган булыр иде.

Боларның һәммәсен дөресенчә язу өчен, язучының, фән эшлеклесенең күңел көзгесе саф булырга тиеш. Югыйсә, кыйшайган көзгенең хакыйкать белергә теләгән халыкка кирәге дә шулкадәр генә.

Бу урында, бик табигый рәвештә, сүз иҗат иреге мәсьәләсенә килеп чыга. Ә чын иректән башка язучы да, сәяси мәүзугка алынган фән кешесе дә ихлас була алмый. Телиме, теләмиме — ул үз сүзен түгел, бәлки кемнәрнеңдер аннан көткәнне әйтергә тиеш була. Иҗат иреге генә табылган мәгълүматлардан, документлардан гадел хөкем чыгару мөмкинлеген бирә.

Безнең язучыларыбызның каләме ирекле идеме? Дөрес, алар мәүзуг, тормыш кишәрлеген сайлаганда еш кына үз ихтыярлары, кызыксыну өлкәләре белән эш иттеләр. Ләкин иҗатта һәрвакыт ике як бар: беренчесе — нәрсә әйтергә, икенчесе — ничек әйтергә? Моның ни рәвешле булганлыгын үз вакытында М. Шолохов бик кыска итеп әйтеп бирде: «Без йөрәгебез кушканча язабыз, ә безнең йөрәгебез — партиянеке». Болай дип яшәү рәвеше, хәтта уйлау үзенчәлеге дә мәгълүм бер иҗтимагый шартларда калыпланган, ахыр чиктә рәсми таләпләргә генә буйсынып эш итүче генә әйтә ала. М. Шолоховны мин андый кеше итеп күз алдына китерә алмыйм. Ләкин, үз чоры кешесе буларак, ул сүз остасының хәлен дөрес итеп билгеләгән. Йөрәк, дөресрәге кеше күңеле, дөньяга караш — үтә шәхси әйберләр. Һәр кеше дөньяны танып-белүдә үзенчә эш иткән кебек, аны бары тик үзенчә генә тасвирлап бирә ала. Ул аны шулай сурәтли дә. Югыйсә нәрсә килеп чыга: бердәй күренеш турында язганда, бер үк сүзләр, бердәй фикерләр бер әсәрдән икенчесенә күчәләр, иҗат йөзе югалып кала.

Менә Н. Баянның «Ленин халыкта» дигән шигыреннән берничә юл:

*Үлде Ленин,*
*Калды Ленин*
*Калды халыкта.*
*Үлде Ленин...*
*Ләкин эше калды...*

М. Садри «Сталин — үлемсез» шигырендә тагын шундыйрак сүзләр һәм фикерләр белән эш итә:

*Сталин мәңгегә*
*йокыга талды,*
*Тынды Сталинның*
*йөрәк тибеше...*
*Халыкта калды,*
*партиядә калды,*
*Даһи акылы,*
*көче,*
*зур эше!*

Болар 1952, 1954 елларда бишенче, алтынчы класс укучылары өчен басылган әдәбият дәреслекләреннән алынды. Әмма мин Н. Баян, М. Садри кебек могтәбәр авторларны, бер-берсенә ияреп язганнар, дип әйтүдән ерак торам. Бу — шул чорның канунлаштырылган сүзләре һәм бәяләре, шигърияттә монументальлекнең чагылышы. Әдәбият, аерым алганда шигърият, халыкка якынрак килгәч, кешеләшә төшкәч, үзәккә кеше йөрәгенә якын гадилек уелгач, әнә С. Хәким В. И. Ленин турында «Күңелем Ленин белән сөйләшә» дигән нинди матур шигырь язды. Шул рәвешле, иҗаттагы диктат, канунлылык әдәбиятның эчтәлеген генә түгел, стилен дә берьяклы итеп, аны фәкыйрьләндерә.

Хәзер бу әйберләргә безнең күзебез ныграк ачылды. Татарстан мөстәкыйль дәүләт булып яши башлагач, уйларыбыз, карашларыбыз үзеннән-үзе киңәеп, иркенәеп китте, ышанычыбыз ныгыды. Димәк, без хәзер иҗатка кагылышлы мәсьәләләрне дә үзебезчә, бәйсезрәк хәл кыла алачакбыз. Биредә язучыдан кыюлык, тирәнлек, ватанпәрвәрлек, активлык таләп ителә. Автономияле республика чагында Бөтенсоюз мәйданына чыгу юлында киртәләр дә бихисап иде. Хәзер, ихтимал, безнең әдәбиятка да караш бераз үзгәрер. Һәрхәлдә, башкалар исәбеннән төшереп калдыра алмаслар. Ләкин шулай да Бөтенсоюз укучысына барып җитүгә юл ача торган сихри көч — әсәрләрнең югары сәнгатьлелеге! Югары сәнгатьлелек исә тормыш дөреслегеннән, сәнгать дөреслегеннән башка була алмый.

...Тормышны сәнгатьчә чагылдыручы көзгебез кыек түгелме? Моңа ничек җавап бирү әдәбиятыбыз язмышына, әдипләрнең тугры сүзенә бәйле.

# ОСТАЛЫК ТАМЫРЛАРЫ — ХАЛЫКТА

Гөлсем Мөхәммәдова язган «Зур тормыш» исемле истәлекләрдә* Г. Ибраһимовның «Татар хатыны ниләр күрми» повестеның язылу тарихы да телгә алына. Әсәрнең хәзерге заман укучысына таныш икенче басмасы 1929 елда дөнья күргән. Г. Мөхәммәдова сүзләре буенча, Г. Ибраһимов аның беренче вариантын кабат эшләп чыгарга ниятләнгән, чөнки әсәр бу килеш сәнгатьчә эшләнеше ягыннан йомшак килеп чыккан, дип санаган. Шул ук вакытта әсәр каһарманы Гөлбануның авыр язмышы татар халкының революциягә кадәрге тормышындагы катлаулы хәлләрне һәм каршылыкларны ачарга мөмкинлек бирә.

«Язучы тормышны дөрес, чынбарлыктагыча күрсәтергә теләсә, аның язган әсәрендәге вакыйгалар, персонажлар тасвир ителгән тормышның үзеннән мәҗбүри рәвештә туарга һәм тормышның иҗтимагый тамырларын ачып бирергә тиешләр. Ягъни бу вакыйгалар, бу персонажлар тасвир ителгән тормышның җимеше үрнәге булырга тиешләр». («Ибраһимов турында истәлекләр».— Казан, 1966, 402—403 бб.).

Әсәрнең сюжеты да, композициясе дә, образлары да, стиле һәм сәнгать чаралары да язучының үз алдына куйган әнә шул бурычларга буйсындырылган.

Г. Ибраһимов үзенең повестенда бик күп халыклар әдәбиятында эшкәртелгән, революциягә кадәрге авылга шактый дәрәҗәдә хас булган вакыйгалардан гыйбарәт бер сюжеттан файдалана: Гөлбану исемле яшь кыз Лотфи дигән егетне ярата, ләкин әтисе, файдалырак санап, кызын бүтәнгә бирә. Яшь килен барыбер ирен яратырга, кайната-кайнана өенә ияләнергә, аны үз өе итәргә тырыша. Тик иске тормышның кырыс кануннары һәм шәригать йолалары аның язмышын челпәрәмә китерә. Балалары үлү, иренең тоташ кыйнавы, кайнанасының явызлыгы аны үз-үзенә кул салу чигенә китереп җиткерә — ул суга ташланып үлә.

Бу сюжет А. Островскийның «Яшенле яңгыр» драмасы буенча да таныш. Ләкин язучыга шушы гади сюжет аша тирән милли үзенчәлекле әсәр язарга, татар кызының шул чордагы авылда узган фаҗигале һәм кыска гомерен күрсәтергә нәрсә ярдәм иткән?

Хатын-кызның авыр язмышы безнең милли фольклорда тирән чагылыш тапкан. Бу таныш мотивлар халык җырларында да, татар фольклорының гаять үзенчәлекле жанры булган бәетләрдә дә күп яңгырый. Күптән түгел чыккан фольклор 12 томлыгының «Бәетләр» китабына сүз башында шундый юллар бар: «Хатын-кызларны үзләре теләмәгән кешегә (картка, сабыйга, наданга һ. б.) кияүгә бирү, аның белән исәпләшмәү бик рәнҗеткән, нәфрәтләндергән һәм рухи протест йөзеннән аларга үз хокукларын яклап бәетләр иҗат итүгә этәргеч булып торган».

Шуны өстәргә кирәк ки, фольклор экспедицияләре вакытында киленнәрнең элекке авыр тормышы һәм хәтта аларның фаҗигале төстә үлүләре турында бәетләр табылып тора. Мәсәлән, 1984 елда Горький өлкәсенә оештырылган экспедиция вакытында безнең тарафтан «Үтерелгән килен бәете» язып алынды. Анда мондый юллар бар:

*Кыйблакайлардин җилләр бара,*
*Кайнатием милчә (тегермән) бора.*
*Кара айгырга су салганда*
*Җиһанша егет хатынын буа.*

Менә «Татар хатыны...» повестеннан бер өзек: «...Аның (Закирның) күзен караңгылык басты, чыбыркы сугуына туймады, битен-башын кочаклап бөгәрләнеп егылган Гөлбануның йөрәген, күкрәген аяк белән таптап изәргә омтылды».

Бәетләрдә көчләп кияүгә бирелгән кызларның, мәсхәрәләү һәм авыр эштән иза чиккән киленнәрнең язмышын чагылдырган шушындый трагик мотивлар күп очрый: андый мәзлүмәләрнең күбесе елга яки күл төбенә ташланып кына котылу таба. Татар халкы үзенең «Килен кеше бичара», «Кыз сату бәете», «Зөлхәбирә», «Моңлы хатын Бибигайшә» кебек бәетләрендә сөекле кызлары өчен күз яше түккән. Шәхси фаҗигаләргә багышланган уннарча һәм йөзләрчә бәетләрдә мәхәббәт һәм бәхет өчен туып, патриархаль авылның рәхимсез шартлары тарафыннан буып һәлак ителгән хатын-кызлар безнең күз алдыбызда әрнүле сафтай тезелеп баса.

Татар хатынының язмышын яктыртырга алынган әдип бәетләргә хас тема, тормыш материалы һәм киң таралган мотивларны игътибарсыз калдырмаган, әлбәттә. Аның повестен тулаем да мәхәббәт өчен яратылган сылу, уңган, җитез Гөлбануның

* Ибраһимов Галимҗан. Әсәрләр, сигез томда, 1 том.— Казан, 1974, 392 б.

һәм Гөлбанудай бик күп хатын-кызларның ачы язмышы өчен сыктау бәете дип атарга мөмкин булыр иде. Г. Ибраһимов татар авылы тормышын җанлы итеп күз алдына бастыру өчен сәнгатьчә тасвирның бик күп чараларыннан файдалана. Хатын-кызның шәхси фаҗигасенә багышланган бәетләрдә кыз чактагы бәхетле, якты көннәр кияүгә чыккач башланган авырлыкларга каршы куеп тасвирланучан. Мәсәлән, «Моңлы хатын Бибигайшә»дә болай диелә:

*Кайгы-хәсрәт күрмәдем яшь үсмерли чагымда.*
*Уйнап-көлеп үстем мин үз әнкәм кочагында.*
*Шулай итеп, яшь килен булып китте кыз башым,*
*Шатлыкларым кайгы булды, кемгә төшәр күз яшем.*

Повесть та, ике төсле буяу белән язылгандай, шулай ук ике кисәккә бүленә. Беренче өлеше — Гөлбануның кыз туе, кияүгә чыгуның беренче көннәре автор тасвирында якты төсләр белән җемелдәп тора, сурәттән нурланып, шатлык хисе бөркелә. Нәкъ шушы тасвир өлешендә татар халык йолалары үзләренең гүзәл бизәкләре белән күз алдына бастырыла. Бигрәк тә туй йоласы тулы гәүдәләнә. Ярәшү, никахлашу, кодалар төшү, кияү килү, «ишек бавы» йоласы, кияү озату, кияү авылына килен төшү эпизодлары тәфсилле һәм искиткеч җанлы тасвир ителә. Кунакларның бәйрәм киеме, яшь килен белән кияүнең бүлмә бизәлеше, аларның туй киемнәре, кияү бүләкләре кебек этнографик детальләрнең җентекле һәм зиннәтле бирелеше шул чор татар авылына хас мохит һәм бүтән бер кайда да очрамый торган милли сәнгатьчә үзенчәлеге гаҗәеп тулы канлы, җисемле һәм ышандыргыч сурәтләнә. Язучы кияү белән килен бүлмәсен менә ничек тасвирлый: «Мәрхәбә өйнең бөтен ялангач стеналарын киҗеле сөлгеләр, чигүле намазлыклар белән бизәп бетерде. Кияү бүлмәсе ак, кызыл, кара, яшел, саргылтзәңгәр, күгелҗем-кара, сыек миләүшә төсләре дулкыны эченә батты... Киң агач ятакның өстенә тау-тау өелгән түшәк-ястыкларны, мендәрләрне яңадан кабартып җәйде, юрганны түбәнрәк салындырды, киҗеле япманың кызыл төстәгесен ак белән алмаштырды да кечкенә мамык мендәрләрне өскә күпертеп куйды».

Повестьта мондый тасвирлау еш очрый. Авторның әлеге этнографик сурәтләргә сокланып каравы, укучы белән бергә шуларны берәм-берәм күзәтеп чыгарга яратуы күренеп тора. Әсәрнең беренче бүлеге, гомумән, бәйрәмчә төсләр һәм бизәкләр белән эшләнгән, оптимистик рух повесть тукымасына халыкның җанын чагылдырган гореф-гадәтләр һәм йолалар тасвирын кертү аша хасил кылына. Бүлмәләрнең бизәлеше, сый мәҗлесе, гомумән, мул җете төсләр белән яктыртыла.

Игенчегә, авыл кешесенә аерым игътибар белән караган Г. Ибраһимов бәйрәм тасвиры белән генә чикләнми. Болары аның бары кыска мизгелләр генә. Игенче тормышы ул тоташ авыр хезмәттән тора. Повестьның каһарманы төскә-буйга чибәр. Аның тышкы кыяфәте халык җырларына хас бәяләнә һәм бизәкләр аша бирелә: «Буйга дисәң — Идел камышы кебек зифа, йөз дисәң — тулган ай кебек, балкып торган йөзендә ялкын уйный, авызы уймак, йөреше — аккош йөреше». Ләкин Гөлбану иркә гүзәл түгел, ул кечкенәдән игенче эшенә өйрәтелгән. Кырыс Нурый карт үз балаларын азындырмаган. Алар яшьли кырда эшләп, таңнан төнгәчә тир түккәннәр. Гөлбану үзенә бирнәлек әзерли (әдип аны өшәнчек дип атый), авыл кызларына тиеш булганча, тукый, бәйли, үзенә һәм булачак киявенә дип чигү чигә. Шушы эш сөючәнлеге аны ире өендә буласы кырыс тормышка ныклап әзерли. Ул яшь килен өлешенә төшкән барлык сынауларны беренче көннән үк намус белән үтә, печән чапканда ирләр белән бертигез эшли. Әсәрдә игенче календаре тоташ сизелеп тора. Менә авылдагы авыр, ләкин көтеп алынган печән өсте. Яшьләр болынга бәйрәмгә әзерләнгән кебек җыеналар, ә картлар яшьлекләрен искә ала. Печән чапканда яшь килен чын мәгънәсендә хезмәт сынавы уза.

Болыннар бу чорда гаҗәеп гүзәл була. Г. Ибраһимов укучыны үзенең туган җире табигатенә хас күренешләргә сокландыра. Әсәрдә шушындый тасвири күренешләр, сурәтләр күп очрый. Табигать әсәр каһарманының кәефен, кичерешләрен чагылдыра, вакыйгаларның тигезләйме-болаймы чишелешенә ишарә ясый. Халык иҗатындагы кебек үк, табигать Гөлбануның язмышына аваздаш рәвештә сурәтләнә. Ул авторны туган җир язмышы турында уйлануларга этәрә. Нәкъ менә табигать, туган җир гәүдәләнеше буларак, халыкның җанлы тарихи хәтере дә булып калка. Табигать күренешләре, халык шигърияте традицияләренә хас булганча, әчтәлек белән органик бердәмлектә бирелә, образларны мәгълүм бер фонда төсмерләргә булыша. Мәсәлән, повестьның башында ук Гөлбануның туе алдыннан ап-ак саф кар яуганы тасвир ителә. Ул бөтен тирә-якны акка төрә. Каһарманның күңел һәм ниятләре сафлыгы шушы күренештә ачыла сыман.

Менә яшь килен кияү өенә килеп төшә. Яңа тормышының беренче ае. Гөлбануның саф яшьлек матурлыгы, гүзәл болын, чәчәкләр һәм җиләкле аланнар күкрәгендәге хезмәт шатлыгы, бәхет хисе әсәрнең бөтенләй икенче эмоциональ көйләнешен

хасил итә. Хезмәт үзе дә, табигать белән кушылып, шатлыкка әверелә. Август аендагы урак өсте күренешләре дә шундый ук бәйрәмчә күтәренкелек белән тасвир кылына. Гөлбану монда да уңган, тырыш, нык эшләүче булып күз алдына баса. Ул барлык сынауларны да намус белән җиңеп бара. Әмма аның киләчәге бик күңелсез.

Гөлбануның кияүдәге тормышын тасвирлаган сәхифәләр язучының үз йөрәген дә әрнетә шикелле. Хикәяләүнең эпик салмаклыгы да, йолалар тасвиры да юкка чыга, табигать тә вакыйгаларда катнашудан туктый. Әсәрнең бу өлешендә хикәяләү теле дә корырак, гыйбарәләр дә өзек-өзек хәлдә, сюжет реалистик кырыс. Менә гаилә башлыгы Шибайның вафатыннан соң ук патриархаль гаилә таркалып китә. Уллары сугыша-сугыша милек бүләләр. Гөлбануның ире Закир өлешсез кала. Анасы Сабира улы белән кала. Башларына төшкән бөтен күңелсезлекләрнең үчен алар бичара килениән алалар. Гөлбануның балаларе дә гадәт-йоланы бозудан башлана: өйдәгеләр берниди житди сәбәпсез аның бирнәләрен туздыра башлыйлар. Киленнең юашлыгы да шунда төкәнә. Ул беренче тапкыр ризасызлык белдереп, халыкның мәңгелек йолаларына нигезләнгән хокукын якларга керешә. Шуннан мәсхәрә һәм кыйнаулар китә. Ярдәм сорап баргач, аны мулла да яклап чыкмый, атасы да, бирнәгә һәм туйга тоткан чыгымнарын кызганып, яклаудан баш тарта.

Гөлбану, бәлки кадерле җан булып баласы тугач бары да рәтләнер дип чыдый. Тик каты кыйнаудан аның игезәкләре үле туа. «Әйтерсең, җанның ике канаты берьюлы сынды да, ул хәзер, имгәнгән кош кебек, үлә алмый җирдә өстерәлеп йөри». Язучы каһарманының интегүләрен канатлы җан — кош образы аша сынландыра. Җан кошы образының сурәтле нигезе исә халык ышануларына барып тоташа. Борынгы төркиләр үк җанны канатлы мәхлүк итеп күз алдына китергәннәр. Җан кошы образы фарсы һәм төрки поэзия тарихында күп эшкәртелгән. Кол Гали (XIII йөз), Нәваи (XV) һәм Мөхәммәдъярда (XVI) аның колоритлы үрнәкләре бар (Хисамов Н. Бөек язмышлы әсәр.— Казан, 184, 126—131 бб.). XX йөз башында бөек Тукай, буржуаз чынбарлыкны кире кагуын һәм азатлыкка омтылышын чагылдырып, «Очты дөнья читлегеннән тарсынып күңлем кошы»,— дип язган. Язма поэзия аша бу образ халык шигъриятенә әйләнеп кайткан һәм җырларда милли психология халәтен чагылдыруның бер чарасы булып йөри. Г. Ибраһимов шушы чараны Гөлбануның балалары үлеменнән соңгы үзәк өзгеч кичерешләрен бирү өчен файдаланган. Повестьтагы имгәнгән җан кошы образы татар укучысын тирән тетрәндерә.

Игезәкләре вафатыннан соң Гөлбану сихерче Гайниягә барырга була. Табигатьтә дә кайгы ташыгандай, халык иҗатындагы кебек үк, ул да Гөлбануның булачак бәхетсезлегеннән кисәтә кебек: «Шомлы караңгы төн эчендә, ялгыз башын кая куярга белмичә, озак, бик озак торды». Сихерченең өен һәм үзен тасвир итү әкияттәгедәй шомлы. Яшь хатынны ул яман юрау белән каршы ала: «Җырымның кайгылы җирена туры килдең ләбаса. Йолдызың каралып бара». Сихерченең имләү сүзләре патриархаль авылның ырымнарга, табигатьтән өстен көчләргә ышануына туры килә. Язучы халык ышануларыннан оста һәм бик белеп файдалана.

Сихерче әйткән сүнгән йолдыз хакындагы яман ырым бәхетсез хатын-кызны мәгълүм бер карарга көйләп куя. Ире тарафыннан рәхимсез кыйналган Гөлбану Караюрга елгасына юнәлә. Елга сулары әле кайчан гына аның эштән кызышкан тәннәренә салкынча сафлык биргән иде...

Коеп яңгыр яуса да, халык болыт кебек җыелып зиратка тула. Барысы да бердәм булып бичара Гөлбануны кызганып сөйли.

Г. Ибраһимов үзенең реалистик әсәрен романтикларча тәгәлли: халыкның тулып ташыган сабырлыгын, кискен ризасызлыгын табигать күренешендә чагылдыра — Үзән елгасы ярларыннан ташып, буаны ерып ата.

Реалист әдип «Татар хатыны ниләр күрми» повестенда Гөлбануның бәхетсез язмышы аша игенченең кырыс тормышын, авылның катлауларга бүленүен, иҗтимагый контрастларын күрсәтә. Әмма йолалар, гореф-гадәтләр, халык шигъриятенә хас чаралар әсәрдә реалистик төсмергә сугарылган.

Әдәбият-фольклор бәйләнешләрен өйрәнүчеләр нык үскән әдәбиятта фольклор чараларыннан файдалануның аңлы рәвештә кулланыла торган алым булуын билгеләп үтәләр. (Далгат У. Б. Литература и фольклор.— М., 1981, 15 б.) Г. Ибраһимовның фольклордан файдалануында берничә этап күзгә ташлана. «Татар хатыны ниләр күрми» повестенда фольклордан килә торган башлангыч саф әдәби башлангыч белән шулчаклы органик үрелгән ки, аларны хәтта аеруы да кыен. Әлбәттә, әсәрне шартлы рәвештә генә чәчмәгә күчерелгән бәет дип тә карарга мөмкин. Аның бу жанр белән бәйләнеше бәрелеп үк тора.

Бәетләр — шәхси фаҗигаләрне дә, тормышта булган көлкеле вакыйгаларны да хикәяләүче жанр. Үзенең «Әдәбият мәсьәләләре» исемле мәкаләсендә (1910) Г. Ибраһимов бәетләрнең халык тарафыннан кемнең дә булса кайгысын чагылдырып һәм шу-

ның белән хәсрәтләнеп яки нинди дә булса килешсез эшеннән көлеп иҗат ителүләрен күрсәтеп үтә. Әлеге повестенда әдип усал кайнана Сабираны тасвирлау өчен зур булмаган ике сатирик бәеттән файдалана. Солтан турындагы сатирик бәетнең дә эчтәлеге сөйләнә. Сабираның бөтен нәселенә ябышып калган «Кәҗә Солтан» кушаматы шуннан алынган икән. Туй вакытында нәкъ менә шушы кушаматны искә алудан Сабира белән яшь киленнең бер җиңгәсе арасында тавыш чыга. Бу очрак соңрак килен өчен бик начар нәтиҗәләр бирә. Шул рәвешле, автор, фольклор элементларыннан файдаланып, сюжет үсешенә нык тәэсир ясаган төп конфликтны билгеләп куя. Биредә фольклор чагылышы әсәр структурасын оештыручы вазифа ролен башкара.

Башка әсәрләрдәге кебек үк, монда да Г. Ибраһимов мәкальләр һәм әйтемнәрне күп куллана. Теге йә бу персонажны сурәтләгәндә, автор сөйләмендә дә алар байтак очрый. Персонажлар телендә дә афоризмнар еш яңгырый: «көндәш көне — эт көне», «җиңел аяк белән килү», «туйган җирдән туган җир артык», «күңел киң булса, урын тарлыгы куркытмый», «көяз туңмас, калтырар», «илдә чыпчык үлми», «өе биек, өйрәсе сыек», «елан авызыннан зәһәр эчәргә риза»... Шушындый афоризмнар һәм халык зирәклегеннән туган фразеологизмнар персонажларның теге яки бу сыйфатын ачып кына калмый, бәлки мәгълүм бер колорит хасил итеп, милли хикәяләү факторларының берсенә әйләнә.

Шул рәвешчә, революциягә кадәрге татар авылын реалистик сурәтләүне туган халыкның бәетләрдән, җырлардан, мәкаль һәм әйтемнәрдән торган фольклор эстетикасы һәм шулай ук этнографик күренешләре белән органик кушу Г. Ибраһимовка чын мәгънәсендә милли, халыкчан әсәр иҗат итәргә мөмкинлек биргән. Әдәбият галиме Мансур Хәсәнов үзенең Г. Ибраһимов турындагы китабында (Казан, 1964) «Татар хатыны ниләр күрми» повестеның татар совет әдәбиятында иң күренекле әсәрләрдән булуын, аңарда революциягә кадәр татар хатын-кызларының авыр язмышы гына чагылмыйча, бәлки тарихи киләчәктә хатын-кыз азатлыгы проблемасы да куелуын, халыкның тарихи тәрәккыяте котылгысыз икәнлеге нигезләнүен дә хаклы рәвештә күрсәтеп үтә.

**Айсылу САДЫЙКОВА.**

# УЛ ГАЛИМ ДӘ ИДЕ

## АФЗАЛ ШАМОВНЫҢ ТУУЫНА 90 ЕЛ ТУЛУ УҢАЕННАН

Авыл мәктәбендә укыганда, бала чагында ук, Афзал ага Шамовны зур язучы итеп белә идем. Ул минем күңелемә «Рәүфә», «Кыз урлау» хикәяләре белән кереп калган иде. Хикәяләрне авыл китапханәсеннән алып кайтып, сукыр лампа яктысында ярты төнгә кадәр бик тәэсирләнеп укып утырганым әле дә хәтеремдә.

Казанга килгәннән соң, бу мәһабәт сынлы, тышкы кыяфәте белән дә чын зыялы һәм салмак характерлы бу әдибебезнең төрле җыелышларда чыгышларын да тыңларга туры килде. Сүзнең кадерен белеп, авыз тутырып әйтеп, һәркемгә барып җитәрлек ачык дикция белән сөйли иде ул. Хәер, моны әллә ни гаҗәп тә түгел, барыбыз да сөйлибез.

Иң гаҗәпләндергәне шул иде: бер мәлне ул минем күз алдымда галимлек сыйфаты белән дә ачылып китте. Бу болай булды. 1983 елда Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтының әдәбият бүлеге Октябрьгә кадәрге татар язучылары һәм мәдәният эшлеклеләре турында био-библиографик белешмә китабы төзеп чыгаруны үзенең эш планына кертте. Без, фәнни хезмәткәрләр, үзебезгә тиешле шәхесләрне сайлап алдык. Миңа утыз язучы һәм журналист тиде. Ләкин алардан күбесенең, мәсәлән, Х. Әбүлхан, И. Биккулов, З. Нуркин, Ф. Ибраһимов, Л. Гадел, Т. Яхин, Х. Әхмәрова һәм башкаларның биографияләре билгесез иде. Иҗат җимешләре дә элекке газета-журнал битләрендә генә сакланып калган. Инде нишләргә? Бу шәхесләрнең биографияләрен кайдан табарга? Мондый очракта өлкән буын зыялыларыбызга да мөрәҗәгать итми булмастыр.

Шулай беркөнне, Х. Әбүлхан турында мәгълүмат таба алмый аптырап йөргәндә, бер танышым: «Афзал агага мөрәҗәгать итеп кара»,— дип киңәш бирде. Аптырабрак калдым. Зур язучы икәнен белсәм дә, аның гыйльми мәгълүматлы кеше булуын күз алдына да китерми идем. Аннан соң, кайбер күп белүче кешеләр үзләрен югары тотучан булалар, белгәннәрен башкалар белән бик үк уртаклашасылары килми.

Мин бераз шикләнебрәк тә, ышанмыйчарак та Афзал агага шалтыратырга батырчылык иттем. Ул трубканы алу белән шулкадәр якын, үз итеп сөйләште, әйтерсең лә без күптәнге танышлар. Аның һәр сүзендә үзенең белгәннәрен башкалар белән уртаклашасы килү теләге сизелеп тора иде. Шуннан соң мин аңа еш шалтырата торган булып киттем. Аның белән күп мәртәбәләр сөйләштек, берничә еллар дәвамында хатлар алыштык. Дөрес, ул зур-зур гыйльми хезмәтләр бастырган кеше түгел. Әмма аралашу дәверендә мин аның киң мәгълүматлы, яхшы хәтерле кеше булуына хәйран калдым. Ул үзе дә: «Табигать миңа яхшы хәтерне кызганмаган, ул яктан зарлана алмыйм»,— ди торган иде. Чыннан да, табигать аңа язучылык таланты гына түгел, галимлек хәтере дә биргән. Андый кешеләрне халык телендә «Аяклы энциклопедия» дип йөртәләр. Афзал ага да нәкъ шундый кеше булып чыкты. Ул шәһәребезнең тарихи биналарын яхшы белә иде. Берләштерелгән татар-башкорт хәрби мәктәбе, коммунистлар клубы, Татар коммунистлар университеты, рабфаклар, элекке мәдрәсәләр, мәчетләр, Гажур һәм башка тарихи биналар турында аңарда мул мәгълүмат саклаган икән.

Афзал ага — озын һәм нәтиҗәле гомер кичергән әдип. Октябрьдән соң чыккан совет газета-журналларының өешу тарихы аның күз алдыннан үткән, ул шул тарихның эчендә кайнаган һәм берсен дә онытмаган. Егерменче-утызынчы һәм аннан соңгы елларда татар зыялыларыннан ул белмәгән, аралашмаган кеше, язучылар тормышында ул катнашмаган вакыйга сирәк калгандыр. Г. Камал, Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимов, Г. Хәбиб, М. Гали, В. Шәфигуллин, И. Кули, К. Нәҗмиләр турында һич иренмичә сөйли иде ул. Татар язучылары һәм журналистларының байтагы турында истәлекләр дә язды. Алар «Чын хикәяләр» (1986) исемле китабында басылып та чыкты.

Шуны әйтергә кирәк, Афзал ага гомеренең соңгы чорында каты һәм озак авырды. «Вакыт-вакыт, асып куелып та, үлә алмый газапланган кеше хәлендә калам»,— ди торган иде. Миндә аның уналты данә хаты саклана. Алар нәкъ менә шушы авыру чорына туры килә. Шул авыру килеш, ул бер соравымны да җавапсыз калдырмады. Хатларын машинкада үзе басар, ахырга имзасын һәм датасын пөхтә итеп куяр, ә үзем язсам, хатны алуы турында хәбәр итәр.

Хәзер уйлыйм-уйлыйм да нәтиҗә ясыйм: шундый авыру тәкъдирдә олы йөрәкле, башкаларга ихтирамы зур булган кеше генә шулай эшли ала торгандыр, мөгаен. Аның хатлары бит сәлам хатлары гына түгел. Ул миңа Әсгать Фәхретдинов, Фәхри Басыйров, Кәшшаф Казаков, Габдулла Әхмадиев, Заһит Нуркин, Каюм Мостакаев, Заман Бикбаев кебек бөтенләй билгесез диярлек, ләкин мәдәни тарихыбызда азмы-күпме өлеше булган шәхесләр турында белешмәләр язып җибәрде. Хәзер әйтергә генә ансат, ул бу белешмәләрне язар өчен авыру килеш күпме утыргандыр, архивларыннан күпме эзләнгәндер, хәтерен эшләткәндер. Ул белешмәләрне язу белән генә чикләнми, кирәкле шәхесләр турында кайдан ничек эзләргә мөмкин, шуларны да күрсәтә. Мисал өчен бер-ике хатын китерәм.

*«Фатыйма туганкай!*

*З. Нуркин тәрҗемәләрен яисә әсәрләрен Сез китапханәләрдән эзләү белән генә чикләнмәгез. Авыр елларда ул китапларның китапханәләрдән алынган булуы ихтимал. Татар китаплары турындагы белешмәдән эзләгез. Мәсәлән, «Татар китаплары», 1 т., Казан, 1979. Бу китапта аның кулы белән тәрҗемә ителгән биш китап исеме бар: Ленин әсәрләре, К. Маркcның «Капитал»ы, Сервантесның «Дон-Кихот»ы һ. б.*

*Китап палатасында бу китапның башка томнары да әзерләнгән. Шуннан карагыз. Анда 1930—1938 елларда чыгарылган китапларның да исемлеге булырга тиеш, тиеш кенә түгел, бар.*

*З. Нуркин 1917 елга чаклы да каләм һөнәре белән яшәгән. Аның Октябрь революциясенә хәтле чыккан тәрҗемәләре яисә оригинал әсәрләре бардыр. Ул китапларның исемлеге сезнең институтта бар, шулардан мин белгәне — Исмәгыйль Рәмиев тарафыннан төзелгән исемлек. Аның сездә барлыгын яхшы беләм. Аны сезгә бирдерүдә минем дә бераз катнашым булды. Сездә, бәлки, тагын башка исемлекләр дә бардыр. И. Рәмиевнең кульязма хәлендә генә «Белешмә»се бар иде. Бу сезгә мәгълүмдер. Шунда З. Нуркинның биографиясе юкмы? Моннан тыш Рәминең эшләнеп бетмәгән кульязмалары арасында да З. Нуркин турында кайбер мәгълүматларның булуы мөмкин. Дәүләт архивында Татгосиздат архивын карамадыгызмы? Заһит абыйның автобиографиясе анда булуы бик ихтимал.*

*Күп сәлам белән Афзал Шамов*
*1985 ел, 11 апрель.»*

Педагог, язучы Хабибрахман Зәбиринең Октябрьгә кадәрге биографиясе Ш. Шәһидуллинның «Заман календаре»нда теркәлеп калган, ә совет чоры эшчәнлеге турында мәгълүматлар сакланмаган. Шушы уңай белән Афзал ага түбәндәгеләрне язып җибәрде:

*«Фатыйма туганкай!*

*Сезгә бер адрес җибәрәм. Х. Зәбирине ул белмиме икән? Казан, 80, ул. Волгоградская, 12, кв. 43, Фәхретдинов Шәрәф Билалович. Әгәр исән булса, аның белән сөйләшеп карагыз. 1922 елдан башлап матбугатта һәм типографиядә эшләгән иптәш. Башта — яшьләр өчен чыгарылган газета-журнал редакторы. Аннары К. Якуб исемендәге типография директоры. Мәгълүм Кәрәм аның кул астында эшләде.*

*1986 ел, 5 май».*

Афзал ага белешмә биргән шәхесенә үз мөнәсәбәтен дә белдерә иде. Шәриф Байчураны ул менә ничек характерлады:

*«Фатыйма туганкай!*

*Татар вакытлы матбугаты тарихында төрле журналистлар бар. Кайберләре аларның Бөек Октябрь революциясен бик рухланып, канатланып кабул иткәннәр, ә кайберләре аңа шактый борылмалы юллар белән килгәннәр. Ш. Байчура да шундый борылмалы юллар белән килгән журналистларның берсе. Шуңа күрә искәрмәгездә аны «журналист» дип атап китү генә җитмәс шикелле. Әгәр аны түбәндәгечә сыйфатласагыз ничек булыр: Байчура Шәриф (1892—1972) журналист һәм тәрҗемәче. Бөек Октябрь революциясенә чаклы «Россия сәүдәсе» журналы секретаре. 1917—1918 елларда татар буржуазиясе тарафыннан чыгарылган «Корылтай» газетасы әдәби сотрудниксы. Соңыннан совет вакытлы матбугатында һәм нәшриятында хезмәт итә. Утызынчы еллардан башлап, Совет учреждениеләрендә эшли.*

*Ихтирам белән Афзал Шамов*
*1983 ел, 16 август».*

Афзал ага, картлык көннәрендә җәмәгате вафат булып, врач һәм укытучы балалары тәрбиясендә яшәде. Авыруы җибәргән вакытларда иҗат эше белән дә шөгыльләнде, мөмкинлеге булган чакта хатынының каберенә дә барып йөрде. Минем Х. Әбүлхан турындагы үтенечемне онытмаган икән, каберлеккә бер баруында Х. Әбүлханның кабер ташын табып алып, таштан түбәндәге язуны күчереп алып кайтты:

«Бөтен гомерен татар милләтен агарту юлында сарыф иткән Хәлил Габделвәли угылы Әбүлхан 1919 елның гыйнвар 6 сында 32 яшьтә вафат. Мәрхүмнең кыскача хәятының мөндәриҗәсе милләт балаларына тәрбия вә тәгълим һәм алардан тормыш өчен көрәшчеләр җиткерү. Мәрхүмнең калдырган мирасы — гыйлем юлына керткән меңнәрчә милләт балалары». Х. Әбүлхан — педагог, балалар язучысы, Октябрьдән соң Казан өязе Мөселман мәгариф шөгъбәсенең беренче рәисе.

Афзал ага хатларында: «архивымны актарганда», «кульязмаларымны актарып утырганда», «моннан егерме еллар элек язып куйган мәгълүматларым» дип еш яза иде. Мин аның шәхси архивы белән таныш түгел, хатларыннан чыгып караганда исә анда мәдәниятебез һәм әдәбиятыбыз өчен кызыклы материаллар аз җыелмаган булырга тиеш. Мин аның Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты архивына килеп йөргәнен дә хәтерлим. Ул — Г. Ибраһимовны якыннан күреп белеп, утызынчы елларда аның «Сайланма әсәрләр»ен редакцияләп чыгарган кеше. Г. Ибраһимов исеме арабызга яңадан әйләнеп кайткач, аның иҗат мирасын туплау комиссиясенең рәисе булып эшләде. Аның Г. Ибраһимов хатларын җыюга куйган хезмәтен аерым билгеләп үтәргә кирәк. Моның өчен аңа дистә еллар кирәк булды. Ул әдипне белгән, аның белән язышкан кешеләрне эзләп табып, күп санлы хатлар җыеп, матбугат битләрендә бастырып чыгарды. Г. Ибраһимовның Яңалифкә күчкәнче гарәп шрифте белән язылган хатлары укырга авыр.

почеркы ачык түгел. Бу хатларны хәзергегә күчерүче дә А. Шамов иде. Ул әдип турында истәлекләр китабы да чыгарды.

Татарстан Үзәк дәүләт архивында, Татарстан өлкә комитеты партия архивында эзләнүләр алып барып, әдипнең автобиографиясен табып алып, аны татар теленә тәрҗемә итте. Аңа Г. Ибраһимовның Украина ССР Үзәк Дәүләт тарихи архивындагы документлары да таныш иде. Тик шуны әйтергә кирәк, Афзал аганың эшне тиз генә хәл итмичә, озакка суза торган гадәте бар иде. Әллә авыруы комачаулады: әнә шул җыйган хатларын, матбугатта бастырса да, аерым китап итеп бастырып чыгара алмады. Хатларның төп нөсхәләрен дә, үзенең архив материалларын да тиешле урыннарына урнаштыра алмыйча, якты дөньядан күчте, күпме белгәннәрен үзе белән алып китте!

Минемчә, үз хезмәтеңне бастырып чыгару — изге эш. Башка берәүнекен җыеп, барлап, фәнни эшкәртеп чыгару — икеләтә изге эш. Монда төзүчедән авторга зур ихтирам, фәнни намус дигән нәрсә сорала. Афзал ага шушы икеләтә изге эшләрне дә башкарды. Г. Ибраһимовның сигез томлык «Әсәрләр» җыелмасының икенче томын (проза әсәрләре) әзерләп чыгаруга катнашты. Г. Ибраһимов әсәрләренә аңлатмалар бирү шулай ук гыйлемлек таләп итә.

Ф. Әмирханның әдәби мирасын халыкка кайтарып бирүдә дә Афзал ага үз өлешен кертте. Бу эш белән ул сугыш алды елларында ук шөгыльләнә башлый. 1941 елда әдипнең «Сайланма әсәрләр»ен, 1957 елда ике томлык «Әсәрләр»енең беренче томын (хикәяләр, повестьлар) аңлатмалар белән бастырып чыгара. Бу эш гаять авыр шартларда эшләнә. Рәхсәт алу өчен аңа берничә мәртәбә Татарстан өлкә комитетына барып, үтенергә, язучы турында хакыйкатьне ышандырырлык итеп исбат итәргә туры килә. Чөнки Ф. Әмирханга озак еллар дөрес бәя бирелмәде, ул либераль буржуаз язучы тамгасы белән йөрде. Әлеге бәя аның әсәрләрен дөньяга чыгаруга киртә булып торды. Бу киртәне беренчеләрдән булып А. Шамов, Х. Хисматуллин алып ташладылар.

Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында Ф. Әмирханның бай кульязма фонды саклана. Афзал ага шул фонд белән дә таныш иде. Ул Институтның китапханәсендә Ф. Әмирханның бит маскасы булуы, аны кемдер төшереп ватуы турында да борчылып сөйли иде.

Татарстан Үзәк дәүләт архивында Ф. Кәрими фонды бар. Ул хәзергәчә тасвирланып бетмәгән. Афзал ага әнә шул фондта Ф. Әмирхан хатлары барлыгын да белгән. «Шул хатларны алып бастырып чыгарыгыз», — ди торган иде ул.

Классикларыбызның күп томлык әсәрләрен дә алдырып барган булса кирәк ул, чөнки берәр язучы томы дөнья күрү белән шалтырата, үзенең куанычын белдерә, күңелне күтәрә торган матур сүзләр әйтә иде. Кайбер томнардагы аңлатма бирелмичә үтелгән аерым кешеләр турында исә ул: «Миннән сорарга кирәк иде, мин ул кешене белә идем», — дип борчылып та куя иде...

Әдәби иҗат эше белән бер рәттән, фән өлкәсенә карый торган эшләр дә Афзал ага өчен рухи ихтыяҗ булып торган икән, дигән нәтиҗәгә киләсең.

**Фатыйма ИБРАҺИМОВА.**

Китап күзәту

# ХӘБӘРДАРЛЫК ЧОРЫНДА ЯЗЫЛГАН ХЕЗМӘТ

Филология фәннәре докторы Әбрар ага Кәримуллинның Совет хакимияте дәверендә татар китабы тарихына багышланган яңа монографик хезмәте үзгәртеп кору елларында язылды[1].

Китап сәхифәләренә күз салу белән хөррият рухы күзгә ташлана. Нихәтле китапларыбызның, аларны язучыларның исемнәрен без моңа кадәр матбугатта күрү, искә алу мөмкинлегеннән мәхрүм булганбыз икән, хәзер анә мөмкин инде...

Исеменнән үк күренгәнчә, китапта Татарстанда 1917—32 елларда эшләп килгән аерым оешмалар, ведомстволар, махсус оешмалар, ширкәт (кооператив) нәшриятларының эшчәнлегенә анализ ясала.

Бөек Октябрь социалистик революциясе илдә җиңүгә ирешкәннән соң, элеккеге Россиянең хосусый милеккә нигезләнгән хуҗалыгын яңа нигездә үзгәртеп кору башлана. Бу үзгәрешләр шулай ук матбугат, нәшрият һәм полиграфия өлкәсенә дә кагыла. Илдә урнаштырылган пролетариат диктатурасы басма сүзнең массалар өчен көрәштә куәтле корал икәнлеген искә алып, аңа дәүләт монополиясе игълан итә. Россия республикасында матбугат, нәшрият һәм полиграфия органнары үзәкләштерелгән дәүләт аппараты карамагына күчә башлый.

Ләкин бу процесс озакка сузыла, төрле югалтулар һәм табышлар аркылы хәрәкәт итә бара.

Бер яктан китап басуда дәүләт монополиясе үсә барса, шул ук вакытта элеккедән калган инерция буенча төрле ведомстволар, махсус оешмалар, кооперативлар карамагында нәшриятлар, типографияләр бер ябылып, яңалары ачылып, шушы хәл 1930 елларга кадәр дәвам итә.

Ә. Кәримуллинның яңа хезмәтендә әлеге хәрәкәтнең бер тармагы ведомстволар, махсус оешмалар, ширкәт тарафыннан оештырылган нәшриятлар, басмаханәләр тарихы, аларның чыгарган басма продукциясенә анализ ясала.

1917—32 елларда татар китапларын бастырып чыгару ягыннан югарыда искә алынган махсус нәшриятларның роле чиксез зур була. Әгәр эш дәүләт монополиясендәге нәшриятларга гына калган булса, без бик зур идеологик зыян кичергән булыр идек. Дәүләт карамагындагы нәшриятлар бу дәвердә татар китабына булган ихтыяҗны үтәүдә көчсезлек күрсәтәләр. Оештыру эшләренең түбән дәрәҗәдә булуы, империалистик сугыш, революция һәм гражданнар сугышы чорында илнең экономикасы чыгырдан чыгу, бер үк вакытта дәүләт бюрократиясе барлыкка килә башлау, нәшрият планнарына да тискәре тәэсирмәләр кертә.

Хәлбуки, татар китабына да ихтыяҗ гаҗәеп зур була. Татар китабы бер халыкка гына хезмәт итмичә тел, графика якынлыгы аркасында казакъ, үзбәк, кыргыз, төрекмән, башкортларга да милли китап булып танылганлыктан, алар арасында революция рухын тарату коралы вазифасын үти. Татар басма китабының туган мәркәзе Казан, үзенең көчле китап басу традицияләре, Ибраһим Юзеев, Мөхәммәт Идриси, Вәли Әхмәдуллин, Н. Харитонов кебек полиграфия һөнәре осталары белән хаклы рәвештә дан тота. Анда берадәран Кәримевләрнең, Хәсәниләрнең һ. б. көчле нәшрият базалары була.

Шунысы кызыклы, кайбер рус буржуаз нәшриятлары революциягә дошманлык белән каршы чыкканда, «Гасыр», «Мәгариф», «Хезмәт», «Сабах» һ. б. татар матбагалары (нәшриятлары) революция ягында чыгыш ясыйлар. Шунлыктан беренчеләре пролетариат дәүләт мәнфәгатьләренә каршы чыкканлыктан ябылалар, ә татар матбагалары яшәүләрен дәвам итәләр. Татар матбагалары, гражданнар сугышы елларында күп миллионлы мөселман халыклары арасында революция идеяләрен тарату өчен илнең төрле якларына йөзләгән пот гарәп хәрефләре, полиграфия осталары җибәреп, революция эшенә зур ярдәм итәләр. Татар мат-

[1] Каримуллин А. Г. Становление и развитие татарской советской книги. 1917—1932. (Очерки о ведомственных, специальных и кооперативных издательствах Татарской АССР).— Казань, 1989.

багаларында шулай ук рус графикасы белән файдаланучы халыклар өчен дә дисталәгән пот хәрефләр әзерләнә.

Ә. Кәримуллинның яңа хезмәтендә әнә шул тарихлар яктыртыла. Китап керештән, дүрт бүлектән һәм йомгактан гыйбарәт.

Беренче бүлек Татарстанда дәүләт матбагасы нигезен оештыру мәсьәләләренә багышлана. Проблема фәндә беренче мәртәбә күтәрелә. Темага кагылышлы аерым хезмәтләр татар милли китабы мәсьәләсенә кагылмый үтәләр иде әле.

Казанда дәүләт типографияләре 1918 елны, каланы ак чехлардан азат иткәннән соң оештырыла. Аның нигезендә 1917 елның 27 октябрендә национализация ясалган «Үзәк типография» торып, ул «Беренче совет типографиясе» дип йөртелә, икенче типография буржуаз «Казанское слово» матбагасы нигезендә оеша. 1918 елда шулай ук өченче, дүртенче дәүләт типографияләре ачыла. Оештыруның икенче өлешендә шул типографияләрне идарә итү мәсьәләләре хәл кылына башлый.

1919 елның 19 маенда берадәран Кәримевләр һәм «Мәгариф» ширкәте матбагалары дәүләт кулына күчеп, алтынчы дәүләт типографиясе булып йөри башлый һ. б. Алтынчы типография, нигездә, татар китаплары басу белән шөгыльләнә.

1920 елның ахырында Татарстан җирендәге барлык типографияләр дә дәүләт карамагына күчерелеп бетә. Дәүләт карамагына басмаханәләрне тартып алу ирекле рәвештә бармый һәм моның гамәлдә ашыктырылып эшләнүе үзен сиздерә.

1922 елның 16 июнендә Казандагы типографияләрнең берләштерелгән идарәсе төзелеп, ул кыскартылып «Казпечать» дип атала башлый, соңыннан ул «Татпечать» тресты дип йөртелә. Ләкин Татарстанда национализацияләнергә өлгермәгән һәм дәүләт предприятиеләренә кушу күздә тотылмаган хосусый басмаханәләр дә була. 1922 елның 2 декабрендә, Хезмәт һәм Оборона Советы карары белән, хосусый матбагалар ачу мөмкин була. Шушы карар нигезендә, Казанда 1923 елда яңа хосусый типографияләр һәм национализациягә эләкмәгән иске басмаханәләр эшкә керешәләр. 1923 елда атаклы матбагачы Н. И. Харитонов та матбага ачарга рөхсәт сорап карый, ләкин аның киң колачлы эшчәнлегеннән өреккән властьлар гаризасына тискәре җавап бирәләр.

Татарстанда матбагаларны идарә итүдә реформалар уздырылып, 1927 елда дәүләт нәшрияты — Татиздат оештырыла. Ләкин туктаусыз сүтү-оештырулар Татарстанда матбагачылык эшенең сыйфаты түбәнәюгә һәм продукциясе кимүгә китерүен күрсәтә монография авторы (94 б.).

Татарстанда вак матбагаларны берләштерү һәм идарәне оештыру 1930 елларда уңышлы тәгалләнә, нәтиҗәдә аларның җитештерүчәнлеге арта.

Монографиянең икенче бүлеге «Татарстанда совет китап нәшрияты эшчәнлеге оештырылу һәм ведомства китаплары» дип атала. Халык комиссарлары Советының 1917 ел, 27 октябрь датасы белән «Матбугат турында декрет»ы чыкканнан соң совет нәшриятлары төзү башлана. Илдә совет һәм партия органнарында нәшрият бүлекләре ачыла.

1929 ел ахырында Татарстанда Дәүләт нәшрияты оештырылгач, ведомство нәшриятлары тарихының икенче баскычы башлана. ВКП(б)ның Татарстан өлкә комитеты һәм Татарстан Үзәк башкарма комитетының 1929 ел ахырында чыгарылган карары Республикада барлык нәшриятларны бер кул астына туплый.

Татарстанда 1917 елдан 1930 елларга кадәр йөзләп ведомство нәшриятлары булып, алар шактый бай китап продукциясе калдырганнар. Ә. Кәримуллин шул төрле нәшриятларның продукциясен өйрәнүгә күп көч куйган, аларның каталогын төзеп мөмкин булган кадәре тулыландырган, күп китапларның тиражларын ачыклаган. Әлбәттә, ведомстволар нәшрияты продукциясе тәкъдир ителерлек. Алар яңа оештырылган совет мәктәпләре өчен йөзләгән әдәби, сәяси, фәнни китаплар, дәреслекләр бастыралар. Татар китабы, бу дәвердә кардәш халыкларга да таралып, интернациональ китап төсен ала.

Болардан тыш хезмәттә Татарстан юстиция, сәламәтлек саклау, эчке эшләр һәм башка халык комиссариатларының нәшрият эшчәнлеге дә тикшерелә. Алар тарафыннан 1921—32 елларда 125 исемдә 389300 китап бастырылган. Татарстан финанс халык комиссариаты 1923—31 елларда 157 исемдә 604725 китап чыгара. Әлеге комиссариатларның нәшрият җитәкчелеге практик эш хаҗәтләре белән бәйле булып, халыкның гомуми эш культурасын күтәрүгә хезмәт иткән.

Уку йортлары буенча карагында Казан университеты, Казан педагогия һәм ветеринария институтлары, Татарстан сәнгать техникумы, Полиграфия мәктәбе, Татрабфак һәм башкалар тарафыннан да байтак китаплар басыла, ләкин аларның күпчелеге рус телендә чыккан, татар телендә культурага, фәнгә кагылышлылары бармак белән генә санарлык. Татар телендә культура һәм фәнни белемнәрне тарту ягыннан «Татар мәдәнияте йорты» басмалары әһәмиятле.

Санап кителгән ведомство, предприятие, уку йортлары тарафыннан 1920—32 елларда барысы 844 исемдә 2169350 китап чыгарылган.

Хезмәтнең өченче бүлеге специальләшкән тармак нәшриятлары эшчәнлегенә багышлана.

Егерменче елларда Татарстан дәүләт нәшрияты татарча китап басу монополиясен үз кулына туплый һәм бу монополияне бөтен СССР буенча законлаштырырга омтыла. Ширкәт нәшрияты оештыру мөмкинлекләре юк дәрәҗәсенә төшә. 20 нче елларның икенче яртысында «Яңа китап» ширкәт нәшрияты оештырылса да, эш җәелдерә алмыйча таралып китә. Ширкәт нәшрияты ачу омтылышлары, дәүләт нәшриятының кискен каршылыгына тап булып, сүнеп калалар.

Ләкин Татарстан дәүләт нәшрияты, бу елларда үзенең бөтен көндәшләренең юлын ябуга ирешсә дә, дәүләт планын үтәү мәсьәләсендә алай өлгерлек күрсәтми. Аның бу җитешсезлеге ул вакытта, ведомстволарның нәшрият эшчәнлеге аркасында, күзгә ташланмаган. Шулай ук бу өлкәдә тармак нәшриятлары да актив эшләп Татарстан дәүләт нәшриятына зур ярдәм күрсәтәләр.

Ә. Кәримуллин билгеләгәнчә, 20 нче еллар башында Татарстан җир эшләре халык комиссариатының нәшрият эшчәнлеге җанланып китә. Аның Казанда специальләшкән, «Игенче» исемен йөрткән нәшрияты 1930 елгача эшләп килә. «Игенче» нәшрияты үз чорында татар телендә авыл хуҗалыгы темасына багышланган йөзләрчә китаплар бастырып чыгара.

Специальләшкән тармак нәшриятларыннан «Гажур» («Газета-журналлар нәшрияты»), «Яңалиф»ләрнең һ. б. эшчәнлеге дә канәгатьләнерлек дәрәҗәдә яктыртылган.

Автор, «Яңалиф» нәшрияты тарихын тасвирлауга керешкәнче, яңалиф (латин) алфавитына күчү тарихына да беркадәр тукталып уза.

Татар графикасын латин алфавитына күчерү югарыдан басым һәм буш вәгъдәләр бирү юлы белән үткәрелде. 1937 ел җиткәч, аны үткәрүгә протест ясаган галим, язучы һәм журналистларны гаепләп каты җәзаларга тарталар. Шул исәптән латинчылык хәрәкәтен экстремистик юл белән тараткан Ф. Сәйфи-Казанлы, Сәлах Атнагуловларга да ташлама ясалмаган. Латинчылыкны пропагандалау өчен 1926 елны «Яңалиф» нәшрияты оештырыла. Ул, 1932 елгача яшәп килеп, 198 исемдә бер миллионнан артык китап бастыра. Латин графикасы вульгар-социологизм чәчәк аткан чорларда, ашыгычлык белән уздырылды. 1930 елларда Сталин башлаган тоталь репрессияләр белән берәттән уздырылуы, әдәби, культура мирасыбызның мең еллык хәзинәләрен физик юк итү юлы белән аралашып баруы — татар халкын әдәби мирасыннан аера башлауның кискен этабы булды.

Латин графикасына күчү тарихы автор тарафыннан берьяклы гына күрсәтелә һәм «Яңалиф» нәшрияты эшчәнлеге уңай яктан гына бәяләнә.

Хезмәтнең дүртенче бүлеге хосусый кооператив нәшриятлары эшчәнлеген өйрәнүгә багышлана. Совет властеның беренче елларында җәмгыятебездә ике төрле нәшрият системасы яшәде. Аларның берсе элекке буржуаз җәмгыятьтән калган, ә икенчеләре совет власте ихтыяҗлары белән оеша. Бу төркемнәр арасында ул елларда көрәш бара. Совет хөкүмәте буржуаз нәшриятларның контрреволюцион пропаганда белән шөгыльләнгәннәрен ябарга мәҗбүр булды. Ләкин бу чарага беренче чиратта рус буржуазиясе карамагындагылары дучар булды. Әйткәнебезчә, революциягә кадәр үк демократик юнәлештә хезмәт күрсәтеп килгән «Гасыр», «Мәгариф», «Хезмәт», «Сабах» кебек татар нәшриятлары ябылмадылар. Октябрь революциясе булгач, әле «Алга», «Корылтай» кебек яңа кооператив нәшриятлары ачыла. Татар нәшриятлары, эре байлар кулында булмыйча, берничә кешеләрнең берләшүе аркасында эш йөртәләр. Аларның кайберләре полиграфик базага да ия була. («Кәримия», «Милләт»), калганнары фәкать нәшрият эше белән генә шөгыльләнәләр. Хосусый нәшриятларның эшчәнлеге, нигездә, 1917—21 елларда бара, аннан соң туктала.

1926 елда «Яңа китап» кооперативы оеша. монографиядә аның кыска вакытлы эшчәнлеге дә карала. Хезмәттә татар кооператив нәшриятларының киң кырлы эшчәнлеге, продукциясе, аларның совет органнары белән тыгыз бәйләнештә эшчәнлеге күрсәтелгән. Шундый бер кызык мисалны күрсәтеп үтү кирәктер. Әхмәтгәрәй Хәсәни һәм Г. Рәхмәтуллиннар карамагындагы «Аң» типографиясе Совет хөкүмәтенә 1919 елда хуҗаларның үз теләкләре белән тапшырыла.

Октябрьгә кадәр үк оешкан хосусый нәшриятларның эшчәнлеген яктырткан авторның барлык мөмкинлекләрдән дә файдаланмаган булуын күрсәтергә кирәк. Әйтик, шушы нәшрият ширкәтләрен нигезләүче төп шәхесләрнең туган еллары, урыннары архив материалларында чагылыш тапкан, дип уйларга кирәк. Кайсыларының язмышлары да билгеледер. Менә шулар турында мәгълүмат бирелсә, нур өстенә нур булыр иде. Әйтик, «Сабах» ширкәтен оештырган Габделвәли һәм Мөхәммәтгали Әхмәдуллиннар яки «Берадәран Кәримевләр» ширкәтенең төп фигураларының язмышлары тарихыбызда тәфсилләп сурәтләнергә лаеклы.

Эшчәнлеге өйрәнелгән нәшриятлар 1917—32 елларда 2395 исемдә китап чыгарганнар. Бу китапларның гомуми тиражы чама белән 10 миллион данә хисаплана. Автор тарафыннан бу өлкәдә четерекле һәм катлаулы исәп-хисап эшләре башкарылып, аларның нәтиҗәләре беренче мәртәбә чагыштырма таблицаларда күрсәтелгән.

**Марсель ӘХМӘТҖАНОВ,**
филология фәннәре кандидаты.

**Тәфкил Камал,**
философия фәннәре кандидаты

# ТАТАР РУХЫ

Татарның рухын фәлсәфи тикшерү мәсьәләсе, бер яктан, хәзерге милли уянуның күтәрелеше шартларында, әһәмиятле һәм зарур бер нәрсә рәвешендә бәяләнергә тиеш булса, икенче яктан, мондый эшне башкарып чыгу, ай-һай, бик читен булып чыкмагае. Биредә сүз мәсьәләнең теоретик катлаулылыгы һәм фәнни яктан бөтенләй эшләнмәгәнлеге хакында гына бармый. Халкыбызның, милләтебезнең рухы кебек изге һәм мөкатдәс бер нәрсәне ниндидер коры «лаборатор» анализга мәҗбүр итүнең әхлакый якларын да күз уңыннан җибәрмәскә кирәк. Ә бу зур җаваплылык таләп итә, хакыйкатьтән тайпылмаска куша. Хакыйкатькә һәрвакыт дөрес бару юлында булганда гына, ошбу адымны азмы-күпме дәрәҗәдә аклап булыр кебек. Чөнки хакыйкатькә барып җиттем, дип уйлаган кеше, хакыйкать дип аңлаган нәрсәсен үзенә буйсындырып, аны шәхси мәнфәгатьләре максатында файдалануы һәм шуның белән хакыйкатьнең асылын җуюга илтүе дә бик мөмкин ич.

Хакыйкатьнең төбенә беркайчан да төшеп җитә алмаган кебек, кеше рухи мотлакка (абсолют рух) тулаем ирешүгә дә сәләтсез. Чөнки кешенең «җирле» нигезе бар: ул, теге яки бу дәрәҗәдә табигый-антропологик зат булуы өстенә, җәмгыятьтә дә матди мәнфәгатьләрдән бөтенләе белән аерыла алмый. Иҗтимагый чынбарлык шуны күрсәтә: кешенең гакылы матди мәҗбүриятлекне тоеп яши һәм үсә. Ләкин аң-белем үсешенең үзенчәлеге шундый ки, ул мәҗүси потка һәм түбән дәрәҗәле дини хорафатларга табынудан арына барып, мотлакка, югары рухка таба баруны китереп чыгара. Рухи мотлакка омтылыш гомумкешелек цивилизациясе рухи эшчәнлегенең барлык күренешләрен — фәлсәфә һәм сәнгать, дин һәм әхлак, фән һәм хокук кануннарын бергә бәйләп тотучы көч тә ул. Рух безнең өчен менеп җитә алмаслык биек кыя кебек күренсә дә, бу аның яшәешен инкяр итә алмый. Моннан чыгып, диндар берсүзсез аллага ышанган кебек, рухка ышанырга кирәклеге бурыч итеп куелмый, әлбәттә. З. әл-Кадыйриның рухи барлыкны исбат итү «хисси нәрсәләр илә булмастан, гакыл вә фикер илә улачактыр»[1], дигән сүзләре белән килешми мөмкин түгел. Рухка акыл һәм кешенең гамәле ярдәмендә генә якынаерга мөмкин.

Безне дә, безне чолгап алган мохитне дә чиксезлеккә омтылыш яшәтә. Матди яшәешебезнең чикләнгәнлеген җиңәр өчен җәмгыять акыл көчен эшкә җигә, ә аның тулы канлы үсеше рухи мотлакка этәрә. Димәк, рух — кешенең чиксезлеккә бару юлында акыл белән ирешкән байлыгы ул. Шуңа күрә һәр халыкның югалмаска, бетмәскә, яшәргә теләве, үзенең үткәнен, бүгенгесен барлап, киләчәккә өметле караш тотып көн күрүе дә табигый һәм тарихи бер нәрсә булып, аның рухы хакында тулаем сөйләргә мөмкинлек бирә.

Сер түгел, җәмгыятебезгә рухсызлыкның киң таралуы соңгы елларда үзен аеруча нык сиздерде. Һәм ул, иҗтимагый тормышта алып барылган нивелировка, тигезләү сәясәтенең нәтиҗәсе буларак, интеллектуаль өлкәдә бер урында таптану, массакүләм мәдәниятнең артуы һәм иҗади фикерне тыюда ачык чагылды. Бу процессның милли җирлеге дә киң иде. Аерым алганда, татар рухының тормыштан читләштерелүе милли мохит үзенчәлекләре һәм, гомумән, милли рух — рухы мотлакның яшәү рәвеше булуы, ә соңгысының җәмгыятьтән куылуы белән аңлатыла.

Халкыбызның рухы аның Болгар дәүләте һәм Казан ханлыгы чорында халык булып оешуы, соңрак милли формалашу һәм үсеш чорында тудырылган мәдәниятка таяна. Әмма аның матди нигезен даими тәэмин итәрлек куәтләрнең азаюы һәм бүлгәләнүе аркасында, татарлыкның рухи көч буларак тормышка йогынтысы бетүгә дучар ителде. Үз чиратында, җәмгыятьтә рухсызлыкның көчәюе аның әхлакый сәламәтлегенә дә, мәдәни дәрәҗәсенә дә, матди бөтенлегенә дә кире йогынты ясамый кала алмый иде. Шөбһәсез, болар милли яшәешнең бик нык тарлыгы туфрагында үсеп җитешкән җимешләр булдылар.

Татар халкының милли-этник оешу шартларының үзенчәлеге аның рухында да чагылыш таба. Шундый үзенчәлекләрнең берсе итеп Идел буе Болгар дәүләте тарафын-

[1] Әл-Кадыйри З. Куәт һәм рух. Уфа, 1910, 27 б.

нан 1101 ел элек кабулланган исламның тәэсирен билгеләп үтәргә кирәк. Казан ханлыгы җимерелгәч, дөньяви мәдәниятнең юкка чыгуы һәм бары XX йөз башында гына кабат күтәрелүе аркасында, ислам гасырлар дәвамында милләтнең рухын тәшкил иткән иң көчле куәтләрнең берсе хезмәтен үтәп килде. Географик яктан татар халкының мөселман дөньясының иң төньягында, башка Шәрекъ үзәкләреннән шактый аерылган һәм дини дошманлык шартларында яшәве нәтиҗәсендә, бердәнбер рухи яшәү чыганагы булып гәүдәләнгән исламның тәэсире тагын да арта бара. Ни генә булмасын, аның аркылы милли рухның гомумкешелек төсмерләренә баюы һәм үзенең кешелек цивилизациясенең рухи тормышы белән бәйләнүе бәхәссез. Болар һәммәсе татарлыкның әхлакый эчтәлеген үстерүгә хезмәт итә иде. Һәм, чыннан да, татар рухының иң төп сыйфатларыннан берсе — милләтнең яшәеше һәм аның үсеше хакында әхлакый эзләнүчәнлек.

Халыкның матди һәм сәяси яктан иң авыр хәлдә яшәгән чакларында да, аның үз яшәешен тәэмин итүгә башка кавем һәм халыклар көченә яки алар иреген кысрыклау бәрабәренә ирешү теләгенең юклыгы шуннан килеп чыга. Татар әдәбиятының меңъеллык тарихы — моның ачык дәлиле. Аның бер генә җәүһәрен — Г. Исхакыйның «Ике йөз елдан соң инкыйраз»ын (1902) мисал итеп алыйк. XIX һәм XX гасырлар чигендә татарлыкны үз иҗатының рухи кыйбласы итеп алган язучы һәм җәмәгать эшлеклесе, милли үсешүзгәреш мәсьәләләрен күздән кичереп, эшләр болай барганда, якын киләчәктә халыкның милли һәлакәткә дучар булуы мөмкинлеген әдәби алымнар белән ачып бирә. Ләкин, мәсьәләнең әсәрдә шундый кискен куелышына карамастан, анда берәр төрле милли аерымлану яисә тагын да хәвефлерәк булган милли үч тойгыларын очрата алабызмы? Юк! Киресенчә, татар әдәбияты, җөмләдән, Г. Исхакый да, гомер-гомергә гомумкешелек кыйммәтләрен яклады, шуның белән халкыбызның милли үсешендә бер рухи маяк булды. Милли һәлакәттән котылу юлы, Г. Исхакый фикеренчә, бер генә: ул мәдәниятне, аң-белемне үстерү һәм гомумкешелек цивилизациясе казанышларын үзләштерү аркылы халыклар арасындагы мөнәсәбәтләрнең сәяси h. б. яктан камиллегенә ирешүдә ята.

Милли рух, җәмгыятьнең барлык өлкәләрен бергә тыгыз бәйләүче буларак, мәдәният һәм әдәбиятта гына түгел, һичшиксез, сәясәт h. б. якларда да чагыла. Әйтик, халкыбызның географик һәм мәдәни үзенчәлеге аның бинһая сәяси көрәшләрдә һәм чыгышларда катнашуын китереп чыгара. Болар — илбасарларның һөҗүмнәреннән саклану һәм өстен катлаулар алып барган ызгыш-талашлардан туган күрше мәмләкәтләр белән сугышлар да, милли-азатлык хәрәкәтләре һәм инкыйлаблар да. Болгар калаларын җимереп монгол яулары узган, күрше халыклар һәм аеруча Русия белән мөнәсәбәтләр дә һәрвакыт дустанә генә булмаган. Әмма дөреслек шундый ки, танылган урыс тарихчысы М. Худяков h. б. дәлилләвенчә, «Русия өстеннән хакимиятләре хәттин ашкан чорларда да татарлар нибарысы ясак түләтү белән чикләнәләр; урыс дәүләтенең сәяси мөстәкыйльлегенә дә, ...диннәренә дә, телләренә дә беркайчан да кул сузмыйлар».[2] Башка күрше Идел һәм Урал буе халыкларының (башкорт, чуваш, мари, мордва, удмурт) Болгар дәүләте һәм Казан ханлыгы чорында мөстәкыйль үзидарәләрен саклавын һәм соңыннан да бәрәкәтле мәдәни алмашу кичереп яшәвен әйтеп тә торасы юк.

Татарлыкны билгеләүдә зур роль уйнаган исламның кешелеклек принциплары татар халкының башка кавемнәр белән бергәләшеп яшәве, һәм, гомумән, тормыш тәҗрибәсе белән ныгытыла килгән. Шулай да, ислам диненең тулаем тәэсиренә килгәндә, аны беръяклы уңай итеп кенә аңларга ашыкмыйк әле. Руханиларның консерватив катлавы халыкны рухи буйсынып яшәргә һәм кеше-ара мөнәсәбәтләрне иске кысалардан чыгармаска тырышкан — моны да искә алмый ярамас. Рухның милли-этник ягына моның кире йогынтысы да көчле була. Озак вакытлар дәвамында милли-этник оешу кайбер даирәләрдә бары дини берлекне саклау яссылыгында гына каралуы аркасында, халык арасында милли-этник берлек төшенчәсе рәвешендә мөселман сүзе дә кулланышта йөргән. Консерватив катлаулар исә, әле XX йөз башына кадәр, исламны татарлыкның рухи куәте үсешенә киртә буларак файдаланып киләләр. Гасырлар буена татар алдынгы иҗтимагый фикеренең мөселманлыкны рухани нәрсә итеп аңлауга омтылышы татар рухы тантана итүенең тарихи үзенчәлекләреннән берсе була.

Халкыбыз рухын билгеләүче тагын бер, бәлки иң төп, фактор — аның сәяси дошманлык шартларында үткәргән авыр хәле. Гәрчә татар халкы Болгар дәүләте, өлешчә Алтын Урда һәм Казан ханлыгы чорында сәяси мөстәкыйльлек шартларында Көнчыгыш Европадагы югары мәдәниятка ия халык рәвешендә формалашкан булса да, милләт булып оешу бары тик Русия составына кертелеп яши башлагач кына кузгала. Мондый сәяси үзенчәлекнең рухи процесска да йогынтысы зур була. Бездә дәүләтчелекнең, аерым алганда, Казан ханлыгының күтәрелеше һәм һәлакәте тарихын өйрәнәсе дә өйрәнәсе әле.

Билгеле булганча, Русия хөкемдарларын Казанны яулап алуга рухландыруда И. Пересветов кебек идеологлар һәм христиан чиркәве әһелләреннән Максим Грек, архиепископ Федосий, митрополитлардан Даниил һәм Макарий h. б. әһәмиятле роль уйныйлар. Алар, Византиядән православиены кабул итеп алганнан соң, Русиягә бөтен дөньяда хак динне яклаучы буларак, ниндидер аерым миссия йөкләнгән, дип аңлаталар һәм «Мәскәү — өченче Рим» дигән теория уйлап чыгаралар. Бу теория буенча, урыс дәүләтенең яулап алу сугышлары үз халкы алдында акланырга, хак эш дип танылырга тиеш

---

[2] Худяков М. Казан ханлыгы тарихы. — «Идел». 1990 ел, 6 сан, бит 45.

була. Русия сәясәтенең бу очрагын хәтта урыс тарихына һәм рухи тормышына кызыксынулы караш белдергән хәзерге заман авторлары да анык билгеләп, аның «Аурупа» дәүләте өчен Аурупадан тыш җирләрне үзләштерү генә булмавын, ә бәлки, бербөтен Аурупа-Азия тирәлегеп урыс халкы өчен түгел, православие дине өчен төзү»[3] да икәнен бәян итәләр. Бөек фикер иясе Н. Бердяев бу хәлне аңлатып: «Урыс халкы, урыс дәүләтенең күләме таләп иткәнчә, биниһая көчен сарыф итеп, үзе басылган була»,[4] — дип яза. Шулай итеп, татар халкының дәүләтчелеге җимерелү Русиянең рухи тормышында тоталитаризмның ныгып урнашуы чорына туры килә. Бу 1552 елның мәгълүм вакыйгаларының сәяси һәм икътисади максатлардан чыгып эшләнгән акт кына булмыйча, үзенә кабалага эләккән халыкның рухына каршы, аны юк итүгә юнәлгән булуы хакында сөйли. Моның шулай икәне Казанны яулап алынганнан соң явыз Иван һәм башка урыс патша һәм хөкүмәтләренең татарларга каршы сәясәте белән гамәлдә раслана. Хәзер, икенче меңъеллык үзенең ахырына таба барган бер вакытта, әйтергә мөмкин: халкыбызның кичергән милли фаҗигасе — соңгы меңъеллыкта тоталитаризм тарафыннан кешелек рухына каршы ясалган иң зур җинаятьләрнең берсе итеп каралырга тиеш.

Тоталитаризмның табигате берьяклы гына була алмый, ул күп йөзле, аның бер ягын империячеллек тәшкил итсә, икенче ягында коллык, рухи бөлгенлек үсеп чыга. Татар кебек басып алынган халыкның гаять зур сәяси, икътисади, мәдәни кысынкылык шартларында милләт булып оешуы, билгеле, үзеннән-үзе аның күңеленә коллык психологиясенең дә, көнлек җан асраучылыкның да үтеп керүен китереп чыгара. Кызганыч ки, моның мисаллары тарихыбызда һәм хәзерге тормышыбызда бихисап. Ләкин халык рухи сафланусыз, чистарынусыз үз-үзен саклап кала алмаган булыр иде. Изелгән-тапталган милләтнең рухи яшәеше җәберсетүгә, чикләүгә һәм аның барлыгына кул сузуга каршы көрәштән башка мөмкин түгел. Хәлбуки, татарлыкның иң асыл сыйфатларыннан берсе — азатлык һәм гаделлек эстәүчелек. Бу татарның тәненә һәм канына сеңгән. Халкыбызның үз азатлыгын яклап, илбасарга каршы күп тапкырлар көрәшкә күтәрелүе, төрле чикләүләрне алып ташлый баруы тарихыбызда кызыл җеп булып сузыла. Мәсәлән, милли матбугатыбызны булдыру өчен кирәкле бөтен шартлар өлгереп җиткәч тә, аның өчен зыялыларыбызның патша хөкүмәте белән 100 ел дәвамында көрәш алып баруын һәм бары 1905 ел инкыйлабы нәтиҗәсендә генә беренче татар көндәлек басмалары нәшер итәргә ирек алынуын искәртү дә җитә. Нәтиҗәдә, татар рухының азатлык эстәүчелеге милләт язмышы һәм ул яшәгән шартларга бәйле рәвештә, аның милли-этник үзенчәлегенә әверелә.

Татарлыкны урыска каршы торучылык кына дип аңларга кирәкми, чөнки аның алда каралган аерымлыгының нигезендә тарихи һәм мәдәни сәбәпләр ята. Төптәнрәк карaганда, бу — бер-берсе белән уртаклыгы булмаган, тагын да төгәлрәк әйтсәк, берберсенә капма-каршы юнәлештә булган ике төрле рухи типның: мәдәниятка нигезләнгән азатлык эстәүчелекнең вәхшилеккә корылган тоталитаризмга каршы көрәше. Шуңа күрә дә урыс дәүләте тарихның тоталитаризмнан чигенеш ясаган һәм шартлы рәвештә «Петербург чоры» дип аталган өлешендә татарлар рухи яктан азмы-күпме ирек алуга ирешәләр. Ләкин империядә тулы азатлыкка чыгу турында уйларга да мөмкин булмый.

Бу җәһәттән, халкыбыз йөрткән «татар» атамасының рухи ягына кагылып китү дә урынлы булыр.

Биредә шунысы игътибарга лаек, башка «татар» дип аталган халыклар бу атаманы кабул итмичә, үз исемнәрен кире торгызалар. Фәкать Казан төркиләре генә татар исемен ахырда күтәреп чыгалар. Әлбәттә, милләтнең өстен катлавының үз көч-куәтеннән һәм бөтен Русия төрки халыкларының милли изелүләреннән файдаланып, аларны берләштерүдә өстенлекне дәгъвалавы һәм шул максатта Чыңгыз хан заманнарына мөрәҗәгать итүе дә, башка тарихи сәбәпләр дә үз нәтиҗәсен күрсәткәндер. Әмма, шулар белән бергә, югары мәдәнилек үрнәге булган бер халыкның һәм аның зыялыларының күрәләтә бу исемне яклауга күчүен һәм «татар» атамасының тантана итүе XX гасыр башына, милли-демократик мәдәниятнең яңарышы заманына туры килүен ничек аңлатырга? Чынлыкта исә бу халкыбыз рухының үзенчәлеге белән билгеләнә иде. «Татар» атамасын кабул итүдә нәкъ менә, бер яктан, халкыбыз тарафыннан азатлыкның бөтенлеген, тулылыгын яклавы, ә икенче яктан, аның бәрабәренә гаять зур, күтәреп булмаслык тоелган югалтуларга да әзер булуы чагыла. Бу — халкыбыз рухын йөртүчеләрнең шәхсән зур корбаннарга барып, милли тигезсезлеккә генә түгел, бөтен изү һәм җәбергә каршы күтәрелүгә сәләтле булуын ачып сала торган күренеш иде. Үз вакытында «татар» атамасын алуның рухи ягына Ш. Мәрҗани дә игътибар итә. Ул урыс халкының кимсетү һәм хурлау рәвешендә татар дип әйтүләреннән куркып, үзләрен мөселман санаганнарга мөрәҗәгать итеп: «И мескен! Әгәр синең «мөселман»нан башка бер исемеңне дин һәм милләтең дошманы белмәсә иде, сине, әлбәттә, мөселман дип дошман күрерләр иде»[5],— дип яза.

Татарлыкны кабул итү милләтебезнең нинди дә булса аерым миссиясенә ишарә иткән нәрсә дә түгел. Әгәр халкыбызның теге яки бу аерымлыгы хакында сүз бара икән, ул — бары тик аның башына төшкән михнәт һәм бәлаләрнең артык күплегендә генә. Бу шартларда татар атамасын үз өстенә алу милли-этник кысрыклауга юнәлгән булмыйча, халыкның иң авыр шартларда да милли чикләнгәнлектән чыга алуын күрсәтә. Шулай итеп, татарлыкның кайвакыт көнкүрештә очрый торган милли үч тойгысы белән уртаклыгы юк, чөнки Русия шартларында татар атамасы астында моңа омтылу

---

[3] Аверинцев С. С. Византия и Русь: два типа духовности.— «Новый мир». 1988, № 7. Бит 219.

[4] Бердяев Н. Русская идея.— «Вопросы философии», 1990, № 1. Бит 79.

миллəтнең болай да авыр хəлен тагын да авырайтачак кына иде. Тарихи мантыйк ягыннан да, рухи яктан караганда да татарлык игълан итү — асылда бөтен золымнарга каршы дошманлык эше кузгату һəм шуннан башка бер нəрсə дə түгел иде. Күренə ки, татар рухы — кешелекнең бертуктаусыз гаделлек эстəүче рухы ул.

Үзенең тарихи Ватаны — Идел һəм Урал буе төбəгендə миллəт булып оешкан татар халкының рухи формалашуына йогынты ясаган тəэсирлəрнең əһəмиятлелəреннəн тагын берсе — аерымланганлык, бүленгəнлек. Халкыбызда Ватан рухының шактый аморфлашуы шуның белəн билгелəнə. Бу хəл, əлбəттə, бик борынгы заманнарга барып тоташа. Əйтик, тарихыбызда югары үсешкə ирешкəн борынгы гомумтөрки мəдəниятнең традициялəре элек-электəн үк көчле булуы, Идел буе Болгар иле кебек мөстəкыйль дəүлəтнең Алтын Урда составына кушылып, төрки халыкларының уртак дəүлəтенең бер өлеше булып яшəве үз эзен калдырган. Күп төрки халыкларның соңыннан Русия составына керүе һəм милли изүгə дучар булулары аркасында килеп туган төрки туганлык һəм telәктәшлекне дә искә алырга кирәк. Җәмгыятьтә һәр нәрсә дә бер үлчәүле генә була алмый, төрки туганлык хисенең кайвакыт өстен катлаулар тарафыннан гомуми төрки-татар дәүләте идеясен яклауда файдалануы да билгеле. Ничек кенә булмасын, төрки туганлыкны татар Ватаны идеясенә каршы кую — зарардан башка нәрсә түгел иде.

Мәсьәләнең мәдәни ягы шулай ук татар җәмгыятенең рухи тормышында элек-электән үк Шәрыкъ традицияләренең көчле булуы белән бергә, аның көн күргән, үз язмышын тапкан җире Европада булуы һәм шуңа күрә Гареп идеяләренең дә киң таралуы белән катлаулана. Мондый үзенчәлек татарлар арасында төрле идеяләрнең һәм традицияләрнең ярашып яшәвен, заманча әйтсәк, фикри һәм сәяси плюрализм хасил итә. Бу күренешнең, уңай яклар белән бергә, фикри таркаулык һәм шуның белән рухи берлекне какшатуга да җирлек тудыруын әйтеп узарга кирәк.

Ләкин Ватан рухының эрозиясенә китергән төп сәбәп төрки туганлыкны яклауда да, фикри һәм мәдәни плюрализмда да булмыйча, татар халкында сепаратчылыкның көчле куәт алуында булса кирәк. Шөбһәсез, моңа объектив шартлар, шул исәптән, сәяси факторлар сизелерлек йогынты ясый. Халыкның үз дәүләтчелеген югалтуы, милләт булып оешкан этник төркемнәрнең үз үзенчәлекләрен консервацияләве, нык саклавы һәм шулай ук аларның төрле административ һәм икътисади бербмлекләргә каравы аркасында уртак милли Ватан идеясе дә йомшара. Үз чиратында соңгысы милли рухның кечерәюенә һәм тараюына китерә. Шундый сепаратчылыкның соңгы гасырда үсеп чыккан һәм идеологик яктан рәсмиләшкән күренеше — «башкортчылык».[6] Халыкның рухына административ-сәяси чикләүләр дә, Ык һәм Сөн елгалары «аерып» торган кебек, ул яшәгән табигый шартларның аерымлыгы киртә була алмаса да, гамәлдә моның тискәре яклары кешеара мөнәсәбәтләрнең рухында чагылмый кала алмый.

Татар халкының, матди кысынкылыкта яшәве аркасында, бәхет эзләп (кайчакта башка халыкларны мәдәни агарту мотивы белән) бөтен дөнья буйлап сибелүе һәм этник ассимиляция әкренләп Ватан рухының җуела баруына этәргеч бирә. Шуны күздә тотыптыр инде, Дәрдемәнд тә:

*Ни газизрәк — бу ватанмы?*
*Аһ, туган каумем газиз!—*

ди, шуның белән рухи берлекне саклап калырга чакыра.

Бу нәрсә татарда ватанпәрвәрлекнең кимүен аңлатмый, билгеле. Сүз бары Ватан рухының милли төсмере югалуы, шуның белән аның рухи берлеге какшавы турында бара. Өстәвенә, әле тоталитаризм һәм сталинизм шартларында милләтнең бер төбәктә яшәгән өлеше арасында да бу аерымлану көчәйгәннән-көчәя бара. Русия колониализмы һәм сталинизмның бөтен тарихы буена татарлык, рухи асылын югалтмаса да, күбрәк эчкә йотыла, һәрбер кешенең башкалардан аерым, үз эченә бикләнеп, яшерен рәвештә кичергән уй-тойгыларына әйләнә. Милләтнең сәяси оешу ягыннан йомшаклыгы һәм аның аерымлануы шартларында һәрбер шәхес коллык чолганышыннан аерым чыгарга дучар ителгәнгә, коллык психологиясеннән арыну аеруча авыр бер эшкә әйләнде.

Ватан рухының, шуның белән бергә татарларның Идел-Урал тарихи Ватаны идеясенең тантана итүе соң чиктә гамәлгә ашмас хыял да түгел. Чөнки татарлык — «юк шул безләрдә берләшмәк»,— дип ачынган Тукай рухы да ул. Әйтергә кирәк, бу җәмгыятебездә кешелеклелеккә таянган мөнәсәбәтләр урнашу, сәяси азатлык һәм Европа диган цивилизацияле гомумйорт төзүдәге уңышларыбыз белән тыгыз бәйләнгән.

...Татарлык — чиксез рухи дөнья ул. Шуңа күрә бер талпынуда гына аны бөтенләе белән танып-белүне күз алдына да китереп булмый. Без эш-гамәлләребездә, теләк-ихтыяҗларыбызда аңа тартылсак, үз асылыбызга кайтканда аның шифалы җилен тойсак, менә шунда ул яшәеш мәгънәсе, чикләнгәнлекне җиңү, безнең мәңгелеккә илтәсе юлыбыз...

---

[5] Мәрҗани Ш. Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар. Казан, 1989. Бит 44.

[6] Бу хакта тулырак мәгълүматны карагыз: Камалов Т. «Башкортчылык» кемгә файдалы?— «Аваз». 1990 ел. 5 сан.

*Күренекле галим, мәгърифәтче*
*Исмәгыйль Гаспринскийның тууына 140 ел*

# ТӨРКИ ХАЛЫКЛАРНЫҢ УРТАК КАҺАРМАНЫ

Соңгы ярты гасырда аның исеме телгә алынмады диярлек, космополитизм чорында, бигрәк тә Кырым татарларын лагъпәти милләт дип үз туган җирләреннән куып, төрле якларга таркатканнан соң, милләтнең танылган шәхесе, аның горурлыгы булган кеше турында язу мөмкин түгел иде.

Элегрәк, бигрәк тә XX йөз башында, Исмәгыйль Гаспринскийның исеме дә, ул нәшер иткән «Тәрҗеман» газетасы да безнең татар вакытлы матбугатында көн саен диярлек телгә алына иде. Мәсәлән, Г. Тукай соңгы елларда язган әсәрләрендә, публицистик мәкаләләрендә, башка төр язмаларында И. Гаспринскийны 22 мәртәбә, ул чыгара торган «Тәрҗеман» газетасын 40 мәртәбә телгә ала, махсус мәкаләләр, репликалар яза, чыгышлар ясый. Без монда Тукайның Гаспринскийга һәм аның иҗади, сәяси эшчәнлегенә мөнәсәбәте, бәяләве турында сүз кузгатмыйбыз, бу аерым, әлегә галимнәребез кузгатмаган тема.

Исмәгыйль Гаспринский ифрат күпкырлы талант иясе, үтә дә эшчән, идеяләрен, фәлсәфи карашларын гамәлгә ашыру өчен җиң сызганып эшләгән, ару-талуны белми көрәшкән тиктормас шәхес иде. Аның төрле өлкәләрдәге эшчәнлеге турында бик күп язарга мөмкин булыр иде. Шулардан кайберләренә генә тукталасым килә. Беренчедән, ул бөек мәгърифәтче. Үзе исән чакта ук, төрки, шәркый милләт халыклары аны «төрки милләтләрнең аксакалы» дип атаганнар. Л. Толстой, М. Горький аның мәгърифәтчелек эшенә югары бәя биргәннәр, таҗик классигы Садретдин Гайни, үзбәк классигы Хәмзә Хәкимзадә, әзербайҗан революционеры һәм язучысы Нәриман Нәриманов И. Гаспринскийны «минем укытучым, остазым» дип атаганнар...

Аның төрки милләтләр арасында мәгариф өлкәсендә ясаган ислахы (реформасы) аерым зур урын тота: ул иске ысулдагы (кадими) мәктәп урынына яңа ысулдагы (җәдиди) мәктәпләр ачучыларның беренчеләреннән булды. Бакчасарайда оештырылган ысулы җәдид мәктәбе бераздан башка илләрдә, төрле җирләрдә таралып, меңнән ашып китте. И. Гаспринский мондый мәктәпләр өчен уку-укыту программаларын төзеде, дәреслекләр язды һәм үз хисабына аларны нәшер итте. Әгәр иске мәктәпләрдә шәкертләр, Тукай әйтмешли, 3-4 ел укып чыкканнан соң, «күп яттык без мәдрәсәдә, аңламадык бер нәрсә дә», дип зарлансалар, Гаспринский программасы һәм сабак китаплары белән укыган галибәләр (укучылар) алты-җиде ай эчендә укырга-язарга өйрәнү генә түгел, байтак дөньяви фәннәрдән дә (тарих, җәгърафия, табигать, җәдвәл-арифметика һ. б) ярыйсы гына мәгълүмәт алалар иде.

Бакчасарайда аның көче белән 1883 елдан чыгарыла башлаган «Тәрҗеман» газетасы бөтен дөньядагы төрки халыклар арасында (Төркия, Америка, Кытай, Франция, Болгария, Мисыр, Россиянең Идел буе, Кавказ) күп таралган һәм аларның мәгърифәтен, мәдәниятен, әдәбиятын җанландыруда зур роль уйнаган.

И. Гаспринский тар кысадагы бер милләтче түгел. Ул, Тукай шикелле үк, руслар, башка халыклар белән дус, тату яшәргә чакырып газетасында мәкаләләр бастыра. Ул чактагы күренекле профессор Виттер Гаспринскийга шәхсән рәхмәтен белдереп болай язган: «Сезнең нинди тәбәкадан (сословиедән — Р. С.) һәм башка диннән булуыгызга карамастан, руслар белән татарлар үзара тату, тыныч, имин яшәргә чакырып язуларыгыз өчен академиклар исеменнән тәшәккер белдерәм».

Исмәгыйль Гаспринский гаҗәеп мәгърифәтче генә түгел, төрки халыклар арасында танылган сәясәтче, нәшрият, матбугат, театр эшләрен гамәлдә оештыручы, әдәби тәнкыйть, публицистика һәм башка иҗади өлкәләрдә башта Кырым татарлары арасында, соңыннан бөтен төрки халыклар арасында да эш башлап, оештырып йөрүчеләрдән булды. Беренче Россия революциясе чагында ук ул Кырым татарларының корылтаен оештыра, бу корылтайга бүтән төрки халыклар яшәгән өлкәләрдән дә чакырылган 700 дән артык вәкил катнаша. Ул беренче булып, Бакчасарайда матбугат өлкәсендә эшләүчеләрнең профсоюзын барлыкка китерә. Төрки халыкларның «Иттифак» дип аталган партиясен оештыру максатында бу халыкларның беренче съездын чакыруда зур эш башкара.

Беренче революция бастырылганнан соң, кара реакция дулкыны башлана, ул бик күпләрнең карашларында һәм эшчәнлекләрендә сизелерлек үзгәрешләр тудыра. Төшенкелек, гаҗизлек, битарафлык, үкенү, элекке карашлардан ваз кичү шикелле күренешләр пәйда була. Гаспринскийның да кайбер карашларында моңарчы күренмәгән ниндидер утопик, хыялый хисләр сизелә башлый. Ул үзенең тагълиматын һәм эшчәнлеген Кырым татар һәм Россиядәге башка төрки халыкларның даирәсе белән генә чикләми, башка мөселман илләрендә, ягъни, халыкара мәйданда җәя башлый, утопик сәясәткә нигезләнгән берничә әсәр бастырып чыгара. Аның исеме, даны күп илләргә тарала. 1910 елда ул үз инициативасы белән «Бөтен җиһан мөселманнары конгрессын» (корылтаен) чакыру нияте белән актив чаралар күрә башлый. Шушы максаттан ул Мисырга (Каһирәгә) китә һәм анда үз идеалларын җәелдерү, пропагандалау нияте белән «Эл-Нахда» («Яңадан туу» — Р. С.) дип аталган газета чыгара башлый. Гарәп илләренең күп кенә шәһәрләрендә төрки-мөселман вәкилләрен чакырып конференцияләр, митинглар оештыра, үзенең яңа программасын бәян итә. Аның төп эчтәлеге — мөселман халыклары теләктәшлегенең географик чикләрен киңәйтү, аны халыкара хәрәкәткә әйләндерү иде. Бу халыкара конгресс булмый калды. Әмма анда каралачак идеяләр соңрак барыбер яңгыраш тапты. 1955 елда Азия, Африка, Европа халыклары төрле милләт вәкилләренең Бандунг Конференциясе (анда 29 илдән делегат катнашты) Гаспринский күп еллар әүвәл күтәреп чыккан идеяләрне, проблемаларны яклап чыкты һәм тиешле карарлар кабул итте. Шуны да өстәргә кирәк, 1910 елда кайбер мөселман-төрки илләр Исмәгыйль Гаспринскийны Нобель премиясенә тәкъдим иткәннәр иде. Ләкин ул бүләккә ирешә алмады: Африка, гарәп, башка мөселман илләрен үз тырнагы астында тотып килгән Англия, Франция, Алмания, Испания шикелле колонизатор илләр моңа юл куймадылар. Исмәгыйльне — Африканы, мөселман илләрен, милләтләрен болгатучы, колониализмны какшатучы шәхес дип гаепләделәр.

Исмәгыйль Гаспринский үз халкының, Кырым татарларының якты киләчәгенә зур ышаныч баглаган:

«Патша хөкүмәтенең Кырым татарларына карата кабахәтләрчә мөнәсәбәте, золымлыгы, җәберләве нәтиҗәсендә үз ватаннарын ташлап китәргә мәҗбүр булуларына ни диим? Бу бик бәхетсез, һичберәүгә зарар китермәүче татарны тупас пычак белән суялар, моңа гомергә дә чыдап тора алмабыз, бәхетсезлеккә, золымга кайчандыр чик булыр» («Тәрҗеман», 1903, 50 сан)». Аның бу сүзләре бүген дә актуаль яңгырый.

**Рәис САФАРОВ**

# ОЛУГ МИЛЛӘТЧЕ ТУГРЫСЫНДА КЕЧКЕНӘ БЕР ХАТИРӘ

Гаспринский хәзрәтләрен мин моннан сигез ел мөкаддәм,[1] Петроградта мөселман съезды вакытында күргән идем. Минем хатирәмдә ул менә ничек булып калган: уртачадан бераз биегрәк, чандыр гына гәүдәле, йөргәндә вә утырганда буен бераз алгарак бөкрәйтебрәк йөри вә утыра торган, шактый озын, чандыр муенлы, гасабилык күрсәтер дәрәҗәдә чандыр, озынчарак йөзле, сакалсыз, зур чал мыеклы, кыска гына агарган чәчле, киңрәк кенә, бик беленеп тора торган кашлы, йомшак, ләкин ниһаять дәрәҗәдә зәкявәтле[2] карый торган матур каргылт күзле бер зат. Моның өстенә аның карлыккан сымаграк бер тавыш белән саф төрек аһәңендәге сөйләшен кушарга кирәк. Аның тавышындагы бу карлыккансыманлык бәлки Петроград һавасының вакытлы тәэсиреннән килгән булгандыр. Ләкин нидән булса булсын, минем хатирәмдәге Гаспринский хәзрәтләре сурәтендән бу тавыш та бер җөзә.[3]

Ул еллар минем иске караш вә иске игътикадларымның[4] җимерелгән, хәяткә карашымда бер тәзәлзел[5] вә бәхрән[6] хасыйл булган еллар булуына карамыйча, Гаспринскийны күрү миңа тирән бер тәэсир калдырган иде: үземне тудырган гаиләдә вә үзем укый торган яңа китапларда исеменең зур бер ихтирам белән зикер[7] ителгәнен ишетеп вә күреп килгәнем бу затны үзем күзем белән күрә алу миңа бер яктан төш сыман вә бар яктан да кәефле тоела иде: Имам Әбүханифә, имам Бохараи... Карл Маркс шикелле «Китаптан укып кына» беленә торган кешеләрне күз белән күрү шикелле иде.

Бүгенге шикелле хәтеремдә, бабаның съезд бюросындагы утырышы: кечерәк бер номер (хәтеремдә яңлыш калмаган булса, бабаның үз номеры) 12—15 кешенең утыры-

---

[1]Мөкаддәм — элек. [2]Зәкявәтле — зирәк, үткен. [3]Җөзә — өлеш. [4]Игътикад — инану. [5]Тәзәлзел — тетрәү. [6] Бәхрән — дулкынлану. [7] Зикер — искә алу. [8] Тарызда — рәвештә. [9]Хатиб — сөйләүче. [10]Ихтар — искәртү. [11]Тәүҗиһ — юнәлү. [12]Тәхминән — чама белән. [13]Маил — сыман. [14]Истигъмаль — куллану. [15]Ихтиляф — дау. [16]Мадам ки — чынлыкта.

шыннан тыгызлык, номер урындыгы — хәтфә төсле диванның югары башында баба утыра (түбән башында — дамелла Галимҗан әл-Баруди). Ул халык сөйләгәнне тыңлый, шау-шу басылгач кына, кыска гына берничә сүз әйтә, шул сүзләр белән үзенә кадәр сөйләп уздырганнарның фикерләреннән бер хасыйл ясый да аның өстенә катгый гына бер тарызда[8] үз фикерен бәян итә. Карар бик күп вакытта шул фикер тирәсенә оеша. Бу мәҗлесләрдә мин аның һичбер озын нотык сөйләгәнен хәтерли алмыйм. Ул әйтә торган сүзләрен бик сәдә генә бер тарызда кыска гына итеп әйтә иде. Ул партия низаглары белән чыккан моназараларда, үзенең кызу табигатенә, чандыр буе күрсәтә торган гасабилегенә капма-каршы буларак, гаҗәп бер салкын канлылык саклый ала вә бу аңар бик килешә, аның ул низаглардан өстен торганлыгын ачык күрсәтә иде. Шундый бер вакыйга хәтеремдә калган: без съездга оппозициядә тора торган берничә яшь җилбәзәкләр (шулар арасында мин дә) бюро мәҗлесләренең бер-икесендә үзебезнең нoктаи назарларын әйтеп калырга теләдек. Минем иптәшләрдән берсе бик озын вә ачы нотык сөйләп, съездны демократиягә каршы ясалган бер нәрсә булуда гаепләде. Аның ачы сүзләре бөтен мәҗлестә безгә каршы протест тудырганда, фәкать өч кеше: баба, дамелла Галимҗан һәм Галимәрдән бәк Тупчыбашов салкын канлылык саклап калдылар, баба исә хатибкә[9] сөйләп бетерергә ихтыяр бирүнең тиешлеген ихтар[10] итте. Безнең хатибымыз үзенең озын вә шактый тәртипсез ачы сүзләре белән вә шул җөмләдән, хосуси бабаның үзенә дә тәүҗиһ[11] ителгән ихтирамсызлыклар белән тулы нотыгын тәмам иткәч инде, Гаспринский тәхминән[12] шушы маилдә[13] җавап бирде:

— Углым, сез яшьсез, тәҗрибәсезсез, шунлыктан кирәгеннән артык каты гыйбарәләр истигъмаль[14] итәсез... Сезнең кеби кызу рухлы яшьләремез милләткә хезмәт итеп, аның мәдәни дәрәҗәсен үстерсәләр, ул вакытта без сыйнфый ихтиляфлар[15] тугрысында сөйләшермез, фикер йөртешермез. Мәдәнияте юк бер милләтнең промышленносте була алмый, мадам ки[16] ул юк әле, сыйнфый низагларга да иртә. Безнең бүгенге вазифамыз әле мәдәни үсүдән вә шуңар юллар хәзерләүдән генә гыйбарәт... Андан соңгысын бездән соңгылар карарлар...

Миллəт мəдəниятенең бабасы агзыннан бу сүзләр һәм ышанычлы һәм олуг яңгырыйлар иде.

**Фатих ӘМИРХАН**

*«Аң» журналы, № 18, 1914 ел, 17 октябрь.*

---

# *Бер сорауга бер җавап*

*СОРАУ. Мансур Хәсәнович, ниһаять, Татарстан республикасының үз Фәннәр Академиясе оештырыла. ТССР Министрлар Советы Рәисенең беренче урынбасары буларак та, Татарстан Фәннәр Академиясен оештыру комитеты рәисе буларак та, профессор буларак та шушы мәсьәләгә ачыклык кертсәгез иде: ул нинди вазифалар үтәячәк һәм бүген аның әзерлекләлеге ни дәрәҗәдә?*

ЖАВАП. Мәсьәлә бик мөһим. ТССР Фәннәр Академиясенең төп бурычы гуманитар, табигый һәм техник фәннәрнең әйдәүче юнәлешләре буенча фундаменталь тикшеренүләрне гамәлгә ашыру булырга тиеш. Татарстан Академиясе төп көчләрне республикабызның икътисади, мәдәни үсеше, аның тарихына кагылышлы юнәлешләрне билгеләячәк. Шулай ук аның алдына СССР Фәннәр Академиясе, башка республикаларның һәм чит илләрнең фәнни оешмалары белән элемтәләр урнаштыру мәсьәләсе дә куела.

Бәхеткә, безнең республикада Фәннәр Академиясе эшен башлап җибәрерлек көчләр бар: 700 ләп фән докторы, 7000 ләп фән кандидаты исәпләнә. Алар ил күләмендә дә абруйлы урыннарны биләп тора.

Инде Академияне ачу мәсьәләсенә килгәндә, шушыны әйтергә кирәк. Хөкүмәтебез бу эшнең Оештыру комитетын раслады. Аңа бик булдыклы галимнәр кертелде. ТССР Министрлар Советы Оештыру комитетының докладын тыңлады һәм булачак Академиянең концепциясен тикшереп, аларны хуплады, Татарстан Академиясен төзү турында карар кабул итте. Мәсьәлә ТССР Югары Советы Президиумы карамагына кертелде.

Матди шартлар тудырылып, үз Академиябез ачылса, бездә аның утызлап хокукый әгъзасы һәм иллеләп член-корреспонденты булачак.

Республикабызның суверенлык алуы бу юлда зур этәргеч, дип уйлыйм.

Яңа төзелә торган Академиянең бүлекләре, институтлары эшчәнлегенә республиканың талантлы галимнәре, бигрәк тә яшь көчләре тартылачак.

## Кояш Тимбикова

# СӘХНӘЛӘРДӘ — ЙОЛДЫЗ



Ике катлы җыйнак ташпулат җиләк-җимеш куаклары, алмагачлар, чәчәк түтәлләре белән бизәлгән бакча эченә ифрат җайлы иттереп урнашкан. Бәләкәй бу утарны нәфис челтәр рәвешендә коелган чуен рәшәткә белән уратып алганнар. Юлда җиңел машиналар кәрваны пәйда булгач, бакчаның серле капкасы тавышсыз-тынсыз гына, киң итеп, ачылып китте. Машиналар түргә үк, өйгә алып керә торган ак мәрмәр баскыч төбенә кадәр үк уздылар. Иң алдан килгән сузынкы ак машинадан Вафирә ханым үзе төште.

Аягын җиргә тидермәс борын ук ул тагын дусишләре үзәгендә торып калды. Кайсылары чәчәк бәйләмнәрен тотышырга ярдәм итә, башкасы җырчының кәефен сораша, яшь-яшь бер кыз исә аның иңбашыннан сыйпалап барырдай итеп тегелгән нәфис күлмәгенең итәген тоткан: тузан тия күрмәсен! Кыз белә: таң алдыннан күккә иңүчән шәфакъ төсле ал ефәк бу күлмәген Вафирә аеруча ярата. Шуңа да, элекке гадәтенә күз йомып, сәхнәдән чыккач та, алыштырмыйча, машинага да шул килеш утырды. Ефәкне Шәрыкның мәшһүр базарыннан кайтартканнар иде. Фасоны-фәләне алдан чамаланмаганга, җитми кала күрмәсен, дип, очы белән алдырдылар. Тегү остасы Франциядән, Парижның үзеннән килеп йөрде. Җиңнәргә, чабуына, муен уемына мең дә бер бәби итәк бөрделәр. Алар төн җилендә талгын гына җилфердәшә. Сылу гәүдәле, җитез хәрәкәтле артистка менә-менә канатланыр да, җирдән күтәрелеп, бакчаның серле караңгылыгына очып китәр кебек.

Хуҗабикә ишек төбенә аяк басуга, өй эчендәге бөтен шәмдәлләрдә, балкып, утлар кабынды. Киң тәрәзәләр аша бакчага бөркелгән яктылык тирә-юньне алтынсу төсләргә манчыды. Кешеләр тагын да җанланып китте. Хуплау сүзләре, артистканы котлаулар, мактаулар тагын да көчәя төште.

— Ура-а-а! Вафирә ханым, бенефис ифрат та шәп узды!

— Афәрин, Вафирә ханым! Сездәй талантыбыз булганга, без бәхетле! Вафирә — безнеке!..

Җырчы да шат, бәхетле, канәгать иде. Әмма ул, гадәтенчә, хисләрен йөгәнләргә кирәк тапты:

— Рәхмәт, рәхмәт! — диде дә кисәтергә ашыкты. — Йә, ярар, җитәр, юкса мин һавалана да башлармын. Әйдәгез, өйгә рәхим итегез!..

Ул бүгенге уңышын бары үзенеке генә дип исәпләми, аңа әле үзен озата килүчеләр дә: татар җыр сәнгатен үстерергә өлеш керткән шагыйрьләр, композиторлар, музыкантлар, залны әзерләүчеләр дә, кыскасы, кичәгә шаһит һәркемне хуҗа итеп саный.

Иптәшләре астагы каттагы иркен залга үтә калды, кайберәүләр музыка салонына керде, Вафирә исә: «Мин — хәзер!» — дип, өске катка күтәрелде. Ул киенүбизәнү бүлмәсенең ишеген япканда да, астагыларның: «И-и бу Вафирә! И-и бу Гыйззәтуллина! Милләтебезнең бәхетенә туган бала бу!» кебек сүзләре, җырчының сәләтенә сокланулары ишетелә иде.

Аңа бик рәхәт. Бер диварны тоташы белән алып торучы күзгә каршындагы үзе йомшак, үзе тирбәлгеч кәнәфигә чумды ул. Күзләрен йомды. Күңелен тутырган сөенеченә шөкерана иткәндәй: «Аh!»— дип куйды. Мондый мизгелләрдә ялгызы калырга ярату ын белгән сердәше дә, бүлмәгә кермичә, аның дәшүен көтеп, коридорда әрле-бирле йөренә иде. Тик бу юлы Вафирә аңа эндәшеп-нитеп тә тормады, кижемамык йонлач халатын киеп, үзе килеп чыкты:

— Мин бер генә чумып алыйм инде!— диде.— Әйдә бергә!

Алар өйнең тыныч ягындагы тар баскычтан аска төштеләр, өсте ябулы тар сукмактан ясалма күлгә таба атладылар. Бер-ике секундтан Вафирәнең чупылдап суга чумуы ишетелде.

Тәүлектәге барлык бурычларын үтәп чыкканнан соң бассейнны аеруча ярата ул, аңа арыганлыгыннан, төрле зәхмәтләрдән арындыру чарасы итеп карый. Бу бәләкәй генә ясалма күл өчен суны әүвәл артистканың туган ягы Алабугадан — Чулман елгасыннан ташыттылар. Кама-Идел пычранып беткәч, Кара диңгездән кайтарта башлаганнар иде. Соңгы елларда бу диңгез дә тәмам шапшакланды, суының төсе үк тоныкланып калды. Табиблары кисәткәч, җырчы Мисырдагы дусларына мөрәҗәгать итте. Хәзер аңа коену өчен кирәкле суны, Искәндәрия каласы аша, Урта диңгездән алдыралар...

Сизәм: укучым бөтенләй аптырашта калды. Сүзнең кем турында баруына төшенә алмый интекте. «Вафирә», «Гыйззәтуллина», «җырчы», «туган ягы Алабуга» дигәннәрдән чыгып һәркем, әлбәттә, сүз үзебезнең күренекле шәхесебез, Татарстанның һәм Каракалпакстанның халык, РСФСРның атказанган артисткасы, Бөтенсоюз һәм Бөтендөнья ярышларында лауреат саналган сөйкемле кызыбыз Вафирә Гыйззәтуллина турында барадыр, дип уйлады. Тик...

Нигә әле — «тик»? Мин, чыннан да, нәкъ шушы талант иясе турында язарга алындым. Күз алдымда — аның концерты. Залдагы меңләгән тамашачының бөтен барлыгы сәхнәгә юнәлгән. Мин моны күрмим, тоям гына. Читтәгеләргә караштырып утырырга мөмкин түгел, күңелне сәхнә, аның үзәгендәге җырчы тулаем әсир иткән. Аның үз-үзен тотышына да, нечкә зәвык белән киенгәнлегенә дә, тамашачыга һәм үз музыкантларына булган үтә шәфкатьле мөгамәләсенә дә сокланмый мөмкин түгел. Боларның һәммәсе шул дәрәҗәдә камил вә сәнгатьчә ки, ул инде сине битарафлыктан тәмам арындыра. Беренчел соклану хисе артыннан синдә саф күңелле, хөр күңелле буласы килү теләге уяна. Уйлана башлыйсың. Вафирә исә җырлый да җырлый, сине ашкынулы хисләр дөньясына әйди-әйди җырлый бирә:

*...Кызарып, кызарып кояш баткан чакта-а-а...*

Мөхтәрәм композиторыбыз Исмай ага Шәмсетдиновның бу романсын бары Вафирә Гыйззәтуллина гына күңелләргә үтеп керердәй итеп башкара. Әсәрнең һәм җырчы осталыгының бу кадәр дә тәңгәлләшүе — сирәк күренеш. Җырдагы һәр сүз, көйнең һәр авазы һәм шул хәзинәне тыңлаучыга ирештерү ысулы — барысы да илаһи бер мөкәммәллек хасил итә. Җырчы гүя бәхетлеләр өлешенә генә тия торган мәхәббәт дигән бөек хиснең иң тирәнгә яшерелгән серен тыңлаучысына ачып бирергә омтыла.

Бер-берсенә омтылучы җаннар турында, күңелдән күңелгә илче бар, дип сөйлиләр. Әмма тамаша залында — йөзләрчә җаннар. Җырчы шуларның һәммәсенә ничек «илче»ләр җибәреп өлгерә?! Нинди алымнар белән йөзләрчә-меңнәрчә күңелләрне үзенә тарта, ышандыра, канатландыра ала?

Минемчә, Вафирә Гыйззәтуллинаның бу көче аның халыкчанлыгыннан килә. Безнең бу артисткабыз — баштан-аяк халыкныкы. Җырчының бу сыйфаты турында уйланганда, ихтыярсыздан, җырчы һәм композитор Сара ханым Садыйкова искә төшә. Керфек очларыннан алып иҗатының иң биектәге үренә кадәр — тоташы: барыюгы, табышы-югалтулары, шатлыгы-кайгысы, казанышы-ирешә алмаганнары — һәммәсе халык белән уртак иде аның. Вафирә иҗаты да нәкъ шундый.

Әзлекле игътибарлылык белән күзәтсәң, бу халыкчанлык иң әүвәл аның биниһая тырышлыгында ачыла. Ул үткән юлга гына карыйк: татар авылы, шундагы мәктәп, Алабугадагы мәдәният-агарту мәктәбе, туган авылы китапханәсендәге эш, Казан музыка училищесы, Түбән Камада музыка мәктәбе укытучысы вазифасы, ниһаять — консерватория һәм, ниһаять, сәхнә, дөнья сәхнәсе! Үзен-үзе белә башлаганнан бирле өзлексез тырышу, үз дигәненә, җырдагы матурлыкка, матурлыктагы камиллеккә ашкыну. Бүген биек, иркен сәхнәләрдә йолдыз булып балкый, аны тыңлаган һәркемне сокландыра. Бигрәк тә иҗат юлына төп билгеләмә итеп сайлаган «Бәхет» җырын да сузып җибәрсә, дөньяда бу кешедән дә бәхетлерәк зат юктыр, дип уйлыйсың. Әмма ара-тирә Вафирәнең бу уңышларга ничекләр итеп ирешүе белән кызыксынырга да кирәк.

Хәер, кайберәүләр бик тырышып карасалар да, максатларына барып җитә алмый, тукталып калалар. Ник, дигәндә, аларның ашкынуы, максат-хыяллары халкыннан, гадиләрдән аерылган була. Талант иясе сәләте белән япа-ялгыз яшәргә тырышып ялгыша. Вафирә Гыйззәтуллина, бәхеткә, шушы табигый хакыйкатьне сабый чактан канына сеңдергән. Ул һәр җирдә — үз.

Мин соклануымның сәбәпләре арасында иң беренче итеп аның үз-үзен тотышына тукталам. Бу бик мөһим. Вафирәнең халыкчанлыгы, гадилеге, тамашачысын туганыдай якын күрә алуы — аның уңышларына нигез ташы булып түшәлгән. Кайда гына чыгыш ясамасын: ерак Кубадагы негрлар каршындамы, АКШ аксөякләре янындамы, Үзбәкстанның иң кечкенә бер кышлагындамы — барыбер, тыңлаучысы аның беренче тын алуыннан ук үзенә карата иң мәрхәмәтле карашны сизеп ала, шуңа да ул аны ярата, хуплый.

Юк, мин моның белән һич тә Вафирә Гыйззәтуллинаның иҗаты хәтфә келәм буенча биеклеккә генә юнәлтелгән юлдан бара, дип расларга җыенмыйм. Җирдә матурлык тудырырга омтылучы һәр иҗат әһеле кебек үк бу җырчы да бик еш сикәлтәләргә, киртәләргә, чытырманлыкларга очрап кына тора. Әмма бу каршылыклар аны сындырмый, киресенчә, көрәшләрдә ул, диңгез ташкынында кайнаган таштай, ныгый, чарлана, остара бара.

Күңеленә ятышлы төрле җырлардан төзелгән концертларда йөреп туйгач, тамашачысын тагын бер баш үстерү, аңа сәнгатьнең тагы да тирәндәрәк яткан серләрен ачу өчен, Вафирә Гыйззәтуллина, Татарстан җырчылары арасында беренче буларак, концертларын аерым темаларга багышлый: «Горурлык һәм мәхәббәт», «Тормышым һәм бәхетем — җырларда», «Өмет», «Ишеттем мин кичә, берәү җырлый», «Сәйдәш моңнары». Болар — спектакль кебек махсус сюжетка корылган концертлар. Спектакльләрдән аермасы шунда ки, режиссеры да, рәссамы да, кием-салым сайлаучысы да, грим салучысы да һәм, әлбәттә, башкаручысы да — Вафирә үзе. Җырчы бу төр ярдәмчеләр турында хыяллана гына ала.

Югарыда телгә алынган концертлар татар кызлары образына, шагыйрә С. Сөләйманова иҗатына, Тукайга, Бөек җиңүнең 40 еллыгына, даһи Сәйдәшкә багышланып, мең-миллион тамашачының күңелен сафландырды, мәгълүматын арттырды.

Тукайга мөрәҗәгать итү — Вафирә иҗатына, артистка үзе дә көтмәгәндә, «Туган тел»нең бөтен тамашачы белән бергәләп, гаҗәеп бер хор итеп җырлау бәйрәмен тудырды. Башта концертка килүчеләр, аягүрә басып, җырчыга кушылдылар. Аннары Вафирә «Туган тел»не дистәләрчә мең кеше җыелган митингларга алып чыкты. Милли байрак итеп күтәрде.

Болай булды ул. Укучыга мәгълүм инде: 1988 елда, илдәге революцион үзгәртеп коруларга көч-куәт бирү йөзеннән, республикабызда Татар иҗтимагый үзәге оешты. «Үзәк»нең төп максаты Татарстанны мөстәкыйль дәүләт дәрәҗәсенә күтәрү иде. Ун-унбиш фидакяр җан башлап җибәргән шушы хәрәкәткә тиз арада Вафирә дә килеп кушылды. Аның көрәш рухы белән сугарылган күңеле чыдап торамы соң?! «Үзәк» утырышына килүенең беренчесендә үк җырчы эшлекле тәкъдим ясады:

— Күрәм: сезнең матди ягыгыз хөрти. Банкта счетыгызны ача алсагыз, мин Татар иҗтимагый үзәге чыгымнарына бер концертымны багышлаячакмын...

Озак та үтмәде, К. Тинчурин исемендәге театр бинасында Вафирә Гыйззәтуллинаның әлеге изге максатка багышланган, өч сәгатьлек концерты узды. «Үзәк», бу кичәдән соң, иркен сулыш алып җибәрде. Вафирәнең күркәм башлангычына башка артистлар да кушылдылар. Ә беренче адымының уңышыннан канатланган артистка үзе исә милләтнең тулы мөстәкыйльлеге өчен көрәшкә тулаем бирелде. Республиканың Югары Советына алдынгы фикерле депутатларны үткәрү өчен сайлаучылар арасында йөрү дисеңме, «Татар кызлары» иҗади төркемендә республикабыз хатын-кызларының хәлен аңлатып чыгышлар ясаумы?! Болар гына да түгел, күпмеңле митингларда ук җырлый башлады ул. Республикага суверенлык даулаучылар арасында, төнге сәгатьләрдә дә мәйданнардан кайтып кермәде. Аның чыгышлары һәрчак «Туган тел»не күмәкләп җырлау белән түгәрәкләнә. Бу гаҗәеп хорны тыңлаганда шундый уйлар туа: җырчы гүя халык моңын, бөек Тукай фикерен бөтен дөньяга берьюлы ишеттерергә тели.

*...И туган тел! Синдә булган*
*Иң элек кыйлган догам:*
*Ярлыкагыл, дип, үзем һәм*
*Әткәм-әнкәмне, ходам!*

Алдарак мин Вафирә ханымның мәшһүр Сара Садыйковага охшаш ягын телгә алган идем. Бу охшашлыкның күзгә иң ташланган сыйфаты аларның һәр икесенең халыкчанлыгында, гадилегендә һәм гаделлек хакына сугышчан булуларында гәүдә-

ләнә. 1986 нчы елның июне безнең арадан Сара ханымны мәңгегә алып китте. Бу югалтуны һәммәбез бик авыр кичерде, шулай да җырчыларның хәсрәте бөтенләй башка. Вафирәдәй нечкә күңелле, бик тиз хискә бирелүчән җаннарга ул көннәрдә аеруча кыен иде. Үлем дигән коточкыч шәрә хакыйкать белән һичничек килешергә теләмәгән җырчы, кайгы күләгәсеннән котылырга теләп, Сибгат Хәкимне эзләп китә. Халык шагыйренең шулай ук нәкъ Сара апа яткан шифаханәдә дәваланган чагы. Хәле дә әллә ни шәптән түгел икән. Янына керәүне дә кертмиләр. Әмма шагыйрь, килүченең Вафирә икәнлеген ишеткәч, катгый рәвештә, очраштыруларын сорый. Керә җырчы. Борчылуларын яшерергә тырышып, елмаеп:

— Исәнмесез, Сибгат ага!— ди.— Әйдә, тизрәк чыгыгыз инде, терелегез!..

Аның сорау-теләкләрен, әйтерсең лә, ишетми дә шагыйрь:

— Мен-ә-ә,— дип әкрен генә зарланырга тотына.— Сара үлгән, миннән яшереп маташалар...

Шомлы хәбәрне шагыйрьдән, чыннан да яшерәләр, чөнки тәмам зәгыйфьләнгән йөрәкнең күтәрә алмавы ихтимал. Мизгел эчендә барына да төшенгән Вафирә сүзне шома гына икенче якка бору әмәлен таба:

— Ярар инде, Сибгат ага, бер-ике минутка кергән арада миңа шыксыз үлем хакында сөйләмәгез әле!— ди.— Минем мәхәббәт турында, яныр-көюләр турында ишетәсем килә...

Шагыйрь елмайгандай итә:

— Йә-ә, ярый-ый,— дип суза.— Килешәм. Алайса, син дигәнчә булсы-ын.— Ул сүзне ничегрәк дәвам итәргә, дигәндәй, бераз уйланып тора. Аннары, сер сөйләгәндәй, пышылдап кына сорый.— Әйдә, үзебезнең «Өянкеләр»не җырла әле!..

Композитор Р. Яхинның осталыгын мактый-мактый җыр дөньясына кереп чумалар:

*...Кайда ул бергә ашкынган, бергә шатланган көннәр?!*
*Минем таныш өянкеләр, сезгә баш иярә кемнәр?..*

Бу — шагыйрьнең җырчы дустын соң мәртәбә тыңлавы булып чыга. Вафирә шифаханә бүлмәсендә ярым тавышка гына «Өянкеләр»не сузганда, Сибгат аганың да көннәре санаулы гына калган икән бит.

Җырчы бүген дә С. Хәким иҗатына таянып яши. Иҗади дуслык дәвам итә.

Һәр адымыннан күренгәнчә, Вафирә Гыйззәтуллина җырларына тирәк итеп, бер яктан, сәнгать сөюче тамашачысына, халык җырларының мәңге төкәнмәс кодрәтенә, икенче яктан, шигъриятебезнең һәм сәнгатебезнең иң талантлы вәкилләре иҗатына йөз тота. Сәйдәш, З. Хәбибуллин, И. Шәмсетдинов, Ә. Бакиров, Р. Яхин, Ф. Әхмәтов, А. Монасыйпов кебек композиторларыбыз әсәрләре аның репертуарында үзәкне тәшкил итә.

Халык җырларын сайлаганда исә җырчының шулай ук үз алымнары бар. Ул, бүгенге табыннарны шаулата, авыл урамнарын яңгырата, дип кенә, теләсә нинди җырга чатлап ябышмый. Дөрес, андыйлар бер-ике ай буена арзанлы мәртәбә китерергә дә мөмкин. Вафирә нәкъ әнә шул кыска вакытлы хуплаулардан саклана да инде. Репертуарына халык җырларын керткәндә ул аларны бер баш биеклеккә күтәрергә, бер карыш алга җибәрергә тырыша. Шунсыз тыңлаучыны ничек әйдәп бармак кирәк?!

Сайлавында хаталанмас өчен ул әдәбият яңалыклары, композиторлар һәм музыкантларның, сәхнәдәшләренең, яшь талантларның һәр адымы белән танышып бара. Соңгы елларда шигъриятькә һәм музыка дөньясына талантлы хатын-кызлар килүенә бик шат ул. Бу җәһәттән шагыйрәләр Ш. Җиһангирова, Ф. Зиятдинова, композиторлар Л. Батыр-Болгари, Р. Ахъяровага зур өмет белән карый.

— Заманның тиз узучан шаукымына бирелеп сай эчтәлекле, арзан шалтыравыклы әсәрләргә кереп бата күрмәсеннәр иде!— ди.— Луиза белән Резеданың потенциаль мөмкинлекләре зур. Әлегә аларның тулысынча ачылып бетә алганнары юк...

Күбрәк алга өмет итеп караса да, Вафирә бу ике талант иясенең әсәрләрен күпләп өйрәнә: «Бөтен нәрсә сине хәтерләтә», «Китмим әле яшьлегемнән», «Су буеннан әнкәй кайтып килә», «Юатма» кебек җырлар аның башкаруында аерата ихлас, үзәккә үтеп керердәй яңгырыйлар.

Артистка, шул рәвешле, репертуарына кирәкле җимне бөртекләп җыя-җыя да, тапканнарын үз хәзинәсендәге осталык белән өртеп, халкына тәкъдим итә. «Халык» дигәне — Вафирә өчен, иң беренче нәүбәттә, туган ягы, Алабуганың Камай авылы кешеләре. Җырчы, җае чыккан саен, әнисе Бәдерниса апа янына ашыга. Еш кына ул, ерак араны якын итеп, юк вакытны булдырып, мең мәшәкатьле иптәшләрен күндереп, авылдашлары хөкеменә үзенең концерт бригадасын да алып кайта. Камайлылар аны көтеп ала, яратып тыңлый, алкышлый. Олылап озатып калалар. Кирәге чыкса,

атын-машинасын, дигәндәй, табышалар, кулларыннан килердәй ярдәмне тәкъдим итәләр. Һәрчак сәфәр йөрүче талантлы якташларының юл газабын җиңеләйтергә тырышалар.

«Тукта әле!— дисездер, хөрмәтле укучыларым.— Сүзеңнең очы очка ялганмый. Башта Вафирәнең патшабикәләр тормышына тиң көнкүрешен тасвирладың лабаса. Инде нинди «юл газабы» турында сүз кузгатасың?»

Язманы, минутлык хисә бирелеп, егерме еллар буе халыкка фидакарь хезмәт итүче сәхнә йолдызыбызның тормышы-көнкүреше турында хыялый тасвирлама белән башлавым өчен кичерә күрегез! Минем уемча, шул кадәр дә тырыш, уңышның һәр мыскалын фәкать карусыз фидакарьлеге белән генә яулап алучы талант иясенә без нәкъ алда сурәтләнгән шартларны тәэмин итәргә тиеш идек. Вафирәнең концертлары дәүләткә мул керем бирә. Дәүләт исә аңа — тереклек сакларлык хезмәт хакы. Сүз башында сурәтләнгән, иҗат кешесенә кирәкле тормыш шартларының бер чалымы гына да тудырылмаган аңа. Хәтта концертының уңышлы чыгуы өчен иң кирәкле чаралары да чамалы: репетиция урыны юк, киенү-бизәнү бүлмәсе юк, оркестры өчен яхшы уен кораллары да, кыскасы, иң кирәкле нәрсәләре дә юк аның. Бүгенге көнгәчә Вафирә Гыйззәтуллина башкарган җырлар граммофон тәлинкәсенә дә яздырылмаган.

Гаҗәп хәл: филармониябездә артистлар язмышы турында кайгыртып йөрердәй бер адәми зат та билгеләнмәгән. Артист барысы турында да үзе генә кайгыртырга тиеш. Шушы чарасызлыктан сыгылып төшеп күп кенә сәләтле ир-егетләр дә филармониядә эшләүдән баш тарта. Соңгы вакытта аларның күбесе кооператив бригадаларга берләшә, адәмчә яшәп калырга омтыла. Халыкка карусыз хезмәт күрсәтү исә Вафирәдәй фидакярләр җилкәсенә тагын да авыррак йөк булып төшә бара.

Сәхнәдә чагын гына күздә тотсаң, Вафирә тормышының килмәгән җире юк кебек. Барысы да — ал да гөл. Җырчы үзе тамашачының нәкъ шул фикердә булуын тели дә.

«Әтием Мөхәммәтдин әйтәдер иде,— ди Вафирә.— Сер бирмә, балам! Авызың тулы кара кан булса да, кеше алдында төкермә!»

Җырчы яраткан әтисенең шундый гыйбрәтле киңәшләрен иҗат һәм гомер юлы өчен беренчел кагыйдә итеп саклый. Җырчыга кайчан рәхәт, кайчан аңа кара кайгы килгән — һич белерлек түгел. Чөнки тамашачысы алдында ул һәрчак шат, матур, сокландыргыч! Бәс шулай күренә икән, аның мең мәшәкатькә каршы торып иҗат иткәнлеген кем белсен?!

Берсендә җырчы: «Минем иң бәхетле сәгатьләрем — шул сәхнәдә инде,— дип әйтеп куйды.— Сәхнә артына чыгуга тигезсез көрәш башлана...»

Мондый шартларда яшь артистларга бигрәк тә кыен. Вафирә, кулыннан килгәнчә, андыйларга ярдәм итәргә тырыша. Филармониянең хезмәт советы рәисе буларак ул башкаларга булышуны үзенең төп бурычыннан саный. Чөнки сәнгать юлында яшь талантларны ни көткәнен ул инде бик яхшы белә.

Мин аның бу хактагы сүзләренә дәлилләр сорап та тормыйм, чөнки әйткәннәрен раслардай вакыйгалар минем күз алдымда да шактый булгалады. Балык Бистәсе районында «Татар кызлары» иҗат төркеменең кичәләрен уздырган идек. Клублар берсеннән-берсе җайсызрак булып чыкты. Язучы, журналист халкы түзә инде — күнелендәген сөйләп бирер өчен генә ул әллә ни шартларга мохтаҗ да түгел. Әмма түшәменнән шыбыр-шыбыр яңгыр явып торган яки ишегеннән туп-туры тамаша залына керә торган иске, салкын клубта күбәләктәй җырчы, үз сәнгатен бөтен тулылыгы белән күрсәтү өчен, бөтен сәламәтлеген корбан итәргә мәҗбүр. Авыздан чыккан сулыш күз алларын томаларлык бу булып күтәрелә. Вафирә шунда да җырлый! Көлә! Бии!

Берәү булса, сөйләшеп тә тормас иде һәм аны һичнинди халыкара хөкемдар да гаепли алмас иде. Юк, тумышыннан халкының кыерсытылган шартларына иялэнеп үскән Вафирә тәртәгә типми, авылына адәм рәтле клуб та салып бирә алмаган, пешмәгән җитәкчеләрне әрли-әрли, җырлый бирә.

— Көчеңне исраф итеп ник сөйләп торасың? Җырла гына син, Вафирә!— дигәнем дә бар. Аңлыйсым килгән иде: бер эзгә төшеп көй суза башлагач, тукталып, сүзгә күчү җырчыга кыендыр, дип уйладым. Әмма җавап башкача яңгырады:

— Бераз сөйләп алмыйча булмый,— диде ул.— Кешеләргә җиткерәсе килгән теләкләр шулкадәр күп, шигырьләрдәге иҗекләр санына да, музыка тактына да сыймый.

Беләм: сөйли-сөйли җырлаучы, үз концертын үзе алып баручы артистлар дөнья сәхнәләрендә дә бар. Шундыйларның берсен телевизор аша да күрсәткәннәр иде. Америкадан. Исеме Диана, бугай. 100—150 генә кеше сыешлы җыйнак-җайлы залда

тамашачылар ашап-эчеп, кәеф-сафа корып утыралар. Менә сәхнәгә, җилфердәк, ап-ак күлмәген сөйрәлдереп, тавис коштай җырчы килеп чыкты. Бик кыска беренче җырын тәмамлауга:

— Минем күлмәкне яраттыгызмы?— дигән сорау ташлады.

Зал гөрләттереп кул чаба, җырчы күлмәгенең матурлыгын хуплый. Шуны гына көткән җырчы:

— Әйе шул, минем тегүчеләрем — дөньяда бер!— диде.

Аннары ул өйләренең кайсы штатларда булуы турында сөйләде, әти-әнисен, балаларын, битенә грим салучыларны мактады. Бары да шәп, бары да — дөньяда бер генә икән. Бу җырчы шул алым белән үз концертларына яңа тамашачылар җыя, билет сатарга, үз байлыгын арттырырга юл яра.

Тамашачысы да аңлый аны. Һәр сүзен алкышка күмә, хуплый, кычкыра, сызгыра. Американнарга хас гадәттер инде: алар шул рәвешле үз шатлыкларын, горурлыкларын да белдерәләр. Янәсе, әнә аларның артисткасы нинди бай! Ничек мул яши! Ул — аларныкы! Алар, концертка килеп, бу җырчыга нинди мул тормыш тәэмин иткән! Нигә? Начармыни? Әйбәт ләбаса! Диана аларга җыр сәнгатенең матурлыгын бүләк итә, тамашачы исә аңа — мул, хөр тормыш шартлары тудыра!

Вафирәнең, әлбәттә, тамашачы алдында сөйли торган сүзләре башка. Ул, җырлары арасында, көй кысасы сыйдыра алмаганны, халкына җиткерергә, кирәкле иң изге теләкләрен әйтеп калырга ашыга. Аннары ул тамашачысын тагын җыр дөньясына алып керергә ашыга — тирә-юньгә нур сирпелә, күңелләр сафлыкка, яктылыкка, бәхеткә тартыла:

*...Минем белән бергә бәхетем туган,*
*Өлешемә тигән көмешем.*
*Шул бәхетемне эзләп юлга чыктым,*
*Шул бәхетемне эзләп килешем...*

Эзләгән табар, диләр. Вафирә Гыйззәтуллинаның бүген ирешкәннәре, сикалтәләреннән курыкмыйча узган озын, катлаулы иҗат юлында табылган. Алда аны яңа чорга хас, тагын да катлаулырак хезмәт, тагын да газаплырак ләззәтләр көтә. Без, тамашачылар исә, аның тырышлыгына мәрхәмәт күрсәтеп, аны олыларга, кадерләргә өйрәнсәк иде!

1979 елны, Каракалпакстанга дуслык сәфәренә баргач, мин талант ияләрен олылауның тагын бер төрлесен күрдем. Вафирә Гыйззәтуллина да бар иде анда. Тамашачы беренче чыгышларыннан ук артисткабызның сирәк очрый торган талант иясе икәнлеген ачыклап өлгерде. Һәм тиз арада үз бәяләрен белдерүнең чарасын да таптылар. Район җитәкчеләре, концерттан соң, сәхнәгә менеп, җырчының иңенә чәчәклечуклы шәлъяулык салалар, муенына нәфис алтын чылбыр тагып куялар. Чылбыр очында — бармак бите кадәр генә сарык башы сурәте. Алтыннан коелган бу тамга, каракалпаклылар инануынча, кешегә муллык, иминлек, бәхет китерә икән...

Талантны кадер-хөрмәт итүнең, күрәсез, төрле алымнары бар. Кызганыч ки, без — татарларда тегe төре дә, бу төре дә гадәткә кереп китә алмаган. Кеше кадерен белмәүдә бер-беребезне тирги-тирги, тыныч кына яши бирәбез. Талант ияләребез исә килә тора, һәм, тиргә батып эшли-эшли, иң гади ихтыяҗын да тормышка ашыра алмыйча... китә тора. Вафирә Гыйззәтуллина да бүгенге көнгәчә тиешле кадер-хөрмәтне тоеп яши алганы юк. Ул айлар буе илебезнең төрле тарафларында җырлап йөрийөри дә, сагынып, очар коштай Казанга кайта. Әллә ниләр булган кебек: дуслар ничек яшәгән? Казан нишләгән? Нинди үзгәрешләр? Аны да сагынып көтәләрдер кебек, дус-иш, тамашачылар, көлтә-көлтә чәчәк күтәреп, каршыларга килгәндер...

Ничәмә-ничә тапкырлар шулай талпынып, ничәмә-ничә тапкырлар ялгышты инде ул. Берәү дә каршыламый, сыңар чәчәк тә юк. Пычрак, шыксыз, суык урамда, такси туктата алмыйча, салмак кына өенә таба атларга мәҗбүр ул. Өй дигәне — тугыз катлы шыксыз ташпулатның җиденче катындагы бәләкәй генә ике бүлмә. Вафирә анысына да шөкерана итә. Өмет чаткысына җылынып атлый бирә, ватык лифт ягына карамаска тырышып, баскычтан-баскычка күтәрелә. «Кызым Ларисаның төш вакыты. Бәлки чәй дә куйгандыр, ашы да өлгергәндер»...— дигән уй аны тәмам тынычландыра. Ул, елмаеп, ишеген ача...

Миңа калса, бу болай булырга тиеш түгел кебек. Табигатьтә меңгә бер очрый торган талант ияләре тормыш-көнкүреш ихтыяҗлары белән тулысынча тәэмин ителсеннәр иде! Шулай булмаганда бу йолдызлар бик тиз арада тоныклана, сүнү куркынычы алдында кала. Мөстәкыйльлек юлына баскан Татарстаныбызның үз талантларына канат куярлык кына мөмкинлеге юкмыни соң? Әлегәчә булмаган икән, хәзер, тиз арада табарга, булдырырга кирәк! Чөнки бары тик акыл ияләрен, талантлы шәхесләрне үстергән халык кына үзенә мөстәкыйль яшәү рәвешен дәгъвалый ала. Бу хакыйкатьне бер генә мизгелгә дә истән чыгарырга ярамый.

# ХАТЛАРДАН ЮЛЛАР

«Казан утлары»н даими укып барам. Бәясе күтәрелүгә карамастан, быел да язылдым, күрше-тирәгә, таныш-белешкә дә язылырга тәкъдим иттем. Журналыбыз — милләтнең аңы да, күзе дә ул. Журналның узган елгы 7 нче санында басылган Роберт Батулла белән Мансур Вәлиев уздырган әңгәмә аеруча истә калды. Редакция аны бастырып бик яхшы иткән. Әңгәмәчеләргә рәхмәтемне белдерәм. Сүз — Тукайлар рухы турында бара, көн кадагындагы мөһим мәсьәләләр күтәрелә. Әйтик, юкка чыгып барган татар теле турында. Рус теленә Татарстанда гел өстенлек бирелеп килде һәм хәзер дә шулай. Ә безнең телебезнең яшәеше һаман шик астында кала бирә. Әле суверенлыгыбызны да танучылар аз. Экономик байлыкларыбызны талаулар туктатылмаган. Шовинистларның хәтере калмасын дигән кебегрәк, матбугат та бу турыда бик юаш яза. Милләт мәнфәгатьләрен кайгыртучыларга «милләтче» тамгасын тагарга әзер торучылар кимемәде әле. Әйтерсең лә һаман Сталин заманы!

Барысын да бик дөрес әйткән хөрмәтле Батулла. Элегрәк тә кыю җанлы кеше дип исәпли идек. Телгә алынган әңгәмә кабат шуны раслый.

Сүз уңаеннан әйтим: аның «Алып батыр маҗаралары» китабын укыгач, мин аны борынгы җәүһәрләребезнең берсе дип уйладым. Бу әсәр халык иҗатыннан аерылгысыз. Язучының башка әсәрләре турында да җылы сүзләр әйтергә була. «Юл буенда зәңгәр чәчәк» әсәре үзе генә дә ни тора! Яхшы, бик нечкә хисле әсәр. Халык язмышының бүгенгедәй бик кискен чорында Р. Батулла кебек актив һәм эшчән кешеләр кирәк.

Әңгәмәдә әйтелгән һәр фикер белән килешергә мөмкин. Тик минә «намуссызлар гына партиядән чыга» дигән фикере белән килешмәс идем. Дөрес, алар арасында намуссызлар да аз түгел. Ә бит партиядән аның тискәре сыйфатларын һәм чиксез зур хаталарын кичерә алмаганнар, инде өметләре өзелгән кешеләр дә чыга.

**Ә. ХӘСӘНОВ.**
*Кырым өлкәсе, Су-Даг шәһәре.*

* * *

Журналның былтыргы 3 нче санында Миргазиян Юнысның телебез язмышы турындагы мәкаләсе өчен авторга да, сезгә дә рәхмәтләремне юллыйм.

Дөнья кешеләре Америка индеецлары язмышыннан хәбәрдар. Бу халыкның аянычлы язмышы турында күп язылды. Ә минә безнең халкыбызның гасырлар буена рухи яктан талануы, иң асыл улларының үтерелә баруы турында ачыктан-ачык язылган мәкаләләр бармак белән генә санарлык. Бу хакта китаплар бөтенләй юк диярлек. Белмим, киләчәктә ничек булыр, кемнәр язар андый китапларны, ничек язарлар икән? М. Юныс кебек кыюлар табылырмы?

**М. ШӘИХЕТДИНОВ.**
*Башкортстан ССР, Нефтекамск шәһәре.*

* * *

М. Юнысның «Телсезләнү: тамыры һәм җимешләре» исемле мәкаләсен укыгач, үземнең кайбер фикерләремне язып җибәрергә булдым.

Мәкаләдә язылган сүзләрне кабатламыйм. Анда ак һәм кара үз төсләрендә бирелгән. Халкыбызның үткәнен, бүгенге хәлен язудан тукталмаска кирәк. Халык үзенең кем икәнен оныткан. Оныкларыбыз белсен, балаларыбызның бу катлаулы дөньяда яшиселәре бар бит әле. Изге юлга баскан әдипләребез армый-талмый мөстәкыйльлегебезне якласыннар, халыкның киләчәген кайгыртсыннар.

Үзәк газеталарда бер журналистның Вьетнамда рус теленең абруе төшә баруына, рус культурасына булган кызыксынуның кими баруына бик тә борчылып язган мәкаләсен укыган идем. Шундый гамьнәре булган кешеләр Татарстанда татар теленең бүгенге хәле турында ни уйлыйлар икән? Ә телсез калган, милләтен оныткан татарларга — ике дөнья бер! Рус кардәшләребез үзләренең «бөек»леген ана карынында чакта ук ишетеп ята. Нигә безнең тарих язылмаган, нигә без Грозныйларның, Ермакларның гына «батырлыгын» укып яшибез?

Тагын бер кайгымны язам. Күптән түгел Татарстанда дәүләт теле дип ике тел игълан ителде. Бу бит безне мыскыл итү. Бүгенге көндә татар теле кыен хәлдә. Кайда барма — һәр җирдә аңа каршылык күрсәтелә. Иә, әйтегез инде, бу ике тел кайчан тигезләшә дә, кайчан тигез «хокуклы» була ала? Шуны уйлап йөрәккә кан сава.

Безгә, гади татарларга, сезнең утлы, илһамлы сүзегез көн дә кирәк, хөрмәтле язучыларыбыз!

Т. ШӘРӘФИЕВ.
*Кыргызстан ССР, Томск шәһәре.*

* * *

«Казан утлары» журналын бик яратып укыйм. Гаиләмдә дә укыйлар. Мин үзем төзелештә эшлим. Укылган әсәрләр турында фикер алышабыз. Журналның былтыргы саннарында хәтердә уелып калган әсәрләре — А. Расихның автобиографик романы, М. Юныс мәкаләсе, В. Юнысовның юлъязмалары. Соңгысын кат-кат укыдым. Мөселман дәүләтләре турында, чит илләрдә яшәүче милләттәшләребез турында күбрәк язылсын иде. Алар турында безнең күбрәк беләсебез килә.

Г. ХӘСӘНОВА.
*Түбән Кама шәһәре.*

* * *

Милләтләр дуслыгы турында күп сөйлибез. Дөньябыз матурлансын өчен нинди изге эшләр кылабыз соң? Менә Кырым татарларын гына алыйк. Бүгенге көндә аларның хәлләре бик кызганыч. Аларның хәлләренә кермәү — милләтләр дуслыгына хыянәт итү белән бер. Мин 1965 елда Евпаториядә булган идем. Аңа хәтле әле Кырым татарларының язмышы турында бик аз белә идем. Анда бер татар кешесен дә очрата алмагач, музейларында җирле халык тарихын чагылдырган берни дә күрмәгәч, йорт хуҗасыннан: «Татарлар нигә күренмиләр?» — дип сорадым. Кырымда озак еллар яшәгән бу урыс хатыны миңа аларның коточкыч язмышлары турында сөйләп бирде. Мин аңардан татарлар турында бер генә шелтәле сүз дә ишетмәдем.

— Без бик дус яши идек алар белән,— дип сүз башлады ул.— Алар тарафыннан илгә хыянәт итү булмады. Электән монда яшәгән кешеләр бу турыда яхшы белә. Төнге сәгать уникедә бик күп хәрби машиналарга төялеп солдатлар килеп тулды. Халык йоклый иде. Әйберләрен алырга да вакыт бирмәделәр. Кешеләрне, көлтә төягән кебек, машиналарга төяделәр. Картлар, карчыклар, бала-чага... Тирә-як елау, ярдәм сорап чакыру тавышлары белән тулды. Бераздан барысы да тынды. Коточкыч тынлык иде бу. Берничә көннән безне татарларның сыерларын саварга куып алып киттеләр. Ачыккан мал-туарның кызганыч тавышлары, кош-кортның ризык эзләп урамнарга таралуы, этләрнең кызганычлы өрүләре бүген дә колагымда тора... Татарлар бик эшчән халык иде, бай яшиләр иде. Без аларның калган әйберләрен таламадык, алмадык. Башка килгән кайгыдан тинтерәп йөрдек. Бөтен өйләрдәге байлыкны начальниклар бүлешteләр бугай. Бер атнадан сыер, сарык көтүләрен дә каядыр куып алып киттеләр. Бераздан татарларның йортларына күрше төбәк кешеләре кереп урнашты. Урамнар чүп-чар белән тулды, чәчәк газоннары тапталды. Ул чакта үскән чәчәкләрнең нәселе корыды. Андый чәчәкләр монда үсми хәзер. Пычратканны җыярга кирәклеген уйлаучы кеше булмады. Татарларның җылы якка киткәннәре генә исән калды, ә суык якларга сөрелгәннәре туңып үлделәр...

Хуҗабикә сөйләгән әлеге сүзләрне хәтергә төшерүем — бер фикер әйтәсе килүдән. Кырым татарларының бу фаҗигасе яңа фаҗигаләр китереп чыгармасын иде. Ә бит фаҗига һәр ике яктан корбаннар сорый. Әйтәсе сүзем шул: Кырым татарлары үз туган илләренә кайтып яшәсеннәр. Аларның юлларына берииди киртә дә куелмаска тиеш. Таланган мал кире кайтарылмаса да, таланган халыкның рухы яңадан терелсен!

Д. ЗОЛКАРНӘЕВА.
*Бөгелмә шәһәре.*

* * *

Мин хәзер сезнең журналда зур үзгәрешләр күрәм. Халкыбыз язмышы турында ачынып, аның киләчәге турында кайгыртып язылган әсәрләрнең, мәкаләләрнең күбәюен һәркем күрәдер. Шул уңайдан мин дә үземнең берничә фикеремне язмакчы булдым.

Туган телебез мәсьәләсен алыйк. Күп кенә милләтләр үзләренең туган телләрен дәүләт теле дип игълан иттеләр. Без дә иттек. Тик... дәүләт теле икәү булып чыкты безнең. Бу — безнең зур хатабыз. Телебез бетеп барганда, әле телләрен оныткан берничә буын кешеләрнең дә булуын онытмаган хәлдә, барын да уртага салып уйлаганда — чыннан да, зур хата бу. Татар телен бик озак еллар «бизгәк тотты». Ул кайчан терелә әле? Үзенең балаларын кайчан эзләп табып кочагына алыр? Дәүләт теле икәү була икән, аларның бүгенге яшәеш хәлләре дә бертигез булырга тиеш. Татар теле гамәлдән чыгу алдында тора. Ә янәшәсендәге «мамонт»ның авызы бик зур булып ачылган.

Миграция хакында бер-ике сүз. Табигатьтәге төрле-төрле тереклек иясен: җәнлекме ул, бөҗәкме ул, чәчәкләрме — аның яшәү мохитен үзгәртсәң яки кыссаң, ул тереклек иясе үз мохитен ташлап китә, күпчелек очракта һәлак була. Кеше дә нәкъ шулай. Татар халкының таралып бетүен дә мин шуннан күрәм. Меңнәрчә дәлилләр китерер идем, сүзем озынга китүдән куенсынам. Бер генә мисал. Әгәр колхозчы теге яки бу эшне эшләүдән баш тартса, яки мөмкинлеге булмаса — аның бакчасына трактор кертеп, үсеп утырган бәрәңгесен сөреп чыгалар иде. Мондый хәлләр 70 нче елларда киң таралган иде. Колхозчылар өчен җәзаларның күп төрлесе кулланылды. Бу золымнарга түзә алмыйча, бик күп кеше илен ташлап китәргә мәҗбүр булды. Ул кешеләрне яңадан кайтарырга кирәк. Кайтырга теләүчеләр күп. Ләкин аларга шартлар тудыру кирәк. Татарстанда әре-әре җитештерү берләшмәләре бар. Алар миллионлаган сум салым түлиләр. Ә ул салымнар һәммәсе үзәккә китеп бара. Бу акчаларның иң зур өлеше Татарстан кулында калырга тиеш. Шул акчага кайтучылар өчен тораклар төзү, эшкә урнаштыру мәсьәләләрен җайга салырга мөмкин. Моны Татарстан хөкүмәте эшләмәсә, кем эшләр икән соң?

Сөйлисе сүзләрем бик күп. Сагышка салган уйларны бергәләп уйлыйк, бергәләп тормышка ашырыйк, туганнар!

**Вил ГАМБӘРОВ.**
*Ташкент шәһәре.*

* * *

Без ата-бабаларыбыздан калган горур «Болгар» исемен бервакытта да кимсетергә, мыскылларга ирек бирмәбез. Үз намусыбызны, үз иманыбызны саклаган кебек, исемебезне дә сакларбыз. Шул уңайдан бер авторның шигырь юлларын тәкъдим итәсем килә:

Язмыш көлгән бездән — болгарлардан:
Ни күтәрми горур җилкәбез?!
Болгар осталарын утка салган
Вәхшиләрнең исемен йөртәбез.

**Хәбиб Рахман әл-БОЛГАРИ.**
*Казан шәһәре.*

* * *

Мин 54 ел гомеремнең 38 елын туган җирдән аерылып үткәрдем. Читтә яшәсәм дә, туган телемне онытмадым. Исемемне дә Захар Захарычка әйләндермәдем. Кайда гына эшләсәм дә, җитәкче эшләрдә эшләсәм дә, миңа үз исемем белән эндәште кешеләр. Аның иң беренче сәбәбе — безнең гаилә иң авыр елларда да, сугыш елларында налогына, заемына акча таба алмый интеккәндә дә «Казан утлары»н (элек ул «Совет әдәбияты» дип аталды) алудан туктамады. Балачагымда шундый дустым булмаган булса, белмим, бүген мин бәхетле кеше була алган булыр идемме икән?

**Шамил ГАБИТОВ.**
*Мари ССР, Йошкар-Ола шәһәре.*

* * *

Журналга язылу бәясе 18 сум түгел, 180 сум булса да — язылмыйча булдыра алмам. Журналны алдыра килүемә быел кырык ел тула. Ансыз мин үземнең мәдәни тормышымны күз алдына китерә алмыйм. Ул минем иң яраткан журналым, иң татлы җан азыгым. Безнең өйдә журнал килгән көн кадерле кунагыбыз килү белән бер. Ул көнне без аны почта әрҗәсенә юри кабат салып куябыз. Оныгым балалар бакчасыннан кайтканны көтәбез. Оныгым Зөлфия журналны миңа үзенең нәни куллары белән тапшыра. Ишектән атлап керүгә үк шатланып:

— Бабай, синең яраткан журналың килгән, шундый матур, шундый калын,— дип аваз сала.

Журналда даими рәвештә халыкның бүгенге омтылышы, көрәше, милли мөстәкыйльлеген тормышка ашыру өчен башкарган гамәлләре турында мәкаләләр һәр санда басылып барсын иде. Беркемгә дә сер түгел, азатлык өчен көрәшнең әле нигезе генә салынды. Алдагы көннәрдә безне тагын да ныклырак көрәш көтә.

**Җиһанша ГАЛИЕВ.**
*Чаллы шәһәре.*

## Сүз

Күк кебек биек ерак үзәктә,
Кечкенә бер сүз — йөз мең йозакта.

Кем соң үзәктә сүзне озакка
Биклә͏теп куйган йөз мең йозакка?

Сүзне бикләтеп, үзен чикләтеп,
Яшәгән үзәк — халкын читләтеп.

Йөз мең йозакны вату озакмы?
Сүз азат булып, халык азатмы?

Әлбәттә, азат... Үзәккә үзе,
Сайланып узып, сүз булса сүзе!

* * *

Килә дә догма уй... тумый кала,
Була иде дә... туй булмый кала.

Әлли догмачы тумаган уйны,
Тиәли камчылап булмаган туйны.

Тизләткәч, була — булмый торганы,
Әрәмгә китми камчы органы:

Тумаган уйны табып бирәләр,
Булмаган туйны — «Булды»,— диләр.

**Хәмидулла ГАБДҖӘЛИЛОВ.**
*Әстерхан шәһәре.*

## Кичке җыр

Кич. Офыкта шәфәкъ нуры сүнә,
Тынлык коча елга буйларын.
Шул тынлыкта йөзә талгын гына
Ерак җырның серле моңнары.

Сүрән учак-утның яктысында
Рәхмәт әйтеп тыңлыйм җырчыны,
Тынгысызлык белән гозерләнәм
Өзмә, туктатма, дип шул моңны...

Җыр туктала. Ә мин, күңелем белән,
Тәмле йокы баскан тынлыкта
Шул ук моңны һаман ишетәм кебек
Гомер юлы дигән офыкта...

**Хәбибрахман ӘМИНОВ.**
*Түбән шәһәре.*

* * *

Без михнәт коесының иң төбенә төшкән халык. Дәүләтебез җимерелгән, шәһәрләребез, авылларыбыз, гыйбадәтханәләребез, китапханәләребез юк ителгән, халкыбыз тәмам хәерчелеккә төшерелеп, ахыр килеп күпләребезне динебездән дә ваз кичтерделәр. Бер без генә шундый язмышлыдыр дип әйтә алмыйм, җир йөзендә бездәй җәбер-золым күргән халыклар җитәрлек. Шундый авыр шартларда да халкыбыз үз йөзен саклап кала алган икән, моны дөньяга, яшәешкә татарның үз карашы, үз фәлсәфәсе булу белән дә аңлатырга кирәктер.

Данын да, малын да югалткан адәмне коткарырлык, аны кабат кеше итәрлек көч бар микән дөньяда? Бар икән ләбаса! «Ярату» дигән җавап яткан язмыш коесының төбендә. Күтәреп алган аны татар кешесе. Җирне, суны, тереклекне изге итеп кабул иткән, яраткан, шуларга табынган, шуларны саклаган. Балаларына мирас итеп тә шушы яратуны калдырган. Аның гыйбадәтханәсе, мәккәсе, дине, күңелен сафландыра торган урыны — газиз табигать булган. Хәтерлим әле, безнең Исергәп авылы (Баулы районы) тирәсендәге һәр сукмак исемле иде: Басу юлы, Басыйр чокыры, Уксынлы кул, эрәмәгә төшсәң — Әхмәди тугае, Сәйфенә төбәге, Аккош күле, Кабан күле. Әллә бар иделәр, әллә төштә генә булдылар — ай күрде, кояш алды аларны...

«Эшен эшләдек, кеше генә була алмадык»,— диләр бездә. Халкымның бу уфтануында бик тә тирән мәгънә ята. Әйе, гомер буе фәлсәфәнең «кешене эш кеше иткән» дигән тәгълиматенә табыну булды безнең язмыш.. Ләкин безнең мал да, дан да, дәүләт тә кире кайтмады. Үзебез дә, ахыр чиктә, кешелегебезне югалтып, аңсыз, уйсыз, эчкече бер халыкка әйләнеп барабыз. Безгә тукыганча, «кешене кеше итәргә тиешле эш» тә, күрәсең, абага чәчәге шикелле кабып йотсаң, могҗиза ясый ала торган әйбер булып чыкмады. «Эш агачының мул җимешен җыяр өчен» дә аерым шартлар кирәктер. Тукай бу турыда шигырь язганда нәкъ менә шундый шартлар күренә башлаган да инде.

**Эшнең генә кешене кеше итә алмавы** — татар фәлсәфәсенең бер ачышыдыр, мөгаен. Кешене кеше итә торган иң кодрәтле көч, минемчә, яратудыр дип уйлыйм.

Нинди булырга тиеш соң бу ярату?

Табигатьне изге итеп санау турында яздым инде.

Кешеләр арасындагы мөнәсәбәт тә, туган көненнән алып соңгы көненә кадәр, шушы төп уйны тормышка ашыра торган гореф-гадәт, ышануларга корылган. Ярату үзәк идея булганлыктан безнең халыкта баланы гаиләдә генә тәрбияләү, аны рәнҗетмәү хупланган. Берни аңламаган сабыйга да «күңеле булсын» дип хәер-күчтәнәч бирү, йомышка кергән баланы буш чыгармау — болар барысы да яратуны сабый чакта ук кеше күңеленә сеңдерә баруны чагылдыра. Шуңа күрә кеше аңын үстерү өчен ярату кирәк. Бу — татар фәлсәфәсенең икенче ачышы. Хәзерге психология фәне баланың 7—8 яшьтә тулысынча формалашып бетүе турында әйтә, ләкин бу формалашуда эшнең төп роль уйнамавы көн кебек ачык ич. Ятимнәр йортларында торып, шунда эшләп үскән балаларның тормышта үз урынын таба алмаулары, фаҗигале язмыш корбаннары булулары шушы табигый ярату җитмәүнең ачык дәлиле түгелмени?

Ярату фәлсәфәсеннән чыгып караганда, бездә гаилә кору ягыннан проблемалар булмаган диярлек. Сабый чактан ук гаиләдә ярату тоеп үскән, җитлеккән яшьләрне башлы-күзле итү ата-ананың, туган-тумачаның төп бурычы булган. Ир-егетләрдән һәм кызлардан өйләнгәнче һәм өйләнгәч тә инсафлылык, тугрылык таләп ителгән. Ирсез бала табу зур хурлык саналганга, кыз-кыркынны кияүгә бирүнең төрле ысуллары булган: ярәшеп, яратып, димләп; апасы алай-болай үлеп китсә, балдызны читкә җибәрү ягын түгел, ә җизнәсенә ярәшү ягын караганнар. Шулай итеп, гаилә бөтенлеге, туганлыгы саклаган. Һәм болар берсе дә түбәнлек саналмаган. Дөрес, болар ризалык белән генә эшләнмәгән — уен һәм йола җырлары моны бик ачык күрсәтә. Ләкин хатын-кызны ял-

гыз калдырмау, аны гаиләле итү өчен барысы да эшләнгән. Хәзер генә ул ярәшү, димләү оят эш санала, шуңа күрә күп кенә хатын-кызлар ирсез генә бала табарга мәҗбүрләр. Ләкин моның ни кадәр авыр икәнен шул язмышка төшкән хатын-кыз үзе генә беләдер.

Тормышның башка якларына да күз салыйк. Әүвәлрәк кеше каты авыруга юлыкса, аның янынnan хәл белүчеләр өзелмәгән (авылда бу хәзер дә шулай). Алар авыруның һәр теләген үтәргә, фатихасын алып калырга тырышканнар. Авыру янында махсус утыручылар да табылган. Болар, гадәттә, чиста күңелле әби-бабайлар булган. Халкыбыз авыру кешегә, үз мөмкинлекләреннән чыгып, аны яратуын, якын итүен күрсәткән, кешенең җаны чыкканда шушы яратуны тоеп үлсә, аңа җиңелрәк булачагын белгән. Кем белә, бәлки ярату — кешегә теге дөньяга күчкәндә юл күрсәтүче бердәнбер маяктыр?

Акылын җуйган кешене дә капчык кидереп кыйнамаган безнең халык, ничек тә күңелендәге яратуны сүндермәскә, акылсыз кеше өчен уңайсызлануын сиздермәскә тырышкан. Юләр кеше өйгә керсә, аны ашату, нәрсә дә булса бирү, җәлләү, сүзен тыңлау — болар да безнең фәлсәфәдән чыгып эшләнгәннәр.

Авылыбызда, ачлык елны (1921) балаларын җуеп, юләрләнгән карчык бар иде. «Курыкмагыз, изге ул»,— ди иде әни. Еш кына аңа хәер илтергә барганым да хәтердә. Күрәсең, сабый күңеленә ярату иңеп, аның да аңын ачып җибәргәндер. Мин килеп кергәндә ап-акыллы әби була иде ул, һич арттырмыйм.

Төрле авыр хәлдә калган авыру, юләр, әчкече кешеләрнең кешелеген уятырдай иң дөрес юл — яратудыр. Бу да татар фәлсәфәсеннән.

Ярату идеясе, мәңгелекме, әллә ул да күп кенә якты, яхшы сыйфатларыбыз кебек юкка чыгарга дучар ителгәнме?

Кеше күңелендәге яратуны киметүче сәбәпләр күп төрледер. Безнең халыкка иң нык тәэсир иткән дүрт сәбәп бар: ялган идеяга ияру, табигатьне җимерү, әчкечелек һәм авыр хезмәт. Безне изеп килгән ялган идеяләргә иярганче үк, татар идеясе, дәүләте җимерелү сәбәпләме, ярыйсы гына какшаган. Шулай да татар идеясен үстерергә мөмкинлек ачылган бер чор булган. Бу — 1905 ел. Күпме зыялыларны уяткан ул! Миңа калса, татар фәлсәфәсен дә менә шушы еллардан эзләргә кирәк. Бу чорда рус дөньясы зур хәрәкәткә килеп, үз идеясын пропагандалаган, үзенең рухи дөньясын без хыялланган биеклеккә күтәргән. Рус сәнгате, рус фәне, рус архитектурасы, рус теле, рус... рус... Болар барысы да шул чор җимешләре булырга кирәк. 1917 ел тагын да зуррак өметләргә юл ачкан. **Татарга дәүләт вәгъдә ителгән!** Ахыр килеп, бу — тозак кына булса да, моңа ышанмаска мөмкин булмаган. Телсез калдыра, сукырайта торган идея булган ул. Гомерең буе бөтен барлыгың белән шуңа омтыл да, «мә», дигәндә ничек сузмыйсың инде кулыңны? Сузганбыз... Ә аларга шул гына кирәк тә: кулларны богаулаганнар, башларын кисәннәр... Халык хәерчелек чокырының иң төбенә убылып, «ачлык» дигән аждаһа авызында калган. «Татар башым белән алдандым бит!» дигән үрсәләнү ишетәм мин Гаяз Исхакыйның хөкүмәткә атап язган язмаларында.

Хәерчелек чокырының төбе бик тирән шул аның. Анда ярату белән генә яшәү кыендыр. Авыр хезмәт, михнәтле тормышны яктыртып коммунизм идеясе калыккач, безнең күзләр янә дә сукырайган. Өстән килгән фәрманны икеләтә-өчләтә үтиләр иде безнең якта. Картлар ничек кенә тырышмасын, әрәмәләрне дә кырып кистеләр, болын-тугайларны да актарып сөреп ташладылар. Кешене дә, ай, изеп эшләтәләр иде! Күтәрелгән мескән башларны «сәвит влачы шулай куша» дип, җиргә кадәр идерү, каршы сүз әйткән кешеләрне милиция белән төрмәгә алып китү, «хезмәт алдынгысы» дип мал караучы, сыер савучы ир-ат, хатын-кызны аракы эчертеп юлдан яздыруны инде без үзебез, үз кулыбыз белән эшләдек. Исергәпнең бер башында «Изгеләр каберлеге» дип йөртелгән җир бар иде. Аны да казып, актарып ташладылар күзләре акайган, башларын аракы миңгерәткән адәмнәр. Бетте изгелек! Чүп тә төшерми торган елгабыздан нефть ага башлады, бакча башлары җимерек, авыл чүплек өеменә әйләнеп бара — бетсен дөньясы, дип яши кеше...

Артык мактау-мактануны һәм хурлауны хупламау — татар фәлсәфәсенең үзәге — тыюларда бик ачык күренә. «Мактанчыкның — арты ачык»,— дип, безнең бүгенгебездән әче көлә татар фикере. Мактану тыелган бездә. Ләкин аңа карап кына татарны мактанчык түгел дип әйтеп булмый: без дә ярыйсы гына күзгә төтен җибәрергә яратабыз. Мактану, мактанганны сиздермәс өчен көчкә таяну (Сталин, Брежнев) — ахыр килеп, төзелгән дәүләт пирамидасының кыйшая баруына китерде. Фәнни-популяр әдәбиятта дәүләтне күзаллау өчен төрле абстракцион модельләр кулланыла. Күп хезмәтләрдә Рус дәүләте итәге киң пирамида рәвешендә күзаллана.

Вакытлар үтү белән багана да чери һәм чүгә. Үзгәртеп коруның төп асылы шуны тануда. Әгәр дә үзгәртеп коруның максаты халыклар тормышы турында чын-чынлап кайгырту булса, үзен сытмауны сораган халыкны көч белән бастыру (кырым татарлары, грузиннар), көч белән ил буйлап сибү (месхет төрекләре), һәм, ниһаять, суешка

юл кую (әзәрбайҗан-әрмән, гагаузлар) булмас иде. Моны күрмәү — безнең өчен дә фаҗига белән бетәргә мөмкин. Шуңа күрә: «Без котылырбыз, урысны коткарырбыз»,— дип коткы тарату — мәгънәсезлек. Урыс котылыр ул, аның безнең буй җитмәслек мөмкинлекләре бар. Рус егетләре Сорбонна, Кембриджларда укый, Африкада арыслан аулый, Парижга барып киенергә-бизәнергә, уйнарга, Италиягә барып рәсем ясарга өйрәнә. Рус егетенең әз генә башы барлыгын сизсәләр, аны үстерү өчен бөтен мөмкинлекләр ачыла.

Тел — халык аңының һәм фәлсәфәсенең тоткасы, баскычы. Безнең телдә кайбер чит фикерләрнең яңгыраш тапмавы, яңгыраса да халык аңына барып җитә алмавы — бик кызыклы күренеш. Тел — халык аңын чит уйдан (идеядән) яклый, аралый икән ләбаса. Гаҗәп, әмма бу шулай. Моны — авыл кешеләренең төрле лекторларның өндәүле-болгавыр чыгышларын тыңлап аптырап утыруы мисалында ачык күрергә була. Өстәп, партия җитәкчеләренең чыгышларын татарча укып, аңламыйча гаҗиз булып утырганыбыз азмыни? Тәрҗемә начар булуда гына түгел эш, ә телнең аңлаешлы булмавында. Мисал өчен, «материя первична» дигән сүзне «матди дөнья беренчел» дип тәрҗемә итсәк тә, татар аңы өчен моның аңлаешсыз сүз тезмәсе булуы бәхәссез. Безнең телдә матди дөньяга караш «Төзегән дә уй, җимергән дә уй», «Башта уең белән, аннан кулың белән», «уй керде», «уй туды» кебек зирәк сүзләр аша яңгырый. Әйе, дөрес аңлаудыгыз, без телебез буенча да идеалистлар. Без аңны тудырган төп сәбәпне яратуда күрәбез. Аңны уятучы да, үстерүче дә — шул ук ярату. Бездә көч читкә түгел, ә кешенең үз-үзенә юнәлтүе өчен кулланыла: кеше үзен тыя, чикли, моны җаны, тәне азып, аңын томаламасын өчен эшли. Безнең фәлсәфә кешене чикле зат итеп кабул итә, шуңа да уйны көч белән тыймый. Уйны, фикерне көч белән тыю — аңны хәлсезләндерүгә китерүче сәбәп дип уйланыла.

Безнең алдагы язмыш өчен «Дөньялар кая барып чыгар?» — дигән уфтанулы сорауга җавап табу бик кыен. Чөнки Үзәк хөкүмәт һаман да көчтән баш тартмый. Әкәмәт бит — милләтнең уен кемдер һаман да үлчәп торырга җыена. Туды микән соң әле бу дөньяга андый чиста күңелле, йөрәге тулы ярату булган адәм?

Рәсәй хөкүмәтенең, ашыгыч рәвештә базар кертеп, халыкларны «экономик зона» дигән читлекләргә кысып кертергә тырышуы — бөек дәүләт идеясенең яңадан балкыячагын күрсәтә. Болар икесе дә безнең өчен гаять куркынычлы дип уйлыйм. Монда бердәнбер котылу юлы — безнең уйны томалатырга ирек бирмәү, ягъни тизрәк үз фәлсәфәбезне булдыру. Бу ике зәхмәт тә көчәйсә, дәүләт дигәнебез хыял гына булып калачагы шиксез. Милли башларны саклау, үстерү булырга тиеш безнең омтылыш. «Татар фәлсәфәсе» үк дип аталмаса да «Иске татар фәлсәфәсе», «милли фәлсәфә» дигән бер җамаяк утыртып, шуңа уйларны тутыра башласак, бу иң ышанычлы адым булыр иде, дигән фикердә яшим мин.

**Зәрия ХӘБИПОВА.**
*Әлмәт шәһәре.*

* * *

Бу гармунның тавышын мин бик яшьтән тыңлап үстем. Аның моңы безнең якларның кайсы гына төбәкләрендә яңгырамады икән. Өемдә әле һаман шул ук гармун. Аны, инде менә кырык елга якын, кулымда тотам. Әле бер генә тапкыр да ватылганы юк. Соңгы вакытта миннән бик күп кешеләр «Вараксин гармунын каян табып була икән?» — дип сорыйлар. Бу сорау белән мин үзем дә күптәннән кызыксынам. Хәтта, «Социалистик Татарстан» газетасы исеменнән Казан гармун фабрикасына да мөрәҗәгать иттек. Фабрикада безгә ул чакта йөз Вараксин гармуны эшләп чыгарырга вәгъдә биргәннәр иде. Бу вәгъдәнең ни дәрәҗәдә үтәлүен әлегә хәтле белә алганым юк. Ә бит шул ук вакытта Вараксин гармуннарына ихтыяҗ кимеми, киресенчә, арта гына.

Вараксин гармуннары белән кызыксынуым мине шушы атаклы гармуннарны ясаган олы останың — Дмитрий Иванович Вараксинның нәсел-нәсәбен эзләргә мәҗбүр итте. Билгеле булганча, аның әле тагын ике туганы — Григорий һәм Николай да гармун ясау белән шөгыльләнгәннәр, улы Михаил исә гармун фабрикасында эшләгән. Мин күптән түгел шушы гаҗәеп нәселнең исән калган бер кешесе — Николай Ивановичның улы белән очраштым. Валентин Николаевич хәзер инде шактый олы яшьтә, әмма хәтере яхшы, Вараксин гармуннары турында сүз чыкса, күзләре очкынланып-очкынланып китә.

— Мин әтиемнең абыйсын — Дмитрий Ивановичны 1925 нче елдан соң күрмәдем инде,— дип сөйли ул.— Чистайда гармун ясаганын, аларны Половников һәм Шишкин кибетләрендә сатканын хәтерлим. Өч бертуган — алар өчесе дә гармун

ясыйлар, гармуннарын Уфа, Казан кибетләренә озаталар иде. Хәтерлим, һәр гармунны озаклап, бөтен нечкәлекләрен искә алып, күңел салып ясыйлар иде. Шишкин кибетләре Туладан да, Вяткадан да гармун-тальян кайтаралар, гармунны Шишкиннар үзләре дә ясыйлар иде бит. Әмма халыкта Вараксин гармуны аеруча бәһале иде.

— Вараксиннарның нәселендә тагын кемнәр исән? Гармун ясау осталары булачакмы?

— Туганнан туган кардәшем Владимир Дмитриевич исән. Юк, исән калганнар арасында инде гармун осталары да, гармун ясау белән шөгыльләнүчеләр дә юк. Шулай ук Вараксиннарны алыштырырлык өйрәнчекләр, шәкертләр дә күренми. Мин үзем, күреп торасыз, авырыйм. Гармун фабрикасында эшләдем мин. Анда бит план бирәләр. Ай эчендә фәлән гармун өлгертергә тиешсең. Юк, чын гармун ясау өчен андый план кирәк түгел. Чын тавыш табу өчен җизне чын җиз итәргә кирәк. Ә бит җиз ул бик нечкә нәрсә, аның моңын йөрәк белән тоеп ясарга кирәк. Хәзерге гармуннарның тавышы нык, моңы гына юк. Татар халкы ул гармуннарны өнәми. Чын гармун тавышын аңлый белүчеләр аларга кул гына селти. Ул гармуннарны суыктан җылыга, җылыдан суыкка йөртергә ярамый. Дым эләксә — бетте. Ә минә җиз тавышлы гармун дымнан да, башкасыннан да курыкмый, тавышы да яңгырап тора.

— Валентин Николаевич, Вараксин гармуны дигән сүз әле дә халык теленнән төшми. Тик менә Вараксин гармуны үзе генә кибетләрдә юк...

— Эш бит фамилиядә генә түгел... гомумән, халыкның үз осталыгына, үз һөнәренә, үз тәҗрибәсенә игътибар кимеде бит соңгы елларда. Әгәр бер-бер хикмәт булып, халык үз тәҗрибәсенә таба йөз тотса, үзенең рухи байлыгы, кулыннан килгән эшләре, кайчандыр үзенә хас булган һөнәрләре турында уйласа, Вараксин гармуннарын да ныклап бер искә төшерерләр әле. Кем белә, Вараксин гармунын ясаучы яңа бер оста да үсеп чыгар...

Бу сөйләшүгә инде шактый көннәр узды. Ә Валентин Николаевичның әлеге сүзләре һаман да колагымда яңгырап тора: «Кем белә, Вараксин гармунын ясаучы яңа бер оста да табылыр әле...»

Өмет. Ләкин табылырмы ул оста? Казан гармун фабрикасы бу хакта уйланмый. Ә халык Вараксин гармуннарын эзли, юксына. Һәм халык күңелендә дә, минемчә, шул бер үк сорау: табылырмы?

**Рәүф ХӨСНЕТДИНОВ.**
*Казан шәһәре.*

# Гомәр Саттаров

## Шәһри Болгар

Әйткәндә үк бу исемне, сер һәм моң бар:
— Болгарыбыз башкаласы шәһри Болгар!
Алып килде мине гүя урау юллар,—
Чал тарихлы текә язмыш, ерак еллар.

Шәһри Болгар — халкымның чын тарих башы,
Мәртәбәле, шанлы, данлы, пакь — һәр ташы,
Эргәсендә Идел-ана дулкын кага,
Гасырлардан хәбәр биреп бу заманга.

Әллә кайдан килә монда сихри моңнар,
Олы тарих үзе монда — шәһри Болгар,
Яңгыраган заманында төрле җырлар,—
Җыр сузганнар тимерчеләр, оста куллар.

---

Гомәр САТТАРОВ — *филология фәннәре докторы, профессор. Шигырьләре журналыбызда беренче тапкыр тәкъдим ителә. Казанда яши.*

Яшел яулыгын бөркәнгән нарат урман
Тирән йокыга талгандай шушы җырдан,
Тылсымлы сер саклый урман ерак чордан,
Болгар чибәре җырлаган дастан-җырдан.

Таш та кирпеч — тирә-юньдә хәрабәләр,
Кая киткән асылташлар, гәрәбәләр?;
Байлык һәм зар катнаш булган Агабазар
Инде тынган, чыгармый ул бернинди зар.

Болгар теле, татар теле — бергә, тоташ,
Шул турыда сөйли миңа һәр каберташ;
Кайда дин һәм мәктәп биргән гәрәбиләр?
Кайда хәзер ак мәчетләр, гаҗәп өйләр?

Һәрберсе арыслан — алып асыл ирләр,
Ничә буын гомер иткән изге җирләр,
Чал тарихы бабамнарның — шәһри Болгар
Каршы алып, озатып калып кулын болгар.

## Замана

Бер мизгелдә, күтмәгәндә, үпкәнең бар, замана,
Кайчагында искәрмәстән типкәнең бар, замана.

Күп вакытта танышны дус кылганың бар, замана,
Кайвакытта дусны дошман иткәнең бар, замана.

Татлы хөрмәң, әче тормаң, суганың бар, замана,
Рәхмәт сиңа, хыянәтсез туганым бар, замана.

Рәхмәт сиңа, туганымдай дусларым бар, замана,
Дуслар кадерен белдергән дошманым бар, замана.

Рәхмәт сиңа, бал-ширбәтең гел белеп биргән өчен,
Әче аша төче әйбернең тәмен белдергән өчен.

Рәхмәт сиңа, дусларымны ихлас көлдергән өчен,
Көлү аша һәрберсенең күңелен белдергән өчен.

Рәхмәт сиңа, дөньясына безне тудырган өчен,
Нурын тигез сибә торган кояш булдырган өчен.

Яшәгәндә сыйпый һәм дә кыйный белгәнең өчен,
Туган көнгә дуслар чакырып сыйлый белгәнең өчен.

Һәрвакыт шат, һич картаймас күңел биргәнең өчен,
Барсына да җиткән өчен, замана, бүген көчең!

# ХӘЙРУЛЛА ХӘЗРӘТ ГОСМАНОВ

1847 нче елда Эстәрлетамак өязе Ибрай карьясендә дөньяга килмешдер. Мәчкәрә карьясендә тәхсиле глүм иткәндән соң, Эстәрлетамак шәһәренә имам вә мөдәррис улды. Бунда унбер ел кадәр торгандан соң Уфа мирзаларының дәгъватене кабул итеп 1888 нче елда Уфаның беренче мәхәлләсенә имам; 89 нчы елда губернски ахундлык мөнасибына тәгаен ителде. 1906 нчы ел Ризаэтдин әфәнде казыйлыктан истигъфа иткәч аның урнына Духавнуй собраниедә казый улды. 1907 ел беренче ноябрьдә Уфада вафат булды. Хәйрулла хәзрәт гомер буенча тәгълим вә тәдрис илә шөгыльләнүчеләрнең beредер. Уфа шәһәренә күчкәндән соң олугъ бер мәдрәсә тәэсис итеп берничә муллалар етештерде. Ошбу соң елларда кызларга махсус бер мәдрәсә тәэсис итеп үзе идарә итте. Асыл шөһрәте дә, ошбу гүзәл эшләре сәбәбледер. Милләтемезнең тәрәккыйсе русча белүчеләремезнең күбәюенә мәрбут идекене белдекендән угылларыны гимназияләргә бирде. Хәйрулла хәзрәт мәктәп вә мәдрәсәләрнең ислахына олугъ хезмәтләре күрелгән дүртбиш мөдәрриснең beредер. Язган әсәрләре: Әл-һилал, Тәрҗемәи ысулы фикъһе, Интихабдыр, бундан башка мәдрәсәләремез өчен зарур берничә яңа әсәрләр мәрхүмнең иҗтиһады илә нәшер ителде. Иң гүзәл тәэлифләрендән Мисырда бастырган гарәпчә гыйльме тәүхидкә даир Сәблис-сәлам исемле рисаләседер.

*Заман календаре. 1909 ел өчен. —Казан. 1908. 35 б.*

**И с к ә р м ә л ә р:** Хәйрулла Госманов (Госмани) (1847—1907) — татар мәгърифәтчесе, Уфадагы күренекле «Госмания» мәдрәсәсе мөдире һәм мөдәррисе, мәктәп дәреслекләре авторы. Карья — авыл; тәхсил глүм — гыйлем, белем алу; дәгъват — чакыру; монасиб — яраклы, яраклылык; Ризаэтдин әфәнде — күренекле татар галиме, язучы, тарихчы, мәгърифәтче, журналист һәм дин эшлеклесе Ризаэтдин Фәхретдин (1859—1936). истигъфа — хезмәттән азат ителү, эштән чыгу; Духавнуй собрание — Диния нәзарәте; казый — дини хаким, судья; тәгълим вә тәдрис — укыту, белем бирү; тәэсис — төзү, оештыру; тәрәккый — алга китеш, үсеш, прогресс; мәрбут — бәйле; ислах — үзгәртү, реформа; «Әл-һилал» — Х. Госмановның 1893-94 елларда Казанда ике тапкыр басылып чыккан һәм күк җисемнәреннән Айның хәрәкәтенә нигезләнгән вакыт исәпләү системасы турында татарча китап; фикъһе — ислам дине хокукы фәне; интихаб — сайлау, аралап алу; иҗтиһад — тырышлык; тәэлиф — җыйнау, төзү, китап язу; тәүхид — бер генә Аллага ышану; даир — караган; рисалә — кечкенә китап, брошюра.

۱۸۴۷ نچی یلده استه‌رلی طاماق اویه‌زی ابرای قریه-سنده دنیاغه کیلمشدر. مه‌چکه‌ر، قریه‌سنده تحصیل علوم ایتکاندن صوك، استه‌رلی طاماق شهرینه امام و مدرس اولدی. بونده اون بر یل قدر طورغاندن صوك اوفا میرزالرینڭ دعوتینی قبول ایتوب ۱۸۸۸ نچی یلده اوفا-نڭ برنچی محله سینه امام؛ ۸٦ نچی یلده گوبیرنسکی آخو-ندلق منصبینه تعیین ایتلدی. ۱۹۰٦ نچی یل رضاالدین افندی قاضیلتدن استعفا ایتکاچ آنڭ اورنینه دو-خاﯗنوی صابرانیه‌ده قاضی اولدی. ۱۹۰۷ یل برنچی نویه‌برده اوفاده وفات بولدی. حیرالله حضرت عمر بوینچه تعلیم و تدریس ایله شغللنوچیلرنڭ بریدر. اوفا شهرینه کوچکندن صوك الوغ بر مدرسه تأ-سیس ایتوب برنیچه ملالر یتشدردی. اوشبو

صوڭ يللرده قزلرغه مخصوص بر مدرسه تأسيس ايتوب اوزی اداره ايتدی. اصل شهرتی ده، اوشبو گوزل اشلری سببليدر. ملتمزنڭ ترقيسی روسچه بلوچيلرمزنڭ كوبه يووينه مربوط ايديكينی بلدكندن اوغللرينی گيمنازيه لرگه بيردی. حير الله حضرت مكتب ومدرسه لرنڭ اصلاحينه الوغ خدمتلری كورلگان دورت، بيش مدرسنڭ بريدر. يازغان اثرلری: الهلال، ترجمهٔ اصول فقه، انتخاب در، بوندن باشقه مدرسه لرمز اوچون ضرور برنيچه ياڭا اثرلر مرحومنڭ اجتهادی ايله نشر ايتلدی. ايڭ گوزه‌ل تألفلرندن مصرده باصدرغان عربچه علم توحيدكه دائر «سبل السلام» ايسملی رساله‌سيدر.

*Текстны журнал өчен Җәүдәт Миңнуллин һәм Раиф Мәрданов әзерләде.*

## Басыйр Рәфыйковка — 70 яшь



Шагыйрь Басыйр Шаһинур Рәфыйков 1921 елның 10 февралендә Татарстанның Мамадыш шәһәрендә туган. 1931 елда гаиләләре Магнитогорск шәһәренә күчеп китә; ул андагы татар мәктәбен, аннары Троицк шәһәрендә татар-башкорт педагогия техникумын тәмамлый. Бөек Ватан сугышында катнаша. Озак еллар буе Троицк мәктәпләрендә һәм педагогия училищесында укытучы, завуч, директор урынбасары һәм директор булып эшли. Хәзер — пенсиядә, Троицк шәһәрендә яши.
Беренче шигырьләре «Совет әдәбияты» (хәзерге «Казан утлары») журналында Г. Бәшировның кереш сүзе белән 1964 елда басылып чыга. Шуннан соң шигырьләре Татарстан матбугатында һәм күмәк җыентыкларда, тәрҗемәләре исә Чиләбедә русча газеталарда, Көньяк Урал нәшриятында чыккан альманахларда дөнья күрә.

1968 елдан башлап, Татарстан китап нәшриятында Б. Рәфыйковның «Җырым сиңа минем», «Кадерле минутлар», «Туган тупсалар» һ. б. шигырь китаплары басылып чыкты.

Б. Рәфыйков — 1974 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы.

## Рәдиф Гатауллинга — 50 яшь



Рәдиф Кәшфулла улы Гатауллин (Рәдиф Гаташ) 1941 елның 30 мартында Башкортстанның Кушнаренко районы Марс авылында туган. Урта мәктәп тәмамлаганнан соң, Уфадагы Башкорт дәүләт университетының татар һәм рус әдәбиятлары бүлегенә укырга керә. Аннары Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә күчә. 1964 елда университетны тәмамлап, Мөслим районы Үрәзмәт урта мәктәбендә тарих, татар әдәбияты укыта. 1967-69 елларда Мәскәүдә СССР Язучылар берлеге каршындагы курсларда укый, аннары Татарстан китап нәшриятында, «Ялкын» журналында бүлек редакторы булып эшли. 1975 елдан башлап — «Казан утлары» журналында поэзия бүлеге редакторы.

1966 елда «Гөлләр су сорый» дигән беренче китабы басылып чыкты. Хәзер ул — танылган шагыйрь, татар, рус телләрендә дөнья күргән унбишләп шигырь китабы авторы. Аерым шигырь бәйләмнәре исә поляк, украин, әзербайҗан, казакъ, башкорт, литва, осетин һ. б. телләрдә газета-журналларда, күмәк җыентыкларда дөнья күрде.

1982 елда аңа Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре дигән мактаулы исем бирелде.

Р. Гатауллин — 1966 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы.

## Фоат Садриевка — 50 яшь



Фоат Миңлеәхмәт улы Садриев 1941 елның 10 мартында Татарстанның Мөслим районы Олы Чакмак авылында туа. Күрше авылда урта мәктәп тәмамлаганнан соң, кибетче, китапханәче булып эшли. Сарман һәм Мөслим район гәзитләре редакциясендә әдәби хезмәткәрдән редакторга кадәр хезмәт юлы уза. Шул дәвердә читтән торып КДУның филология факультетында белем ала, 1981—82 елларда исә Мәскәүдә югары театр курсларында укый.

Ф. Садриев иҗаты сәхнә әсәрләре язудан башлана — 1970 елда «Идел» альманахында аның «Оҗмах ишеге төбендә» исемле беренче комедиясе басылып чыга. 1976 елда Әлмәт татар дәүләт драма театрында «Их сез, егетләр» пьесасы куела. Аның «Ач тәрәзәң», «Кондырлы кодачасы», «Әһем, әһем» дигәчтен», «Тозлы бал» драма һәм комедияләрен тамашачылар аеруча яратып каршы ала. Татарстан китап нәшрияты аның «Ач тәрәзәң» (1986), «Ике икең — ундүрт» (1988), «Шаһзаманов эше» (1989) дигән пьесалар, балалар өчен хикәяләр, повесть һәм хикәяләр җыентыкларын укучыларга тәкъдим итә.

Ф. Садриев туган ягына тугрылык саклаган сирәк татар язучыларының берсе. Ул бүген дә Мөслимдә яши һәм әдәбиятыбызга шул төбәкнең җанлы сулышын, табигатен һәм йолаларын, бай халыкчан телен алып керә, үткен мәсьәләләр күтәрелгән, тормышчан каһарманнар сурәтләнгән сәнгатьчә әсәрләр яза.

Ул — 1981 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы.

## Нурислам Хәсәновка — 50 яшь



Нурислам Габдулла улы Хәсәнов 1941 елның 1 мартында Татарстан җөмһүриятенең Саба районы Шәтке авылында туган. Ул 1959 елда Казанга килә, техник училищеда слесарь-ремонтчы һөнәренә өйрәнә һәм Казан моторлар төзү берләшмәсендә эшли башлый. Хезмәтеннән аерылмыйча авиация техникумын, аннары җиңел промышленность институтын тәмамлый. Моторлар төзү берләшмәсендә озак еллар буена мастер, өлкән мастер, инженер вазифаларын башкара.

Нурислам Хәсәнов башта республика матбугатында шигырь һәм нәсерләрен, очеркларын бастыра. Ә 1982 елда аның беренче хикәяләр җыентыгы — «Энҗеләр балкышы» дөнья күрә. 1985 елда, Казан телестудиясендә редактор булып эшләгән чагында, ул «Бәхилләрме йөрәк?» исемле повестен аерым китап итеп чыгарды. 1988 елда «Язмышың сыналганда...» исемле китабы дөнья күрде.

Нурислам Хәсәнов хәзер Язучылар берлегенең матур әдәбиятны пропагандалау бүлегендә эшли. Ул — 1986 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы.

*Татарстан Язучылар берлеге идарәсе һәм «Казан утлары» журналы редакциясе юбилярларны кайнар котлыйлар, аларга сәламәтлек һәм иҗат уңышлары телиләр!*

## ТАТАР ИҖТИМАГЫЙ ҮЗӘГЕНЕҢ II КОРЫЛТАЕНДА

15—16 февральдә Казанда, Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры бинасында Татар иҗтимагый үзәгенең икенче корылтае (съезды) булып узды. Корылтайда илнең төрле почмакларыннан җыелган 637 делегат һәм 200 дән артык кунак катнашты. Алар арасында Кырым татар азатлык хәрәкәте лидеры Мостафа Җәмил, Диния нәзарәте җитәкчесе мөфти Тәлгат хәзрәт Таҗетдин һ. б. бар иде.

Корылтайны Татар иҗтимагый үзәге рәис-координаторы Г. Фәйзрахманов ачты.

Татар иҗтимагый үзәге идарәсенең эше турындагы докладны ТИҮнең рәис-координаторы, ТССР халык депутаты М. Мөлеков ясады.

Аннары «Иттифак» фиркасе җитәкчеләреннән берсе, Татар иҗтимагый үзәгенең рәис-координаторы Ф. Бәйрәмова чыгышы тыңланды.

Иҗтимагый үзәкнең контроль комиссиясе рәисе Г. Мортазин чыгышында ТССР суверенлыгын тормышка ашыруда хокукый мөмкинлекләрне киңрәк файдалануның кирәклеге әйтелде.

ТИҮнең яңа платформасы турындагы докладны Үзәк рәис-координаторларының берсе Д. Исхаков ясады. Аннан соң мандат комиссиясе рәисе Р. Сафин докладны тыңланды.

Фикер алышуларда Татар иҗтимагый үзәгенең ике корылтай арасында башкарган эшчәнлеге анализланды.

Делегатлар 11 резолюция һәм ике мөрәҗәгать кабул итте. Алар арасында Конституциягә чит төбәкләрдә яшәүче татарларга Татарстан гражданлыгы бирүне дә кертү, татар мәгариф системасын булдыру, барлык татар мәктәпләре һәм классларын Татарстан Мәгариф министрлыгы эшләгән программа нигезендә укыту, җомга көннәрендә радио һәм телевидение буенча 30 минутлык дин тапшырулары оештыру, Татарстан милли банкын төзү, Казан консерваториясенә Салих Сәйдәшев исеме бирү турында ТССР Югары Советына тәкъдим кертү, Бөтенсоюз татар газетасын булдыру һәм башкалар бар.

Корылтай бертавыштан ТИҮне Бөтенсоюз татар иҗтимагый үзәге итеп үзгәртергә дигән карар чыгарды, аның идарә органы — вәкилләр Советына илебезнең барлык төбәкләреннән милләтпәрвәр әшлекләләр сайланды.

Корылтай Татарстан дәүләт, совет һәм җәмәгать эшлеклеләренең актив катнашында үтте. Татарстан ССР Министрлар Советы Рәисенең беренче урынбасары М. Хәсәнов делегатлар күтәргән мәсьәләләр буенча чыгыш ясады, сорауларга җаваплар бирде.

Вәкилләр Советы пленумы эшнең шактый катлаулануын күздә тотып, иҗтимагый үзәктә президент идарәсе кертергә дигән фикергә килде. Демократик сайлау юлы белән Бөтенсоюз Татар иҗтимагый үзәге президенты итеп Казан дәүләт университеты доценты, тарих фәннәре кандидаты Марат Әбдерәсүл улы Мөлеков сайланды.

## АКШ КОНГРЕССЫНА

Татар иҗтимагый үзәгенең II корылтаенда Америка Кушма Штатлары конгрессына бертавыштан мөрәҗәгать кабул ителде. Анда болай диелә.

«Татар халкының гомуммилли демократик хәрәкәтен тәшкил иткән Татар иҗтимагый үзәге безнең туган телебездә тапшыру алып бара торган «Азатлык» радиосының күп еллык игелекле эшчәнлеге өчен Сезгә рәхмәт белдерә. Кыска дулкында эшли торган бу радиостанция Европа һәм Азиянең гаять зур киңлекләрендә сибелеп яшәгән сигез миллионлы татар һәм башкорт халыкларына ана телләрендә радио тыңларга мөмкинлек тудыра. Күп еллар дәвамында «Азатлык» радиосы безнең халыкка кирәкле хәбәрләрне җиткереп тора, аның мәдәниятен, әдәбиятын, сәнгатен пропагандалый. Киләчәктә «Америка тавышын» да татар телендә ишетербез, дип ышанабыз».

## «ВАТАН» ҖӘМГЫЯТЕНДӘ

26 февральдә Казанда «Ватан» җәмгыяте советының киңәйтелгән җыелышы үткәрелде.

Җыелышны җәмгыятьнең президенты академик М. Мәхмүтов ачып җибәрде. Вице-президент Д. Гыйсметдинов оешманың бер ел эчендә чит илләрдә яшәгән татарлар белән урнаштырган элемтәләре, алып барган эшчәнлеге турында киң мәгълүмат бирде.

Киләчәктәге эшләрне оештыру һәм уставка кертелгән үзгәрешләр турында Римзил Вәли чыгыш ясады.

Киңәйтелгән совет компетентлы шәхесләр, фән эшлеклеләре һәм язучылардан 60 лап кешене берләштерә. Җыелышта оешманың уставына кайбер үзгәрешләр кертелде, мөстәкыйль Татарстан декларациясенә туры килмәгәнлектән, Россия Конституциясе, Россия кебек сүзләр төшерелде.

Уставка тышкы экономик эшләр белән шөгыльләнү хокукы турында үзгәрешләр кертелде. Оештыру комиссиясе, тышкы экономик мәсьәләләр, фән, дин һәм эмиграция тарихы буенча комиссияләр, Америка Кушма Штатларында, Көнбатыш Европа, Финляндиядә яшәүче татарлар белән элемтәләр алып барачак аерым комиссияләр төзелде.

## РӘСМИ ЯКТАН ТЕРКӘЛДЕЛӘР

Февраль аенда Татарстан ССР Министрлар Советы карары белән яңа оешмалар — «Суверенитет» һәм «Мирас» рәсми яктан теркәлделәр.

**«Суверенитет»**

Билгеле булганча, халыкның үз ихтыяры белән барлыкка килгән бу сәяси оешма Татарстан Республикасын тулыканлы мөстәкыйль дәүләт итү, халыкның тормыш хәлен яхшырту өчен көрәшә һәм үз эшчәнлеген республика территориясендә алып бара.

«Суверенитет» комитеты милли, дәүләт суверенитеты турындагы халыкара-хокукый нормаларны хөрмәт итә һәм Татарстан халкының да үзбилгеләнү хокукы булырга тиеш, дигән мөһим принципны үзәккә куя. Яңа хәрәкәт тарафдарлары эшне комитетның уставы һәм программасы, координация советы планы нигезендә оештыралар.

**«Мирас»**

Бу оешма мәдәни мирасның хәзерге иҗтимагый-сәяси тормышта роле үсә барган шартларда төзелде. Бер яктан, әлеге мирас халкыбызның милли үзаңын үстерүдә, аны берләштерүдә мөһим чарага әверелә. Икенче яктан, ул татар халкының үткәне турында гасырлар дәвамында рәсми пропаганда тарафыннан таратылып киленгән тенденциоз һәм хәтта яла ягучан карашларны кире кагып, аның иҗтимагый-рухи яшәеше турында чын дөреслекне торгызуга булышып, хәзерге милләтара мөнәсәбәтләрне камилләштерүгә хезмәт итәчәк.

## «ТАТФИЛЬМ» БУЛАЧАК!

Татарстан Министрлар Советы милли киностудия оештыру турында карар кабул итте. Казан кинохроника студиясе кинофабрика һәм нәфис фильмнар студиясе итеп үзгәртеп корылачак. Павильоннар төзү өчен чыгымнарны ТССР Финанс министрлыгы бүлеп бирәчәк. Тәүге фильмнарны 1992 елда чыгару күздә тотыла.

## ЯЗУЧЫЛАРЫБЫЗ ТӨРКИЯДӘ

Январь аенда Татарстан Язучылар берлеге рәисе Р. Мөхәммәдиев, «Иттифак» партиясе рәисе, язучы Ф. Бәйрәмова «Төрки-Ислам берлеге» чакыруы буенча Төркиядә булып кайттылар. Депутат язучыларыбыз бу илнең байтак шәһәр-авылларында булып күп кенә рәсми очрашуларда катнаштылар. Шулай ук, Татарстан — Төркия мөнәсәбәтләрен ныгыту юнәлешендә, эшлекле сөйләшүләр алып бардылар, килешүләр төзеделәр. Сәяхәттән кайткач, алар Язучылар берлеге клубында каләмдәшләре белән очраштылар, тәэсирләр, уй-фикерләр белән уртаклаштылар.

## КАРДӘШЛӘРЕБЕЗГӘ ТЕЛӘКТӘШЛЕК

Моннан илле елга якын элек мәсхәрәле рәвештә Туган илләреннән куылган кырым татарларының язмышы гаять аянычк. Соңгы елларда күп авырлык, мең михнәт белән бу халыкның бер өлеше — 100 меңләбе туган туфрагына кайтып егылды. Әмма туган җирдә янәдән тамыр җибәрү процессы гаять авыр булып чыкты. Кырымның бүгенге хакимияте кырым татарларына җир бирми, торак, эш белән тәэмин итми, социаль яктан кыерсыта, геноцид сәясәтен дәвам итә...

Кардәшләребезнең шушы авыр хәлен искә алып, мораль һәм беркадәр матди ярдәм итү йөзеннән, Мәрҗани җәмгыяте президенты Зәки Зәйнуллин һәм язучы, җәмәгать эшлеклесе Роберт Батулла Казан татар халкына мөрәҗәгать иттеләр. Берничә көн эчендә байтак кием-салым, юрган-мендәр, хуҗалык өчен башка кирәк-яраклар җыелды. Декабрь һәм январь аенда бу мөхтәрәм иптәшләребез халыктан җыелган әйберләрне ике КамАЗ машинасына төяп Кырымга илтеп тә куйдылар. Бу мәрхәмәтле эш өчен Кырым татар милли хәрәкәтенең җитәкчесе Мостафа Җәмил безнең язучыларга, алар аша бөтен татар халкына ихлас рәхмәтен белдерде.

## БҮЛӘК ЯҢАДАН БИРЕЛӘ БАШЛАДЫ

Моннан 10 еллар элек күренекле татар әдибе Ш. Маннур васияте белән яшь язучыларга һәм Мамадыш районының «Чулпан» колхозы алдынгыларына аның исемендәге еллык премия бирелә башлаган иде.

Аңа язучылардан Зөлфәт, М. Галиев, Р. Мөхәммәдиев, Н. Гыйматдинова, С. Манналов һәм Г. Сәгыйров лаек булган иде. Шуннан соң әлеге традиция беркадәр вакытка өзелеп торды.

Быел «Чулпан» колхозы идарәсе рәисе Р. Гыйззәтуллин инициативасы белән ул яңартылды.

Бу юлы бүләк яшь язучылардан З. Хөснияр, Мамадыш егете Р. Газизов һәм колхоз уңганнарына бирелде.

Январь аенда Ш. Маннурның туган ягы Мамадышка барган язучылар И. Юзеев, Р. Фәйзуллин, публицист Ш. Мостафин һәм яңа лауреатлар район хезмәтчәннәре белән очраштылар.

## ҮЗ ИХТЫЯРЛАРЫ БЕЛӘН

КПСС әгъзалыгыннан баш тарту безнең бүгенге җәмгыятебез өчен яңа нәрсә түгел. Фирка сафларыннан чыгаруны сорап башлангыч партия оешмасына түбәндәге язучылар мөрәҗәгать итте: М. Галиев, Мансур Вәлиев, Р. Хәмид, Н. Гыйматдинова, Ә. Мушинский, М. Насыйбуллин, Г. Паушкин, Р. Корбанов, Ф. Латыйфи, Д. Вәлиев, А. Бадюгина, Л. Кожевников, М. Шабаев, Р. Гатауллин, М. Хәбибуллин, К. Тимбикова, М. Маликова. Язучыларның партия оешмасы аларның гаризаларын канәгатьләндерде.

## ИҖАТ КИЧӘЛӘРЕ

21 февральдә Актерлар йортында шагыйрь Ркаил Зәйдулланың иҗат кичәсе булды.

Шигырь кичәсендә шагыйрьне котларга килгән өлкән каләмдәшләре һәм дуслары Р. Фәйзуллин, Г. Морат, Л. Зөлкарнәй, рәссамнар Э. Зарипов белән Ф. Фәсхетдин, артистка З. Зарипова, җырчы-композитор З. Хәким чыгыш ясадылар. Кичәне шагыйрь Р. Гатауллин алып барды.

Мәгълүм булганча, В. И. Ленин Үзәк музееның Казан филиалында моңа кадәр гадәттә җитди җыелышлар, киңәшмәләр һәм рәсми очрашулар гына була иде. Хәзер филиал үз ишекләрен сатирик язучыларга да ачты. Күптән түгел генә биредә Фәнзаман Батталның иҗат кичәсе булып үтте. Язучының әсәрләрен танылган артистларыбыз Равил Шәрәфиев һәм Хәлим Җәләлов укыдылар. Сатира-юмор сөючеләр белән автор арасында сөйләшү кызыклы һәм мәгънәле булды.

22 февральдә шул ук бинада шагыйрь Ә. Рәшитов һәм язучы М. Маликова әдәбият сөючеләр белән очрашу уздырдылар. Сүз бүгенге сәясәт, әдәбият-сәнгать проблемалары турында барды. Кичәнең икенче өлешендә сәнгать осталары чыгыш ясады.

## ЯҢА БАСМАЛАР

«Милләт». Инде ике саны дөнья күргән Татар иҗтимагый үзәге газетасының исеме бу. Яңа газета үз алдына нинди максатлар куя соң? Моңа җавапны 1 санда басылган мәкаләдән табып була. Анда болай диелгән: «Татар иҗтимагый үзәгенең төп максаты — ирекле татар иле — мөстәкыйль җөмһүрият төзү... Газета аңа милли үзаңны үстерер, горурлыгын уятыр, уяулыкка, бердәмлеккә, көрәшкә туплау өчен кирәк». Газета 10 мең данә белән басылган. Мөхәррире Фәния Хуҗиәхмәт.

1991 елның башыннан Башкортстанда татар телендә «Вакыт» исемле газета чыга башлады. Иҗтимагый, сәяси, әдәби бу басманың нашире һәм мөхәррире Равил Карамов. Шушы елның 1 апреленнән бу газетаны яздырып алып булачак. Ел азагына тикле барлыгы 25 сан чыгару күздә тотыла. Төкле аягың белән, «Вакыт»! Халык рухын баетуда һәм аңа файда китерүдә өлешең революциягә кадәр чыккан мәшһүр «Вакыт»ка тиң булсын!

Алабугада Кама ягы татар яшьләренең «Ислах» (Яңарыш) исемле газетасы чыга башлады. Атналык бу газета 8 биттән тора. Аның беренче саны оста кулы белән бизәлеп, кызыклы, уйландыра торган, танып-белүгә булышлык итәрдәй язмалар белән чыгарылган. Мөхәррире — Радик Әмин. Редакциянең адресы: 423630, Татарстан республикасы, Алабуга шәһәре, 51 йорт.

## ЯҢА КИТАПЛАР

Әле күптән түгел генә Япониядә М. Солтангалиев турында яңа китап чыкты. Япон телендә чыккан бу китап «Солтангалиевнең хыялы: ислам галәме һәм Россия революциясе» дип атала. 383 биттән торган бу монографиянең авторы Токио университеты профессоры Масаюки Юмачи. Укучыларыбызга шуны да искәртеп узыйк, элегрәк елларда Солтангалиев турында гарәп телендә роман язылып, Алжирда басылып чыккан иде инде.

1990 ел ахырында Төркиядә «Оренбур шәле» исемле роман басылды. Китапның авторы — Хакан Улу. Чыгышы белән татар кешесе. Китапта Идел-Урал һәм Кырым татарларының тормышы тасвирлана.

Татарстан үзенең Дәүләт суверенитетын игълан иткәч, безнең язучыларга Россиянең «Современник», «Советская Россия» нәшриятларында китап чыгару, табигый, кыенлашачак. Шуңа күрә «Художественная литература», «Советский писатель», «Молодая гвардия», «Детская литература», «Дружба народов» кебек Бөтенсоюз нәшриятына мөрәҗәгать итү кирәк булачак. Дөрес, бу нәшриятларда да әсәрләр чыккалап тора. Әле күптән түгел генә илнең төп әдәби басмаханәсе саналган «Художественная литература» нәшриятында Муса Җәлилнең «Сайланма шигырьләре» һәм Равил Фәйзуллинның «Лунные тополя» исемле бер томлык шигырь китабы дөнья күрде. Андый китаплар күбрәк чыгуын теләргә кала.

## *Тышлыктагы сурәтләр*

**Тышлыкның икенче битендә**: Татарстанның архитектура истәлекләреннән. Зәй районының Әхмәт авылында таш мәчет.

**Рөстәм МӨХӘММӘТҖАН** фотосы.

**Тышлыкның дүртенче битендә**: күренекле шагыйрь Әхмәт Исхак.

**Юрий ФИЛИМОНОВ** фотосы.

# *Китаплар дөньясында*

Татарстан китап нәшрияты былтыр түбәндәге китапларны бастырып чыгарды:

**Шәехзадә БАБИЧ.** Зәңгәр җырлар. *Шигырьләр, поэмалар, эпиграммалар, мәкаләләр, хатлар.* 544 бит, портрет белән. Б. 2 с. 20 т.

**Гомәр БӘШИРОВ.** И язмыш, язмыш. *Повестьлар.* 479 бит, портреты белән. Б. 1 с. 80 т.

**БАТУЛЛА.** Юл буенда зәңгәр чәчәк. *Повесть.* 352 бит. Б. 1 с. 40 т.

**Фәнзаман БАТТАЛ.** Сакалыңа ут капса. *Көлкеле һәм сатирик хикәяләр.* 96 бит. Б. 25 т.

**Әхсән БАЯН.** Аргы яр. *Повестьлар.* 320 бит. Б. 1 с. 30 т.

Бәхетлеме икән ул? Эстон хикәяләре. 192 бит, портретлар белән. Б. 1 с.

**Рәшит БӘШӘРОВ.** Ай кызының зәңгәр чиләге. *Балалар өчен шигырьләр.* 96 бит. Б. 15 т.

**Рәшит БӘШӘРОВ.** Иртәгә дә яшисе бар. *Повесть.* 109 бит. Б. 20 т.

**Резеда ВӘЛИЕВА.** Ялгыз аккош. *Балалар өчен шигырьләр, поэмалар, әкиятләр.* 224 бит. Б. 60 т.

**Рафаил ГАЗИЗОВ.** Чөгендер хикмәтләре. *Балалар өчен шигырьләр.* 32 бит, рәсемнәр белән. Б. 10 т.

**Нур ГАЙСИН.** Таза Мортаза. *Балалар өчен рәсемле поэма.* 24 бит. Б. 15 т.

**Шәүкәт ГАЛИЕВ.** Дөресен әйткәндә. *Шигырьләр.* 160 бит. Б. 40 т.

**Фирдәүс ГАРИПОВА.** Борынгы Болгар шәһәрләре. 77 бит. Б. 15 т.

**Флера ГЫЙЗЗӘТУЛЛИНА.** Сер ачкычым сердәштә. *Шигырьләр.* 176 бит. Б. 60 т.

**Җәүдәт ДӘРЗАМАН.** Безнең әлифба. *Шигырьләр.* 16 бит, рәсемнәр белән. Б. 15 т.

**Нәби ДӘҮЛИ.** Яшәү белән үлем арасында. *Повесть.* Җимерелгән бастион. *Роман.* 446 бит, портрет белән. Б. 1 с. 90 т.

**Рәшит ИБРАҺИМОВ.** Ерак илләргә сәяхәт. 144 бит. Б. 50 т.

**Нәкый ИСӘНБӘТ.** Әсәрләр. 3 том. *Комедияләр.* 432 бит. Б. 2 с. 4 том. *Пьесалар.* 392 бит. Б. 2 с. 20 т.

**Шәриф КАМАЛ.** Бәхет эзләгәндә. *Хикәяләр, повесть.* «Мәктәп китапханәсе» сериясеннән. 160 бит. Б. 30 т.

**Барлас КАМАЛОВ.** Язмыш сәхифәләре. *Роман һәм повестьлар.* 464 бит. Б. 2 с. 10т.

**Эдуард КАСЫЙМОВ.** Гомер ике килми. *Роман һәм хикәяләр.* 352 бит. Б. 1 с. 70 т.

**Камил КӘРИМОВ.** Күләгәдә төлке бар. *Повестьлар, хикәяләр.* 224 бит, портрет белән Б. 75 т.

**Ләбиб ЛЕРОН.** Күрше тавыгы. *Эпиграммалар, пародияләр.* 120 бит. Б. 30 т.

**Мәхмүт МАКСУД.** Яз җыры. *Хикәяләр, нәсерләр, истәлекләр һәм очерклар.* 128 бит. Б. 25 т.

**Шамил МАННАПОВ.** Җиргә сыенам. *Шигырьләр.* 160 бит. Б. 65 т.

**Роберт МИҢНУЛЛИН.** Сандугачның туган көне. *Шигырьләр.* 192 бит. Б. 80 т.

**Роберт МИҢНУЛЛИН.** Энекәш кирәк миңа. *Балалар өчен шигырьләр.* 16 бит, рәсемнәр белән. Б. 25 т.

**Рафаэль МОСТАФИН.** Кабан күле серләре. 144 бит. Б. 35 т.

**Сафуан МУЛЛАГАЛИЕВ.** Мәңгелек йөрәк. *Шигырьләр һәм поэма.* 80 бит. Б. 15 т.

**Ринат МӨХӘММӘДИЕВ.** Кенәри — читлек кошы. *Роман.* 448 бит. Б. 1 с. 80 т.

**Рашат НИЗАМИЕВ.** Фәрит Яруллин (Язмыштан көчлерәк). *Роман.* «Атаклы кешеләр тормышы» сериясеннән. 266 бит, рәсемнәр белән. Б. 75 т.

**Һади ТАКТАШ.** Тәүфикълы песи. *Шигырь.* 12 бит, рәсемнәр белән. Б. 25 т.

**Кояш ТИМБИКОВА.** Тын бакчада. *Повестьлар һәм хикәяләр.* 256 бит. Б. 90 т.

**Габдулла ТУКАЙ.** Исемдә калганнар. 32 бит, рәсемнәр белән. Б. 10 т.

**Хәсән ТУФАН.** Гүзәл гамь. *Моңарчы басылмаган шигырьләре.* 304 бит. Б. 1 с. 30 т.

**Җәвад ТӘРҖЕМАНОВ.** Очрашулар, очрашулар. *Хикәяләр, очерклар, юлъязмалар.* 368 бит. Б. 1 с. 80 т.

**Әхмәт ФӘЙЗИ.** Аучы Мәргән белән Болан кыз әкияте. 80 бит, рәсемнәр белән. Б. 20 т.

**Мәгъфүр ХАННАНОВ.** Хәвефле юлда. *Повесть.* 144 бит. Б. 30 т.

**Альберт ХӘСӘНОВ.** Кемгә сөйлим серләремне. *Повестьлар һәм хикәяләр.* 254 бит. Б. 90 т.

**Эльмира ШӘРИФУЛЛИНА.** Җитәкләшеп җил белән. *Шигырьләр.* 46 бит, рәсемнәр белән. Б. 10 т.

**Азат ӘХМӘДУЛЛИН.** Әдәбият белеме сүзлеге. 240 бит. Б. 1 с. 10 т.

**Роберт ӘХМӘТҖАНОВ.** Җәяүле күбәләк. *Шигырьләр, балладалар, поэмалар.* «Шигырь китапханәсе» сериясеннән. 416 бит. Б. 1 с. 60 т.

Якындагы кибеттә булмаса, бу китапларны почта аша сорап алдырырга мөмкин. Адреслар: **420057, Казан шәһәре, Октябрьская урамы, 18.** «Китап-почта» кибете. **420084, Казан шәһәре, Бауман урамы, 19. 1 китап кибете,** «Китап-почта» бүлеге.

Бәясе 1 сум 50 тиен. Индекс 73210



**КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)**

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРСТАНА
(на татарском языке)